ISSN 0206-4189

# Казан утлары

1.2004





**Фәрит Яруллин**
**1914–1943**

# Казан утлары
# Qazan utları

2004

# 1

(975)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*редакциянең хезмәт коллективы*


*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Фоат Галимуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Диләрә Максутова, Флера Сабирова,Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**



420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Баш мөхәррир — 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 92-36-49.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 92-38-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 92-39-63,
гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 92-93-16.
**Факс** — (8432) 43-56-12.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## *Бу санда*

### БАШ МӨХӘРРИР СҮЗЕ

Равил ФӘЙЗУЛЛИН.....5

### ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Роберт ӘХМӘТҖАН. Уйлана табигать... *Шигырьләр*.....12
Рауль МИРХӘЙДӘРОВ. Карга короле. *Роман*.....17
Рашат НИЗАМИ. Тормыш фасыллары кайнамакта. *Шигырьләр*.....86
Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ. Кылдан нәзек, кылычтан үткен. *Роман*.....90
Илдус ГЫЙЛӘҖЕВ. Горурлыгын югалтмаган җаным. *Шигырьләр*.....130
Әхәт ГАФФАР. *Хикәяләр*.....134
Рәмзия ГАБДЕЛХАКОВА. Күзгә яшен. *Шигырьләр*.....146

### ФАКИЛ САФИНГА 50 ЯШЬ

Фоат САДРИЕВ. Йолдыз нуры.....148
Факил ӘМӘК. Гөлләрем, сиреньнәрем. *Хикәя*.....151

### ПУБЛИЦИСТИКА

Әгъдәс БОРҺАНОВ. Мәүлә Колый каны.....158

### ДИСКУССИЯ: "БЕЗНЕҢ ЗАМАН ГЕРОЕ"

Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ. Киләме, күрәбезме?.....161

### ФӘН

Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге.....168

### КОРЪӘН ТАТАР ТЕЛЕНДӘ

65–Талак (Талак) сүрәсе.....174
66–Тәхрим (Харам) сүрәсе.....175
67–Мөлек (Падишалык) сүрәсе.....176

### КИТАП КҮЗӘТҮ

Нурфия ГАФИЯТУЛЛИНА. Хәтер сызлануы.....177

Безнең календарь.....182
"Казан утлары" архивыннан.....186
Берлекнең яңа әгъзалары.....188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан.....189

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

Вступительное слово главного редактора Р. ФАЙЗУЛЛИНА.
"Проза и поэзия": роман Р. МИР-ХАЙДАРОВА "Масть пики" (начало); роман А.ГИЛЯЗОВА "Тоньше струны, острее меча" (начало); рассказы А. ГАФФАРА; стихи Роб. АХМЕТЗЯНА, Р. НИЗАМИ, И. ГИЛЯЗОВА, Р. ГАБДУЛХАКОВОЙ.
"К 50-летию Ф. Сафина": статья Ф. САДРИЕВА "Свет звезды"; рассказ Ф. САФИНА "Цветы мои, сирени мои".
"Публицистика": А. БУРГАНОВ. "Род М. Кулый".
"Дискуссия: "Герой нашего времени": статья Р. ШАРАФИЕВА о героях современной татарской прозы.
"Наука": А. ТИМЕРГАЛИН. "Словарь нации".
Коран на татарском языке.
"Книжное обозрение": Н. ГАФИЯТУЛЛИНА рецензирует книгу З. Мансурова "Теплее греет раненое сердце".
В номере отмечаются 130-летие поэтессы М. Музафарии и 80-летие писателя Р. Тухфатуллина.
Новые члены союза писателей.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: картина из жизни древних тюрков; поэт Гусман Садэ.

## IN THIS ISSUE:

*The magazin edits monthly*

Opening address by editor-in-chief R.FAJZULLIN.
"Prose and poetry": novel by R.MIR-HAJDAROV "Spades" (beginning); novel by A.GILJAZOV "Thiner than a string, sharper than a sword" (beginning); stories by A.GAFFAR; verses by Rob. AKHMETZYAN, R.NIZAMI, I.GILJAZOVA, R.GABDULHAKOVA.
"To F.Safin"s 50-anniversary": article by F.SADRIEV "Light of a star"; F.SAFIN'S story "My Flowers, my lilacs".
"Publicism": A.BURGANOV. "Kin of M.Kuly".
"Discussion: "Hero of our time" article by R.SHARAFIEV about heroes of modern Tatar prose.
"Science": A.TIMERGALIN. "The dictionary of nation".
Al Quran in Tatar language.
"Book"s review": N.GAFIJATULLINA reviews Z.Mansurov's book "Wounded heart warms more".
In the issue the 130-anniversary of poetess M.Muzafaria and the 80-anniversary of writer R.Tukhfatullin are marked.
New members of the union of writers.
From photoarchive of the magazine.
Diary of public - cultural life.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән китерелгән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 19-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 25.12.2003 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 7031. Заказ Я—860
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2004 ел.

*Баш мөхәррир сүзе*

# ЙӘ, НИШЛИБЕЗ, ГАЗИЗ КАЛӘМЕМ?

Йомшак кар явып үткән. Тирә-юнь ап-ак, шундый тын, чиста, пакь... Өстәвенә, сихри яктырып ак каеннар тезелеп киткән... Бу аклыкны күнелләргә генә күчерәсе! Авыл өемнең тәрәзәсеннән караганда әнә шундый идиллик манзара. Яшәешнең шушы мәлендә, Табигатьнең җанлы бер күзәнәге буларак, аклык эчендә рәхәтләнәсе, талгын гына тибрәнәсе, хәтта эреп югаласы килә... Аннарысы янәдән тереләсең, сабый бала күзләре белән тирә-юньгә карыйсың. Ә Дөнья шундый гүзәл, Яшәү—шундый бәхет! Тик баштагы уйлар гына менә...

...Янә берәү үз-үзен (камикадзе диләрме әле?) шартлаткан. Соңгы чиккә җитеп, якты Кояш белән хушлашкан. Кемдер аны террорист-бандит ди, кемдер шәһит-патриот саный... Вәгъдәләр ярминкәсе—сайлаулар үтте. Алда—яңалары... Аларга киткән чыгымнарны фәкыйрьләргә тотсаң, тормыш бераз яхшырыр иде... Нәни улымның иртән балалар бакчасына барасы килми, киреләнә, күрәсең, "шәхес иреге" кысыладыр. Ә халыкларныкы?.. Нишләптер Страсбург мәхкәмәсе искә төште... Рәссам Әхсән Фәтхетдиновнең альбомын Шүрәлеләрнең үзләренә дә күрсәтәсе иде, нишләрләр икән?.. Котыплар ел саен әкренләп җылына бара, имеш. Нух пәйгамбәр көймәләре кирәк булмагае... Сәйдәшнең бик матур һәйкәлен күрдем. Төштә. Ә чыны Высоцкийныкы булып чыкты. (Хәер, бу арада, хәтта бер ай эчендә тагын һәйкәлләр куелды әле: "Бакыр бабай"—Державин торгызылды, Әгерҗедә Тажи Гыйззәт бюсты куелды, Кремль эчендә татар-рус осталары истәлегенә сыннар калыкты... Афәрин, хәрәбәләр түгел, сыннар калка, тынычлык-иминлек, хәтерлелек билгесе бит!)... Борынгы Багдадны янәдән утка тотканнар (моннан мең еллар элек безнең якларга ислам динен юллаган шәһәр!). Бу Америка дигәннәре кайчак теләсә кемне тукмап китә торган яшь, таза, кансыз урам бандитын хәтерләтә... Казаныбызның мең еллыгы да җитеп килә. Ә бәйрәмгә кадәр башкарасы эшләр бихисап икән!..

Тышта ап-ак кар. Өстәлемдә ап-ак кәгазь. Кеше гомеренең сабый чагы кебек чип-чиста. Йә, синең ярдәм белән, Каләмем, ниләр төшәр икән бу ак кәгазьгә. Хәер, каләм изгегә тартыр, диләрме әле, вөҗданы булган әдип җанның кешеләр күңеленә ниләр түгәсе мәгълүм инде. Гуманист булу, халкыңның асыл сыйфатларын үстерешеп, гомумкешелеккә хезмәт итү, киләчәк буыннар язмышы өчен җаваплылык тою, үз чорыңның һәм халкыңның игелекле баласы булу... Мөмкин эшме бу? Әдәбиятның алтын гасырлары үтте түгелме? Үзен алыштырырлык роботлар ясаган, алай гына түгел, клонлаштырып, теләгән җан иясен укмаштырыр сәләткә ия XXI гасыр затлары өчен эмоциональ әдәби сүз, образлы сурәт кирәкме? Җәмгыятьтә әдәбиятка ихтыяҗ бармы? Ак кәгазьдәге язу буразналарын без дөрес сөрәбезме, Каләмем? Моннан йөз еллар элек тикмәгә генә әйтмәгәндер бит шагыйрь: "шигырь бүтән дә, дөньяны әйләндерә торган чыгыр бүтән!" Гомумән, гуманлы әхлак хасмы бу заманга? Чыннан да, Акча кодрәте белән Дөнья чыгырын әйләндерүче идарә көчләр (алары да күктән төшмәгән, шул бер камырдан әвәләнгән адәмнәр ләбаса!) Кешелек дөньясы монарчы тудырган хикмәтле китаплардан, аларда тупланган акылдан гыйбарәт-сабак алсалар, ахырзаман галәмәтләренә охшаш вәхшилекләр, сугышлар, геноцидлар, янау-талаулар, җәбер-золымнар, ашкынып коралланулар шаһите булыр идекме? Әй, наив җан! дияр кемдер,—"Каргалар шигырь укыса, күгәрчен булыр иде!"

Шулай да, оптимист буласы килә. Эчке тоемым белән әдәбиятыбызның киләчәгенә өмет белән карыйм, аның үзенә йөкләнгән тарихи миссиясен югалтмаячагына ышанам. Әлбәттә, нинди генә көчле әдәбият булмасын, ул барыбер замана басымына дучар. Тамыры булмаган әдәбият юкка да чыгарга мөмкин. Зур традицияләргә,

бай мираска ия булганнары тиз генә югала алмый. Элегрәк Җир шарының алтыдан бере дип исәпләнгән киңлекләрдә әдәбиятыбыз иң борынгылардан исәпләнә. Китап рухы—безнең генналарда. Әдәби сүз культурасы бүген дә югары дип исәплим мин. Әйтик, "әдәбият әнкәсе" саналган шигърияттебез дөньядагы теләсә кайсы халык шигърияте белән ярышырлык хәлдә. Проза яки драматургия жанрларында да югары сәнгать әсәрләре җитәрлек... Киләчәк турында уйланганда, иң кирәк төп сорау туа: бармы бездә бүген талантлы язучылар? Иҗади учаклар дөрлиме? Аңлашыла торган табигый сорау. Кистереп, "бар!" дип әйтер идем. Шөкер, әдәбиятыбызның горурлыгы саналырлык дистәләгән менә дигән язучылар, шагыйрьләр, драматурглар бар (Дөрес, гасыр алышынган елларда байтак мөгътәбәр әдипләребезне югалттык. Ә. Еники, Г. Бәширов, М. Мәһдиев, Г. Ахунов, А. Гыйләҗев, Т. Әйди, Ш. Хөсәенов, Г. Афзал... Алар белән тулы бер чор, кабатланмас дөнья китте! Һәрчак сагындырачак шәхесләр!) Исемнәр атау гаять четерекле, үпкә-сапкага сәбәп хәл булса да, әйтелгән сүземә дәлил итеп, бүген исән-имин иҗат итүче кайбер каләмдәшләрем турында искәртеп китәм. Туфан Миңнуллин. Ул—бүгенге көннең иң абруйлы аксакалларның берсе. Хезмәте зур, иманы нык, холкы гаярь, дәрәҗәсе югары. Ә Нурихан Фәттах? Үткән әдәбиятыбызда мондый тарихчы әдип булдымы икән әле? Илдар Юзеев. Берничә буын шигырь сөючеләрнең Такташ кебек кумиры булып кара әле! Без Фәнис Яруллинлы әдәбият дип горурланып әйтә алабыз. Хезмәте белән кеше рухының бөеклеген раслаган язучы ул... Айдар Хәлим. Мондый публицист белән теләсә кайсы әдәбият горурланыр иде. Кирәксә шигырьне, кирәксә прозаны коеп куя... Күп кырлы иҗаты белән поэзия, җыр, төрле музыкаль жанрлар, гомумән сәнгатьнең байтак төрләрен үстерүгә зур өлеш керткән Ренат Харис... Диңгезен, күгeн иңләп чын ир-егет булып яшәгән, тематик яктан әдәбиятыбызны баеткан Миргазиян Юныс... Иҗатлары белән үз шигъри дөньяларын тудырган, шул дөньяга байтак укучыларын кертә алган, шәхес буларак та үзләре үк бер кызыклы дөнья булган олуг шагыйрьләр Роберт Әхмәтҗанов, Лена Шагыйрьҗан, Мөдәррис Әгъләмов... Шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе сүзләре үзләренә табигый ябышып торган, халык арасында популяр каләмдәшләребез Роберт Миңнуллин, Разил Вәлиев, Гәрәй Рәхим... Иҗаты һәм эшчәнлеге әлегә тулы бәяләнеп җитмәгән, эпик киңлекләрдә тирән сөрә алырлык фәлсәфи шагыйрь, матбугат хадиме Зиннур Мансуров... Кабатланмас стиле, юмор-сарказмы белән алыштыргысыз Марсель Галиев... Тәнкыйтьтә дә, прозада ат уйнатучы олпат галим Тәлгат Галиуллин... Үзләренең публицистикасы белән күпләргә үрнәк булырлык Газинур Морат, Ркаил Зәйдулла. Ә бит алар иң әүвәл кызыклы шагыйрьләр. Икенчесе, өстәвенә менә дигән прозаик та... Шул ук буын вәкиле—Зиннур Хөсняр. Потенциаль мөмкинлеге зур булган прозаик, нәшер эшләрен заманча оештыручы унган мөхәррир... Соңгы елларда әдәбиятта феномен саналырлык Мөслим егетләре төркемен кая куясың. Флүс Латыйфи, Зөлфәт, Фоат Садриев, Харрас Әюпов, Факил Сафин, Наис Гамбәр... Русча язып та, татар мәнфәгатен кайгыртып яшәүче язучыларыбыз—Рафаэль Мостафин, Рауль Мирхәйдәров, Равиль Бохараев, Локман Закиров... Ир-атлар да көнләшерлек иҗат итүче Фәүзия Бәйрәмова, Нәбирә Гыйматдинова, Флера Гыйззәтуллина, Клара Булатова... Бөтен яктан да ил агасы саналырлык, татар тарихы буенча энциклопедик гыйлемгә ия Миркасыйм Госманов. Милләтебезнең уникаль шәхесе Рабит Батулла, Зәки Зәйнуллин. Яшьрәкләрдән—Рамис Аймәт, Луиза Янсуар... Берничә исем белән чикләнермен дигән идем дә, өч дистәдән артык якын исем саналган. Иҗатлары зур булган каләмдәшләребез, шөкер, байтак. Исемлекне тагын дәвам итәргә була. Әйтик, халык шагыйрьләре, халык язучылары исәбенә дә... Югарыда искә алып киткән каләмдәшләр үзләре дә бик төрле, бик катмарлы халык. Арада карашлары, холыклары, иҗат алымнары буенча берсе белән берсе сыеша алмый торганнары бар... Нишлисең, иҗат мәйданы шулай булырга тиештер. Шул төрлелек белән кызыклы һәм көчледер дә әле без. Безгә бергә, бердәм булмый ярамый. Төрекләрдәге мәгълүм сүзне, үзебезчәләтеп болай дибез: татарның татардан башка дусты юк...

Димәк, әле бездә дары бар! Ә укучылар бармы соң? Дары юешләнеп эштән чыкмасын өчен шарт—коры урын, ышык-ныгытма. Учак дөрләсен өчен утын, аның өчен урман кирәк. Язучы өчен Укучы кирәк. Алдында торган килеш, сырхау тәнеңә ризык үтмәсә, Галиябану кебек сылу булып үсеп тә, ярын табылмаса, бөек җыр туып та, аны башкаручы булмаса?.. Сер түгел, ни кызганыч, татар китабын укучылар кими бара (Дөрес, юлын табып, авыруга укол ясаган шикелле, кешеләр күңеленә вакытында "китап вирусы" сала алсаң, күпләр файдасын күреп, рухи савыгып, рәхмәтләрен әйтәчәкләр). Моннан ун еллар элек тикмәгә генә мондый юллар язылмагандыр.

Кичәрләр дип, озак еллар күпер салдым,
Эш беткәндә карап баксам—елгам кипкән...
Нур чәчәм дип, гомер буе җырлар яздым,
Томнар чыккач карыйм: укыр җаннар беткән!

Ни өчен? Чөнки, үз дәүләтең юк. Телебез, декларатив рәвештә дәүләт теле саналса да, асылда, ул үз функциясен үтәми. Телнең иясе—халык, хуҗасы—дәүләт. Нинди имля-графикада язасын да бүтәннәр хәл иткәч, чамалап була... Өстәвенә, йотылу, ассимиляцияләшү процессына интеграция, глобальләштерү кебек замана хикмәтләре килеп кушыла... Социологик анализлар ни күрсәтәдер, белмим, минемчә, элек караңгы дип саналган Россия империясендә—Себердә, Идел буе төбәкләрендә, Азиядә—татарча сөйләүчеләр күбрәк булган. Тел булгач, нигез-тамыр булган, шаулап тормаса да, рухи шытымнар булган. Ә хәзер?..

...Авыр сорау тугач, кәгазь буйлап йөгерек кенә барган Каләм, арган ат кебек, тукталып кала. Мин дә урынымнан торып, йөренеп алам. Тәннәр язылып китә. Янәдән, тыштагы идиллик күренешкә карап торам. Гаҗәп: көч кереп, уй ямтырып китә!

Миллилекне билгели торган кайбер сыйфатлар югалып барса да, гомумән, җир йөзендә татар кимемәде дип уйлыйм. Бетә торган милләт түгел бу! Күбрәк сәясәт уенына корылган, дөрес үк булмаган җан-исәп алу буенча да хәйранга чыга әле ул! Татарны тикмәгә генә яһүдләр белән ярыштырып тиңләмиләр шул. Яһүдләр дигәннән, гыйбрәт-сабак алырлык охшашлыклар да бар бит. Һәр икәве дөнья буйлап сибелгән, байтагы телен җуя баруга дучар ителгән, гасырлар буе геноцид кичергән... Һәм шул яһүдләр, бер көн җыелып (әле бик ерак тарихта түгел, моннан 60-70 ел элек кенә), дәүләт кордылар, югалган дип әйтерлек алфавитларын торгызып, телләрен яңарттылар, бөтен дөньядан җыйган малларын милли байлык итә алдылар. Бу, мөгаен, гомумтарихта чыгарма хәлдер. Ә начар чыгарма мени! Гаҗәп үзенчәлекле тарихи катаклизмнар кичергән татарның, чыгармалымы, чыгармасызмы, нигә үз юлы булмаска тиеш ди әле. Милли идеягә, югары үзаңга, олы максатка, бердәм хәрәкәткә ия чакта булмастай нәрсә юк ул! Әлбәттә, иң мөһиме—үзаң. Үткән гасырның совет дәверендә (кайбер халыкларның тәррәкыятен таныган хәлдә) үзаны үсешенә иң нык киртә куелган халык, мөгаен, татар булгандыр. Чын мәгънәсендә торгынлык (бу сүз безгә бик туры килә) чоры. Шөкер, соңгы дистә елларда үзаң терелеп, милли янарыш башланды. "Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?" дигән сорауга анык җавап табылды, ул уянган! Дәлилләрме? Уяну халәте булмаса, төрле кыйтгаларда яшәүче милләттәшләребез уртак мәсьәләләр турында фикерләшергә берничә мәртәбә Бөтендөнья татар конгрессына җыела алырлар идеме? Меннәрчә мәчетләрнең манаралары кораб-ракетадай күккә төбәлер идеме? Милләттәшләребез күпләп яшәгән төбәкләрдә уртак бәйрәм—Сабантуйлар гөрләп үтә алыр идеме? Сонлап булса да, Урал буйларында (соңрак Башкортстан дип йөртелгән төбәк) яшәүче татарларга игътибар артыр идеме (ә бит бу төбәктә татарның бик зур потенциалы)? Республика көне оештырылыр идеме? Туган тел бәйрәмнәре (халык бәйрәме дәрәҗәсенә күтәрергә иде бу бәйрәмне. Латышлардагы "Җыр бәйрәме" кебек) үтәр идеме?..

Әйе, халык булып киләчәктә сакланып калу юнәлешендә җәмгыятьнең төрле катламнары арасында билгеле бер унай аңлашу бар. Зур нәрсә бу. Житәкчелек белән халыкның берлеге нәтиҗәсендә 90 нчы елларда кайбер биеклекләр яуланды да... Шул нисбәттә, пропорциональ каршылык та житәрлек. Хәтта артыгы белән. Шовинистик даирәләр (күрелмәгән хәл: матбугатта һәм радио-телевидениедә кайбер партия вәкилләренең ачыктан-ачык расистик, фашистик рухтагы чыгышлары еш булып тора хәзер) Россиядә, рустан тыш, милли факторны бөтенләй үк юк итмәкчеләр. Алда бераз әйтелгәнчә, бу мәсьәлә дөнья күләмендә житди төс алды. Әйтик, Америка бөтен жир шарын үзенчә әйләндермәкче. Синең телең, рухың, тарихың кирәкме аңа (әнә Иракны нишләттеләр! Кеше хокукларын яклау кирәкме? Юк, нефть кирәк! Бай Америкага тагын да күбрәк байлык кирәк!). Бөтен дөнья халкын идентификацияләп, компьютер белеме (дөресрәге, үзләренә кирәк информация җыеп) биреп, алардан интер-космополит көч—робот-коллар ясап, җиһангир булу, дөнья белән идарә итү кирәк. Һәр кеше код—"шөреп" исәбендә булгач, аларны автоматик рәвештә юк итү технологиясен эшләү дә жинеләя бит!

Менә кайларга кереп киттең бит әле, газиз Каләмем! Сүз башы гадирәк—әдәбият хәлләре турында иде бит. Башы шулай иде дә, ә дәвамы, тәбе әнә нәрсәләргә килеп чыкты. Милләт язмышы, балаларыбыз язмышы, тел язмышы... Бу хәл

табигый да. Әйтик, тел—минем эш коралым, ахыр чиктә, яшәү чыганагым, язмышым... Тел—милләтне билгеләүче иң төп компонент. Ягез, туган телләреннән башка французны, немецны яки японны күз алдына китереп буламы? Юк, билгеле. Бу канун җирдәге бөтен халыкларга да кагыла бит! Ә телнең бакчасы—мәгълүм хакыйкать—ул—Әдәбият. Кайчандыр дәүләтен югалткан, әмма янарышка өметләнгән халыклар өчен бу бакча—әдәбият аеруча әһәмияткә ия. Аңа дәүләти институтлар башкарырга тиеш булган кайбер идеологик вазифалар да йөкләнә. Әйтик, бездә дәүләтчелекне тою хисе дүрт-биш гасыр буе югалмаган икән, иң әүвәл, без Сүзгә, язуга, әдәбиятка бурычлы (Дин факторын да исәпләми мөмкин түгел. Әйтик, телне, әхлакны саклауда аның роле ифрат зур. Соңгы вакытларда мөселманнарның да кайберләре Коръәнне дә русча укып өйрәнүләре генә сәеррәк). Бәс, шулай булгач, әдәбиятны саклау, турыдан-туры милләтне саклау булып чыга түгелме соң? Бер шагыйрь әйтмешли, "ул шулайдыр әле, уйласаң!" Чыннан да шулай. Әгәр Әдәби Сүз бетсә, милли сәнгатьнең бүтән төрләре дә юкка чыга. Иң әүвәл, театр бетә, музыка, рәсем һәм башка сәнгатьләр дә табигый сүлен югалтып космополитик дәрьяда эри, югала...

Менә шулай, газиз Каләмем! Син кодрәтле дә, хәвефле дә, көч тә бирәсең, исәп-хәсрәткә дә батырасың. Ил теленнән сүз җыеп, арган чакларың да буладыр... Язучының эш нәтиҗәсе—китап. Китап—әдәбиятның таҗы, язучының йөз аклыгы. Бездә гомер-гомердән Китап Сүзе дигән төшенчә яшәп килә. Китап сүзе, ягъни кануни сүз. Коръәннең бер сурәсендә "кыямәт көнендә һәр халык үз китабы белән кубарылыр" дип тә әйтелгән бит әле! Без үскәндә һәр җәмәгать урынында, үткән гасыр термины белән әйтсәк, һәр "кызыл почмак"та "Китап—белем чишмәсе" дигән шигарь-язулар эленеп торыр, яше-карты шул өндәмәгә тугрылыклы булырга тырыша иде. Кызганыч, идеяләр, идеаллар үзгәрә-үзгәрә, акчага табыну иманга әверелә барган заманда, хәлләр нык үзгәрде. Елында түгел, гомерендә бер генә татар язучысының китабын да укымаган (хәтта тәрҗемәдә дә!) бәндәләр ишәйде (шунысы көлке: шундыйларның кайбер активистлары татар зыялыларына нинди алфавитта язарга өйрәтеп маташа!). Татар мәктәбен бетереп, татар мохитендә яшәп, бүгенге әдәбияттан бөтенләй бихәбәр эреле-ваклы түрәләр ничаклы! Бер генә данә "Казан утлары"н алмаган татар авыллары бар (Сүз уңаеннан әйтеп узыйк, Кама аръягы, Тау ягы районнарында әдәби журналлар, шул исәптән, безнең журнал да начар тарала. Нәтиҗәсе хәзер үк күренеп тора: бу якларда яшь әдәби талантлар күренми диярлек. Димәк, җирле түрәләр, мәгариф һәм мәдәният җитәкчеләре тарафыннан әдәбиятыбызга мөнәсәбәт шуның кадәрле генә). Хәтта әдәбиятның, бигрәк тә бүгенге әдәбиятның көзгесе булган журналыбызны кулына да алмаган татар теле һәм әдәбияты "укытучылары" бар. Әйе, "юк"тан да яманрак әнә шундый "бар"лар да җитәрлек шул. Вәзгыятькә фаҗигаи төсмер бирергә теләмим. Сүз тәмен тоючылар, китап кадерен белүчеләр, әдәбиятның тәрбияви ролен тирән аңлаучылар да байтак. Шигырь юлларын ташка, агачка чокып уючы ир-егетләребез, сүз энҗеләрен кульяулыкларга, сөлгеләргә чигүче кызларыбыз да яши арабызда. Шөкер, туган телдә бишек җырларын көйләп, сабыйларын юаткан аналарыбыз бар. Дәүләткүләм бәяләргә лаек яңа әсәрләребез бар. Әмма...

Әгәр без бердәм булып, Әдәбиятны (китапны) милләтне саклауда һәм үстерүдә иң төп чыганакларның берсе дип саныйбыз икән, вәзгыятьне һич кенә дә үз агымына куя алмыйбыз. Планета коммуникаль бәйләнеш ягыннан "кечерәеп" һәм "ачыгаеп" калганда (кирәксә, космостан авылдагы өеңнең морҗасын да күрәләр бүген!), халыкара аралашу тәртипләре, алда әйтелгәнчә, аз санлы яки державага ия булмаган халыклар өчен торган саен кырысрак, рәхимсезрәк төс ала башлады. Без Гаяз Исхакый юраган инкыйраз рас киләме, юкмы дип яки "уңга карасаң да юк, сулга карасаң да юк" җырын шыңшып, тез кочаклап, оеп утыра алмыйбыз. Максатчан актив хәрәкәт кирәк (җан башына туган телдә чыккан китап исәбе бездә алдынгы илләрдәгенекеннән шактый түбән икәнен дә онытмыйк!). Күрәсең, милли китап үсешен тәэмин итәрлек дәүләти махсус Программа булдыру зарурдыр (әйтик, тузган торакны бетерү кебек нәтиҗәле Программа). Китап чыгару, китап тарату, гомумән нәширлек эше сәясәтен үз кулында тоткан махсус координацион Үзәк кирәклеге үзен бик нык сиздерә. (Дәүләт структураларында эшне белеп алып баручы милли рухлы җитәкче кадрлар җитенкерәми әле. Совет заманындагы кайбер эш алымнарының тәҗрибәсен өйрәнү дә һич комачау итмәс иде бүген). Әлеге Үзәк (ничек дип аталуына карамастан) реаль ихтыяҗны өйрәнеп (элек нәшриятның тематик планнары буенча җирле оешмалардан реаль заказлар җыйнала иде, тираж комиссияләре эшли иде), мөмкинлекләрдән чыгып, халык соравын ихтыяҗларын үтәү, тиешенчә тәэмин итү вазифаларын да башкарыр иде...

Гомумән, татар китабы—газаплы, авыр язмышлы, данлы тарих. Башлангычы да (XVIII гасыр башында басмаханәләр ачырга рөхсәт алгандагы кимсетелүле хәлләр турында мәшһүр галимебез Ә. Кәримуллин тәфсилләп язып калдырды), бүгенгесе дә... Язучы, һәм башка сәнгаткярь дә, үз эшенен киләчәккә кирәклеген тоймаса, эшли алмый, ижат итә алмый. Әдәбият-мәдәният өлкәсендә хәл итәсе мәсьәләләр күтәрелгәч, гадәттә, "базар" дигән сүз калкып чыга. Базар мөнәсәбәтләре хәзер, барысын да шул хәл итә, базар шартларында яшәргә өйрәнегез, диләр. Элек тә булган ул базар. Бар һәм булачак. Исәпләшми булмый: яшәешнен матди бер "чыгыры" инде ул. Әмма базарга иман кирәкми. Базар ансыз да яши. Ә кешегә—кирәк, кешегә күп нәрсә кирәк. Жанлы сүзе дә, ягымлы көе дә, күнел байлыгы да... Байлык димәктән, узган гасыр башында да булган ул байларыбыз. Булган төрлесе, булган мәгърифәтлеләре, булган "каралары". "Ак" байлардан хәтер булып мәдрәсәләр, мәчетләр, китапханәләр калган. Ә фәкать мал өчен генә яшәгәннәренен исемнәре дә нәмәгълүм диярлек. Тирәнтен уйлап баксаң, татарнын төп байлыгы фәкать рухи мирас кына. Жырлар, көйләр, китаплар... Безгә мирас булып калган рух байлыгын тудыручыларны кемнәр ничек кенә санаса да, барыбер, исемнәр бер тирәдә булыр. Алар—Тукай, Исхакый, Сәйдәш, Жиһанов, Урманче... Хәер, империя шартларында бүтән байлыкнын, матди милли байлыкнын дип әйтүем, булуы да мөмкин түгел бугай (әнә Мәскәүдә Әсәдуллаев йортын татарлар һаман үзенеке итеп бетерә алмыйлар әле). Ә бүгенге, зур хосусый байлыкларга ия яшь байларыбызга килсәк, алар турында ниндидер фикер, бигрәк тә уңаен, әйтергә иртәрәк әле. Күбесендә—"кыргый базар" шаукымында гади халыкнын "күзен буып", алдап-йолдап жыйналган байлык. Капитал туплаунын да үз кануни традицияләре, үзенә генә хас этик кысалары, әйтер идем, үз культурасы бар. Киресенчә икән, димәк исраф итү культурасы да юк дигән сүз. Хәрам кергән малнын, гадәттә, бәрәкәте булмый, тиз әрәм-шәрәм ителә яки "этләргә" кала... Бу хакта сүз куертып та тормас идек тә, юк шул, китап чыгару өчен дә чыгымнар, байтак чыгымнар кирәк. Ярый да хәзергә дәүләт өлешчә булыша, ә бер көн килеп, андый мөмкинлек бетсә, яки "бик өстән" бетерттерелсә? Ирексездән, меценатлык мәрхәмәтенә өмет тотачаксын. Ә бармы сон ул бездә меценатлык? Меценатлык дәрәжәсенә күтәрелер өчен, малтабар кеше үзе дә күнеле белән күпмедер дәрәжәдә шагыйрь, музыкант, рәссам, артист булырга, һәрхәлдә, рух дөньясын, сәнгатьне тоярга, анларга тиеш. Кайда сез, бүгенге Рәмиевләр, Хөсәеновләр, Кәримовләр, Юнысовлар, Акчуриннар?

Сәнгать әсәре—кем өчендер товар. Әйе, бер караганда товар да. Оста тарафыннан бердәнбер данәдә ясалган (язылган) бәһале товар. Китап рәвешендә меңнәрчә тираж белән чыгарылганнары чыннан да товар. Шул ук вакытта, ул товар да түгел. Бөек әсәр бәясез ул! Уй-кичерешләрне, шатлык-кайгыларны үлчәр бирәмлек юк.

Ике хәзинә бар дөньяда: саклагыз!
Каберстан анын берсе. Гел гөлдә булсын!
Китапханә икенчесе. Күнелдә булсын!
Базар болай да калыр...

Бүгенге көндә гомерен язучылык эшенә, әдәбиятка багышларга алынган кеше фидакарь зат ул. Әшәкелек күзгә кереп торган заманда якты шигырь язу—үзе бер батырлык. (Дөрес, кайбер спектакльләрдә, аерым әсәрләрдә—анлапмы-юкмы—шагыйрьне ниндидер зәгыйфьрәк зат, наив, беркатлы итеп күрсәтүчеләр дә очрый. Күрәсен, андый ижатчылар чын шагыйрьне белмиләр.) Үзен зур миссиягә әзерләгән кеше генә чын язучы була ала. Кемнәрнендер күзлегеннән караганда, яшәештәге рейтингы зур булмаса да, бай һәм тук яшәмәсә дә, шушы хаос, имансыз заманда халык күнеленен елъязмачысы, алай гына да түгел халык рухынын байракчысы булырга омтылу пәйгамбәрләргә хас сыйфат. Тарихи жаваплылыкны, авыр миссияне кемнәрдер алырга тиештер бит! Кемнәр сон алар? Жирле хакимият түрәләреннән берәрсеме? Депутатмы? Банкирмы? Шикләнәм...

Газиз Каләмем! Хискә бирелебрәк салулап китмәденме? Артык катгый сүзләр тезәсең түгелме? Халык рухынын байракчысы!.. Бик зур сүзләр бит... Бәлки... Хезмәтен язмышына әверелгәндә, сайлаган юлынны идеаллаштыру да булырга мөмкиндер. Әлбәттә, тарихи миссия кебек категорияләр белән сөйләгәндә Шәхес факторы алга баса. Шәхес юк икән, әллә нинди юл, әллә нинди профессия сайла, һични барып чыкмас. Шәхес бар икән, яшәеше тормыш үзәгендә булып, халыкнын иң мөкатдәс теләкләрен эшкә ашырып, киләчәк өчен бөек гамәлләр кыла икән, андый Шәхеснең байракчы саналуы гажәп түгел. Әйтик, Минтимер Шәймиев

соңгы дистә елларда татар халкының байракчысы түгелмени! Җир шарының төрле почмакларында ул халык вәкиле, аның илчесе булып татарны танытмадымыни? Шулай, Вакыт галиҗәнабләре билгеле бер илнең, билгеле бер дәвернең символ иярләрен үзе сайлый.

Яу-дауларны күргәннәр күп.
Көрәш-шауда җиңгәннәр күп.
Вакыт-Яу—ин-иң яманы!
Җиңүчеләр сирәк аны

Вакыт белән хезмәте тау
ирләр генә алыша ала.
Заман иелеп, җиңүченең
данлы исемен алып кала.

Булды заманнар—теге яки бу халыкның байрак-символы итеп бөек шагыйрьләр, язучылар, композиторлар, сынчылар, гомумән, сәнгать кешеләре саналды. Итальян Данте, испан Сервантес, әзәри Физули, рус Пушкин, украин Шевченко кебек даһиләрне искә алып китик тә, үзебез яшәгән чорда иҗат иткән, үзләре белән беркадәр аралашырга да туры килгән бөек язучыларның кайберләрен барлап узыйк. Алар да шул когортадан!.. Дөнья алдында үз халыкларының тулы вәкаләтле вәкилләре, илчеләре. Кыргыз—Чыңгыз Айтматов, авар—Расул Гамзатов, калмык—Давыт Көгелтинов, рус—Александр Солженицын, башкорт—Мостай Кәрим, казакъ—Олжас Сөләйманов... Ә үзебезнең Тукай, Җәлил шул миссияне башкармадымы? Шөкер, маяк саналырлык үрнәкләр бар. Булган һәм булачак алар. Шәхес кенә бул, үлемсез әсәрләр генә иҗат ит! Вакыт—Кояш астындагы тарихи урыныңны үзе билгеләр ул!

Язучы исеме, язучылык хезмәте моңа кадәр һәр халыкта да дәрәҗәле саналды. Ерак гасырлардан бирле. Ул шагыйрь дип аталамы, чәчән яки акынмы, халык аларны үз итте, хезмәтләреннән гыйбрәт-сабак алды, әйткәннәрен күңелендә йөртте, мирас-васыят итеп балаларына сөйләде... Килешмәгән, хәтта дошман очракта да, хаким-хөкемдарлар санлашырга, исәпләшергә мәҗбүр булды алар белән. Юкса, шагыйрьләрне хандай зурламаслар яки иленнән сөрмәсләр иде, төрмәләрдә череттмәсләр, асмаслар-кисмәсләр иде! Шулай да, Дөнья гел хәрәкәттә, гел әйләнештә. Мәңгелек дип саналган аксиомалар да үзгәреш кичерә. Язучы дигән атамада да мәгънәви үзгәрешләр бар. Инглизләрдә writer (райтэ) сүзе, язучы дип тәрҗемә ителсә дә, мәгънә спекторы үзгәрәк... Монысы бер хәл булса, үзебезнең халыкта да язучы сүзенә караш беркадәр үзгәрә башлады кебек. Сәбәпләре бар. Мәгълүм гыйбарәне үзгәртебрәк әйтсәк, "килде бер көн, язучылар йөрер төркем-төркем". Дөресрәге, үзләрен язучы санаган графоманнар армиясе нык ишәйде. Андый төркемнең булуы гаҗәпләндерми дә, һәрчак булган алар (хәтта булырга тиешләрдәдер), ләкин, пәри башка җен башка дигәндәй, элек алар, гадәттә, үзешчән статусында иделәр. Көндәлек матбугатта, кумәк җыентыкларда басылгалыйлар иде, әдәби мохитнең күренеш-фонын тәшкил итәләр иде. Ә хәзер... күбесенең амбицияләре бөтенләй бүтән! Акча юнәтеп (өлгер, булган халык!), төрле басмаханәләрдә бер-бер артлы китапны чыгарып кына торалар! Калын итеп чыгаралар, яхшы кәгазьдә, матур бизәкле итеп... Аннан Язучылар берлегенә керүне максат итеп куялар. Язучылык билеты чын язучы итә дип уйлыйлардыр инде (әнә, кесәсендә язучы билетын йөртмәгән, оешмада рәсми әгъза булып тормаган Зөлфәт Хәкимнән Бөтендөнья татарлары Конгрессында барлык язучылар, гомумән, интеллегенция исеменнән чыгыш ясавын сорадылар һәм ул менә дигән нотык тотты). Өстәвенә бу "актив язучылар"ның күбесе иҗат эшенә пенсиягә чыккач тотынган иптәшләр. Әйдә, җаны теләгән елан ите ашаган, язсыннар рәхәтләнеп дияр иден дә... Алай да булмый. Халык алдында әдәбиятның дәрәҗәсе төшә, китапның абруе кими. "Кар башына кар җитә" дигән гыйбарә бар; шуның кебек, эшләр болай барса "китап башына "китап" җитә диярсең! Чүп үләне баскан басуны күргәнегез бардыр, кайда бодай анда, кайда сарут та билчән... якын килеп карамасаң белмәссең дә, еракта һәммәсе ямь-яшел булып үсеп тора!

Әдәби мохит, китап дөньясы чүпләнүнең икенче бер әшәке формасы да бар әле бездә. Ул—кеше өстеннән әләк, шикаять, донос язу. Нинди генә негатив фактлар табылмый да кайларга гына (министрлыкларга, прокуратураларга, төрле дәрәҗәдәге Президентларга...) язылмый алар! Дәүләт структураларында интеллектуаль өлкәдә аннан башка да бик аз сандагы җитәкче хезмәткәрләрнең күпме вакытын, күпме җегәрен ала ул "гаделлек сагында" торучы яла ягучылар! Мәхкәмәләргә дә тынгылык юк, процесс арты процесс... Әлбәттә, әдип кеше, талантлы кеше шөгыльләнми моның белән. Ул кирәген, күңелендәгесен, ярым-

аноним шикаятьләр белән түгел, кешеләргә турыдан ярып әйтә. Шикаятьчелек белән әлеге дә баягы, көнләшү катыш амбициядән чирләүче, русча әйтсәк, окололитературный контингент шөгыльләнә дә инде. Бу чир, кызганыч, галимголәмә арасында да җитәрлек икән. Бер-берен хурлаган, хәтта дошманлашу дәрәҗәсендә ярсыган бәгъзе адәмнәрнен матбугатта (татарча гына җитми, күбрәк русча матбугатта "бугазлашалар", ишләрәк кеше укысын, татарнын үзара талашын күбрәк кеше белсен!) чыккан язмалары укшыта кайчак... Кораб давыл-штормда бату хәлендә чайкалганда, кемнәрнендер каюташханәдә тиешенчә ашатмыйлар, компотка җимешне җитәрлек салмыйлар, дип, коры җир—материкка жалу язуы белән бер бу гамәлләр. Күрәсен, рух-иман юлында, "кеше җаны өчен көрәш"тә, акыл-фикер бәрелешендә шәйтан вәсвәсәсе булмый калмыйдыр. Иблис тә фәрештә санала түгелме сон? Бер яктан әлеге тискәре күренешләр бик аяныч булса, икенчедән, язу эшенен, иҗат эшенен, күпләр өчен никадәр кызыктыргыч мөһим, никадәр җаваплы һәм дәрәҗәле миссия икәнен дә күрсәтә. Ширбәте булган чәчкә тирәсендә генә бал кортлары оча, шулай ук, чебен-черкие дә...

Иҗат итү—илаһи халәт, кеше акылынын җинүле тантанасы. Иҗат—илһам дигән күнел дәрте белән бәйле рухани акт. Шуна күрә, үтә индивидуаль, серле, тылсымлы шөгыль дә инде ул. Галимнәр арасында бөекләрнен иҗат лабораториясенен хикмәтләрен ачарга омтылучылар бар. Әлбәттә, иҗатнын кайбер тенденцияләрен, алымнарын, стиль рәвешен һ. б. ачыкларга була. Әмма кош юлынын эзен "тотып" булмаган кебек, иҗат процессынын төбенә төшү дә мөмкин эш түгел. Еш кына автор үзе дә бер нәрсә турында язарга тотынып, башта уенда да булмаган әллә нәрсәләргә килеп чыга... Хикмәт. Шулай да, әдәбиятта сер булмаган тәртипләр, кагылгысыз традицияләр дә бар. Әдәбиятта ин элек әдәп булырга тиеш. Әдәбият багына, гыйбадәтханәләргә кергән шикелле, чиста күнел, изге уй белән керү мөһим. Бу Бакчага кергәннәр нәрсә яхшы, нәрсә яман, нәрсә ярый, нәрсә тиеш түгел кебек сорауларга җавапларны алдан ук белеп керергә тиешләрдер. Сүз—эстетик идеал, әдәби этика, профессионализм кебек төшенчәләр турында бара. Хәзер, сүз иреге дип, теләсә нәрсә турында, теләсә ничек язгалаучылар барлыкка килде. Әдәбият бүген генә яралмаган, үткән юлы анын әллә ничә мен еллар. Татар әдәбиятынын традицияләре дә, Аллага шөкер... Укы, бел, гыйбрәт ал. Әлбәттә, әйтелгәнчә, читтән яки өстән кушып, диктат белән иҗат итү мөмкин түгел. Өндәмә белән генә булса, совет чорында партиянен "әдәбият-сәнгатьне үстерү турында" чыккан бихисап карарларыннан сон, әллә никадәр шедеврлар туар иде. Иҗатны стимуллаштырып була. Конкурслар, иҗади ярышлар, фестивальләр, премияләр... Әдәби хәрәкәтне идарә итү (элек без ышанганча) мөмкин үк булмаса да, булган әдәби байлыкны анализлап, орлыгын кибәктән аерып, халыкка анлатып, яшь талантларга булышып була. Бар әдәби җәмәгатьчелек, бар иҗади оешма, бар әдәби профильдәге журналлар... Бу өлкәдә һәммәбезгә дә эш җитәрлек. Бу—корылтайлар, семинарлар, утырышлар кебек компания рәвешендә генә түгел, әдәбиятта үз җаваплылыгын тойган һәркем өчен көндәлек даими эш булырга тиеш.

...Алдымдагы кәгаземнен байтак битләре шыплап тулды. Ә тәрәз алдымдагы күренеш һаман шул: ап-ак килеш. Дөньяда Яна ел икән бит! Күпләр шунын хозурында. Күнелем белән үзем борын заманнардагы ерак бабаларым көтеп алган яна ел—Нәүрүз ягында. Яна елнын яз булуы табигый. Шәрык илләрендә ул шулай да. Яз, чыннан да, яна фасыл булып, янарыш циклын башлый. Җиргә орлык чәчелә, кошлар кайта, табигать уянып, яшелләнә, күнелләргә яна дәрт өстәлә, өмет-ышаныч арта. Зәмһәрир кыш уртасында, суыклар, бураннар котырган көннәрдә, менә апай, пәрәмәч! дигәндәй, менә сина, Яна ел! Вакытны болай сындыру мизгелен, шартлы рәвештә, биле өзелергә җиткән кыска Көннен тулыша башлау вакыты дип анлатсан гына инде... Хәер, аны Раштуа, Христос тууы белән бәйлиләр, европалылар гадәтен Россиягә Петр патша керткән, диләр. Шулайдыр. Күбебез, бу хакта уйламый да инде. Яна ел тек Яна ел. Яшәгән дөньян, бөтен тирә-юнен гөрләп мәш килгәндә, бәлки, безгә дә бәйрәм рәвешен китереп, бераз ял итеп алырга ярыйдыр?

Шулай дип яздым да, тәрәзәдән күренгән тышкы аклыкка карап алдым, аннары янәдән алдымда яткан кәгазьләремә текәлдем. Йә, нишлибез, газиз Каләмем? Җин сызганып эшлибез, дисенме? Әйдә, шулай булсын!

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН**,
*Татарстанның халык шагыйре*



**Роберт Әхмәтҗан**

## УЙЛАНА ТАБИГАТЬ...

### Чыгыр

(«Якты юраулар» этнографик циклына)

I

**Гаҗәпләнмәс әле беркем,**
**Кем сөйли дип кем турында:**
**Вөҗдан белән сөйләшәмен,**
**Җавап бирәм ыруыма.**

**...Аратаңда алашаң юк,**
**Ашлыгың юк ындырыңда...**
**Көчкә тотынып торасың**
**Буыннарың чылбырында!**

**Нәселемнең ир затларын**
**Сугыш йотты бит барын да...**
**Тегермән тартмый—канатсыз,**
**Орлык такыр амбарыңда!**
**(Эленеп тора сыңар канат**
**Буыннарым чылбырында!..)**

**Сарыга сарылган җиңги,—**
**Җырлыйм дисә, моңы беткән.**
**Кунасында камыр җәйми,—**
**Җилпучында оны беткән...**
**Җете төсләрен җил алган,**
**Уңасылар уңып беткән...**
**Кузгалмый да тәрәш-каба,**
**Эрлим дисә—йоны беткән.**
**Урак—кыршау, гармун—иске,**

---

Роберт ӘХМӘТҖАН (1935)—*шагыйрь, "Идел-йорт", "Таң шәһәре", "Җәяүле күбәләк" һ. б. китаплар авторы; Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Күрүгенең тыны беткән!
Оябызга ниләр булды,
Тузгыттымы шайтан-мәләк?

Әнкәй, сине оныткандыр
Аралыкта сырлы бәләк?..

Әнкәй, синең уйларыңны
Аңласа, бары ул аңлар—
Безнең гомерне шаулатып
Агы беткән ак самавар!?

Матча өрлеге искергән:
"Он тарталар" кырмыскалар...
Карт тупылым тәсбих тарта:
"Гомерең калган бер мыскалга..."

Бер Ходайдан игелек сорап,
Сузылган кул-тармаклары:
"Оҗмахыңнан урын алсын
Бу нигезнең әрвахлары!.."

...Онытылган иске кое,
Чиләге юк чыгырында...
Әллә мин дә соңгы божра
Буыннарым чылбырында?!

II

Булмый болай!.. Ничек итеп
Уятырга бу Нигезне?..
Ауганнарын торгызабыз,
Җыелышып сиплибезме?

Әйтерсең лә нидер көтә,—
Ишегалды тора тып-тын...
Януларын төштә күрә
Ягылмаган иске утын...

Мин дә менә ниләр көтәм,
Уй-киңәшчем юктыр бүтән?..—
Ни әйтсен соң—
"балта ашап"
Гомер иткән
Иске бүкән?!.

Тормышны тергезим дисәң,
Карама гомер үткәнгә,
Иң беренче, җиңең сызган,
Балтаңны чап, дим,
бүкәнгә!
Морҗабыздан чыксын төтен,—
Ут кабызыйм учагыма.
Шулчак, узган безнең гомер
Кайтсын кабат
бу чагыма!..
...Кайный казан,
Кайта гомер,

Төшә күмер
учагыма!

Җанланамсың, Иске Нигез,
Килче, алыйм кочагыма!
Тәрәзәмне ачып куям,—
Җиләтәм мин сине,
Дөньям!..

## Ә Табигать яши...

Туган төбәк, күзгә урман, сезне
Соңлап булсын, сагынып кайттым мин!..
Туйралыгың кайда, ләбентеләр[1],
Алтын кишәнкеләр?
Тапмыйм мин.

Ул Пүчинкә өсте—күксел рәшә,
Тәрбелиең нигә боеккан?..
Таулар сабыр, утырып чүгә таулар,
Сагыш тама
такта кыектан!..

Ә Табигать—яши...
Тау битендә йомран яшәп ята,
Бәбиләре әле сукырлар...
Оясыннан ак дөньяга чыккач,
Табигатькә
рәхмәт укырлар!..

Балачакның учак урыннары—
Кемнәр өчен—
Иске чокырлар!.
Торналарның бер авазы өчен
Җаны белән түләр бу кырлар!..

Басу-кырлар—гамәл дәфтәредәй,—
Ни чәчкәнең чыга тишелеп!
Яши-яши нәфесе арта гына,—
Картаямы шулай
Кешелек?!
Бәхеткә дә батып үлә мокыт,
Дулкын булып килсә ишелеп!

Яңа токым шаулап үсә монда,
Яшәргәннәр күрше-күләннәр!..
Дәвам итә нәсел: орлыкларын
Күздән чәчеп кала
үләннәр!..

...Чалбарыңнан тиз башларың чыккан,—
И, балачак,
ниләр
чәчәсең?..
Картлыкнымы?
Күптән ашадың шул
Яшьлегеңнең
соңгы
көлчәсен...

---

[1] ләбентеләр—куакның яшь үсентеләре.

Инде хәзер
Кайтып алтын чакка,
Минутында
        еллар кичәсең!..
Ә Табигать нихәл?
Ә Табигать... яши!
        Нишләсен!?

## Уйлана табигать...

Уйлана Табигать узган Җәй хакында,
И җәйге тупыллар шаулавы якында!
Төнге урманда таланган кыз сыман,
Чал чәчле ападай, сеңелдәй үз сыман—
Ялангач Көз тора тәрәзәм артында.
И җәйге тупыллар шаулавы якында!..

Көз берни сорамый, күкләргә ул баккан.
Әремнәр шаулатып җил исә төньяктан...
Сагынулар күңелдән мөлдерәп түгелде,
Иң соңгы яфрактай, җилкетеп күңелне,
Ут-песнәк сикерә куакта!..
Әремнәр шаулатып җил исә төньяктан...

Кыштырдый көзге җил саргайган кыякта.
Көз берни сорамый, уйларга чумган ул.
Агыла офыкка болытлар олавы...
Шыгырдый тәгәрмәч, бу—Көзнең елавы,—
Көз китәр төялеп үзе дә еракка!..
Кыштырдый соры җил саргайган кыякта.

Көз берни сорамый, сораудан узган ул:
"Бәгыренә боз каткан и күксел тугайның!"
Бу узган Җәемне мин Сиңа охшатам,
Бер янып, бер көеп күңелемне бушатам:
"Син килеп чыгарсың, мөгаен...
Син килеп чыгарсың шикелле... бер чаттан..."

Әлегә боз каткан...
        бәгыренә...
            тугайның!..

## Көзге җыр

...Токарлыйсы иде Көзне,
Көз шул кузгалган инде!..
Аерып та булмас безне:
Син бит күзалмам инде лә,
син бит күз алмам инде!..

Бәгыремне бер сүз өзде:
"Синсез түзалмам инде лә,
синсез түзалмам инде!.."

Көзләр куенына сеңеп,
мин сине яраттым ла!..
Шул сүзләрем очты кебек
кыр казы канатында шул,
кыр казы канатында...

Булмас инде һичбер чаклар
безнең ул чаклар сыман!..
Кызыл-комач бу яфраклар
көзге учаклар сыман ла,
көзге учаклар сыман!..

Сине миннән көзләр алыр,
ятлар кочаклар сыман, аһ,
ятлар кочаклар сыман!..
Көз каршында бер ялгызым
дөрлим учаклар сыман ла,
дөрлим учаклар сыман!..

Сезнең якларга очалмыйм...
инде ул яклар... томан...

## Тере Поэма

...Бер поэмам Синдә яши минем,
Шул поэмам ия тылсымга...
Табындым мин тере Поэмага,
Шул поэмам
Синдә булсынга!..

Югары ул гади мәхәббәттән,
Һәм, соңлаган гыйшык-гашрәдән...
Төче мактаулардан,
татлы сүздән,
Юхалыктан,
юк-бар нәрсәдән!..
Мин кәгазьгә төшерә алмыйм утны,—
Талантыңнан кабыныр ялкыны...
Соңлап килгән илһам,
соңгы күкрәү,
Соңгы Поэмадай
балкыдың!—
Чәч дулкының ташлап иңнәреңә,
Узып киттең...
йөрәк аркылы!..
...Төнлегемдә йолдыз сакта хәзер,
Баш очымда... тып-тын фәрештәм...
Бер Поэмам Синдә кала минем...
Яшәп йөри...
Синең
рәвештә!

## Сонет

*Л...гә*

Шаһит булып торсын Төнге Сирень,—
Төнге вокзаллар да түгел,
Диңгез ярларын да көтми күңел,
Җанны баскан йөкне бушатыйк та,
Бер яшьлектә кебек, бер картлыкта
Йөрәгеңдә очрашыйк без Синең,
Шаһит булып торсын Төнге Сирень!..

Күңелнең бер аулак почмагында,
Сыенып, хатирәләр кочагына,
Кайтыйк әле Язның шул чагына,—
Утырыйк бер. Үкенеч калмасын...
Яшәрсеннәр, яңарсыннар еллар,
Бу мизгелне, шатлыгыннан елап
Һәм, алкышлап, Сирень шауласын!..



# Рауль Мирхәйдәров

# КАРГА КОРОЛЕ

**РОМАН**

*Рауль Мирхәйдәров исеме татар укучысына инде шактый таныш. Аның "Иртәләгән сагыш" һәм "Һәрнәрсәгә акчалата" романнары "Казан утлары" битләрендә дөнья күргә үк әдәбият сөючеләрдә зур кызыксыну тудырган иде. Бу саннан басыла башлаган роман әдипнең "Кара даирәнекеләр" исемле күләмле тетралогиясенә керә. Ул әсәрләр рус телендә инде 19 тапкыр нәшер ителгән һәм гомуми тиражы миллионнар белән исәпләнә. Американың "Филадельфия Инкуайер" газетасы Рауль Мирхәйдәровны "мафияне тикшерүче" дип бәяләде. Европадагы байтак газеталар язучы белән җинаятьчелек темасына интервьюлар бастырып чыгарды. Белгечләр аны дистә еллар алга, киләчәккә күз ташлый алган аналитик дип тә атыйлар.*

*Романны үз вакытында әдипнең дусты, язучы Рафаэль Сибат тәрҗемә итә башлаган иде. Әмма аяусыз үлем аны арабыздан бик иртә алып китте. Каралама хәлендәге ул язмаларны тәртипкә китереп, тәрҗемәне ахырына җиткерү безнең өлешкә тиде. Автор һәм тәрҗемәче әсәрне аның истәлегенә багышлый.*

*Флүс ЛАТЫЙФИ*

## Беренче кисәк

### Пики төсе, кара төс

Кинәт кенә, көтмәгәндә төшкән көзге, ниндидер юеш-ябышкак әңгер-меңгер гөрләп торган вокзал мәйданындагы җанлылыкның бар төсен-матурлыгын юкка чыгарды. Гүя бер минут элек кенә трамвай юлы янында янып торган өрәңгеләр, алардан чак кына читтәге мәһабәт платаннар, колач җитмәс имәннәр сары яфракларын күз явын алырдай жир-паласка йомшак кына коеп утырдылар да, күз ачып йомганчы, барысы да төсләрен, кыяфәт-рәвешләрен югалттылар, әйтерсең лә тирә-якны төтен басты. Хан-атлас дигән затлы тукымадан тегелгән күлмәкләрнең күз чагылдыргыч матурлыгы юкка чыкты, салават күперенең барлык төсләрендә балкыган спорт сумкалары, төрекмән хурҗиннары шулай ук төссезләнделәр, юлга әзерләнгән балаларның чуар киеме үзенең гүзәллеген җуйды, хәтта

вокзалның иркә-яшел фирүзә түбәле бинасы да нииндидер көрән төскә керде, әллә нинди җайсыз-ямьсез кыяфәт алды.

Эңгер-меңгер төсләрне генә түгел, төрле тавышларны да йотты. Әле генә мәйданда трамвайлар гөрелдәве күңелле ишетелә, балаларның яңгыравык авазлары җанны иркәли, әле анда, әле монда шат көлү тавышлары яңгырый иде. Һәм менә мә, әйтерсең лә кинәт кенә барысы да—трамвай-троллейбуслар да, кешеләр һәм машиналар да сүз берләшкәндәй пышылдауга күчтеләр. Ни нәрсә соң әле бу? Көнне басып килгән төн тылсымымы? Әллә зәңгәрсу азиат эңгер-меңгеренең сихереме? Көнчыгышның тагы бер сереме?.. Берәүләрнең икенчеләргә эше, кызыксынуы кимегәндәй тоелган менә шушы мизгелдә, тәүлекнең беразга вакытын югалтып торган чагында, төнге тормыш якты көнгә көч җыйганда, вокзал мәйданында машина күренде. Карасу төтендәй җәелгән эңгер-меңгердә аның төсе акмы, сарымы, көрәнме икәнен анык кына танырлык түгел иде инде. Кипкән-корышкан розалар утырган чәчәк түтәлләре янында борылып, машина түләүле тукталышка килеп керде. Моңа беркемнең дә игътибар итмәвенә ант эчәргә мөмкин булса да, рульдәге кеше нигәдер бик сак кылана, хәтта машинасы ясаган шушы маневрга да ниндидер зур факт итеп карый, үзенчә борчылу-кайгырту күрсәтә иде.

Яңа "Жигули" хуҗасы кабинасыннан тиз генә чыкмады, машинаны куяргамы-юкмы дип уйлангандай, күпмедер вакыт эчтә утырды әле. Күзләре кереп килүче машиналарны капшады. Шикләнерлек берни дә тапмады булса кирәк, ниһаять, ул ишеген ачып җибәрде, йозакларының төзеклегенныклыгын тикшереп әйләнеп чыкты. Шуны гына көтеп торгандай, вокзал өстендәге ачык кызыл төстәге неон хәрефләр кабынды. Һәм тагын барысы да үзгәрде, күз ачып йомганчы, әйтерсең, Ташкентка һәм бөтен тирә-юньгә тормыш әйләнеп кайтты. Әле генә бөтен дөньяны басып торган авыр тынлык бердән юкка чыкты һәм гүяки машина хуҗасына ишетү сәләте әйләнеп кайтты, ул янәдан трамвай кыңгыраулары тавышын, кешеләрнең сөйләшүләрен ишетә башлады. Әнә аның яныннан гына "Әй, сакланыгыз!"—дип кисәтә-кисәтә кондукторлы трамвай узып китте. Шулвакыт тагын әллә нәрсә булды, вокзал өстендә балкыган сүзнең баштагы өч хәрефе кинәт караңгылыкка чумды һәм ниндидер чит тел сүзен хәтерләтеп "кент" дигән өлеше генә янып калды. Машина иясе үзалдына елмаеп куйды, теле исә шул яңа сүзне тәмләп кабатлады: "Кент..." Һәм ул җәһәт-җәһәт атлап станциягә юнәлде. Төн чаршавына күмелеп килгәндә тагын да зураеп калгандай тоелган мәйдан янә бер үзгәреш кичерде: әле анда, әле монда кабынган машина фараларыннан төшкән ут көлтәләре вокзал тәрәзәләрендә уйнаклады, икенче каттагы ресторанда музыка тавышлары яңгырады—башкала вокзалында кичке тормыш үз агымына керде. Машинасын тукталышта калдырган кеше Сухроб Әхмәт улы Әкрәмхуҗаев исемле булып, ул үзе озын буйлы, әзрәк кенә авыр гәүдәле, әмма спортчыларга хас матур бәдәнле, җинел адымлы бер инсан иде. Читтән караган кемсәләр аның ничә яшьтә икәнен билгели алмас иде, чөнки ул әле яшь күренә, үз-үзен тотышы да яшьләрчә: иркен, ачык, әмма тупас түгел; өсте-башы, кием стиле дә аның кешеләр арасында, җәмгыятьтәге урынын анык кына билгеләргә мөмкинлек бирми иде.

Сухробның кулында берни дә юк, аны күзәтүчеләр булса, бу кеше кемнедер каршыларга килгәндер дип кенә уйлар иде. Беренче платформада торучы Мәскәү—Дүшәмбе поезды янында кеше кайный. Әмма монда аны танучылар булуы шикле. Хәер, аңа алар кирәкми дә. Ул аралаша торган кешеләр гадәттә фирменный "Үзбәкстан" поездында гына йөри.

Беренче платформага чыккан Сухроб шулай да тирә-ягына каранмыйча булдыра алмады, аннан соң вагон номерларын карый-карый, поезд башына таба китте. Ул үзе тышкы кыяфәте белән әлләни күзгә дә ташланырлык түгел. Өстендә артык кычкырып тормаган соры төстәге твид пиджак, каракөрән чалбар, аякларында тавышсыз йомшак "Саламандра" туфлиләре; чия төсендәге күлмәк якасы ычкындырылган, ләкин бу аның кыяфәтен бер дә бозмый, киресенчә, яшьләрчә күренүче кешегә спортчылар төсе бирә иде.

Ул инде барысын да алдан уйлаган, исәпләгән иде, әмма барыбер беләгендә

балкып торган зур һәм авыр алтын сәгатенә—Швейцариядә ясалган мәшһүр "Ролекс"ка күз төшерми булдыра алмады, жинел сулап куйды. Димәк, өлгерәчәк! Вакыт бар әле. Ул, каршылаучылар һәм китеп баручылар агымына кушылып, кемнедер эзләгәндәй, вагон номерларына күз сала-сала атлый бирде. Бу хәрәкәтләре, кыланмышы шулкадәр табигый иде ки, вокзал тирәсендә берәр күренеш төшереп алырга җыенган теләсә кайсы кинорежиссер аннан разый калыр иде.

Жир асты юлына кергәндә генә ул бер секундка тукталып алды, эчтән генә сүгенгәндәй итеп сул ботинкасындагы шнурын сүтеп кабат бәйләде һәм шулвакытта артыннан "койрык" килмәвенә тәмам ышанды. Хәер, үзен күзәтергә алынучылар булса, аларның үзеннән мең кат хәйләкәррәк эш итәсен ул бик яхшы белә иде.

Поездлар янына алып чыгучы жир асты юлына кергәч ул Ташкент—Наманган поезды китәренә биш минут калганын ишетте, жинел сулап куйды. Хәзергә барысы да ул корган план буенча бара иде.

Туннельдән ул инде туп-туры үз вагонына таба китте. Башка вагоннардагы кондукторлар байтактан тамбурга менеп басса да, ул барачак йомшак вагонныкы исә әле һаман соңга калучыларны көтә иде. Мөһим пассажир эч пошкан кыяфәттә басып торучы тимер юл хезмәткәренә ике билет сузды. Тегесенең теленнән үзеннән-үзе ычкынды: "Юлдашын кайда?" Сорауга җавап аңлаешлы булды:

—Беләсезме, йоклаганда мин нык кына гырлыйм бугай, шуңа күрә, күршеләр белән йөрергә яратмыйм, купены берүземә алам.

Чәйханәдә дус-ишләре белән шактый гына сыйланып өлгергән вагон хуҗасының кәефе шәп иде, ул шаяртып сорап куйды:

—Хәтта поездда дүрт урынлы купелар гына булса дамы?

Ләкин мондый сорау да твид пиджаклыны чыгырыннан чыгармады:

—Әлегә берьюлы дүрт билет алырга туры килгәне юк, хәер, мин поездда бик сирәк йөрим.

Ул сүзе беткәнгә санап жинел генә вагонга күтәрелде, ә үзе шул мизгелдә составның башына һәм ахырына карап алды.

Нишләп сорау биргәненә чын күңелдән үкенгән кондуктор да аның артыннан күтәрелде. Тәҗрибәсе буенча мондый кешеләргә артык сорау бирергә ярамаганын ул яхшы сиземли иде. Галстуксыз һәм озатып килүче хезмәткәрләрсез булса да, күренеп тора: бу адәм теләсә кемгә баш июческәрдән түгел, шәрыкта андыйларны биш чакрымнан таныйлар. Мондыйларны аз күрмәде инде ул. Поезд кузгалырга торганда уникe купеның җидесендә генә пассажирлар булганлыктан, ул бу рейсның чагыштырмача жинел булачагын да чамалап өлгергән иде инде. Тик, шулай да, берүзенә ике билет алган пассажир аның күңеленә шик-шөбһә, борчу кертте. Юкса, озын юлда ул бераз гына акча-төшем керәсенә дә өметләнми түгел иде. Бер генә танышын да очратырга атлыгып тормаган пассажир ашыгып купесына керде, чөнки теләсә нинди очрашу да аның планнарын челпәрәмә китереп ташларга мөмкин иде. Хәтта планның берничә запас варианты булса да.

"Булды бу!"—дип куйды ул үзалдына елмаеп һәм купега күз төшерде. Вагон яңа, җайлы һәм чиста иде. Йокы кирәк-яраклары пөхтә итеп төреп куелган, идәндә затлы келәм, өстәлдә савыт-саба... Болар барысы да аның күңелен күтәреп җибәрде. Бик тар даирәдә һәм бик азлар гына Сенатор дип белгән, киң катлау даирәләрдә исә Сухроб Әкрәмхуҗаев буларак танылган пассажир тынычланып ишектәге көзгегә карап чәчләрен төзәтте, үзендә дулкынлану, ашыгу-кабалану галәмәтләре сизелмәвенә ул разый-канәгать калды.

Вагонда артык җылы иде, ул ашыкмыйча гына пиджагын салды, аны элгәндә кесәсеннән күнегелгән хәрәкәтләр белән сигаретларын һәм уткабызгыч чакмасын чыгарды; нәкъ шул мизгелдә поезд кузгалып та китте.

Үтә комфортлы купе пассажиры тәрәзә яныннан артка шуышучы вокзал перронына күз салды һәм шундук бина өстендәге дүрт хәрефне шәйләп алды: "...КЕНТ". Ул тәтенсыман соры төстәге каптан бер сигарет тартып чыгарды, затлы чакмасын чыкылдатты. Сигарет та, зажигалка да "Кент" фирмасында

эшләнгән әйберләр иде, ләкин хәзер вокзал бинасындагы "...КЕНТ" хәрефләре белән кулындагы "Кент" сигареты һәм чакмасын чагыштыру баягы кебек елмаю тудыра алмады. Аның уйлары экспресстан да алдарак чаба иде инде.

Алда ни гамәлләр кыласын кат-кат уйлап ул бер ун минут тирәсе тын гына утырды, шулвакыт сак кына ишек кактылар һәм купе ишеге ачылып китте. Вагон хадиме үзенең шәхси запасыннан кайнаткан чәй алып керде, шушы гадәти эш-гамәле аша ул мөһим пассажир белән сөйләшүендәге, үзе санаганча, итагатьсезлекне йомшартырга теле иде булса кирәк. Чөнки, ни дисән дә, үзенең мәгънәсез соравы өчен үкенә иде әле ул. Проводник өстәлгә фарфор чәйнек һәм пиала куйды, тагы нәрсәләр алып килергә кирәклеген сорады, әмма пассажирның аны күрмәвен дә, ишетмәвен дә сизенгәч, купедан чыгып таярга мәҗбүр булды. Бу галстуксыз кеше аңа һич тынгылык бирми иде, шуңамы ул хәтеренә үзе белгән обком секретарьларын, сәүдә базасы директорларын хәтереннән үткәрде—кондуктор аларга юл буе хезмәт күрсәтеп бара торган иде—әмма йомшак-тыныч атлап йөрүче бу кеше исенә төшмәде. Пассажирның үзен борчулырак тотуы бик үк күзәтүчән булмаган кешенең дә күзенә ташланырлык иде шул. Әлбәттә, кондуктор кыйммәтле Америка сигаретларын да, затлы уткабызгыч-чакманы да күрде, Ташкенттан Наманганга кайткан фырт егетләр аны сыйлаганда, бер генә мактанмаганнар иде: сигаретның пачкасы ун сум имеш! Андый кыйммәтле сигарет тартучыга ихтыярсыз хөрмәт белән карый башлыйсың инде ул.

Вагон хадиме чыгып китүгә, Сухробның эчәсе килеп китте һәм ул рәхәт ләззәт хисләре тоеп, пиалага тутырып чәй агызды. Самаварда күмер белән кайнатылган, яхшылап пешерелгән хуш исле чәй күңел киеренкелеген йомшартып җибәрде, һәм ул, тиз арада чәйнекне бушатып өлгергәч, озаклап тәрәзәгә карап барды; аның алдагы эшләр хакындагы уйлардан беразга булса да арынып торасы килә иде. Тәрәзәдә Ташкент янындагы бистә күренешләре чагылып узды, төн галиҗәнаплары табигатьтә хакимлекне үз кулына алып килә иде инде. Ул сәгатенә карап алды. Бервакытта да иртә ятарга яратмаса да, аңа яхшылап ял итәргә кирәк иде. Әйе, иртәгә көн катлаулы булачак, әле кире кайтасы да бар, дүшәмбе, һәрвакыттагыча, сәгать унда эштә булырга кирәк. Аның эшкә килмәвен, хәтта бер сәгать соңга калуын да күрми калмаслар иде, ә ул үзенә шикләнеп карауларын теләми.

Пассажир беләзегеннән сәгатен салды, "Ролекс"ның уяткыч-будильнигын төнге дүрткә куйды, ул йоклап калырга тиеш түгел, юкса качып-посып барып-кайтып йөрүләренең яшеренлеге юкка чыгачак. Аны, әлбәттә, вагончы да уята ала иде, тик Сенатор моны теләмәде, әгәр кондуктор аның кайсы станциядә төшеп калганын белсә, кызыксынырга теләүчеләр аның кая юл алганын төшенеп алачаклар, ә моны һич кенә дә белгертергә ярамый иде. Әгәр берәрсе аның яшеренеп кенә тауларга барып кайтканын белә калса, бу аның хезмәт карьерасында чып-чын һәлакәткә тиң булачак.

Карьера югалту кая, бу юлның төрмәгә илтүче юл булуы да ихтимал, ә моның һичшиксез шулай булганлыгын ул яхшы белә, шуңа күрә һәр адымын үлчәп кенә атлый. Сухроб алтын сәгатьнең күңелне иркәләүче авырлыгын тоеп, кулында биетеп алды, шуннан соң гына аны сигарет һәм чакма белән янәшә өстәл өстенә куйды. Әмма сәгать үзенә тарта иде, ул аны кабат кулына алды, кульяулыгы белән бер генә сыдырылган урыны да күренмәгән сапфир пыяласын озаклап сөртте, авыр беләзегенең алтынын чистартты. Аннан еш кына: "Әллә, чыннан да, алтын сәгатьме ул?" дип сорыйлар иде. Ә ул: "Сез нәрсә? Охшатып ясалган инде шунда. Дөрес, әйбәт фирма ясаган анысы!"— дип гел бер төрле җаваплар белән котылып килде. Шәхси әйберләре арасында аның моннан да артык яраткан әйбере юк иде.

Аңа "Ролекс"ның зурлыгы, матур ялтыраган алтыны, төтенсу платина циферблаты, төнлә яктырып торучы телләре һәм, әлбәттә, үтә төгәл йөрүе ошый иде. Мондый сәгатьне аның бары берничә зур дәүләт эшлеклесендә генә күргәне бар, шунадырмы, горурлык хисе күкрәкләрне ташып чыгарлык иде шул. Кинәт кенә исенә Рәшидовны күмгән көннәр төште, бу "Ролекс"ка ул нәкъ шул көннәрдә ия булган иде бит.

Ә ана кадәр бер көн элек якын дуслары Рәшидовның Каракалпак башкаласы Нукуста, инспекция тикшерүе вакытында, үзенә туган тиешле кеше—өлкә секретаре Камалов янында инфарктан кинәт кенә үлеп китүен хәбәр иттеләр.

Бу яналык Үзбәкстандагы хәлләрне азмы-күпме белгәннәр өчен аяктан егарлык иде. Иң зур республикаларның берсенең Хуҗасы, идарә эшләрен дә, кадрлар мәсьәләләрен дә, башкаларын да бер үзе хөкем кылган, еш кына күпләрне үзенең колачлылыгы белән таң калдыра белгән кеше вафат. Житмәсә, ул күптән түгел генә гүр иясе булган генсек Брежневның дусты, Мәскәүдәге олы түрәләренең әшнәсе иде, байтак эшләрен алар аша рәткә сала алган кеше иде. Дөрес, Брежнев урынына калачак Андропов ул кылган "эшлекле" гамәлләргә бервакытта да шаккатмаган диләр, аның дусты да булып саналмаган, әле киресенчә түгел микән? Соңгы вакытларда Мәскәү эмиссарлары Ташкент туфрагын еш таптый. Алар инде кояшлы республиканың туктаусыз җинүләрен мактау өчен килмиләр, күрәсен, кулларында башка мәгълүматлар дә бардыр.

Шулайдыр. Әле күптән түгел генә Мәскәү кешесе килгән, алар икәүдән икәү генә калып биш сәгатьтән артык сөйләшкәннәр, Шәрәф Рәшидовичның соңгы сәяхәтенә кәефсез китүе дә шуннан диләр. Боларны Сухроб соңыннан гына ишетте. Һәм менә—инфаркт. Аппарат һәм зур түрәләр арасына шундук шик-шөбһә, борчылу килеп керде.

Ул вакытта Әкрәмхуҗаев Ташкентның бер районында прокурор булып эшли иде, юридик фәннәр кандидаты булса да, югары күтәрелергә артык өмет багламый иде. Чөнки ул өметләнгән урыннарда утыручы кешеләр белән аның тартышыр көче юк, һәрберсе артында бай һәм сүзе үтә торган кланнар тора, әле кайберләре Рәшидов һәм аның якыннары белән дә бәйләнгән. Ә ул Шәрәф Рәшидовка, күпме азапланса да, бер карыш та якыная алмады. Ни кызганыч! Хәтта бервакыт: "Бу Сухроб Әхмәтович нигә яшь-яшь башы белән хакимияткә ыргыла икән? Аның вакыты килмәде әле!"—дип, яратмыйча әйткән икән дип тә сөйләнделәр. Шуннан соң кайберәүләр аны район прокуроры урындыгыннан да тартып төшермәкче булды, ләкин ул үзен күрсәтә алды: кемнедер тешләп өзмичә, постын беркемгә бирмәячәген яхшы ук аңлатты.

Олы хуҗаның вафаты турында ишеткән көнне республика прокуратурасында ниндидер чираттагы кинәшмә булырга тиеш иде, бу хакта алдан ук белдерелгән, хәтта үлем турындагы хәбәрдән дә алдарак иде.

Гоголь урамындагы бинага Сухроб билгеләнгән вакыттан шактый алда килде, чөнки кайбер хезмәттәшләре белән очрашуга ният тота иде, алар республикадагы хәлне төгәлрәк белмиме икән, хакимияттә булачак яңа курс һәм сәяси вәзгыятьне чамалау мөһим иде ана. Үзәк Комитетның Беренче секретаре вафаты турында белдерүләр рәсми рәвештә матбугатта, радиотелевидениедә игълан ителмәсә дә, республика прокуратурасында бу яналыкны һәркемнең белүе сизелеп тора иде инде.

Ләкин шунысы аптыратты: ул килгәндә житәкчелектән дә, хезмәттәшләреннән дә беркем дә юк иде әле. Власть алышынганда югарырак күтәрелеп калу шансын чамалау өчен, көчле кланнардан, туганнарыннан ярдәм сорарга чыгып чапканнар, күрәсең. Шулай да ул юкка гына килмәгән булып чыкты. Соңыннан ул көнне булган вакыйганы анализлап, ул моны язмыш бүләге, югарыдан бирелгән, Ләүхел-мәхфүздә язылган дип уйлый башлады.

Ул икенче каттагы коридор буйлап киң холлга илтүче мәрмәр баскычка таба бара иде, кинәт кенә астагы ишек ачылды һәм вестибюльгә кулына "дипломат" тоткан ап-ак чәчле өлкән яшьләрдәге кеше килеп керде. Бер секунд үтүгә, аның артыннан спортчы кыяфәтле егет атылып килеп керде, аның яклау эзләп прокуратурага килеп кергән "дипломат" иясен эзәрлекләве әллә каян күренеп тора иде. "Дипломат"лы кеше баскычка йөгереп менде, Сухроб, ана ярдәмгә килә алса да, колонна артына посты һәм алга таба ни булырын көтә башлады. Баскычтан йөгереп менүчегә икенче катка житәргә берничә генә басма калган иде инде, кинәт ул абынып китте һәм "дипломат"ын кулыннан ычкындырды. "Дипломат" аска, эзәрлекләп килү-

ченең нәкъ аяк астына барып та төште. Анысы күз ачып йомганчы "дипломат"ны эләктереп тә алды, тупас сүгенеп, аяк астына тәгәрәгән кешегә китереп типте. Посттагы милиционер, күрәсең, хәлне аңлап алган иде, кобурасын ычкындыра-ычкындыра тарткалашучыларга таба килә башлады. Аның якынаюын күреп, спортчы кыяфәтле егет пируэт ясагандагыдай житезлек белән борылды, күкрәгән "дипломат" белән каплап, усал тавыш белән ысылдады:

—Атай, пушканны ташла, юкса атып үтерәм!

Чыннан да аның кулында кара төстәге авыр пистолет елтырый иде. Милиционер калтыранган кулы белән коралын читкә ыргытырга мәҗбүр булды. Шунда бөтенләй көтелмәгән хәл булды: идәнгә егылган карт бар ихтыярын, көчен җыеп аягына басты һәм эзәрлекләүченең кулына ябышты:

—Мин сине кисәттем бит, Коста, беренче очрашуда ук, безнең юллар хокук храмында кисешәчәкләр, дидем...

"Дипломат"ны эләктергән егет мыскыллы көлемсерәде, картны ул комачау ясардай адәм итеп күрми иде булса кирәк, кискен итеп кулын тартты, әмма ычкындыра алмады, озак уйламыйча, корбанын йөзе белән идәнгә бәрде. Вестибюль стенасына кан чәчрәде, әмма "дипломат" хуҗасы үзен эзәрлекләүчене ычкындырмастай итеп ябышкан иде. Сәер "дипломат"ны аулаучы берничә секунд вакытны санагандай торды, ләкин менә-менә холлда яисә баскычта кем дә булса күренәчәк, ул вакытта чыгып сызу авыр булачак—ул, ике дә уйламыйча, картка терәп диярлек атып җибәрде, аннан ярсуын баса алмыйча тагын, тагын атты.

Шул мизгелдә бина ишеге ачылып китте һәм холлга милиция киемендәге кеше атылып керде. Сухроб аны бер карауда ук танып алды: бу республика угрозыскы начальнигы полковник Чураев иде, аның кеше ышанмаслык батырлыгы һәм куркусызлыгы турында күптән инде легендалар йөри. Полковник ишек тупсасыннан ук диярлек Коста исемле кешегә сикерде, аны ниндидер алым белән икегә сындырды да пистолетын идәннән эзләп маташкан милиционерның аяк астына, стена буена ыргытты һәм канга баткан "дипломат" хуҗасына иелде.

Ату тавышларына кабинетларның ишекләре шартлап ачылды, йөгерешеп чыкккан кешеләр, соңлап булса да, ярдәмгә, вестибюльгә ташландылар. Кан чәчрәгән холл уртасында барысына да таныш полковник Чураев утыра, ул кемнеңдер канга баткан башын тоткан һәм күз яшьләрен тыярга тырышып пышылдый иде:

—Гафу ит, прокурор, өлгермәдем, гафу ит...

Чураев авызыннан "прокурор" сүзен ишетүгә, поскан колонналары артыннан әле һаман чыкмаган Сухроб әлеге серле "дипломат"ны прокуратурага китерү өчен гомерен биргән кешенең кем икәнен аңлап та алды. Бу, әлбәттә, элеккеге өлкә прокуроры Азлархановl Йа, Ходаем, ничек картайган ул, чәчләре агарган, әле алты-җиде ел элек кенә бөркет булып йөри иде бит. Сухробның аны төрле җыелыш-киңәшмәләрдә күргәне булды, ул вакытларда аның исеме теллән төшми иде. Аны данлы карьера көтә дип юрый иделәр. Көнләшүчеләр һәм дошманнары телендә Азлархановның исеме "реформатор" иде. Соңыннан аның хатынын үтерделәр, үзе ул ниндидер керамикамы, әллә фарфор коллекциясе беләнме яман күңелсезлекләргә дучар булды һәм аның тормышы аска тәгәрәде. Хәтта аны хастаханәдә инфарктан үлгән икән, дип тә ишеткән иде Сухроб.

Азлархановның соңгы еллардагы тормышын юньләп белмәсә дә, прокурорның ниндидер көчле, якын-тирәдәге бар байлыкны үз кулында тотучы нәсел белән бәрелешкә кергәне ишетелгән иде аңа. Әле генә күргәннәре исә Азлархановның соңгы минутларына кадәр үзеннән өлкә прокуроры вәкаләтләрен төшермәгәнен сөйли иде. Чыннан да, бик көчле кеше булган бу дип, битараф кына уйлап куйды Әкрәмхуҗаев. Аның бу уй-версиясен сатылмас полковник Чураев та раслап тора иде кебек. Әле моннан биш еллар чамасы элек кенә Ташкенттан килгән полковник законны санга сугарга яратмаган байтак бәндәләрнең ашына кара таракан булып төште, әле дә каннарын бозып тора. "Башыбызга кайдан төшкән бәла булды соң бу", дип

аптырый иде Сухробның дуслары аның хакында. Гәрчә, аны угрозыскка утырту өчен Азлархановның озаклап кодалап йөрүе, Эчке эшләр министрлыгында бу хактагы мәсьәләне нәкъ менә аның күтәрүен ачык беләләр иде. "Дөреслек өчен көрәшүче тагын берәү китеп барды",—дип, усал гына уйлап куйды Әкрәмхуҗаев һәм шулчак үзенең фаразларын раслаган тавыш ишетте:

—Иптәшләр, бу бит Әмирхан Даутович Азлархановлархов, хәтерлисезме, бездә өлкә прокуроры булып эшләгән иде...—Тирә-яктагылар шаулашып алдылар, элеккеге коллеганың вафаты бигрәкләр дә сәер һәм көтмәгәндә иде шул.

Район прокуроры бу тавыш-болганышта сиздерми генә ишектән чыгып, машинасына утырып китәргә теләгән иде, әмма аның башында көтелмәгән фикер-хыял туды: әгәр кейстагы документларны эләктерсәм, мин югарыга тиз күтәрелер идем! Күп кенә галиҗәнап әфәнделәр: министрлар, депутатлар минем дус булырга тырышырлар иде, ә мин кемне коткарырга, кайсысын төрмәдә черетергә икәнен үзем белер идем. Юк-бар өчен генә прокурор Азларханов үз тормышын куркыныч астына куймас иде—андый кеше түгел!—ул һәрвакыт безнең эштә радикаль үзгәртүләрне күтәреп чыкты, законнарның беренчелеге, югарылыгы, хокукый дәүләт турында хыялланды, димәк, ул бик эре "җәнлек" эзенә төшкән, юкса аны прокуратураның үзендә үк атып үтермәсләр иде. Документлар тулган кейс белән бергә Коста исемле хәтәр егетне эләктерү дә начар булмастыр, бернәрсә алдында да куркып-тукталып калмыйча, бурычын ахыргача үтәүче мондый "боевиклар" бик тә кирәк дип, үз-үзен кыздыра төште колонна артында качып торучы Әкрәмхуҗаев. Өске каттан ул дежур торучы яшь кенә кешенен "Ашыгыч ярдәм" сорап, врач таләп итеп шылтыратканын күрде, хәер, Азлархановка бернинди ярдәм кирәк түгел иде инде. Ә менә дивар янында бөгәрләнеп-кәкрәеп газапланып ятучы Костага ул кирәк, полковник Чураев аның арка баганасын имгәткән кебек.

Калырга башка сәбәпләре булмаса да, район прокуроры китәргә ашыкмады, нидер аны колонна янында тотты, шайтан колагына пышылдый иде: уйла, уйла, югарыда утыручы байтак кешеләрнең сере синең кулда булачак. Бу уйларыннан аңа эссе булып китте, ул муенын сузып галстугын бушата төште. Күрәсең, йөзе агарып та киткәндер, чөнки яныннан йөгереп баручы таныш тикшерүче: "Сез авырыйсызмы әллә?"—дип сорап узды.

Әкрәмхуҗаев үзенә булган күз-карашлардан куркып елмайгандай итте, астагы хәлләр белән чагыштырганда үземне менә дигән итеп сизәм дигәндәй, кулын селкеп куйды.

Канга баткан прокурорны носилкага салуга, Чураев тиз генә үзен чолгап алган кешеләр арасыннан чыкты һәм телефонга ташланды, бераздан вестибюльне янгыратып кемгәдер приказ биргәне ишетелде: "Ашыгыч рәвештә барлык ГАИ постларына хәбәр итегез: ТНС 85-04 номерлы ак "Жигули"ны тотсыннар! Шәһәрдән чыгу юлларын ябыгыз, сак булыгыз, җинаятьчеләр коралланган, уйлап та тормастан атарга мөмкиннәр".

Прокуратурага килгәндә үк "угрозыск" начальнигының үткер күзе Костаны көтүче ак төстәге шикле машинага төшкән иде инде, полковникта беркайчан да уяулык хисе сүнеп тормый, һәр детальне хәтеренә сеңдереп бара торган затлардан иде ул.

Әмма телефон трубкасын куюга борчылып әйтеп куйды:

—Шау-шуны юкка күтәрдем ахрысы, профессионалларның номерлары ялган, машиналары урланган була.

—Сез хаклы, әмма постовойлар саграк эш итәчәк, юкса алар кайчак кешеләргә ышанып күпләп һәлак булалар,—диде кемдер.

"Угрозыск" начальнигы телефоннан сөйләшкәндә дә, кешеләргә нәрсәдер аңлатканда да кулындагы "дипломат"ын ычкындырмады, күрәсең, анда ни барлыгын, аларның бәясен, кыйммәтен белә иде ул. Монда да юкка кермәгән иде ул, бары Азлархановлархов белән очрашырга күпмедер соңга калды.

Сухробның колаклары үткен иде, Чураев белән прокуратураның бүлек начальнигы сөйләшкәннән үзе кулга төшерергә теләгән кейсның икенче каттагы сейфларның берсендә бикләнеп калачагын да аңлап алды. Полковник Чураев бу кейсны үзе белән ала алмый, чөнки министрлыкта Азларханов

документларын юкка чыгарырга теләүчеләр аз түгел. Бервакыт өлкә прокуроры МВД югары чиннарының мафия белән элемтәләре турында кисәтте инде, бүгенге безнең очрашу турында җитәкчеләрең белмәскә тиеш, диде.

Алга таба планнар корунын мәгънәсезлеген аңлаган Сухроб колонна яныннан тайпылып, аска ашыкты, Чураев янына атлаганда, ике адым җитмирәк туктап калды: аның күзенә ташланмау хәерлерәк булыр.

Полковник "дипломат"ны прокуратураның тикшерү бүлеге начальнигына сузды:

—Үзегездәге сейфка бикләгез, аңарчы башка берәр бүлектәге хезмәттәшегез каршында шнурлагыз, пичәтләгез, андагы кәгазьләр бик күпләрнең тормыш бәясенә тора, зур кешеләрнең... Иртән үз кулыгыз белән республика прокурорына тапшырырсыз, бүген ул килмәс, Үзәк Комитетта ашыгыч киңәшмә. Чамалавымча, кара төнгәчә сузылачак әле ул...

Сухроб элегрәк республика прокуратурасының тикшерү бүлегендә аеруча мөһим эшләр буенча тикшерүче булып эшләп алган иде, бүлекнең начальнигын да яхшы белә, аның белән аралары әйбәт, нәкъ менә ул аңа район прокуроры булып күтәрелергә ярдәм иткән иде.

Кәефе төшкән Әкрәмхуҗаев күпмедер вакыт колонна янында басып торды әле, нәкъ менә шушы урыннан ул республика прокуратурасын тетрәткән фаҗигане җентекләп күзәтә алды. Күзләре күрде, колаклары ишетте: МВД врачы прокурор ярдәмчесеннән травматология институтында Костага рентген үткәрүләрен үтенде, үзләрендә ул аппарат инде өченче ай эшләми икән.

Аста ике җыештыручы хатын идәндәге канны сөртәләр, вахта милиционеры башын иеп утыра, иртәгә аңа яңа эш эзләргә кирәк булачак, ә бит пенсиягә өч кенә ел калган иде. Алда аның соңгы дежур сәгатьләре, дөресен әйткәндә, бу бинада төн чыгу аны шактый шикләндерә иде, күз алдында кеше үтерсеннәр әле.

Сенаторның да кәефе һич тә вахта милиционерыныкыннан яхшырак түгел иде. Ул машинасын кабызды да әкрен генә бөтен Ташкентта мәшһүр Алай базары ягына юл тотты, миендә уйлар өермәсе купты: эшкә барырга кирәкме, юкмы? Шулвакыт бушап калган урамда каршысына килүче ТНС 85-04 номерлы ак "Жигули" күренде. Әкрәмхуҗаев полковник Чураевның ГАИ постларына биргән фәрманын яхшы хәтерли иде әле. Угрозыск начальнигы машинасын күргәч Костаның "дуслары" берәр ишек алдында качып яткан булганнардыр, хәзер менә үзләренең группа әгъзасы язмышын белергә телиләрдер.

Сенатор үзе дә сизми калды, куллары пультка үрелде, машина фаралары куркыныч барлыгын белдереп күз кысып алды. Шоферлар, гадәттә, берберләрен ГАИ засадасы турында шулай кисәтәләр. Рульдә зур кара күзлекләре ярты йөзен каплаган ябь-яшь егет утыра иде. Машиналар тигезләшүгә, ак "Жигули" клаксоны "рәхмәт!" дигәндәй тавыш бирде, моның өстенә яшь егет ачык тәрәзәдән бала башыдай йодрыгын күрсәтеп узды. Ак "Жигули" тизлеген бер генә мизгелгә дә киметмичә узып та китте, район прокуроры арткы утыргычка сеңгән тагын ике кешене күреп калды. Алар, табигый ки, аның машина номерларын күрделәр, бер-ике сәгать үтүгә, шиксез, кемнеке икәнен дә беләчәкләр һәм сөенергәме моңа, әллә көенергәме, дип аптырап калачаклар. Әкрәмхуҗаев нәрсәнедер хәл иткәндәй йодрыкларын төйнәде, эшкә бармаска булды һәм иске мединститут ягына юл алды.

Травматология институты яныннан узганда, ул иске санитар машинадан врач белән озата килүче хезмәткәрнең Коста яткан носилканы иплəп кенә чыгаруларын һәм бинага алып китүләрен күреп калды. Эш көне бетеп килә, ашыгыч рәвештә рентген рәсеме кирәк, моны врачка ярдәмгә килгән шофер да аңлый иде. Алар шулай өчәүләп казармага охшаган бинаның баскычлары буйлап йөгереп диярлек менеп киттеләр.

Прокурор Әкрәмхуҗаев дистә еллар буе ачык-җимерек тәрәзә-ишекләре белән куркытып торган һәм дәүләтнең дингә карашын ачык күрсәткән ташландык поляк костелына барып җитүгә, кинәт кенә уйлап куйды: "Ну, ярар, зур түрәләрнең яшерен серләре тутырылган "дипломат" мина эләкмәсен ди, тик, әгәр дә тырышсам, көч куйсам, Костаны кулга төшерә алам ич,

андый егет бурычлы булып калмас, анын хужаларынын да тормышта кирәк булуы бар". Һәм ул машинасын кырт кына кирегә борды—анарда сунарчы хирыслыгы уянды, холкындагы авантюристлык көтелмәгән куәт белән калкып чыкты. Хәер, ул бу тәвәккәллекнен башсызлык түгел икәнен яхшы аңлый. Костанын язмышы күп яктан тормышта һәрчак булып торган тәртипсез буталчыкларга бәйле һәм бу эштә дә нәкъ шулай булачагына анын иманы камил иде.

"Керергә ярамый" дигән язулы тактаны күрсә дә, прокурор институт ихатасына килеп керде, хәер, ул тормышта моннан усалрак "ярамый"лар белән дә чутлашып тормый иде. "Жигули"ен розарий янында калдырып, ул бинага арт ишектән керде, шул арада рентген бүлегенен кайдалыгын сорашып белергә дә өлгерде. Озак эзләп йөрисе дә юк икән, рентген рәсемнәрен беренче катта ясыйлар иде. Төрмә хезмәткәрен еррактан күрде, ул, берүзе генә як-ягына каранып, коридорда тора, ә ябылып бетмәгән ишектән кемнәрнендер бәхәсләшеп ятулары ишетелә иде.

Сакчынын игътибарын җәлеп итмичә генә ишек янында һич югы бер минут туктап алырга, эчтә ни-нәрсә хакында сүз барганына колак салырга кирәк иде. Шуны эшли алса, җинаять эшләрендә бер пот тоз ашаган прокурор хәлне аңлаячак һәм үзе корган планга туры килү-килмәвен чамалый алачак иде. Сенатор сакчы янына килде дә кесәсеннән сигарет чыгарды:

—Туганкай, шырпың юкмы?

Тегесе төрле вак-төяктән кабарып торган чалбар кесәсендә шактый озак кармаланып шырпы эзләде. Ул кабызган беренче шырпыны Сухроб-Сенатор ялгышкан шикелле сиздермәстән сүндерде, бары икенче шырпыдан гына кабызып алды. Кыйммәтле, затлы сигаретнын хуш исенә кызыккан төрмә хезмәтчесе үзе дә тартырга сорады һәм прокурор юмарт байларча кыланып, аңа тулы пачкасын сузды.

Шул арада ул таныш булмаган тавышларны ишетеп тә өлгерде. Кемдер ризасызлыгын яшереп тә тормыйча, кычкырып аңлата иде:

—Минем хәлемә дә керегез. Безнен дә ял көне бар. Рентгенолог китте инде, установка токтан өзелгән. Иң яхшысы, авыруны изоляторда калдырыгыз, иртән клизма ясарбыз да сәгать уннарга рентген рәсеме әзер булыр.

—Аңлагыз, без аны төнгә калдыра алмыйбыз, ул җинаятьче, ул сак астында булырга тиеш,—дип үзенекен тәкрарлады МВД медсанчастеннән килгән табиб.

Җавапка көлеп кенә куйдылар:

—Сәер кеше икәнсез, иптәшкәем, умыртка баганасы сынган кеше кая качсын, ди?! Житмәсә, икенче каттан... Ул хәтле курыксагыз, сакчысы да калсын. Изоляторда урыннар икәү. Мин каршы түгел. Кичке ашны да оештырырбыз...

Барысы да аңлашылды, алга таба тыңлап торуның кирәге калмаган иде инде, изоляторның кайдалыгын белешер өчен Әкрәмхуҗаев шыпырт кына икенче кат баскычына таба юнәлде. Шул арада врачның сакчыга дәшкәнен дә ишетеп өлгерде:

—Сабиров, сиңа монда кунарга туры киләчәк...

Икенче катта авыр яралылар бүлеге булганлыктанмы, коридорда кешекара юк иде. Бары тик "Изолятор" дип язылган палата белән янәшәдәге туалеттан кулына чиләк тоткан җыештыручы хатын чыгып килә иде. Прокурорга барысы да аңлашылды. Уйлаганнарын тормышка ашыру өчен бер генә деталь җитми иде инде. Һәм ул анысын да хәл итте:

—Зинһар, әйтегез әле, бу катта телефон кайда?—дип сорады ул җыештыручы хатыннан рәсми тавыш белән.

Нәчәлник кыяфәтле ирләрдән гомер буе куркып яшәгән карчык тиз-тиз генә аңлата башлады:

—Туп-туры барыгыз да, алтынчы палатадан сулга борылыгыз, андагы почмакта өстәл булыр, шәфкать туташыныкы...

Сенатор күп сүзле хатынга баш иеп рәхмәтен белдерде һәм кинәт, шәфкать туташынын да кирәк булачагын исенә төшереп, сорады:

—Анын исеме ничек, ул кайчан алышынырга тиеш?—диде.

—Әле генә килде,—дип тезә башлады сүзчән хатын. Күрәсең, аңа эре кыяфәтле бу адәмгә нәрсәдер аңлата алу рәхәтлек бирә иде.—Иртәнгә кадәр торачак ул, Хәлимә Насыйровна дип йөртәбез аны. Үзе бик усал нәрсә, тавыш чыгарырга дисәң, аңа куш инде, авырулар янына халатсыз беркемне дә кертми. Иң яхшысы, яңадан аска төшегез дә вестибюльдәге Нюра әбидән халат сорагыз.

—Рәхмәт, рәхмәт,—дип кабатлады шатлыгы тышына чыккан прокурор.—Киңәшегезне тотмый булмас. Ни дисәң дә, больница тәртибен бозарга ярамас шул,—дип сөйләнә-сөйләнә аскы катка төшеп тә китте.

Вестибюльдә авыр яралылар бүлегендә кизү торучы шәфкать туташының телефон номерын табу авыр булмады, бәхеткә дигәндәй, холлда да кешефәлән юк иде. Ул автомат телефоннан шул номерны җыйды һәм берничә гудоктан соң трубкада кырыс хатын-кыз тавышы ишетелде.

—Әйе, тыңлыйм сезне...

—Хәлимә Насыйровнамы?—диде Сенатор коры тавыш белән.

Телефоннан "Әйе..." дигәнне ишетүгә үк трубканы элеп тә куйды. Барысы да ул теләгәнчә бара иде. Күп вакыт эчке сиземләүгә, интуициягә буйсынып эш иткән прокурор бу юлы да оттырмаячагын сизенеп, канәгатьләнү хисләре кичерде. Кесәсеннән тагын акча алды һәм прокуратурадагы ярдәмчесенең номерын җыйды:

—Сәлим, мин хәзер килеп җитәм, кичкә эшләрең булса, калдырып торырга туры килер, ашыгыч эш килеп чыкты, дусларны да кисәтеп куй, кирәк булулары бар.

Ул сәгатенә күз төшерде һәм авыр мәсьәләне хәл иткән кешедәй җиңел сулап куйды, башыннан исә кискен уй йөгереп узды: шушы минуттан катлаулы операция башлана, чигенергә урын да, вакыт та юк.

Болай да шәһәрдә кызу йөрергә яраткан прокурор, алда торган эшләр азартына бирелеп, янгынга чапкандай очты, аны туктатырга хокуклары булмаган ГАИ хезмәткәрләренә һәм постта торучы милиционерларга баш чайкап кына калырга туры килде. Үз районында аңа хәтта "честь" биреп калдылар, машинасына "яшел урам" ачтылар.

Кайчандыр университетта бергә укыган сабакташы, хәзер ярдәмчесе булып эшләүче Сәлим ишек төбенә чыгып каршы алды. Телефоннан боерык биргәндәй әйтелгән кыска-кыска җөмләләрдән үк ул шефының ниндидер зур эш майтарырга җыенганын аңлаган иде инде, чөнки байтак еллар бергә әвәрә килгән әшнәләр, кәрт уенындагы шулерлар кебек, бер-берсен ярты сүздән аңлыйлар иде.

Әнә шул сыйфатлары аркасындамы, әллә максатлары бер үк төрле булуданмы, соңгы елларда зур түрәләрнең яраткан шөгыленә әйләнгән кәрт уенында да алар маһирларча эш итәләр, үзләренә икърар итмәсәләр дә, шактый оста шулерга әйләнгәннәр иде инде. Мәктәп елларыннан ук алар гел бергә булдылар, хәтта кемдер аларга "сиам игезәкләре" дигән кушамат та таккан иде. Танылганрак, күренеклерәк нәселдән булган Сухроб бу бергәлекнең башында тора иде кебек. Ләкин бу читтән караганда гына. Чынлыкта, Хашимов дустыннан бер яктан да калышмый, хәтта тактика мәсьәләләрендә күпкә өстенрәк тә иде әле, шунлыктан, иң куркыныч операцияләрне оештыру аның өстенә төшә иде. Юкка гына кушаматы да Миршаб түгелдер. Миршаб[1]—ягъни, төн патшасы. Гомумән, алар бер-берсенә иш килгән сирәк кешеләрдән иде!

Кабул итү бүлмәсенә кергәч, болай да тавыш йоткыч ковролан белән тышланган тышкы һәм эчке ишекләрне тыгызлап ябып куйдылар. Йөзенә күз салуга ук, Сәлим Хәсәнович шефының ниндидер гадәти булмаган нәрсә маташтырырга йөрүен сизеп алды, шуңамы, сүз башына хәйран калмады да.

—Беләсеңме, Сәлим, без бүген синең белән закон бозарга тиеш булабыз...—Прокурор тавышында шундый да тантаналы янгыраш ишетелде ки, ярдәмчесе теләмәстән елмаеп куйды һәм төрттермичә түзә алмады:

—Ялгышмасам, без моның белән күптән шөгыльләнәбез инде...

Кабинет хуҗасы көтмәгәнчә җитди җавап кайтарды:

—Моңарчы башкарган нәрсәләр чүп кенә, вак-төяк, мескен омтылыш-

лар... Андый кыланышлар өчен җавап тотуы да оят, билләһи. Минем уйлаганым сәясәткә, хакимият өчен көрәшкә кагыла, ул безне яңа тормыш даирәләренә, бөтенләй башка үрләргә, омтылышларга, башка кабинетларга алып чыгарга тиеш.—Прокурор, беренче тапкыр күргәндәй, тирә-якка чирканулы караш ташлап алды.

Аның артыннан ярдәмчесе дә кабинетны күзе белән сөреп чыкты, әмма кимсетә торган мескенлек күрмәде. Бу бүлмәне бизәү өчен заманында аз акча түкмәгәннәр иде. Әмма бүлмә хуҗасына каршы төшүне кирәк тапмады, чөнки дусты дәртләнеп, ялкынланып тагын сөйли башлаган иде инде.

—Кырыктан уздык, дөньяда урыныбызны табар вакыт җитте. Кайчанга кадәр сәләтсез бәндәләргә самавырчы малай булып йөрербез? Аларның бөтен өстенлекләре югарыдагылар белән әшнәлектә, акча капчыклары белән туганлыкта гына бит. Бүген безгә дә язмыш шундый мөмкинлек бирә. Бугазларыннан алачакбыз әле, безгә дә саекмас табын янында урын табарлар, кысрыкланырга мәҗбүр булачаклар.

Ул кинәт туктап калды, сигарет кабызды һәм, түшәмгә төтен балдаклары җибәрә-җибәрә, гадәти рәвештә сөйләп китте:

—Син хаклы ансы, икәүләшеп без шактый законсыз гамәлләр кылдык бугай. Руслар "Семь бед—один ответ" диләрме әле. Мин аны никадәр гөнаһ кылсаң да, җавапны бер тапкыр бирәсе, дип аңлыйм. Бәлки ялгышамдыр. Шунысында иманым камил, яңа гөнаһыбыз искеләрен каплап китәр. Бу хакта да уйладым мин. Заманалар үзгәрде, болгавыр көннәр килде. Алдын-артын уйламыйча эш итеп булмый. Безнең яклар өчен берни дә җәлләмәгән Леонид Ильич вафат. Шул кайгыны күтәрә алмаган дусты Шәрәф Рәшидович дөнья куйды, Кремльнең яңа сәясәте, аның яңа хуҗасы Андропов мин белгән кешеләрнең барысын да өркетеп тора. Шуңа күрә, кадерле Сәлим, мин ва-банк уйнарга карар бирдем дә. Шушы минуттан эшкә тотындык дип исәплә. Ә исәп зурдан булачак!

Прокурор кискен хәрәкәтләр белән урыныннан торды, урам якка караган зур тәрәзәләрдәге калын пәрдәләрне ябып куйды, ут кабызып җибәрде.

—Хәзер операциянең беренче этабын башлыйбыз, ул минемчә, катлаулы түгел, ә соңрак, "Время" программасы узгач, аның төп өлеше турында да әйтермен,—диде ул тавышына тәвәккәллек чыгарып.

—Син миңа ышанмыйсыңмы?—дип, аптырап сорады Миршаб.

—Ышанасыңмы, ышанмыйсыңмы... Андый сүзләрне оныт. Икебезгә бер бау сабынлап куелган инде. Мин синең операцияне кире кагуыңнан куркам, бәлки, сине тыңлап йомшап, җебеп калырмын да, аннан соң гомерем буе кулыма эләккән алтын балыкны ычкындырдым, дип газапланып яшәрмен. Өч сәгатьтән Костаны кулга төшерсәк, аннан соң чигенергә урын калмый.

—Нинди Костаны тагын?—дип сорады берни аңламаган ярдәмче.

—Менә дигән егет, кулымны кисәргә бирәм, безнең дус башкисәрләр арасында андыйлар юк. Карале, теге чибәркәең, Нәргизең өендә аш-мәҗлес әзерләтеп куй. Ана яхшы җир кишәрлеге белән өй сатып алганыңны ишеткән идем. Костаны шунда алып килерләр. Мин ул мәхәлләне беләм, әйбәт кешеләр яши, участковый да минем танышым.

—Сухроб, үтенеп сорыйм, аны безнең эшләр белән бутама, ә кунакка дигәндә, рәхим ит, үз өемдә генә түгел, Нәргиз йортында да сине күрергә без һәрвакыт шат.

—Коста анда бер көн, күп дигәндә дә, көн торыр. Курыкма, ул йортсыз-җирсез бер бәндә түгел, бары бәлагә тарыган кеше.

Шефының тавышыннан Сәлим инде мәсьәләнең хәл ителгәнлеген, үзенә исә килешергә генә калганлыгын аңлап алды.

Прокурор гасабиланып сәгатенә карап алды, аннан соң өстәл артыннан чыгып, ярдәмчесе белән янәшә утырды, күпмедер уйланып торганнан соң кызу гына сөйләп китте:

—Игътибар белән тыңла. Хәзер минем янга ОБХССтан теге хезмәткәрне чакыр, ул күптән инде, пычрагын юар өчен, миңа да, сиңа да юллар эзли.

---

[1]Миршаб (үзбәкчә)—Шәрекъта төнге каравыл башлыгы.

Мин аны үз өстемә алам, файдасы икеләтә булыр. Коста операциясен ул башкара, безгә милиция киемендәге кешене эзләп йөрүнең кирәге калмый. Шуның өстенә, ул гомере буе бабасы белән безнең капкында утырачак, шыбырдаса, больницадан кемне урлаганын исенә төшерербез, бу яңалык сыек буынлылар өчен түгел. Тагын ике кесә карагын тап, милиция капитанына ассистентлыкка алардан да кулай кеше булмас. Артистларча кылана белүче салкын канлы тагын кемне табасың. Костаны носилкага салу алар өчен чүп кенә... Әле әйтмәдем бугай, аның умыртка баганасы зыянланган булырга тиеш, ипләбрәк кылансыннар. Вәт шул! Эшне башкарып, капкадан чыгуга, дүрт яклары кыйбла! Тагын шунысы, ул "капшаучылар"га ике ак халат тап, носилка изоляторда бар. Болар өчен сиңа сәгать ярым вакыт бирәм. Костаны больницадан артык соң алырга ярамый, шик тудырачак.

—Кеше урлау, икенче кием киеп шамакайлану... Әллә нинди сәер детектив бу,—дип шаяртырга тырышты Хашимов караңгы йөз белән һәм ишеккә таба атлады, әмма каршы төшмәде.

—Нинди генә детектив әле, кадерле Сәлим, ике серияле, әле тагы йозак ватып урлашу да булачак,—прокурорның бу сүзләрен ярдәмчесе тамбурга чыккач ишетте. Шефның кәефе шәп иде, бу аның классташына ышаныч өстәде.

Ярдәмчесе кабинеттан чыгуга, Сенатор ике тумбалы өстәл тартмасыннан коньяк алып, юан тәпле бокалга койды, тәмләп йотып куйгач, янә шул ук хәрәкәтләрне кабатлады. Үз-үзенә икърар итәргә теләмәсә дә, прокурор борчыла, артык нык борчыла иде, куллары дерелди, юка бәллүрдән ясалган баккара-бокал чак кына кулыннан төшеп китмәде.

Шешәне урынына куйгач, ул ОБХСС капитаны Кодрәтов эше теркәлгән папканы алды. Моңа кадәр бу кәгазьләрне ул юньләп укымаган да, өйрәнмәгән дә иде, чөнки эшне ябачагын алдан ук сизенде, бик югарыда утыручылар күптән инде киная белән шуны аңлатырга тырышалар, аларча эшләмәсәң, яшим димә, теләсә нинди мәкер, шантаж белән каныңа тоз салачаклар. ОБХСС кешеләре белән үтә сак булырга кирәк, андагы халык иләнгәнигәүләнгән, һәркайсының җил-яңгырдан саклаучы йонлач кулы бар, ул эшкә күзләрең матур булган өчен генә алмыйлар. "Эш"не өйрәнгән саен ачуы кабарды, иреннәре арасыннан "подлец, сволочь, акыртып талаучы" сүзләре ычкынды.

—Юк, мондый кешеләргә органнарда урын булмаска тиеш!—дип, прокурор тагы өстәл эчендәге коньякка үрелде, капитанның оятсызлыгы аны чыгырыннан чыгарган иде.

Аның боерыгы буенча караклар иерархиясендә, блатной дөньяда иң югары баскычта саналучы кесә каракларын эзләү белән мәшгуль Миршаб бу минутларда котырынып утыручы шефын күрә һәм ишетә алса, рәхәтләнеп көләр иде, әлбәттә.

Ярдәмчегә бирелгән вакыт бетеп килә иде инде, шулвакыт ишекне сак кына кактылар һәм бусагада фырт киенгән капитан пәйда булды. Күрәсең, ул үзен гаепле санаган, вөҗдан газабы кичергән адәмнәрдән түгелдер, прокурор моны капитанның йөзенә чыккан ясалма кайгылы кыяфәтенә һәм бөгелеп пышылдавына да карамастан, бик тиз аңлап алды.

—Чакырган идегезме? Мин капитан Кодрәтов булам.

"Иртә азынган яшьләрдән икән... Ну, яңа буын үсә, йә, Алла!"—Прокурорның башына килгән беренче уй шул булды.

—Ничек син шундый кабахәт тормышка барып җиттең?—дип кычкырды кабинет хуҗасы ихлас күңелдән яман ачу белән һәм капитан эше теркәлгән папканы өстәлгә шулкадәр каты итеп бәрде ки, эчендәге кәгазьләр, гаризалар, шикаятьләр, актлар, экспертиза нәтиҗәләре очып чыкты, берсе исә Кодрәтовнең аяклары янына ук килеп төште. Хискә бирелүчән кеше буларак, бәлки, артыгын да җибәргәндер, ләкин бу мизгелләрдә артистлык табигате өскә чыккан прокурор, чыннан да, бу шома егетне ни өчен чакырганын да онытып җибәрә язган иде. Милиция органнарында әле бер ел да эшләмәгән обэхэсэсникнын нәфесе, ертлачлыгы, чыннан да, шаккатарлык иде.

Кодрәтов кәгазьне—азык-төлек кибете сатучылары күмәкләшеп язып

жибәргән шикаятьне иелеп алды да күз кырые белән генә булса да карап алды.Ниләр яздылар икән? Хәер, ниләр язылганын чамалый ул, күпме сумма алганын да белә. Иң борчыганы: яшь кибетчеләрне үзе белән йокларга мәҗбүр иткәнен яздылар микән? Бөтенесе дә шулар аркасында бит. Гастрономны кысуы да шуннан. Бүлек саен берсеннән-берсе яшь, берсеннән-берсе чибәр кызлар. Органнарда эшләвенең беренче көнендә үк капитан ачыш ясады: билдән түбән өлешкә сыеграк мут хатыннарны һәм җилбәзәк кызларны сәүдә ноктасына эшкә алган директорлар чистый юләрләр икән. Кибетләрендәге күңелсезлекләрнең менә яртысы шулардан килә бит. Әмма никадәр тырышмасын, үзе белән булган мәгъшукаларыннан берсенең дә йөзен күз алдына китерә алмады. Хәтта иң чибәрен дә... Алар тоташ бер масса кебек иде.

Ул калтыранган куллары белән үз өстеннән язылган шикаятьне прокурорга сузды һәм карашын читкә алды, чөнки Әкрәмхуҗаевның усал карашыннан бернинди дә яхшылык көтәрлек түгел иде.

—Йә, җавап бир, авыр тормышың турында сөйләп җибәр, ачка тилмерүче балаларың, кечкенә хезмәт хакың турында да онытма. Мин диктофонны кабыздым...

Прокурорның тагы "син нәрсә, бәдбәхет, хәсис, сәүдәне шулхәтле кыскансың, эш кешеләре ничек яшәсен, алар бер синең өчен генә урлашырга тиешмени, гомумән, кем соң син, манка, районда берүзең барысын кочагына алырга, әле бит синнән югары начальство бар, үз урыныңны бел", диясе дә килә иде. Ләкин ул моны әйтмәде, шома капитан әлеге сүзләрне "урланган байлыгың белән бүлеш", дип аңлар иде. Юк, болай булмый, аның белән нечкәрәк сөйләшергә кирәк. Сенатор аның ничә сум урлаганын исәпләп караган иде инде һәм кармакка капкан капитанның үзенә күпме чыгарырга тиешлеген дә белә. Хәзергә законның бер хәрефеннән дә чыгарга ярамый, хакимият йөзен сакларга кирәк иде. Юкса, ым гына как—акча үзе йөзеп киләчәк, хәтта кыл кыймылдатмасаң да. Ришвәт алу—нечкә нәрсә, прокурор аны җинаятьләр кодексы һәм хокук белеменә караганда да яхшырак белә иде.

Кабинет хуҗасы диктофонны капитанга таба шудыртты һәм, шуны гына көтеп торгандай, фырт егет телгә килде:

—Бу эш башка кабатланмас, мин яшь әле, төзәлермен...

—Нәкъ менә төзәтү өчен документлар әзерлим,—дип, борын җыерып елмайгандай итте прокурор.—Синең уеннарына ничә ел бирәчәкләрен беләсеңме?

—Биш ел, диделәр...

—Адвокатларың начар синең, капитан, биш ел ришвәт өчен генә әле ул. Ә "Универсам" складларын сәбәпсез ябып-пичәтләп күпме зыян китергәнеңне беләсеңме? Аннан сине ике көн буе эзләгәннәр, без синең кайда типтереп ятканыңны да беләбез. Кибеттә суыткычлар сүндерелгән, күпме товар бозылган, аларның бәясе үзе генә дә илле мең тарта. Тагын шундый өч "батырлыгың" бар, җәмгысе йөз меңгә тарта, ә син беләсеңме ул йөз меңнән ни аңкыганын?

Бу сугу шулхәтле үтемле, осталарча булды ки, капитан хәтта үзен коткарырга тиешле йонлач кулларның көченә ышанмый башлады, хәер, аңа, судан коры чыгарсың, дип әйтүче дә булмаган иде, ниндидер ишарә, ым, хуплап күз кысу гына...

—Коткарыгыз, үлгәнче онытмам, мәңге бурычлы булырмын,—дип ялынды бер мизгелдә тәкәбберлегән югалткан Кодрәтов.

—Беләсеңме, сәүдәдә сине кем дип атыйлар? Чума! Синдәйләр халыкка үләт алып килә,—прокурор тагы кызып китте һәм шунда гына капитанны ни өчен чакыртканы исенә төште. Дулкынланудан ул кинәт кенә урыныннан торды һәм ярсуын басарга теләп, кабинет буйлап арлы-бирле йөреп килде. Тактиканы үзгәртергә кирәк иде. Кодрәтов ялына-ялына үзе үк аңа булышты.

—Үтермәгез, зинһар, колыгыз булырмын...

—Син эшне ябу җиңел дип уйлыйсыңмы, ни өчен мин сине коткару өчен үземне авыр хәлгә куярга тиеш, ди әле?! Кем соң әле син миңа?

Туганыммы, кодаммы? Болай да эшләрем муеннан. Берсеннән-берсе хәтәр. Минем бүген дә бер эш бар. Аны миннән сине яклауны сораган берәү үтенгән иде, хәзер белмим дә инде, сине коткарыргамы, әллә шофернымы?

—Нинди шоферны?—дип, өмет белән сорады капитан.

—Күп белсәң, тиз картаерсың,—дип кисте прокурор кабинет буйлап йөри-йөри.—Алай дисәң, чөйне чөй белән чыгаралар, ди, бәлки синең йонлач куллы абзаларыннын ике үтенечен дә башкарып чыгып булыр, ике язмыш та синең кулда, үз бәхетеңне үзең кой. Тәвәккәлләргә ризамы?

—Әйттем бит инде, хурлыктан һәм төрмәдән генә коткарыгыз, колыгыз булачакмын,—диде капитан күпмедер канатланып, чөнки ул алда ниндидер өмет туып килүен сизгән иде инде.

—Тулаем алганда, артык четерекле эш түгел, тик шулай да тәвәккәллек кирәк,—диде Әкрәмхуҗаев тыныч кына урынына утырып.—Мин моны икенче берәүдән сорармын дигән идем дә, ә нигә сиңа тапшырмаска, ди. Бер үк вакытта үз сүзеңә хуҗамы, юкмы икәнеңне дә тикшерербез.

Прокурор сәгатенә карап алды һәм елмаеп әйтте:

—Куркып калмасаң, синең дә, теге шофернын да күңелсезлекләре юкка чыгар. Ике сәгатьтән...

—Мин нишләргә тиеш?—дип, түземсезләнеп сорады Кодрәтов.

—Хәйран калырлык берни дә... Әмма башта мин сине ни эшләргә тиешлеген белән таныштырырга тиеш, гомуми билгеләрдә генә, әлбәттә. Онытма, мин сине көчләргә теләмим... Тыңла!

Кыскасы, бик зур бер кешегә килгән кунак бүген төштән соң хуҗа машинасында авариягә эләккән. Машина да, үзе дә нык кына зыян күрә. Хәзер ул больницада ята, иртәгәсен органнар аның эшен кузгатырга тиеш. Син тагын ике егет белән хастаханәнең икенче катына күтәрелергә, дежур торучы Хәлимә Насыйровнадан изоляторның кайдалыгын сорап, теге кешене носилкага салырга һәм машинага алып төшәргә тиеш. Бурычың шуннан гыйбарәт. Алып чыгып икенче урамга җитүгә үк син иректә. Машина хуҗасы, әйткәнемчә, бик зур кеше. Операция уңышлы үтсә, ул "Минем "Волга"мны урлап киткәннәр" диячәк һәм шуның белән барысы ла вәссәлам. Йә, алынасыңмы? Ничек уйлысың?

—Әгәр шаяртмыйсыз икән, мин риза! Бу бит бик вак эш...

—Әйе, син капкан "эш" белән чагыштырганда, әлбәттә, көнбагыш чиртү белән бер. Безнекеләр эшли башлады инде, изоляторда төрмә больницасыннан Сабиров фамилияле сакчы утыра, сез килергә ярты сәгать кала, начальство Насыйровнага шылтыратып, аны өенә кайтарып җибәрәчәк. Шылтыратучы кеше каравыл хезмәте майоры Сәетов булачак, онытма! Һәм соңгысы, әгәр шәфкать туташы сораса, начальство алырга кушты, диген, майорны белүеңне дә, сакчы итеп Сабировны куюларын да сиздер. Ә көтелмәгән хәл килеп чыга калса, җаеңа карарсың. Икенче каттан җиргә сикерү сезнең кебек бөркетләргә чүп кенә дип уйлыйм. Бу проблема түгел. Килештекме?!

Капитан, бу фартка һаман әле ышанасы килмичә, дәртсез генә кулын сузды.

—Ә хәзер болай эшләрсең... Моннан ике өй аша гына чәйханә бар, чәй эчеп кил, ял ит, мөмкинлекләреңне барла, беркая да телефоннан шылтыратма, больницага бер сәгатьтән китәбез.

Кодрәтов кабинеттан чыгып китүгә үк Сухроб чәйханәгә шылтыратты.

—Әхмәт-әкә, әле генә чәйханәгә миннән бер яшь чибәр капитан китте, син күзәт әле: чәйханәдән чыгып югалып тормасмы, берәр җиргә телефоннан шылтыратмасмы?

—Яхшы,—дип кыска гына җавап бирде чәйханәче. Прокурор белән аларның серләре күптән килешкән иде инде.

Сәлим Хәсәнович ярты сәгатькә соңга калды.

—Нәрсә, безнең районда кесә капшаучылар калмаганмы әллә?—дип каршылады аны прокурор.

—Күз алдына китер, нәкъ шулай. Аларның бүген ниндидер җыеннары, корылтайлары, ди. Башкаланы бүлешәләр, соңгы елларда аларда яна автори-

тетлар барлыкка килгән, аларга урын житми башлаган. Менә шулар кулында хәзер Ташкент картасы, алар аны үзләренчә үзгәртә, картлар урын бирә, яшьләр өскә менә.

—Хакимият кая карый? Гомумән, шәһәр белән кем идарә итә?—дип ычкынып китте Сенатор.—Димәк, жинаятьчеләр дөньясы аерым, ә хокук саклау органнары аерым. Шулаймы?—дип куйды ул.

Ярдәмчесе, шефының бүгенге артык фәлсәфи корылган уйларына тагын бер кат гажәпләнеп жавап бирде:

—Нәкъ өстенә бастыгыз, аларның үз кайгысы, безнең үз кайгыбыз. Алар без белгәнне белә, бәлки яхшырак та беләдер әле. Без дә кемнең кем икәнен беләбез. Тигезлек күренеп тора, сарыклар да исән, бүреләр дә тук. Кесә каракларына килгәндә, мин аларның икесен жыеннан чакыртып алдым, алар машинада көтә, хәйран егетләр, барысын да ярты сүздән аңлыйлар. Бездә шундый хезмәткәрләр булсын иде ул.

—Рәнжетәсең, туган, безнең системада алардан да шомарак карчыгалар бар, кесәңне генә чистартып калмаслар, дәүләтеңне теләнчелеккә төшерерләр. Кызганыч, Кодрәтов эше белән танышмый калдың, менә ул сәүдәне чистарткан да чистарткан, ичмасам. Бу кесә капшаучыларның төшенә дә керми, бер елда йөз мең...

—Бирелэм, бирелэм!—дип, кулларын өскә күтәрде ярдәмчесе.—Димәк, син аны яхшы кыскансың, күрдем мин аны, чәйханәдә утыра иде.

—Кая барсын ул. Сина гына әйтәм, мондый оятсызны күргән юк иде әле. Костаны коткару белән генә аны кулдан ычкындырырга ярамас, костырам әле мин аны, үз рангы буенча алмый. Димәк, без аңа сукыр бер тиенгә дә тормыйбыз. Хатынының атасын дөньяның кендеге дип саный. Көтик әле, мин бабайга да барып житәрмен,—дип тәмамлады ул сүзен янау белән. Шунда телефон шылтырады. Сәлим Хәсәнович та ишетсен өчен прокурор трубканы колагыннан читтәрәк тотты.

—Капитан әле генә чыгып китте. Бик бетәшеп килгән иде, ләкин бик тиз рәткә керде. Аның янына беркем дә килмәде, чәйханәдән чыгып йөрмәде, телефоннан файдаланмады.

—Рәхмәт, Әхмәт-ака, профиларча эшлисең! Сине аракыга төнге тарифны арттырган дип сөйлиләр, клиентларыңны югалтып бетермәссеңме?

—Югалтмам, төнлә аракы эчәргә яратасың икән, акча янчыгыңны ач, яхшы сервис бөтен дөньяда кыйбат тора.—Икесе дә кычкырып көлеп жибәрделәр.

...Прокурор сейфтан пистолет алып кесәсенә яшерде. Узган ел Цхалтубода ял иткәндә сатып алган бу коралның да кирәге чыкты. Ялгышмаса, милиция органнары аны инде ун еллап эзлиләр иде бугай.

—Ниһаять, барыбыз да жыелдык, операциянең беренче өлешенә керешәбез,—диде ул.

—Пушка? Нәрсәгә ул?—дип сорады шаккаткан ярдәмчесе.

—Кадерлем, безне бүген Нәргиздә сый-нигъмәт кенә көтми, алдыбызда зур эшләр... Бу кара елтыр нәрсә булганда мин үземне иркенрәк хис итәм. Кичке аш белән ничегрәк анда, киләсе зур кунакка сюрприз ясыйсым килә. Бәхәсләшә алам, яхшы коньяк эчсә бер бокал шампанский турында башына да китерә алмый әле ул. Ә кыздырылган кош ите, пылау турында әйтеп торасы да юк, аларны яңа йорт хуҗасы менә дигән итеп әзерли, диләр.

—Анда барысы да тәртиптә, шул мәҗлесне оештырып йөреп соңга калдым, базарга керергә туры килде, "Интурист" подвалларын карап чыктым, деликатеслар эзләктерергә иде исәп. Сез яраткан миногалар, ысланган елан балыклар... Югары кунак мондый каршылауны ошатыр, үз бәясен бирер, дим. Сүз уңаенда әйтим, анда барысы да Рәшидовның үлеме турында беләләр!

—Хы! Подвалда утыр да барысын да белмә, имеш. Алар югарылар иснәнгәнче үк ис сизгәннәрдер инде, ә бәлки... үлгәнчегә кадәр...—дип, борынын ышкыды прокурор.

Шул чакта сакланып кына ишек шакыганнары ишетелде. Бусагада, керимме, юкмы дигәндәй, капитан Кодрәтов тора иде.

"Чыннан да селәгәй икән әле, житмәсә, бөрешке, кем мондыйларга

шундый эш урыннарын бирә: тормыш тәҗрибәсе дә, органнарда эшләү зирәклеге дә юк ич монын",—дип уйлап куйды Сәлим Хәсәнович, башкаларның мәгълүм кешеләреннән берсенең киявен күзләре белән ашап.

—Приемныйда көт!—дип кенә кулын селкеде прокурор һәм капитан ишекне япты.

Ярдәмчесенең уйларын китаптан укыгандай, прокурор бер генә җөмлә ташлады:

—Кияве бабасына охшаган, һәркем үзенә кирәк агачны кисә.—Икесе дә ирексездән көлеп җибәрделәр.

—Китәр алдыннан бер-ике сүз. Сәлим, син капитан белән кесә капшаучыларны алып, "рафик"ка утырасың һәм минем арттан барасың. Травматологиягә барып җиткәнче туктарсыз, мин сигнал бирермен. Больница янына мин үзем генә барам, автоматтан икенче катка шылтыратам. Сакчы киткәч кенә, бер ярты сәгатьтән ишегалдына керерсез, машинаны подъезд алдына куярсыз. Менә шулар. Капитан белән сөйләшенгән, ул бар детальләрне белә, кесә капшаучылар да үз эшләрен беләдер, диик. Әйдә, юл алдыннан утырып алыйк, Алла сакласын.

Хастаханә янына килеп туктауга, Сухроб урамдагы телефон-автоматтан шылтыратты:

—Авыр яралылар бүлегеме?—Таныш тавышны ишетүгә кабат сорады:—Хәлимә Насыйровнамы?

—Сезне шәһәр төрмәсе каравыл хезмәте башлыгы майор Сәетов борчый. Сезнең каттагы изоляторда яралы җинаятьче ята. Безнең врач аны начальство белән килештермичә генә сездә калдырган, ә бу уставны тупас бозу...

—Кая китсен ул,—дип бүлдерде аны шәфкать туташы.—Аның бит умыртка баганасы сынган, мин әле генә изоляторда булдым, сакчыга да, авыруга да ашарларына бирдем.

—Рәхмәт! Качуын качмас, әмма безгә инструкция закон, без аны үтәргә тиеш. Без хәзер транспорт белән кешеләр җибәрәбез, сезгә бер җитез капитан килер, авыруны аңа тапшырыгыз, иртәгә рентгенга алып килербез, шулай итсәк, барысы да тәртиптә һәм ышанычлырак булыр...

—Әгәр сездә шундый усал кагыйдәләр икән, килегез, алыгыз.

—Әйе, оныта язганмын. Анда авыру янында безнең сакчы Сабиров булырга тиеш. Мыеклы, тулы гәүдәле егет. Аның хатыны шылтыраткан иде, егетнең сменасы сәгать биштә тәмамланды, әгәр ул анда икән, кайтып китсен, аңа көтмәгәндә генә Башкортстаннан кунаклар килгән.

—Ярый, ярый, мин аңа әйтермен,—дип, трубканы куйдылар.

Сенатор кульяулыгы белән дымланган кулларын сөртте һәм тыныч кына машинасына китте, аның авызы кипте, үтереп эчәсе килә башлаган иде.

Хастаханәдән читкәрәк китеп, ул иске медицина институты янында борылды һәм яңа урынга туктады. Моннан травматология институтына керү юлы ап-ачык күренә иде. Ул машинасын очраклы рәвештә генә булса да кемнеңдер күрүен теләми, иртәгә шундый шау-шу кубачак—куркыныч җинаятьчене урлап алып китү коточкыч ЧП—һәр нәни генә деталь зур, мөһим нәрсәгә әйләнәчәк әле.

Прокурор үзен кая куярга белмичә, сәгатенә күз төшереп алды, юкса, Сабиров чыгарга тиеш иде инде. "Начальствосына шылтыратмагандыр ич?" дигән уй йөгереп узды. Мондый вариантны ул бөтенләй күздә тотмаган иде. Әгәр эшләр шуңа китсә, качып китәргә генә кала, ләкин шул мизгелдә ишектә сакчы күренде. Сабиров капка янында бераз тукталып торды, узып баручы берәүдән сигарет сорап алды һәм кинәт кенә урыныннан кубып, якынлашып килүче трамвайга таба чапты.

Прокурор иркен сулап җибәрде, кесәсеннән кульяулык тартып чыгарды, дымланган куллары сизелерлек дерелдиләр иде.

Машинаның утын яндырып, Сәлим белән алдан килешеп куйганча, ике тапкыр күз "кысып" алды. Энгельс урамының каршы ягындагы "рафик" акрын гына травматология институты капкасына юл тотты. Хастаханәнең ишегалды яхшы яктыртылганлыктан, прокурор алгы утыргычтан сикереп төшкән капитанны да, ак халатлар кигән кесә каракларын да аерымачык

күрде. Менә алар өчәүләп мәрмәр баскыч буйлап өскә күтәрелделәр. Капитан үзен бик иркен, егетләрчә тота, "эшкә баручы" капшаучыларга нәрсәдер аңлата иде.

Кинәт кенә Сенатор анын турында ачу белән уйлап куйды: "Бүкән дә—бүкән, бу да—бүкән. Үзен нинди эшкә җибәрүләрен белми микәнни?! " Шулай да, эчтән генә ул Кодрәтовка уныш теләп калды.

Ак халатлылар ачык ишекнең кара уемында югалуга, прокурор сәгатенә карады, операция, корылган план буенча, ун минуттан да артыкка сузылырга тиеш түгел. Бил каешыннан пистолетын алды, пиджак кесәсенә салды һәм, машинадан чыгып, "Жигули" тирәсендә гасабиланып атлый башлады. Ул вакытны саный, ә секундлар бик акрын узган кебек тоела иде. Фаразлавынча, ун минутлап вакыт узгач, больницага борылды, нык яктыртылган баскыч буйлап Коста салынган носилканы алып төшеп киләләр иде инде. Кесә капшаучылар, физик эшкә өйрәнмәгәнгә күрә, бөгелеп төшкәннәр, шуңамы капитан алдагысына булышып бара, текә баскычта иң зур авырлык аңа төшә иде. Шулвакыт аларга ярдәмгә Сәлим белән шофер килеп җиттеләр, берничә минуттан носилка өстендәге "багажы-ние" белән машина корсагына кереп югалды һәм "рафик" Коста кунак булып яткан җирдән алга ыргылды.

—Әлхәмделилләһи! Уныш мина үз аягы белән килә,—дип куйды прокурор һәм пистолетын кабат иске урынына яшерде дә машинасына чумды. "Рафик"нын поляк костелы яныннан борылып килүен көтеп, ул магнитофонны кабызды, тәмләп кенә тартып җибәрде, эшнең унышлы чыгуыннан башы әйләнеп киткәндәй булды. Эх, хәзер берәр бокал шампан аударасы иде! Үзен куркынычның күзенә карый алучы, тәвәккәл, кыю, батыр йөрәкле кеше итеп тою ана рәхәтлек китерсә дә, куллары һаман дерелди иде әле, ләкин бу икенче төрле дерелдәү иде инде.

Пикапны уздыруга, Сухроб анын артыннан китте, алдан сөйләшенгәнчә, икенче урамга чыгуга, ягъни "Үзбәкстан" кунакханәсе янында, Сәлим кесә каракларын төшереп калдырырга тиеш иде.

Хәер, бу урын үзе дә капшаучыларнын яраткан ноктасы иде. Отель алдындагы мәйданда "РАФ" бер минутка гына туктап алды һәм бик тә ыспай киенгән карак малайлар күз ачып йомганчы бәйрәм рухында тирбәлгән халык өерендә юкка чыкты.

Алга таба ул "рафик"ны күздән ычкындырмады, чибәр Нәргиз яшәгән мәхәллә начар яктыртыла, прокурор аларны исәпсез-сансыз тупиклар, чатлар, агач диңгезе каплаган урамнарда югалтудан курка иде.

"Әллә Сәлим белмичәрәк Нәргиз әзерләгән мәҗлескә капитанны да чакырганмы?"—дип, кыбырсып уйлап куярга өлгермәде, пикап кинәт кенә туктады һәм ОБХССчы җинел хәрәкәт белән юл читенә сикерде.

Аны күрмәмешкә салынып үтү мөмкин түгел иде, прокурор тормозга басты, алгы ишекнең тәрәзәсен төшереп әйтте:

—Ну, нәрсә дим, капитан... Аңладым, сүзеңдә тора беләсен икән, сезнең белән эш итәргә була. Мин сезгә булышырга тырышырмын, әмма, үзегез әйтмешли, минем үтенеч белән сезнеке, гомумән, янәшә куярлык түгел...

Капитан, ун кулын йөрәгенә куеп, шатланып башын иде:

—Рәхмәт, Сухроб-әкә, рәхмәт! Мин яхшы анлыйм, мәңге сезгә бурычлымын...

Ерактагы "рафик" сулга борыла иде, Сухроб аны күздән югалтудан куркып, машинасын кинәт кенә урыныннан кузгатты. Капитан машина төтененә һәм "Гудьир" исемле инглиз шиннары чыгарган тузанга күмелеп калды.

"Сәгатьләп түгел, минутлап акыл керә бара моңа",—дип күнелле уйлап куйды Сенатор капитан турында. Зур төргәк акчасыз котыла алмасын капитан аңлаган иде булса кирәк, прокурор моны анын күзләреннән күрде.

Эшчеләр шәһәрчеге урамнарында тагы бер ун минутлап әйләнеп йөргәннән соң, "рафик" прокурор ярдәмчесенең сөяркәсе яши торган мәхәлләгә килеп керде, кирпеч койма янына туктады. Койма традицион үзбәк дувалына караганда, күбрәк төрмәнекенә охшатып эшләнгән иде. Өстендә чәнечкеле тимерчыбык кына юк, әмма ләкин дивар өстендәге бетонга тырпаеп торучы пыяла ватыклары катыштырылганлыгына прокурорның иманы камил иде.

Костаны өйгә алып керми торып, Сухроб машинасыннан чыкмады, "рафик" күршедәге тыкрыкка борылгач кына ишек алдына керде, ул кергәч тә ярдәмчесе яхшы майланган тимер ишекләрне ябып бикләп куйды.

"Мондый койма артында озак качып ятарга була икән",—дип, никтер уйлап куйды Сенатор, шулвакыт верандадан Нәргизнең тавышы ишетелде. Прокурор үзенең ярдәмчесен көтеп алды һәм алар балкып торган верандага икәүләп күтәрелделәр. Сый-нигъмәт тулы өстәл әзер иде инде.

—Ну, исәнме, гүзәл Нәргиз, менә сиңа өй туена килдем әле,—дип, кунак аны кочаклап үпте. Нәргиз киң танылган фольклор ансамбленең элеккеге биючесе иде.

—Үз йортымда сезне сәламли алуга мин бик бәхетлемен, Сухроб-әкә, хәзер инде Сәлим белән сезне ешрак күрергә өмет итәм,—шул сүзләрне әйтүгә, ул, гафу үтенеп, кухня ягына ашыкты һәм ярты сәгатьтән дастарханга чакырасын кисәтте, дөресрәге, вәгъдә бирде.

—Ә безнең өстәл янына утырганчы нәкъ ярты сәгатьлек эшебез бар әле,—диде Сухроб һәм ярдәмчесенә эндәште:—Сәлим, операция башыннан бирле мине тамак кибү газаплый, дустым бул, салып бир әле.

Сәлим Хәсәнович өстәлдәге боз тутырылган чиләктән бер шампан шешәсе тартып алды, аны житез генә, тавышсыз гына ачты да ике тирән бокалны тутырып салды.

—Рәхмәт, кадерлем, син минем уйларымны укыйсың, минем нәкъ шампан эчәсем килгән иде. Әйдә операциянең икенче өлеше өчен эчәбез!—диде шеф.

—Уңыш өчен!—Миршаб аның сүзен куәтләде һәм алар бер күтәрүдә бокалларны әйләндереп салдылар.

—Хәзер мин Коста белән танышам, ә син безнең дусларга шылтырат, өчәүләп килсеннәр. Сергей, Погос һәм Бармаксыз, исеме ничек әле?

—Артем,—дип исенә төшерде ярдәмчесе.

—Әйе, әйе... Артем инструментын да алсын, Гоголь урамындагы сейф гап-гади...

—Син республика прокуратурасын басмакчымы?—дип ычкындырды шаккаткан Сәлим.

—Әйе, прокуратураны. Борчылыр сәбәпләр күрмим, гадәти объект. Банкта сейф ачу куркынычрак, анда басучыларны тотарга әзерләнеп торалар. Ә прокуратурага бәреп керү тарихта беренче ул. Мин анда бүген күрдем инде, сакта жебегәннәр утыра, пенсионерлар...

—Гогольдәге сейфта сезнең өчен нинди кыйммәтле нәрсә ятканын башыма да китерә алмыйм. Әгәр ниндидер мәгълүмат кирәк икән, аны сатып алып та була, кешеләре бар, беренче тапкырмыни инде.

—Син һәрвакыттагыча хаклы, кадерле Миршаб, әмма безнең арадашчылар эзләп йөрергә дә, сатып алырга да вакыт тар, сейфтагы документлар иртән республика прокуроры өстәлендә ятачаклар.

—Хәзер инде берни дә аңламый башладым. Ул документлар кайдан калкып чыккан һәм алар ничек тикшерү бүлеге начальнигы өстәл өстенә салынганнар?—диде аптыраган ярдәмче.

—Башыңны катырма—барыбер аңламассың. Мин сиңа кичке аш вакытында барысын да аңлатырмын. Ләкин ышан, безгә бик-бик сирәк очрый торган мөмкинлек эләкте, шуны ычкындырмаска кирәк, уйнарга икән—ва-банк уйнарга! Ә хәзер бар, дусларга шылтырат, сәгать ярымнан килеп житсеннәр, мәжлескә өлгерәчәкләр, алар шундый сый-нигъмәтне үзләре өчен әзерләнгән дип уйлаячак, монысы да әйбәт. Ә хәзер мине Коста янына озат.

Сәлим Нәргизнең зур йортындагы бар почмакларны биш бармагыдай белә иде, көтелмәгән кунак утырган йокы бүлмәсен күрсәтте дә Бармаксызга шылтыратырга дип, телефон янына китте, әлеге компания шефның чакыруын көтеп күптәннән аның квартирында ята иде инде.

Алда бик үк гади булмаган сөйләшү торасын аңлаган Сенатор бер мизгелгә ишек янында туктап алды. Коста кебек һәр төенне чабып кына өзә торган кеше белән бәйләнүнең файдалы яклары белән бергә, башка сыймаслык нәтиҗәләргә китерү мөмкинлеген дә күз алдына китерде, аның артында торучыларны искә алды. Ул Костаны больницадан урлап алып китүнең нинди

зур башсызлык икәнен төгәл тоемлый иде. Әле бит республика прокуратурасына бәреп керәсе дә бар. Әгәр ниндидер сәбәпләр аркасында "дипломат" хуҗалары ул үткәргән операциядән риза булмыйлар икән, башынны биреп кенә җавап бирә алачаксың. Әмма, әмма... Эш уңышлы барса...

Дулкынланудан Сенаторның йөрәге дөп-дөп тибә башлады һәм ул имән ишекне ничарадан бичара ачты. Биек түшәмле, тәрәзәсез йокы бүлмәсендә менә дигән әфган келәменен йомшак сыртын сыпыргалап дивар янындагы тәбәнәк тахтада Коста ята иде. Яхшылап майланган бакыр күгәнле ишек тавышсыз ачылганга, Коста аның керүен ишетмәде, әллә ишетмәмешкә салышты, һәрхәлдә ул башын борып карамады, келәмне сыйпавын дәвам итте, әмма ул ачык ишектән җил өргәнен дә сизде, йомшак паласта йотылган аяк тавышларын да ишетте, ул гомумән, гаҗәеп ишетү сәләтенә ия иде.

—Хәерле кич,—дип сәламләде беренче "йөреш"нең аның файдасына булмаганын аңлаган прокурор.

Коста ялкау гына башын борды, әмма күзәтүчән кеше аның чәнечкеле карашы белән керүчене каптырып алуын сизенер иде.

—Хәерле, хәерле,—дип җавап бирде Коста, анда дулкынлану да, кызыксыну да сизелми иде һәм ул кинәт кенә ыңгырашып куйды.

—Ни булды?—прокурор булышырга теләп аның янына атылды, әмма Коста тынычланды, үзенең минутлык йомшаклыгына читенсенгәндәй итте һәм яткан мендәрен төзәтүен үтенде.

Сенаторның иелүе булды, ишектән атлап керүгә үк аның пистолеты барлыгын сизенгән Костаның сул кулы өскә ыргылды, көчле бармаклар бугаз яныннан күлмәк якасын умырып алды, уң кулы прокурорның бил артындагы пистолетын тартып чыгарды һәм күкрәгенә терәде. Имгәнгән кешедән мондый да җитезлек, елгырлык көтмәгән прокурор куркудан телсез калды.

—Син нәрсә, акылсыз баш?—дип гырылдады ул.—Мин бит сине төрмәдән коткардым, сиңа "вышка" иде. Хәзер үк җибәр!—Күкрәгендәге пистолетның салкыны бөтен гәүдәсенә күчте, җитмәсә, ул аның ялгыш атылып китүеннән курка иде.

—Селкенмә!—диде Коста акрын гына.—Син бүген минем бер кешене атып үтерүемне күрдең инде, икенчесе син булырсың. Бер прокурор үләме, икеме, хәзер барыбер. Хөкем бер.

Костаның барысын да үтәли күрүенә шаккатып, ул бөтенләй каушап калды, башында уйлар чәбәләнде: каян барысын да белә икән бу?

—Мин сине прокуратурада күрдем, колонна артында качып тора иден,—диде Коста.—Ә хәзер "дипломат"ның кайда икәнлеген әйт?!—Һәм прокурор тәненә пистолет көпшәсенең батып керүен сизде, бу адәм аны ике дә уйлап тормыйча атып үтерәчәк, ул аның, чыннан да, кеше үтергәнен күрде бит инде.

—Исең киткән "дипломат"ка, рәхмәт укы, без сине төрмәдән йолып алдык,—Сенатор чын күңелдән ачуланды.

—Сез генә ул эш бетүгә кыякларга торасыз, бездә алай түгел, безгә ышаныч, репутация яшәүдән дә кадерлерәк. Әйт, кайда "дипломат"?

—Аның кайдалыгын белүеннән ни файда?—дип ачуын ташытты прокурор.

Коста аның якасыннан шундый итеп селкеде ки, өзелеп чыккан төймәләр идәнгә тәгәрәде, күлмәге аркасыннан икегә аерылып чыкты.

—"Дипломат" кайда?

—Прокуратурада...—Әкрәмхуҗаев гырлап тахтага ауды.

—Хәзер үк әйт, телефон китерсеннәр, юкса, мин сине атып үтерәм.—Коста пистолетны аның чигәсенә терәде. Ни гаҗәп, чигәдәге пистолет куркудан ихтыяр көчен югалткан прокурорны тынычландырып җибәргән кебек булды.

—Мине үтерсәң дә, телефон пәйда булмас, мәхәллә шәһәр читендә, йорт яңа гына төзелгән, бер ай элек кенә яши башладылар, телефон станциясен тиз генә төземмәячәкләр әле.—Ул алдамый иде. Миршад Бармаксызга шылтыратырга чәйханәгә китте. Кварталдагы бердәнбер телефон-автомат анда гына иде.

Бу яңалык Коста өчен шулкадәр көтмәгәнчә яңгырады, ул хәтта югалып калды, аның запаста бер уен кәрте бар иде, анысын да бик тиз кападылар

түгелме? Ул кулын якасыннан алып, пистолетны Сенаторга кайтарды.

—Ну, агай-эне, псих икәнсең син,—диде прокурор тыныч кына, күлмәген күкрәк турыннан төзәткәләп.

Бу вакыйга аның кәефен бозмады, киресенчә, "дипломат"ның мөһимлеге турындагы фикерен ныгыта төште, ул бик җитди кешеләр белән эш алып барачагын да аңлады.

—Әйдәгез танышыйк,—диде ул тахта янына килеп, әмма Коста кулын биреп тормады.

—Сухроб Әхмәт улы Әкрәмхуҗаев, прокурор...

—Мине Коста дип йөриләр,—дип җавап бирде яралы.—Минем хакта ишеткәнегез бардыр дип беләм.

Хәйләкәр прокурор төртмәле сорауны колак яныннан уздырып җибәрде, чөнки Костаны үзенә файдалы сөйләшүгә тарта алуын сизенгән иде инде. Ләкин тахтадагы кеше вариантларны аннан да җитезрәк исәпләп өлгергән иде инде, ул Әкрәмхуҗаевның маңгаена бәреп дигәндәй, тагы сорау бирде:

—Нишләп сез мине гадел җәзадан коткарырга уйладыгыз әле, мин бит сезнең күз алдында коллегагыз Азлархановны үтергән кеше. Аны сезнең дөньяда белмәгәннәр сирәк.

Сенатор туры сорауга туры җавап бирергә кирәклеген, мондый типлар белән уйнасаң, ачыктан-ачык уйнарга кирәклеген белә иде. Һич югында, баштарак булса да, аның уяулыгын киметергә кирәк иде.

—Хәзер кемгә төртсәң, шул канәгать түгел. Мин дә шулай. Еллар чаба, мин инде малай түгел, ә мин һаман район прокуроры. Үсү перспективасы күренми. Республикадагы кадрлар политикасын беләсездер. "Верховный" адәм рәтле һәр урынны үз кулында тотты. Аптырамагыз, әйе, тотты. Сезнең өчен генә бер серне ачам, ул инде юк, өченче көн Нукуста инспекция эшләре белән йөргәндә кинәт үлеп киткән.

—Ялгышасыз, прокурор, миңа болар сер түгел. Ул гынамы, кичә кайбер кешеләр белән мин инде анда булдым, хушлашып биек маңгаен үбәргә өлгердем. Сүзегезне бүлгәнгә гафу итегез, дәвам итәргә була...

Коста әйткәннәр ышанычны көчәйтә генә төште, ул үзенең дөрес юлда икәнен аңлап алды һәм берни дә булмагандай, тыныч кына сүзен дәвам итте:

—Мин, әлбәттә, "Верховный"га юллар эзләмәдем түгел, әмма, нигәдер, ул мине якын китермәде. Менә бүген уйламаганда-көтмәгәндә прокуратурага барып чыгарга туры килде, андагы хәлләрне күргәч, уйлап куйдым: әгәр "дипломат" белән сезне үземнеке итә алсам, минем язмыш кинәттән үзгәреп китәчәк.

—Сезнең "дипломат"ны урларга мөмкинлегегез бармы?—дип кинәт сорап куйды Коста.

—Юк. Эшли алганымны эшләдем инде мин,—дип мәрхәмәтсез җавап бирде прокурор. Аның вакытыннан элек Костага үз уй-планнарын чишәсе килми иде.

—Кызганыч. "Дипломат" сезнең кулда булса, тормышыгыз, һичшиксез, үзгәрер иде, үзегез омтылган урынны алыр идегез.

"Мин монысын синнән башка да беләм",—дип, эчтән генә уйлап көлемсерәде прокурор.

—Тик шулай да... Бу вакыйгага кушылып, сез язмышыгызны бик нык бутап ташладыгыз. Мине рәхмәтле кеше түгел дип санамагыз, чын күңелдән әйтәм, минем тормышым әлләни зур бәягә ия түгел, бүген "дипломат"ны кулдан ычкындыргач бигрәк тә. Бары "дипломат"ны кире кайтара алсам, яисә аларны юкка чыгарсам гына минем яшәвемнең мәгънәсе һәм кыйммәте булачак,—диде Коста.

—Шул... прокуратураны шартлатсаң гына инде,—дип шаяртып алды әңгәмәдәше, әмма Коста аны чын-чынлап кабул итте.

—Ә нәрсә, шәп идея,—диде ул. Күзләрендә өмет уты кабынды.—Бүлмәнең төгәл урынын гына белергә кирәк. Безнен Ташкентта ярты тонналап шартлаткыч бар, геологлардан сатып алган идек, ул эш буенча һөнәр иясен дә таба алабыз.

—Бу планны башыгыздан чыгарып атыгыз,—диде Сенатор.—Беренчедән, мин "дипломат"ның кайсы катта икәнен белмим, икенчедән, прокуратура бинасы ярты кварталны алып тора, сезнең шартлаткычыгыз аның бер канатына да житми, һәм онытмагыз—безнең карамакта бер генә төн...

Әмма Коста прокурорның куркуданмы, әллә башка сәбәптәнме, нәрсәнедер әйтеп бетермәвен сизенгән иде инде, турыдан-туры янауга күчте.

—Мин сезгә әйттем инде, больницадан без бәндәгезне урлап чыгып тормышыгызны үтә катлауландырдыгыз. "Дипломат"та Рәшидов урынына чамалаучыларның документлары... Хәзер инде уйлагыз: аларның дустымы, әллә дошманы буласыгыз киләме? Анда байтак эшкуарларга—республикадагы миллионерларга да, жинаятьчелек дөньясы белән идарә итүче олы агайларга да компромат тупланган.—Коста сөйләүдән туктап пауза ясады, уенда барын да әйтергәме, юкмы дигән нәрсә иде, шулай да томанлы гына итеп булса да сиздереп куярга булды:—Алар жинаятьчелек дөньясы белән генә идарә итмиләр... Саксызлык аркасында менә нәрсәгә эләктегез сез, прокурор...

—Нишләргә соң миңа?—Прокурор югалып ук калды.

—Сезгә бер генә юл бар: мин сезгә телефон номеры, хәтта ике телефон номеры бирәм, шуларның теләсә кайсысын жыеп, минем исемнән Артур Александрович белән очрашуны таләп итегез. Ә хәзер иң мөһиме: прокуратурадагы кейсның кайдалыгын, кемнәрнең белүе мөмкинлеген ачыклагыз. Аларның адресларын, телефон номерларын билгеләгез. Үзегез әйттегез, безнең карамакта бер генә төн... Артур Александровичның шундый кешеләре бар, алар ул адреслар буенча безнең кәгазьләрнең кайдалыгын беләчәкләр һәм урлаячаклар. Ни каршылыклар булса да. Хәзер тормышыгызның шушы кейс белән бәйләнгәнлеген аңлагансыгыздыр инде?..

—Әйе, әйе,—дип баш какты Сенатор, ул эчтән генә үз вариантларын уйлаштыра башлаган иде инде.

—Каләм белән кәгазь бирегез!—дип таләпчән эндәште Коста һәм прокурор аңа үзенең блокноты белән "паркер" маркалы каләмен сузганын сизми дә калды. Шул чакта сак кына ишек кактылар.

—Керегез,—диде ул борылмый гына, чөнки шакучының Миршаб икәнен белә иде.

Каралтылган пыяласын ялтыратып зур ишек киерелеп ачылды һәм ярдәмчесе кабымлыклар, эчемлекләр белән тутырылган арба-өстәлне эчкә тәгәрәтеп кертте.

"Сәлим һәрнәрсәне вакытында эшли, рәхмәт төшкере",—дип уйлап куйды прокурор үзенең классташы турында һәм арбаны тахтага таба этте.

—Оһо!—дип, сокланып аваз салды Коста.—Минога! Еланбалык! Мондый тәгамнарны күрсә, валлаһи, хәтта Икрам Мәхмүдовичның авызына сулар жыелыр иде.

—Кайсы Икрам Мәхмүдович?—дип, аны сүзендә тотарга чамалап, сорады прокурор.

—Аның белән танышырга мөмкинлегегез булыр әле. Андый тәмле тамакгурман бөтен Үзбәкстанда берәү генәдер дә.

"Әйе, моны коры кул белән генә алып булмый",—дип уйлап куйды Сенатор һәм сораштыруын дәвам итте:

—Коста, дөресен әйтегез әле, бүген төнгә каршы шампан белән сыйларлар дип башыгызга да китереп карамагансыздыр бит, житмәсә, мондагы шәраб заводларының болганчык суы белән түгел, ә чын Абрау-Дюрсо белән.

—Миндә шампан һәм минога кайгысы түгел иде. Әлбәттә, уйламадым. Әйе, нәрсәдер буласын көттем мин. Артем Александрович бәладә ташлап калдырмый, андый кеше түгел. Палатага капитан белән ак халатлы егетләр килеп кергәч тә, моны бары тик ул оештырган булырга тиешлеген аңлап алдым. Теге егетләргә бер күз төшерүгә үк аларның кем икәнен, ни белән шөгыльләнүләрен сизендем ич. Житмәсә, берсе миңа ым кагып өлгерде, андый ым-шымнар белән мәгълүм бер даирәдә генә аңлашалар, ул хәтта сезгә дә билгеле түгел, андый серне ачучыларны үлем көтә. Иртәгә сезнең арттан ук мине алырга икенче кешеләр килүен белсәм дә шаккатмам. Сез Японнан алда өлгергәнсез, ә бу булмастай нәрсә кебек.

—Сез Артур Александровичны әйтәсезме?

—Әйе, мин аның кешеләре турында әйтәм, бәладә ялгыз калдырмаячакларын беләм мин, менә бу минутларда алар "дипломат" белән мине эзләп шәһәрне айкыйлардыр...

—Яхшы, әйдәгез танышлык хөрмәтенә, алдагы эшләр уңышлы булсынга эчеп куйыйк!—дип тәкъдим ясады Сенатор һәм алар өчәүләп бокалларын күтәрделәр.

Прокурор тахтада, Коста янында яткан блокнотны кулына алды һәм язуга күз төшерде, телефон номерлары Ташкентның икесе ике читендәге районга караган иде.

—Сезне ташлап китәргә туры килә, ачуланмагыз, безнең карамакта бер генә төн, иртән документлар республика прокуроры өстәлендә булырга тиеш. Мин моны үзем ишетеп калдым. Хәзер кайнар аш китерерләр, ашагыз-эчегез, күнел ачыгыз, магнитофон да китерерләр, ә без эш белән шөгыльләник. Уңыш теләгез.

—Юлыгыз уң булсын!—диде Коста һәм йодрыкларын төйнәп, кулын өскә күтәрде. Алар тавышсыз гына бүлмәдән чыгып киттеләр.

Йокы бүлмәсендә бер сүз дә дәшмәгән һәм ни булганын аңлап җиткермәгән Сәлим ярымкараңгы коридорга чыккач Сенаторга иелеп пышылдады:

—Әйдә, күрше бүлмәгә керик, күлмәгеңне алыштыр, яңа галстук та кирәк булыр,—диде, әмма үзе югында ниләр булганын сораштырып тормады.

Сенатор яңа күлмәгенә галстук тагып азапланганда Миршаб шикләнгән, икеләнгән сыманрак итеп сорады:

—Әллә туктыйкмы соң, бик куркыныч уенга керәбез түгелме, һавадагы торнага карап кулдагы чыпчыкны ычкындырмыйк, диюем...

—Һәрвакыттагыча син хаклы, кадерле Сәлим. Эше дә куркыныч, башны югалту ихтималы да бар. Ләкин мин инде үземне атылган ук кебек хис итәм, барып кадалмыйча туктый да, кире чигенә дә алмыйм. Сиңа бер генә тәкъдимем бар—кал монда.

—Ничек калыйм, беләсең бит инде, без энә белән җеп кебек.—Сәлим Хәсәнович бүтән сүз әйтеп тормады, Сенаторның җилкәсеннән кочаклады һәм барысы да аңлашылды.

—Рәхмәт,—диде прокурор көзгегә карап һәм алар икесе дә елмаеп куйдылар, ләкин бу елмаюда ниндидер моңсулык, сагыш бар иде.

Алар Нәргизнең сеңлесе табын әзерләп йөргән якка, верандага чыктылар. Озакламый Сәлим, гафу үтенеп, хуҗабикәгә булышырга китеп барды. Вакыт ашыктыра иде инде. Берәр сәгатьтән дуслары белән Бармаксыз килеп керәчәк. Сый-нигъмәтләрдән сыгылган дастархан янында бик күп нәрсәне уртага салып сөйләшергә, киңәшергә кирәк иде әле.

Берүзе калгач, Сухроб ак "Жигули" хуҗаларын кисәткәненә нык үкенә башлады. Шул гамәле белән ул үзенең кемлеген танытты, тамгалыга әйләнде, хәзер аны, бәлки, иске шәһәрдә Костаның дуслары көтәдер, Япон кушаматлы Артур Александрович кешеләре эзлидер. Бу кушаматны ул бер генә тапкыр ишетмәгән иде инде. Хәзер Костадан ычкынырга маташса да, барып чыкмаячак, җавап бирү тулысынча үз өстендә. Җавап бирүе дә кайда бит әле, ул сиңа халык суды түгел! Анда алдый да, ялагайлана да, боргалана да алмыйсың, ялган шаһитлар да, судья да, адвокат та юк. Кемгәдер телефоннан да шылтырата алмыйсың. Җавапны үзең бирәсең һәм башың белән түлисең. Менә шул инде ул белер-белмәстән, уйламастан, ашыгып, каударланып машина фараларыннан күз кысу!

Шулай булгач, үзеңне стенага китереп терәдең инде, кадерле Сухроб, дип фикер йөртте ул. Хәзер прокуратурага бәреп керүдән дә котылып булмый. Хәер, бер юл бар бугай, бу куркыныч адымны Артур Александровичның үзенә калдырсаң?! Әмма болай булганда, синең үзеңә нинди өлеш тия соң? Әлбәттә, алар акча кызганмаслар, Костаны коткарган өчен дә, биргән мәгълүмат өчен дә мулдан түләрләр. Аларга бит кейснын кайсы бүлмәдә булуын белү генә кирәк. Исәпләә, кесәңә, шиксез, йөз мең кереп кенә утырачак.

Ләкин аны акча кызыктырмый иде, әлеге сумманың яртысын шушы атнада

ук аңа ОБХСС капитаны Кодрәтов алып киләчәк, ялына-ялына бирәчәк. Андый чыганаклар теләсә каян бәреп тора, буа бөяргә була. Кирәк чакта күз йомсын өчен прокурор белән бүлешергә атлыгып торучылар житәрлек, теләгең генә булсын. Юк шул, бәхет акчада гына түгел, дөнья малы—дуңгыз каны, дип юкка гына әйтмәгәннәр. Халык ялгышмый ул. Әйе, алардан зуррак урынга күтәрелергә ярдәм итүләрен дә сорарга була, ләкин ул биектән, югарыдан булмас. Сухробның маңгаена салкын тир бәреп чыкты. Уйларының очына чыгарлык түгел иде. Ничек кенә борып караса да, хыялында йөрткән нәрсәләр күренми иде. Аh, менә кулда "дипломат" булса, мин-минлекләре азган, тавышларын бөердән генә чыгарып сөйләшүче түрә абзыйларың аның алдында ничек бөтерелерләр! Алар да бит Анхор ярындагы ап-ак кар кебек бинаның бишенче катындагы кабинет турында хыялланалардыр... Бер син генә түгел!..

Кулына эләгә калса, ул кадәр компромат белән ниләр кыла алачагын Сенатор бик яхшы белә, бу хакта бер кәррә дә шикләнми иде.

Коста белән сөйләшкәннән соң тагы каттыян бер вариант туды: "дипломат"ны Артур Александровичка тапшырырга, шулай итеп, зур гына пай-мая белән көчле корпорация әгъзасы булып китәргә мөмкин. Аның кешеләре Рәшидов урынына утырырга йөри. Бу очракта да андый пайга ия булган кеше ярык тагарак янында калмас. Теләсә кайсы структурада автомат рәвештә аңа да урын табылыр. Прокурор моны да аңлый иде. Әмма "дипломат"та саклаучы мәгълүматлар боларның барысыннан да кыйммәтрәк түгелмени?! Алар бүгенгечә хакимият алышынырга торганда да, башка чорда да, кыскасы, теләсә кайсы вәзгыятьтә кыйммәтләрен югалтмыйлар, хәтта дистәләрчә еллар узганнан соң да... Шулай булгач, сергә ия кеше—зур урынга ия дигән сүз, чөнки синең кулда кешеләр язмышы, син тормыш агышы белән идарә итәсең. Сенаторның шикләнүе, шөбһәләнүе, икеләнүе соң чиккә житте. Әмма ул уйлар газаплы да, татлы да иде. Ахырдан уйлары төгәл бер фикер тирәсендә бөтерелә башлады: теләсә нинди юл белән кейсның бердәнбер хуҗасы булып калырга кирәк, юкса гомер буе "рядовой" булып калачаксың, хәтта бик көчле идән асты оешмасында әгъза исәпләнсәң дә. Ләкин моны ничек тормышка ашырырга? Шушы якты һәм ымсындыргыч хыялга ничек ирешергә соң?

Ике кулы белән башын тотып, ул кәефсез генә бер ноктага карап утыра бирде, гаҗәеп бай табын да, бүлмәдә дулкынланып тибрәлүче хуш исләр дә аны кызыктырмый иде шикелле. Әгәр шушы позада фоторәсемгә төшсә, аның астына: "Бу нәрсәне аңлата?" дип язып куйсалар, мона җавапны айһай таба алучы булыр иде микән?! Газаплы авыр сораулар миен бораулады, көмеш куна башлаган башы аска иелде. Аңа бер нәрсә ачык иде—ничек тә булса Японның ярдәменнән башка гына "дипломат"ны кулга төшерергә, ә аннан соң күз күрер. Кинәт кенә аның миеннән "Нәрсә мин үтерелмәгән аю тиресен бүлеп ятам әле", дигән уй йөгереп узды, шул уй белән бергә шикләре дә эреп тарала башлады.

Хискә бирелүчән кеше буларак, ул бик тиз кабынып киткән шикелле, тиз арада моңсу, кайгылы халәткә дә бата ала торган иде. Нәргизнең сеңлесе Мәмләкәт чытык йөзле Сухроб-әкәнең кинәт кенә башын күтәреп шаян елмаюына хәйран калды. Ә прокурор уртак яшерен эшләре булган кеше шикелле күз кысып, гаҗәпләнү хисен тагын да арттыра төште:

—Әйдә, апаң югында берәр чәркә шампан җибәрәбез, кара аны, үзе монда чыкса, сиңа рөхсәт итмәячәк.

—Әйдәгез,—дип, җинел генә ризалашты Мәмләкәт, аңа Сухроб-әкә ошый иде. Ничек ошамасын ди, хәтта, апасына бакчалы, бассейнлы, сауналы йорт алып биргән Сәлим Хәсәнович кебек бай һәм дәрәҗәле кеше дә шушы кешегә сүзсез буйсына ич.

Мәмләкәт бокалларны чиләк янындагы көмеш подноска куеп кына өлгерде, верандага Сәлим белән Нәргиз килеп тә керделәр.

Апасы тәртип ярата аның, өстәл бизәү, савыт-сабаны эзлекле бер тәртиптә урнаштыру кебек эшләр аның иң яраткан шөгыле иде. Аның бу гадәтен бигрәк тә Сәлим-әкә ярата, чынлап бәяли белә һәм шуның өчен хөрмәт итә

иде булса кирәк. Хуҗабикә зур табак белән кабымлыклар куйды: куй бавыры һәм май белән тутырылган бытбылдык түшкәләре авыз суын китерерлек итеп кыздырылган иде.

—Уф!—дип ычкындырды прокурор, борынына бу тәмле азыкның баш әйләндергеч хуш исләре килеп керде, алар кан тамырлары буйлап тәнгә таралды, күзләре көмеш приборларны һәм озын-матур бокалларны иркәләде.

—Ну, Нәргиз, син тылсымчы, билләһи!—диде ул чын күңелдән һәм аның хөрмәтенә тост күтәрергә тәкъдим итте.

Әле ун минут элек кенә шефын тирән уйларда калдырган Миршаб аның кинәт үзгәрешенә сөенде, димәк, нindидер рәтле уйга килгән яисә операцияне үтәмәскә карар кылган һәм ул хуҗабикә өчен шатланып бокал күтәрде. Әле ул шефның Нәргизгә өй сатып алганына нинди күзлектән караганын белми иде, ни генә димә, Нәргиз аның сөяркәсе генә ич, шулай булгач, аны борчучы бер проблема җилкәдән төшәчәк. Бытбылдыкка җитешкәнче прокурор сорарга тиешле тапты:

—Кунакны онытмадыкмы? Әгәр Нәргизнең бу чын сәнгать әсәрен татып карамаса, күп нәрсә югалтачак бит.

—Кунак барыннан да кадерлерәк, моңаеп утырмасын өчен аңа магнитофон да керттек әле,—дип, хуҗабикә өчен җавап бирде Миршаб.

Ике дистәгә якын бытбылдык эреп беткәндәй бик тиз юкка чыкты. Эченә бавыр тутырып, зәйтүн маенда кыздырылгангамы, кош түшкәләре йомшак булулары өстенә, әллә ничек нәфис иделәр, бу инде сиңа шашлык таягына тезеп учакта кыздырылган ит түгел. Хатыннар тагын кайнар кабымлыклар алырга киткәч, ә болары —бәрән кабыргалары белән катнаштырылган сумса һәм симез кучкар мае өстәлгән сый-нигъмәт иде, ирләр бер минутка өстәл янында үзләре генә калдылар. Хатын-кызлар юктан файдаланып, ике рюмка әрмән коньягы эчеп куйгач, прокурор ярдәмчесен операциянең икенче өлеше белән таныштырырга керәште.

—Минем сиңа ни өчен башта ук бөтен план хакында сөйләмәвемнең сәбәбен хәзер аңлагансыңдыр, дип беләм,—диде ул эшнең нечкәлекләре белән таныштыргач.—Уен эш түгел.—Һәм ярдәмчесенең агарып киткәнен күргәч, кистереп өстәде.—Ләкин чигенергә соң инде, "дипломат"ның бәясе артык кыйммәт, безнең куркаклыкны, ярты юлда туктап калуны гафу итмәячәкләр.

—Аңлыйм шикелле,—диде Миршаб.—Әгәр безне прокуратурада сакчылар атып үтермәсә, моны, мөгаен, без төрмәдән коткарган Коста үзе үк эшләячәк.

—Әйе. Артка юл юк,—диде Сенатор тыныч кына. Аның бүгенге халәте сәер иде, фәлсәфи тирәнлекләргә төшеп фикер йөртүе, уйчанлыгы гаҗәпләндерә иде.

Өстәлгә кайнар сумса китерделәр, яшь сарык итенең хуш исе башка бар исләрне күмеп китте кебек. Прокурор күз кырые белән генә сәгатенә карап алды. Бармаксыз кушаматлы Артем дусларын ияртеп үзбәк сыеның йөзек кашы булган пылауга килеп җитәргә тиешләр иде. Нәргизнең пылавы да тегенди-мондый түгел, һәрвакыт кызыл дивзир дип аталган Наманган дөгесеннән булыр, аңа итне Миршаб бары каракучкарныкын гына ала, ул ит аеруча туклыклы була, менә шуңа күрә дә шәрекъ дастарханында сыйлanучы ирләр, эчемлекне башка җирләрдәге кебек үк мулдан куллансалар да, бер дә исермиләр.

Хуҗабикә, кунакның сәгатькә карап алуын күргә, моны үзенчә фаразлады һәм әйтеп куйды:

—Мин дөге салдым инде, ун-унбиш минуттан пылау китерәм. Әйдәгез әле, житешегез, беркем дә уылдыкка да, казылыкка да кагылмаган, ә мин булсынга дип тырышкан идем...

—Рәхмәт, барысы да бик тәмле,—диде кунак елмаеп.—Пылау да артмас, хәзер безнең янга таныш-белешләр килә, алардан уылдык та калмас, Кытайның сян-гу гөмбәләре дә очар, дерелдекле телләрне дә йотып кына җибәрерләр, күңеленне төшермә!

Сәлимнең Бармаксыз вә аның дусларын да чакыруын сөяркәсеннән яшереп торуын белеп, ул көлеп җибәрде.

—Нигә башта ук әйтмәдегез,—дип Нәргиз кулларын җәеп җибәрде.— Дусларыгыз өчен приборлар куярга кирәк, үпкәләүләре бар.—Һәм ул өстәл артыннан очып кына чыкты, аңа ярдәмгә Мәмләкәт йөгерде.

—Нәргиз белән ундың син, аңа бүләккә йорт бирүенне дә дөрес саныйм, ул андый бәягә тора. Давай, аның өчен эчәбез, бу өйдә, күрәсең, безнең җаннар бер генә ял итмәс әле,—диде прокурор хисләнеп һәм шуның белән дустын тәмам тынычландырды. Хәзер Миршаб аның артыннан утка да, суга да керергә әзер иде.

Нәргиз киләчәк кунакларга приборлар куюга, тимер капкадагы кыңгырау шылтырады—Бармаксыз нәкъ билгеләнгән вакытка—минутка минут килеп житте һәм Сенатор эчтән генә аның төгәллеген билгеләп куйды.

Төгәллек, пөхтәлек, барысын да алдан исәпләп кую кебек сыйфатларны прокурор кыюлыктан, батырлыктан, хәтта, кирәк булса, үзенне корбан итүдән дә өстен саный иде, чөнки тәҗрибәсе буенча белә: җинаятьчеләрнең туксан проценты нәкъ менә шушы сыйфатлары булмаганга органнар кулына эләгә дә. Шуңа күрә ул төгәл кешеләргә аеруча ышана иде. Кунакларны каршыларга прокурор үзе дә чыкты, чөнки куркынычлы заданиегә барыр алдыннан бер-беренә ышану, танышу кирәклеген яхшы белә иде. Кунакларны өстәл янына да үзе алып килде. Өстәл ялт иткән. Әле генә монда кемдер тәгам җыеп утырган диярлек түгел. Сухроб тагы бер мәртәбә йорт хуҗасының сәләтенә сокланып куйды.

Җинаятьчелек дөньясын китаплар һәм кинофильмнар буенча гына белүчеләр шунысын да искәрсен: соңгы биш ел эчендә генә дә аларның бу өлкәдәге "белемнәре" нык искерде, ярамас хәлгә килде. Розарий янында каршы алынган өч яшь ирне, тышкы кыяфәтләренә карап, йә, кем соң инде җинаятьче дияр, болар сөйкемле, ягымлы, беренче карашка, яхшы тәрбия алган кешеләр, менә дигән итеп киенгәннәр, үз-үзләрен тоту манералары да зыялы, хәтта аристократларча дияргә була иде.

Нәргиз белән Мәмләкәт аларны шулай кабул иттеләр дә, хәер, алар прокуратура әһелләренең эшен дә юньләп белмиләр иде, шәрекъта ирләр хатын-кызга үз эшләре хакында чишелеп сөйләмиләр, сөяркә күкрәгенә ятып, авыр тормыштан зарланып егълап яту гадәте юк. Хәтта аларны якыннан белгәннәр дә ялгышыр иде. Әйтик, мәсәлән, Сергейны проект институты архитекторы, коммунист, җәмәгать эшләрендә актив катнашучы, филателист, гаиләсен кайгыртучы ата дияр иде. Аның икенче, серле тормышта да яшәвен кем белсен? Әле бер сәгать элек кенә ул Бармаксызның фәрманы буенча "Зеравшан" рестораны яныннан "Жигули" урлап китте, хәтта таныш кешесенеке икәнен белсә дә, тайчанып тормады. Шул машинада алар Нәргиз өенә килделәр дә инде.

Икенчесе, Погос атлысы, озын буйлы, чибәр, бераз калкыбрак торган үгез күзлесе—хатын-кызлар андыйлар өчен үлә инде—шулай ук партия әгъзасы, авыл хуҗалыгы министрлыгында эшли, бүлек белән җитәкчелек итә, тутырылган анкеталары буенча да менә дигән кеше. Хәзер Европа буенча круизга документлар тутырып йөри, ә анда, кордон артына, бик тә ышанычлыларны гына җибәрәләр. Төнге операция өчен Артем вәгъдә иткән акча аңа шул круиз өчен кирәк иде. Нинди операция ул, анда нишләргә—таларгамы, үтерергәме, урларгамы, берәүдән бирәчәген суырып алыргамы, зур түрәнең баласын урларгамы? Монысы аның башына да кереп карамады. Бармаксызның юкка чакырмаганын белә, чүп-чар белән маташмаячагын да сизә ул.

Бармаксыз кушаматлы Артем гына партиядә түгел, югары белеме дә юк, шуңа карамастан, ике тапкыр утырып чыгу мәктәбе узды, ә хезмәт урыны—"Сыра-Су" системасында эретеп ябыштыручы. Эшендә артык күзгә ташланмый, шулай да аның белән күрешергә трест мөдире иң беренче йөгереп үзе килә, кечерәк рангтагы начальникларны әйтәсе дә юк. Аның алтын куллы икәнен белүчеләр якты акылга ия икәнен дә онытмыйлар. Ул ремонтлап булмый торган импорт автоматларны, суыткычларны, агымга корылган линияләрне, суытма ясау установкаларын шундук рәткә кертә, аякка бастыра, шушы осталыгы, таланты өчен аны яратып Ювелир дип кенә йөриләр, тик

шулай да, дөньяга Бармаксыз кушаматы белән билгеле. Әлеге кушаматны ул Карагандадан, беренче утыруыннан котылып чыкканда ияртеп кайтты, анда бер бәрелештә үткен хәнҗәрне йөзеннән тотып каерганда җуелган бармак истәлеге дә ул кушамат. Җәйге сезонда Ташкентның иң күп кеше йөрүче урыннарында: аэропортларда, автовокзалларда, тимер юлда эшләп утыручы иллеләп газлы су автоматы аныкы икән, дип тә сөйлиләр. Уен бизнесында пай алу өчен хәзер Бармаксыз акча туплый, ә уен автоматлары белән бөтен башкала тулган. Шушындый тормыш алып барган Артем Парсегян ярдәмчел кешеләргә таяна белде, бигрәк тә хокук сагында торучыларга, шуңа да ул прокурор Әкрәмхуҗаев белән дуслыгын саклый, хуҗасыдай санаган кешесе янына беренче чакыруга ук йөгереп килә иде.

Төнге кунакларны хуҗабикә белән таныштырганнан соң, Сухроб киң күңелле хуҗаларча аларны дастархан янына чакырды. Өстәл янына утырганчы Бармаксыз табынны буеннан-буена үлчәгәндәй карап чыкты һәм, гаҗәпләнүен яшерә алмыйча, әйтеп салды:

—Мин нидән башларга да белмим, монда чын мәгънәсендә "могҗизалар кыры" икән, хәтта мин үлеп яраткан яшь бамбук салаты да бар...

—Анысы да проблема түгел, кадерле Артем, подвалда синең өчен махсус әзерләнгән күчтәнәч тә күрдем мин. Анда яшь бамбук үсентеләре дә булмас дип кем әйтә ала...—дип бүлдерде Парсегянны прокурор ярдәмчесе.

—Хикмәт подвалдамыни, Сәлим, анда барысы да бардыр, бары тик булдыклы хуҗабикә генә җитми,—дип җаваплады Бармаксыз һәм шушы сүзләре белән Нәргизне тулысынча үз ягына аударды.

Кунаклар утырышуга, табын шунда ук җанланып китте, күңелле генә әңгәмә башланды, бәйрәмчә төс алды. Мәмләкәт тагы да чибәрләнеп, җанланып китте бугай. Сухроб күрмәде түгел, күрде: кыз чибәр Погосның карашларыннан читенсенә, бәлки моңа кадәр шулай ачыктан-ачык аңа беркемнең дә караганы булмагандыр. Әмма прокурор инженерның кәефен бозмады, һәрнәрсә үз вакыты белән дип уйлап куйды ул, Погосның карашында бернинди ут, дәрт юк (ә чын кызыксыну шунсыз булмый), кызның күкләрдә йөзүен сизми, күрәсең, ул үзенең чибәрлегеннән теләсә кайсы хатын-кыз затын аяктан дә егарлык дип саный ахрысы.

Нәргизгә дә күңелле булып китте, яшьләрнең кабымлыкларны мактавы аңа ошый, салат, сумса сонга калып килгәннәрнең аппетитын шулкадәр күтәреп җибәрде ки, барысы да бердәм сый-нигъмәткә ташландылар, шуңа карамастан, исерткеч эчемлекләрне беркем егылып эчмәде. Бармаксыз бер грамм да капмады. Озакламый Сәлим белән хуҗабикә ике табак пылау алып керделәр, аны ашар алдыннан кечкенә генә бокал белән коньяк эчтеләр. Сенатор аны соңгысы дип атады, пылау ашаганнан соң эчәргә ярамаганлыгын барысы да белә иде.

Өстәлгә бер поднос төрле төстәге чәйнекләр утыртылгач, Сухроб үзенең ярдәмчесенә карады, тегесе Нәргизгә ым какты һәм хатыннар өстәл янынннан гаип булдылар. Сенатор сәгатенә карап әйтте:

—Төн резина түгел, эшкә тотынырга кирәк.

—Без эшкә әзер, шеф, көзге төндә без башкарып чыга алмас эш юктыр дим, яшел кытай чәе эчә-эчә тыңларбыз,—дип елмайды Бармаксыз һәм аркадашларының пыялаларына чәй агыза башлады. Әмма хуҗа эш турында, операция хакында сөйли башлауга, чәй онытылды, пыялаларга кагылучы да булмады.

—Шәрекъча ерактан башлап тормыйм. Әйләнгечтән юл яхшы дисәләр дә, үгезне мөгезеннән тотар чак, вакыт ашыктыра. Башта кыскача гына. Бер оешманың сейфында пичәтләнгән "дипломат" ята. Анда нәрсә бар? Безне дә, сезне дә кызыксындырган нәрсәләр—акча, кыйммәтле ташлар. Джизак өлкәсендә конфискациягә эләккән әйберләр.

—Димәк, анда репатриант әрмәннәр Якын Көнчыгыштан китереп саткан энҗеләр дә бар...

—Булырга мөмкин,—дип тыныч кына җавап бирде прокурор Артемга.

Үзе ул энҗегә шаккатмый, бриллиантны өстенрәк күрә иде, шуның өстенә, кейста тегесе дә, монысы да юк икәнен дә яхшы белә иде. Бармаксызга

җавап биргәндә, күз кырые белән ярдәмчесенә карап алды: акча һәм кыйммәтле ташлар мәсьәләсенә ничек карар икән? Миршаб, ир кеше буларак, тынычлыгын җуймады, ул прокурорның нигәдер ялган сөйләвен дә аңлаган иде.

—Операция җинелләрдән түгел, ләкин шундый типтагылардан катлаулырак та, куркынычрак та булмас, нәтиҗәсе безнең кыюлыгыбызга торырлык булыр. Син әйткәнчә, Артем, куркынычның күзенә карамаган кеше шампан эчми. Кейс яткан бина саклана, әмма мин бинаны яхшы беләм, анда эшләгәнем бар. Калган вак детальләр турында барып житкәч әйтелер. Ставка болай: яртысы—безнеке, яртысы—сезнеке! Барамы? Килешәсезме?

—Бер шартым бар,—дип сүзне Бармаксыз бүлдерде, прокурор шиккә төшеп Парсегянга карап куйды.—Тиешлесен бүлешкәнче, бер бик гүзәл ювелир эшләнмәне яисә энже муенсаны гаҗәеп хуҗабикәбезгә бүләк итәрбез, шундый да бай табын, кунакларга хөрмәт-игътибар андый бүләккә торырлык!—Кинәт яңгыраган бу тәкъдимгә барысы да ризалаштылар.

—Сейф кайсы катта?—дип сорады Парсегян.

—Икенчедә. Бүлмә тәрәзәсез, шуңа башта лифт янындагы холлга үтәбез, андагы тәрәзәгә тимер рәшәткә куелмаган. Бездән соң башларын ташка орырлар, рәшәткә дә куярлар, сакчыларны да арттырырлар, әмма соң булыр. Яшен яшьнәмәсә, урыс чукынмас, ди. Бездә шулай. Ә кейсның кайсы этажда булуы мөһим түгел, бина бит дүрт катлы гына, бу сина Нью-Йорк түгел, анда гына ул илле яисә сиксәненче катларда йорт басып йөрүләр. Артем, нигә әле сине этаж кызыксындыра?—дип борчыла калды прокурор, ул аның юк-бар сорау бирмәсен белә иде.

—Өченче көн инде уң аягым тартыша, рульдә йөри алмыйм, чыдармы дип куркам. Штраф изоляторның бетон идәннәре шаукымы, яшь чагында тәҗрибәсезлектән мин аннан чыкмадым диярлек. Лагерь паханнары белән үлемгә үлем дип сугыштым. Мине дә хөрмәт итсеннәр дидем, ә анда матур күзләр өчен генә берни дә бирмиләр.

—Кызганыч, әлбәттә, борчылма, үтәр әле. Киләчәктә Хужа-Оби-Гарма дип йөртелгән родон чишмә-күлләренә барырсың, алар Памирдамы, Варзоб тарлавыгындамы шунда, радикулит, артрит кебек нәрсәләрнең бар икәнен дә онытырсың. Тик алдан әйтеп куй: син эштән чыксаң, Сергей яисә Погос сейфны ача алалармы?

—Булдырырлар микән...—диде Бармаксыз һәм, шикләнгәндәй, иптәшләренә карап алды.

—Ничек инде алай... Бөтен илдә комплекслы хезмәт бригадалары канат җәя, һәр кеше ике-өч профессия үзләштерә, ә сездә тәртипсезлек,—дип сүзгә кысылды Сәлим-ярдәмче, барысы да ихтыярсыздан көлешеп алдылар.

—Ә сезнең өлешкә кертеп, тагы кемнедер алып булмыймы? Куш бит шути-мути гына түгел,—диде Сенатор.

—Сезнекенә түгел, безнекенә икәне аңлашыла,—дип уйга калды Бармаксыз. Аннан, авыр паузадан соң, әйтеп салды:—Бездә бер егет бар-барын, хәер, ул безнеке үк түгел, Ростовтан, ярты ел элек кенә ирекkә чыккан. Кушаматы—Кощей, тәнендә сөяк тә, наколкалар гына, ләкин оста егет, чукынмыш... Аны бик мактап сөйлиләр. Ташкентта беренче тапкыр гына әле. Безнең якны күрергә, җылынып алырга, җиләк-җимеш ашарга килгән. Төрмәдә витаминнар белән кысынкы бит, ә ул гомеренең өчтән берен шунда уздырган.

—Ул синең белән бергә утырган идеме, әллә берәр ташкентлы беләнме?—дип сорады прокурор, Кощейга карата анда идея туган иде инде.

—Срокны ул минем белән дә, берәр ташкентлы белән дә узмады, дуслар шылтыраттылар, ике атнага шундый-шундый адәмне кабул итегез, диделәр. Бу гадәткә кергән инде. Эш турында да ым кактылар, әгәр килеп чыкса, Кощей кебек "взломщик"ны табу кыен.

—Риза! Кощей икән Кощей, әмма ул бу сәгатьтә лаякыл исерек яисә афьюннан җиденче кат күктә йөзми микән?—дип саклану чарасы күрде прокурор.—Кайберәүләр шулай ял итә бит...

—Юк, ул үзенә тиешлене эчеп бетергән инде, ашказаны кабул итми, ди,

шуңа да җимешкә килгән дә. Хәзер ул формада, кәрт уенында бик зурдан тәгәрәтә.

—Бик шәп, әйдәгез машиналарга. Артем минем янга утырыр, юлда Ростовның җимеш яратучысын алырбыз, ә калганнар Погосның урланган "Жигули"ена. ГАИ туктатса, алга чапмагыз, Сәлим әйтер, прокуратурада урланган машина калдырганнар, ә сез янәсе, аны хуҗасына илтәсез. Сергей адрес, фамилияләрне әйтер, алар аның әшнәләре булыр, соңыннан адрес, фамилияләр постта торучы милиционерга да ирешер. Шулай булгач, операциядән соң машинаны хуҗасына кайтарырга кирәк булыр. Аерылып шактый гына киткәч, прокурор тагын сорады:

—Эш кораллары алырга онытмадыңмы, карап-тикшереп чыктыңмы? Бер егерме минутка утны сүндереп торасы булыр, анда электр хуҗалыгы койма буенда гына, юри эшләсәң дә алай җайлы булмас.

—Барысы да тәртиптә. Сезнең белән очрашмый торган арада мин Германиядә эшләнгән нәрсәләр кулга төшердем, шуның өстенә бер комплект швед инструментлары. Фантастика, билләһи, корычын, кискечләрен күрсәң иде! Эх, кайда безнең Круппլар, Золингеннар?!

—Миңа да йортта, хуҗалыкта бер набор булса артык булмас иде,—дип куйды Сухроб. Ул, чыннан да, яхшы инструментка мөкиббән иде.—Миңа да таба алмассыңмы?

—Бу арада гына булмас, әмма юлын өйрәтермен. Каталог буенча берәүгә заказ биргән идем, ул кордон артына чыккалап йөри. Сезнең андый танышларыгыз минекеннән күбрәктер.

—Киңәшең өчен рәхмәт. Колак салмый булмас, ахрысы...

Машина Луначарский шоссесына килеп керде, Парсегян әйтмәсә дә, прокурор Кощейның кайдалыгын чамалый иде инде, ул шәһәрдәге кәрт уеннары уздырыла торган барлык яшерен урыннарны—катраннарны белә, ә хөкүмәт йорты янындагысында чын-чынлап гаять зур суммаларга уйныйлар, аны тотучы да чырлы-бырлы адәм түгел, танылган кеше, теләсә кемне кертми дә кертми инде ул. Әгәр Кощейны Ташкентның иң кыйммәтле катранында күргәннәр икән, Сенатор моңа да шатланды гына, татуировкалы ростовлы артыннан ачык эз калырга тиеш. Нәкъ ул фаразлаган җиргә килеп җиттеләр. Бармаксыз машинадан чыга башлаган иде инде, прокурор җәһәт кенә аны туктатты:

—Юк, син түгел, сине бу кичтә монда күрергә тиеш түгелләр,—диде ул аңа ышандырырлык итеп, хәер бу кисәтүдә аның үз максаты да бар иде.—Әнә чибәр Погос керсен. Кощейга якын килмәскә, аңа ничек ым кагарга өйрәт-күрсәт, шунсыз ул чыкмаячак. Кемнәндер йөз тәңкә "атсын", алга таба бу аның өчен алиби булачак,—болары турында да тиешенчә сөйләп, прокурор һаман үз максатларын кайгырта иде.

Җиде минутлап вакыт узгач ике катлы бинаһая зур йорт капкасыннан, як-якларына каранып, ябык гәүдәле, үтә ыспай киенгән берәү килеп чыкты.

—Кощей шушы инде,—диде Артем һәм машинадан тышка ашыкты. Алар озак кына нәрсә хакындадыр бәхәсләштеләр, Кощей кулларын болгый-болгый нәрсәдер расларга маташтымы, анысы билгесез, ә Сенатор уйлап алды, ростовлы яисә бик күп ота, йә бик күп оттырып килә, аның оттыруы кирәк иде, шулай булса ул, шиксез, ризалашачак, йомшара төшәчәк.

Погос күренмәде, күрәсең, аңа бурычка бирүче табылмый торгандыр, аның гадәтен беләләр бит. "Акча бирмиләр, әмма нинди ныклы алиби оештыралар",—дип эчтән генә иронияга чумды прокурор. Бу минутларда Әкрәмхуҗаев тагын шунысын да уйлап куйды: әгәр дә мәгәр шушы Погос яисә Сергей Бармаксыз белән бер җинаять өстендә тотылсалар да моны мәңге танымаячаклар, Артемны күрсәтмичә, барысын үз өстенә алачаклар. Законда гы бурны күрсәтү—үзеңә үлем карары чыгару дигән сүз ул. Тикшерү вакытында ычкындырсалар, күзгә-күз очраштырганда яисә судта барысын да кире кагачаклар. Ә безнең теоретик законнчылар моны исәпкә алмый. Төрмәгә җыен вак-төяк эләгә, тәҗрибә туплаган Бармаксыз кебек авторитетлар инде беркайчан да! Үзләрен үтә акыллы санаучы академиклар, депутатлар закон чыгарган булалар. Беләмени алар җинаятьчел мохиттагы

вәзгыятьне, ул бит гел үзгәреп тора, төрмәләрдә икенче эшелондагы вактөяк, төп гаепләләр исә шампан эчә һәм алдагы җинаятьләргә план кора, дип ачулы гына уйлап куйды прокурор.

Еш кына ул шулай үзенең кем икәнен онытып җибәрә, үзен бер үк вакытта шымчы-юрист та, бур да санап бутала һәм берәр кинәшмәдә, уйларын чыгарып салып, "башын балта астына кую"дан шикләнә иде.

Чынбарлык белән теория арасында буталып беткән һәм, тормыш параметрлары бөтенләй икенче булса да, чит илләрнекенә тәңгәлләштерелеп килүче законнарның камил булмавы турында уйланып, прокурор арткы утыргычка Бармаксыз белән Кощейның кереп ауганын сизми дә калды.

—Синең шоферың бигрәк тә важный кеше икән,—дип йозак ватучы татуировкалы кулы белән прокурорның җилкәсенә сугып алды.

—Тимә кешегә, иң яхшысы, башта исәнләш, ул фамильяр сөйләшүне яратмый,—диде каңгатьлеге йөзенә чыккан Артур, аңа, күрәсең, гастрольләрны сындыру җиңел булмагандыр.

—Менә сиңа мә! Уен мач килеп барганда гына тартып чыгардың, сезнең белән ни табарымны юньләп белмим, мәгәр биш кисәк минем яннан шуып очты... Житмәсә тагы тәрбияле адәм булуымны таләп итәләр, авызына кергәнне тартып алганда каян килсен ул тәрбиялелек?!

—Авызыңа су кап, Кощей, юкса хуҗа сиңе бер тел бистәсе дип уйлар, ә сине аңа мин тәкъдим иттем...—Артем йомшак кына әйтсә дә, Кощей шундук тынды, гәүдәсен турайтты, ул монда Бармаксызның түгел, ә руль артындагы кешенең "главный" икәнен аңлап алган иде инде.

—Гафу, егетләр, гафу, җыен исәр җыелган катраннан чыгуга ук кинәт кенә җитди кешегә әйләнеп буламыни?—диде Кощей ризалашкандай.—Ә сез әллә нинди шпионнар кебек, видиктан детективлар карап өйрәндегезме?

—Кесәләренне тикшер әле, анда берәр документ-фәлән юкмы, Аллаһ сакласын, төшеп калулары бар,—диде прокурор.

—Мин эшкә җыенмадым бит, ксива үзем белән.—Кунак Артемга яна паспортын сузды.—Тагы Ростовка билет бар,—дип өстәде ул, кесәсен актарып.—Кайтыр юлга алдан ук алып куйган идем.

—Билетка аптырама, ул төшеп калмас,—диде прокурор тәкәллефсез генә, ул билетның аның кесәсендә калуын тели иде.

Пушкин мәйданына җиткәндә, Әкрәмхуҗаев күз кырые белән генә сәгатенә карады: барысы да уйланылган график буенча бара иде. Аның фикеренчә җинаять кылу өчен иң яхшы вакыт төнге өч белән дүрт арасы, йөзләрчә җинаять эшләре шуны раслый, хәер, ул моны аңлауга үз тәҗрибәсе аша да килде.

Сәгать өч тулып килә иде инде, кирәкле урынга барып җитәргә бишалты минут вакыт калды. Иске балалар тудыру йорты артындагы тыкрыкка керүгә, Артем Парсегян шыбырдый башлады, ул кая килгәннәрен аңлады, чөнки бу урам прокуратура ишегалдына терәлеп тора, ләкин авыз ачып берни әйтмәде. Машинадан чыккач кына әйтте:

—Сухроб, бу республика прокуратурасы бит!

—Шуннан ни булган,—дип тыныч җавап бирде прокурор.—Җинаятьләр кодексы банк талау белән прокуратура талаудагы аерманы исәпкә алмый.

—Шулай да...—диде Бармаксыз шикләнеп һәм каушый төшеп.—Мондый өй басуда катнашканым юк иде әле...

—Бигрәк тә шәп! Тәҗрибә тупларсың, хәер, син үзең дә чамалыйсыңдыр, алар безне көтеп тормый, шул өстенлекне файдаланып калыйк. Эшкә алыныйк дисәк, без синең белән караштырып килик, алар тәмәке тартмый гына, машинада тыныч кына көтсеннәр.

Бармаксыз нишләргә кирәклеген әйтеп машиналарны йөреп чыкты, Әкрәмхуҗаев янына килде һәм алар икәүләп караңгылыкта гаип булдылар.

—Кайчандыр эш юлымны мин монда башлаган идем,—диде Сенатор пышылдап кына.—Эштән таясы булса, бервакытта да парадныйдан китми идем, соңга калсам да гел арткы ишектән йөрдем, шулай булгач, арткы юлны яхшы белү безнең файдага.

Алар балалар тудыру йортының ташландык ишегалды буйлап киттеләр,

монда төрле ярдәмче биналар, иясез калган торак йортлар гына иде. Бары койма буендагы флигельда гына кемдер тора булса кирәк. Элек монда эшләгәндә йөзем бакчасында кемнәрнеңдер казынып йөргәнен күргәләгәне бар иде.

Койма буенда алюминийдан эшләнгән зур һәм ныклы баскыч бар иде, аны икәүләп тиз генә кирәкле урынга илтеп куйдылар. Төн караңгы, ай урагы беленми дә диярлек, шуңа да карамастан, яктылык җитәрлек, чөнки прокуратура ихатасы яхшы яктыртыла һәм бу урынны күзгә-башка ташланмыйча кисеп үтү куркыныч кына түгел, хәтта мөмкин булмаслык иде.

Хәзер нишләргә? Уйлаштылар да койма аша икәүләп үтәргә булдылар, үзләре белән алып килгән нейлон баскычны ишек алдына аттылар, шулай итеп ихатага керү һәм чыгу юллары барлыкка килде. Артем инструментларын алып килде. Әкрәмхуҗаев Парсегянны электр шкафлары янына үзе алып барды. Болай килештеләр. Утны өзүгә әзерлекне Артем башкара, ә сүндерүен Сенатор сүндерә, чөнки ул бердәнбер кораллы кеше һәм, кирәк була калса, страховка аның ягыннан булырга тиеш, прокурорның "дипломат"сыз да китәсе килми, әмма сак булу да кирәк, болай уйлау акыллы һәм затлы кеше фикеренә тартым иде, шуңа Парсегян аның белән килеште.

Щитны әзерләгәч, Парсегян Сергей белән Погос янына барып килергә тиеш, алар, үз вакытында икенче этаждагы тәрәзәне алып, бинага керү өчен Кощейга юл ачарга тиеш булалар. Аннан соң алар машина янына кайтып, салонда операциянең төгәлләнгәнен көтәләр. Алга таба эшкә Ростов кешесе керешә. Кабинет тәрәзә янында гына, лифттан ундарак, ишектә "Тикшерү бүлеге начальнигы иптәш Ходжаев А. Х." дип язылган такта. Әгәр операция уңышлы килеп чыкса, ишектәге "Бодэ" фирмасы йозагына һәм сейфның йозакларын ачу өченгә җиде-сигез минут вакыт кирәк булачак.

Бармаксызны ишек алдыннан җибәреп, прокурор архитектор белән инженерны көтә башлады, алар бинага таба килә башлауга, ул щитны сүндерергә тиеш.

Ул тагы сәгатенә карады, сәгать телләре дүртенче унбиш минутны күрсәтәләр иде. "Мин утны сүндергәндә сакчы черем иткән чак булсын иде. Күзләрен ачканда, ул кайчан йокыга киткәнен, күпме йоклаганын белмичә мингерәүләнеп торган арада кейс Кощей кулында булачак",—дип фикер йөртте Әкрәмхуҗаев, үзенең салкын канлылыгы һәм тынычлыгына хәйран калып. Барысы да тәҗрибә белән килә икән шул, Коста белән ныграк дулкынланган иде. Фәлфәси уйларга тирән керергә аның вакыты юк иде, койма өстендә Погосның көдрә башы күренде һәм Сенатор аңа нейлон баскычны сузды. "Аңа әҗәткә бирделәр микән?"—дигән уй башына килде һәм прокурор елмаеп куйды.

Матур егет артыннан Сергей күренде, аларның койманы бик җинел үтүләрен күреп, Әкрәмхуҗаев "эшкә килгәннәр"нең спорт белән дус икәнлекләрен дә аңлап алды. Алар машинада киемнәрен алыштырганнар, хәзер исә гади трикодан, аякларында йомшак башмаклар иде, Сергейның муенында ябышкак тасма төргәге да бар иде. Бу тасма тәрәзә пыяласына ябыштырыла һәм пыяла һич ватылмыйча тавышсыз гына киселә. Тәрәзә кискеч алмаз, кечкенә фонарь, өтерге сыман пәке һәм ефәк бау төремтесе—бар булган кораллары шулар иде. Сухроб аларга тәрәзәне күрсәтте, ничек барырга икәнен аңлатты, аннан соң, щиттагы тотканы тартып, утны сүндерде дә егетләрнең аркасына төртте—алга!

Пистолетны ул прокуратура ишегенә төбәде, әгәр ишегалдында тавыш ишетсә, сакчы шуннан чыгарга тиеш иде. Прокурорның сак колагы егетләрнең аяк астында нидер шыртлаганын, коелганын ишетте, алар инде икенче катны штурмлап яталар иде, күз кырые белән стенада фонарь яктысын күрде, әмма бина ишеге ишегалдына таба ачылмады. "Көндезен коты ботына төшкән милиционер йокымсырый бугай, иң йокы килгән чак шул бу. Кощей эшкә тотынгач, уянса да, утның нилектән сүнгәнен уйлый-уйлый, бернәрсә дә эшли алмаячак"—Сенатор шулай фикер йөртте һәм ул хәзергә барын да дөрес исәпләгән иде.

Тәрәзә пыяласын алу операциясе сузылды, шунда ул ефәк бауда җиргә

төшерелгән пыяла тавышын ишетте, бер-ике минуттан икенчесе дә алынып. Прокурорга күнелле булып китте, сигарет кабызыйм гына дигән иде, кемдер кинәт анын җилкәсенә кулын салды... Сенатор борылып пистолетыннан чак кына атып җибәрмәде, Артемның тавышын ишетте:

—Эшләр ничек, шеф?—Ул Кощей белән бергә килгән иде.

Прокурор, куркуын һәм дулкынлануын яшеребрәк, әйтте:

—Нормально, график буенча. Ике-өч минуттан монда булачаклар һәм соңгы этап маэстроныкы.—Шулай да түзмәде, кисәтү ясады:—Операцияне боздыгыз сез, әгәр анда шухер булган булса? Барыбыз да баскычта калабыз, ә син, Артем, авырткан аягың белән, давай марш машинага, бернинди дә үзешчәнлек кирәк түгел безгә. Кощей белән безне руль артында көт.

—Мужик дөрес сөйли, ычкын, Бармаксыз, "Жигули"га. Безгә тамашачылар һәм кул чабулар кирәкми.—Ростовтан килгән егет Әкрәмхуҗаевның сүзләрен яклап чыкты.

Алар бинадан аерылып киткән фигураларны күрделәр. Сергей белән Погос коймага таба чабалар иде, аларның авыр сулауларына кадәр ишетелеп тора. Якын килүгә эстафетадагы кебек фонарьне Кощейга тоттырдылар.

—Ну, киттем мин,—дип тыныч кына әйтте ростовлы һәм кызу адымнар белән бинага таба китте, күрәсен, бу анын өчен гадәти эш. Йөгергәндә анын муенында инструментлар салган тире сумка селкенә иде.

Сергей белән Погосны прокурор койма аръягына озатты һәм аларга иске шәһәрдә, үзе эшли торган район прокуратурасы янында көтәргә кушты. Сенатор элеккеге урынына басып ишекне тагы мушкага алды, бу юлы ул кыштыртау да ишетмәде, фонарь яктысын да күрмәде, Кощей чын asларча эшли иде, прокурор анын биек тәрәзә рамыннан кереп киткәнен генә күреп калды, сейфка барып җитәргә аңа өч кенә атлыйсы иде.

"Берничә минуттан теләгем тормышка ашар да зур кешеләрнең серләре минем кулда булырмыни?" дип хыялланды ул. Әмма күнелендә яңгыраган каты тавыш татлы хыялларны өзәргә мәҗбүр итте:—Үзеңне кулга ал, игътибарлы, җыенкы бул, тагы нибары биш минут калды...

Әгәр баштарак ул күзләрен ишектән алмаган булса, хәзер бар игътибарын тәрәзәгә юнәлтте, әмма Кощей күренмәде. Ул исәпләгән вакыт узгач, ростовлы белән бер-бер нәрсә булмадымы, коралны бирәсе калган икән дип уйлавы булды, тегесе тәрәзә арасына кысылды.

Прокурорның "Ура!" кычкырасы килде, хәзер ул аннан күзен дә алмый иде: егыла, сөртенә, тавыш чыгара күрмәсен тагы.

Бу дулкынлану, азарт, түземсезлек Сенаторны алдадылар, ул үзе мушкага тоткан ишекнең ачылуын күрми калды, бетон баскычта милиционер күренде. Көндез пистолет кобурасын ача алмый интексә, Костаның прокурор Азлархановны атып үтерүенә комачау ясый алмаса, ул хәзер коралын кулына тоткан һәм үзенең шул югалып калуын, акрынлыгын кайтарып алырга, тизҗитез эш-гамәл күрсәтергә әзер иде, алга таба милициядә пенсиягә кадәр эшләп китәрлеге бар иде. Утны сүндергәндә ул йокымсырый иде, ләкин караңгылыкны прокурор Әкрәмхуҗаев мантыйгында түгел, ә үз уйларында кабул итте: милиционер төне буе һөҗүм көтте. Кеше үтерткән чит-ят "дипломат" аңа тынычлык бирмәде һәм икенче этажда кыштырдаулар ишетеп, басып керүче кебек тыныч кына ишеккә китте, нияте: "төнге кунак"ны яхшылап каршыларга иде!

Кощей "дипломат" белән ишегалдында күренүгә баскычтан тавыш ишетелде:

—Селкенмә, юкса атып үтерәм!

Милиционер тәбәнәк баскычның ике басмасыннан төшеп төнге каракка таба китте. Шушы мизгелдә үк Кощей койма ягыннан ату тавышы ишетте, ул хәтта пистолет утын да күрде, сакчы кычкырып куйды да җиргә егылды. Көтелмәгән хәлдән сейф ачучы урынында катып калды, ул анын үзенә таба чабып килгәнен күрде.

—Ну, син молодец, әйбәт майлыйсың,—диде ул аңа пышылдап кына. Сенатор дәшмәде, кейсны сузучыга пистолетын төзәде дә атып җибәрде, анын башын тишеп чыккан пуля баскыч янындагы имәнгә барып керде.

Кощей кулыннан "дипломат"ны тартып алып, прокурор сакчы янына килде, аны аркасына әйләндерде. Пистолетын тартып алганда тегесе хәйран калып пышылдады:

—Сухроб Әхмәтович?!—сакчы шәһәр прокурорларының барысын да бик яхшы белә иде.

Башка чара юк, Сенаторга аңа пистолетны терәп атарга туры килде.

Икенче пистолетны бил каешына тыгып, прокурор койма янына йөгерде, нейлон баскычтан үрмәләп чыкты да аны тартып алды. Машинага таба ул яшеренмичә йөгерде, пистолет тавышларын исәпкә алганнарын белә иде. Прокуратура территориясендә ни барганын аңлаган Бармаксыз машинасын борып якынрак китерде, моторын да сүндереп тормады.

Прокурор салонга кереп аугач та сорады:

—Ә Кощей?

Сенатор, авызы белән һава йотып, аның тезенә канлы пистолетны ыргытты һәм Артур ишек алдындагы өч атуның нәрсә икәнен аңлап алды. Прокурорның "Амин!" диеп куюы да бернинди икеләнүгә урын калдырмый иде; машина тиз генә урыныннан кузгалды. Погосны моннан унбиш минут элек җибәрү тактикасы да аңлашылды, ике машина белән качып китү бик хәтәр эш буласы булган икән шул. Урам чатында ул машинаны акрынайта төште, кая чабарга дип уйлады, прокурор, рульне унга борып, боерды:

—Иске ТашМИ ягына, әйләнгеч юлга чык, үзәкне бикләделәр инде, ә бездә юлларны бикләү яхшы куелган.

Машина әйләнгеч юлга чыккач кына Сенатор телгә килде:

—Тизлекне кимет, кума. Берәр арык янына туктат, кулны юасым бар!—Үзе көтмәгәндә көлеп җибәрде:—Артем, карале, кейсны мин һаман да кулдан җибәрмим икән.—Сенатор аны арткы утыргычка куйды һәм бераз паузадан соң шатланып әйтә салды:—Операцияне барыбер үтәдек бит!

—Ә Кощей?—дип сагышлы сорады Бармаксыз.

—Җину югалтуларсыз гына бирелми, кадерле Артем,—дип философларча ычкындырды прокурор.—Аның өлеше изге, дуслар таләп итсә, мин үзебезнең ярты өлештән бирергә дә әзер,—дип тәмамлады ул, башка бу темага сөйләшергә теләмәвен сиздереп.

Кощейның үлеме прокурор алдында торган зур мәсьәләләргә җавап табарга мөмкинлек тудыра иде: кем һәм ни сәбәпле республика прокуратурасыннан "дипломат"ны урлаган?

Ростовка алынган авиабилеттан тыш та, теләсә кайсы тәҗрибәле тикшерүче, татуировкасы буенча гына да, Кощейның тулы биографиясен яза алыр, ә бер сәгатьтән аның чын фамилиясен әйтеп бирер иде. Хезмәте буенча Әкрәмхуҗаев прокуратурада берничә "эш"нең ятканын белә, бу бандит группалары нәкъ менә Ростовтан, алар эссе Үзбәкстандагы яшерен миллионерларны дер селкетеп торганнар, үз максатларына ирешү өчен бернинди чарадан да тайчанмаганнар. Аларның бәреп керүләрен дә акларга була, эш "почерк"лары да бер-берсенекенә охшаш: тегеләре дә, болары да үтә усаллык белән аерылып торалар. Бигрәк тә Кощейның ташкентлыкылар белән берәр җирдә утырганын да белсәләр, кансыз Сенаторның алдан уйланган версиясен газиз прокуратурасы шымчылары күтәреп кенә алачаклар. Аннан соң җинаятьчеләрне эзләү барышы Ташкентны чыгу гына түгел, республика чикләреннән үтәчәк һәм кайдадыр тыныч кына төртелеп туктап калачак. Хокук саклау органнарының эш ысулларын яхшы белгән прокурор алдан ук шуңа исәп тоткан иде инде.

Киң һәм күп сулы арыкны күреп, Парсегян машинаны туктатты, бергә чыктылар, ана да канлы пистолетны юарга кирәк иде. Прокурор сабынлап кулын юды, йөзен, күлмәгенә ябышкан канлы эзне чистартты, чәчләрен тарады. Чистарынгач Артемга әйтте:

—Пушканы бүләк итәм, син аны күптән эзлисең бугай инде.

—Рәхмәт, ышанычлы әйбер,—дип ризалыгын белдерде Артем, ул бу бүләкнең бәясен белә иде.

—Ә хәзер ку, егетләр борчыладыр, таралырга вакыт, аларга бит иртәсен эшкә.

Иске шәһәрдәге район прокуратурасына килгәндә, Сергей урлап киткән машина анда тора һәм егетләр, чыннан да, борчулы күренә иде. "Дипломат" белән машинадан чыгучы Сенаторны күреп, аларның күнелләре күтәрелде, димәк, операция уңышлы барып чыккан, Кощей турында сүз чыгарып та тормадылар.

Миршаб шефны аның кабинетында көтә иде, барысы да шунда кереп тулдылар.

Сухроб авыр "дипломат"ны селтәнеп полировкалы ялтыравык өстәлгә ыргытты. Кейсны ачканчы өстәл тартмасыннан башланган коньяк шешәсе алды, бокал төбенә койды да калганын әйләнә буенча җибәрде. Түземсезлекләре йөзләренә чыккан кәсептәшләре шешәнең авызыннан гына чөмерде. Кабинет хуҗасы Артемның кнопкалы хәнҗәрен сорап алды һәм сургучлы пичәт сугылган шнурларны кисеп җибәрде, көләргә тырышып: "Бер, ике, өч!"—диде һәм "дипломат"ны каерып ачты.

Барысы бергә кейскка иелгәнгә маңгайларын бәргән кәсептәшләрнең ризасызлык авазлары яңгырады.

—Кощей башка "дипломат"ны алган,—диде Артем һәм усал-пычрак итеп сүгенеп куйды.

Әкрәмхуҗаев башын тотып урындыкка ауды, мондый чарасызлыкны сәхнәдән Смоктуновский да күрсәтә алмас иде. Һәрвакыттагыча Сәлим генә түземлелек күрсәтте. Погос еларга җитешкән иде.

—Минем әҗәтләрем күпме, әле круиз өчен түлисе бар, кәрттә оттырган өчен иртәгә счетчик куябыз диделәр.—Аның хәле хәл түгел иде, моны яхшы беләләр: оттырган өчен счетчик куйдыру хәтта төшенә керә күрмәсен!

—Анда тагы бер "дипломат" булгандыр, сейф зур, идәннән түшәмгә хәтле, мин алдан әйтмәгәнмен, Кощейның гаебе юк, ул үзенекен эшләде, яткан җире мамык, гүре якты булсын,—дип тезеп китте прокурор.—Дуслар, гаеп миндә, җавабын да мин бирәм. Сәлим, ач минем сейфны!—Ул Погосны кочып алды.—Кайгырма егет, синең бәланне генә төзәтергә була анысы, бурычыңны да бирерсең, үзебезнекеләрне бәладә ташламыйбыз без.

Ачык сейфтан прокурор йөз сумлык төргәкләр алды һәм унар мең акчаны өстәлгә салды:

—Менә сезнең өлешегез, егетләр, сез үз эшегезне эшләдегез.

Егетләрнең йөзләре бер мизгелдә үзгәрде, Бармаксыз прокурор ярдәмчесенә дәште:

—Сәлим, шефның киң күңеллеген юарга тагы бер шешә юкмы?

Анысы тавышсыз гына башын иде, кабинетына кереп югалды. Бер минут узуга, ул ике шешә коньяк күтәреп әйләнеп керде.

—Шунысы начар, Нәргиз бүләксез калды,—диде Артем, бокалларга "Варцихи" коеп.

Прокурор көлемсерәп "дипломат"ны япты һәм ярдәмчесенә дәште:

—Ә хәзер, Сәлим, син бу документларны өйрәнергә тиеш, сатып алучылар тап, илле кисәктән дә кимгә бирмә, юкса без утыз меңгә яначакбыз.—Кейс кабат сейфта югалды.

Эчеп алганнан соң барысы да өйләренә ашыктылар. Эшкә кадәр бер-ике сәгать ял итеп алырга кирәк, ә прокурор белән ярдәмчегә эш башланмаган әле. Эштәшләре китүгә, алар бикләнделәр һәм сейфка ташландылар.

—Очсызга төште, шактый кыйбат булыр дип уйлаган идем,—диде Сәлим кейсны кабат сейфтан алып.

"Белсәң иде, бу "дипломат"тагы серләр өчен мин ниләр генә түләмәс идем!" дип уйлады прокурор. Әмма хәтта классташына, якын дустына да ул бер сәгать элек ике кешене үтерүен сөйләп тормады.

Прокурор өстәл артына кереп утырды, ярдәмчесе "дипломат"ны аның алдына куеп, янына чүмәшергә теләгән иде, тегесе сөйләп китте:

—Иртә белән "дипломат"ны без хуҗаларына кайтарырга тиеш.—Үзе сәгатенә карап дәвам итте:—Ләкин безнең кулда дүрт сәгать булачак әле, шулай булгач син бик җәелеп утырырга җыенма...

—Кейсны бирергә? Нишләп без үзебезне куркыныч астына куйдык?—дип аптырап сорады ярдәмче, бүгенге төнне ул үз шефын аңламый җәфалана иде.

—Бирмәскә безнен хокукыбыз юк, җаныбызны алырлар, хәзер алар нәкъ шул турыда уйлап утыралар. Хәтерлисенме, операциянең икенче өлешендә мин сиңа чигенә алмыйм дидем. Безне аңламаслар, гафу итмәсләр, хәзер дә шундый ситуация. Кейска ия кешеләр шулкадәр дә көчле, без синең белән күз алдына да китерә алмыйбыз, аларга безнең гомер—тьфү...

—Анлашыла, күрдем мин, Коста сындырылган килеш тә үзен Аллаһы тарафыннан җибәрелгән кеше итеп тота.

—Бик әйбәт, син дә аңладың кемнәр белән эш иткәнне. Алга таба тыңла: без "дипломат"ны кайтарабыз. Костаны Япон кушаматлы Артур Александровичка тапшырабыз, чөнки стенага терәлгәнбез, ләкин "дипломат"ның сере белән танышачакбыз.

—Ничек инде, үзең кайтарабыз дисең?—Миршаб берни аңламый сорады.

Кабинет хуҗасы ярдәмчесенең анламаганлыгын күреп, түземле генә елмаеп куйды:

—Син хәзер подвалга япон ксероксы янына төш һәм барлык документларның да копиясен ал. Ә мин менә бу дүрт кассетаның берсен тыңлап чыгам һәм аларны яздырып алам. Аннан соң без документлар белән кассеталарны кире "дипломат"ка салабыз, пичәтлибез һәм хуҗаларына тапшырабыз. Алар хәзер йөгерәләр-чабалар, нишләргә дә белмиләр. Вакыт узар, бу тарих онытылыр, информациянең читкә чыгуын оештырган кеше зур абзыйларны кисәтеп йөрмәс, документлар анда бит инде. Ә без синең белән материалны үзебезчә файдаланырбыз. Ул вакытта көчле-нык компания эчендә булырбыз.

—Димәк, Коста һәм "дипломат" крайны идарә иткән яшерен "масон" орденына керү өчен безнең взносыбыз?

—Менә син дә минем уй һәм хыялларымны укый башладың,—дип мактады ул иптәшен.—Шулай килеп чыга, әмма партия байлары безнең масоннар белән тигезләшүебез өчен үпкәләргә мөмкиннәр, шайтан алгыры. Хәзер безнең кулда аларның күбесенең сере, аны белеп кулланcак, әле чыбыркы тотып, әле иркәләп, без хакимияткә ирешергә тиешбез, бу минем гомерлек хыялым... Ә хәзергә, кадерле Сәлим, матур хыялларны өзеп торыйк. Эшкә! Кабинетыннан ике кассеталы "Шарп"ны алып кил, без аны узган атнада конфискацияләгән идек, ә үзең подвалга төш, ксероксны әзерлә. Ун минуттан мин сиңа беренче документларны бирермен.

Ул өстә яткан кәгазьләрне алды, алар распискалар, хезмәт хакы бирү буенча төрле сәер ведомостьлар булып чыкты, алар бухгалтерия отчетларыннан төгәл-матур итеп кисеп алынганнар иде. Бит артыннан битне тиз генә карап чыгып, Сенатор шаккатудан сызгырып куйды, әлеге кәгазьләрдә бик тә кызыклы фамилияләр күренә иде, бигрәк тә бер өем расписка кәгазьләрендә, күрәсең, аларны чит күзләрдән нык саклаганнардыр.

—Башлап җибәрергә начар түгел бу,—диде ул ярдәмчесенә һәм дистәләрчә фамилия тезелгән документларны күрсәтте. Бирүче—А. А. Шубарин. Шунда гына аның башына сукты: бу бит Коста очрашырга кушкан Артур Александрович Шубарин, кушаматы Япон. Фамилия барысын да үз урынына куйды, аның бу миллионер хакында ишеткәне бар иде инде, күләгәдәге икътисад хуҗаларының берсе, узган елны аның җанын алырга дип Ростов бандасы килгән иде, килде дә эзсез югалды, аларның Ташкентка тәпиләвен угрозыск хезмәткәрләре дә белеп тордылар, ничә баш киләчәкләре дә сер түгел иде, менә шунда Шубарин фамилиясе калкып чыккан да иде инде...

Шефның артык дулкынланганын күргән Сәлим бер өем расписканы кулына алды һәм аларны тиз-тиз актарып, шатлыклы кычкырып җибәрде:

—Эләктеңме, күгәрченкәем, сиңа да килеп җиттек!

Прокурор кәгазьдән йөзен алды һәм кызыксынып сорап куйды:

—Син анда кемне каптырдың?

—Капитан Кодрәтовның бабасын.

—Мин сиңа әйттем ич, ана да барып житәрбез, ә менә моның да шушы колодада икәнен көтмәгән идем, вәт сиңа пики валеты!—Прокурор Миршаб көтмәгәндә генә сүгенеп алды, аннан соң магнитофонны кабызып җибәрде һәм сүзен дәвам итте:—Анда Кодрәтовның бабасыннан да өстәрәк утыру-

чылар бар, мин шундый унышка йөз тоткан да идем инде, хәзер аңлыйсыңмы Костаның нишләп уылдык чәчкәнен, "дипломат"ны тапмасак, кире кайтармасак үлем белән куркытканын?

Әкрәмхуҗаев ярдәмчесенә тагы бер өем кәгазь ташлады, ул аларны өстән-өстән генә караган иде әле, алар, һичшиксез, кызыклы документлар булырга тиеш, Сәлим аларны күтәреп подвалга күбәйткеч машина янына төшеп китте.

—Андый-мондый хәл була калса кирәге чыгар, өчәр экземпляр бастырып ал,—дип кычкырды прокурор аның артыннан.

Кассеталарны тыңлап тормады, вакыт аз иде. "Дипломат"тагы әйберләр кызыклы, мәгънәле, ымсындыргыч дәрәҗәдә серле иде, аларны игътибарлырак укырга, анализларга һәм җентекләп сайлап алырга кирәк булыр. "Шарп" магнитофонында, тиз яздыру режимында эшләтсәң дә, дүрт кассетаны күчереп алу өчен сиксән алты минут вакыт китәчәк иде. Димәк, запаста сәгать ярым вакыт бар, шул арада күз йөгертеп кейстагы кәгазьләр белән танышa торырга, копияләрен алу өчен Сәлимгә бирә барырга, кассеталар тәмамлануга Коста биргән телефон номерына шылтыратып өлгерергә дә кирәк иде.

Никтер Сенатор үзендә кара тәшвиш, шөбһә уянуын сизде. Кейс хуҗаларын тизрәк тынычландырырга кирәк. Кызып китеп бар дөньяны тузгытып ташламагайлары. Прокурор тагы документларга күмелде, арада бүген үк эшкә кертеп җибәрердәйләре дә күп иде. Тик әлегә ярамый, үзенне тыя белергә кирәк. Ул бу документларның көчле атом-төш бомбасына тиң көч-куәтен чамалап алды һәм шатлыгыннан чыйнап җибәрер хәлгә килде, рәхәтләнеп көлде, иләнгә типкәләде—ул үзен күкнен җиденче катында хис итә иде.

Ксерокс янында утыручы Сәлимне бер генә сорау бимазалады: нишләп шеф капитан Кодрәтовның бабасын, югары партия аппаратчысын валет дип, җитмәсә, "пики валеты" дип атады, ул да яшеренеп кенә отышлы кәрт уеннарында катнаша микәнни? Шунамы ул яңа кәгазьләр алырга кергәч, түзмәде, сорап куйды:

—Нәрсә, Кодрәтовның бабасы, чыннан да акчага кәрт сугамыни?

—Ачил Садыкович кәрт уйный дигәнне каян алдың әле? Кәгазьләрдә аның бурычлары турында берәр нәрсә бармы?—дип көлде прокурор, күрәсең, ул партбоссны кәрт өстәле янында дип яисә Коста ана счетчик ачкан дип күз алдына китергән иде.

Хәзер аптырау чираты ярдәмчегә күчте.

—Үзең "пики валеты" диден ич, сүгенден дә әле.

—Булды бугай шул,—дип куйды Сенатор.—Мин, чыннан да, аны "пики валеты" дидем, ул сүзнең ни аңлатканын белмисеңмени? Ул прокуратурада җинаятьчеләрне төркемнәргә бүлеп өр-яңадан классификацияләү өчен барлыкка килде. Аның аерым бер кастасын билгеләү өчен "пики валеты" диден, и бетте китте, барысы да аңлашыла. Ә бездә пикины "карга" дип тә йөриләр. "Карга валеты" дисәң, тагын да шәбрәк яңгырый икән, каһәр!

Алга таба шеф кинрәк аңлатуны да кирәк тапты:

—Игътибар иткәнсеңдер, без кылган гамәлләре буенча җинаятьчеләрне төркемнәргә бүлә идек: кесә караклары, йорт басучылар, автомобиль урлаучылар, урланганны сатып алучылар, фарцовщиклар, валютчиклар, артельщиклар... Алар янында көтмәгәндә җинаятьчелекнен бу тармакларына карамаган тагын бер куәтле катлам барлыкка килде, боларны инде башка категория җинаятьчеләр белән бутый алмыйсың, аларның "үзәген"н партия, совет җитәкчеләре тәшкил итә, кайберләре шундый да югарыда утыра ки, түрәлек рангларын белсәң—шаклар катасың, хокук саклау органнары кешеләренен дә коты чыга, чөнки вакыт-вакыт әлеге хезмәткәрләр шундый айсбергларга барып төртеләләр дә, кая барырга белмиләр, жалоба белән йөрсән—кая кемгә сугылырга, кулга алам дисән, арестны кем белән килештерергә, әле шундый гайре табигый хәлләр дә очрый: син арест дисәң, шул кешенең янына барып, шул барган кешенне кулга алырга үзеннән санкция сорарга тиешсен. Республика прокуратурасында шул адәмнәргә шифр уйлап таптылар да инде—"карга валеты". Шифрны әйтүгә үк кем хакында сүз барганын аңлап аласың, артык сүз кирәкми. Валет нәрсә, әле аның корольләре дә, тузлары да бар...

—Ә мин аны чыннан да кәрт суга дип уйлаган идем, күз алдына гына китер, яшерен бер затлы катран-салонга килеп керәсең ди, ә анда Ачил Садыкович утыра һәм ялтырап торган шәп кәртләр белән химичить итеп маташа.—Һәм алар икесе дә рәхәтләнеп көлеп җибәрделәр.

Миршаб тагы бер пачка алып, документлар белән ксерокс янына әйләнеп кайтты, шефның документларны кабаланып яздыруын күреп, ул да ашыгырга кирәклеген аңлаган иде. Тик шулай да "пики валеты" баштан чыкмый иде, республика прокуратурасындагы коллегаларының тапкырлыгына шаккатарсың, никадәр төгәл сүз табылган, моннан ачык, аңлаешлы итеп әйтә дә алмассың! Ә мөнә шеф белән мине кайсы исемлеккә кертергә? Пики корольләре, тузлар янынамы? Кая карама, бөтен җирдә пики төсе, кара төс. Урыслар әйтмешли: бур өстендә бур утыра, бурны бурдан кудыра. "Ниндидер афәткә, һәлакәткә барабыз ахрысы",—дип уйлап куйды фикер йөртергә яратучан Хашимов. Ул кайчан да булса бер халык ләгънәтеннән котылып кала алырына ышанып җитми, шуңа күрә өендәге яшерен сейфта пистолет тота, "дөнья барамы, бара" диебрәк яши, әмма чигәгә-колакка ниндидер салкын көч өрә башлаганын сизенә, төннәрен шаштырырлык төшләр күрә, Нәргизгә менә дигән йорт алып бирүе дә хет соңыннан кемнеңдер күңелендә яхшы күңелле, юмарт булып истә калу өчен бит... "Бер генә яшибез, гүләй, Габдерәшит!"—бернича көн элек кенә сыраханәдә бер исерек адәмнең шулай дип кычкырганын ишеткән иде. "Пики төсе—кара төс",—дип, кычкырып кабатлап куйды ул, әйе, власть башындагы жулик җитәкчеләр турында томтом романнар язарга мөмкин булыр иде, ә ул романга нәкъ шушы исемне куеп булыр иде. Копияләрне дә, шеф сораганча, өчәрне генә басмады, дүртәр иттерде. Кем белә, бәлки, кайчан да булса Сухроб белән юл-сукмаклар аерылыр, менә шунда инде артык нөсхәнең дә кирәге чыгуы бар.

Прокурор Әкрәмхуҗаев бу вакытта тагы бер пачка документларны карап чыгарга өлгергән иде инде, кайсы гына кәгазьне алма, һәрберсендә яшерен көч, үтә яшерен сер, һәркайсын җентекләп укырга кирәк иде. Күрәсең, барысыннан да копия алырга кирәк булыр.

"Дипломат" төбеннән аерым яткан шикелле тоелган ике калын конверт килеп чыкты, дулкынлануын басарга тырышып, аларны кулына алды. Бәлки иң зур сер шушында яшерелгәндер?

Яхшылап машинкада басылган текстның беренче битләреннән үк ул бу кәгазьләрнең күбәйтергә куелганнарга бернинди бәйләнеше юклыгын аңлап алды. Болар прокурор Азлархановның илдәге хокук, дәүләт төзелеше, юстиция, суд алып бару эше, прокуратура, законнар турында фәнни уйланулары булып чыкты. "Юкка гына аны Теоретик, Реформатор дип атамаганнар икән",—дип, уйлап алды ул үтерелгән коллегасы турында. Аның кинәт кенә баш миенә яшен уты керде: "Соң бу әзер докторлык диссертациясе ич!" Шатлыгыннан ул урыныннан сикереп торды да бүлмә буйлап йөреп китте.

"Әлбәттә, фәнни трактат хәзер Азлархановка кирәк түгел,—дип фикер йөртте ул.—Ә мина койган да куйган. Яңа баскычлар яулыйм дисәң, нәкъ шул кирәк бит. Доктор, юридик фәннәр докторы—шәп яңгырый бит, каһәре! Теләсә кемне көнләштерерлек гыйльми титул-исем. Юридик фәннәр докторы Әкрәмхуҗаев! Мондый кешегә иң-иң югары вазифа да килешеп кенә торачак. Коста хаклы, "дипломат"ка бәя биреп бетерерлек түгел, димәк, бүген ул—Сухроб яңа фәнни хезмәткә дә ия булды.

"Монысы күбәйтү өчен түгел",—дип хәл итте Сенатор һәм ике конвертны да алып, өстәл тартмасына яшереп куйды. Ул бу конвертлар хакында Төн патшасы Миршабка әйтәчәк түгел, минем шеф нинди акыллы һәм тыйнак, шыпырт кына докторлык диссертациясе язып яткан икән дип уйласын әле. Аның зур суммага докторлык диссертациясе сырлап бирүче бер танышы бар барын, Сенатор хәтта аңа заказ бирергә җыенып та йөри иде. Ашыкмавы әйбәт булган. Хәзер аның янына керергә дә әйтергә, еллар буе эшләгәнемне кондициягә кертергә ярдәм ит, диярге. Прокурор шатланып бетә алмады.

Өченче кассета күчерелеп бетеп килә иде инде, эшне тизләтү өчен ул калган кәгазьләрне подвалга үзе алып китте.

—Ярты сәгатьтән соң мин Азлархановның элеккеге коллегасы монологын

яздырып алам, син дә ул вакытка бетерерсен, дим. Кейсны без хуҗаларына эш көне башланганчы тапшырырга тиеш, артык күзләр кирәкми. Шунысы да бар, безнең барыбызны да бүген иртүк "Тревога" буенча күтәрерләр дип уйлыйм. Прокуратура ишегалдында ике мәет, тикшерү бүлеге начальнигының сейфы ватылган, мондый хәлнең гомердә булганы юк!

—Бүген тагы бер ЧП турында да әйтерләр инде. Милли кайгы... Рәшидовның үлеме хакында... Бусы да безгә дә кагыла,—дип өстәде Сәлим.

—Әйдә, тизрәк бетерик, мин Артур Александрович белән элемтә урнаштыра башлыйм. Бик кызыклы кеше, читтән торып та күнелгә курку, шом сала ул.—Һәм прокурор ашыгып кабинетына юнәлде, әле соңгы кассетаны яздырасы бар иде.

"Шарп"ка кассета тыккач, Сенатор блокнотын алды һәм Коста язган битне ачты. Ул телефоннан шылтыратырга кулын күтәргән иде инде, "дипломат"ны шнурлап пичәтләргә өлгергәнче, вакытыннан алда ябырылсалар дигән уйдан эче жу итеп китте, ни дип җавап бирерсең, башың беләнме? Ашыксаң да сак булырга кирәк иде. Ярдәмчесе алып килгән бер шешәдә йөз илле граммлап коньяк калган иде әле, ул аны эчке калтырану белән ләззәтләнеп йотып куйды. Нервылар өзелер чиккә житкән, әле "дипломат"ның хуҗасы белән очрашасы, сөйләшәсе бар, ул очрашуның ничек узуына бик күп нәрсә бәйләнгән. Шубарин белән очрашу турында уйланганда, прокурор Миршабның бүлмәгә килеп керүен дә сизми калды.

—Минем барысы да әзер,—диде ул һәм өстәлгә өч пачка документларның копияләрен китереп салды.

Башта Әкрәмхуҗаев аларны сейфка салмакчы булды, әмма шундук кире уйлады, ярдәмчесенә кәгазьләрне үз кабинетында яшерергә кушты, ә үзе төп документларны кейска тутыра башлады, шулчак "Шарп" та соңгы кассетаны чыгарып салды. Кейсны шнурлап пичәтләделәр, сейфка яшерделәр, шеф телефонга тотынды, ярдәмче чәйханәгә ике чәйнек чәй алып килергә китте, булса, кайнар коймак та алырга иде исәбе. Прокурор шәһәр уртасындагы телефон номерын җыйды, вакыт иртә булуга карамастан, трубканы шунда ук алдылар, гүя телефон янында дежур торалар иде. Трубкада хатынкыз тавышы яңгырады.

—Миңа Артур Александрович кирәк иде,—диде прокурор булдыра алганча тыныч, ваемсыз тавыш белән.

—Бер генә секунд, сезне кем дип белик?

—Прокурор Әкрәмхуҗаев.—Яшеренеп тору кирәк түгел иде, чөнки аның турында алар инде шактый беләләр булыр.

—Ниһаять!—дип куйды сөенечле тавыш иясе, аннан үзен кулга алды булса кирәк, эшлекле рәвештә әйтте:—Сез телефон номерыгызны әйтмәссезме, бер ун минуттан ул сезгә үзе шылтыратыр.

Ул үзенең координатларын әйтте һәм кызыксынып китүен сизми дә калды, аның Шубаринның эш рәвешен тикшерәсе килә башлады һәм ул аның Чиланзардагы номерын да җыйды.

Шундук җавап бирделәр, бу юлы трубканы ир кеше алды, ул тыныч, сүзгә саран-житди сөйләште, бары соныннан сорап кына куйды: кая шылтыратырга, эшкәме, өйгәме; телефон номерларын алар беләләр иде инде.

Миршаб күренүгә, прокурор әйтте:

—Мин шылтыраттым инде, алар әзер, килеп житәрләр.

Ярдәмче поднос белән ике чәйнек куйды, кайнар коймак белән бер пиала сөт өсте өстәлне бизәп җибәрделәр. Шул ук вакытта ярдәмче сөенечле хәбәр житкерергә дә өлгерде:

—Миңа калса, алар монда инде, мин өч машина күрдем, алар прокуратура яныннан узып киттеләр.

—Алар арасында ТНС 85-04 номерлы алтынчы модельдәге ак "Жигули" бармы?—дип сорау атты Сенатор.

—Бар иде, нәкъ менә шунысы ике тапкыр күземә чалынды да инде.

—Алар,—диде прокурор. Шул ук минутта телефон тавышы ишетелде.

Сухроб трубканы алды, җайлабрак утырды. "Биш минуттан сездә булам",—диде тыныч ирләр тавышы, сөйләшү шуның белән бетте.

—Ул биш минуттан монда була,—диде югалып калган прокурор, хәер, ярдәмчесе бу сүзләрне үзе дә ишетте, чөнки хуҗанын трубканы колактан читтәрәк тотып сөйләшү гадәте бар иде. Шубарин кебек кеше белән сөйләшүдә инициативаны үз кулына алуның никадәр авыр булачагын Сенатор яхшы белә иде, ләкин ничек кенә булмасын, әлегә ул башлап җибәрде һәм алга таба да җепне ычкындырмас.

—Чәй эчәргә дә ирек бирмәде, каһәр,—диде Төн Патшасы тыныч кына.—Анын машинасында йөз номерга исәпләнгән япон телефон установкасыдыр, йә булмаса "Алтай" системасы аша элемтәсе бардыр. Анда да теләсә кем борын тыга алмый. Яхшы эшлиләр, чукынмышлар!—дип бетерде ул сүзен сокланып.

—Хәтерлисеңме, прокуратурада, МВДда җинаятьчеләрнен техник яктан бездән яхшырак коралланганлыгы турында инде ничә тапкыр сүз кузгатылган иде...

—Начальствога нәрсә, имеш, чит ил детективлары укып, видеофильмнар карап халык азынды... Шул да булдымы җавап!

—Җинаятьчелекне каян белсен алар, аерым районнарда, махсус йортларда яшиләр, көнен дә, төнен дә милиция саклый, җинаятьчеләр ул районнарны әйләнеп уза, аларныкын түгел, гади кешеләрнең квартирларын басалар бит. Трамвай, троллейбус, автобусларда йөрсәләр, алар кесә каракларын, хулиганнарны да күрерләр иде,—дип кызып китте прокурор, андый сөйләкләр тотарга ярата иде шул ул.

Сәлим Мәскәүдәге Новодевичье зиратында Никита Хрущевка куелган һәйкәл-ташны исенә төшерде: атаклы сынчы Эрнст Неизвестный ясаган әлеге һәйкәл ике кисәк ак һәм кара мәрмәрдән тора иде, анын дусты Сухроб та шундый, кайчан нинди җаны белән яши—һич белмәссең!—менә хәзер анын җанынын ак-якты ягы сөйләп алды. "Чәй эчеп алырга өлгермибез инде, бәлки кунак белән бергә эчәрбез, ләкин ана кадәр барып җитмәс",—дип ялкау гына фикер йөртте ул, кызгылт-күперенке коймакка карый-карый. Шунда кинәт ишек ачылды һәм бүлмәгә берәү керде.

—Исәнмесез,—диде ул ишек төбендә үк һәм, өстәл янына килеп, кулын сузды.—Шубарин Артур Александрович.

Кабинет хуҗалары да үз исемнәрен әйттеләр. Әйтергә кирәк, керүче ялгышмыйча кемнен кем икәнен белүен сиздерде, күрәсең, кемдер ана икесен дә төгәл һәм профессиональләрчә сурәтләп биргән иде.

Сенатор бу җыенкы, унай холык-характер билгеләре шактый чагылган, нык ихтыяр көченә ия кешене кайда күрдем соң дип хәтерләргә тырышты. Көч, интеллект... Болар бер кешедә берьюлы булмый да диярлек, көчле кеше интеллектка аксаса, интеллектка күп вакыт физик көч, ныклык, тазалык житеп бетми. Үзәк Комитетнын партия активы җыелышларында күрен гәләдеме бу кеше? Юктыр. Дөресен генә әйткәндә, анда мондый типтагы кешеләр бөтенләй юк. Беренче күрүдә кешегә карата ялган фикер туучан, ә тормыш кино түгел. Әйе, әйе, анын күргәне бар, төрле кыяфәтләрдә, дистәләрчә полиция фильмнарында күрде ул аны, ә андыйлар шәхси фильмотекасында бихисап. Әгәр Шубарин инглиз теленда сөйләп җибәрсә дә, прокурор хәйран калмас иде. Әлбәттә, нәрсәдер анын партия элитасыннан икәнлегенә дә ишарәли кебек, мондый кеше һәрвакыт номенклатурада, кастада була (прокурор үзе дә шунда!), ул да шул штамптан. Бу билге ачык сизелмәсә дә, тоемлана иде. Манералары, киенү рәвеше, тышкы кыяфәте, йөреше анын башка "даирә" кешесе икәнен күрсәтәләр, мондыйлар өчен хәтта классификация дә юк, чөнки алар кешеләр дигән төркемгә керми, бик-бик сирәк очрый торган сирәк экземплярлардан санала. Аларда үз дәрәҗәсен белү коточкыч сизелеп тора, менә шундый берәү Әкрәмхуҗаев каршында утыра да иде инде.

—Артык иртә визитым өчен гафу итегез, прокурор,—дип, бернинди кереш сүзсез башлап җибәрде кунак шәрекъ йолалары кушкан итагать нормаларын санга сугып тормыйча гына.—Әмма сез катнашып китәргә мәҗбүр булган мәгълүм вакыйгаларны бераз анлатсагыз иде, әгәр булышсагыз тагы да яхшырак булыр.

Шубарин ачыктан-ачык сөйли, хәтта бу кабинетта тасмага яздырып алу мөмкинлеген дә искә алмый, курыкмый, читенсенми иде. Күрәсең, кемгә мөрәҗәгать иткәнен яхшы белә, йә булмаса, үзе артында көчле һәм властьлы кодрәт иярләре торганын аңлый. Прокурор дәрәҗәсендәге кеше дә ана берниниди тәэсир ясамый иде кебек.

Кунак та, аның шикелле үк, төнлә тамчы да йокламагандыр, ләкин тышкы кыяфәтеннән болай әйтерлек түгел иде. Аның алдында утыручы, күрәсең, гаҗәеп энергиягә, ихтыяр көченә, сабырлык-түземлеккә ия кеше. Бары күз төбендәге бер нечкә җеп кенә йокысыз сәгатьләр турында сөйли дә, күзләре зур, авыр, киеренке эш алып баруы хакында әйтеп торалар. Ул коточкыч көч белән кысылган пружинага охшаган, аз гына кагыл, барысы да берьюлы читкә атылачак, юлындагы бар нәрсәне себереп түгәчәк. Мондый кеше белән эш иткәндә саклыктан да кадерлерәк нәрсә булмас.

Менә дигән итеп үтүкләнгән аксыл-зәңгәр күлмәк, шул тондагы "а-ля америка" манерындагы тыйнак, әмма күп мәгънәгә ишарә ясаган, "Париж. Карден" дигән язуы күренеп торган галстук. Аксыл-көрән костюмында беленер-беленмәс зәңгәрсу сызыклар киемнең атаклы инглиз фирмасы "Дормей"да тегелгәненә ым каксалар, тәбәнәк үкчәле, йомшак "Рейнбергер" туфлиләре галстук төсендә булулары белән Сенаторга боларның барысының да бер генә ноктада сатылулары турында сөйлиләр иде. Анда да әле мондый затлы киемнәрне теләсә кемгә бирү юк, ул алдан ук бүленеп куела, чөнки "Үзбәкберләшү" сәүдә базасы дефицитларның да дефициты булган затлы товар ала һәм бу "берләшмә" аның территориясендә иде.

"Вәт, шайтан, тантаналы мәҗлескә чакырылган кунакмыни, ә мин ана зур бурычлы бер бәндәме әллә",—дип көнләште аннан Сухроб.

Сүзсез утыру берниниди кагыйдәләргә дә сыймый башлаган иде инде, җавап бирергә һәм турыдан-туры җавап бирергә кирәк, теләсә нинди боргаланып маташу ышанычны югалтырга сәбәп булыр иде. Җитмәсә, әле бит Шубарин бүген Коста белән дә очрашачак, ә ул барысын да булганынча сөйләп бирәчәк. Тик, шулай да, бар карталарны да берьюлы ачып ташлыйсы да килми иде...

—Шулай килеп чыкты инде, һич көтмәгәндә бу эшнең шаһиты булырга туры килде,—дип башлады ул.—Нииндидер Коста исемле егет элеккеге прокурор Азлархановтан "дипломат"ын тартып ала алмады, үзе милициягә эләкте. Башыма кейстагы документлар һәм акчалата, һәм сәяси яктан зур кызыксыну тудыра торгандыр, шулай булмаса, үзен шундый куркыныч астына куймас иде, дигән уй килде. Өстәвенә, күз алдымда кеше хәтле кеше үтерделәр. Югыйсә мондый гамәл өчен нинди җәза көткәнен дә белгәндер бит ул. Мондыйларга ярлыкау булмый. Болар башымнан яшен тизлегендә йөгереп узды. Азлархановның "дипломат"ын кулга төшерү миңа мөмкин булмас эш булып тоелды. Дөресен әйтим, миңа Коста ошады, аның башсыз куркусызлыгы, үз бурычын үтәү хисе, хуҗаларына бирелгәнлеге ошады, бер мизгелдә, баш миемдә фикер оешты, менә аны коткарсаң да ярар иде дип уйлап куйдым. Һәм моны гамәлгә ашырырлык көчем барлыгын да тойдым.

Сухроб күзгә күренеп гасабилана иде, ул ярдәмчесенә "чәй агыз" дип ым какты.

—Мин сезнең гамәлегезнең сәбәпләрен аңламыйм,—дип Шубарин сөйләшүне кирәкле сукмакка кертте.—Сез үсеп баручы прокурор, профессиональ яктан яхшы бәяләнәсез, ярлы да түгел... Карьера эшләргә мөмкинлегегез җитәрлек. Нишләп сез профессиональ җинаятьчегә ярату белән карарга тиеш тә, нигә аны гадел хөкемнән коткарырга тиеш, ди?!

"Кем соң әле монда прокурор?"—дип уйлап куйды уңайсыз хәлдә калганын тойган Сенатор һәм каты кулга капканын аңлап алды. Коста кебек соңгы сулышына кадәр үзеңнекен итәргә, тугрылыклы хезмәт итәргә генә кала, башкаларны, күрәсең, якын да китермиләрдер.

—Рәхмәт, сезнең телдән мактау сүзләре ишетү күңелле. Ләкин сез ялгышасыз, минем зур карьера ясау мөмкинлегем юк иде. Верховныйга да, аның якыннарына да якынаерга җай таба алмадым. Үзләре утырган көрси белән риза булмаган кешеләр күктәге йолдызлар кадәр, мин—шулардан берсе...

—Ни диярсең, җаныгызны ачып салуыгыз өчен рәхмәт. Димәк, сез

Костаны аның хуҗаларының якты карашын күрер өчен коткаргансыз?

—Дөресен әйткәндә, әйе! Әле шунысын да исәпкә алырга кирәк, кичә мин ак "Жигули"дагы сезнең егетләрне дә коткардым. Шәһәрдә бу машинаны тоту буенча облава игълан ителгән иде инде, егетләр полковник Чураевның мөмкинлекләрен белеп бетермиләрдер дидем.

—Без сезнең гамәлегезне аңладык һәм безнең белән элемтәгә чыгуыгызны көттек.

—Кем белән?—дип ихлас хәйран калды кабинет хуҗасы.—Кырдагы җил беләнме? Машина урлап кителгән яисә ялган номерлы булырга мөмкин.

—Анысы шулай. Ахыр исәптә сез барыбер безгә чыктыгыз һәм, безнең гаҗәпкә каршы, гадәттән тыш хәлләрдә генә файдаланылучы ике телефон номеры да сездә булып чыкты. Әгәр берни дә белмәсәгез, ул телефон номерларын кайдан алыр идегез?

"Костаның миндә икәнен белми микәнни?" дип кабат гаҗәпләнде прокурор, теленнән исә бөтенләй башка сүзләр ычкынды.

—Мина ул номерларны Коста бирде.

Көтелмәгән бу сүзләрдән Шубарин урыныннан кузгалып ук куйды.

—Димәк, Коста сездә?

—Әйе, әйттем бит инде, аны урлап китү минем кулымнан килә иде һәм мин моны эшләдем дә.

—Ә без аны төнгә төрмәгә алып китkәннәр дип уйлаган идек, нибары ярты сәгатькә соңга калдык, дип терсәгебезне тешләрдәй булдык. Шәфкать туташы ышандырды безне. Шулай да, чиста эшләгәнсез.—Прокурорга сүзләренең ничек тәэсир итүен, ләззәтләнүен күзәтеп торды һәм берәздан акрын гына әйтте:—Ашыгуыгыз дөрес гамәл булган, иртәнге шылтыратуыгызны күздә тотам, юкса, бер ярты сәгатькә генә соңласагыз да, моның ни белән тәмамланачагын сез күз алдына да китерә алмас идегез. Минем егетләр ике сәгать инде прокуратура тирәсендә бөтерелә, алар эшнең ничек барганын белми. Инде бөтенесе дә ачыкланды, мин сезнең рөхсәт белән отбой бирәм. Аллам сакласын, анда кемнеңдер түземе төкәнеп тәрәзәгә менеп атланмагайлары.

—Сез моны чынлап әйтәсезме?—диде прокурор һәм көчәнеп елмайды.

—Без уйнап сөйләшмибез,—диде Шубарин җитди генә.—Нәкъ менә сезнең арттагы тәрәзәгә. Барысы да уйланган.—Һәм кабинет хуҗасының җавабын да көтмичә, акрын салмак тавыш белән эндәште:—Ашот!

Күрәсең, ул ишек катында ук торгандыр, исеме әйтелеп тә бетмәстән, бүлмәгә төксе йөзле егет килеп керде. Спорт костюмының бил кереше тирәсендә бүлтәеп торган нәрсәнең пистолет икәнен җүләр кеше дә аңларлык иде.

—Ашот, дөрес әйткәнсең, күпләрегез ышандырырга тырышканча, прокурор Әкрәмхуҗаев алай ук начар кеше түгел икән. Безгә яманлык теләми, киресенчә, әле ул Костаны коткарып калган.

Ашотның йөзенә шатлыкка тартым нәрсә кунды, хәер, күз ачып йомганчы ул аны сүндереп тә өлгерде.

—Бар, отбой бир, мина кичә әзерләнгән "дипломат"ны керт тә егетләрне кайтарып җибәр.

Ашот шундук кире әйләнеп тә керде һәм алар сүзне дәвам иттерделәр.

—Сез телефон номерын Коста бирде, дидегез, очрашу кирәклеген дә ул әйттеме?—дип сорады Шубарин. Күзләре прокурорны бораулады, бу күзләрдә миһербан да, кызыксыну да, аз гына кеше хәленә керергә тырышу да абайланмый, бу тиң кешеләр сөйләшүе түгел, курткасын чишеп утырган Ашот янында чын-чынлап сорау алу бара иде. Әгәр кейсны урлаганлыгын яисә аның кайдалыгын белдертмәсә, шуның белән үзенә үлем карары чыгарганлыгын Сухроб шушы мизгелдә генә аңлап алды. Болар рәхимле була белмиләр, Беспалый кебек икеләнеп тормаслар.

Әгәр имтихан алучының алдан ук риза булачагын сизенсәң, ин күнелсез, кансыз сорауларга җавап бирүе дә күнелле гамәл генә, шуна күрә ул инсәләрен баскан шомны, куркуны коеп төшергәндәй итте һәм һәр сүзен үлчәп җавап бирергә тырышты:

—Әйе, Коста әйтте. Әйтү генә түгел, янады да. Әмма вакыт соң иде инде, минем катнаштан башка берни эшли алмаган булыр идегез, хәтта прокуратураны шартлатсагыз да. Коста нәкъ шулай, шартлатабыз, дип куркытты да. Минем сезгә шылтыратуым хезмәттәшлек тәкъдим итү, төгәлрәге, бер тапкыр очрашуны сорау булып кына аңлашылыр иде. Һәрхәлдә, тиннәр булып хезмәттәшлек итү түгел. Ә инде "дипломат"ны үзем кулга төшерә алсам, бу сезнең арада миңа аерым бер урынга, лаеклы мөнәсәбәткә хокук бирер иде. Мин өстемдә әмер биреп торучыларны гомер буе яратмадым, болай да гарык инде.

Сухроб Шубаринның дулкынланудан ниндидер киеренке хәлгә керүен, теленнән ычкынырга тиешле сорауларны көч белән генә тыя алуын да сизде.

—Минем дә сезнең кебек көчем җитәрлек. Баштарак бу гамәлне үзем өчен бик үк кулай санамасам да, "дипломат"ны үзем кулга төшерергә булдым. Кейста сез күз алдына да китерә алмаган үтә мөһим кәгазьләр бар. Коста мине шуңа ышандыра һәм шушы эшкә күндерә алды. Бу документлар иртәгә хәтта Шәрәф Рәшидович урынына утыруы ихтимал кешеләргә дә кагыла. Ә андыйларны батырырга юл куя алмыйм, моңа минем әхлакый хокукым юк. Бу хәзерге матавыклы көннәрдә кадрлар сәясәтенә башбаштаклык кертү булыр иде. Шуның өстенә, әгәр белә торып юл куйсам, кече җанлык күрсәтүемне, ярты юлда туктап калуымны да гафу итмәсләр иде.

Кунак, ниһаять, өздереп сорады: "Дипломат" сездәме?—диде. Бу аның сөйләшү барышында беренче һәм соңгы тапкыр түземсезлек күрсәтүе булды да бугай.

—Әйе, кейс миндә, ышанычлы урында,—дип, пошынмаганга салышып җавап бирде Әкрәмхуҗаев һәм Шубаринның күз алдында үзгәреп китүен күрде, гүя четерекле вакыйгаларга бай булган озын-озак тоелган көн вә төннән соң аның йөзенә акрынлап арыганлык билгеләре чыга бара иде. "Үзеңне кулда тотар өчен никадәр ихтыяр көче кирәктер",—дип сокланып уйлады Сенатор һәм кәнәфи аркасына ята төште. Эчендә яшерен шатлык тантана итте, барыбер Шубаринны сындырды бит.

Артур Александрович беркавым сүзсез генә утырды, галстугының төенен бушата төште һәм кискен итеп башын күтәрде. Сенатор алдында тагын элеккеге Шубарин утыра иде инде. Күз ачып йомганчы бер мизгеллек югалып калу узган, сораулар элеккечә катгый һәм таләпчән яңгырый башлаган иде.

—"Дипломат" кайда?—Юк дисәң, яисә җавапны сузып торсаң, бу сорау бернинди яхшылык та көтмә дип кисәтә иде. Прокурор моны шундук аңлап алды, хәтта Шубарин артындагы Ашот исемле егетнең, сикерешкә әзерләнгәндәй, бөтен гәүдәсе кысылып куюын да сизенде.

Ләкин Әкрәмхуҗаев сузарга да, кире кагарга да җыенмый иде, ярдәмчесенә әйтте:

—Сәлим Хәсәнович, сейфны ачыгыз.

Ачкычлар чылтырады, корыч эчлектән кайчандыр Венгриядә эшләнгән шыксызрак кыяфәтле "дипломат" чыгарылды һәм прокурор урыныннан кузгалып, аны шома өстәл өстеннән Артур Александровичка таба этеп җибәрде.

Шубарин учы белән кейска кагылып алды һәм уйланып торгандай итте, аннан соң кинәт кенә сораганга да, белгәнен әйткәнгә дә охшатып ирен арасыннан битараф сүзләр чыгарды:

— МВДның иртәнге сводкасыннан... Бүген төнлә прокуратура ишегалдында өч тапкыр пистолеттан атканнар...

—...һәм ике мәет тапканнар,—дип аның сүзләренә ялгап куйды прокурор.—"Дипломат" бәясе шундый булды, без анда бик әйбәт кунагыбызны югалттык.

Кейс хуҗасы баш ишарәсе белән Ашотка "дипломат"ны ачарга кушты, анысы Бармаксыз кебек үк, кнопкалы финка чыгарды һәм сургуч печатьле шнурларны кисеп ташлады. Шубарин кейсның капкачын ачып прокурор инде танышып өлгергән иң өстәге кәгазьләрне—зур суммаларга кул куелган распискаларны алды, күз йөгертеп чыкты һәм яңадан "дипломат"ка ташлады. Сүзе боерык кебек кыска яңгырады:

—Безнең "дипломат".

Бернинди боеру көтеп тормастан, Ашот шунда ук аңа икенче бер "дипломат" сузды. Монысы үгез тиресеннән ясалган, код йозаклы, ялтыравык тышлы атташе-кейс иде.

—Коста кебек үк ачыктан-ачык әйтәм: "дипломат"тагы документлар бәһасез, берәүләрнең карьерасын сындырырга да, икенче берәүләрнең гомерен кыскартырга да, күңелсезлекләр китерү өстенә, керем чыганакларын ябарга да мөмкиннәр. Шуңа күрә әйләнми-чолганмый гына тиярен әйтегез, сатулашып тормаячакмын, башыгызны куркыныч астына куюыгызның бәясе күпме?—Һәм ул кейсның код йозагын чыртлатып куйды.

—Мин сезгә "дипломат" белән Костаны кайтарып бирәм, ләкин акча турында сүз булырга мөмкин түгел, таләп тә итмим, сорамыйм да. Үзегез үк мине ярлы түгел, дидегез ич.

—Шушы кадәр сумманы кире кагасызмы?—Кунак атташе-кейсны ачып җибәрде дә аны прокурорга таба борып күрсәтте. "Дипломат" банк төргәкләрендәге акча белән дыңгычлап тутырылган иде.

—Акча табуда үз юлларым бар, аны мин таба алам,—диде прокурор тыгызлап тутырылган пачкаларга карамыйча гына һәм ул юлларны атап торуның да кирәген тапмады. Ул бернәрсәне яхшы аңлый иде, бүләкне ал гына, Шубарин үзен бурычтан азат санаячак, ә Сенатор һич кенә дә моңа омтылмый иде.

Акча алса, ул кейстан чыккан кәгазьләрдән дә юньләп файдалана булмас, җилнең каян искәне бик тиз ачыкланыр. Японның борыны сизгер. Миршаб әйтмешли, Әкрәмхуҗаев үзе масон орденына кабул ителсә генә, ул кәгазьләрдән юньле-рәтле файдаланып булачак та.

Прокурорның әллә нинди үҗәтлек һәм үзсүзлелек белән акчадан баш тартуы Артур Александровичны беркадәр читенсендереп куйды, ул ирексездән шәрекъ гадәт-йолаларын исенә төшерде. Әйе, монда бернәрсә дә ачыктан-ачык эшләнми, хәтта законлаштырылган ришвәтне алганда да әллә никадәр шартлылык, уйнау була, алучыларны да, бирүчеләрне дә күп күрде инде ул, әмма ничә сум икәнен белешеп тә тормастан кире кагу, аның өчен яңалык иде, кызыксынуы күзләренә чыкты, тагын бер тапкыр прокурорга карап алды.

"Никадәре югарырак утырсаң, шулкадәр күбрәк аласың. Шәрекъ кешеләренең гел өскә үрмәләргә омтылуы шуннан килә. Һәрхәлдә мин моңарчы белгәннәр үзләрен шулай тота иде",—дип уйлап куйды Артур Александрович һәм башкача фикер йөртүче яңа тип көнчыгыш кешесен очратуын аңлап алды, ул күпмедер дәрәҗәдә аңа үзен үк хәтерләтә иде. Акча белән сынау—иң җитди сынау һәм ул аны уңышлы үтте.

—Гафу итегез, Сухроб Әхмәтович, мин сезне дөрес аңламадым бугай,—диде аңа Шубарин ихластан.—Әмма минем тормыш кагыйдәм бар, һәр җитди, җаваплы эш юмарт түләнергә тиеш. Әгәр бүгенге хәлдә акча кулай түгел икән, мин сезне бәхилләтерлек башка алымнар табармын, бүгеннән минем ярдәмемә өмет баглый аласыз, дусларым да читкә тибәрмәс. Эш-гамәлегез белән безгә мөнәсәбәтегезне белдердегез. Акча тәкъдим иткәнем өчен тагы бер кат гафу ит, ул ихлас омтылышыгыздан, ярдәмегездән акча биреп котылу, сөяк ташлау, мыскыл итү булып тоелды бугай. Мин сезне бәяләп бетерә алмаганмын... Рәшидов вафатыннан соң дусларымның аның урынын биләү мөмкинлеге туды, табигый ки, аннан соң кадрларны күчереп утыртулар башланачак, һәм сезгә, әлбәттә, лаеклы урын табылыр.

—Ничек уйлыйсыз, Рәшидовны кем алыштырыр?—дип сорады моңарчы озак вакыт сүзсез торган Миршаб.

—Тәгаен, Шәрәф Рәшидовичның иске дусты, Заркент өлкә комитеты секретаре булырдыр, ләкин икенче бер кешенең мөмкинлекләре аныкыннан ким түгел, анысы—Акмал Арипов, мәгълүм Аксай ханы, ул да Рәшидовның якыннарыннан, ул үзе бу урынга Ташкенттан ике кешене кодалый. Шушы өч кешенең берсе күтәрелер дип беләм. Башка дәгъвачыларга җитди карый алмыйм. Ни генә булмасын, һәркайсына юлларыбыз бар—борчылмагыз, монысында сез оттырмас карткә куйдыгыз...—Шубарин пиджагының өске

кесәсеннән визит карточкасын алып прокурорга сузды, сөйләшү тәмам дигәнне аңлатып йомгаклап куйды:—Без иртәгә Хуҗаны күмгәндә очрашырбыз, дип беләм?

—Сез минем мөмкинлекләрне артык югары бәялисез, Артур Александрович, минем чакыру кәгазем юк, кемдер китереп бирер дип тә уйламыйм.

—Бусы авыр мәсьәлә түгел, минем фамилияләре куелмаган ике артык билетым бар, аларны Сәлим Хәсәнович белән үз исемегезгә тутырыгыз, сезнең эштә кинәт күтәрелеп китүегез кемнәрдер өчен көтелмәгән хәл булып тоелмас.—Ул саубуллашып кабинет хуҗасына кулын сузды һәм кинәт нәрсәнедер исенә төшергәндәй әйтте:—Гадәти булмаган танышуыбыз көнендә символик рәвештә сезгә истәлекле бүләк калдырасым килә, авырсынмагыз зинһар, бу сәгатьне кабул итеп алыгыз. Көнбатышта да сирәк очрый торган әйбер ул. Шушы сәгать безнең кеше икәнлегегезне күрсәтер.—Артур Александрович беләгеннән сәгатен алды һәм "Ролекс"ны прокурорга сузды, ә ул кирәк түгел дия алмады, бүләк бирү ифрат ихлас, дусларча иде.

Швейцариядә эшләнгән затлы, кыйммәтле "Ролекс" сәгате Сенатор кулына әнә шулай килеп кергән дә иде инде.

## Икенче кисәк

### Аксай хуҗасы

Поезд, начар салынган һәм караучысыз калган юлларны бар дип тә белмичә, рельсләр тоташкан урыннарда авыр чыкылдау-бәрелү авазлары чыгара-чыгара, төнне ярып алга чапты; вагоннар әле якякка селкенде, әле кинәт аска ыргылды, состав менә-менә корыч юллардан чыгып китәр дә берәр җирдә мәтәлер сыман тоела иде.

Сухроб заманында "Мәскәү—Вена" экспрессында Австриягә барган иде, ә кайтканда Көнчыгыш Берлин аша кайтты, менә шунда чын тимер юлның нинди икәнен аңлаган иде ул. Анда йөрү үзе бер җан рәхәте икән! Әкрәмхуҗаев Австрия һәм Германия тимер юлларын Урта Азия юллары белән чагыштырып тормады, вакыты ул түгел, хәер, теләге дә юк иде. Ә бәрелү, селкенү, чайкалулар барыбер үзен сиздерми калмады, аны әле стенага, әле өстәлгә бәрде, өстәлдәге һәр нәрсә сикеренә, зеңләп тора, бер кырыйдан икенче кырыйга күчә иде.

Ике-өч сәгать булса да черем итеп алырга кирәк, тик күзгә йокы кермәде, хәер, бу чаклы селкенгән поездда ничек йокламак кирәк! Ул хәзер өйдә чакта да еш кына йокы даруы эчеп тә йокыга китә алмый. Кинәт кенә исенә Шубарин төште. Бу аның кәефен күтәреп җибәрде, чөнки матавыклы авыр көннәрдә ул һәрчак Артур Александровичны эзләп таба ала, аның белән берәр чынаяк чәй эчеп яисә бер рюмка коньяк җибәреп ярты сәгать кенә сөйләшеп утыру да тәҗрибәле гипнотизер, экстрасенс янында булгандай тәэсир итә иде. Әйтерсең, гаҗәеп тынычлык, салкын канлылык, фикер тирәнлеге хас булган Япон үзенең бу сыйфатларын аңа да күчерә һәм мәрәкәле гамәлләрендә буталып беткән Сухроб Артур Александрович ярдәмендә теләсә кайсы авыр хәлдән чыгу юлын таба. Бүгенгә кадәр ул аны бервакытта да хөрти хәлдә калдырмады, ә бит Рәшидов үлеменнән соң өч елга якын вакыт узган инде.

—Өч ел...—дип, кычкырып-көйләп әйтеп куйды прокурор, ул аларны гомер агышында иң озын һәм нәтиҗәле вакыт аралыгы дип исәпли иде. Чәйнек алып коридорга чыкты, бүген йоклап булмаслыгы ачык иде инде. Проводник каты итеп чәй ясаган арада, ул поездның ничек баруы белән дә кызыксынып өлгерде, график бозылмый икән, димәк, барысы да тәртиптә. Ул төннәрен озаклап эшләргә ярата иде. Мондый вакытта чәйсез булмый. Вагон хуҗасы да тырышкан, чәй нәкъ ул теләгәнчә пешерелгән иде. Һәм йокы алмаган пассажир, чәй эчә-эчә, уйларында тагы Шәрәф Рәшидович үлгәч узган озынозак өч ел тарлавыгына чумды, ә бит бу еллар аны биек күтәрделәр, хыялы тавына атлаттылар. Рәшидовны күмгән көннәрдә ил белән инде бер ел Юрий Владимирович Андропов җитәкчелек итә иде. Ә ул, дәүләттәге хәлләрне бөтен

ваклыкларына кадәр яхшы белүче кеше буларак, мәмләкәтнең иң алама төбәкләреннән исәпләнүче Үзбәкстанга аерым игътибар юнәлтте. Әле Дәүләт куркынычсызлыгы комитеты председателе булып эшләгәндә, ул американнарның Рәсәй тупрагын аэрофотога төшереп, еллык уңышка гаҗәеп төгәл прогноз ясауларын белә иде. Америкада һәм башка чит илләрдә Үзбәкстанның ел саен бер миллион тонна мамыкны арттырып язуы хакында мәгълүматлар басыла килде. Моны распагандай, илдә урын-ятак кирәк-яраклары җитми башлады, юкса, ел саен тугыз миллион тонна мамык җыела иде. Күрәсең, әлеге хәл озак еллар барган талауга күз йомуның соңгы тамчысы булгандыр.

Гади дехканнар, намуслы коммунистлар Мәскәүдәге зур министрлыкларга, партия һәм совет оешмаларына, үзәк газетларга дәүләтне алдау, урлашу, үзләштерүләр хакында ачыктан-ачык язып килделәр. Шулай итеп, соңрак "Мамык эше" исеме белән танылачак тикшерү "эшләре" башланып китте, республикага Мәскәүдән беренче тикшерүчеләр килде, ләкин әлегә бернәрсә дә күк күкрәячәге, көчле яшен утлары уйнаячагы турында белгертми, беркем дә миллиардларча сум үзләштерү-урлаулар турында уйламый, казна талаучылар арасында югары урындагыларның саны ни дәрәҗәдә икәнен дә башына китергән кеше юк иде.

Шубаринның прогнозы дөрескә чыкты, Рәшидовны Акмал Арипов кешесе алыштырды. Аксай ханы Сухроб уйлаганнан көчлерәк булып чыкты. Беренче көздә үк Рәшидовны алыштырган дәвамчы чираттагы бер миллионны арттырып язды, аннан азракка кул күтәрелми иде инде.

Алдан исәпләп эш итүчән һәм сак холыклы Әкрәмхуҗаев тирә-яктагы пошмаслыкка үзе үк аптырап йөри иде, беркем дә житди үзгәрешләр буласына ышанмый, ә алар булырга тиеш; ил кризиска тәгәри—икътисади, экологик, сәяси, милләтара, финанс һәм дистәләрчә башка кризиска. Сухроб үзе өчен хәлиткеч адым ясады: партия газетында бер бәйләм мәкаләләр бастырып чыгарды, үтерелгән прокурор Азлархановның күп еллык уй-фикерләрен чагылдырган хокукый дәүләт хакындагы трактаты редакциягә тапшырылды. Ул мәкаләләр республикада шау-шу күтәрде, фикер кыюлыгы, һәрнәрсәгә яңача караш, проблемаларны яктыртудагы кинлек авторның принципиальлеге турында сөйли, моңа кадәр әле беркемнең дә моңа батырчылык иткәне юк иде.

Атна буена аның эшендә һәм өендә телефон шылтырады, дуслары хәйран калды, кайчан гына язып өлгерәсең син, диеп шаккаттылар. Ул кыска гына җавап биреп котылды—түзәр хәлем калмаудан! Ләкин өстә җитди караучы булмады, әмма алар да селкенергә мәҗбүр булдылар, чөнки зур бер киңәшмәдә генсек Андропов Әкрәмхуҗаев мәкаләләренә тәңгәл фикерләр әйтте, менә шунда аны беренче тапкыр Үзбәкстанның Үзәк Комитетына чакырдылар да инде.

Яна ҮК секретарьларының берсе белән озак гәпләшкәннән соң, ул республикада шау-шу, зур кызыксыну тудырган бу язмаларның илдәге вәзгыять аркасында өстәл тартмасында бикләнеп ятучы докторлык диссертациясеннән икәнлеген әйтеп бирде. Диссертация белән ҮК карары буенча, республиканың хокук галимнәрен таныштырырга туры килде. Берничә вактөяк төзәтүләр керткәч, ана җирле академия кысаларында докторлыкны якларга тәкъдим иттеләр. Шулай итеп, бер елдан ул юридик фәннәр докторы булды. Дөрес, шунысын да искә алырга кирәк, прокурор Әкрәмхуҗаев белән очрашу фикерен ҮКның яңа житәкчесенә Заркент өлкәсе секретаре бирде, ә аннан моны эшләүне, үзеннән-үзе аңлашыла, Шубарин сораган иде.

Бер ел эчендә ул ярдәмчесе белән хезмәт баскычлары буйлап югары үрли башлады, республиканың Югары судында зур урынга билгеләнде, аны перспективалы юрист санйылар, баш әйләндергеч карьера ясаячак дип өметләнәләр, ә ул үзе моның астында нәрсә ятканын яхшы белә иде: Артур Александрович "дипломат"ны һәм Костаны коткарган өчен шулай юмарт түли. Шубаринның уйларын алдан белү авыр иде, читтән караганда, ул һәрвакытта да ачыктан-ачык сөйләшә, теләкләрен дә яшереп тормый кебек үзе. Докторлыкны яклагач, ул банкетта да булды, ялгыз калып котлаганда, безнең хокук белемендә мондый киң һәм демократик карашлар үтеререлгән прокурор Азлархановта да бар иде, дип куйды. Аның бу сүзләре астында ни

ятканын Сенатор ни ул вакытта, ни аннан соң да аңлый алмады. Аның карашлары белән килешә идеме ул, әллә башка берәр нәрсәгә төрттерә идеме? Сенатор гомуми сүзләр әйтеп җаваптан качты.

—Идеяләр барыбызныкы да, алар һавада очып йөри, иң мөһиме: аларны язып, бастырып чыгару, үзеннең приоритетыңны баганалап кую.

Илдә, акрынрак булса да, эзлекле рәвештә үзгәрешләр китте, хакимият-нең югары эшелоннарында да тәртип кертелә башлады. Әмма казнаны талау, ришвәтчелек, коррупция, хуҗасызлылык, эшлексезлек белән кискен көрәш башлаган, партиядә чистартулар үткәрергә керешкән Андропов кинәт кенә үлеп тә китте.

Үзбәкстанда властька Черненконың килүенә шатланып бетә алмадылар, бары шау-шулы митинглар һәм манифестацияләр генә булмый калды, хәер, алар зур түрәләр һәм власть башындагыларның җаннарында узды. Шул көннәрдә Сенаторга хезмәт вазифалары буенча берничә мәртәбә ҮКга кереп чыгарга туры килгән иде, ул андагыларның йөзләрендә искиткеч шатлык күрде, зур сөенечне яшереп булмый шул. Юкса анда бик тә тотанаклы кешеләр эшли. Ул аларның үзенә карашлары үзгәрүен дә тоймый калмады. Кайберәүләрнең күзләрендә чагылганны ачыктан-ачык укып булырлык иде: "Йә нәрсә, кәгазь корты, уздымы синең вакыт? Ирек, демократия, хокукый дәүләт кирәк идеме? Партия өстеннән Закон хакимияте урнаштырмакчы идеңме?"

Ул көннәрдә Әкрәмхуҗаев озак кына Артур Александровичны таба алмый йөрде, аның төп резиденциясе булган Лас-Вегаска да бармакчы иде, әмма Шубарин, аның кәефен сизгән кебек, төнгә каршы үзе килеп төште, ул кичне алар төн урталарына кадәр ачыктан-ачык сөйләшеп утырдылар.

—Шүрләмә...—диде Шубарин һәрвакыттагыча тыныч кына.—Ленинның "Бер адым алга, ике адым артка" дигән хезмәтен хәтерлисеңме? Хәзер бездә дә шул хәл. Чагыштырмача, билгеле. Дәүләт үзгәрешләрсез булмый, хәтта радикаль үзгәрешләрсез... Ышан миңа, илдәге икътисади хәлләрне анык тоям мин, ул еларлык, без эшләгәннән артык ашыйбыз һәм тышкы базарга тәкъдим итәр нәрсәбез юк, житештергән әйберләребез барысы да искечә, авыр, сыйфатсыз, нефтьтән килгән долларны ашап-эчеп бетердек, ә яңалары күренми. Буш киштәләр, очсызланган акча илне сәяси реформаларга этәрәчәк әле. Әмма синең Андропов чорында әйткән фикерләрең күптән инде халыкта яши, аның интеллигенциясендә, бары сиңа аны алардан алда мәкалә итеп басып чыгарырга гына туры килде, шуңа күрә алар әзерләнгән туфракка төшкән орлык булдылар да, киң яңгыраш алдылар, кешеләрнең күңелләренә үтеп керделәр.

Аппарат кешеләре, алар арасына сез дә керәсез, өстән күрсәтмә булмаса, бик калкынып күренергә яратмыйлар. Аларның кредосы—аноним яшәү һәм иҗат итү. Сездә исә алар җанлы кеше, шәхес күрделәр, сездәйләрне массалар ярата икән, аппарат кабул итми. Шуңа да ул сезгә булган мөнәсәбәтен бердәм һәм яшендәй тизлек белән күрсәтте. Ләкин, алар монысында да ялгыштылар, җәмгыятьне демократияләштерү һәм хокукый дәүләт төзү—илне кризислардан алып чыгуның төп юлы. Халык рәнҗетелгән кеңәзләрне ярата, сез әле үзегезнең популярлык җимешләрен татырга өлгерерсез.

Сезнең хокук өлкәсендә теоретик эзләнүләрегез һәм шәхси тормышыгыз, омтылышларыгыз бер-берсеннән күпмедер аерылалар, кеше җаны белгечләре исәпләнүче язучылар раслаганча, автор белән әдәби герой бер үк кеше түгел. Шулай булгач, уйлавымча, сез җан икеләнүен тоймыйсыздыр. Мәскәү еракта, властьта Черненко утырганда барысы да монда—Ташкентта хәл ителә. Сезнең карьерагыз, иминлегегез конкрет кешеләргә бәйле, һәрбер аппаратчикка сезнең аерым зур эшләрегез турында сөйләп йөрмәбез бит инде.

Шубарин белән сөйләшү күңелгә тынычлык кертә, аның белән очраш-каннан соң ул хәтта үзе өчен аерым бер тәртип-тотыш кагыйдәләре, тактика булдырды, кайбер җирләрдә Әкрәмхуҗаев рәнҗетелгән кеше ролен уйный, әмма бу аңа Югары судта зур пост биләргә комачауламый, тормыш бер эздән ага да ага, хәер, Бармаксыз белән төннәрен банклар, саклык кассалары, идән асты миллионерларын таламый. Мондый акчалы урыннарның төгәл исемлеге бар иде анда, бу досье үтерелгән прокурор кәгазьләрен карап чыккач, тагы да озынайды. Документлар катлаулы роман кебек, укыган саен ниндидер

төгәллекләр, детальләр өстәлә тора иде. Кайбер мәгълүмат кинәт кенә бөтенләй икенче ягы белән ачылып китә, мантыйкый вариантларын да чутлап чыгарасың. Күрәсең, Азлархановн материалларын ашыгып әзерләгән, магнитофон язмаларына соңрак тагы да киңрәк аңлатмалар бирергә уйлаган, бу гаҗәеп дәрәҗәдәге бәхәсле "эш"не дә ул үзе алып барырга җыенган ахрысы. Гаҗәп кызыклы процесс буласы булган да... Аңа судта бер үк вакытта шаһит тә һәм гаепләүче дә роле бирелер иде һәм җинаятьчеләр шайкасыннан беркем дә—министрлар, ҮК һәм өлкә секретарьләре—берсе дә ирекккә чыга алмас иде, каты каптырган аларны булдыклы теоретик һәм эшлекле практик.

Сухроб рәнҗетелгән демократ ролендә шул кадәр кереп китте, хәтта вакыт-вакыт Үзбәкстан газет-журналлары редакторларына, мәкалә, күзәтү, комментарийлар язам дип, хат белән мөрәҗәгать итә башлады. Исеме яисә темасы ук куркуга төшерүче ул хатларга матбугат җитәкчеләре төрле уйдырма сәбәп табып җавап язган булдылар, яисә, үзләре аңа, редакцияне борчучы бөтенләй йомшак темалар, проблемалар күрсәтеп, шул турыда языгыз әле дип үтенгән булдылар. Кыскасы, алар барысы да Сенатор уйлап тапкан мәкерле кармакка эләктеләр. Күңеле теләгән җавапны алуга, ул аны аерым папкага "тегеп" куя, җае чыкканда дусларына, коллегаларына күрсәтә, "яшәргә ирек бирмиләр", "тынны кысалар, бугаздан буалар", "фәнни фикергә җәелеп китәргә урын юк", "академиягә юлны яптылар" дип зарлана, "юкса, мин докторлыкны "на ура" яклаган идем", ди. Күп нәрсәне алдан күрүчән дипломлы юристның, сейфлар вату остасының аппетиты бик зурдан иде шул.

Дусты артыннан шәүләдәй ияреп йөргән тугры һәм ышанычлы ярдәмчесе Миршаб та аның белән бергә күтәрелде һәм көннәрдән бер көнне ул үзе өчен ачыш ясады: "Элек ул бер үк вакытта шымчы да, карак та иде, ә хәзер бер үк вакытта изелгәннәрне яклаучы һәм... изүче дә, ирекне күтәреп чыгучы һәм... аны буучы да булырга омтыла түгелме?!" Хактыр! Тормышта бик күп нәрсә күргән Сәлим Хәсәнович шефына шаклар ката иде.

Әкрәмхуҗаевның хезмәт баскычында тагы да күтәрелүе Артур Александровичның алдан күрүчән булуын тагын бер кат раслады. Хәтта ышанычлы Ленинчы Черненко вакытында ук, шул ук аппаратта... Брежнев үлгәннән соң, кадрлар политикасындагы череклек үзен иң яман яктан күрсәтте, Юрий Владимиров Андропов вакытында исә һәркайда тетрәнүләр булып, ыбыр-чыбыр коела башлады.

Кадрларны алыштырганда Черненко да "эш күрсәтте", моны аның караваты янында утыручылар башкарды. Бу эпедимия Үзбәкстанны да әйләнеп узмады, киресенчә, монда урын алыштырулар башка җирләрдәгегә караганда күбрәк тә иде әле. Иртә белән газет ачкан саен обывательләр авыз ерып кызыксыналар иде: "Карыйк әле, бүген тагын кемне алып атканнар икән?.." Һәм кызыксынган кешегә канәгатьләнерлек нәрсә җитәрлек булды.

Сенаторның бу күтәрелүе Артур Александрович ярдәменнән башка гына булды, ул бу вакытта Франциядә иде, киткәндә: "Карден белән очрашасым килә",—дип шаярткан да иде әле. Ике илнең ике эшкуары очрашса, аларга киртә куймасалар, ике ил дә, бигрәк тә совет кешеләре отачагын да чамалый иде прокурор.

ҮКның административ бүлеге мөдире урыны бушаячагын Сенатор бөтенләй уйламаганда, көтмәгәндә ишетте, андый вакансия турында быргы кычкыртып хәбәр итмиләр, барысы да аулакта тыныч кына эшләнә. Ул бу урынга кулын сузган кешене дә белә, кемнәрне ничек куясын да белә; бу вазифаны үзенә чамалап та карады, соңгы вакытта укымышлы һәм тирән фикер йөртүче юрист дигән даны таралгач, үзенең шундыйлыгына ышана да башлаган иде инде. Шубаринның ярдәменнән тыш теоретик яктан ышаныч-мөмкинлекләре юк иде. Менә шунда ул Азлархановн кәгазьләрен искә төшерде, аның документлары белән уңышлы комбинация ясасаң, күп кенә власть кешеләренә юл ачылачак, моңа шантажны да өстәсәң, аларның сиңа кирәк чагында ярдәм итүе дә мөмкин. Ләкин мондый шартлый торган материалны файдаланырга шикләнде. Әгәр тикшеренүчән Япондa бер кечкенә шик тудырсаң да, ул үзенең акылы белән шундук Әкрәмхуҗаевның намуссыз

уен алып барганын исәпләп чыгарачак, документларнын копиясе барын да беләчәк. Ут белән уйнарга ярамый, Ашот, инде формага кергән Коста, ә аны иң яхшы клиникалар һәм курортлар аякка бастырды, аннан барысын да әйттерәчәкләр, әгәр Сенатор авызын ачмас итеп яба икән, Сәлимнең телен барыбер чиштерәчәкләр, бу яктан аларда тәҗрибә җитәрлек.

Ләкин, аның шул ук вакытта унайлы моментны югалтасы килми, карьера ясау өчен тагы шундый хәл кайчан туачак, андый урыннар гел бушап тормый, вакансияне гомер буе көтәргә мөмкинсең. Аның бу постка күз атуының төп бер сәбәбе бар иде. Әгәр югары урыннарда зур белемле, бөек интеллектлы, яхшы күңелле, гамәлләрендә дә зыялы, чын мәгънәсендә олуг җанлы кешеләр утырса, ул үзенең Югары судтагы урынында калыр һәм андыйларның юлына аркылы төшмәс иде. Әмма ул һәр түрәнең үз карьерасын ничек ясаганын бик әйбәт белә, бу кеше артында кем тора—монысы да яхшы билгеле, туган ягы, кемгә өйләнгән, болары кайсы гаилә балалары белән ярәштерелгән, капиталлары күпме, кем аларга докторлык диссертациясе, китаплар, акыллы мәкаләләр, докладлар яза, алар кемне күтәрә, култык астына ала—боларын да ул күреп-белеп тора иде.

Шимбә һәм якшәмбе көнне Сәлим белән икесе, ике көн өйдән чыкмадылар, пасьянс уйнаган кебек, документларны әле болай, әле тегеләй салып карадылар, Азлархановның кассетага яздырганнарын тыңладылар, әмма Артур Александровичны шикләндермәс вариант таба алмадылар, һәркайсында яшерен куркыныч бар, һичшиксез җиңү китерердәй юл күренми иде. Прокурор йортында куныл калган Миршаб дүшәмбе иртән идәнгә җәеп салынган документларны җыештырып маташканда бик зур суммаларда хезмәт хакы бирү хакындагы бер ведомостька игътибар итте.

—Сухроб, кара әле бу фамилиягә, безнең хөрмәтле Дулкын Назаровичның абыйсы түгелме бу?—Бу ведомостьны алар унлап тапкыр караганнар иде инде, ләкин үзләре эзләгән кеше фамилиясен генә тапмаганнар иде.

"Назаров Уткур" дип укыды ведомостьтан Әкрәмхуҗаев. Үзбәкстанда туганнарның, бер ата, бер ана балаларының да кайвакыт төрле фамилияләр астында яшәгәнен беләләр иде.

—Юк, Дулкын Назарович Фирганәдән, бу барысына да билгеле, ә ведомость икенче өлкәдән,—диде кәефе төшкән прокурор.

—Дулкын Назаровичның әтисе карьерасын кайда башлаганын беләсеңме син? Ул бит анда ун ел шәһәр комитеты секретаре булып эшләгән, бары картайгач кына Фирганәгә кайта, дөресрәге, Маргиланга, ә ведомость чыннан да шуннан. Берәрсенә шәп йортын калдырып китмәстер бит ул, аның бит җиде улы бар. Уткур Назаров, күрәсең, безнең Дулкын Назаровичның абыйсы.

—Кызык, кызык,—дип, шундук җанланды йорт хуҗасы.—Әгәр шулай икән, мин бу партия кортын кысам, стенага терим. Син бүген үк анда барырга тиеш. Сакланып кына Уткур Назаровка материаллар җый, компромат.

Шул көнне кич белән Сәлим шефның өенә шылтыратты һәм эзне дөрес алулары турында шатланып хәбәр итте һәм буш кул белән кайтмыйм, диде.

—Һай Сәлим!—дип сокланды Сенатор, шатлыгыннан хәтта шампан ачты, аның хөрмәтенә тост әйтте, мона хатыны да гаҗәпләнде.

Менә кайда ул куркынычсыз вариант, хәер, алар җеп очын барыбер теге документлардан алдылар, әмма ул сизелерлек түгел, хәзер ул мин-минлекле түрәне стенага ныклап терәячәк, шул ук вакытта Шубаринның да "борынына чиртәчәк". Югары судта эшләгәнлектән, аның кулында теләсә нинди материал була ала, бу "босс"ның бөтен туганнарын микроскоп астына алырга мөмкин, шундый зур постка билгеләнү аннан тора бит—тимер логика!—Төн Патшасы кирәк кадәр материал да алып кайтса һәм Шубарин "дипломат"ындагы (ул аны "кормушка" дип атый) ведомостька таянып торасы калмый.

Ярдәмче икенче көнне эш ахырына кайтып җитте. Кабинетка керүгә, ул шаярып әйтеп куйды:

—Югары суд кабинетына юньләп ияләшеп тә бетмәдегез, Ак йортка күчәргә туры килә.

—Бары өченче катка гынамы?—дип, шул тонда әйтте шеф.

—Ә син бер сикерүдә бишенче катка менмәкчеме?—дип сорады Сәлим

һәм алар икәүләп көлеп жибәрделәр. Ярдәмче портфелен ачты һәм өстәлгә өч папка ташлады. Аларга, ату тавышы кебек, кыска гына сүз язылган иде: "Эш". Аларның икесе иске, тыгыз катыргыдан, болардагы язулар каләмне карага манып язылган, әле шариклы ручкалар эрасы тумаган-килмәгән чакта ук. Өченчесе, иң калыны, бер-ике ел гына элек башланган һәм тышына яхшы фломастер белән Назаров дип язылган. Әкрәмхуҗаев папкаларга карата кызыксыну күрсәтмәде, хәтта аларны өстәл кырыена этеп куйды, аңа барысы да аңлашыла иде, шулай да сорарга мәжбүр булды:

—Нәрсә, Уткур туганкай гакыллы, талантлы, бик сәләтле адәмме?

—Каян уйлап таптың? Ачу китерерлек дәрәҗәдә примитив. Гадәти схема: бер туган хокук саклау органнарына эшкә бара, икенчесе партия аппаратына, өченчесе советларга, ә калганнары икмәкле урыннарга утыралар: ит комбинаты, урман склады, аракы заводы, сәүдә, төзелеш, автотранспорт, нефтебаза... Кем нәрсә булдыра ала, шуны тарталар. Төрле яктан шундый страховка булса, иң сак кыланучы да көн-төн үзенә ташыячак. Аннан соң, үзең беләсең, андыйлар үзләре кебекләр белән туганлашалар, әгәр кланда прокуратурага чыгу юлы юк икән, аны яңа өйләнешкәннәр аша табалар, һәр өйдә әти-әнисе теләгенә каршы төшми торган кияү һәм киләш була. Әйтүләренә караганда, бервакыт Уткур Назарович болай дип мактанган: тикшерүләрнең озын чылбырында, аның һәр звеносында аның туганнары бар, алар алдан кисәтеп куячаклар, күрердәйне күрмәгәнгә салышачаклар, әгәр кирәк булса, яклап чыгачаклар. Уткур анда төрле вакытларда Шәрекъта иң абруйлы саналучы өч урында утырган: ит комбинаты, урман сату сәүдәсе, ә соңгы елларда һәм бүген дә—зур автокомбинат, ә аның шәһәрара автобус паркы, рефрижератор автобазасы зур йөк күтәрүче машиналар паркы бар. Бу сиңа ит комбинаты яисә аракы заводы гына түгел инде.

Ит комбинаты һәм урман сәүдәсендә башлык чактагы гөнаһлы эшләрен иске хезмәттәшләре һәм әтисе йомып калдырганнар, хәер, монда Дулкын Назаровичның да кулы тими калмаган, чөнки ул республика халык контроле комитетында эшләгән, аның сүзе ике тапкыр Уткур-каракны коткарып калган. Ә өченче эшне Юрий Владимирович Андропов вакытында башлаганнар, монысында ул ычкына да алмас иде, ләкин властька Черненко килү белән илдә хәл үзгәргән, әтисенең коллегалары һәм дуслары тагы үз урыннарына утырганнар. Шуңа карамастан, эшнең барышына иң зур йогынтыны Артур Александрович Шубарин ясаган. Бер шофердан башкалары барысы да, директор бездән һәр рейс саен ясак җыя дигән гаризаларын кире алганнар. Күрәсең, Ашот белән Коста нык тырышкан, шоферлар никадәр үзбашлы, кире, үҗәт булмасын, барыбер бирелгәннәр, гадел һәм каты куллы директор өстеннән ялган яздык дигәннәр. Вакыт кыса иде, алар озакка сузмыйча хәрәкәт итәргә булдылар. Әкрәмхуҗаев телефоннан Дулкын Назаровичның ҮКдагы номерын җыйды һәм шактый ук кырыс тавыш белән үзен иртән кабул итүен сорады. Нинди мәсьәлә буенча һәм нишләп шулай ашыгыч рәвештә дип кызыксынгач, ул томанлы җавап бирде: "Телефоннан сөйләшер сүз түгел..."

Бу инде искереп беткән һәм күп тапкырлар сыналган алым иде, әгәр кемнедер шөпһәләндерергә, йөрәгенә курку салырга, уйланырга мәжбүр итәсең килсә, нинди сер микән дип шомландырырга теләсәң, "телефоннан сөйләшер сүз түгел" генә дисең.

—Андагы очынулар һәм амбицияләр белән ул сине кире дә кага ала иде,—диде Сәлим.—Син аны барыбер китереп кыстың һәм беренче йөреш синеке.

—Минем аны стенага терәвем карьера өчен генә түгел, алар мине санласыннар, минем белән чутлашсыннар өчен дә. Андый кешеләр көчне генә аңлый, көчлене генә кабул итә, ә без бүгенге болгавыр чорда синең белән моңарчы булмаган зур куәткә ия.

ҮКга барганда, ул республика прокуратурасына бәреп кергәннән соң, беренче тапкыр Шубарин белән очрашуын күзаллап чыкты һәм бик пөхтә киенде, сөйләшүне каты оештырырга әзерләнде—кысарга һәм аңлатырга кирәк. Анхор елгасы ярындагы бинага ул ныклап һәм озакка килергә уйлый. Алар сәгать тә унбиш минут сөйләштеләр, шундый мизгел дә булып алды—кабинет хуҗасы Югары судтан килгән бу оятсыз шантажистны куып

чыгарырга да теләде, әмма тегесе шундый дәлилләр китерә башлады, Дулкын Назарович шундук килешүчән тонга күчте һәм ахырда, шәп кенә кыйналганнан соң, сорады:

—Сез нәрсә телисез, нәрсәгә ирешергә маташасыз?

—Мине хаксыз рәвештә югары постлардан читкә этәрмәсеннәр,—диде Әкрәмхужаев үз бәясен белеп һәм шундук бу җавабы өчен үзен эчтән генә мактап алды. Шубарин дәресләре һәм анын белән аралашу үз эшен эшләгән иде.

—Югары судта эшләү сезне канәгатьләндермимени?—дип аптырады кабинет хуҗасы.

—Минем бүгенге урыныма зурдан бәя бирүегезгә рәхмәт, ләкин монда минем кандидатурам бер генә житди постка да исәпләнелмәгән, мин сездә резервта да түгел. Бу гаделме соң? Партия кушканчамы? Мин сездән, коммунист коммунисттан сорыйм. Мин—фәннәр докторы, зур тәҗрибәгә ия кеше, бәлки хокукый реформага карата минем карашларым сезгә дә билгеледер, алар турында республикада бер генә сүз йөртмәделәр.

—ҮКда сез кайсы бүлектә эшләр идегез?—дип сорады хәйләкәр Дулкын Назарович, прокурор Әкрәмхужаевның сүзне кайда борганын анлап.

—Белүемчә, сездә хәзер административ органнар мөдиренә вакантлы урын бар...

—Бу бик катлаулы эш, без ике кандидатураны карадык инде, ризалар да бар, каршы төшүчеләр дә...—дип тартәне кирегә бора башлады кабинет хуҗасы.

—Менә хәзер өченчесен тәкъдим итегез, сез әйткән хәлдә бу бик объектив күренәчәк, сез әйткән кандидатураны икенче төрлерәк караячаклар,—дип, анын салпы ягына салам кыстырды Әкрәмхужаев, ни генә дисән дә ана теше үтми иде әле, тынычрак аерылу мәгъкуль булыр.

Киткәндә, ул ана, танышыр өчен дип, туганы Уткур Назаровичка кагылышлы өч папка эш калдырды, бу папкаларга өр-яна анлатмалар да өстәлгән иде, Сәлим белән юкка гына төн буе эшләп утырмадылар, уйланыр нәрсәләр күп булды, ләкин чыгармалар һәм тәкъдимнәр аннан да артык иде. Әлеге эшләргә прокурор бер кочак аноним шикаятьләрне дә өстәде, алар барысы да Уткур туганы өстеннән иде, боларын да аннан ярдәмче алып кайтты, алар мәнгелек директор Назаровның тормыш юлын белгән кешеләр тарафыннан язылганнар, ин сәере: шикаятьчеләрнен берсе дә Уткурның Дулкын Назарович белән туганлыгын искә алмаган иде.

Өч атнадан Артур Александрович Франциядән кайтып төште һәм шундук Сенаторга шылтыратты, яна урынга билгеләнүне юарга, Парижлан кайтуны билгеләп үтәргә тәкъдим итте. Кем өендә очрашабыз дип озак баш ваттылар, һәркем үзенә чакырды, бер-берсен кодалады. Шубарин үз өенә чакыра, прокурор миндә утырабыз, ди. Бәхәскә Сәлим Хәсәнович чик куйды. Ул да үзенен хезмәт урынында күтәрелүен юарга булды. Озак еллар бергә эшләгәннән соң алар аерылдылар. Хашимов Югары судта калды, шефның урындыгы автомат рәвештә аныкына әйләнде. Дулкын Назарович белән сөйләшү вакытында Сенатор тырышып-тырышып аны калдыруларын сорады. Прокурор Югары судтагы эшләрнен дә үз контролендә калуын тели иде һәм Сәлим белән шулай килештеләр дә: ярдәмче анда кала, ни әйтсән дә, суд соңгы инстанция, суд—хөкем итүнен, хокук сагының тажы ул. Монда эшләр дә катырак һәм бәяләр дә югары—берәр эшмәкәрне "вышка"дан, ягъни үлем җәзасыннан коткардыңмы, миллион кесәдә дип уйларга була. Моның ничек эшләнгәнен алар әйбәт белә. Судка кадәр журналистларны вә башка каләм кыштырдатып маташучыларны сатып алалар да, газетларда совет законнарының катылыгы турында күз яшьләре белән елаучы, гуманлык хакында язучы әлеге каләм әһелләреннән безнен прогрессив халык ин каты җәзаны—атып үтерүне кабул итми, чөнки социалистик җәмгыятьтә максат җәза бирү түгел, ә тәрбияләү, шәфкатьлелек, кеше хәленә керү, мәхәббәт, фәлән-фәсмәтән диган матур мәкалә әвәләтәләр, мондый язмалар белән соңгы егерме елда матбугат муеннан тулган иде.

Газетлардагы шундый чыгышлардан соң теләсә кайсы эшне тоткарлап

була—миллион кесәдә, ул гынамы әле, сиңа гуманист, либераль карашлы кеше дигән дан да килә. Хашимовны эштә калдырганда прокурор шул миллионнарны да күз алдында тотты, әлбәттә.

Миршаб өчесенең тормышында булган өч зур вакыйганы үзенең мәгъшукасы Нәргиз йортында билгеләп үтәргә тәкъдим ясады.

—Нәргиздә?—дип кабатлап сорады Шубарин, ул һәрвакытта да үзенең кая барганын белергә тиеш, страховка дигәндә, океан арты президентларын да уздырып җибәрә иде.

—Коста булган урын,—дип аңлатты прокурор.

—Ах, Нәргиздә...—дип искә төшерде тегесе,—бытбылдык түшкәсен бавыр паштеты белән тутырып искиткеч ризык әзерләүче. Аның осталыгын сөйләп Коста минем Лас-Вегастагы ярдәмчемне акылыннан яздыра язды. Мине дә бик кызыктырды ул, Нәргиздә булырга мин риза...

—Сез болай да ҮКдан башка бер генә җирдә дә тән сакчысыз йөрмисез, бүген Ашотны Костага алыштырыгыз. Янында Ашот булганда үзеннең иреклe кеше, көчле шәхес икәнеңне онытасың... —Икесе дә көлеп җибәрделәр.

—Гомумән, кадерле Сухроб, Костаны идеальләштермәгез, аның үз-үзен тотышы, тышкы матурлыгы, Кавказ горурлыгы һәм галантлыгы артында төксе Ашоттан да явызрак кеше утыра,—дип кинәт кенә әйтеп ташлады Япон. Куркытасы килдеме, кисәтүе идеме—Сенатор монысын аңлый алмады. Гадәттәгечә, Шубарин томанлы сөйләшә, сүзләрен серле һәм усал итеп әйтә белә, моңа Әкрәмхуҗаев ияләнгән иде инде. Японның ни уйлаганын белергә тырышу—буш эш, барысы да көтмәгәндә генә ачыкланып куя.

Нәргизнең сый-нигъмәтле өстәле янында Артур Александрович Әкрәмхуҗаевны зур урынга күтәрелү белән котласа да, соңыннан җаен туры китереп, әллә үзешчәнлек, әллә артык катылык өчен пешереп тә алды. Тәгаен ни өчен икәнен Сенатор барыбер аңлый алмады. Шубаринның бер иске дустының омтылышларын кисә язганы өчендер, күрәсең.

—Ну, син, Сухроб, ясап та куясың инде, Дулкын Назаровичның якасыннан алырга кирәк бит, ә?! Бу, Ашот әйтмешли, чамасызлык. Авторитетларны санларга кирәк, ягымлым, син бит Шәрекъта яшисең.

Сенатор, аңламагансымак, җавап бирде:

—Кадерле Артур Александрович, хөрмәтле Дулкын Назаровичның сезнең иске дустыгыз икәнен мин каян белим ди, сез бит мине алар арасына бик үк алып кермисез. Минем көтәсем дә килмәде, сез еракта, Парижда ләззәтләнәсез, Елисей кырлары буйлап йөрисез, ә вакансия тю-тю булырга мөмкин, алар мине исәптә тотмадылар бит. Шуңа үземне аларның исенә төшерергә булдым, аны һәм тагы берничә кешене ныклап күзәттемтикшердем, нәтиҗәләре көткәннән дә артыграк булды. Минемчә, сез үзегез дә, юлыгызга аркылы төшсәләр, шулай эшлисез...

—Мин гаепләмим, сезнең каптыруга шаккатам, максатчанлыгыгызга хәйран калам, беренче хутта ук шомарган, күпне күргән “үттем-киттем”не стенага терә әле син, бу, һәрхәлдә, дилетантлар эше түгел.

—Рәхмәт, Артур Александрович!—дип бүлде аны прокурор.

—Нәрсәдәдер, бәлки, сез хаклыдыр да, үзегез белән санлашырга мәҗбүр иттегез. Әгәр ачыктан-ачык әйтсәм, алар мине көтә-көтә көтек булганнар, сезнең төп омтылышыгызны, ни-нәрсә теләвегезне ачыкламакчы булганнар.

—Нинди максатлар инде ул, Артур Александрович,—дип, аны тынычландырырга тырышты Сенатор,—дусларның дусты минем өчен изге. Аңа каршы мин берниндн начарлык та кормадым, шулай ук башкаларына каршы да... Теләгем бер генә—минем белән санлашсыннар, мине дә аңласыннар.

—Әйе, синең бәхет баскан чак, әйдә исәнлеккә эчик.—Шубарин бу юлы ачык әйтте, бернинди астыртын мәгънә булмавын Сенатор үзе дә сизенде.

Сухроб ҮКның административ органнар бүлегендә эшли башлауга ике ай узуга, генсек Черненко үлде һәм партия аппаратын һәм җитәкчелекне яна бизгәк калтырата башлады, алга таба Кремль нинди курс алыр? Яңа генсекның беренче адымнары аның Андропов юлын дәвам итәргә теләвен күрсәтә иде—авыру һәм инде вафат илбашы тарафыннан вакытлыча туктатып торылган процессны торгызу, җәмгыятьне яңарту һәм сәламәтләндерү. Партиядә үзгәртеп

кору курсы программа итеп кабул ителде. Менә шунда газет һәм журналлардан Әкрәмхужаевка үз битләрендә чыгыш ясарга тәкъдимнәр ява башлады. Кайберәүләрен ул әдәпле генә кире какты, сәбәбе—вакыты юк, эше күп, ә берничәсе өчен язмалар әзерләде, урланган "дипломат"тагы папкалар байтак мәсьәлә күтәрергә мөмкинлек бирә иде әле.

Аппаратчикларның да ана карашы үзгәрде. Кайда гына булса да, аның белән матур гына исәнләштеләр, баш иделәр, елмайдылар.

Дөресен әйткәндә, үзе белән кызыксынуның бик нык артуы Әкрәмхужаевны куркытып ук җибәрде, аппараттагы: "Иҗат ит һәм сиздерми идарә ит!" гыйбарәсе аның күңеленә якынрак иде.

Сенатор тикшерүчеләргә төрлечә булышырга тырышты, аларның көнкүреше, ашау-эчүе турында кайгыртты, мөмкин булганда һәркайсы белән бәйләнешкә керде, бары шушы юл белән генә ул алар алып барган эшнең масштабын һәм юнәлешен чамалый, перспективаларын билгели ала иде.

Ләкин югарыда һаман битарафлык хөкем сөрә, тикшерүчеләрнең зур отрядын бирү дә җитди кабул итми, аппарат тәҗрибәсенә таянсаң, бу чираттагы кампанейщина, бинаның алгы ягын гына буяп чыгу, әйтик, ике-өч йөзләп колхоз рәисен урыныннан алып икенче урындыкка утырталар, шул ул хәлне йөзләгән мамык заводы директорлары белән эшлиләр, аннары астагыларны селкетәләр, аларның бармакларына ак алтын тузаны йоккан була. Шуның белән эшне туктатырлар һәм барысы да элеккечә дәвам итәр.

Республикада тикшерү эшләренең кинәюенә борчылган Сухроб Дулкын Назарович янына бармый кала алмады. Кайчан да булса аны Мәскәү прокуратурасы белән бәйләнешкә керүдә, үз халкының омтылышларын кисүдә, аның иң яхшы улларының юкка чыгуында, милләт төсенең тоныклануында гаепләячәкләрен ул аңлый иде, андый вакытта яңгыравык сүзләргә һәм хәтәр сыйфатламаларга саранлык булмый.

Дулкын Назарович аның борчуларын шундук аңлады һәм чын күңелдән әйтеп салды:

—Әйе, сине күрми йөргәнбез, алданрак күтәрәсе калган икән, синең көчеңне сизгән ул адәмнәр бездә болай казынып йөри алмас иде.

Ул көнне алар ишекне бикләп озак киңәштеләр. Дулкын Назарович алдан билгеләнгән очрашуларны да туктатты, телефон шылтырауларына җавап бирмәде, бу эш икенче көнгә калдыруны көтми иде. Төнгә алар тикшерүләрне тоткарлау, мөмкин булганча, тикшерүчеләрне пычрату-буяу буенча стратегик план әзерләделәр.

Берничә көннән сынау рәвешендә бер газетта "Аталар җирендә тәртипне без кертмәсәк, кем кертер?" дигән мәкалә күренде. Мәкалә астына республика Югары судының зур житәкчесе Хашимов исеме куелган иде. Газеттагы очеркның максаты еракка төбәлгән иде—көчләрнең ни рәвештә урнашуын чамалау, ул Генераль прокуратура мандаты белән килгәннәргә генә кагылып калмыйча, партия, хокук саклау органнарына һәм башка югары урыннарда утыручыларның уй-фикерләрен ачыклау өчен дә язылды, чөнки аларның күбесе ришвәт, урынчылык, кода-кодагыйлык белән буялып беткән иде.

Миршаб үзенең мәкаләсендә үзәк һәм республика матбугатында күренгән мәкаләләрнең берсен дә кире какмаган иде, әлбәттә. Фактлар, вакыйгалар, сумнар, фамилияләр, югары урыннар үзләренең кыргыйлыгы, оятсызлыгы, масштаблыгы белән хәйран калдыралар иде, хакимият башындагыларның череп таркалуын күрсәтәләр иде. Ул да аларга, рәсми фикер ноктасыннан ерак тайпылмыйча, усал бәя бирде, СССР прокуратурасы кешеләренең хезмәтен унай бәяләде һәм шул ук вакытта юл арасына мәкерле Сенатор белән утта янмас, суда батмас сәясәтче Дулкын Назаровичның стратегиясен яшерде. "Үзебез бозганбыз икән, төзәтүен дә үзебез төзәтергә тиеш!" Мәкаләнең төп мәгънәсе шуннан гыйбарәт иде.

Мәкалә үзенең кайнар яклаучыларын да, каршы төшүчеләрен дә тапты, авазлаш мәкаләләр күпләп басыла башлады, аларда дирижер кулы сизелми, ләкин каләм ияләре "халык пычрактан үзе арынып", "читтән ярдәм кирәкми", "массалар аны өлгереп житте" дигәнрәк сүзләрне муллан куллана иделәр.

Мәкаләләрдә урам җинаятьчелегенә, квартир басуларга, машина урлауга,

кесә караклары һәм рэкетирлар террорына зур игътибар бирелә, ләкин болар артында яшерен максат—тикшерүчеләрнен карашын югары түрәләрдән һәм алар кылган гамәлләрдән читкә юнәлтү ята иде.

Дулкын Назарович хәтта Мәскәүгә дә язып җибәрде, бу иске шаблон иде һәм язманың төп идеясе: "Үзбәкстан халкы үз йортында тәртипне үз кулы белән урнаштырырга тели" дигәннән гыйбарәт иде.

Җавап аптыраткыч булды, еллар буе өйрәнелгән мантыйкка сыймый иде. Хезмәт ияләренең һәм юристларның омтылышларын хуплаганнар, ләкин тизрәк чистарыну һәм могҗизалар тудыручы хезмәткә тотыну өчен илнең бар якларыннан өстәмә көчләр тәкъдим иткәннәр.

Шулай да беркемгә дә юкка маташтык дигән уй килмәде, чөнки алар бу гамәлләре белән тикшеренүчеләр күңеленә вәсвәсә салып өлгерделәр: кемнеңдер тирән казыну теләген үтерделәр, кемгәдер курку ояладылар, вакытлы эшкә килгән кешеләр буларак, алар аяк астындагы җирнең ныклыгын тоймадылар, аларның бер генә хатасын да гафу итмәячәкләрен дә ачык сизенделәр.

Вакыйгаларның кызу агышы һәм алышынуыннан каушап калган, иртәгәге көнгә ышанычларын югалткан хезмәттәшләре инстинктив рәвештә Сенаторга тартылдылар, чөнки ул үзен ышанычлы һәм дәрәҗәсен төшермичә тота белде. Көннән-көн Шубарин дәресләрен күңелендә ныгытып барып, ул үзенә тартылучылардан да файдаланды: берәүләрне тынычландырды, икенчеләргә ярдәм итәргә вәгъдә бирде, өченчеләрдән үзенә кирәк мәгълүмат алды. Шуңа күрә үзен бишенче катка чакырулары аның өчен көтелмәгән хәл булмады. Аеруча мөһим эшләрне тикшерүче юристлар Заркент өлкә комитеты секретарен, әле күптән түгел генә шушы кабинетка өмет сузган кешене кулга алу мәсьәләсен карыйлар иде. Мәскәүнең бу карарга килүе барысын, хәтта Рәшидов урынына утырган Беренче өчен дә көтелмәгән хәл булды. Сухроб катып калган йөзләрдә сәерсенү, аптырау күрде, бары ул гына бу хәлгә әзер иде, хәер, ул да Шубаринның иганәчесеннән башларлар дип көтмәгән иде.

Сөйләшү үтә серле-яшерен булса да, беренче секретарь кабинетыннан чыгуга ук ул Лас-Вегаска, Шубаринга шылтыратты һәм аны кичкә Ташкентка кайтып җитәргә чакырды.

Өлкә комитеты секретаре Тилләхуҗаевны кулга алу турында сүз чыккач, Сенатор үзе дә анлап бетермәгән хис кичерде. Ул... сөенде, Әнвәр Абидович аның бүгенге язмышында зур роль уйнаса да, хәзер ул моны искә алып тормый иде инде, кайчандыр, кайдадыр укыган иде: җәлләү, кеше хәленә керү, йомшак җанлылык сәясмәннәр өчен артык һәм кирәкмәс хисләр. Ә политик буларак, шатланырга, шампан эчәргә сылтау бар дип саный иде ул. Барыннан да элек, булачак көндәш читкә тибәрелә, чөнки, белүенчә, Тилләхуҗаев республикадагы властька дәгъва итүчеләрнең берсе иде бит. Заркент секретаре партия эшендә зур тәҗрибәгә ия, әйтүләренә караганда, Мәскәүдәге зур түрәләр арасында әшнәләре җитәрлек, зур байлыкка ирешкән кеше, алтын-көмешләренең күплеге ягыннан ул Аксай ханыннан гына калышырга мөмкин иде.

Җәмгыятьтәге тоткан урыны, байлыгы өстенә ул Артур Александрович Шубаринның дусты да бит әле, ә Японның яшерен властеның көчен Сенатор үзе дә анлап бетерми иде әле. Менә шундый көндәш үзеннән-үзе юл бирергә мәҗбүр: кайгы-борчу да, кирәкмәгән йөгереп йөрүләр дә калмый, акча һәм атулар да кирәкми, соң Абрау-Дюрсо подвалларында сакланган шампанны эчми нишләрсең, бәлки монда "Интурист" запасларыннан француз "Гордон Верт"ны ачарга кирәктер. Ләкин, болар шатлану һәм шампан өчен беренче сылтау гына, ә икенчесе аның өчен шактый әһәмиятле тоела иде.

Шубарин үзенең төп таянычын югалтып бара иде, ул аңа озак еллар намуслы һәм ышанычлы хезмәт итте, үзенең хуҗасы санады. Менә хәзер Артур Александровичка сизелер-сизелмәс кенә итеп суктыру мөмкинлеге туды, Әкрәмхуҗаев шундый биек күтәрелде, инде хәзер ул үзе Шубаринның таянычы, өстә торган саклаучысы була ала, бу бик авыр нәрсә иде, әмма вакыт шуны сорый, хәзер Сенатор югарыда. Бу турыда ул бер көн генә уйланмады, үз астына кемне салырга чамалаганын белә, әмма уен кыен булса да, руслар әйтмешли, "игра стоила свеч", Шубаринны үз кулыңа алу аның

башка кешеләрен дә үзеннеке итү ич. “Әлеге яна бүленеш һәм перспектива шатлык, шампан, елмаюлар өчен сылтау түгелмени, менә дигән сәбәп!— монда биеп жибәрсәң дә гөнаһ булмас”,—дип уйлады ул эчтән генә Шубарин белән сөйләшүгә әзерләнеп.

Кич белән Артур Александрович Әкрәмхужаев йортына килде, прокурорның чүп-чар сүз өчен генә үзен эштән аермавын ул белә иде, димәк, нинди-дер тетрәнү булган һәм ул эштә ана катнашырга кирәк. Йорт хужасы кунакны якты йөз белән каршы алды, тыштан караганда, ул борчылган кешегә охшамаган иде, бу Японга ошады, ул тотрыклы адәмнәрне хөрмәт итә иде. Шубаринны көтәләр иде һәм залда мул сыйлы табын белән каршы алдылар, бу йортта ул сирәгрәк булса да, хужабикә иренең башка дусларыннан аермалы буларак, әлеге кунакның зәвыгын һәм гадәтләрен яхшы хәтерли, ул чәчәксез һәм бүләксез килүчеләрдән түгел. Ире: “Бездә бүген Лас-Вегастан кеше була”,—дигәч, өстәл әзерләү һәм башка вак-төякләр аның өчен күнелле генә булды. Хужа белән кунак башта кабинетка үттеләр, йомшак, озын аркалы, күн кәнәфиләргә утырдылар, шулай кара-каршы утыргач, йорт хужасы ясалма рәвештә сүзсез торды, әйтергәме, юкмы дигән кыяфәттә иде ул, күрәсең, хәбәр итәсе сүзнең нинди әһәмиятле булуын да күрсәтәсе килгәндер.

—Мин сезгә дәүләт югарылыгындагы серне ачам,—дип сүз башлады ул.— Бүген Әнвәр Әбидовичны кулга алу турында карар кабул ителде.

Яңалыкны Шубарин ирләрчә кабул итте, бары кәнәфинең яхшы эшкәртелгән үгез тиресе генә шыгырдап куйды, Австрия кәнәфие шуннан артык тавыш чыгармады.

—Бу кайчан булачак?—дип сорады, һәрвакыттагыча акылга таянып эш итүче әңгәмәдәш, көтелмәгән яңалыктан соң ул үз гамәлләренең киләчәк юлларын уйлый иде булса кирәк.

—Чама белән ике атнадан соң, ә анарчы Мәскәү белән килешергә тиешләр, ни генә дисәң дә, андый дәрәҗәдәге кеше беренче тапкыр кулга алына бит, аңа бик житди гаеп тагыла. Ышанам, аны кулга алу Мәскәүдә дә, илдә дә шом тудырачак. Бу турыда хәбәр иткәч, кабинетка жыелганнарның йөзләрен күрсәгез иде сез, күнелле тамаша түгел. Күпләр бүген тыныч йоклый алмаячак...

—Мин моны чамалый идем һәм кисәтеп тә куйган идем,—диде Шубарин.—Аның бажасы, өлкә ОБХССы полковник Нурматовны кулга алгач, кисәттем. Ә бит полковникның хатыны Әнвәр Абидовичның әллә кайчангы сөяркәсе.

—Гаепләү буенча төп материал шуннан китәр дисезме?

—Аннан да... Кулга алынырына бер ел кала, комсыз полковникның да алтын жыйганын белеп, Әнвәр Абидович аның унике килограмм алтынын тартып алды, алтынның күп өлеше патша тәнкәләре иде. Нурматов озак вакыт моны кичерә алмады, юкса, бажасының патша тәнкәләренә табынганын яхшы белә иде.

—Көчле ОБХССчы, өлкә хужасына көндәш булырга теләгәндер, алар, күрәсең, барысы да шундыйлар, мин монда берсен селкетеп караган идем, дөрес, яшь әле, үзе капитан,—дип искәртте прокурор, Кодрәтовны искә алып.

—Полковникны кулга алгач, мин аны агуларга тәкъдим иттем, безнең монда жай бар иде, Әнвәр Абидовичка аның белән очрашырга рөхсәт иттеләр, ни дисәң дә, туганнар бит. Ул бажасын сигарет белән сыйларга тиеш иде, бер тәүлектән тегесе кинәт кенә үлеп китәчәк иде һәм бер генә экспертиза да, ә инде хан заманыннан калган борынгы техника белән эш итүче безнең совет экспертизасы бигрәк тә, үлемнең сәбәбен ачыклый алмаячак иде. Әмма ул Нурматовны кызганды, барыбер коткарам диде. Очрашу аның ризалыгын алу өчен булды да. Иреккә чыгу хакы йөз меңнәр белән исәпләнеп, ул полковникның үз кесәсеннән чыгарга тиеш иде. Хужа бәяне куя белә иде.

—Дөньяның үзгәргәнен һәм әле тагы да үзгәрәчәген аңламаучы бер ул гына түгел,—диде йорт хужасы кемгәдер төрттереп һәм кертелгән чәйне чынаякларга бүлә башлады.

—Мин аңа нәкъ шулай дидем дә, хәзер башка заман, дустыгыз Леонид Ильич юк, аның кызына каракүл манто бүләк иткән чакларыгыз узды.

Кодрәтле Шәрәф Рәшидович та вафат, хәзер ул сезне канат астына ала да, яманлыклардан саклый да алмый, дидем. Элеккеге генсекнең кияве, генерал-лейтенант, МВДда икенче кеше, хәтта ул да миллион сум хакына да Нурматовны элмәктән тартып ала алмый, полковник белән СССР прокуратурасы тикшерүчеләре генә түгел, ә КГБдан кызыксыналар, аларга ришвәт бирү—кайнап торган майга сикерү ул.

—Шундый ачыктан-ачык сөйләшүгә ул ни диде соң?

—“Син партия аппаратының көч-куәтен белмисең. Мин анда төшеп калганнардан түгел”,—диде. Хәер, ни дисең, Леонид Ильич гаиләсе белән аралашкан кешенең фикерен тиз генә үзгәртеп тә булмый ул.

—Гаҗәп, шундый ышандырырлык итеп, КГБ хакында искәртеп әйтүгә дә колак салмадымы, тикшерүдә катнашкан берәү сезне “күрәзәче кебек алдан күрә белә” дигән иде.—Үзе өчен кайбер нәрсәләргә ачыклык кертергә теләгән йорт хуҗасы хәйләкәр генә сүз ташлады.

—Полковник Нурматовны коткарырга көчемнән килә дип ышана иде ул һәм мин аңа каршы төшмәдем дә. Шәхсән үземә полковник Нурматов бер дә ошамый, аңа хәерхаһ булу хакында әйтәсе дә юк, аның язмышы борчымый мине. Аны үземә бервакытта да якын җибәрмәдем. Ә ул якынаерга бик тели иде. Хәтта бервакыт мундирыннан файдаланып бугаздан алмакчы булды, кулыннан килмәде. Хуҗага бу турыда әйтеп тормадым. Әмма Тилләхуҗаев арабыздан кара мәче узганын белми түгел, белә иде. Мине Әнвәр Абидовичның язмышы борчый. Бәлкем мин иске карашлы кешедер, бераз сентиментальлек тә юк түгел. Мин аңа күп яктан бурычлы кеше, ул бәлагә тарыгач читкә юыртасы килми. Өстендә болытлар куерганын, куркыныч янавын әйтә килдем, аңлата алмадым. Ләкин киләчәк өчен кайбер нәрсәләрне әзерләп куярга өлгердем. Гаиләсе ишле, алты бала, оныклары... Аларны ташларга ярамас.

Рәшидов урынын даулаган кешенең гаилә хәлен яхшы белүен күрсәтәсе килдеме, прокурор өстәп куйды:

—Әйе, аның ике улы да университетның юридик факультетын тәмамлый.

—Булдыклы егетләр, айга бер тапкыр алар белән очрашып торам. Бадамзардагы чәйханәдә бераз капкалап чыгабыз. Әнвәр Абидович белән без аларны Ташкентта калдырырга дип килешкән идек. Икесенә дә абруйлы районда кооператив квартир алырга булыштым, шәһәр читендә дә йортлары бар. Әтиләре аларны икенче исемгә бер ел элек үк алып куйган иде инде. Аларның киләчәге турында вакытында уйланылды. Ләкин, әйтергә теләгәнем ул түгел. Полковник Нурматов кулга алынгач, мин аннан бер танышыма миллион сум ссуда бирүен үтенгән идем. Бик зур эш майтарырга җыена иде. “Синең белән ни генә булмасын, әлеге миллион гаиләң өчен страховка булачак”,—дидем. Шул “лимон” белән ул автомат рәвештә беренче пайчыга әйләнде, акчалар әйләнешкә кергәч, процентлары килә башлады. Шул процентларга оныклары хәлле генә тормыш кора алачак. Икътисадны ярыйсы гына аңлый иде ул, соңгы елларда кәгазь акчаның очсызлануын белеп торды, алардан уфтанмыйча аерылды да. Мин исән чакта гаиләсе хәерче булмас.

Йорт хуҗасына Шубарин хиссирәк дулкынга кергән кебек тоелып китте. Юкса, обком секретаре хәзер хакимият башында утырмый инде, бер карaганда, моның белән килешмичә һәм вакыйгаларга буйсынмыйча да мөмкин түгел кебек. Уйларына чумган прокурорны кабат җиргә төшереп, каты сорау яңгырады:

—Хуҗага сез кайсы яктан ярдәм итә аласыз? Дустыбызның хәлен җиңеләйтү өчен шаһитлардан кайсысын юлдан алып ташларга, кемнәр белән җитди сөйләшү алып барырга?

—Ярдәм итәргә?—дип ихластан гаҗәпләнде прокурор. Ул акрынлап үзенең Шубарин йогынтысына эләгә баруын аңлаган иде инде. Сорауларын гына кара, алар күбрәк фәрманга охшаган түгелме.—Белмим шул,—дип дәвам итте ул,—бердән, эшне мин күрмәдем, ул КГБ тикшерүчесе кулында. Икенчедән, барысы да гаепләү игълан ителгәч, сорау алулар башлангач кына ачыкланачак. Менә шунда инде кемнәр комачаулаганы, кемне юлдан алып ташларга кирәклеге тәгаенләнәчәк. Әлбәттә, бу эшкә күпләр алынырга теләмәс, аның

белән үземә шөгыльләнергә туры килмәгәе. Шулай булгач, мин аның үзен дә күрәчәкмен, бәлки сорау алуларда да утырырга туры килер. Болар минем вазифага керә... Авыр заманнар килде, Артур Александрович...—дип фәлсәфи нотада тәмамлады ул сүзен.

—Нишләп авыр, дисен? Кайсы заманның жиңел булганы бар? Дөрес, хәзергә аңлашылып бетми. Яңа властьның ни теләгәнен аңлагач, барысы да үз урынына утырыр әле.—Ул сүз беткәнен сиздереп әйтеп куйды.—Сәгать тә унбиш минуттан Заркентка самолет оча. Кичекмәстән мин аның белән очрашырга тиеш, бәлки унай якка нидер кылып булыр. Ә сезгә мәгълүмат өчен рәхмәт.—Шубарин аның кулын кысып кабинеттан тиз генә чыгып китте.

"Менә Шубаринны култык астына алдың!"—дип уйлады югалып калган Әкрәмхужаев һәм ачы итеп елмаеп куйды.

Заркент өлкә комитеты секретарен кулга алу югарыда утыручыларны гүя йокысыннан уятты. Республикада үз көч-тәэсирләрен бүлешә алмаучы кланнар яшерен генә берләшә, дуслаша башлады. Ахыр килеп алар да хәзер конфронтацияләр, амбицияләр заманы түгел икәнен аңладылар, исән калыйм дисән, үзгәртеп коруларга, крайга тәртип кертүчеләргә каршы бер фронт булып оешырга кирәк иде.

Республика өчен гаять җаваплы чорда үзенең нинди әһәмиятле урында утыруын аңлаган Сенатор вәзгыятьне дөрес бәяли алды. КГБ, МВД, прокуратура, Юстиция министрлыгы, Югары суд кебек барлык рәсми оешмалардан мәгълүмат ана агылып керә торды. Шуның өстенә, ул теләсә кайсы оператив кинәшмәгә кереп утыра ала. Югары суд Сәлимнең ышанычлы күзе астында. Анда урнашып калып, алар баштан ук дөрес юлдан киткән булып чыга иде. Чөнки байтак акча капчыкларының язмышы анда хәл ителә, аларны тотып селкү берни түгел. Болар партия элитасына керми, андыйлары белән Мәскәү турыдан-туры үзе шөгыльләнә иде. Мәскәү тикшерүчеләре рапортларыннан Сенаторның байтак нәрсәгә күзе ачылды. Тилләхужаевның бажасы белән бер вакытта кулган алынган өлкә сәүдә идарәсенең башлыгы Шудратов үз эшен республика судына күчерүләрен сорап, ике дә уйлап тормыйча, бер миллион сум акча төртмәкче булган. Рапортларда болар да теркәлгән иде. Жирле Фемиданың гадәт-холкын яхшы белгән бу адәм хәлен шулай җиңеләйтмәкче булган, күрәсең.

Аноним хатлар да бетмәс-төкәнмәс хәбәр чыганагы иде. Дәһшәтле утызынчы елларда ук башланган бу агым Андропов-Черненко идарә иткән чорда уннарча мәртәбә көчәйде.

Тарихтан үзләренчә сабак алган кайбер кемсәләр дәүләт кулы белән кемнәрнедер батырырга теләге иде. Сухробның үткен күзе, аларда ике генә нәрсәне күрде, бу хатлардан нәфес һәм хөсетлек бөркелеп тора иде. Ә чын дөреслеккә һәм гаделлеккә омтылучылар бик тә аз булып, аларның хатлары сүз боткасында, аңламамышка салынулар дингезендә батып калды. Хәер, алары прокурорны кызыксындырмый да иде.

Әкрәмхужаевның бер яраткан шөгыле барлыкка килде, ул тырыша-тырыша һәм яратып шундый хатларны җыя башлады, аларны аерым бер системага салды: үзләштерүләр, урлау, ришвәт, җитәкче буларак җинаятьчелек, әхлакый бозыклык, сәяси ышанычсызлык. Кайвакыт чәчләрен үрә торырлык сигналлар була. Әмма җинаятьчелекне биш бармагыдай белгән прокурор бу анонимкалар артында дирижер торганлыгын, яисә кемнеңдер түзем буасы ерылганлыгын бер карауда ук сиземләргә өйрәнгән иде инде. Ул чын, дөрес мәгълүматны аерып ала белде, аларны еракка яшермәде, кул астында тотты. Чөнки анонимкада күрсәтелгән адәмне кирәк вакытта аяк астына салып таптау ана чүп кенә иде. Кайчагында ул анонимкалар укып сәгатьләр буе утыра, кроссвордтан да мавыктыргычрак бу шөгыль аңа кызык, акылынны эшкә җик: чутла, чагыштыр, анализла. Һәм ул шулай итте дә һәм бөтенләй көтелмәгән нәтиҗәләргә килде.

Әгәр вакыт булса, "Вазифа һәм җинаятьчелек" дигән трактат язар идем, дип тә уйлап куйгалый иде ул. Кешелек дөньясы аның муеннан эшкә чумган булуы, тик тора белмәве аркасында гына искитәрлек фәнни хезмәттан колак каккандыр да. Җинаятьчелекне ишетеп кенә белмәгән һәм "вазифа" дигән-

нәре белән дә Аллаһ тарафыннан рәнҗетелмәгән бу адәм бик күп нәрсәгә маһир иде шул.

Заркент өлкә комитеты беренче секретарен кулга алу күпләрне телсез калдырды. Вассалы кисәтеп куйганнан соң узган ике атнада Тилләхуҗаев ниләр кылгандыр, билгесез, әмма кулга алынганнан соңгы гамәл-хәрәкәтләре күпләр өчен күз алдына да китерерлек түгел иде.

Ул урланган малыннан үз теләге белән баш тартты, йөз алтмыш сигез килограмм алтынын һәм алты миллион сум акчасын дәүләткә кайтарды, тормышта буталдым дип, чын күңелennән тәүбә итте, партиягә төзәтелмәслек зыян китердем, дип гаебен үз өстенә алды, җәмгыять алдындагы гөнаһларына үкенүен танып, тикшерүчеләргә булышырга омтылды, шулай итеп акланырга теләде. Тикшерү аның үкенечен искә алды һәм хәйләкәр тактик йөреш ясады. Тилләхуҗаевның эше ябык суд утырышында каралды һәм ул атарга хөкем ителде дигән белдерү басылып чыкты. Моны ишеткән бик күп партия һәм дәүләт түрәләре, ә алар “Матросская тишина” дигән Мәскәү төрмәсендә яталар иде, күзгә күренеп җанланып киттеләр һәм мөмкин булган бар гаепне аңа аударырга тотындылар. Мәеттән ни сорыйсың ди!

Тикшерүчеләр исә бу ялганны тыныч кына язып-сызып баралар һәм кичләрен сорау алу беркетмәләрен Тилләхуҗаевка күрсәтәләр иде. Элеккеге коллегалары явызлык һәм юньсезлектә ул көткәннән дә уздыралар иде. Үртәлгән, ачуы ташыган секретарь нишләргә белмәде. Хәтта аның хисчән кеше икәнен белгәннәр дә андагы кайнарлыкка, ярсуга хәйран калыр иде. Мондый күренешләрне бик оста актерлар да булдыра алмый. Аларның күзгә-күз очрашуларын күргән кешеләр дә хәйран вә вәйран булыр иде, партиядәш дус-иптәшләр бер мизгелдә кан дошманнарга әйләнде. Әйе, тормышны ул артык зур бәягә сатып алды. Анда бер теләк—үз караватына ятып үлү теләге генә калды, тикшерүчеләргә ярарга тырышты, атып үтерү урынына бирелгән унбиш елны киметмәсләрме дигән өмете дә юк түгел иде, әлбәттә.

Заркент хуҗасының гаебен тануы, тәүбә итүе республикада күпләргә ошамады, ике тапкыр йортына ут төртергә маташтылар. Бу аңа “телеңне кыскарт” дигәнне аңлатырга тиеш иде. Ләкин ут төртүчеләр икесендә дә маңгаена пуля алды. Тилләхуҗаев йорты янында кулларына бензин тоткан ике мәет табылу житди нәрсә, өченче тапкыр ут төртергә теләүче табылмады. Шулай итеп, Артур Александрович сүзендә торды, элеккеге шефына тугры калды, аның гаиләсен рәнҗетергә юл куймады. Күзгә артык ташланмаган “туган тиешле” Ариф исемле егет ул йортта бер елга якын яшәде. Һәр пышылдауга, кыштырдауга карап та ата белгән егетнең бер генә пулясы да читкә китми, һәрвакыт иясен эзләп таба иде шул.

Бервакыт Сухробка да Тилләхуҗаевның гомерен саклап калуда катнашырга туры килде. Уйламаганда-көтмәгәндә Заркентның элеккеге хуҗасын күзгә-күз очрашуга Ташкентка китерергә тиешлекләрен, шунда аны агулап үтерергә җыенганнарын белеп алды. Заговорның детальләрен һәм үтәүчеләрен ул белми иде, әмма бу хакта Шубарингa хәбәр итүне үзенең бурычы санады. Элеккеге шефын коткару өчен Япон тау булып күтәрелде, бу турыда КГБга хәбәр итәргә кушты. Бу тугрылыкны ошаткан Сенатор аның теләген берсүзсез үтәде дә.

Әнвәр Абидовичтан соң бик күп зур дәүләт эшлеклеләрен кулга алулар башланды, монысы да халык өчен бөтенләй көтелмәгән хәл булды.

Үзен пики тузы санаган, үзенә “безнең Ленин” дип дәшүләрен яраткан, тыйнаклык дигәннең “т”сын да белмәгән тагын бер обком секретаре Кара Түбә ханы буларак билгеле, аны шулай дип йөртәләр дә иде. Кулга алган вакытта ул үзенә-үзе пуля җибәрде. Сухроб иң зур урлау-үзләштерүләрнең йомгак очы ҮК секретарьләренә барып тоташканын белә иде.

Шулай итеп, көтмәгәндә туган ягының тагын бер сере ачылып китте. Партия аппараты чиксез властька ия булса да, монда да ил белән яшерен көчләр, күләгәдәге кабинет идарә итеп килгән икән.

Әгәр берәрсенә яңа министрны Ташкентта түгел, ә Наманган тирәсендәге тыйнак кына Аксай кышлагында билгелиләр дисәң, ул моны әкият санар һәм кычкырып көләр иде. Әмма көләр урын юк, Сенатор көчләр нисбәтен,

власть пирамидасын яхшы белә, әгәр Аксайдан аны хуплап-яклап бирәр сүз булса, ул хәзер югарырак урында утырыр иде. Агропромышленность берләшмәсенең тыйнак директоры, ике тапкыр Социалистик Хезмәт Герое, СССР Югары Советы депутаты, чаптарларны, юртак атларны яратучы, элеккеге трактор бригадасы хисапчысы, адәм рәтле белеме дә булмаган Акмал Арипов, Кара Түбә ханына ияреп, үзен "безнең Сталин" дип әйттерүче, "безнең Гречко" дисәләр дә күнеле булган шул Акмал республиканың бөтен Югары Советын алыштырып бетерә язды. Аксайга иң беренче министр портфеленә өмет тотучылар килә иде. Ул үзен шулкадәр дә көчле, тинсез саный, хәтта Шәрәф Рәшидовны да ачыктан-ачык Шурик дип атый ала иде. Шурик исә аңа көн саен диярлек телефоннан шылтыратып торды. Аксай ханы резиденциясенә кыйммәтле хөкүмәт элемтәсе кертелгән. Үз вакытында Сенатор Шәрәф Рәшидовичка да, Аксай ханына да сукмак таба алмады, алар район прокуроры Әкрәмхуҗаевтан башка да әйбәт кенә яшәделәр, ләкин бүген миннән башка мәгърур һәм көчле Акмал Арипов та әллә ни кыра алмас дип исәпләде ул.

Сенатор югарыда утыручыларның байтагының язмышына төкереп тә бирми, әләгүләренә хәтта сөенә дә иде, әмма Мәскәү тикшерүчеләренең Аксай ханына элмәк салырга тырышулары аны бер дә шатландырмады.

Сенаторның Аксай ханын хөкем кулына тапшырасы килми иде.

Нишләп ҮК кешесе Акмал Ариповның эшләре һәм шәхесе белән тикшерүчеләрнең кызыксынуына көенә, моны авыр кичерә икән? Кем ул аңа? Туганы, кодасымы? Әллә аңа бүгенге дәрәҗәләргә ирешергә ярдәм иткән кешеме? Әлбәттә, бүгенге хәлендә ул Сенаторны кызыксындырмый кызыксындыруын. Барысы да шулай, әмма Аксай ханының көчен белгәннәргә бу алай тоелмый. Акыл иясе, көче-кодрәте булган Рәшидов тә эш көнен иртән Аксай белән сөйләшүдән башлаган, Акмал белән кинәшмичә бер генә зур урынга да кеше утыртмаган, дошманнары белән алыш-бирешне шул ук Арипов аша башкарган.

Акмал-әкә шулкадәр дә бай иде ки, бервакыт ул Мамык Наполеонына турыдан-туры җитди итеп: "Мин—Крез, ә син—хәерче" дияргә батырчылык иткән. Әнвәр Абидович хәерчеме? Ике атна алдан Шубарин кисәтеп куюга карамастан, ун пот алтынын, алты миллион сумын дәүләткә кире кайтарган кеше хәерчеме?

Тик, шулай да, Аксай Крезының төп байлыгы акча да, алтын да, бер көтү нәселле атлар да түгел. Аның кулында чын мәгънәсендә шымчылар бюросы бар иде. Аның республикадагы югары яисә түбәндәрәк утыручы һәркемгә досьелары бар, хәтта мондый "эшләр" Мәскәүдән килгәннәргә дә ачыла барган. Хокук органнары Аксайдагы тимер-бетон катакомбаларда саклануычы бу папкалар өчен әллә ниләр бирер иде. Акмал-әкәнең Шәрәф Рәшидович белән дуслашып китүе дә бәлки әлеге "компроматлар музее" аркасында булгандыр? Аксай подвалларыннан, аңа ошамаган, каршы килгән байтак адәмгә каршы хатлар-шикаятьләр китте, шушыннан торып куркыттылар, провокациягә керттеләр, ялган яла әвәләделәр, болар өчен аның тулы штат кешеләре бар иде, алар аңа һәрвакыт турылыклы булдылар, хөсетсез хезмәт иттеләр. Менә шуңа да таулар арасында яшеренгән, юлларында шлагбаумнар торган әлеге кышлакка портфель өмет иткән яисә портфельсез калган министрлар да баш ияргә, бил бөгәргә киләләр иде. Бары Аксай ханының ярдәме белән генә тулы хокуклы министрлар санына керергә була, шуннан башка юл юк! Шул кеше бугазына элмәк кысылып килә, бер көн эчендә йөзләрчә миллион сум акча дәүләт казнасында йотылырга, бәяләп бетергесез архив КГБ төпкелләрендә юкка чыгарга мөмкин, барысы да шуңа бара. Аксай ханының алдагы язмышына әлләни өметләнми Сенатор, аннан күпләр йөз чөерде инде, һәркем үз тәнен-җанын саклый, котылырга тырыша, ә Акмал-әкә яңа замана килгәнне сиземли алмый, һаман элеккеге горурлык, минминлек белән яши, власть өчен зур акчалар түгә, тән сакчылары тота, вәзгыять үзгәрәчәк дип ышанып йөри.

Бәлки, вәзгыять үзгәрер дә, ләкин ул чакта архив һәм акчалар Ташкенттагы бер үк урамга очкан булыр. КГБ да, Үзәк банк та бер үк урамда—

Ленинград урамында. Акмал-әкәне, бәлки, демократия йөгәнсезлегендә җәфа күргән кеше дип, төрмәдән дә коткарырлар, пенсия дә билгеләрләр, әмма моннан ни фарт—акчасыз, досьеларсыз, тән сакчыларысыз ул инде хан түгел дә түгел! Хәзер бер генә зур киңәшмәдә дә аның исемен телгә алмый калмыйлар, Сенатор боларның барысын да күреп-белеп тора. Инде Акмал Ариповны депутат кагылсызлыгыннан, илнең иң югары бүләкләреннән мәхрүм итү турында документлар да әзерләнде.

Акмал Ариповны күзгә-күз прокуратура белән ялгыз калдырасыларын да төшенде Әкрәмхуҗаев, хәзер аның эшләре белән беркем дә кызыксынмый, ә бит аның хәленә төшкәннәрнең язмышына бөтенләй битараф калмыйлар иде. Беренченең киңәшмәләрдә аның турында кискен сүзләре дә читенсендерә иде, ә бит Акмал-әкә аны Брежнев заманында коткарып калган кеше. Нәрсә аңлата бу? Тактикамы? Маневрмы? Әллә алар арасыннан кара мәче йөгереп уздымы? Әллә инде Беренче иске дустын үз куллары белән тотып бирәме? Үзенең дә яшисе бар ич! Сораулар буа буарлык, җаваплар гына кош теленә салырлык та түгел. Әгәр бу маневр икән, шәхси гәпләшүләрдә сиздерерләр иде, Аксайның абруйлы кешесен коткарырга ризалыкны читләтеп тә әйтеп була бит. Акмал хан үз заманында хәтта Брежневнең үзен дә бер-ике провокациягә тарта алган кеше. Әмма Ак йорт башлыгы битарафлык саклый бирде, төрттерүләрне аңламамышка салышты. Менә шунда гына Акмал ханны сугышсыз гына Фемида кулына тапшырырга булганлыкларын аңлап алды Сенатор.

Нәкъ шул чакта Әкрәмхуҗаев башында республика прокуратурасын талагандагы кебек һичкем көтмәгән адымга барырга кирәк дигән фикер туды да. Әгәр зур булмаган бер “дипломат”ны кулга төшерүдән шулай күтәрелгән, нинди кешеләргә хут тапкан, нинди ишекләрне аяк тибеп ача икән, ә инде Аксай ханының архивын кулга төшерсә!.. Баш әйләндергеч зур перспективадан аның хәтта күз аллары яктырып китте, тиз-тиз биегәндәге кебек йөрәге кага башлады, җырлыйсы, биисе, бөтен Ак йортка “Менә хәзер сез барыгыз да минем кулда!” дип кычкырасы килде.

Архив белән бергә Акмал кешеләрен дә эләктерсәң... Болар бит үз эшләрен осталарча башкаручы шымчылар, компромат җыючылар, фотографлар. Ә алардагы фотомылтыклар, тыңлә күрү приборлары. Тагын каллиграфистлар, профессиональ шантажистлар һәм шантажисткалар. Акмал-әкәдә иң яман кабахәтлекне дә эшли ала торган “спец” бар диләр, ул төрле профильдәге кешеләр белән эш иткән, тар маңгайлыларны да тотудан чирканмаган, әйтик, аның ирен кыймылдавыннан тәрәзә аша сүз укучы бәндәсе һәм агу ясаучы табибы да булган.

Ә акча? Аксай Крезы нинди суммага ия булды икән? Монда да фикерләр төрле иде: берәүләр анда миллиард сум бар диде, икенчеләр биш йөз миллионда туктап калды. Ярты миллиард та коточкыч күп акча. Сүз бит әле кулдагысы турында гына бара. Һәрбер Шәрекъ кешесе кебек Аксай ханы да алтын ярата, әгәр “хәерче” Әнвәр Абидович казнага ун поттан артык алтынын биргән икән, коммерция сенере бүртеп торган агропромышленность директоры ул сары шайтанны күпме җыйгандыр дисең...

Вакыт-вакыт Сенаторны бик үк гади булмаган сорау да бимазалап куя. Нигә аңа акча? Булганын да кая куярга белми, архив та ни-нәрсәгә кирәк, аны тоту мәшәкатьле дә, куркыныч та. Ул болай да фәннәр докторы исеме астында бер серия мәкалә бастырды, хокук мәсьәләләрендә республикада күренекле шәхес санала, Ак йортта соңгы кеше түгел, Дулкын Назарович ул “ә” дисә, “җә” дип кенә тора, моның өстенә Шубарин да кул астында гына, ярдәм итмичә калмас, алар бит хәзер бер-берсен ярты сүздән аңлыйлар.

Чегәнчә әйтсәң, пики валетына нигә кирәк ди артык һәм буш мәшәкатьләр? Ариповның миллионнары, потлаган алтыннары, пычрак эшләр буенча мастерлары нигә аңа? Нишләп һәм ни сәбәптән? Тәгаен гына, хәтта үзенең фәнни югарылыгыннан да, ул җавап таба алмады. Белми иде. Әмма бер нәрсәне төгәл тоемлый, бүген бәлки болар кирәкмидер, ә иртәгә шул ук судларга йөреп шомарып беткән шантажист һәм шантажисткаларның да кирәк булуы бар. Дөресрәге, Сенаторның җанында утырган авантюризм тагы

баш калкыта башлады, ә властька омтылыш, көне буе чегләдә далада йөргән кешенең чишмәгә юлыкканы кеби иде. Анда сәясәтче уянды, ә сәясәтче һәрвакыт беренче булырга тели, лидерлыкка омтыла, ул спортчы кебек. Әнә ниндидер фракцияләр, яна партияләр... Һәркайсы әз генә булса да югары пьедесталга басарга омтыла. Бүген ул башкаларга күрсәтми генә Троцкий хезмәтләрен укып утырды, укыды һәм аны үзенчә анлады. Анын карашынча, Троцкий социализмына да, коммунизмына да, идеологиянә дә, иленә дә төкерә, анын бары үзенчә, үзе уйлаганча барысын да үзгәртеп төзисе килә. Ана иң мөһиме: беренче, лидер булу, шуна ул үз карашларында Ленин белән дә, Сталин белән дә килешми, бу бит идеологик мотивлар аркасында түгел, үзенең холык-гадәтеннән, җанынын куелышыннан килә торган нәрсә. Ул беркем белән дә бернинди килешүгә бара алмый, троцкизм—шәхес культынын башлангыч күренеше, анын дансөяр экспериментлар объекты Россия булу жәл, ул бит бу илне юньләп белмәгән, дөресен әйткәндә сөймәгән дә. Ә анын тарих тәгәрмәченә күпме таяк тыккан.

Сенаторнын уйлары һаман власть тирәсендә бөтерелә, алга таба кем реаль көч булыр? КПСС идарәче партия булып калырмы яисә яна политик көчләр оешырмы? Алга таба КПСС нинди булыр, анын линиясен кемнәр билгеләр, Дулкын Назарович кебекләрме, әллә яна генсек Горбачевны яклаучыларммы? Соңгыларын ул күрмәде әле, бигрәк тә югары эшелонда. Листовка-программалары Кокандта, Фирганә үзәнендә таратылган пантюркистларга ышансаң, Үзбәкстан алга таба Россия белән союзга кермичә үз юлы белән барачак.

Ул чакта монда властька кем киләчәк? Ничә еллар хакимияткә омтылып, ярык тагарак янында калыргамы? Юк, Сенатор мона бармаячак! Димәк, ана үзгәртеп кору ягында торырга кирәк, республикада КПСС идарәче партия булып калсын. Әйе, дип уйлады Сенатор, партия җимерелсә, анын да башыннан сыйпамаслар, ул бит анда шулай югары күтәрелде. Шул ук вакытта КПССка да ышаныч юк. Жан икеләнми нишләсен, ул бит берьюлы ике урындыкта утырырга тели. Әгәр Үзбәкстан Россиядән аерыла калса, идарәче партия үз көчен югалта түгелме? Шулай булса, ана икенче бер партиягә керү авыр булачак, чөнки Сенатор идарәчеләр сафында бит. Бәлки, яна көчләр республикадагы бер генә коммунистны да хакимияткә кертмәсләр, әйтерләр: җитте, хужа булдыгыз, барысын җимереклеккә китердегез, диярләр.

Шунда анын йөзе яктырып китте, ул хәтта елмаеп куйды, туктале, ничек бу турыда башка килмәгән? Юк, бер власть та коммунистларсыз булмас, чөнки аристократ бәндәләр барысы да партиядә тора, болар бит аксөякләр, зәңгәр канлылар, хаҗилар нәселеннән кайсы кеше партия билеты алмаган, йә күрсәтсеннәр аны мина, ул үзе дә, әлбәттә, нәсел агачы белән горурлана. Бу кешеләр һәрвакыт идарә иттеләр һәм итәчәкләр, нинди генә система килмәсен, нинди генә байрак җилфердәмәсен—яшеле булса бигрәк тә шәп!—болар югалмаячак. Барлык партбайлар КПСС әгъзасы билетларын тапшырырлар да, икенче—ләкин, идарәче партиягә керерләр, менә сина саклаучы һәм уртак табыннан умырырга рөхсәт кәгазе. Ул да башкалар кебек эшләр, Сухробнын коммунистлар вакытында кем булганын дә искә төшермәсләр, чөнки барысы да бер иш, бер төс.

Киләчәктә үзе өчен сонгы үр булырга тиешле вакыйгаларны күз алдына китерә-китерә ул фәлсәфи фикер йөртүен туктатмады: дөньяда беркайда да властька акыл ияләре, алдан күрә белүчеләр килми, югары урыннарга һәрчак бер көнлек мәнфәгать белән яшәүче хәйләкәрләр һәм явызлар омтыла. Миннән соң хет үлән үсмәсен, миннән соң дөньяны хет туфан бассын—бу хакимияткә атлыгучы сәясәтчеләр турында әйтелгән. Нишләп тарих сабаклары бер дә искә алынмый, дип гомер буе акыл ияләре, фәйләсуфлар баш ваткан. Шулай, чөнки, тарихны наданнар һәм ярымбелемле кешеләр яза. Мисал эзләп ерак барасы юк: юньле белем дә алмаган Аксай ханы, элеккеге трактор бригадасы хисапчысы, Югары Советтагыларнын барысын бергә кушып исәпләгәндә дә, Үзбәкстаннын язмышына ныграк йогынты ясамадымыни?

Башыннан төрле уй-фикерләр йөгереп узды, дәлилләрен үлчәп карады, "риза" һәм "каршы"ларын санап чыкты, ләкин мона карап кына ачыклык

килмәде, чөнки вакыйгалар күз алдында үзгәреп тора иде. Аларга яраклашу өчен хамелеон булырга, барысына да: сулларга да, уңнарга да, неформалларга һәм милләтчеләргә дә, либералларга вә радикалларга да ярарга кирәк иде. Аның башы әйләнде, карап баксаң, барысы да көч жыялар кебек һәм барысы да өметле күренәләр. Менә шунда аның бер үк вакытта шымчы һәм карак булуы ярап куйды. Командировкага килгән тикшерүчеләр арасында ул үзен алар таянырдай бердәнбер кеше кебегрәк тотса, пики валетлары янында исә прокуратурага үтеп кергән "үз кешебез" итеп танытты, шул марканы төшермичә тотты—моңа ни осталык кирәк!

Ләкин ул тегендә дә, монда да үз мәнфәгатьләрен күздә тотты, бер генә идея-идеалны да үзенә Коръән Китабы итмәде, чөнки анда алар юк һәм булмаячак та иде. Аны кызыл байрак та, яшел байрак та, башкалары да дулкынландырмый, ул һәрвакыт һәм теләсә кайсы властьта да югарыда булырга тиеш, бу яктан караганда Сенатор яраткан политигы Троцкийга охшаш иде, аның хезмәтләрен Ак йорттагы кабинетында юкка гына качып укып ятмады лабаса.

Ул беркемгә дә табынмый, шулай да Аксай ханы таяныч була алыр иде, дип исәпли. Андый архивы, чиксез күләмдә акчалары булган кешене киләчәккә төбәлгән планнарында ул читкә куя алмый иде. Теләсә нинди бәягә булса да, аның белән элемтәгә керергә кирәк. Авыр минутта аңа кул суз, бәлки, синә да аның ярдәме тияр, Акмал-әкәнең варисы ук булмасаң да, аның архивында һәм миллионнарында тигез өлешче булу ярап куяр иде! Бу миллионнар, бу архив теләсә кайсы хакимият вакытында, теләсә нинди байрак күтәрелсә дә—бәһаләп бетергесез кыйммәткә ия.

Әгәр кем дә кем аның Аксай ханы ягына күз ташлавын сизенсә, бу күптән ыргылган урыныннан очу гына түгел, ә партбилет белән ирегенне дә югалтуга тиң булыр. Ул күп серләрдән хәбәрдар кеше, боларны кемгәдер житкерүне дәүләт мәнфәгатьләрен сатуга тиңләячәкләр, юрист, фәннәр докторы буларак, Сенатор монысын яхшы белә. Болары югалтуларның башы гына, моннан соң ул барысыннан да колак кагачак: йортларыннан, гаиләсеннән, капиталыннан, жәмгыятьтәге урыныннан. Аннан инде бер генә перспектива да калмый. Бер карасаң, бу балта астына башны куюга тиң. Ул Акмал белән очрашуга шул кадәр зур өметләр баглый, аның уңышлы буласына шул кадәр ышана иде ки, бу хакта Дулкын Назарович белән дә, Шубарин белән дә киңәш-табыш итмәде, юкса алар аңа бәлки кирәкле бирәр фикер дә әйткән булырлар иде.

Сенатор һичшиксез унышка ирешәчәгенә дә ышанып бетми иде. Хан ягыннан хәерхаһлыкка өмет итү дә шикле, чөнки аның кире беткән адәм икәне күпләргә билгеле. Үтерерләр дә, шакалларны сөендереп, гәүдәнне тарлавыкка атарлар. Анда үләксә козгыннары житәрлектер. Жир өстендә каберен дә, эзең дә калмас. Мондый эшләргә аны бик маһир дип сөйлиләр, бәлки, әле тагы да газаплырак үлем уйлап табар, туйганчы кыйнатып, кул-аякларыңны бәйләтеп ач дуңгызлар ябылган читлеккә аттырыр, ата дуңгызлар соңгы сөягенә кадәр чәйнәп-суырып бетерерләр, бармак очың да калмас, әйтүләре буенча, ул шулай итәргә дә ярата икән. Бәлки подвалга бикләтер, еланнар кертеп жибәрер, аларны күрүгә күпләр акылдан яза, йә йөрәкләре ярыла икән. Халык депутаты исеме, әллә ничәмә дәүләт орденнары йөртүче бу адәм актыгы кеше үтерү буенча ис-акылларың китәрлек фантазиягә ия иде ки, аңа торырлык башка берәүне мәнге дә таба да алмассың.

Әлбәттә, күз алдына китергән бу куркынычлар теләсә кемне шыр жибәртер иде, ләкин Сухроб үзенең унышына шулкадәр ышана, өметләнә иде, чөнки Акмал белән әшнәләшү—ул алдындагы проблемаларны мәңгелеккә чишүгә тиң иде.

Озаклап үлчәп,чамалап торырга вакыт калмады да, Ариповны кулга алуга әзерлек бара иде инде. Һәм ул хәтәр адым ясады, менә хәзер аның качып-посып, яшеренеп тауларга, Аксай ханы резиденциясенә барып яткан чагы иде.

Поездга утыргач кына прокурор хатынына хат калдырмавына үкенде, аның бит дүшәмбе көнне өенә әйләнеп кайтмавы да бар.

Поезд элеккечә рельслар ялганган урыннарда дөбер-шатыр, чыкы-мыкы килде. Тиешле станциягә ике сәгать ярымлык юл бар иде әле, йокы качты,

унышлы барган эшләрне искә төшерү аның алҗыганын юып төшерде, күнелен күтәрде. Чәй эчеп алу да комачауламас. Бүген йомшарырга ярамый. Ул чәйнекне алды да сак кына коридорга чыкты, титан суынмаган иде әле, тик шулай да ул мичне ачты, кисәү таягы белән сүнеп баручы күмерләрне болгатып җибәрде һәм ашыкмыйча гына суның кайнап чыкканын көтә башлады.

Янәшәдәге купе ишеге ачык иде, вагон башлыгы кулларын як-якка ташлап, хәтәр гырлый, өстәлендә ачкычлары ята. Сенатор аларны алды, тамбурга чыгып сулдагы ишекне тавышсыз гына ачты, аннан ачкычларны урынына куйды, моңа чама белән ике минут вакыт китте.

Сүз башлауның төрле вариантларын уйлап карады, тик аларның берсе дә аңа ошамады, Аксай ханы белән ялагайланыбрак та, фәрман телендә дә сөйләшеп булмаячак. Ул шунда гына аңлады. Ах, сәяхәт алдыннан Шубарин белән белән сөйләшеп алган булса! Ләкин бөтен хикмәт тә шунда, аңа Аксай ханы белән көрешү хакында беркемгә дә белдерергә ярамый иде. Ул бу хакта хәтта Хашимовка да әйтмәде. Киләчәктә тагын да күтәреләсе булса, моны беркем дә Акмал хан белән бәйләп карамаска тиеш. Докторлык диссертациясе күпләр өчен аяз көнне күк күкрәгән кебек булды. Бусы да шундый бер сюрприз булырга тиеш.

Поездның йөреше акрыная төште, көпчәкләр чикылдап алды, бер кечкенә, шыксыз полустанокта туктап, каршы килүче игезәген—“Наманган-Ташкент” поездын үткәреп җибәрде, кешесез караңгы бу разъезд прокурорга бик уңайлы җир кебек тоелып китте.

“Вакыт житте”,—дип, үзалдына пышылдап куйды Сенатор.

Проводник һаман гырлый иде, Сухроб аның яныннан тавышсыз гына узды, тамбурга чыкты, поезд кузгалуга, чуерташлы җиргә сикереп тә төште. Начар яктыртылган перронда хәтта дежурный да юк иде.

Поезд, коридордагы утларын балкытып кузгалып та китте, тик соңгы вагондагы өч кызыл фонаре гына чайкалып бардылар да төн караңгылыгында эреп юкка чыктылар.

Сухроб һаман юл читендә тора иде әле, ул разъездның ике ягына да күз салды, башында бер генә уй бәргәләнде, әллә башта ук уңышсызлык сагалап торамы? Ачуыннан һәм чарасызлыктан тешләрен кысты, әмма шулчак вокзалга терәтеп салынган бинаның сул ягыннан ике тапкыр машина фаралары күз кысып алдылар. “Ниһаять!”—дип, җиңел сулап куйды Сенатор һәм чуерташлы өемнән алга атлады, аңа таба шыбырдап“Жигули” килә иде. Килеп житәр-житмәс, машина фараларын кабызды һәм ул Шәүкәтнең ак “алтылы”сын танып алды. Шәүкәт аның хатынына туган тиешле кеше, узган ел Сенатор аңа Автовазда ниндидер бер эш майтарырга ярдәм иткән иде.

—Син соңга калдынмыни?—диде ул анарга сәлам дә биреп тормыйча.

—Юк, мин күптән инде монда,—дип акланырга ашыкты Шәүкәт.—Мин поездның утларын ерактан ук күргән идем инде, сизми дә калдым, шул арада күзләрем йомылган, ачсам, составның койрыгы гына ялтырый.

—Әйе, өч белән дүрт арасы хәвефле, куркыныч чак,—диде аның җавабыннан разый калган прокурор. Аның теориясен тормыш тагын бер кат раслады бит.

Берничә минуттан машина Наманганга таба көзгедәй ялтырап ятучы асфальт юлдан чаба иде инде. Шәүкәт өйдәге хәлләр, саулык-сәламәтлек турында сораштырып алды, үзе бер кулы белән радиоалгычны көйләде—төнге юлда яхшы концерт—машина йөртүчегә иң шәп иптәш инде ул.

Кунак җыерылып-бөрешеп куйды, моны шофер да күреп алды.

—Әйе, безнең якта төннәр суык, таулар якынлыгы сиздерә...

Шәүкәт “бардачог”ын ачып туганына авиаторлар белән хәрбиләр бик ярата торган хромланган фляжка сузды.

—Эчегез, җылытып җибәрер.

—Рәхмәт!—Сенаторның кәефе күзгә күренеп күтәрелде, фляжканың капкачын ачты, берничә тапкыр тәмләп йотып куйды.—Коньягы да начар түгел...

—Мин сезнең ни яратканны беләм, чын әрмән коньягы,—дип елмайды Шәүкәт, ул туган тиешле кеше ачуланды бугай дип борчылып беткән иде инде.

—Вертолет бармы?

—Әлбәттә! Алдан сөйләшенгәнчә. Хәтта аның иртүк очуы да күзгә ташланмаячак, авиаотряд өчен бу иң ерак нокта санала.

—Анысын ничек аңлаттың инде?

—Монысы да гадинен дә гадие. Аксайга гел зур кешеләр килгәнен бөтенесе белә. Житмәсә, комиссия өстенә комиссия. Акмал Арипов хуҗалыгы Үзбәкстанның визит карточкасы бит ул. Мин аңа сезнең кичтән үк килә алмавыгызны, иртүк кемнәрдер белән сөйләшеп аласыгыз барлыкны әйттем.

—Хуп!

—Хәер, аларга аңлатып тормыйча да эшли ала идем, мин бит баш диспетчер, файдалы рейсләрне оештыру миннән тора,—диде Шәүкәт. Ул ҮК кешесе белән туганлыкның өлкәдә аерым бер урын тотуга ярдәмен яхшы аңлый иде.

—Артык борыныңны күтәрмә,—дип йомшак кына шелтәләп алды аны Сенатор, ләкин бажасының елгырлыгыннан, уйлап эш итүеннән канәгать калды. Тауларга да вертолет белән барасы булыр әле дип уйлап куйды.—Ә бу очучы анда нишләмәкче була?

—Нишләмәкче дип... Дефолиация вакыты, һавадан мамыкка ашлама сиптерәбез.

—Димәк, халыкны җирдән генә түгел, һавадан да агулыйлар?—дип сорады кунак.

—Без бәләкәй кешеләр, ни кушалар, шуны эшлибез. Ә болай бәла инде, самолеттан сиптергән көнне күпләр газап чигә, бигрәк тә балалар. Ә терлек-туар? Ул болай да аз калды, анысын да агулыйбыз.

—Ак алтын! Мамык—үзбәк халкының горурлыгы!—дип мыскыллап әйтте Сенатор төксе генә, әмма башка бу темага сүз кузгатмады, кем-кем, ә ул мамыкның бәла икәнен белә иде, авыл кешеләренә дә, шәһәрнекеләргә дә каһәр иде мамык. Ул тагы фляжка эчендәгене йотып куйды, утыргычка терәлеп утырды, эчке бер канәгатьлек белән сигаретын кабызды, үзе шундук көрәнсу-озын сигарет пачкасын бажасына сузды.

—Әһә, "Кент!"—Шәүкәт зажигалкасына сузылды.

Сухроб күзләрендә вокзал бинасы өстендәге утлы-кызыл неон хәрефләр җемелдәп куйгандай булды: "Кент". Һәм ул шундук китәр алдыннан җибәргән хатасын хәтерләде. Ул портмонесын алды, анда блокнотыннан бер битне ертып, үзенең ачык каллиграфик почеркы белән "Артур Александрович Шубарин" дип язды һәм аны борын астыннан гына нидидер көй мырлаучы Шәүкәткә сузды:

—Әгәр дүшәмбегә кадәр хәбәрем булмаса, Ташкентка апаңа шылтырат, менә шушы кеше белән элемтәгә керсен, әйтсен, мин Аксай ханы янына киттем.

—Бу шулай ук куркынычмыни?—дип шөбһәле сорады тегесе.

—Юк, шулай да страховка кирәк, син бит Акмал-әкәнең характерын беләсең.

—Беләсем дә килми, аннан монда бөтен тирә-як куркып тора, хәтта обком секретаре дә...

—Яктыра,—диде пассажир һәм киерелеп куйды. Аның Акмал Арипов турында сүз куертасы килми, чөнки уйлары, бәйләнчек чебен шикелле, һаман шул тирәдә бөтерелә иде.

Район үзәгендә урнашкан авиаотрядка таң беленә башлаганда гына килеп життеләр, эш көне башланырга ике сәгать бар иде әле. Шәүкәт чәйханәдә капкалап чыгарга тәкъдим итте, ул чәйханәче белән алдан сөйләшеп куйган икән, ләкин кунак шаярып кире какты:

—Аппетитны алдан бетерәсем килми, Аксай ханы белән капкалармын, вакытында барып житмәсәм, ул мине көтеп тормас, табын янына берүзе утырмагае,—диде. Шаян сүздән икесе дә көлеп куйдылар.

Шәүкәт машинасын мәйдандагы вертолет янына алып китте. Көтелмәгән кунак чыннан да ашыга иде булса кирәк, куркуның эзен дә күрсәтмичә, очучы янына кабинага үрмәләде. Биш минуттан авыр машина һавага күтәрелде һәм таулар ягына таба юл алды.

Вертолет шактый таушалган, хәтта кай ягы беләндер иске чытыр арбаны

хәтерләтә иде, шуның өстенә, кабинада чыдап булгысыз тавыш, гөрелте. Шулай да, бер-берсен юньләп ишетмәсәләр дә, әдәплелек өчен берничә сүз алыштылар.

—Аксайга күпме очасы?—дип кызыксынды кунак.

—Гадәттә кырык минутлап, ләкин бүген җил аркан, ярты сәгатьтә барып җитәрбез... Сонга калмыйсыздыр бит?—дип җавап катыш сорау бирде Баһадур атлы очучы егет.

—Юк, юк... өлгерәчәкмен. Болай гына кызыксынуым. Мин вертолетта беренче тапкыр бит. Дөресен генә әйткәндә, мин сездә шартлары комфортлырак дип уйлый идем.

Баһадур көлеп җибәрде:

—Без шул ук шоферюгалар инде, бары һавадагылар гына.

—Элек Аксайга очканыгыз бар идеме соң?

—Ба-а-р. Беренче тапкыр гына түгел. Аучылар алып барган идем. Мәскәүдән килгән зур түрәләрне... Мылтыкларын гына күрсәң дә ис китәрлек, исемнәре генә дә ни тора, теленне сындырырлык, билләһи. "Зауэр", "Винчестер", "Манлихер", биш зарядлы "Беретта", "Франчи"...

—Олы кунакларны шушы чытыр арбадамы?—дип гаҗәпләнде кунак.

—Юк, әлбәттә, башкасында. Начальствоның махсус вертолеты бар, анда да очарга туры килгәләде. Кемгәдер ошамаганмынмы, авыл хуҗалыгы авиациясенә күчерделәр, бутифос белән кыр эшкәртергә. Дөресен әйткәндә, анда да эш майлы ботка ашау түгел. Исерек түрә каршында үрә кат, һәр мәгънәсез-мәнсез сүзенә "әйе!" дип, ләббәйкә укып торырга кирәк. Сезне идарә янына төшерергәме?

—Белмим, үзен кара, ничек җайлырак, шулай ит. Бәлки Аксайга керә торган пост янында төшәрбез. Аны бит һәр яктан шлагбаумнар белән ябылган дип сөйлиләр.

—Әйе, шлагбаум аның чире,—дип ирен чите белән елмайды очучы егет.—Гитлерныкыннан да зәһәррәк аның баррикадалары, җир асты бункерлары. Кемнән качарга җыенадыр? Ләкин шулай да мин сезне пост янында калдырмыйм, анда теләсә кемнән сорау алып җанына тияләр, муен тамырына берне тондырырга да күп сорап тормаслар. Аның ялчылары кул күтәрергә ярата... Иң яхшысы, мин сезне берләшмә идарәсе янында, Ленин һәйкәле куелган җиргә төшерермен. Шунда гына зур айван да бар. Ул шундый биектә уйланып, бөек хыялларга чумып утырырга ярата. Кремль хыялчысы диярсең. Бервакыт мин Наманганнан бер капчык алып килгән идем, җиргә төшеп тормыйча, айванга, аның аяк астына гына ташладым. Капчыкта бик кирәкле нәрсә булгандыр ахрысы, ул моның өчен мина бер сарык вәгъдә итте, төшеп утырырга туры килде. Анда тагын әле янәшәдә генә демонстрацияләр мәйданы, Мәскәүдәге кебек үк, Кызыл мәйдан дип атала. Аның барысы да Ленинча эшләнгән.

—Нәрсә, сарык яхшы мал идеме соң?—дип кызыксынды пассажир, Аксайда ленинча яшәүне хуп күрүләрен ул күптәннән белә иде инде.

—Әйе! Чын каракучкар иде. Курдүгеннән генә дә пот ярым май чыкты. Юмартлана белә ул. Үзе турында мактап сөйләгәнгә һушы китә.

Тауларга якынлашуга вертолет нык кына селкенә-калтырана башлады, вакыт-вакыт һава чокырларына төшеп китте, ләкин Баһадур машинаны кулыннан ычкындырмады, күрәсең, әйбәт очучы иде. Юкка гына ана Акмалаканең таулардагы йортына килүче югары кунаклар гомерен ышанып тапшырмаганнардыр. Сухроб бу минутта вертолетның ышанычсыз һәм җайсыз бернәрсә икәнен уйлап алды, әмма Аксайга бару өчен аңа башка юл юк иде. Олы юлдан килеп шлагбаумнар коймасын сиздермичә генә узам димә, андагы кораллы сакчылар арасыннан Ташкентка да, башкага да хәбәр сугучылар табылачак.

Аксай ханы эше белән КГБ тикшерүчеләре дә ныклап кызыксына башлауга, барысы да исәпкә алына иде, мәсәлән, ике тапкыр Социалистик Хезмәт Герое янына кемнәр килгән? Шуңа күрә, куркынычсыз юл Аксайга һавадан гына булырга мөмкин иде. Кырларны дефолиант белән эшкәрткәндә

бу бигрәк тә җайлы. Сухроб һавадан юлны ап-ачык күреп барды, ул өч рәт шлагбаумнар санарга өлгерде, постовойлар башларын күтәреп, күзләре белән вертолетны озатып калдылар. Ләкин бер постта вертолетның поселок өстеннән очасын сизенделәр бугай.

Баһадур бераз хәвефкә төшеп әйтеп куйды:

—Күрдегезме, чапанлы бер адәм каравыл өенә чапты, безнең Аксайга килүебезне чамалады ахрысы. Һәр көтелмәгән кунак монда ЧП санала бит, бары тик чакырылган кешеләр генә килә ала. Акмал ханның тәртипләре каты аның.

—Әйе, кунаклар барысы да Аксайда инде, ә мине һавадан көтмиләр,— диде битараф булырга тырышып Сенатор. Шәүкәт фаразы буенча аңа очучыны шикләндермәскә кирәк иде.

Озакламый тупыл аллеясе күренде, Баһадур аның өстеннән очып узды, поселок әле йоклый, әмма кайбер ихаталарда бәрәңге казучы кешеләр күренә инде.

—Менә килеп тә җиттек,—диде очучы һәм шунда гына Сухроб агачлар арасыннан күтәрелгән Ленин һәйкәлен абайлап алды. Аның янында гына мәһабәтлеккә дәгъва кылып салынган зура бина калыккан, аның бер ягында каланча сыманрак корылма да бар. Анысының йөк күтәрүче лифт икәнен дә чамалап була иде. "Безнең Гречко" дип эндәшкәнне яратучы инсан ил язмышы турында бөек уйларын шунда уйлап утырырга ярата имеш, ничекләр иттереп ленинча яшәргә дип баш вата, ди. Баһадур шушы корылмалар өстендә бераз асылынып торды һәм инде бер минуттан Сенатор ачык кызыл төстәге затлы келәмнәр түшәлгән айванда басып тора иде.

Хушлашып кул болгауга геликоптер үкереп күккә ыргылды һәм мамык кырларына таба борылып очып та китте. Әле уйнап торган бау-баскычтан төшеп барганда ук Сенатор идарә бинасыннан ашыгып чыгып килүче ике кешене күреп алды. Текин келәмендә каккан казыктай басып тору уңайсызрак тоелдымы, ул айваннан төште дә якынлашып килүче кешеләргә карамаска тырышып, сигарет кабызып җибәрде. "Рәсми визит башланды", дип шаяртырга уйлады ул, ләкин күнелендә шаяртыр нәрсә таба алмады.

—Әссәламегаләйкем,—дигән тавыш ишетелүгә кырт кына борылды. Янында йөзләрен елмаюга чумдырган ике таза ир-ат басып тора иде. Алар икесе дә үзләренә кирәктән зуррак үлчәмле чит ил костюмнары кигән, аякларында бик тә кәттә йомшак күн итекләр иде.

Аксай хуҗасын модага консерватив кеше, дип сөйлиләр, вакыты-вакыты белән ярымхәрби френч та киеп йөри имеш, аякларында исә шыгырдап торган хром итек булыр. Яраннары да шул моданы тота иде, ахрысы.

—Вәгаләйкемәссәлам,—дип җавап бирде ул, һәм дәрәҗәсен белеп, кул биреп күреште. Алтын тешләрен җемелдәтеп көлүләренә караганда, болар бернинди төнге каравылчылар түгел иде. Дөрес, шәрекъгә, тышкы кыяфәтенә карап кына, кешенең кемлеген чамалый алмыйсың, монда икенче төрле кануннар хакимлек итә. Урта Азияне җентекләп өйрәнгән бер инглиз галименең кайчандыр шулай дип язып калдырганлыгы мәгълүм.

Тылсым таягы селтәп әмер бирделәрмени, якындагы куаклар арасыннан ап-ак киемле, какча гәүдәле бер карт калкып чыкты, тавышсыз гына айван кырыена чәйнек, кайнар пар бөркеп торган коймаклы поднос куйды һәм тылсым көченә буйсынгандай шунда ук эреп юкка да чыкты. Хуҗалар кунакны баш иеп табын янына чакырдылар. Иркен һәм киң айванның бер почмагында эреле-ваклы атлас мендәрләр тезелгән, алар янында ике кат марля капланган дастархан. Болар бер-берсен тулыландырып, уңайлы бер табын урыны хасил итәләр иде. Ирләрнең берсе салмак хәрәкәтләр белән ак өрфия тукыманы ачып җибәрде һәм кунак алдында тагын бер матур күренеш пәйда булды. Ак ашъяулык өстен җиләк-җимешле вазалар, конфет савытлары, чикләвекле бәллүр касәләр, миндаль тутырылган бакыр савытлар, фарфор чынаяклар бизи иде. Соңгыларына, гадәттә, чикләвек белән ашарга бал салалар, сөт өсте бирәләр.

Сенатор шунда гына бик нык ачыкканын тоеп алды һәм артык тәкәллеф

саклап тормыйча, аягын салды да дастархан янына барып утырды. Әле төнге салкынлыкларын югалтып өлгермәгән курпачлар өстенә утыруга, хуҗалардан берсе: "Амин",—дип куйды, гүя кунакның атеизм ныклыгын сыный иде, үзе шунда ук чәй бүлә башлады. Чәйне җиләк-җимеш капкалап эчтеләр, пешә-пешә кайнар коймак ашадылар, сөт өсте һәм дә бал каптылар, артык мәгънәгә ия булмаган бер-ике сүз әйтештеләр, гүяки бер-берсенә сүз башларга юл куялар иде.

Сенаторга шәрекъ итагате кагыйдәләре дә, Шубариннан өйрәнгән кадәренчә генә булса да, европача дипломатия кануннары да таныш һәм мәгълүм иде. Ул вакыйгаларны ашыктырмады. Шуңа карамастан, иртәнге мәҗлестәшләренең сабырлыгына шаккатты. Нишләп алар "Кем син, ник килдең?" дип сорамыйлар икән. Ул бит Ленин һәйкәле янына күктән килеп төшкән кеше.

Кояш күзгә күренеп күтәрелде, Аксай урамнарында берән-сәрән кешеләр күренә башлады, кайберләре "изге урын"да утыручыларга карый-карый китте. Ак киемле картлач тагы ике тапкыр кереп чыкты, бушаган чәйнекләрне алыштырды, әмма бер сүз дә дәшмәде. "Бәлки ул чукрактыр, телсездер",—дип уйлап куйды Сухроб. Кыек күзгеләр илендә, бәлки, нәкъ шундый хезмәтче кирәктер дә.

Бераздан хуҗаларның күзгә күренеп борчыла башлаганы сизелде, берсе "Маяк" радиосыннан әйтелгән вакытны ишеткәч, сизелер-сизелмәс кенә баш чайкап куйды. Күрәсең, озакламый чын хуҗа Акмал хан килер вакыт җитәдер. Шуңадырмы, олырак яшьтәгесе иреннәре арасыннан берничә сүз сыгып чыгарды:

—Кем килде дип әйтергә?

Прокурор твид пиджагының түш кесәсеннән ялтыравыклы калын фин кәгазенә яхшы итеп басылган визитка алды һәм аларга сузды.

Визитканы бик карыйсы килгәнлекләрен Сухроб аларның күзләреннән үк күреп торды, ләкин итекле адәм кунак каршында мондый әдәпсезлеккә бармады, шәрекъ гадәтен саклап әйтте:

—Гафу итегез, ялгыз калдырып китәргә мәҗбүрбез, озакламый хуҗа киләсе. Ә сез ял итеп алыгыз, тагын чәй китерерләр. Капкалап аласыгыз килсә, Сабир-бабаны дәшегез. Ул күз ачып йомганчы бавырдан яисә иттән шашлык оештырыр. Без һәркөнне тәкә суябыз, бүген дә суйдырттык, шулай булгач читенсенмәгез.—Шул сүзләрдән соң мәҗлестәшләре, арт белән чигенеп, айваннан чыгып киттеләр.

Идарәгә барганда очраган зур чинар агачын әйләнеп узганда, ул аларның визитканы башларын ия-ия укып маташуларын күрде. Шәп хром итекләр шыгырдавы туктауга, прокурор гадәтләнгән хәрәкәтләр белән кесәсеннән сигарет һәм чакма алды, аларны тәлинкә янына куйды. Кыйммәтле вә затлы инглиз тәлинкәсендә ау күренешләре сурәтләнгән иде. Аннан соң дастарханнан көл савытын эзләп тапты, Акмал хан да тарта икән дип уйлап куйды һәм савытны үзенә таба шудырды.

Кояш кыздыра башлады, иртәнге салкынча җиләслек күзгә күренеп юкка чыкты һәм ул пиджагын салырга ашыкты, тирә-юньгә күз ташлап, тәмләп кенә киерелеп куйды. Иртәнге аш вакытында алар мөселманча утыра иделәр, өендә Сенатор европача яшәсә дә, монда шәрекъчә, аякларын бөкләп утырырга мәҗбүр булды, ияләнмәгән кешегә исә бу шактый авыр гамәл, шуңа күрә үзе генә калгач, ул аякларын сузып җибәрде, астына мендәр салды, мондый хөрлек шәрекътә рөхсәт ителә. Монда гореф-гадәтне, йолаларны җиренә җиткереп үтәүләре күзгә күренеп тора, аларны санга сукмау оятсызлык кына түгел, хуҗаларны мыскыллау да булыр иде. "Йокымсырап китмәсәм ярар иде",—дип уйлап куйды ул һәм сигарет кабызды.

Кыйммәтле Вирджиния тәмәкесенең йомшак төтене гадәттә аны тынычландыра, төрле күнелле уйларга этәрә торган иде, әмма бүген эчтән нәрсәдер бикли, ул элеккечә иркенлек тоймый, үзен хөр, бәйсез тоту гадәте дә эреп юкка чыкты шикелле. "Аксай һавасы шулай тәэсир итәме әллә?"—дип үзалдына елмаеп куйды прокурор, ләкин борчыган шик-шөбһәләрдән арына

алмады. Юкса, дулкынланыр-борчылыр өчен сәбәп тә юк кебек, әнә бит ничек әйбәт каршы алдылар.

Акмал ханга әйтәсе сүзләрен хәтерендә әвәләргә тырышып маташты, ләкин башына адәм рәтле ярты гына уй да килмәде. Чәйнекне күтәреп карады, ул буш иде, шул ук вакытта картны борчыйсы да килми, шулай да чәйне кайдан алып киләләр икән дип кызыксынмыйча булдыра алмады, әмма әйбәтләп кыркылган калын куакларның "тере стенасы" артында берни дә абайларга мөмкин түгел иде. Житмәсә, айван тирәсен шау чәчәктәге лоницера дигән үсемлек чолгап алган. Әмма берничә минут үттеме, юкмы, айванда Сабир-баба күренде, кулында тулы чәйнек иде. Гажәпләнүенең чиге булмады. Карт бу юлы да чәйне бер тавыш чыгармыйча аның алдына куйды һәм юкка чыкты. Әллә монда кешенең уйларын да укый беләләрме икән? Чөнки чәйнектә бу юлы яшел чәй түгел, ә менә нәкъ ул теләгән кара чәй иде!

Чәйне эчеп бетереп килгәндә генә Кызыл мәйданнан сызгырып кара "Волга" узып китте. Күрәсең, Акмал хан эшкә килгәндер, дип уйлаган кунак бу юлы да ялгышмады. Күз явын алырлык ялтыравык кара машина идарә бинасы янындагы каланча алдында туктады, йөк лифтының ишекләре ачылганы ишетелде һәм лимузин аның эчендә юк та булды. Могҗизалар илендә көн шулай башланды.

Прокурор ашыкмый гына чәен эчеп бетерде, тәмләп тагы бер сигарет тартты, вак-төякләрен кулына алып айваннан төште. Иртәнге чәйдәшләре көтелмәгән кунак килеп төшүен хәбәр иткәннәрдер, озакламый идарәгә чакырырлар, бәлки агропром берләшмәсе директоры инде үзе аның янына ашыгадыр, ни генә димә, ул бит Үзәктән килгән кеше!

Кунак ашыкмый гына "тере койма" буенда йөрергә тотынды, идарә ягына караштырып алды. Берәүләр керә, икенчеләр чыга, ул үзен тәрәзәдән күзәтә алуларын да аңлый, ләкин беркем дә аның янына килергә ашыкмады, чакырып алучы да булмады. Шактый вакыт узды, ҮК кешесе, түзмичә, сәгатенә дә карап алды, директор килгәнгә бер сәгатьләп вакыт узган иде инде.

"Тынычрак бул",—дип үз-үзен кисәтте Сенатор һәм битараф кыяфәт белән айван тирәсендә әйләнүен белде, хәзер ул бик тартасы килсә дә тотенләми, чөнки еш тарту аның дулкынлануын сиздерер дигән уе бар иде. Бәлки, Акмал хан кинәшмә уздырадыр, яисә Ташкентка шылтыратып маташадыр. Бәлки, инде аның хакында ашыгыч мәгълүмат җыялардыр? Уйлана-уйлана ул тагы бер сәгатьләп йөренде, арыгач, айванга менде.

Йомшак курпачларга жайлап урнашуы гына булды, алдында тагы Сабир-баба калыкты, ул зуп-зур бакыр подноска төяп алып килгән тәлинкәләрдә әле генә мангалдан алынган эссе-кайнар шашлык изри иде. Икенче тәлинкәдә ваклап туралган һәм өстенә корея борычы сибелгән суган, шашлыклар өстендә әле генә тандырдан алынган кайнар-кызыл кабартмалар.

"Күрәсең, мине тиз генә кабул итмәсләр",—дигән уйга килеп прокурор акрын гына ашарга кереште. Шашлык гажәеп дәрәжәдә тәмле, баш әйләндергеч хуш исле иде. Шулчак ул коньяклы фляжканы машинада калдыруына үкенеп тә куйды, юкса әбәткә һәм кәефне күтәрергә бик ярап куяр иде.

Йомшак яшь тәкә итен саксаул күмерендә кыздырганнар булса кирәк, пешекче үз эшен яхшы беләдер, мөгаен. Сухроб шашлыкка мөкиббәннәрдән түгел иде, ләкин Аксай шашлыгы аңа ошады. Беренче порцияне ашап та бетермәде, икенчесен китерделәр. Башта боларының шампурларының сәер бөгелеше гажәпләндергән иде, әмма шашлыкның хуш исеннән ул аларның ачык утсыз яна торган тандыр-кебабта кыздырылганын аңлап алды. Ташкентта андый мичләрдә шашлык эшләүне инде онытып баралар, пешекче осталар Фирганә үзәнендә генә калып бара, күрәсең, шундыйларның берсе ашау-эчүдә талымчан Акмал ханга хезмәт күрсәтәдер. Тандыр-кебаб белән бергә сүзсез карт ачык-чучук дигән үтә дә яндыручан салат һәм ике чәйнек чәй алып килде, шашлык ашагач, гадәттә үтереп эчәсе килә башлый.

"Суярга ашаталармыни",—дип, ирония белән уйлап куйды кунак, идарә

ягына сиздермәслек карашлар ташлап алды, ә анда анын килгәнен белмәгән кебек кыланалар иде. Юкса, һәйкәл янындагы айван дүртенче каттан яхшы күренә булыр. "Хәзер мин капкында,—дип уйлады Сенатор тыныч кына.— Артка чигенергә дә юл юк, кертмәгән кебек, ханның ихтыярыннан башка чыгып та китә алмыйсың". Ул курку сизми иде, эч пошуы да үтте, ханның вакчыл мин-минлеге файдага гына булды, шулай итеп, ул үзенең йомшак якларын ачып ташлады түгелме соң? Бүген, бигрәк тә анын хәлендәге кешегә, ҮКның административ бүлек мөдирен ярты көн мәйданда тотарга ярыймы соң?

Дүртенче катка кара "Волга"да гына менүче кешедән үзенең өстенлеген сизгән прокурор вәзгыятьне тәмам аңлап алды. Төп сәбәп киңәшмә-мазар да, каядыр ашыгыч шылтырату ихтыяҗы да түгел, бу—кунакны кимсетергә маташудан туган вакчыллык кына иде, янәсе кемгә килгәненне бел!

Шашлыкны ашап бетерүгә, тавышсыз картка ияреп яшь кенә бер кыз килеп керде, кул юарга кечкенә ләгән урнаштырды, комганнан су салып торды, дастарханны җыештырды, савыт-сабаны алыштырды, газетлар кертте. Бусы да уенның бер өлеше иде бугай, аны онытмыйлар, ашыгычлык белән нидер кырырга да маташалар ахрысы.

Газетлар иске булып, аларның күбесен прокурор укыган иде инде. Ул ашыкмый гына аларны актарды, үзе дүртенче катка караш ташларга да онытмады. Тәрәзә пыялалары чиста, алар аша ул анда кемнәрнеңдер әле бер, әле икенче тәрәзәгә килүләрен күреп алды. Табигый ки, аларны Ленинга куелган һәйкәл-сын кызыксындырмый. Әмма прокурор беркатлы кешеләрдән түгел, иртән үк чакырмаган икән, хәзер менә нигә килгән дип башын ватсын, яраннары белән киңәшсен, прокурор анда үз аягы белән барып кермәячәк.

Кояш кыздырганнан кыздыра, айванда бөркү була башлады, юлбашчы һәйкәленнән төшкән күләгә уңгарак авышты, Сенатор сәгатенә карап алды, тагы ярты сәгатьтән чакырмасалар, торам да Аксайдан китәм дип уйлап алды, шулчагында селкенә башларлар. Күрәсең, анын бу хәрәкәтен дөрес сизенделәр, бер егерме минуттан иртәнге шәп итекләрнең шыгырдавы ишетелде.

—Гафу итегез, Сухроб-әкә, эшләр-мәшәкатьләр күбрәк шул,—диде ул.— Мин сезнең килүегез турында директорга әйткән идем, тик аны ашыгыч рәвештә обкомга чакырып алдылар, ул сезне яхшылап кунак итәргә кушты.

—Ничек алай? Идарәдән машина китмәде, йөк лифтының шыгырдавын мин ишетми калмас идем,—дип кырыс итеп сорады Сенатор.

—Тагы бер тапкыр гафу итегез, сез бит Аксайда беренче тапкыр, безнең бинага төрле юллар белән керергә, төрлесе белән чыгарга мөмкинлеген белмисез, ә бер үк номер тагылган кара "Волга"лар, сер итеп кенә әйтәм, берничә, шуңа алар вакыт-вакыт кешеләрне бутыйлар. Хуҗа бүген сезнең белән кичке ашны бергә ашыйм диде, ә хәзер әйдәгез, мин сезне кунак йортына алып барам. Юл кешесенә ял яхшы, юынып чыгыгыз, анда, сез килүгә дип бассейнда суны алыштырдылар, фин саунасын җылыта башладылар.

Шунда прокурор тагы үзенең Кыек көзгеләр илендә икәнлеген исенә төшерде, җир асты бункерлары, катакомбалар, шоссега һәм елга ярына чыгучы тоннельләр дә барын ул онытып җибәргән иде.

Кунак йорты, прокурор уйлаганча, янәшәдә түгел икән, анда машинада барырга туры килде. Алма бакчасына салынган, көнен дә, төнен дә яхшылап саклаучы искитмәле чуар йорт декоратив агачлар, сирәк куаклар белән чолгап алынган, ике метр биеклектәге тимер челтәр белән коймаланган иде.

Эчке якта, паркта диик, бар урыннарга озын тимер чыбыклар сузылган, болары бәйдәге бүре буар этләрне иркен йөртер өчен. Ишегалдындагы хезмәтчеләрнең тыз-быз йөрүеннән ул шуны аңлады: кунакны каршылау турында фәрман әле янарак кына бирелгән булса кирәк.

Кышкы бакча янынннан узганда уң тарафта ябык өсле бассейнны да күреп алды, анын зәңгәрсу кафельле стена-диварлары, су төсенә кереп ымсындырып торалар иде. "Чумып чыгу начар булмас, су коенмаганыма йөз елдыр инде",—дип прокурор елдам гына уйлап алды, шулвакыт үзенең плавкисыз икәнен искә төшерде. Кунак йортында аңа бирелгән бүлмәгә

килеп керсә, тагы бер шаккатты: караватта алтын төсендәге йомшак халат, кибет төргәгендә су коену ыштаны-плавки, ак махер одеал һәм шундый ук сөлге ята иде—барысы да өр-яңалар. Сенатор шундук пижаманы киде, ул аңа тап-таман булып чыкты һәм коенырга китте. Башта ул ишекләре бассейнга караган сауннаны тикшереп чыкты, анда берәү мунча алдында электр самавырын көйгә сала, суыткычка чех сырасы тутырып маташа иде.

"Тау ханы заманча яши белә",—дип үзалдына уйлап куйды ул, монда байлык өстендә байлык, зиннәт өстендә зиннәт барын ишетсә дә, болай ук булыр дип күз алдына да китерә алмый иде. Тауда аучылар өчен салынган әкияттәгечә зиннәтле сарайлар, мәрмәр колонналы, сырлап-бизәкләп эшләнгән ат сарайлары, яхшы нәселле атлар, аларның аукционнарда адәм башына сыймаслык бәяләрен дә искә төшерергә мөмкин иде. Ләкин суы жылытыла торган бассейн һәм үзенә әзерләп куелган кием-салым прокурорны ныграк гаҗәпләндерде.

Ул озак итеп, рәхәтләнеп йөзде, коенды. Акмал хан мондый йөзү залын нинди видеофильмнарда күреп, күчереп эшләткәндер, анысы нәмәгълүм, әмма бассейн гаҗәепләр дә әйбәт, матур һәм унайлы иде. Дөрес, жирле, милли архитектура чалымнары юк диярлек. Диварлары тоташтан озынбиек тәрәзәләрдән тора, затлы һәм чыдам кирпечтән эшләнгән стена, куе чия төсендәге калын тукыма белән каплау мөмкинлеге дә каралган пыяла түбә, зур агач кисмәкләрдәге пальмалар, сирәк очрый торган кәрлә агачлар, келәм юллар, бинаның төсенә тәңгәл китереп сайланган паласлар мондагы һәрнәрсәнең уйлап эшләнгәнлеге турында сөйли иде. Ул әле тагы су керергә җыена иде, ләкин саунадагы кеше кереп сорады:

—Сухроб-әкә, йөз ун градус эсселек житәрме?

Халатны эләктереп саунага күчәргә туры килде.

Ул инде бассейннан, саунадан, бай өстәлдән дә ифрат риза кебек булды, ләкин иң ахырда нервылары уйнап китте, кәефе кырылды, ул үзенең кайда икәнен уйлый башлады. Саунадан ул коену залына өч тапкыр йөгереп чыкты, бассейнның зәңгәрсу чоңгылына чуму шундый рәхәтлек китерә ки, су бераз салкынчарак булса да, тәнгә сихәт бирерлек дәрәҗәдә йомшак иде, самавырга да шифалы суны бер чыганактан алалардыр. Соңгы мәртәбә йөзгәндә прокурор бассейнның ахырына кадәр барып житте, анда күгәрми торган корычтан матурлап бөгелгән өч баскыч куелган, алар судан чыгарга бик жайлы иде. Йөзеп килүгә, ул кулын тоткаларга сузды, кинәт кенә гәүдәне каучук белән тышланган басмаларга ыргытасы килеп китте. Бармак очларын тидерүгә, аны электр тогы суккандай итте, ул куркынудан кычкырып куйды, шунда авызына су керде һәм бассейнның уртасына таба йөзә башлады, шунда үзе "менә Аксай ханының тагы бер кеше башы житмәслек алымы" дип уйлады, баскычларга ток бирден, анда бер дошманыңны йөздерден һәм кеше юк—зәңгәр бассейнда матур үлем булачак. Ләкин икенче мизгелдә аңлап алды, шуны оештырсалар, ул бит үләләр патшалыгына атлар иде. Шундук үз хәленә бәя бирде: нервылар нык какшаган, мунча алдыннан коньяк белән артык мавыкты шул, югыйсә кабымлыклар бик шәптән иде бит. Ярый әле саунаның калын ишеге нык ябылган, хезмәтче аның куркынып кычкырганын ишетми калды. Прокурор судан чыкты да бассейнны чолгап алган киң бордюрга барып ауды, чөнки куркудан аяклары дерелди, атларлык хәле дә юк иде. Мунча алдында сыйлану теләге шундук башыннан очты, ул сауна хуҗасы белән саубуллашып үз бүлмәсенә атлады. Керүгә караватын көйләде һәм җәймә астына чумды, ике тапкыр Социалистик Хезмәт Герое исеме алган, күкрәгендә, үзе әйткәнчә, ике Гертруда йөрткән кеше белән сөйләшү алдыннан әйбәт кенә йоклап алырга кирәк иде.

Бассейндагы куркуга карамастан, шундук йокыга китте, татлы изрәү белән онытылды, бәлки ул иртәнгә кадәр дә йоклаган булыр иде, ләкин шыгырдавыклы итек кигән иртәнге чәйдәш уятты:

—Торыгыз, торыгыз, Сухроб-әкә,—дип ул аны жилкәсеннән жиңелчә генә селкетә иде.—Бер сәгатьтән хуҗа килә, пешекчеләр күптән кичке ашны әзерлиләр, торыгыз.

Прокурор теләми генә торды, алтын тешле адәм чыгып киткәч кенә аңлап алды—бер сәгатьтән теләгән кешесе—күпме куркынычлар аша янына омтылган кеше белән очрашачак. Ул тагы тиз генә алтынсу төстәге халатка төренде һәм бассейнга ашыкты, бары салкынча су гына күңел көрлеген, тән ныклыгын кайтара ала, ә алар кирәк булачак әле.

Озаклап коенды ул, хәтта хан белән нәкъ менә бассейнда очрашу теләге дә баш калкытып куйды, ләкин ул бу теләкне башыннан куарга тырышты һәм ашыгып коену залыннан чыгып китте. Бүлмәдә телевизор карап утырып та булыр иде, әмма аңа дүрт стена эчендә тар, тәрәзәдә көчле кондиционер гүелдәп утыруга карамастан, эссе-тынчу булып тоела башлады һәм ул ишегалдына ашыкты.

Җәйге кухняда пешекчеләр кайнаша, алар янында иртәнге якта газет алып килгән Мәүлидә ярдәм итеп йөри, әмма ак киемле сүзсез карт килеп житмәгән иде әле, күрәсең. Ул паркның иң ерак аллеяләренә борылды, аның ишегалдына килеп керүгә үк махсус көтеп торгандай Арипов белән очрашасы килми иде. Шулай да ул бакчада нинди хәрәкәт барганлыгын абайларлык, кунак йортының яшел капкалары шәйләнерлек юллардан читкә китмәде. Энгер-менгер төште, хуҗа килер алдыннан аллеяләргә шлангтан су сиптерделәр, бакчада яңгырдан соң була торган салкынча-саф һава урнашты. Өлгереп житкән алма исе бөтен паркка җәелгән, монда башка жимеш агачлары юк иде, ләкин кыргый-матур агачлар һәм куаклардан (аларның кайберләре әле чәчәк атып утыра), розарий һәм кура җиләклеге ягыннан тәненне иркәләр, җаныңны дулкынландырырлык ис-аромат аңкый иде. Болар өстенә, жил таулардан чикләвек урманнары, кыргый алыча исләрен дә алып килә, болар барысы да йорт янында сулышны кинәйтеп, тәнеңне рәхәт дулкынга көйләүче мохит тудыра иде.

Бераздан аллеяләрдә ут кабынды, беседкалар янында, тыгыз-куе артыш куаклары арасында декоратив яктылык җемелди башлады. Имеш, алар янында яшәгән кешенең гомере озын була. Бикле яшел капкалар янында да ут кабынды. Ә хуҗа һаман күренми иде әле. Прокурор акрын гына атлап йөрүен дәвам итте, сукмакларга искечә манерда юеш кызыл ком сибелгән иде, кинәт кенә аның исенә Ташкенттагы балачак хатирәләре белән бәйле җәйге "Хива" кинотеатры килде, тавышсыз кино заманнарында "Солей" дип аталган ул кинотеатрның да бик матур бакчалы ишегалды булып, аның сукмакларына да нәкъ менә шушындый ком сибәләр иде. Аксай бакчасы балачак истәлекләрен яңартты. "Хива" театрында күрсәтелгән киноларны ул юан чикләвек ботагына утырып карый иде, ләкин аңа еракта калган яланаяклы балачак хатирәләрендә казынырга ирек бирмәделәр, йорт бусагасында алтын тешле кеше күренде.

—Сухроб-әкә,—диде ул.—Өйгә рәхим итегез.

Хан тагы мөгез чыгармакчы була, дип уйлап куярга өлгерде прокурор. Күрәсең, очрашуны иртәнгә калдырмакчыдыр. Ләкин ул якынлашуга, кыйммәт костюмлы, шыгырдавык итекле елмаеп әйтә салды:

—Рәхим итегез, минем арттан барыгыз, хуҗа сезне көтә.

Сенатор иртәдән бирле үз исемен дә әйтмәгән кеше артыннан иярде. Күрәсең, йортка керү өчен дә туннель бардыр. Юкса, күктән төшмәгәндер ич. Башны юк белән ватарга кирәкми иде, ләкин шунысы хак, хуҗа, чыннан да, цирк трюклары ярата икән. Кинәт ачуы кузгалган прокурор аңа эчтән генә "Күз буучы" дигән кушамат тагып та өлгерде. Аксай ханына бу исем бик тә килешеп торыр иде.

Алар озак кына галерея буйлап бардылар, монысы кышкы бакча иде, аннан сулга, ачык-кызыл төстәге келәм-юл җәелгән паркет идәнле коридорга борылдылар, шулчак алтын тешле сул яктагы ишекне шакыды. Эчтән җавап ишетелмәде кебек, ләкин аны озатучы ишекне ачып җибәрде һәм керергә яраганлыгын ишарәләп Сухробка ым какты.

*Дәвамы киләсе санда.*



**Рашат
Низами**

# ТОРМЫШ ФАСЫЛЛАРЫ КАЙНАМАКТА

*Умом Россию не понять...*
(Тютчев)

**“Коммунизмга дип барган шәпкә”,**
**Өзелсен дә китсен әле лепкә!**
**Корыч фундамент дип лаф орулар**
**Уратылган булган черек җепкә!**

**Кара халык эшкә карышмады.**
**Үстерде ул бодай, арыш, тары.**
**Шигарьләрен чөеп җилгә очты**
**Россиянең күпме алтыннары!**

**Тирән тамырларда сут калырмы,**
**Илнең амбарында кот калырмы?**
**Батып бара торган албастыны**
**Иганәләр генә коткарырмы?**

**Белем кыяларын кимерсәк тә,**
**“Тимер диварлар”ны җимерсәк тә,**
**Шовинизм дигән кара чуан**
**Гел кычытып тора бу терсәктә...**

**“Үткәннәр”не тоташ сагыну бар,**
**“Яңа чор” дип дөрләп кабыну бар.**
**Халыкларны кая таба илтер**
**Демократик битлек ябынулар?—**

**Космосларга, әйе, менгән чакта,**
**Завод-фабрикларны бүлгән чакта?**

---

Рашат НИЗАМИ (1930)—*шагыйрь, прозаик, публицист; “Йолдыз яңгыры”, “Кызыл җәй”, “Ут һәм Җыр” һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Тетри дәүләт—эзсез, бер хәбәрсез
Бер кешесе хәтта үлгән чакта...

Кече парламентлар хокук сорый,
Башларына суксаң—йокымсырый.
Берни аңламыйча яшәп ята
Йә Машенька шунда, йә Шәмсурый.

Гөрләп кенә бара дисәң эшләр,
Буып ала яңа үзгәрешләр:
Камчаткадан алып Кавказгача—
Забастовка, утлы түнтәрешләр.

Киллерларга ирек биргән чакта,
"Держава!" дип күкрәк төйгән чакта,
Халыкларга татлы Азатлыкны
Тамчы-тамчы итеп бүлгән чакта,

Россияне
Әйе, аңлау мөмкин
Фәкать кан һәм күз яшьләре аша...

## Дөнья урамында уйлану

Бар сәгатьләр дөрес йөри бугай,
Камиллеккә дөнья ирешкән.
Берәүне дә рәнҗетмичә генә
Агып ята елга-инешләр.

Дөнья урамына чыктым әле
Язарыма азык табарга.
Үлчәүләр дә кайчак дөрес үлчи—
Кибетләрдә булсын, базарда.

Дивардагы авыр маятниклар
Уңга-сулга дөрес чайкала.
Чал болытлар күпме капламасын,
Күктә кояш барыбер сау кала.

Миллионнар бәхет эзләп, әнә
Таптый илнең такыр идәнен.
Менделеев таблицасыдай
Шаулап тора тормыш дигәнең.

Трамвайлар юлдан дөрес бара
Шыгырдатып тимер рельсны.
Ә син, кешем, әйтеп бирче миңа:
Кылган эшең—бар да дөресме?

Шахта арты шахта авып төшә,
Шәһәрләрне ташкын су баса.
Нишләр идек, илнең лабазында
МЧСлар әгәр булмаса!

Тагын кайда, нинди шартлау булган?
Бюрократлар, зинһар, азмагыз:
Фәлән кадәр зыян килде, диеп
Суга сәнәк белән язмагыз...

Төрмә диварлары чалыш әнә,
Чалыш язмыш белән тутыргач.
Терәү арты терәү салыйк әйдә,
Инде килеп эшкә тотынгач.

Илдә бәя күтәрелгән саен
Дөреслекнең төшә бәясе.
Нинди генә микроүлчәү белән
Үлчәргә соң яшәү мәгънәсен?

Бар да дөрес бара бугай бездә:
Ак-карадан төсләр кабына.
Тик нигә соң дөнья урамында
Хакыйкатьләр ешрак абына?

## Күңел яшьлеге

*Р.гә*

Мин дөньядан качып китмәк идем,
Ә ул—качып бара үземнән...
Тәлгәш-тәлгәш энҗе миләш булып
Күз яшьләре ага күземнән.

Нигә, энкәй, сагышлы җан итеп
Яраткансың мине дөньяга?
Еллар аша карыйм:

Синең ак яулыгың
"Матурлык!" дип һаман чаң кага!

Каберендә—миләш...
Миләш ачы,
Ачыттыра кайчак күңелне.
Без яшәгән саен яшәрбез,
Әллә картаябыз түгелме?

Кеше булып яшәү җиңел түгел,
Мең кат үләм, мең кат терелам:
Яки чәчәк булам буразнада,
Кирәк икән—гади бер үлән.

Кырларымны бик еш сагынамын,
Сагына булыр мине дә күкчәчәк.
Үләм икән, минем белән бергә
Ярты дөнья җирдә үләчәк...

Шундый яратабыз сине, тормыш,
Килми синнән, килми китәсе.
Бар бит әле бәхет капкасыннан
Шаулап-гөрләп бергә үтәсе.

## Сыналу

Хәтеремдә:
Көзге бозлар көзге кебек...
Кырпак карлар бәгыремне өзде кебек.
Чәчрәп кердем шул бозларның уртасына,
Таза дисең, әмма ләкин ул да—сына!

Көзге бозлар, ни әйтсәң дә, чыртлап тора,
Ничә адым атлавыңны чутлап тора.
Аяк асты чатыр-чотыр чәрдәкләнә—
Яшькелт сулар алда әнә күтеп тора.

Язгы сулар хәтеремә төшә минем,
Туган ягым—карлы-бозлы Мишә минем.
Ургып-ургып ташу төшә басулардан,
Калын бозлар сәфәр көтеп тәмам арган.

Бала чакның саф акылы хәтерле шул,
Язгы бозлар, ни әйтсәң дә, мәкерле шул:
Ул, пышылдап, кинәт кенә ярыладыр,
Чоңгыл булып чабуыңа сарыладыр.

Тормышның да фасыллары кайнамакта,
Тайгак бозлар безне һаман сынамакта.
Әй, син, язмыш, дөрес итеп атлар өчен
Без бәндәңә мәдәт бирче—шундый чакта!

*

Араннарда күрдем моңсу атны,
Шомырт кара ялы—катлы-катлы.
Нинди сагыш урап алган аны,
Керфек йомар микән таңга чаклы?

Моңсу кызны күрдем тын бакчада,
Атлап йөрешләре бигрәк садә!

Дидем: шөкеранә, югалмас бу
Хәсрәт чоңгылына эләксә дә.

Бакчы моңсу сулар агышына:
Тәңкә-тәңкә төсләр алышына.
Күпме тылсым сыйган—балыкларның
Суны чупылдаткан тавышына.

Кояш нурлары, әй, бәйрәм итә
Җиһан өстәлендә корып табын.
Күктә таган атына алсу кояш,
Күргәнем юк аның моңсу чагын.

## Син һәм мин

Калдырдым да трамвайлар шавын,
Ялгызлыкка бүген ашыгам.
Кочак җәеп әнә тын бакчадан
Көз йөгереп чыга каршыма.

Учларыма сары яфрак ята,
Тоям күктә серле моң барын.
Аһ, алтын көз!
Якын сердәш сыман
Син җилкәмә салдың кулларың.

Әй, сөйгән яр!
Син дә мине шулай
Каршылаган идең бүлмәңдә.
Яфрак төсле учларыңны кыстым
Бусагаңнан атлап кергәндә.

Катлаулы соң сөю баскычлары:
Анда—шатлык, сагыш, гарасат.
Якты көз бит, беләм,
Синең сыман
Дәшми генә китеп барачак...

## Яшьлекнең бер көне

Күзләреңдә—таң сурәте,
Анда вакыт кабатлана.
Ул керфекләр!..
Әйтерсең лә
Карлыгачлар канат кага.

Күзләреңдә—көн яктысы,
Анда нурлар тулышкандыр.
Сине матур итәр өчен
Бар табигать тырышкандыр.

Күзләреңдә кояш байый,
Нәрсә булды сиңа кинәт?
Ачы сөю тәлгәшләрен
Татыгансың бүген, димәк...

## АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ

# КЫЛДАН НӘЗЕК, КЫЛЫЧТАН ҮТКЕН

РОМАН

*Аязның соңгы ноктасын үзе куеп матбугатка тапшырырга өлгерә алмаган романы 1988 елдан бирле аның эш өстәлендә ята бирде...*

*Шул еллардан бирле байтак кына күләмле әсәрләр тәмамлады ул. Мәсәлән, Якуб Зәнкиевнең "Иртеш таңнары" романын әдәби яктан эшкәртергә, үзенең "Йөгез, бер дога!" романын "Кылдан нәзек, кылычтан үткен" романыннан соң яза башлап та, соңгы нокталарын куярга өлгергән. Ә бу әсәренә тагын да күбрәк материаллар туплавын дәвам иткән...*

*1994 елның август аенда аны инсульт "дусты" килеп кочаклап алды. Аннан соң да әле ул байтак кына күләмле әсәрләр язды, әмма ләкин романга тотына алмады... Мин аңа: "Ник язмыйсың инде бу романыңны?" дип сорау да биреп караганым булды. Ул аны 1997 елда Зәйдә яшәгәндә яңадан эшләргә керешеп тә карады, ләкин гел үк тәмамларга насыйп булмагандыр шул. "Карчык, мин бу әсәрне бик тирән мәгънәле әсәр булыр дип өметләнәм, савыгып җитү белән язып бетерермен",—диде.*

*Соңгы айларда Аязның бу романын кулыма алып елый-елый укып утырдым да: "Никадәрле гыйбрәтле вакыйгалар, мәгънәле фикерләре бар ич бу әсәрнең",—дип, "Казан утлары" журналына тәкъдим итәргә булдым. Аның өстәлендә язылып ятучы әсәрләрен тикшереп укып йөри торган гадәтем булмаганга, һаман язу өстәлендә ятканга күрә аңа вакытында минем дә кул тимәгәндер шул! Журнал укучылар күңеленә хуш килер дип уйлыйм.*

***Нәкыя ГЫЙЛӘҖЕВА***
13 июль, 2003 ел.

Кеше гомерендә еш кабатлана торган очраклы хәлләрнең, гомер азагына килеп житкәндә, акыл белән җентекләп тәфсилләгәндә бер дә очраклы булып чыкмаганына ышана гына барасың. Алар кешенең табигатенә, холкына, омтылышларына турыдан-туры бәйләнгән булалар икән. Асаф Сәхиповичны истә-оста югында Югарыга чакырып алдылар да N районына командировкага барып кайтырга тәкъдим иттеләр. Башкарырга тиешле эше бик гади һәм җиңел булса да, Асаф Сәхиповичның йөрәге дерт итеп куйды. N районы хезмәт ияләренә байрак тапшыруны ялга барып кайту дип кенә атасаң дап ярый. Барасың, күз өстендә каш буласың, халыкны тантана үзәгеннән торып күзәтәсең. Соңгы вакытта саулыкка туймый башлаган, алтмышка якынаеп килә торган министрның беразга гына өеннән югалып торуы зыянга түгел иде. Ни әйтсәң дә гаилә синнән, син гаиләдән

ялыга башлыйсың... Йөрәгенен дерт итеп алуының житди сәбәбе болар түгел иде, әлбәттә. N районы белән чиктәш авылда аның яшьлек мәхәббәте, озак еллар сөйгән, гомере буе табынган Гөлсинәсе яши иде. Алар бик күп вакытлардан бирле бер-берсен сагынышып яшәсәләр дә, соңгы өч-дүрт елда күрешкәннәре юк. Ул якларга барып чыгарга туры килмәде диярлек, атап Гөлсинә янына барып керә алмыйсың. Башкалада, ишле халык арасында халык күзенә кадалып йөрмәсәң дә, авыл җирендә министр кадәр министрның һәр адымы, һәр төчкергәне мәгълүм, ниятләп бирәр яры юлга чыксаң үзеңнән күп алда хәбәрең барып житә... Дөрес, N районы үзәгеннән Гөлсинә яшәгән авылга йөз чакрымнар барасы була, әмма хәзерге заманда йөз чакрым арамыни?.. Выжлап барып җитәсең. Гөлсинә яшәгән авыл әллә кайчан тарала башлаган иде, хәзер юньле-башлы кешесе дә калмагандыр, машинаны ындыр артына ук килеп җиткән урманда калдырасың да, миләш, балан куаклары белән чуарланган үзән буйлап туп-туры авылга барып керәсең... Гөлсинә шул авылда фельдшер булып эшли, авыл читендәге өйдә яши. Ялгыз бер әбидә фатирда тора... Әби исән микән инде? Элекке килүендә дә бик сыкранып, зарлана-зарлана гына урыныннан кузгала иде...

Алай да сак булу зыян итмәс, Асаф Сәхипович белән Гөлсинә арасын авылда да, районнарда да белгән кешеләр бар, яшьрәк чакта, әле министр кәнәфиен биләгәнче, ул Гөлсинәне урман аланнарында: ышыкта үтә торган яшерен мәҗлесләргә дә алып баргалый торган иде. Дөрес, утырдашларының күбесе хәзер Татарстанда юк, калганнары да, соңгы еллардагы җилләр тигәч, теләр-теләмәс булса да урыннарын алыштырдылар... Гөлсинә сылу, чибәр, ирләрне котырта торган матурлык белән өретелгән зат иде. Ул чагында Асаф Сәхипович мактанырга ярата иде әле...

Хатыны—Суфия ханым, Асаф Сәхиповичның N районына барасын белгәч, әдәп өчен генә: «Бәлки берочтан әтиләргә дә кереп чыгарсың?»—дип сорады.

Асаф Сәхиповичның әтисе, ялгыз Сәхип карт, N районыннан ерак түгел авылда яши иде. Байтактан күренгәне юк, хат та язмый, Зәкиевләрнең үзләренең дә кайтканы юк иде.

Асаф хатынына карап алды да, шулай ук әдәп өчен генә: «Вакыт сыйдырса карарбыз»,—дип кенә куйды. Алар бу хакта сүзне озайтып тормадылар. Суфия ханым иренең әткәсе Сәхип картны килен булып төшкәннән бирле яратмый, аны санга сукмый, иренең шундый гади нәселдән булуы белән хурлана иде. Министр булып расланганнан бирле Асаф та туган йорты белән араны өзде диярлек, хат язмый, посылка салмый, кайтырга да ашыкмый...

Район үзәгендә тантана артык шау-шулы булмаса да, күңелле генә узды, район житәкчеләре Асаф Сәхиповичка рәхмәт укыдылар, аны «шушы төбәкнең патриоты» дип атадылар. Әле район житәкчеләренең карамагыннан ычкынып бетмәгән, карурман уртасында, күл янына салынган йортка дәштеләр, ләкин Асаф Сәхипович кырт кисте. Шунда, ашханәгә кереп кенә, аннан-моннан капкаладылар. Асаф Сәхипович Гөлсинә янына ашыга иде, тынычлыгы югалган, ашау дәрте дә кимегән иде. Шулай да, район житәкчесе, шоферга күз кысып, аның кулына олы гына төргәк тапшырып өлгерде. Төргәкне күрсә дә күрде Асаф Сәхипович, күрмәсә дә күрде. Шофер тәҗрибәле, күпне күргән Тәлгать төргәкне урнаштырганда анда өч шешә эчемлек, башка вак-төякләр барлыгын абайлап, тамагын кырып куйды. Мондый бүләкләрдән Тәлгатьнең дә өлешсез калганы юк иде әле монарчы...

Район үзәгеннән кичкә кырын чыктылар. Кыстасалар да кунарга калмады. Беренчедән, Гөлсинә янына кереп өлгерергә, аның яныннан да ярты төндә юлга чыгарга һәм иртәнге сигездә Асаф Сәхипович пристаньда катерда булырга тиеш. Мәскәү кунагын балыкка алып чыгу аңа һәм тагын берничә иптәшкә йөкләнгән иде. Дөрес, Мәскәү кунагы Асафлар министрлыгына килмәгән, әмма аның атаклы балыкчы булуы өстенә, аш-су тирәсендә осталыгын да күздә тотып, житәкчеләр кунак кабул итүдә аның да булуын мәслихәт тапканнар иде. Ул бу бурычны сөенеп кабул итте...

Юлга чыкканда аның икеләнүләре бетмәгән иде әле, әмма N.да булган тантаналар, аның исеменә яуган тоташ рәхмәтләр Асаф Сәхиповичны яшәртеп җибәрделәр, ул Гөлсинәсенә бармыйча кайта алмаслыгын сизенде. Инде төнне юлда үткәрә икән, түзәр, ул машинада рәхәтләнеп йокларга гадәтләнгән һәм Тәлгатькә үзеннән дә ныграк ышана. Тәлгать Татарстан юлларын һәм хуҗасының гадәтләрен биш бармагы кебек белә, ял иттереп алып барачак та, иртәнге алтыларда алып та кайтачак... Кунак иртәнге поезд белән килеп төшсә Асаф Сәхипович аны каршыларга да, балыкка алып барырга да өлгерәчәк. Кайчан тагын җае чыга да, кайчан Гөлсинәне күрә ала әле ул?..

N районыннан чыгам дигәндә генә юл икегә аерыла: сулдагысы Гөлсинәләр ягына китә, уңдагысы—Казанга. Юл чатына җитәрәк Тәлгать машинаны акрынайтты һәм каршыдагы көзгедән хуҗасының йөзен күзәтә башлады. Асаф Сәхипович кулын авыр гына күтәреп:

—Сулга,—диде.

Тәлгать машинаны тизләтеп сулга борды һәм Асаф Сәхипович җинел сулап куйды.

Аз гына булса да ул тормыш ыгы-зыгысыннан онытылып торачак, ял итәчәк. Тантана тавышы колагыннан чыга төшкәч, азрак тынычлангач, ул аз гына черем итеп алды. Гомере буе сагаеп өйрәнгән кеше бер секунд эчендә йокыга да китә ала, ул үзен шулай өйрәткән, төннең теләсә кайсы вакытында телефон тавышына уяна һәм көч җыйган була...

Бу юлы озаграк йокланган ахрысы, ул уянганда машина агачлар арасына кереп туктаган, тирә-як тып-тын, машинаның ачык ишегеннән салкынча, рәхәт һава агыла иде. Ул тиз-тиз машинадан чыкты һәм мотор тирәсендә кайнашкан Тәлгатькә карады.

—Әллә машина белән генә илтимме?—дип сорады Тәлгать.

—Юк,—диде.—Моннан ерак түгел ич,—диде Асаф урман авызы яктылыгын чамалап.

—Төенчекне аласызмы?

—Юк... Ә анда нәрсә бар?

—Иң кирәге бар шикелле.

Асаф Сәхипович иртәнге хәлләрне чамалап башын какты һәм китәргә җыенды.

—Плащ алыгыз,—диде Тәлгать.

Ул күккә карады: караңгылык өстәп урман өстендәге күктә болытлар куера башлаган иде. Ул плащын иненә салып, буш кулы белән генә, сукмактан чыклы үләннәргә чыкмаска тырышып, авыл ягына карап китте. «Озак торырсызмы?»—дип сорарга теләде зирәк Тәлгать, сорамады, хуҗасы кызыксынганны яратмый иде.

Өйдәме Гөлсинә, сау-сәламәтме, Асаф Сәхиповичны кабул итәргә ризамы, әзерме? Юлаучы бөтенләй алар турында уйламады. Ул Гөлсинәнең үзенеке, бары тик үзенеке генә икәнлегенә шул кадәр ышанган иде ки, ул сукмак уртасыннан барганда яшь хатынның кайнар кочагы, эре башлы тыгыз күкрәкләре, йомшак куллары хакында гына уйлады... Ул авылга барып кергәндә караңгы шактый куерган, баш очындагы сәрәпәләнеп торган болытлар шактый тыгызланганнар иде. Җил юк, ник бер яфрак селкенсен. Ә баш очына күтәрелеп карасаң, болытларның хәрәкәтен, ишелеп-ишелеп акканын күрәсең. Асаф Сәхиповичның күкрәгенә күптән татылмаган шикләнү, шом керә башлады. Кереп тормыйча гына борылып китәргәме әллә, дип уйлады. Ләкин зарыгу аны тагын алга атлатты. Бер минуттан ул Гөлсинә яши торган йортка барып житте. Тагын да өшәнгән, тагын да мескенләнгән йортның урам якка караган тәрәзәләренең икесендә ут бар иде. Тыгыз томаланган пәрдәдә кемнеңдер шәүләсе дә уйнап алды.

Ишек бикле түгел иде. Ул тимер тоткага ябышып чак кына тукталып торды, күңеленең түрендә икеләнүле катыш борчылу, борчылуга өстәп шик килде: гомерен ана багышлаган, яшьлеген, сафлыгын ана биргән хатынның ике елдан соң, инде онытылып барырга вакыт җиткәндә ишеген кагып, хатирәләрне янартып ни алып килә ул?.. Ничек каршылар аны Гөлсинә?..

Кызганычка каршы, Гөлсинә өйдә булмады, ул әлерәк кенә мунчага киткән икән. Әбкәсе—Мәрфуга карчык, танырга теләп Асафның йөзенә якынаеп кына күзләрен тырыштырып карап таныгач, таныганын сиздермәде, салкынча, әдәп белән генә:

—Уз, кунак. Көтәсеңме, китәсеңме?—дип сорады.

Мондый турылыкны әллә кайчан оныткан министр бераз дәшмичә утырды да:

—Көтим инде,—дип сүз кузгатты.

Карчык ир-атсыз йортның ятимлеген, кызганычлыгын, мунчалары юклыгын, авылда кеше калмавын, Гөлсинәне район үзәгенә чакыруларын беркемгә дә карамыйча гына, берәүгә дә адресламыйча гына тешсез уртларын чапылдата-чапылдата сөйләп бирде. «Район үзәгенә чакырдылар», дигәч, ак төшкән сул күзен дә тутырып кунакка карады, тел төбендә нидер ятканлыгын сиздерде.

Өстәлдән ерак та түгел урындыктагы электр самоварына су тутырып куйган иде, кунакның тиз генә чыгып китәргә җыенмавын чамалап, ул электр җәпләкәсен куш тишеккә тыкты. Ул Асаф Сәхиповичны күргәч үк таныды, сөенмәде, эченнән генә: «тагын каян килеп чыкты инде карачкы!» дип уйлады. Асаф Сәхиповичның күнелендә ниндидер җылылык уянса да карчык ачылып китмәде...

Көтеп утыра торгач анын килеп кергәндәге кыюлыгы кимеде, карчыкның сүзсез генә табын хәстәрләп йөрүе, самоварның гөрелдәп кайнап чыгуы, анын инде шактыйдан бирле утыруын күрсәтә иде.

Гөлсинә соң гына кайтты, Асаф Сәхиповичны күргәч гаҗәпләнмәде, куе сызылган кашлары гына чак кына өскә күтәрелеп куйды, ул кунак белән ике куллап күреште, кече якка кереп әбкәсе белән пышылдашып нидер сөйләшеп алды, моннан ары Мәрфуга карчык бу якка чыкмады. Көттереп кенә, кече якта чәчен аралап тараган, өйчә җыйнак кына зәңгәрсу күлмәк кигән Гөлсинә килеп чыкты, бу як хуш ис белән тулды. Гөлсинәнең яңаклары алсуланып яна, иреннәре тулышып ниндидер бик мөһим хәбәр китергән шикелле, бер-берсенә аерылмаска ябышканнар иде. Гөлсинә каш астыннан бер-ике тапкыр карап алды да сүзсез генә чәй ясарга тотынды.

—Нихәлләр соң, Гөлсинә?..

—Күргәнегезчә. Үзең ни хәлләрдә, Асаф?

—Картаябыз. Менә алтмышка барып житәргә исәп.

—Күптән күренгәнең юк.

—Эш күплектән гаҗизмен...

Ул, хатынына рапорт биргән сыман, кыска-кыска гына җансыз җөмләләр белән эш күплегеннән, заманның катлаулы булуыннан зарланып алды. Сүз ялганмады диярлек, Гөлсинә элекке кебек күтәрелеп кабынмады, чәйне суыта-суыта, теләр-теләмәс кенә эчтеләр. Чәй урынын аннан-моннан җыештырып, табынны шакмаклы ашъяпкыч белән япканнан соң, Гөлсинә иңнестенә яулыгын салды. Асаф Сәхиповичка да кузгалырга бик вакыт иде. Чыктылар.

Болытлар тагын да аска салынганнар ахрысы, төн кап-караңгы иде. Алар, калтырап торган баскычтан төшмичә, ишек борысының ике ягына икесе сөялделәр.

—Синең бездә икәнлегеңне кергәнче үк белдем,—диде Гөлсинә.

—Ничек белдең?

—Әнә тегендә, ындыр башында машина күзе яктырып алды.

Асаф Сәхипович башта Тәлгатьне ачуланырга уйлаган иде, эченнән генә сокланды: «Төн караңгы, сукмак чалыш-молыш», килеп житеп дөрес эшләгән дип шоферның зирәклегенә сокланды...

Ул сул кулы белән Гөлсинәне кочакларга теләде, тик хатын беркем дә үпкәләмәслек итеп кенә, анын кулын җайлап кына кире этәрде.

—Кирәкми, Асаф!

—Мин сине сагындым, Гөлсинә.

—Болар бит сүзләр... Сүзләр генә! Җаваплы урында утырган кешеләр, җитәкчеләр сүзләрнең кадерен югалталар, алар сүзнең чынлыгын да, анын

эченәниләр сыйганны да белмиләр... «Сагындым» дигән сүзнең ни аңлатканын беләсеңмени инде син?

—Ә син?

—Мин белү генә түгел, елдан-ел ачыграк, татлырак итеп тоям.

—Ничек?!

«Тыңлап тормасыннар», дигән кебек Гөлсинә караңгы ишеккә карап алды, Асафны култыклап баскычтан төште. «Кая алып бара икән инде мине?» дип уйлады кунак өметләнеп. Урамга чыккач Гөлсинә нәкъ баягы кебек итеп, Асафны бер якка бастырып, үзе икенче якка сөялеп калды.

—Хатын-кызның өметләнә торган чагы чикле... Мин сине гомерем буе яраттым, беләсең. Тугры булдым, ни көтсәң шуны алдың. Бер чакта да син минеке булырсың, кавышырбыз дип уйламадым, икеләнмәдем, газапланып яшәмәдем... Менә хәзер иллегә житеп килгәндә, мин яшьлегемне сагынам!..Нинди бәхетле булганмын мин! Азга да куана белгәнмен, бер күрешү бәхете еллар дәвамында мине канатландырып яшәткән... Тик яшьлек тә, мин сөйгән кеше дә инде артта, еракта калган. Килгәнсен—исем китмәде, күрештек—шаккатмадым, китәсең—җанымның бер тамыры да борчылмый... Димәк, гомер үткән инде. Киләчәк белән яшәп булмый, ул юк дәрәҗәсендә, ә үткәннәр мәңгегә хәтердә калыр... Син хәзер яңа кеше, Асаф, ят кеше.

—Килдем ич, күрәсең, үзгәрмәгәнмен.

—Сиңа да бу чор җитәр, син дә үткәннәр белән яши башларсың. Әле син хәзер тәхеттә, тәхеттән тирә-як та, үткәннәр дә күренмидер дип беләм.

—Синең хөкем чыгаруыңмы бу миңа?

—Юк,—дип көлемсерәде Гөлсинә.—Бу минем үткәннәрем белән хушлашуым. Кызганыч, аларны бераүгә дә сөйләп калдырып булмый. Синең белән дә уртаклашып булмый аларны.

—Нигә?

—Син минем мәхәббәтемнең бәясен белмәдең, белә дә алмадың... Сагынуларым сагышлы түгел иде минем, ялгызлыгымда да бәхетле идем, андый җаннар да була икән! Ләкин хәзер үтенеп сорыйм: килмә минем янга янадан!.

Әңгәмәнең сәер булуы өстенә уен түгеллеген дә аңлады Асаф Сәхипович, һәм нәрсә әйтергә белмичә аптырап сүздән туктады, әгәр төн чак кына яктырак булса Гөлсинә аның кызарганын күрер иде. Гөлсинә бу очрашуга әзер түгел иде. Ул күптәннән Асафны көтми башлаган иде, сирәк-сирәк кенә Асаф Зәкиевнең, министрның катылыгы, танымаслык үзгәрүе турында хәбәрләр аның сак колагына да килеп ирешкәли иде. Кемнәрдер Казанга бара, нидер ишетә, шул кемнәрдер белән район үзәгендә күрешкәндә, күңелсез хәбәрләр аңа да килеп ирешкәли иде...

Гөлсинә белән басып торып сөйләшмәгәннәренә бик күптән икән инде Асафның, очрашуга ул аны комсызланып караватка өнди торган иде, аңа күп сөйләшеп торырга жай да калдырмый иде... Бүген ул капка баганасына сөялеп шактый басып торды, бер якка да килешә алмадылар: Гөлсинә бүген сынмады, каушамады, үгет-нәсихәтләргә бирешмәде...

Тәлгать бик сирәк кенә кече фонарьларын сирпетеп билге биреп куя иде, шундый мизгелнең берсендә Асаф машинаның кайда туктаганын чамалап алды, мунчадан кайтуын көтеп тә шактый вакыт үткән иде, хәзер Гөлсинәнең хөкемен тынлый-тынлый да күп кенә басып торылды. Басып торып өйрәнмәгән Асаф Сәхипович тез тирәләре авырткаңын сизенеп күңеле белән кабалана башлады. Кайтып житәргә кирәк ич аңа! Иртәгә аңа аерата мөһим, аерата катлаулы эш йөкләнгән! Болай гына, коры сүз белән генә ташлап китәргә дә уңайсыз: инде Гөлсинә белән дә арасы тәмам өзелә икән, кем белән кала бу дөньяда Асаф?! Гөлсинә исенә төшкән минутларда аның күңеленә күптән онытылган җылылык иңә иде ич!..

Шулай да китәргә бик вакыт иде, дегет кебек куерган тома караңгылыктан бер уч нур сузылып чыкты да ялт кына сүнде. Бу Тәлгать билге бирә, ашыктыра!..Кайтып житәргә кирәклеген ул да чамалый!..

Бәлки ул бүген Гөлсинә янына тәнен сагынып түгел, болай гына, нидер сизенеп килгәндер?..

Машинаның арткы утыргычына кереп таралып утыргач та ул тиз генә исен җыеп сүз әйтә алмады, бераз ял иткәч иелеп чалбар балакларын капшап карады, шуннан соң гына:

—Киттек!—дип эндәште.

Юлны зарыккан машина Тәлгатьнең тәкатьсез боерыгына буйсынып алга ыргылды, фаралардан кабаланып чыккан ут көлтәләре юлны, юлның ике ягына салынган кап-кара агачларны яктырталар, тар, урман юлын капшап табып яңадан-яңа сурәтләр шәйләтеп алга агыла торалар.

Урман чыккач та сулда кечкенә генә авыл булырга тиеш. Асаф тырышып-тырышып караса да авыл утларын эзләп таба алмады. Сәгатенә карарга теләгән иде, карамады, барыбер хәзер һәммәсе дә Тәлгать кулында. Асаф белде ни вакытның күпме икәнен, белмәде ни—бернәрсә дә үзгәрмәячәк. Ул машинада йөреп гадәтләнгән формасына кайтты, сул кулын утыргыч өстенә сузды да, эшләпәсен янына куеп беләгенә ятты, йокымсырады. Йокы белән өн арасында ул Гөлсинә турында уйлады. Нишләргә? Ничек аның язмышын үзгәртергә мөмкин? Япа-ялгызы, гомере бушка үткән, ә ул ник бер сүз белән аны гаепләсен дә, күз карашы белән әрләсен... Нинди ипле аның фикерләре, сүзләре йомшак, кулларыннан бигрәк сүзләре иркәлиләр... Әгәр аны Казанга чакырып алсаң? Бер, яисә ике елда квартир мәсьәләсен дә хәл итәргә булыр иде. Ялгыз хатынга күпме кирәк?.. Бер бүлмә бик җиткән... Һәм ул кемнәр аша, кемнәр ярдәмендә, ничек итеп бер бүлмәле квартир алу турында уйлый башлады. Моннан ике-өч ел элек кенә булса... Ул чагында бер түгел, өч бүлмәлесен алу да җиңел иде, ә хәзер... Шәфыйковны урыныннан алдылар. Никитинны утыртып ук куйдылар. Нинди ышанычлы, туры егетләр иде! Ярты сүз җитә иде аларга, ярты сүз! «Асаф Сәхипович!» дип килеп җитәләр иде... «Асаф Сәхипович та Асаф Сәхипович!»..Нигә Гөлсинә турында бүтәнчәрәк, менә бүгенге кебек итеп уйламаган ул моңарчы?! Ялгыз хатынны тинтерәтеп, интектереп, гомере буена ялгызлыкта тотты... Әнкәсе белән икесенә бер бүлмәле квартир да бик җиткән иде ләбаса... Дөресен әйткәндә, Гөлсинә аның иң соңгы, иң актыккы мәхәббәте ләбаса! Дөрес, яшьрәк илгәзәк хатыннар Асаф Сәхиповичны игътибарсыз калдырмыйлар, сүз белән дә, күз белән дә аңа ярарга тырышалар, аулак мизгелләрдә елышалар да. Ләкин Асаф Сәхипович җуләр түгел, хатын-кызларның аңа түгел, дәрәҗәсенә тартылганын ул бик яхшы аңлый. Министр кирәк аларга, министр сөяркәсе булу кирәк, ахирәтләре алдында «менә мин аның белән!..» дип булганы-булмаганын болгатып мактанырга кирәк...

Ә Гөлсинә...

Тулып-тулышып, тәмле исләре белән җанны котыртып әнә генә басып тора, янәшәдә, капка баганасында...

Ул уянып китте. Машина туктаган, ишек ачык һәм Тәлгать каядыр киткән иде. Ул ашыгып кына машинадан чыкты, күзгә төртсәң дә күренмәслек караңгылыкта юлдан алгарак киткән Тәлгатьне шәйләде.

—Ни булды?—дип сорады ул кырыс кына һәм үз кырыслыгыннан үзе читенсенеп китте, Гөлсинә турында уйлап килә-килә күнеле нечкәргән иде Асаф Сәхиповичның.

—Чама белән күпергә җитәргә тиеш идек, Асаф Сәхипович,—диде борчылулы тавыш белән Тәлгать.—Юк та юк... Әллә борылышны үтеп киткәнбез инде.

—Синең ялгышканың юк иде,—диде ул мөмкин кадәр ягымлы булырга тырышып.

—Ашыкканда адашырсың да!—дип куйды Тәлгать һаман як-ягына каранып.

Иренеп кенә кайдадыр еракта күк гөрселдәде, офыкны иңләп, болытларны дәһшәтле төсләргә манып яшен уйнады. Асаф Сәхипович борчылуын, күкрәгенә тула башлаган салкынны Тәлгатькә сиздермәскә тырышты, хәзер аны талкымаска гына кирәк, егет сыналган, тәҗрибәле, бер-бер әмәлен табар.

—Бераз барып карыйк әле,—диде Тәлгать ишекне нык кына ябып. Асаф Сәхипович күнегелгән позасын алса да йокымсырый алмады, ул нидер

табарга өметләнгән кебек, күзләрен салкын тәрәзәгә терәп бара башлады. Янгыр тамчылары тәрәзәгә сыланып аны тәмам сукырайттылар.

Ничек күрә алгандыр, бераздан Тәлгать кычкырып җибәрде:

—Дөрес барабыз икән, Асаф Сәхипович! Әнә, әнә!

Берни күрмәсә дә Асаф Тәлгать ишарәләгән сул якка йотылып карады.

—Машиналар бәрелешеп монда биш кеше һәлак булган иде, әнә, шуларга куелган ташны үттек...

Кемнендер вакытсыз әҗәле дә кайчагында ярдәмгә килә бит дигән сәер уй Асафның башына килде. Ул:

—Кайтып житәбезме? Өлгерәбезме?—дип сорады.

—Аптекадагы кебек булыр, Асаф Сәхипович,—диде Тәлгать күңеллеләнеп. Ул да якшәмбе көнне, хуҗасын тиешле урыннарга илтеп кайтканнан соң, хатыны белән бажасына кунакка кайтырга планлаштырып, сөйләшеп, килешеп килгән иде. Сонга калу аның өчен дә файдага түгел түгелен, ләкин нишләмәк кирәк, «убыр упкан табылмас—пәри суккан сау булмас»,—дигәннәр ич өлкәннәр. Нәрсә упканны һич аңларлык түгел иде бу очракта. Бажасы өч тапкыр чакырып, Асаф Сәхипович аркасында өчесендә дә бара алмадылар.

—Тиздән асфальтка чыгабыз,—диде ул, машинасы гадәттән тыш сикереп куеп, Асаф Сәхипович башы белән түбәгә бәрелеп куйганнан соң...

Асаф Сәхипович бер халәттән икенче халәткә жинел күчәргә гадәтләнгән иде. Житәкче эштә озак эшләгән кешеләр шуңа гадәтләнәләр, характерлары тормыш законнарына яраклаша. Әгәр Асаф Сәхипович үзен өлкә комитетына, Министрлар Советына яки Верховный Советка чакырып күпме шелтә ишеткәнен санаса... Дөрес, макталган чаклары да була, мәгәр, житәкче кешегә шелтә күбрәк эләгә. Бигрәк тә соңгы айларда... Аннан югарырак житәкчеләр дә яна заман таләпләренә яраклашырга өлгерә алмыйлар, гомер буе килгән законнарны бозу, бигрәк тә алыштырып яңаларын эзләп табу кыен, житәкчеләр эш күрсәтер өчен үзләренә буйсынганнарны жәфалап тәм табалар. Алар эзләнә, эзләнгән саен түбәнге баскычтагыларга кыенгарак килә. Житәкчеләр юл күрсәтергә тиеш, ә алар үзләре дә ул юлны белмиләр... Әнә Тәлгать белә! Мәетләр өстенә куелган таш та аның өчен маяк!

Янгыр сизелерлек көчәйде, тәгәрмәчләр астыннан су чәчрәп-чәчрәп чыкты, еракта яшен уйнады. «Августта да яшен яшьни!» дип уйлады Асаф һәм үзенә ике елдан алтмыш туласын уйлады...

Фикере тагын Гөлсинәгә әйләнеп кайтты...

Ява икән, шәп... Машина эзләрен юып бетерер, аның бу төндә бу районга кергәнен дә, Гөлсинә янына кагылуын да беркем белергә тиеш түгел. Серне янгыр ярдәмендә күмеп тә калдырырга теләде Асаф.

Яхшылыкка булдымы аның Гөлсинәне күреп чыгуы, ямангамы?..

Илле сигез яшьтә үзең кылган гамәлләрнең мәгънәсенә тиз генә дөрес бәя бирү кыен, күпмедер вакыт узарга тиеш, шул арада гына, алдагы көннәрне кушып кына адымнарның турылыгын яки ялгышлыгын дөрес бәяләп була... Ашыкмаска кирәк...

Шулай да, нидер эшләргә, Гөлсинәгә ярдәм итәргә иде...

Ничек итеп?

Ул тагын йокымсырады. Йокымсырады һәм дерт итеп уянып китте, машина каядыр стенага бәрелгән кебек кинәт туктады. Асаф берни аңламыйча башта як-ягына һәм алга карады. Тәлгать тә алга карап, ниндидер сәер позада, ике кулы белән чытырдап ябышып, алга иелә төшеп текәлгән иде. Мотор тавышсыз диярлек эшли, димәк, машина төзек... Асаф Сәхипович шунда гына үзләренең күпергә килеп кергәнен һәм күпер өстендә фаралар яктысында дүрт кешенең шәүләсен күреп алды. Шәүләләр ут яктысыннан сакланып куллары белән күзләрен каплаганнар да иләп кенә, бер сафка тезелеп машинага таба киләләр.

Тәлгать күзе белән нидер эзләгән төсле каранып Асаф Сәхиповичка дәште:

—Исерекләр ахрысы...

Күпер... Бу күпер таныш Асаф Сәхиповичка... Совмин председателенең урынбасары Котин белән бергәләп ачканнар иде бу күперне. Моннан олы юлга ерак та түгел инде.

—Нишлибез, Асаф Сәхипович?

—Тыңлап карыйк, нигә туктатканнар алар безне.

—Әллә борылабызмы?..

—Кая борыласың ди монда? Дамба читендә бетон баганалар...

—Әллә араларына бәреп керикме?.. Яхшылыкка килмиләр болар!..

Яңгыр сүрелә төшкән, алай да аның сыек пәрдәсе якынлашып килгән гәүдәләрне озынайтып күрсәтә, егетләр шуны аңлаган кебек, тәэсир көчен арттырырга, машинадагыларны куркытырга теләп кулларын як-якка чайкыйлар, чайкалалар һәм каршыга дүрт җил тегермәне килгән кебек бер манзара хасил итәләр иде.

Тәлгать кулына монтировка тотты һәм борылмыйча гына:

—Исерекләр болар... Әллә чыгып урабызмы? Мин өчесен алам,—диде.

Асаф Сәхиповичның мие яңгырап китте, уйлар язгы боз кебек бер-берсен кысрыклап тоташ чылбыр булып актылар. Юлда скандал? Дөрес, Тәлгать кинәт һөҗүм иткәндә өч егетне дә юлдан алып ыргытачак, бокс буенча беренче разряд. Асаф Сәхипович та ахыр чиктә бер егет белән бер вакытка кадәр алыша алачак, искәрмәстән һөҗүм иткәндә... Егетләрне алып ыргыталар да машинага юл ачалар... Ыргыта алмасалар, егетләрнең берсе машина астына килеп керсә? Шау-шуы бөтен дөньяга таралачак. Асаф Сәхиповичка болай да чокыр казучылар күп. Нишләп бу юлга килеп кергән ул? Иң хәтәре әнә шул инде! Нишләп моннан кайта ул? Уравычтан юл туры, дип шаяртыр иде, уравычы ике йөз чакрым...

Озак уйлап торырга да, икеләнергә дә ара юк иде, ул машина ишеген ачты да йомшак, ләкин шактый кырыс кына дәште:

—Нигә юлны бүләсез, егетләр?!

Егетләрнең берсе (хәзер аларның чыннан да унсигез-егерме яшьлек егетләр икәне) ап-ачык күренә иде, алгарак чыкты, машинаның ачык ишегенә иелде, Асаф Сәхиповичның борынына сасы перегар исе килеп бөркелде.

—Бүләбез икән, кирәк,—диде ул оятсызларча хихылдап.

—Әй, начальник,—диде икенче егет аның янына килеп басып. Егетләрнең икесе чайкала-чайкала машина алдына килеп басты. Берсе капот өстенә менеп утырырга теләде, таеп китеп егылды, икенчесе кул биреп ана торырга булышты, әмма алар урыннарыннан китмәделәр.

—Нәрсә кирәк сезгә?

—Безгәме?—Икенче кул хәрәкәте белән машина ишегенә иелгән егетне читкәрәк тибәрде һәм якынрак килде.—Сез безне Сәлмән авылына илтеп куясыз!

Егетләрнең соравын ишеткәч Асаф әз генә тынычланган кебек булды, вакытны сузып җавап әзерләр өчен:

—Нинди Сәлмән ул тагын?—дип сорады.

—Моннан утыз-кырык чакрымда,—диде Тәлгать, тимерне кулыннан ычкындырып, тирләгән учын чүпрәккә сөртә-сөртә.

—Кая, кырык булсын? Күп булса—утыз биш!—диде егет.

—Булмый, егетләр, без болай да соңга калабыз.

—Бу без монда соңга калабыз! Минем чибәрем яши анда. Менә егетләрне күрсәтергә алып барам.

—Бүтән вакытта барырсыз, егетләр, тоткарламагыз безне.

Егет тавышына сүрән катылык керде, ул, машинага керергә омтылып, Асафның ишеккә куйган кулын читкә кагып җибәрде.

—Бүген! Һәм хәзер үк! Син, начальник, бәхәсләшеп торма! Барыбер илтәсен. Без шулай әйттек и все! Сәлмән авылында чибәрем барлыгын менә болар күрергә тиеш...

—Егетләр,—дип сүз катты Тәлгать үз урыныннан.—Шау-шу кубарып торуның файдасы юк. Без командировкадан кайтып киләбез...

Ул арада капотка менәргә маташкан егет пычрак кулларын юл читеннән умырып алган үләнгә сөртә-сөртә килеп җитте дә, егетләрнең икесен ике якка аерып Асафның алдына ауды. Асаф җирәнеп артка чигенгән арада эчкә кереп тә утырды. Аның бөтен җиреннән, чыланган курткасыннан,

чалбарларыннан пычрак су ага башлады, су тиз арада Асаф янына барып та җитте. Ул тагын да эчкәрәк тартылды һәм егетләрнең икенчесе дә машина эченә төшеп сенде. Алдагы егет иптәшләренең берәм-берәм кереп утыруларын күреп монда таба килә башлады, шул минутта Тәлгать газ бирде, машинада икәү, тегеләр хәзер чәчелеп калачак, бераз киткәч боларын да дөмбәсләп төшереп калдырып булыр, ике кеше дүртәү түгел инде. Ул арада машинада утырганнарның берсе елтыр пычагын чыгарды һәм Асафның корсагына китереп терәде.

—Тукта, Тәлгать, ашыкма,—диде Асаф саңгырау гына.

Эш уеннан узган, хәзер сабырлыкны җыеп, бөтен акылны җыеп, эчәэчә күпчеп беткән егетләр белән арадашлык табасы калган иде.

—Нәрсәдән бәхәсләштегез соң сез?—дип сорады Асаф.

—Анысы синең эш түгел.

—Син безне илтеп ташла инде!

—Андагы юлларны беләм,—диде Тәлгать.—Лай да пычрак, илтеп кайтырга ике сәгать вакыт кирәк булачак.

—Шым бул, шеф!—диде егетләрнең берсе, тимер йодырыгы белән машинаның өстен төеп.—Шым булмасаң, күрерсең күрмәгәнеңне.

Тәлгатьнең егетлегенә көч килде, ул хуҗасына ярым борылып:

—Төрмә сагынганнар алар, баланда сагынганнар!—дип кычкырды.

Бәхәсләшеп ни файда, Асаф Сәхипович машинаның икенче як ишеген ачып җиргә басты һәм үз янәшәсенә кереп сеңгән пычрак киемле егетне чакырды:

—Чык әле монда!

Егетне бераз читкәрәк алып китте һәм:

—Менә нәрсә, егет, күрәм, сезгә җитеп бетмәгән. Болай итик, мин сезгә хәзер ике ярты бирәм, ә сез безне үткәреп җибәрәсез. Ахыры сезнең өчен күңелле булмас, тоткарламагыз!..

Егетнең авызы ерылды:

—Яртыларыңны алабыз, безнең авыл җирендә хәзер аны таба алмассың, мәгәр үткәреп җибәрмибез. Бәхәсләшеп торганчы кузгалсак, ярты юлны үтә идек инде.

Асаф үзенең хата җибәргәнен аңлады, аракы турында сүз кузгатырга кирәкми иде, егетләрнең эчемлек сүзен ишеткәч ашказаннары котырынып өстәмә сорый башлады. Шешәләрнең икесен түгел, өчесен дә чыгарырга туры килде. Асаф шунда күпер астында көтеп калды, Тәлгать эченнән генә каргана-каргана, көч-хәл белән машинасын борып егетләрне төяп утыртып алар кушкан якка китте. Егетләр машинага кереп тулдылар да шаркылдап көлә-көлә бер-берсенең җилкәсен тимер йодрыклары белән төйделәр. Асаф сөзәк җирдән тая-тая аска төште, күпер астына керде. Монда коры, әмма үтәли җил йөри иде.

Асафның мондый хәлдә калганы бик күптәннән юк иде, ул үзен дөньяның кендеге үк дип санамаса да, «тигез җирдә бер түмгәк, тибеп аудара алмассын» дигән ышаныч белән яши иде... Әле ничә сәгать элек кенә ул Казаннан килгән рәсми вәкил, министр, тантана үзәгендә күкрәк киереп басып тора иде. Әйтерсең лә, алдынгылыкка чыккан район хезмәтчәннәренә иң зур өлешне ул үзе керткән!.. Дөрес, байрак алырга җыелган халык элекке еллардагы кебек тоташ алкышларга күмеп ташламады, арада күпләрнең кул чапмауларын, президиумда утырганнар белән күзләре очрашса, түбән карауларын, кемнендер һич читенсенмичә залдан чыгып ук китүләрен күрде, ләкин мондый вак-төякләр генә Асафның кәефен кыра алмадылар. Ул дөньяны учында тота торган төркем вәкиле, район хуҗалары аның һәр сүзен йотып, сеңдереп кенә баралар, һәр күз карашыннан вәкилгә лаек тирән мәгънә, аның үзен тотышыннан күркәмлек сыйфатлары эзлиләр иде...

Нинди көнгә төште?.. Хатын-кыз аркасында гынамы бу? Гөлсинә хакына эшләндеме бу тоташ ялгышлар?.. Хатын-кыз теләсә Казанда да таба ала иде ич Асаф Сәхипович! Нигә ашкынды ул? Нигә бүген, илле сигез яше тулып ашканда Гөлсинәне күрергә теләде. Аның тәнен зарыкты дисәң,

андый уй Асафның уенда да булмады. Хатынның каен себеркесе исе китеп тә бетмәгән кайнар кулларына кагылгач кына беразга нәфесе уянды да, тынды. Ни эзләде ул күптәннән күрешмәгән, хат алышмаган, бер-берсенә ят булып барган хатыннан? Нинди уй китерде аны монда бүген?! Гөлсинәгә булган игътибарсызлыгымы? Кеше алтмышка җиткәндә үткәннәргә ешрак кайта, кылган яхшылыклары турында түгел, кылган гөнаһлары, ялгышлары турында уйлый дип ишеткәне бар иде. Якын дусты, алтмыш бергә чыккач та бер көндә йөрәге ярылып үлгән Локман Шакиров, алтмыш тулгач: «Алтмышка җиткән кеше бөтән измерениеләрдә яши башлый, аны аңлау читен, аңлату тагын да авыррак», дип көлгән иде. Нинди измерениедә булды икән Локман?

Әллә әнә шул, алтмышка якынаю авырлыгы китердеме аны Гөлсинә янына? Җанына җылылык эзләп килдеме?.. Гөлсинә дә аны күргәч сәерсенеп, югалып һәм юашланып калды түгелме?.. Димәк, ул да аның юклыгына ризалашкан, аның юклыгына күнегә башлаган булган да Асаф хәбәр итмичә-нитмичә карурманнан чыккан качкын кебек аның төнге ишеген каккач сискәнеп китте. Ул Асафның үтә куркак икәнен белә иде. Асаф аның белән очрашкан чакларда гел бер сүзне кабатлый иде: «Сакла син мине, Гөлсинә, әгәр син безнең дуслыкның дәвамлы булуын теләсәң, сакла!» Саклады Гөлсинә, гайбәтен таратмады, чакырган җиренә кушканнан элек килеп аны көтте... Беркемгә күз салмады, беркемгә! Хатынына ышанмый иде Асаф Сәхипович, Гөлсинәсенә ышана иде...

Үзенең ник килгәнен ачыклап бетермәгән Асаф Гөлсинәнең ни уйлап калганын белми дә белми иде... Менә ул да хәзер йокыга китә алмыйча кинәт ябырылган борчулар арасында тыршылдап, җаны белән тәне талашканын тыңлап ятадыр...

«Ни тартып кайтарды аны бүген шушы якларга? Куркак, куркак... Иртәгә иртүк ул Казанда булырга тиеш иде, аның бик җаваплы, авыр бурычны төгәл башкарасы бар иде. Шуны ап-ачык аңлаган хәлдә ул тәвәккәлләп шушы юлга төште... Бәхетсез юлга!»—дип эчтән сүгенде Асаф Сәхипович. «Бәрәкәтсез юлга!» Үзен-үзе тынычландырырга да тырышып карады ул. Мәскәү кунагын кабул итү эше аның белән берничә мәртәбәләр сыналган дуслары катнашында башкарылачак бит. Ничек алар аны бу очракта йолып кала алмаслар икән?..

Яңгыр йомшады, әмма җил көчәйде, ул күпер баганалары арасыннан сызгырып керде дә Асафны төрле яктан тентеп-капшап сызгырды, аның тәнендәге соңгы җылыны умырып алып чыгып китте. Кайчандыр көймәләр йөргән инеш, хәзер юаш кына сызык булып, тонык ялтырап һаман ага, яңгыр да аңа көч өсти алмаган, әллә югары якта яңгырлар бөтенләй юкмы?..

Ул машинасын талап алган егетләр турында да, Тәлгатьнең ризасызлыгы хакында да уйламады, аның күз алдында корсагына терәлгән үткер, озын пычак булды. Әгәр аңа кадаган булсалар?.. Яраласалар? Яки үтерсәләр? Тәлгать ни дип аңлатыр иде икән? Гомумән, Тәлгать белән бик яхшылап сөйләшәсе булыр. Хәзер егетләргә Асафның кемлеген ычкындырмаса яратырсың. Егетләр машина номерына күз төшермәсләр, күзләре бик тонган, юлда эчеп барсалар Тәлгатькә дә әлләни сүз куша алмаганнардыр...

Аңа бүген ипләп кенә, тавышсыз-тынсыз гына бу районнан чыгып ычкынырга кирәк иде.

Тәлгать шактый озак торып, машинасын пычракка манчып, әмма зарсызсүзсез әйләнеп кайтты. Машинаны бу хәлдә асфальтка алып чыгарлык түгел иде, мыштым елгадан кара су ташып машинаны ныклап юдылар...

* * *

—Мина шалтыраттылармы?—диде ул керә-керешкә.

Хатын аңа җентекләп карады, җавап бирергә ашыкмады, плащын салдырып алып чөйгә элде. Эшләпәсенә кунган пычракларны күреп башын чайкады.

—Шалтыраттылар. Үзе ике тапкыр сорады.

Асаф Сәхиповичның тәне эсселе-суыклы булып китте.

—Үзе-е?

Хәзер ахыры хәерле булсын дип теләргә генә кала. Хатыны һаман аңа төпченеп карап тора иде.

—Нигә алай озакладыгыз? Әти янына кереп чыктыңмы әллә?

—Анда да кагылдым,—диде Асаф таркау гына.

—Ни хәлдә соң?

—Ни хәлдә дип... Чирләштерә икән. Районнан врач чакырттым, тоткарландым. Кайтышлый яңгырга эләктек, машина батып, аны трактор белән тартып чыгарып...

Асаф Сәхипович җавапларны хатынына бирсә дә асылда күңеле аша хуҗалар белән сөйләшә, алар алдында аклана иде. Җавап бик житди, төпле һәм ялгышсыз булырга тиеш. Әти—козырь! Хуҗа кеше ата-анасына үтә игътибарлы булган, семьячыл кеше, мәсьәлә шактый катлаулы булса да бу очракта Асаф Сәхиповичны кичерер, аңа кинә сакламас... Димәк, атасы янына кагылган, аны чирләп ятканда ташлап китә алмаган, шулай, шулай... Ул тиз генә душта юынып чыкты да, көзге каршысына басып кырынырга керешә.

—Тагын берәү шалтыратты...

—Кем ул?

—Авылдашын. Җәгүр дидеме...

—Нинди Җәгүр?

Хатынның сүзе аңа бер дә ошамады. «Үзе» эзләде дигәнгә караганда да бу сүз аны тирәнрәк борчыды, чөнки хәзер туган яктан килгән һәр кеше аның оста корылган планнарын сүтеп ташлау ихтималы бар иде.

Кырынып бетергәч, исе китмәгән кыяфәт белән генә:

—Кайда тукталган ул?

—Гостиницада бугай... Әллә түгелме? Кирәк дип санамагач мин төпченеп тормадым. Җәгүр икәнен дә, авылдашы икәнен дә ул үзе әйтте.

Бу зур бәла, җайсызлык иде... Асаф Сәхипович «авылда булдым», дип торганда гына Җәгүр килеп керсә?! Дөрес, ул бәлки авылдан күптән чыккандыр... Алай да, авыл белән арасы бөтенләйгә өзелгән дип санаганга, Асаф Сәхипович ул яктан беркемне көтми, күрергә, күрешергә теләми иде...

Нигә төпченә бүген Суфия? Нигә: "Җәгүрне оныттыңмыни?" дип сорый.

Онытмады Җәгүрне Асаф Сәхипович, күптән онытылган дип уйланган кешеләр, әле шушы соңгы ике елда гына янадан күңелгә кайтып, үзләре белән ниндидер канәгатьсезлек, борчылу алып килделәр.

Җәгүр шуларның берсе иде...

* * *

Үз улы Эдуардка карый да яшьлеге исенә төшә. Яшьлегенә ияреп бик күп кирәксез вакыйгалар: авыл, сугыш еллары, сугыштан соңгы авыр вакытлар, Зәйдә яшәгән чаклар искә төшә. Нигә ул күңелсез, кадерсез чаклар күңелдә саклана икән? Кемгә кирәк? Соңгы ике елда Асафның хәтере саега башлады. Кешенең ми күзәнәкләре санаулы гына икәнен, шул күзәнәкләргә бик күп чүп-чар кунып мәңгелеккә катып калганнын аңлый Асаф, шуңа күрә эченнән генә зарланып ала: «Теге юк-барлар күзәнәкләрдән ычкынып, ачылып калсалар, күп нәрсәләрдән бушаныр идем», дип куя..

Гөлсинә, аның фатир хуҗасы Мәрфуга апа тынган, ипләнгән җанын бер актарып ташласалар «Җәгүр» исеме аңа өстәмә гамь китерде. Хафа уты камап алды Асафны.

Төп борчылу Җәгүрнең авылыннан килүендә генә түгел, эш шунда иде ки, Акъюл авылында Асафның әтисе яши иде. Моннан биш ел элек күкрәк бакасыннан әнкәсе вафат булгач Асаф авылга кайтып әнкәсен җирләде дә әтисен үз янына чакырды. Күңеленнән генә «килмәсә ярар иде!» дигән кебегрәк итеп чакырды. Аралары өзелгәнгә байтак иде инде.Сәхип абый, әле үз көчендә йөреп торган кеше, улының күзенә карамаска тырышып кына:

—Ярар, улым, рәхмәт. Карт агачны күчереп утыртыр өчен әлләничаклы тамырын кузгатырга кирәк. Аннан соң тернәкләнеп китәме, янарамы ул,

белүе кыен. Әз-мәз яшәп карыйм әле. Инде һич торырлык хәлем калмаса карап карармын,—диде.

Аның килергә исәбе юклыгын белгәч Асаф ныграк кыстап та карады. Карт, йомшак кына рәхмәт әйтеп, карышты, авылда калды...

Хат язышмыйлар, авылда туган-тумача юк, агай-энеләре дә ялгыз калган картка игътибарны киметтеләр. «Әти янында булдым, кагылып чыктым, хасталанып тора»,—диде Асаф Суфияга...

Асаф очны-очка ялгарга тырышып караса да ялганмады, нидер чуалды, буталды, һәм чуалчык мизгелдә арага Жәгүр килеп керсә... Ни калган инде аңа? Өй телефонын каян алган диген? Хәер, Сәхип карт биргәндер, Жәгүрнең Казанга барасын ишеткәч «белеш хәлләрен, нишләп яталар икән?» дигәндер...

Алай да сак булырга кирәк, өйдән чыгып китәргә ярамый, Суфияга туры килеп сирәк тешләре арасыннан кирәкмәгәнне ычкындырмасын.

Асаф кабинетына кереп китап караштырган булды, телевизор тоташтырды, уйлары әйләнеп-тулганып әзгә генә китеп тордылар да тагын Гөлсинәгә, авылларга, юлларга, Жәгүргә әйләнеп кайттылар. Ул биш бүлмәнең бишесе дә яңгырарлык итеп төчкереп җибәрде. Бер төчкерде, ике, төчкерүе хәтәр аның, тыймыйча төчкереп җибәрсә түшәмгә эленгән люстралар зыңлап куя. Кухня ягында нидер әвәләп маташкан Суфия ишекне ачып карады.

—Салкын тидергәнсең син, Асаф,—диде.

Асаф эндәшмәде. Хатыны ишектән югалгач, шкафын ачып аннан кыйммәтле француз коньягы тартып чыгарды һәм бәллүр чәркәнең күзеннән тутырып эчеп җибәрде. Эчте, тагын Жәгүр искә төште...

Асаф әле беркем дә түгел иде, өйләнмәгән, яңа-яңа тәпи басарга маташкан чагы, Яңа Бистәдә Вилдан абзыйларда фатирда яшәп ята, акчасын ким түлисе дип мехкомбинатның сасысын исни. Ашказаны авырып Жәгүр Казанга килеп төште дә, Асафны эзләп тапты. Асаф үзенең фатирының хөртилегеннән дә, ат җигеп ашханәдә вак-төяк йомыш үтәүче Вилданның хәчтерүш кеше булуыннан да, эш урынының да телгә алып мактанырлыгы юклыгыннан да үтә гарьләнеп Жәгүрне чыраен сытып кына каршылады. Үткән-сүткәнгә аракы куярга ашыкмаган кеше, ичмасам бу ягы шәп булсын дип аракы алып кайтып Жәгүрне түренә утыртты. Асаф ашаганда үтә комагай, бер тотынса ике куллап, ун бармагын ялый-ялый ашый торган иде. Утыралар икәү, өстәлгә шешә куңды, күз туярлык кына ризык килде. Асаф чәркәләргә аракы тутырды да: «Исән булыйк!» дип эчеп куйды. Ә Жәгүр утыра чәркәгә күз дә салмыйча, иплән кенә хәл белешә, тормыш хәлләрен сораша, заманына күрә шактый саллы сораулар да ычкындыра. Кыстый Асаф, «Әйдә эчеп җибәр!» дип уйнаклаган була. Ә Жәгүр ашыкмый, иплән кенә, түрә булып түрдә утыра, өч-дүрт тапкыр кыстагач кына, «Ярый инде, аш булсын, рәхмәт!» дип чәркәне алды да кабаланмыйча уртлап куйды. Үзен шундый ипле, олысымак тота керәшен баласы Жәгүр, Асаф таң калды. Ризыкны да олылап, хөрмәт белән вак кына каба, ашыкмыйча гына чәйни, ара-тирә хуҗага да рәхмәт әйтергә онытмый. Каян килгән аңа шундый итагать? Караңгы авылдан чыккан мокыт ләбаса ул! Очлы-кырлы гына җидене тәмамлап колхозда шомарып кына аз-маз кеше арасына кергән адәм...

Яшьлек дусты турында сызланып уйланды Асаф, ул арада Суфия пәрәмәч пешереп өлгертте, Асафны ашарга чакырды. Суфиясының чакыруыннан канәгатьлек алып, аның янына юнәлүдән элек ул шкафны тагын ачты, рәттән бер-бер артлы ике чәркә коньяк эчте, коньяк кан юллары буйлап китте, хәтерне сүндереп, зиһенне җиңеләйтеп йөри башлады. Ул ашаганда тагын өч-дүрт тапкыр нык кына төчкереп җибәрде. Суфия белән алар мондый вакытта да бик аз сөйләшәләр, аш янында гомумән тып-тын утыралар, иренә ни кирәген Суфия сорамаса да белә, ашау чиратын бозмый. Асаф аштан соң рәхмәт әйтеп тормый, кабинетына уза, шунда өстенә дөя йоныннан тукылган плед ябынып, йомшак диванда чак кына черем итеп ала. Ятыр алдыннан телефонны диванга якынрак китереп куя, уянгач та әүвәл шунда сүз сала: «Шалтырап, ишетмичә йоклап калмадыммы?»

Министрларга ял көннәрендә дә телефоннан тынычлык юк. Бүген телефон үч иткәндәй тып-тын утырды, Җәгүр кичке караңгы төшә башлаганда, Асаф Сәхипович тәмам гаҗиз булганда гына шалтыратты. Җәгүр, гадәтенчә, хәл-әхвәл сорашты, «өйдәгеләр ничек?» дип куйды. Соңыннан гына, Асаф Сәхиповичның коры тавышыннан уйларын сизгән кебек: «Мин монда гостиницага урнаштым. Әллә килеп чыгасыңмы? Сиңа әйтә торган сүзләр бар иде»,—диде.

—Телефонннан гына булмыймы?

Җәгүр тиз генә җавап бирмәде, трубкада нидер озак кына кыштырдады.

—Юк. Син килеп чык әле. Теге чакта, Яңа Бистәдә сыйлаган идең, хәзер минем чират, яртым да бар. Бер сөйләшеп утырыйк әле.

Асаф «нинди сәбәп табып баш тартыйм икән? «—дип газапланып уйлап торган арада трубка тагын җанланды:

—Безгә әбәзәтелне күрешергә кирәк,—диде Җәгүр.

—Өйгә килеп чык,—дип ычкындырды Асаф Сәхипович.

—Юк, өйгә бармыйм. Үзең монда кил, гостиницага...

«Министрга теләсә кем янына, гостиница кебек җирләргә барып йөрергә ярамаганын белмисеңме әллә?»—дип чак ычкындырмады Асаф. Ул арада Җәгүр тагын да кискенрәк тавыш белән:

—Асаф Сәхипович, уйнар өчен чакырмыйм ләбаса... Бер күрешик, гәпләшик... Бәлки берәр хакыйкатькә барып чыгарбыз...

«Әһә, бәла-каза килгән икән егеткә, күптән шуны әйтсәң соң!» дип уйлады Асаф.

—Болай итик алайса. Син хәзер тимер юл вокзалына төш. Яңа бинада билет кассалары янында мине көт. Озакламый мин дә барып җитәрмен.

Тәлгатьне бимазалап тормады Асаф. Электричкага утырып йөрергә ярамаса да (ыбыр-чыбыр халык дәрәҗәне төшерә), Җәгүр дә булгач, болай, кеше рәтеннән генә барырга булды.

Анын җыенганын, плащын иңенә салганын күреп Суфия килеп чыкты.

—Чирле килеш кая җыенасың син? Мин сиңа компресс куярга әзерләнеп йөрим,—диде.

—Җәгүр шалтырата. Аннан болай гына котылып булмас. Дачага алып барыйм да шунда куныйк инде без. Тәҗел генә эш чыкса Тәлгатьне табып җибәрерсен. Инде ашыгыч эш булмаса ул мине алырга кич кенә килер, үзе белә.

Киенеп беткәч кенә, соңгы сәгатьләрдә шактый яраланган күнеленә шик килде, ул Гөлсинә янына барып кайту белән Җәгүрнең килүендә ниндидер бер ялгау күрде. Онытылып беткән кеше тик торганда «бик күрәсе килә!» дип шалтырата икән, юкка түгел. Эзләүчесе Җәгүр генә булса да, эзәрлекләнүчесе Асаф Сәхипович Зәкиев ич анын, министр!

Ул башта Җәгүрне танымады. Картайган, таушалган, элек тә озын муены аркан юанлыгы гына калган, кап-кара яргаланган куллары гел тамырлардан гына тора дип уйларсың. Муены, янаклары чуен кебек кап-кара булса да, өр-яңа күлмәгенең киң камыт булып торган якасыннан ап-ак сөйкемсез муены күренеп-күренеп китә. Кулы буш иде. Җыерчыклар эченә вакытсыз чумган кап-кара күзләре генә элеккедәй елтырап, ягымлы карыйлар. Кайтарылыбрак торган яргаланган иреннәренә китмәскә елмаю кунган. Ул корычтай ике кулы белән Асафның итләч бармакларын эләктереп алмаса, валлаһи, кырыеннан үтеп китәсе икән.

Вагонда кеше әлләни булмаса да алар өч кешелек урынга кысылышып утырдылар, өченче кеше яман таза иде, Асаф Сәхипович та җайлашкач Җәгүргә урын калмады да диярлек. Ул ярым утырып, ярым асылынып, ягымлы күзләре белән яшьтәшенә, авылдашына йотылып карап барды. Сүзләр өзек-өзек иде. Асаф сорады, Җәгүр һәр сүзенә сөенеч өстәп, нигәдер куанып җавап биреп барды.

—Бабай булдыңмы инде?

—Һи, әллә кайчан! Внучканы кияүгә биреп йөри идем дә...

—Үзең ни хәлдә?
—Әйбәт, әйбәт! Тик менә...
—Тынычлыкмы?
—Тәртип, тәртип! Тәртип тә...

Бу сүзләр тоташтыра торган әңгәмә түгел иде. Бер-ике чакрымга Асаф бер сорау биреп куя да, Жәгүрнең ымын, ишарәләрен күрми дә калып тәрәзәгә, тәрәзә артындагы мең тапкыр күренеп калган манзарага карый. Жәгүрнең «Идем дә... «, «тик менә», «тәртип тә» дигән тәмамланып бетмәгән сүзләренә ул бөтенләй дикъкать итмәде...

Поезд гадәттәгедән озаграк барды, Юдинога житәрәк борылышта озак кына туктап торды, аз санлы пассажирлар иренеп кенә төштеләр, тимер юл аша Идел ягына чыга алмыйча байтак кына көтеп тордылар. Алар Асаф Сәхиповичның дачасына күз бәйләнгәндә генә барып элгәштеләр. Кеше аз, күрше-күләндә жан әсәре күренми, гадәттә йөгереп килеп житә торган Валентин да юк, хужаның юклыгын белдереп ачыккан этләре генә һау-һаулап алалар.

—Караңгы димәсәң, бакчаны караштыра тор. Мин капкалап алырга бирәр нәрсә әзерләрмен.

Жәгүр бик теләп риза булды. Бераздан аның бакча буйлап сокланып йөргәне һәм шаккатып тел шартлатканы ишетелә башлады. Чәй кайнап чыгар-чыкмаста Асаф кунакны табынга чакырды, консервалар ачты.

—Ай-һай шәп икән бакчаң, Асаф! Бу кадәр шоннықны үзегез карап бетерәсезме дигәндәй?..

—Төрле чак була.

Асаф табын өстенә күз йөгертеп чыкты да саран елмаеп:

—Бакчада эчемлек юк икән,—дип куйды.

—Нинди эчемлек? Кирәкми! Очрашуны бозмыйк әле... Сүз дә...

Жәгүрнең соңгы ишарәсе дә һавада эленеп калды, куллар ризыкка үрелде, Асаф «кабаланып ашама, ашыкма», дип үз-үзенә беркетсә дә аның көчле, юан бармаклары арасында тавык сөякләре шытыр-шытыр чәрдәкләнделәр.

—Кармак таяклары күрдем, әллә балыкка йөрисең инде?

—Мин шул балык тотканда гына ял итсәм итәм дә!

Форсат чыкканнан файдаланып Асаф үзенең бер дә вакыты юклыгын, көне-төне эштә булуын, ял көннәрендә дә телефонның өзмәс шалтыратылып торуын, Казан белән районнар арасында бер янса, Мәскәү белән Казан арасында икенче януын, эшенең зурлыгын, жаваплылыгын шактый озын итеп сөйләп, аңлатып бирде. Үзенең урынбасарларыннан зарланды, кемнәр-недер исемнәрен атап «эшлексезләр, бушбугазлар, заманны аңламыйлар»,—дип зарланды. «Тинтәк имгәкләрне үзебез үстердек, бездән соң килә торган буын чистый ялкау булып чыкты,»—диде Жәгүр аны кызганып, аның саулыгы өчен борчылып. Быел Болгариягә ялга да бара алмавына исе китеп, «әй-һәй-һәй күрә синең башлар!» дип һаман аңа теләктәшлек күрсәтүен сиздереп башын кагып утырды.

—Ә без... Безнең андый зар-мон юк! Ял дип... авыл эше үзе ял инде ул, авыл жире үзе дача...

Аның күтәренке сүзләре, бер сәгать тә ял күрмәгән куллары, бирчәеп буртайган бармаклары, суырылып кергән корсагы, аркан юанлыгы гына калган муены белән килешеп үк бетмәсә дә Асаф аны-моны әйтеп, жөпләп яки кире кагып тормады, күз ачып-йомганчы салкын тавыкны бөкләп тә куйды. Жәгүр һаман шул икән әле, меже-меже утырды, кашык очына гына эләктереп консервадагы балыкны капты, мактады, тәмләп чәйнәде, онытылып беткәч кенә тагын ризыкка үрелде.

Чәй эчтеләр, шунысы гажәп, озак очрашмый торган кешеләр, гадәттә, бер-берсеннән элеккеге таныш сыйфатларны эзлиләр, хәзерендә үзләренең кем булуларын сөйләп бирәләр дә, якынаерга тырышалар, ә болар, икесе тин сөйләшкән саен бер-берсеннән ерагаерга тырышалар иде. Дөрес, Жәгүр бер тиенгә кирәге булмаган сүзләрне өзеп, әңгәмәне бер юлга алып керергә тырышып карый: үзенең тик кенә йөрмәгәнен, авылда да кырык эш кыры-

лып ятканын, курмы әзерләнмәгән, утын китертелмәгән, ихаталары каралмаган дип нык кына зарланып аласы да килә. Ләкин бу тап-таза, күз кабаклары май басып салынган, корсагы түгәрәкләнеп килә торган, ятсынылган, сәер кешенең бер җай белән генә олысымак кыланып фикерне гел кирәкмәс якка алып керүен сизенеп, сүздә читенсенеп утырды. Бер генә ягы да үзгәрмәгән иде яшьтәшенен—һаман да тамакка таза икән. Һаман да ризыкны авылча ике куллап ала да ботарларга керешә икән.

Шуны сизенепме Асаф кулын чиста ап-ак тастымалга сөртте дә, иренен учы белән сыпырып алды. Бусы да яшьлектән килгән гадәте. Бүтәнчә танырлык та түгел иде Асаф.

—Балыкка да йөрим диген...

Ишек катына чүгәләп тәмәке тартырга керешкән Җәгүр шулай дип куйды.

—Йөргәлим, вакыт житкереп кенә булмый.

—Ә менә минем шушы яшемә җитеп көймәгә утырганым да юк.

—Теләсән, мин сине иртәгә балыкка алып керәм.

Җәгүр тәмәкесен сул учына кысып яшьтәше янына килеп җитте һәм уң кулы белән иненә берне кундырды.

—Чынмы?!

Сак кына кагылса да сизде, Асафнын инбашлары салынмаган, тыгызлап тутырылган кебек нык, көчле иде.

Шулай итеп Асаф яшьлек дустына Иделне дә күрсәтеп мактанырга җай чыгуга куанып ризалаштылар.

Сабан туе жилләре исә башлагач чабышкы атларнын талаклары тавышланып, уртларга тотына. Диндар картлар намаз вакыты җиткәнен уч төпләре кычытудан сизәләр. Балыкка барырга ниятләп яткан ирләр дә шулай, алар керфекләре йомылып, буыннары таралып та өлгерми, дерт итеп уяналар, чап-чап басып идәндә йөриләр, бертуктаусыз тәрәзәгә һәм сәгатькә карыйлар, салкын суны чүмеч белән шопырдатып эчәләр. Мондый чакта министрын да, Акъюл авылынын буасыннан елга бер мәртәбә кәрәкә белән ташбаш тоткан Җәгүрен дә бер.

Ә-ә, сугыш беткән елда, дәдәләре белән барып Ирнә елгасыннан җәтмә белән балык сөзгәннәр иде, беләк буе кызылканатларны каптырганнар иде. Җәгүр бу кадерле истәлеген сөйләргә дип авызын ачкан иде, Асафнын дөнья янгыратып, тәрәзә пыялаларын кыймылдатып гырлап җибәрүен ишетеп иренен тешләде...

Иртән ут кебек чәйне кабалана-кабалана эчтеләр. Тәҗрибәле балыкчы Асафта Җәгүргә чалбар да, өс киемнәре дә табылды. Тик нигәдер чалбарлар биллә бик кин, пиджаклар мул иде. Җәгүр алар арасына кереп кенә чумды. Билен яхшы каеш белән буып җибәргәч ул көлеп куйды...

Агачларнын тут йөгергән, саргая башлаган яфракларына эленгән, йортлар арасында ак җилкәннәр булып киерелеп йөзгән аксыл томан толымнары яр буена килеп житкәч тагын да куергандай булды. Биткә дым сарылды, кулдагы кармак сапларына чык кунды.

—Томан!—диде сокланып һәм исе китеп Җәгүр.—Ай-һай куе томан.

—Кояш күтәрелә башласа тарала ул,—диде Асаф Сәхипович яшьлек дусты алдында кыюлыгын күрсәтергә теләгәндәй, үзе шикләнеп кенә култык буйлап арлы-бирле йөреп килде. Иделнең атаклы балыкчысы Федор Степановичнын үзенә охшаган дәү, көчле көймәсе дә монда. Тыйнак, басынкы Зиннур әкәнен көймәсе дә вак камышлар арасына кереп поскан.

Әйберләрне ашыкмыйча гына урнаштырдылар, кузгалдылар. Кулына корал кергән солдатка бүтән төрле җан инә дигәндәй, машина руленә, моторлы көймә койрыгына утырган ир-атта да шундый ук үзгәреш сизелә. Асаф Сәхипович моторга көчле газ биреп, ян-якларда су чәчрәтеп, артта су кайнатып көймәне алга өндәде. Барасы юл таныш, йөз мәртәбә анда барылган да, йөз тапкыр борылып кайтылган, күз йомып та барып таба ала Асаф Сәхипович Моркваш күлен. Көн ачык чакта ул Олы күл янындагы утрауны бизәп торган ике талга турылар иде, әле тан яралмаган булса арьяктагы утларга карап юлны

табар иде, бүген дә каушарлык-куркырлык түгел, көймә койрыгы ышанычлы кулларда. Көймә эскәмиясенә утырган Жәгүр томанны кулы белән сөзеп карый, юеш учын теленә тидереп карый, борылып Асафка нидер кычкыра, тик анын тавышы Асафка килеп кенә житми. Томан һаман куерды, алар өсте алынган сөт эченнән бара башладылар. Хәзер шушы утраулар тезмәсен үтәләр дә шактый кин жәелгән көзге өстенә керәләр, аннан соң ике утрау арасыннан туры чыгарга тырышырга кирәк. Унга борылсаң да су астыннан төпләр чыгып тора, сулда да камышлар, төпләр житәрлек... Мотор тыныч кына гүли, дулкыннар кош канаты булып артта сызылып калалар... Кинәт уң яктан ниндидер кара күләгә ишелеп килгән сыман булды, әллә камышлар арасына килеп керделәрме? Ул көймәне сулгарак аерды һәм озак та үтмәде моторы агач төбенә килеп менде, шпонка өзелде, Асаф күнегелгән гадәт белән тиз генә моторны туктатты. Дөнья тып-тын булып калды.

—Ни булды?

—Болай гына... Син ишкәккә утыр да ишә тор, мин шпонканы алыштырып алыйм,—диде Асаф.—Шушы юнәлештә бара торыйк, туры тот.

Жәгүр ишкәкләрне куркып кына эләктереп алды да ишәргә тырышып карады, көймә әле чайкалды, әле тукталды, әле бер урында әйләнгәләде. Асаф эшен тиз генә бетереп моторны кабызды да уң кулын каш өстенә куеп, көймәне бик акрын гына алып бара башлады. Унда да, сулда да сай иде.

—Ишкәкнең берсен алып төпнен тирәнлеген үлчәштер әле, Жәгүр,—диде ул туктар-туктамас.

—Сай! Монда да сай.

—Сул якны кара!

—Монда тагын да сайрак.

Стена булып тагын кара күләгә ишелеп килде һәм алар куе камышлык арасына барып керделәр. Жәй урталарында чак күренеп торган камышлар, августта су төшә башлауга озынаеп, шәбәеп калалар, керсәң чыга алмаслык урманга әйләнәләр.

Мотор белән барырлык түгел иде. Асаф ишкәккә үзе утырды һәм әле бер якка, әле икенче якка, алга, артка тартылып карады, су сай, бер якта да үтеп китәрлек ачыклык юк иде. Жәгүр хуҗаның хәле мөшкел икәнен күреп, әдәп саклап, сүз катмады, жайсыз сүз ычкындырып Асафның мыегын тагын да ныграк чуалтудан курыкты. Икесе дә дәшмәделәр.

«Камыш төрмәгә килеп каптык», дип уйлады Асаф һәм кичәге вакыйгалар ап-ачык булып күз алдына килде... Теге егетләр ни уйлады икән? Ни сөйләште? Юлда берәүнең котын алдык дип район буенча шапырынып йөрмәсәләр яратырсың!..

Жәгүр аягүрә басып, өскә карап нидер табарга тырышты.

—Ни эзлисең?

—Кояш күренмәсме икән дим... Чыккандыр ич инде?

Асаф сәгатенә күз төшереп алды.

—Әллә кайчан...

—Томан таралырга бик уйламый әле монда!

Моннан берничә еллар элек Федор Степановичлар балыкка чыгып, куе томанга эләгеп, кая барырга белмичә утрауда кунып кайтканнар иде... Бүген шундый хәл була күрмәсен...

Шактый утырдылар.

Асаф башын калкытты да, мөмкин кадәр уенчак, гамьсез күренергә тырышып, жинел тавыш белән:

—Ә безнең карт анда ни хәлдә ята?..

Жәгүр жавап бирмәде, бераз тамак кырып торды, шуннан соң гына:

—Сәхип абзыйны утыз беренче майда жирләдек,—диде.

—Ничек, ничек?

—Жирләдек дим... Вафат Сәхип абзый, үлде.

—Ничек үлде? Ә мин? Нигә мина хәбәр итмәдегез? Нигә монарчы авызына су кабып утырдың?

—Әйтмәскә кушты, хәбәр итмәскә...

—Әткәйме?

—Син кызып китә күрмә, яшьтәш, рәнҗегән булганмы, бер-бер ым җиткерергә теләдеме, әткәң бик нык үтенде, «Үзе кайтмыйча хәбәр итә күрмәгез»,—диде. Җылый-җылый ялварды. Мин вәгъдә бирдем.

—Кая җирләдегез?

—Үзебезнең авылда.

—Керәшен зиратындамы?

—Ә бер почмактан, аулак җирдән киртәләп анын үзенә урын бирдек. Шунда күмегез, диде. Белмәгән, ят җиргә нигә барып ятыйм, диде.

—Ә Сарман зираты?

—Сарман зиратын сөреп ташлап анда сәүдә үзәге, культура йорты салып куйганнар икән. Яна башка чыккан зиратка барасы килмәде ахры.

—Нигә килгәч тә мина сөйләмәдең?

—Ә син сорамадын да... Кайтмыйча хәбәр итмәгез, диде. Аптыраганнан килдем. Эш өсте. Чыдарым калмады. Асаф, кайтмыйсың да, кайтмыйсың, кичәдән бирле «Әткәй ни хәлдә?» дип сорамыйсың! Менә җитешеп сорадың, мин әйттем.

—Ә район җитәкчеләре? Ник алар хәбәр итмәгән?

—Яңалар бит. Читтән килгәннәр. Акъюл авылында дөнья белән бәхилләшкән Сәхип карт барын беләләрдер дисеңме? Хәзер кеше кешегә туган түгел шул инде. Курыкма, җиренә җиткереп үзем җирләдем. Табутын ясадым, әйбәт кеше иде... Әйе шул, нигә аны каядыр илтеп күмәргә? Юк-юк дигәндә дә зиратка килгән кешеләр анын исемен дә хөрмәт белән искә алырлар. Яхшы кеше иде! Хәзер андый кешеләр юк. Беттеләр алар. Хәзер ата улны, улы ата-ананы белми дисәң дә ярый...

Бу сүзләрне Җәгүр майнын утыз береннән бирле күнелендә йөрткән иде, хәзер, томан арасында, куе камышлыкта, ниһаять, яшьлек дустына әйтеп биргәч, ул җиңеләеп калды һәм шаккатып, телсез хәлдә көймә койрыгында утырган Асафны тынычландырырга кереште.

—Сәхип абзый бик матур китте, озак чирләп интекмәде. Үләренә өч көн калгач мине чакыртып алды, хәлендә иде әле, кичләрен озаклап сөйләшеп ятты... Юк,юк сина үпкәләмәде, гаепләмәде, рәнҗемәде дә. «Заман үзгәртте кешеләрне. Элеккеге тормыш мөнәсәбәтләре югалды, яңалары тумады; ата-ана белән бала арасы бозылды»,—дип кенә куйды...

—Хәбәр итмәгез дип сорады дисеңме?

—Кат-кат үтенде... «Ишеткәч кайтмый калмаслар, сездән чыкмасын»,—диде. Хатын әйтә: «Хәбәр ит, сонынннан үкенерсен», ди. Хаталангандыр, мөгаен, мәгәр Сәхип абзыйнын сүзен сүз итмичә дә кала алмадым. Иң соңгы үтенече шул иде бит, иң азаккысы, мәрхүмнең! Бүтән үтенече инде анын булмаячак. Шунын белән ни әйтергә теләгәндер, аңлап җиткермим... Чөнки мин сезнең арагызны да, сине дә юньләп белмим ич, Асаф! Аралар ерагайды, мин һаман шул керәшен Җәгүр булып калдым. Ә син... Безнең күз генә җитә торган түгел сина...

Асаф өметсезләнеп як-ягына каранды, ишкәккә тотынды. Ишкәк белән камыш төпләрендәге суны болгатып этенеп карады, көймә төбе куе, ябышкак лайга кереп утырган иде. Ул сүзсез генә чишенә башлады.

—Ни эшләргә уең?—дип сорады Җәгүр.

—Этеп карыйм. Мин төшкәч көймә дә җиңеләер.

Ул трусиктан гына калып суга сикерде. Суга салкын кергән иде, ак тәне куырылды, аннан күрмәкче Җәгүр дә суга сикереп төште. Кешесез калган көймә су өстендә тирбәлә башлады, алар янәшә басып коерыктан көймәне алга эттеләр.

—Кайсы якка барасы?—дип сорады Җәгүр, үзенең гел мускуллардан гына торган инбашы белән Асафнын тәненә тиеп китеп.

—Кая, Кая? Кая барасын белсәм мин!..

—Әз-мәз дә чамаң юкмыни?

—Чама чамага туры килми... Хәбәрең башка балта түтәсе белән китереп орган сыман булды!..

Алар камышлыкны ерып шактый бардылар, икесенең дә маңгаена бөртек-бөртек тир йөгерде. Җәгүр маңгаендагы вак-вак сәйлән кебек тир бөртекләре елтыраса, Асаф маңгаеннан Идел суына борчак-борчак бөртекләр тамды...

—Бераз хәл алыйк.

—Аякны суырып чыгарыр хәл юк,—диде Җәгүр.—Бата...

—Бата...

—Һәй!—дип кычкырып җибәрде Җәгүр.—Ахмаклар. Агымга карап кая баруны чамалап буладыр бит?

—Агамы соң, кара?! Акмый. Мин агымны баядан бирле күзәтәм. Хәзер Иделнең агымына ышанырга да ярамый; әле үргә ага, әле аска.

—Замана үзгәрде дип юкка гына әйтмәгән алайса Сәхип абзый!? Сулар үргә ага диген...

Бераз ачыклыкка чыккан кебек булдылар, томан таралмады, ул ачыклыкта да ак пәрдә булып салынып суга тиеп үк тора иде. Өстә, баш очында йомарланып-йомарланып ак болыт акты. Тагын ләмгә бата-бата аякларын тераәп һаман авырая барган көймәне эттеләр, кайда йөзеп, кайда авыр сыдырылып бара торгач тагын камыш арасына барып керделәр.

—Син утыр, Асаф, мин этим,—диде Җәгүр.

—Кая барырга белсәк, җиңелрәк булыр иде.

—Әллә кояшны көтәбезме?

—Нинди көтү? Син минем хәлне аңлыйсыңмы?

—Аңлыйм,—диде Җәгүр, аңык кына берни аңламаса да.

«Менә ничек итеп җәзалаган икән әтисе Асафны!». «Менә ничек итеп үч алган!»

Аралары өзелгән иде инде аларның, байтак еллар аралашканнары да, хат язышканнары да юк иде. Әмма ата белән улы арасы шуңа барып житәр дип ул күнеленә дә китереп карамаган иде. Мондый катылык: шәфкатьсезлек... Әнә, Җәгүр дә «аңлыйм»дип бара, гәрчә ул ике араданиләр булганын бөтенләй белми диярлек. Ата белән ул икәүдән-икәү генә сөйләшкәннәр иде һәм бу соңгы сөйләшү булып калды...

«Соңгы»... Ул Суфия ханымга «әти бер хәлдә ята, врач чакырттым», диде... Хәзер аны ничек көйләргә?.. Нинди йөз белән авылга кайтып керергә?.. Кайтмый калырга ярамый, һич ярамый... хәзер ярга чыгарга да... шәһәргә кайтырга... Җәгүр белән кайтып та ук китәргә кирәк.

Кайтып нишлисең?.. «Теге чакта хәбәрен алган идем, кечерегез, авылдашлар, әтине җирләргә кайтып булмады... Хәзер менә каберен карарга, чардуган торгызып, таш куярга кайттым», дияргәме?.. Кайтышлый ук Чаллыдагы «Таш эшкәртү берләшмәсе»нә кагылып чыгып әллә әзер таш белән кайтыргамы?.. Ә Суфияга ни дип әйтерсең?.. Аның ни әйтәсен алдан белә алмассың: әтине җирләргә мин дә кайтам дисә?.. Ул хаклы булачак... Гәрчә ул, аның нәсел-нәсәбе гап-гади авыл укытучысы, ярым крестьян хәлендә сыер асрап, бәрәңге утыртып, яшелчә үстереп гомер иткән Сәхип Зәкиевне бер чакта да тиң санамадылар, аны гел түбәнсеттеләр, саннамадылар, арага кертмәделәр, йөрешмәделәр, мәгәр кайбер очракларда Суфия көтелмәгән хәлләрне ясап куйгалады... Бу юлы да шулай кыланса?..

Камышлыктан авырлык белән чыктылар, монда су тездән түбән булса да камышлар сирәк, анда-санда гына тырпаеп торалар, көймә җиңелрәк китте, әмма икесе дә талчыкканнар иде, туктап капкалап алдылар, термостан суына башлаган чәй агызып эчтеләр.

Өйдә үк төчкерә башлаган Асаф байтактан август суында килеп калтырана, дерелди башлады. Чәй әзрәк җылытырмы әллә дисә дә, киресенчә, калтырау бөтен тәненә йөгерде, ияге биеп-биеп алды, ул су өстен яңгыратып кат-кат төчкерде, күкрәк читлегенә салкын керде. Ул күлмәген алып шәрә тәнен төреп, өметсезләнеп су өстен китмәскә сарган тыгыз томанга карады.

—Тукта,—диде кинәт Җәгүр, аның беләгеннән кысып тотып.

—Нәрсә бар?—Хыянәтче ияк сизелерлек биеп алды, тешләр тешкә тиеп шыгырдады.

Асаф су шопырдаганын һәм ниндидер җан иясенең мышлаганын ишетте.

—Бер-бер хайванмы?—дип сорады Җәгүр.
—Эт йөзәме?
—Киттек!

Арган саен авырая барган көймәгә күкрәкләре белән ятып алар тавыш килгән якка киттеләр, барган саен шопырдаган һәм мышлаган тавышлар ачыграк ишетелде, ләкин бичара сәфәрчеләр әле ни уйларга да белмәделәр.

Су тирәнәя башлады, тубыкка менде, тезгә житте, алар икесе ике яктан көймәгә сикереп менделәр, Асаф ишә үк башлады, күзләре һаман тавыш ишетелгән якта булды. Нәрсә булыр?.. «Пәриме, җенме?.. «

Ул арада камышлар арттарак калды, су киңлеге ачылды һәм алардан ерак та түгел әкерен генә йөзеп барган төп күренде.

—Эт түгел!—дип кычкырды Җәгүр
—Кычкырма, куркытасың!
—Поши ич бу!

Авыл урманнарында пошилар белән шактый очрашкалаган җете күзле Җәгүр судан бөкре борыны, кинчә текә маңгае һәм киң җәелгән борын тишекләре генә күренеп торса да Иделне инләгән хайванны танып алды.— Ипидер, поши!

—Артыннан калмыйк,—диде Асаф, ишкәкләрен суга чак-чак тидереп.— Ул, мөгаен, кая барырга кирәген беләдер.

Көймә нәкъ поши үткән эздән, иркенләп үк йөзә башлады, бик якында гына камыш утраулар, судан ямьсез караеп чыгып торган черек төп башлары еш-еш күренгәләсә дә, поши юлны шулкадәр дөрес таба иде ки, көймә төбе бер тапкыр да ышкылып карамады... Берзаман ул сөзәк ярдан бара башлады, корыга чыкты, көчле башын чайкап, пошкырып суын селкеде һәм шунда гына үзенә ияргән көймәгә һәм ярым шәрә балыкчыларга борылып карады, аннары ялкау гына юртып томан пәрдәсе артына кереп югалды. Ярга чыгып як-ягына карангалап торгач кына Асаф үзләренең нәкъ тиешле якка, әмма дачаларыннан бераз гына түбәндәрәк корыга чыгуларын аңладылар...

Кояш чыкмады, томан таралмады, көн тагын суытты, шыксызланды, алар әйбер-караларын, кармакларын аннан-моннан гына урнаштырып туптуры платформага киттеләр. Асаф Сәхипович, әле нишләсен, кая барасын белмәсә дә шәһәргә кайтырга ашкына иде.

Казанга кайтып житәрәк кенә ул Җәгүргә үз ихтыярын белдерде.
—Мин иртәгә үк синең белән авылга кайтып китәм.
—Бусы ярый,—диде Җәгүр сабыр гына.—Кайту кирәк, әткән рәнҗеп ятадыр.

Җәгүрнең соңгы сүзләре Асафка ошап бетмәсә дә авылдашының хаклы икәнен чамалый иде ул. Ә рәнҗеп яту дигәннән, анысы юк сүз, үлгән—беткән, югалган, менә кеше телендә, халык күнелендә калганнарның исеме ямьсез яктан яңгыраганда, хәл чыннан да шәптән түгел. Әле ярый Җәгүр килеп хәбәрне ирештерде, уйламаганда, истә-оста югында командировкага барып чыгасы булсаң... Шунда, туган жирендә кайгы хәбәрен ирештерсәләр, ни кылырсың?.. Хәзер дә авылга кайтып керү җиңел булмас, әмма бу очракта белеп кайтасың, әзерләнеп. Иң яхшысы таш яздырып кайту уңайрак булыр. «Теге чакта кайтып житә алмаган идем, кичерегез, авылдашлар, менә кайттым».

Ул бу көннәргә билгеләнгән утырышлары, җыелышлары, киңәшмәләре, чакыруларны, бурычларны күнеленнән берәм-берәм үткәрергә тотынды, һич кичектерергә ярамаган утырышларның күплеген исәпләп чыгаргач, үзенең дә исе китте.

Җиде урынбасары булган министрнын эше алай күп дип әйтеп булмый иде, әмма җыелышларнын күбесенә Югары йорт кешеләре, кайчагында Үзе дә катнашачак, андый чакта министрның катнашуы зарур санала иде...

Ярый, аларын көйләр дә... Менә Суфия белән нишләргә? Сәфәр чыгуын ни белән аңлатырга? Элек күнләшүен артык сиздермәгән хатыны, соңгы елларда искәрмәс чыгып киткән чакларында янып-көеп көнләшә иде. Телен теш артында тотарга гадәтләнгән министр хатыны, әлбәттә, чәчрәп чыгып анын якасына ябышмаса да, хатынынын кара коелуыннан, йөзенә төшкән

зәһәр күләгәдән. Суфиянын түшендә нинди утлар янганын чамалый иде Асаф һәм бу хәлдән сагаерга тырыша иде. Бу юлы алдан белдермичә чыгып китәргә туры киләчәк. Иртәгә дүшәмбе, эшкә чыгарга да, нигезле генә сәбәп уйлап табып чыгып китәргә кирәк. Бәлки авылга кайтуын әйтеп тә тормаска кирәктер. Чаллыга барырга да, кирәк-яракларны әзерләткәч, авылга кайтып керергә булыр... Бүген үк Чаллыга, горкомга шалтыратырга кирәк, дип уйлады Асаф Сәхипович.

Планнарны Асаф Сәхипович иртәрәк корган булып чыкты. Кайтып житүгә анын температурасы күтәрелде, кичкә таба бөтенләй хәле бетте, ул янып-көеп, корып ямьсезләнгән иреннәрен ялкау гына кыймылдатып врач чакыруларын үтенде.

Врач килде, таныш, күз күргән кеше, анын кызын институтка урнаштырырга ярдәм иткән иде Асаф Сәхипович. Врач, гомергә рәхмәтле булып, министрны бик жентекләп карады, түшен, аркасын тынлады. «Бер-ике көн ятырга туры килер», дип, бишкә бөгелеп саубуллашып чыгып китте.

Суфия эшкә чыгып киткәч Асаф Сәхипович Жәгүргә шалтыратты.

—Мин чирләп ятам әле монда... Син бүтән йомышын юк икән кайта тор. Мин үз жаем белән килеп чыгармын ,—диде.

—Юк, юк, бүтән йомышым юк. Эш өсте, кайтырга кирәк. Без сине көтәрбез. Туп-туры үзебезгә төш,—диде Жәгүр, Асафны кат-кат чакырып...

Температурасы бераз төшсә дә, эсселек тәненнән бөтенләй китеп бетмәде, башы авыртты министрнын, врач тагын килде, шуннан торып кына кардиогруппа чакырттылар һәм Асаф Сәхиповичка «бер атнага постельный режим» дип чыгып киттеләр.

Өй арасында торып йөри башласа да Асаф Сәхипович врачлар сүзен жиренә житкерергә тырыша иде, урамга чыгып йөрмәде, иртә-кич министрлыкка, секретарена шалтыраткалап торды. Ашыгыч эшләрне анын аша гына урынбасарларына, ярдәмчеләренә, бүлек башлыкларына йөкли торды, сүзе кыска, боерыклары катгый, тавышы кискен иде анын...

Эш мәсьәләләрен хәл иткәндә ул жинеләеп авыр кайгысын онытып торса да, телефон трубкасы кулдан ычкынуга ук Жәгүр китергән хәбәр тишепкисеп күнеленен түренә үк үтеп керә иде.

Хәле авыр иде Асаф Сәхиповичнын, катлаулы иде...

Шушы атнада аны тетрәндергән өч вакыйга булып алды, вакыйгаларнын өчесе дә анын алдагы тормышында зур урын тотканга күрә, без аларны берәм-берәм һәм кинрәк итеп анышып үтәргә булдык...

Атна уртасында анын шоферы Тәлгать килеп керде. Бүтән чакта ишек катындарак кына торып Суфия апасыннан, йә Асаф Сәхиповичтан: «Мина йомыш юкмы? Берәр нәрсә табарга кирәкмиме?» дип кыска гына сораштыра торган Тәлгать, бүген аяк киемен салып ташлап хужасы кырын яткан диван янына килде. Асаф торып ук утырды. Тәлгатьнен чырае житди, күзләре төбәлеп нидер белдерергә тырышып карыйлар. «Әллә теге малайлар берәр нәрсә чишеп ташладымы?» дип сорарга теләде Асаф, гадәте буенча, тыелып калды. Битараф рәвештә.

—Нәрсә бар, Тәлгать?—дип сорады.

Тәлгатьнен аскы иренен аста калдырып тешен өскә чыгара торган гадәте эшнен мөшкел булуын сөйли торган билге иде.

—Гөлсинә апа Казанга килеп чыккан!..

Асафнын кашлары дугаланып өскә чөелде.

—Шалтыратып сезне сораган. Кат-кат... Сезне күрәсем бар дигән...

Бу чүкеч өстенә тукмак иде, мондый хәлдә чакта Асафка Гөлсинәнен килеп чыгуы бер дә кирәк түгел иде.

Ул анын килеп төшүен сонгы очрашуларына ялгарга тырышып карады. Фатир хужасынын кинаяләп кенә әрләве, каты-каты сүзләр дә ычкындыруы, Гөлсинәнен үз-үзен тотышында монарчы булмаган сәер гадәтләр тагын да ныграк пошаманга төшерделәр.

—Кайда тукталды икән?

—Апаларында булыр,—диде каш астыннан гына карап Тәлгать. Ул борчылган, берүк вакытта борчылуын хуҗасына сиздермәскә дә тырыша иде.

—Син хәзер бар, аны эзләп тап, хәзер үк миңа шалтыратсын.

—Син кара, аны юатырга тырыш...

Чуалган булсалар да әлегәчә бер юнәлештәрәк йөргән уйлар хәзер ихтыярсыз икегә бүленделәр. Асаф Сәхиповичның күңеленә әле әткәсе килде, әле Гөлсинә килеп тыгылды. Сорауларына җавап, уйларына йомгак табалмыйча ятканда чырылдап телефон шалтырады.

Гөлсинә шалтырата икән, тиз барып тапкан Тәлгать...

—Асаф абый...

«Абый» дип эндәшмә дигәне бар Асафның, әмма Гөлсинә кызыпкайнарланган чакларда гел шуңа күчә.

—Тыңлыйм сине, Гөлсинә.

—Асаф абый, хәзер үк минем яныма кил!

—Кая?

—Апаларга... Өйдә берәү дә юк. Мин апаларда...

—Чирләп ятам, Гөлсинә. Хәлем шәптән түгел.

—Миңа әйттеләр... Алай да син килергә тырыш. Мин сине көтәм.— Шушы сүз артыннан ук Гөлсинәнең сулкылдап җылап җибәргәне ишетелде.

Нишләргә?.. Менә тиле хатын! Артыннан бастырып килеп җитүе генә түгел, чакыра, каршы килә алмаслык итеп чакыра...

Көн иртәдән бирле сүрән иде бүген, ара-тирә яңгыр пыскаклап ала, тротуарлар пычрак, һава дымлы, әллә Гөлсинәнең кискен сүзләреннән, әллә болай гына Асафның тәне тагын кызыша башлады, градусник куеп караган иде, утыз сигез!..Юк, мондый температура белән урамга чыгып йөрсәң, өзлегәсенне көт тә тор. Асафка хәзер озак ятырга ярамый, әзрәк кенә калкынуга авылга кайтып китәргә кирәк. Хәзер һәр көн аның гаебен зурайтачак кына.

Сәгать үткән саен телефон ике тапкыр шалтырады, әмма бер сүз дә эндәшмәделәр, соңгы шалтырауда трубкадан Гөлсинәнең сулкылдап җылаганы гына ишетелеп калды.

Ни булган Гөлсинәгә?

«Шикле шикләнер», Суфия эштән кайтты. «Хәлең ничек?» дип кенә сорады да бүлмәсенә кереп бикләнде. Берәр нәрсә сизенәме?..

Кичкә таба хәле аруланган кебек булса да Гөлсинә янына барырга соң иде инде, апасы эштән кайткандыр, җизнәсе, бүгенге хәлдә, чуалчык сынаулар алдыннан Асафка кеше күзенә күренеп йөрергә ярамый иде.

Әтисе вафат... Инде бик күптәннән тормышының бөтен тамырлары белән туган йортыннан, яшәгән авылыннан, ата-анасыннан аерылган Асаф Сәхипович күңеленә көтелмәгән уйлар килеп бөялде... Моңарчы ул, инде күптән бәлигъ булып, алтмышка якынлашкан кеше, барыбер ата баласы булган икән. Менә хәзер бабайлар, борынгы бабалар белән тоташтырып торган тере җеп өзелде, Зәкиевләр нәселенең тоташ бер буыны өзелде. Хәзер дөньяда Асаф үзе дә, улы Эдуард кына калды. Күптәннән ата белән очрашмаса да, кинәшмәсә дә, күңеленең түрендә моңарчы ул бала иде, ул иде, аның әткәсе исән иде. Күңел үзеннән-үзе атага барып тоташа иде һәм нииндидер бер дәрәҗәдә ваемсыз яшәргә ирек бирә торган иде. Әле ул дөньяның соңгы сүзен әйтергә ашыкмаса да, яши, чөнки аның атасы бар... Ата үлү, атаны югалту—ир кеше өчен искиткеч җаваплы, кабатланмас бер халәт икән...

Уң ягына ятып стенага караган Асафның уйлары ике кеше арасында йөрде: атасы һәм улы арасында. Атасы белән арадашлык өзелгән елларда өзелдеме аның Эдуард белән арасы?.. Кайчаннан юньләп сөйләшкәннәре юк, бер-берсенен ничек яшәүләре хакында белмиләр дә диярлек. Эдуард белән бабасының мөнәсәбәтләре дә Асаф аркасында өзелде түгелме? Бала чакта бер-ике тапкыр алып кайтканнар иде аны авылга. Соңра Суфия катгый рәвештә баланы җибәрмәде, «Акъюлга кайтып шакшы дуңгызлар, керәшеннәр арасында бозылып йөрмәсен әле», диде. Әле ул чакта Асаф министр

түгел иде, хатынының сүзеннән бер чакта да узып сүз әйтә алмый иде. Хатынының каты кулына ачу итеп, Гөлсинә янына китеп, хатынының богавыннан ычкынып тора ала иде...

Асаф әтисез калган мәлдә, Эдуард атасыз да, бабасыз да калган булып чыгамы?..

Моннан фәлән ел элек, Асаф нәкъ министр булып билгеләнгән истәлекле елда, хәтәрләнеп, кара «Волга»ның түренә утырып Акъюл авылына кайтып төште. Әнисе дә исән иде әле ул чакта. Өйгә керде, әнисе чебиле тавык кебек кыртлап мич белән табын арасында йөреп торды, төче коймак өлгерт-те, балын-маен куйды, улы кайтуына чиксез нык сөенде.

—Әткәй кайда?—дип сорады Асаф берничә мәртәбә.

Әнкәсе бик яхшы ишетсә дә ишетмәмешкә салышып, сүзне ансат кына читкә борып торды да, инде сузып торырга җае беткәч, әйтеп салды...

—Күрше Мостафин авылында Әюб карт вафат икән. Авыл бәләкәй, картлар юк, тәртибен белеп, аз-маз укыштырып мәет куяр адәм дә калмаган. Менә ялынып-ялварып атаңны мәет куярга алып киттеләр, дип аңлатып бирде.

Асафның колагы үрә торды: ничек? Гомере буе мәктәптә балалар укыткан, динне, алла белән мулланы бар дип тә белмәгән Сәхип Зәкиев муллалык хезмәтен башкарамы?.Улы министр булып киткән көннәрдә фидия козгыны булып түрдә утырамы? (Асаф «фидия козгыны»ның нинди булуын да, фидияне дә бик томанлы гына белә иде!) Ул кулындагы кашыкны атып бәрде, әнкәсенә сүз дә әйтеп тормастан Мостафин авылына китеп барды. Ара сигез чакрым гына, калын, куе урман аша барасы, юл коры, көн матур, монда килгәндә Асаф күптән татылмаган рәхәтлек кичергән иде. Хәзер һәммәсе дә челпәрәмә килде...

Ул машинасын зират капкасы төбендә туктатты да бер читкәрәк төйнәлгән биш-алты кешене күреп, шулар янына ашыкты. Таралган авылның зираты да хәл эчендә була, ауган-янтайган комташлар, туфрак, үлән эченә сеңгән агач чардуганнар арасыннан урап-чурап барганда Асафны танырлык түгел иде... Кабер тирәсенә чүмәшкән карт-коры, йодрыкларын кысып йомарлап, иреннәрен тешләп килеп баскан әзмәвердәй кешегә сәерсенеп карадылар. Әткәсе кабернең баш очына чүгәләп Корьән укый иде... Сәхип карт улына сыңар күзен төшереп алды, тавышы калтыранды... Ниһаять, җеназа тәмамланды.

Ата белән ул авылга кайтып җиткәнче сөйләшмәделәр. Шоферы ул чагында Тәлгать түгел иде әле Асафның, сөйкемле генә урыс егете Вася Миргунов иде. Шуннан читенсенде Асаф. Мәгәр өйгә кереп, капка-ишекләр ябылгач әткәсен пешерде генә. Кулыннан килсә ул аны бүген терелләй утка салыр иде. Әйтмәгән сүзе калмады. «Бәлеш козгыны», «дин сакчысы», «туймас тамак» дип сүкте Асаф, тагын әллә ниләр дип өстәде. Кече якта бу әңгәмәнең шаһиты Мөнәвәрә—Асафның әнкәсе шыпырт кына балавыз түксә, Сәхип карт, иелә төшеп, бер ноктага караган килеш, гел сүзсез-өнсез утырды, аның иреннәрендә көлемсерәү дә чагылып алды, әмма ул дәшмәде.

Асаф тузынып-тузып сүз бетергәч тә беравык тып-тын утырды.

—Ни әйтим сиңа, улым, диде ата көрсенеп.—Чакыргач бардым инде. Җолаларны беләм, Корьән сүрәләрен хәтерлим. Булыр-булмас кеше Әюб абзыйны җирләп аның рухын, җанын рәнҗеткәнче мин аңа чынын укыдым... Безнең халык мөселманча күмгән, күмә, алда да шул җола калыр, Аллаһы боерса! Бүтән җолабыз юк безнең... Ә адәмнең гәүдәсен шыпырт кына җиргә индереп булмый, ярамый. Эт баласы түгел лә, кеше гәүдәсе!

Әтисенең сабыр акыл белән әйтелгән дәлилләрен ватып-җимереп ташлыйсы килсә дә Асаф ул чакта аңа әлләни сүз әйтә алмады. Кайтуының нәтиҗәсе шул булды: авылына хат язмады, ата-анасының хәлен белешеп тормады...

Дөнья кызык: күрше-тирә татар авылларына мәет куярга йөргән Болгардан килгән нәселле Сәхип Зәкиевнең үзен керәшен зиратының бер почмагында аулак урын бүлеп алып керәшеннәр җирләде. «Үзем куйдым» диде

Җәгүр. Бусы да улы Асаф белән туган каршылыкның, бәрелешнең дәвамы идеме? Шуның бер йомгагы, ишарәсе, бердәнбер улына әйтеп калдырган сүз-ымы идеме?

Вафатын хәбәр иттермәгән, керәшен авылында куюларын үтенгән. Ни әйтергә теләде болар белән Сәхип карт?!

Асаф Сәхиповичлар йортында шәһәрнең әүкатле, көчле кешеләре яши, алар күптәннән берсен-берсе генә түгел, һәркемнең шәһәр баскычында тоткан урынын, кемнәр белән аралашуын, кемнәр белән йөрешүен—һәммәсен белеп торалар. Арада сирәк-мирәк кенә гади кешеләр дә килеп керә. Асафлар подъездында беренче катта яшәүче Ибраһим атлы балта остасы шундый гади кешеләрнең берсе иде. Ул искиткеч пөхтә киенеп йөри торган чал мыеклы кеше, хатыны Мәсрүрә, кызы Фагыйлә һәм әнкәсе туксан өч яшьлек карчык белән ике бүлмәдә яшәп ята. Очраганда еractан ук елмаеп, ике кулын сузып килә, һәрчак илтифатлы, ягымлы бу кеше Асафка да чит түгел иде... Шәһәр башлыкларының берсенә арзанга гына төшереп дача салып биргәннән соң шушы атаклы йортка килеп урнашкан Ибраһим монда үзен чит итеп тә саный, сәлам биреп, сүз катып китә торган кешеләре бернечә генә иде. Ара-тирә, йорт арасында йомыш-кара чыкканда Суфия ханым, гади кешеләргә керергә, аралашырга бер дә яратмаса да Ибраһимнарга барып керә, Ибраһим бөтен эшен ташлап, карышусыз аның эшен үтәп чыга, беркайчан да акча алмый, чәй эчәргә дә утырмый, исерткечне авызына да алмый иде. Асаф ишетеп белә, Ибраһим дин белән эш йөртмәсә дә анасының хәтерен саклап гаеткә мәчеткә бара, мәчет алдында рәт-рәт тезелешкән гарип-горәбәгә мул итеп сәдака өләшә иде. Балта остасы Ибраһимның югары разрядлы булуын да, акчаны министрдан ким алмавын да белә иде Асаф.

Чирли башлавына атна була дигәндә Асафларга Ибраһим килеп керде. Басынкы булып, кая бассам хуҗаларны рәҗетмәм икән дип, сак кына атлап керде дә бераз ишек катында көтеп торды, аннан Асаф яткан диван кырындагы урындыкка килеп сенде.

—Чирләп киткәнсең икән, күрше?!—диде.

—Иделгә чыккан идек, шул ярамады ахрысы,—диде җәлләтеп кенә Асаф.

—Булгалый, булгалый. Адәм баласы корычтан коелмаган шул, җил тиеп тә аудара кайчак.

Алар һава хәле, якынлашып килгән көз хакында ары-бире сүз алыштылар да сүз бетеп тә куйды.

—Мин олы йомыш белән йөрим әле, Асаф Сәхипович,—диде, ниһаять, кыюланып Ибраһим.—Минем Мәсрүрә төш күргән.

—Нинди төш?

—Минем әткәм, ягъни аның кайнатасы, безгә бик нык рәнҗеп ята икән.

—Рәнҗеп?..

—Шуңа бүген картларны чакырып, Корьән укытмакчы булган идек. Өйләдән соң картлар безгә керә. Синең дә өйдә чак... Әллә димен, картлар янына син дә төшеп утырасыңмы? Безнең өчен зур мәртәбә булыр иде.

Бүтән чак булса Асаф йә кычкырып көлеп җибәрер, ачулы чагы туры килсә Ибраһимны эт итеп сүгеп чыгарыр иде, «провокация корып, корыны бушка аударып йөрмәче, күрше» дияр иде. Бүген Ибраһимның тәкъдиме ана сәер булып тоелмады...

Ул Ибраһимнарга төшкәндә мәчеттән өйлә намазыннан чыккан картлар, олы бүлмәдә, өстәлнең ике ягына өчәр-өчәр кереп утырганнар иде, бирге якка, ишек каты ягындагы урындыкка Асаф кереп утырды. Ибраһим аны: «Безнен бик якын күршебез, мөселман кеше», дип тәкъдим итте. Кем булуын, кайда эшләвен белдермәве өчен Асаф ана эченнән генә рәхмәт укыды.

Картлар аны хуплап, үз итеп каршы алдылар...

Аның артыннан ук ишек катына йомшак урындык кертеп куйдылар, ана Ибраһимның әнкәсе, туксаны әллә кайчан тулган Фәтхия карчык кереп утырды. Ул картларга сәлам бирмәде, табынга яны белән утырды да, ничектер йомылып, күзгә күренмәскә әйләнде. Шунын ире, моннан бик күп еллар элек вафат

булып Мәсрүрәнең төшенә кереп, жаннарын тынычсызлаган иде инде.

Картлар үзара ипле генә сөйләшә башладылар, фәндәге яңалыкларга, газета хәбәрләренә игътибар иттеләр. Кайсыдыр илдә гел агачтан гына берәүнең кул сәгате ясавын хәтергә төшерделәр. Кара кәләпүш киеп, сакал-мыегын төзәткән Ибраһим яшәреп тә, көязләнеп тә киткән, ул тавышсыз-тынсыз гына табынга ризык китергәли башлады. Камыр ашлары, кәнфитләр, төрле-төрле тәм-томнар өстәл өстенә ямь биреп, тәмле исләрен аңкытып урыннарына урнаша тордылар.

Асаф бабайларга игътибар белән карады. Алтысы да Ватан сугышында катнашканнар икән, түшләрендә орден, медаль тасмалары бар, берсенең, иң картының пиджак якасында ике Кызыл йолдыз ордены янында Ватан сугышы ордены да жемелди. «Мәчеткә дә шулай баралармы болар, әллә бүген, аерым тантана уңае белән генә такканнармы?» дип уйлады ул, хәтта сорасы да килеп китте. Иң карты монда баш кеше иде ахрысы, һәммәсе дә аңа олылап, «Хәлил абзый», дип дәшәләр, башлап сүзне ул әйтә, бүтәннәр аның ни әйткәнен көтебрәк тә торалар иде. Иң яшь бабай, ул да житмешләр тирәсендә булгандыр, чигелгән бәрхет түбәтәй кигән, сирәк сакаллы кешенең ике кулы да бик нык гарип, сул кулының бармаклары оешып учына бөгелеп килгәннәр дә, шулай катканнар. Бабайлар бик чиста киенгәннәр, өс-башлары пөхтә, йөзләре ниндидер бөек вакыйгага катнашучыларныкы кебек иман нуры белән өретелгән... Үзара татулыклары да, хужаларга булган хөрмәтләре дә йөзләренә чыккан иде. Алар Асафтан син кем соң, мәчеткә йөрисеңме, мөселманлык бурычларыңны башкарасыңмы дип тә сорамадылар. Арага ят кеше керүгә һич исләре китмәде, киресенчә, сөенгән кебек көнә булдылар...

Асаф сиздермичә генә карчыкка да карап ала иде. Карчык гел-гел Ибраһимнар белән генә тормый, күбрәк төпчек кызы, Ибраһимның сеңлесендә, киявендә гомерен үткәрә, шуның өчен Асафның аны юньләп күргәне дә юк иде.

Иренең гүрдә тынычсызланып ятып, килененә хәбәр бирүен ул ничек кабул итте икән? Мәсрүрәнең төшен ишеткәч ни уйлады? Ни дип юрады?.. Тынычлыгын югалткандыр ул да... Һәм хәзер шушы өч кеше күңелләренә галәти тынычлык инсен өчен ни кылырга, нәрсә эшләргә тиешләр? Фәлән картның рухына радиодан Әлфия Афзалова жырласын әле дип заявка бирә алмассың! Шушы алты карт, Ватан сугышы гариппләре алар өстеннән шикшөбһәләрне алып китеп, аларга жан тынычлыгы, күңел сафлыгы калдырып китәргә тиешләр. Бу бурычны министр булса да Асаф та үти алмый, туганнары жыелышып килеп сүз белән, юаныч белән дә аларның борчылуын кимә алмый. Бу бурычның әжерле сәвабы шушы картлар кулыннан гына килә. Картлар бер-берсе белән якын таныш, мондый экстренный хәлләрдә очрашкалаганнар булса кирәк, алар тантаналы тынлыкны шул кадәр зирәк рәвештә саклыйлар иде ки, Асаф Сәхипович, никадәрле кешеләр алдында үзен тотарга өйрәнгән, пошмас жанлы кеше дә дулкынлана, тынычсызлана башлады.

«Нигә тизрәк башламыйлар инде? Кемне дә булса көтәләрме? Әллә Коръән укуның үз вакыты бармы?» дип кереп-чыгып йөргән Ибраһимга сораулы күз карашын да төшереп алды. Ибраһим да гади чәй мәжлесенә жыелмауларын бик яхшы аңлый иде кебек, ул тавышсыз гына атлап йөри, һәр ишарәсендә, күз карашында аларга жан тынычлыгы биреп китәргә килгән юмарт ил агаларына хөрмәт сизелә иде.

Өстәлгә өстәмә ризыклар килде, моңарчы Асаф янында буш торган урындыкка хужа килеп утырды, Мәсрүрә дә, кызы да күренмәделәр. Ибраһим йомшак кына тавыш белән эндәште.

—Ягез, хөрмәтле кунаклар, без әзер!

Иң өлкән карт түш кесәсеннән дәфтәр калынлыгы гына китапчык чыгарды, тышкы, ал кесәдән гади түгәрәк күзлек чыгып картның әле көчен югалтмаган күзләренә менеп утырды. Бабай:

—Ярый, жәмәгать, «Тәбәрәк» сүрәсен укыйбыз,—диде. Табындагы ризыкларга күз йөгертә башлаган бабайлар кинәт үзгәрделәр, алар ниндидер олысымак, житди, фикри кыяфәт алдылар. Карт моңлы, үтемле тавыш белән, артык кычкырмыйча гына сүрә укый башлады. Иң яшь гарип карт,

күзләрен чытырдатып йомып өстәлгә иелә төшеп аның артыннан иреннәрен кыймылдата башлады, сүрәне ятларга җыена иде булса кирәк. Әллә шушы картны алыштырырга әзерләнәме бу карт? Ике-өче оеп кына, күзләрен түбәнгә төшереп, бик житди кыяфәттә Коръәннең колак һәм җан күнеккән сүзләрен мөкиббән китеп тыңладылар. Картларның берсе—чандыр, сары сакаллы, озынча кеше генә нигәдер тынычсызланды, ишек төбендәге карчыкка күз салгалап, борынын мышкылдатып алды. Ят тавышка берәү дә игътибар итмәде, өстәл тирәсендә Асаф аңлап бетермәгән, аның аңына барып житми торган мең төрле хиссият уятучы тантана бара иде.

Коръән укылып бетте. Өлкән бабай карчыкның ире—Ибраһимның әтисенең исемен сорады. Укылган Коръәннең шул кеше рухына, аның якыннарына, башка хатын-кыз һәм ир туганнарга багышлануын белдерде.

Багышлауны олылап, чын йөрәктән һәммәсе дә битләрен, ияк очын сыпырып амин тоттылар. Ишек катында үз иренә һәйкәл булып утырган карчык кына кыймшанмады, колакка сак иде ахрысы...

Асаф өчен бик кыен момент килеп житте. Иң әүвәл Ибраһим өч сумлык акчаны Коръән укыган бабайга сонды, калганнарның һәрберсенә бирәр сум өләшеп чыкты. Яшен ташы булып житез генә килеп кергән Мәсрүрә дә бабайларга бирәр сумнан акча таратты. Асаф эсселе-суыклы булып китте, кеше рәтеннән аңа да ике бирәр сумлык сәдака эләкте... Картлар амин тотып рәхмәт укыдылар. Асаф Сәхипович үзенең ике учы ияк тирәсенә менеп житкәнен сизенми дә калды... Каш астыннан гына бабайларга, Ибраһимга күз төшерде: көлмиләрме? Юк, һәммәсе дә үтә житди, бер-берсенә хөрмәтле һәм ачык чырайлы иделәр.

Аш янында нинди сүзләр булгандыр, Ибраһим тыйнак кына кыстый торды, Мәсрүрә сай эчле дип әйтерлек өлеш тәлинкәләренә салып хуш исле тавык шулпасы китерде, аннан итле бәрәңге чыкты, гөбәдия, төрле-төрле баллы пироглар өлеш тәрилкәләренә өелеп һәркемгә таратылдылар.

Мөнәсәбәтләрдә мондый риясызлыкны, сафлыкны тагын кайда күреп була? Болар китүче, соңгы буын вәкилләре... Аның әткәсе дә шундый булгандыр ич!?

Һәркемнең тәлинкәсенә өстәмә вак бәлеш салып чыктылар. Бабайлар әүвәлге житдилекләрен бер минутка да хәтерләреннән чыгармыйча, ашыкмыйча гына мактап ризыкларны тәмләп, яратып ашадылар... Аштан соң ризыкка дога кылынды. Ризык белән мавыгып Асаф һәйкәл карчыкны күздән югалткан икән, борылып караганда әби дә, урындыгы да юк иде.

Алар Ибраһим белән икәүләп ишек катында бабайларны озатып калдылар, Асаф та озак юанмады, хужаларга эчкерсез рәвештә рәхмәт укып, лифт чакырмыйча гына үз фатирына менә башлады...

Яшь чагында керәшен арасында үсеп, татарның мәчет, җеназа, Коръән уку кебек йолаларына күнекмәгән Асаф өчен һәммәсе дә серле һәм тантаналы иде. Аны бабайлар таң калдырды! Аларның бер-берсенә җылы мөнәсәбәте, хужаларга ихлас игътибары, әллә кайчан дөнья куйган җан ияләрен телгә алып, аларны олылап утырулары аның өчен көтелмәгән нәрсә, яна һәм сәер иде!..

Озак менде ул үзенең бишенче катына, туктап-туктап уйланып торды. Лифт чоланнары аның яныннан әллә ничә мәртәбә төшеп, әллә ничә тапкыр менеп киттеләр.

Ул һаман картлар хакында уйлады, һәм үзе өчен тагын бер коточкыч авыр, четерекле хакыйкатьне ачты...

Хәзер шушы биеклектән бабайлар үз бусагаларын атлап өйләренә керәчәкләр. Ике, яки бик күп булса өч бүлмәле хрущевка квартирларына кайтып керәчәкләр. Картлар яшьләргә комачау, алардан туйганнар, алар белән исәпләшеп тормыйлар. Күпчелек авылдан килгән: йорт, мал-туар саткан акчалар күптән тузган, алар йә утыз-кырык сум, йә аннан да кимрәк пенсия алалар. Малайлары эчә, киленнәре явыз, явыз булмыйча да ярамый: балалар бакчасы юк, кибетләрдә ризык өчен талаш, ире тапкан житми, бурычка батканнар. Малайлар урамда, чөнки алар өйгә сыймыйлар, тәмәке тарталар,

яшьтән үк кыска итәкле, утлы табанлы кынҗыр кызларны кыскалыйлар, наркотиклар белән дә шаяралар... Шул ыгы-зыгы, талаш, ызгыш, кимсетүләр, «үлә белмәдең инде карт тәре!» атмосферасына кайтып керәчәкләр алар!..

Нинди мактаулы, затлы һәм бөек икән шушы тыйнак бабайларның, Ватанны иң явыз дошманнан саклап калган кешеләрнең миссияләре!

Ибраһимнарга төшкәндә фатир ачкычын алырга онытканы икән, ул ишек катында бераз басып торды да түбәнгә төште, ишегалдына чыкты. Шунда жилсез, шыграк урынны сайлап шактый озак утырды, Суфияга нигәдер шалтыратасы килмәде. Бәхете, ул арада Эдуард та кайтып житте, өйгә алар бергәләп керделәр.

* * *

Улы Эдуард сәләтле бала иде, бик яшьтән инглиз телен үзләштерде, Казанның махсус, зур кешеләр балалары укый торган унсигезенче мәктәпне тәмамлады. Төзелеш институтының архитекторлар факультетын тәмамлады. «Студент-архитекторлар студентларның аристократиясе!» дип йөртеләләр, архитектура ул заманда бик престижный санала, алда үзләрен ни көткәнен белмәсәләр дә студентлар үзләрен бик текә тоталар. Казанның абруйлы семьяларыннан чыгып, медицина институтында укучы чибәр кызлар аларга тагылып йөри, «ире архитектор, хатыны врач»—иң унайлы гаилә санала иде. Эдуард ни теләсә шуны киде, ни теләсә шуны ашады. Суфия аны өрмәгән жиргә дә утыртмады. Эдуард бишенче классны тәмамлагач ике ел рәттән Германияга Росток шәһәренә барды, ел саен диярлек Артекта ял итте, чит ил балалары белән аралашты, яшьли белгән инглиз теле янына немец телен дә чибәр генә өйрәнде, әтисе белән әнисе бер-берсе белән ярыша-ярыша аңа махсус әдәбият, белешмәләр, сүзлекләр ташып, олы бер шкафны сыртлап тутырып та куйдылар...

Институтны тәмамлагач Асаф улын бик өметле урынга, башкалага, Мәскәүгә терәлеп кенә торган шәһәргә жибәрде. Эдуард шунда эшләп, ару гына кыз белән танышып—йә урыс, йә яһүдә алып шунда калырга, Зәкиевләр нәселен Мәскәүчә дәвам итәргә тиеш иде.

Суфия бер баладан артыкны алып кайтырга ризалашмады, «безнең заманга бер бала бик житкән, шуны дөньяда күренекле кеше итеп калдыра алсак, бурыч үтәлер», диде ул икенче бала хакында авыз ачкан Асафка...

Хатынынннан узып сүз әйтә алмаган чагы иде әле Асафның, күнде. Соңыннан, Эдуард кызамык, сары авыруларын бик кыен кичергәндә баласының, бердәнберенең язмышы өчен борчылган чакларда, Суфияга ярым әрләү сүзләре дә ычкындыргалады.

Ничек булса булды, Эдуард укыды, үсте, өйне магнитофон, дисклар, кассеталар белән тутырды; инглиз, немец телләрендә журналлар укыды. Йортта нинди генә телләрдә жыр яңгырамады!..

Әлбәттә, Суфия татарча ярым-йорты сөйләшә белсә, Асаф та ана иярep үз телендә бик күптәннән сөйләшми. Алар, республиканың югары эшелонында утыручылар үзара татарча сөйләшүне онытып баралар, балаларын да шуңа күнектерәләр иде... Эдуард татарча бер авыз сүз дә белми, татар театрына аяк басып кергәне юк, радиодан татар жырларын яңгыратып, телевизордан татар биюләрен күрсәтә башласалар, ул жирәнеп кенә «ярым кыргый татар»ларны сүгә-сүгә, аларны артта калуда, искелектә гаепләп радио-телевизорларны үзеп ташлый иде.

Ул бер чакта да татар кызлары белән дуслашмады. Ул татар кызларын тар карашлы, аң җәһәтеннән артта калганнар дип белә иде. Ул ата-анасы сызып куйган перспективага риза, инде Мәскәүдә зур дәрәжәләр алып, баскан урынын ныгытып калганнан соң, кайчан исә бер Татарстанга олы бер житәкче булып кайтырга тиеш иде. Бер генә нәрсәдә Эдуард ата-анасына бирешмәде—партиягә кермәде. «Кеше иреген чикли торган, бары тик хайваннар өереннән генә торган партия миңа ни-нәрсәгә?» диде ул аяк терәп. Котлары очып, ата белән ана аның авызын томаларга тырышып ниләр генә әйтеп карамадылар: «бу дөньяда партиясез юньле бер эшкә дә куелачак түгел, әнә кеше балалары

аякка чак кына басуга партиягә керәләр дә үзләрен югары урыннарга әзерлиләр», дип мисаллар китереп карадылар. Мисаллар җитәрлек иде. Чыннан да партиянең ни икәнен дә аңлап бетермәгән, мәгәр партиягә кереп урнашкан бик күп ахмакларның, ярымакыллыларның тиз-тиз генә югары күтәрелеп, җылы урыннар элэктереп алуларын сукыр күз дә күреп ала торган чак иде...

Кермәде Эдуард партиягә. Мәскәүгә барып өч ел фәнни институтта чалбар төбе туздырып утырды да, ата-анасына тагын каршы килеп, көннәрдән бер көнне шәһре Казанга кайтып төште... Бик җылы урыннарга урнаштыра ала иде улын Асаф Сәхипович, партиясезлеге комачаулады, илдә җылы урыннар бары тик партия әгъзаларына гына әзерләнгән иде.

Эдуард үзе дә эшкә керергә ашыкмады, әти-әнисе бик кыса башласа өзеп бер сүзне кабатлады: «Архитектурага якын да бармыйм... Трамвай тукталышларын яки шәһәр бәдрәфләренең проектын ясап адәм көлкесе булып йөрисем юк... Безнең илдә бүтәнчә архитектор була алмыйсың... Җитди проектларны казанлыларга бирмиләр һәм бирмәячәкләр. Йөз ун сумга кол булып, тиенгә тиен кушып утырырга мин җүләр түгел!..Эштә саналуымны теләсәгез балалар бакчасына каравылчы булып керәм. Мәскәү яшьләре әнә шулай эшлиләр, шулай яшиләр... Акча миңа кирәкми, сез тапкан җитәрлек. Квартир хаҗәте дә юк. Әлегә сыябыз. «Ә өйләнсәң, балаларың була башласа?»

—Өйләнергә дә җыенмыйм...

Суфия ханым күз күргән танышларын сорашып-белешеп бик тырышып үзенә килен эзли башлады. Кем баласын тиң күреп, кемнәр белән аралашырга ярар?.. Андый кызлар шактый икән Казанда... Министр Асаф Сәхиповичның бердәнбер улына кәләш булырга атлыгып торучы кызлар ишле генә икән... Бер кызны әйтеп карадылар Эдуардка, көлеп кенә куйды, Суфия әле генә белгән кызны Эдуард әллә кайчан белә икән инде. Кызның әниләре дә үзләренә затлы кияү эзләп Эдуард йөргән сукмакларда йөргәннәр икән. Ике кызны әйттеләр... Өчне... Ел үтте, ике ел, Мәскәүдән кайтканга биш ел булды, Эдуард кичләрен чыгып йөрде, соң гына кайтты: авызыннан йә аракы, йә коньяк исе килде, кулъяулыкларыннан ирен буяулары да чәчрәп Суфияның күзенә керде. Егет өйләнмәде, эшкә дә кермәде...

«Безнең Эдуард шаккатыргыч бер проект эшләп ята», дип йомды Суфия ханым улының эшлексезлеген. Утызга җиткән егетнең ата-ана җилкәсен кимереп ятуы, Казанның престижный гаиләләре арасында алай ук куркыныч саналмый иде: квартиры бар, иркен, ата-анасыннан каласы байлыкның чуты юк. Нигә куркырга?

«Чит ил туристларын йөртергә гид булып керәм, курсларга йөрим», диде бер мәлне Эдуард. Инде ана да ризалаштылар. Әмма Казан чит ил туристлары өчен кызыктыргыч җим түгел иде, иске чиркәү-мәчетләр җимерелеп ята, атаклы Зөя утравы чиркәү-монастырен акылга сай адәмнәргә биргәннәр... Чит ил туристлары турыдан-туры Сәмәрканд, Ленинград, Бохара тарафларына юл тотканда Казанда тарихи йортларны, иске урамнарны иплэп кенә җимерә-җимерә яңа тормыш, иркен тормыш һәм яңача яшәү формаларын ныгыталар иде...

«Аспирантурага керәм», диде Эдуард. Кермәде.

Хәзер иптәшләре белән туристик сәяхәттән кайтып килә иде. Ерактан түгел, шунда, үзебезнең күршедән—Мари иленнән генә кайтып килә иде Эдуард. Алар шунда Яльчик күлендә, Сура елгасында балык тотып мәж килгәннәр, гөмбә кыздырып ашаганнар, су кергәннәр, кызынганнар... Киткәндә үк ак жире калмаган Эдуард тагын да каралган, күлмәкне күтәреп күрсәтте, корсагы тартылып ябыккан иде.

—Ә без...—диде ул һич тайчынмыйча.—Һәммәбез дә анадан тума чишенеп кызындык!

—Ә Нурания бардымы?—дип сорады кинәт Асаф Сәхипович, ярсуын көчкә тыеп.

Шәһәрнең бик абруйлы хирургы Сәлам Даишев кызы Нурания белән Эдуардны җәй уртасында гына таныштырганнар иде. Беренче тапкыр татар кызы белән таныштырдылар. Инде милләтен онытып, татарлардан туеп яшәгән

Асаф Сәхиповичның күкрәгендә бер җылы утрау хасил булды, шул утрауга ул Эдуард белән Нуранияне урнаштырды. Дөрес, кыз да татарча бер сүз дә белми, мәгәр әтиләренә ияреп бер тапкыр «Зәңгәр шәл»не карарга барганы бар икән дә, татарлардан җырчы Ибраһимовны ярата икән... Бу инде зур казаныш иде!

—Нишләп барсын ул?

—Сез очрашмыйсызмыни?—диде каны кайнарлана башлаган Асаф Сәхипович.

—Әллә кайчаннан. Ул мин аңа өйләнер дип уйлаган. Әнисе шулай дигәнме, әллә минем әниме, белмәссең хатын-кызны... Кияүгә чыгудан бүтәнне уйламыйлар да...

—Ә син үзеңнең утыздан узганлыгыңны чамалыйсыңмы?

—Көн дә әйтеп торасыз ич...

—Өйләнергә уйламыйсыңмы?

Эдуард ягымлы елмаеп, гөнаһсыз зәп-зәңгәр күзләре белән әткәсенә туп-туры карады.

—Өйләнмим мин.

—Беркайчан дамы?

—Беркайчан да... Нигә өйләнеп торырга? Хатын-кызлар житәрлек. Бу дөньяда кеше саны болай да җитәрлек. Хәтта бераз артык та. Халык саны ишәйгән илләр өстендә бер-ике атом бомбасы шартлатканда да зарар булмас иде.

—Ни сөйлисең син?!

—Белеп, уйлап сөйлим. Үзең раслаганча, миңа утыздан арткан инде, тормыш тәҗрибәм җитәрлек. Әйт әнигә, миңа яңадан кызлар эзләмәсен. Көлке, честное слово! Өйләнгән кешеләргә карыйм да, не завидую! Кабалага кергән коллар! Шәхес буларак күмелгәннәр, беткәннәр... Ялгызлыкка ни җитә? Мин үземчә яшәргә телим. Гаилә—коллык...

Асаф Сәхипович шып туктады, сүз озайтуның мәгънәсе юк иде. Хәзер ни әйтсәң дә улың алдында җуләр булып кына калачаксың... Шулай да түзмәде Асаф, чыдары бетеп, ярсып:

—Чыгып кит! Югал күз алдымнан!—дип кычкырды.

Эдуард каршы әйтмәде, исе китмичә генә ишекне япты, озак та үтмәде, аргы зур бүлмәдән музыка тавышы яңгырый башлады, тавыш коридорны гына түгел, Асафның кабинетын да күмеп китте.

Телефон шалтырады, ул калтыранган куллары белән трубканы алды. Аргы башта дәшмәделәр, кемнендер борынын тарта-тарта җылаганы гына ишетелә иде...

Кичкә кырын врач килде, Асаф Сәхиповичны көндәгегә караганда да, озаклап, төпченеп тыңлады, башын чайкап куйды.

—Миңа эшкә чыгарга кирәк,—диде Асаф Сәхипович.

—Ярамый, кадерлебез, иртәрәк... Бүген йөрәк тә бераз атлыгып тибә. Димәк, тагын бер атна...

* * *

Суфия ханымның яшь чагындагы сылулыгын, аш-суга уңганлыгын, алдан күрүчәнлеген белдереп китү белән бергә, аның аерата сизгерлеген дә истә тотарга кирәк...

Ул бу яктан әнисенә—Фазыйла карчыкка охшаган диләр...

Фазыйла карчык дүрт мәхәлләле авылның имамы Шиһабетдин хәзрәт кызы булып үсә, утызынчы ел башында Шиһабетдинне хатыны, бала-чагасы белән Себергә сөрәләр, мал-туарын, йорт-җирен тараталар. Фазыйла әлерәк кенә яңь-яшь милиционер Кәримҗан белән танышкан була, шул милиционер аны саклап алып кала. Фазыйла Минзәләгә туганнарына утырмага китә дә, шуннан соң авылына кайтмый. Кәримҗан Фазыйлага өйләнә дә күрше районнарның берсенә барып урнаша. Ничек яшәргә, кемнәр белән аралашырга, кемнәрдән сагаерга, кемнәрнең җанына ничек итеп үтеп керергә кирәклеген аңа зирәк Фазыйла өйрәтә. Имзасын чатлы-ботлы гына куя алган, ертык шинель, ямаулы туннан ары кием-салым кимәгән, гомергә ачлы-

туклы яшәгән ярлы баласы Кәримҗанны Фазыйла көнгә чыгара. Укыта, карый, өс-башын рәтли, партиягә керергә киңәш бирә һәм алар иплəп кенә яшәп тә китәләр. «Ярлы баласы» булу, бик яшьли милициягә кереп совет властена «тырышып хезмәт күрсәтү», нәкъ Фазыйла әйткәнчә, гомерлегенә ярап куя Кәримҗанга. Аны күтәргәннән күтәрәләр, ул Фазыйла өйрәтүе буенча «ялкынлы сүзләр» сөйләргә остара. Митингларда, җыелышларда атылып чыга, бер чакта да тик утырмый... Почта атларын каршыларга һәм таларга чыккан бандитларның берсен тотып та биргәч Кәримҗанның абруе бермә-бер үсә. Аны ел саен кыска курсларга укырга җибәрәләр, партоешма секретаре итеп сайлыйлар. Тора-бара ул партия хезмәткәре булып китә, утыз җиденче елларда аның ярлы баласы булуы, бик күптәннән совет хөкүмәтенә тугры хезмәт итүе һәм тагын кайбер хезмәтләре аңа якты юл ача... Бераз вакыт ул НКВД начальнигы булып эшли, аннан тагын партия эшенә күчә, Казанда эшләп ала һәм сыналган иптәшне сугыш алдыннан райком секретаре итеп җибәрәләр...

Фазыйла иренә тугры була. Ул бер-бер артлы алты бала алып кайта, вак-тәяк эшләрдән баш тартып, хуҗалыкны, йортны һәм балаларны «кардәш апа»ларына тапшыра. Ул бистә бикәсе булып түр башында утыра. Райком секретаре хатынына эшләмәү килешмәгәнен дә ул яхшы аңлый һәм «чирлим» дигән хәбәр тарата. Кем райком секретаре хатынына каршы сүз әйтә ала? Район врачлары гына түгел, Казан белгечләре дә аннан «йөз төрле хаста» табалар һәм шуннан бирле Фазыйла йортта да, бүтән җирдә дә бер көн дә эшләми. Ул бөркет күзләре белән ирен, балаларын, улларын һәм кызларын күзәтеп тора. Кешедән сер алырга, гайбәтләрнең тамырына төшәргә ул шул кадәр остара ки, үзләре эшләгән районны гына түгел, Казан хәлләрен дә төбенә-тамырына хәтле белеп тора. Һәр елны Казанга, обком больницасына барып ай, ай ярым дәвамында дәвалана. Больницаның—сер җыя торган банк икәнен ул бик яшьли белеп ала.

Еллар үтә, балалар бер-бер артлы югары уку йортларына укырга керәләр. Алар белән район үзәгеннән генә торып күзәтү алып бару кыенлаша төшә. Фазыйла ирен Казанга, йә һич булмаса гел Казанга терәлеп торган районнарның берәрсенә эшкә күчү ягын кайгыртуны тыкырдата. Кәримҗан хатынының акыллы тәрәге икәненә инанган кеше буларак бу фикернең дә хаклы булуына шикләнмичә хәстәрен күрә башлый. Һәм алар теләгәнчә мәсьәлә хәл ителә дә. Кәримҗан Казан тирәсендәге районнарның берсендә райком секретаре булып эшләп ала. Суфия—төпчек кызлары югары уку йортына кергәндә алар инде Казанның үзенә үк килеп төпләнәләр...

Уллары урнашып олы кызлар кияүгә чыгып беткәч эш төпчек кыз Суфияга терәлеп кала. Төпчек кызны шәп кешегә бирергә тели Фазыйла! Шәп тә булсын, басынкы да, үзеннән алты яшькә кече Кәримҗан дөнья куйса, Фазыйланы карап, аны сыендырырлык та булсын. Баш балаларына бай урыннан, абруйлы кешеләр арасыннан туганлашу эзләсә, Суфияга ул кияүне түбән катлау арасыннан эзли...

Асаф Зәкиевнең комсомол өлкә комитетына килеп эшли башлаган елы гына иде әле. Шәһәр комсомол комитеты хезмәткәрләре яшелчә базасына кәбестә бушатырга барган җирдән кайтканда Фазыйлалар яшәгән урам аша кайттылар. Шунда, һич көтмәгәндә, Суфия уенын-чынын бергә кушып: «Бик тундык, әллә безгә кереп чәй эчеп алабызмы?»—дигән тәкъдим кертте. Өч егет, ике кыз бу тәкъдимне «ур-ра!» кычкырып каршыладылар, кабул иттеләр. Һәм бер кергәч җәелеп кенә чәй дә эчтеләр, Фазыйла апаларының бөркет күзе астында кайнар аш та ашадылар. Фазыйла өч егетнең өчесен дә бөртекләп, тикшереп карады һәм иптәшләре таралгач Суфияга болай диде:

—Син бу Асаф дигән егетне күптәннән беләсеңме?—Анасының юкка гына сорамавын чамалаган кыз кызарынып:

—Һәй, авыл мокыты ич ул! Җитмәсә миннән дүрт яшькә кечерәк тә әле.

—Әткәннең миннән алты яшькә кечерәк икәнен онытма!..Менә сина шул: иплəп кенә ул малайны кулга ияләштер. Аннан күз күрер.

Бер ел дигәндә Асаф Суфияга өйләнеп, атаклы Кәримҗанның кияве булып бабай йортында яши башлады.

Кәримҗан Сәфәргалимовның өлкә комитетында эшләгән бик абруйлы чагы, баш балалар кайсы кайда, төшемле, матур урыннарга урнашканнар, аралашкан, йөрешкән кешеләре дә менә дигән, сирәк кенә булса да мәҗлестә Үзе белән очрашкалыйлар.

Асаф Сәхипович шомарды, кашык-чәнечке тотарга өйрәнде, Кәримҗан ярдәме белән елдан-ел позициясен ныгытып, өскә үрли барды. Бәйрәмнәрнең берсендә, аерата тантаналысында, Суфия белән Асаф җизнәләре аркасында бик сирәк кешеләр генә эләгә торган, мөһим бер мәҗлескә эләктеләр. Мәҗлескә Үзе дә килгән иде. Шунда Үзе Асафка карап-карап торганнан соң йорт хуҗасыннан «бу кем?» дип сорады. Аңа «бүлектә инструктор булып эшли» диделәр. Үзенең кашы җыерылды. «Нигә инструктор гына? Куегыз Курамшинның урынбасары итеп!» диде. «Аның болай да урынбасарлары биш» диделәр аңа. «Яңа штат табыгыз, мин инструктор белән бер мәҗлестә утыра алмыйм ич!» диде катгый итеп Үзе...

Асаф Зәкиев министр урынбасары булды.

Башта ул бик аптырап калды. Үзенә тапшырылган өлкәдә ул бөтенләй әзерлексез, белемсез, шыр надан иде. Аптырагач бабасы янына киңәшкә керде. Инде кайчандыр «ярлы баласы» булып власть даулаган Кәримҗан матур гына түгәрәк корсак үстергән, иң яхшы тегүчеләр теккән киемнәре белән атаклы булган, әллә кемнәргә әллә нинди яхшылыклар эшли ала торган, депутат кына түгел, Верховный Совет президиумы члены да иде.

Ул төпчек киявенә кыска гына инструктаж бирде.

—Үз тирәндәге һәр кешенең йомшак ягын табарга тырыш. Һәр кешедә дә йомшак як була. Берәү мал ярата—андыйга бер төрле мөнәсәбәт уйлап тап. Берәү шыпырт кына эчә—аңа да ачкыч яратырга кирәк! Кемдер хатынкызга хирыс, аны да истә тот! Саран бар, мокыт бар, надан да янәшәңдә яши, ул да синең кебек үк чиннарны эләктергән. Ялагай бар, әләкче, шымчы, астыртын хат язучы, интриган, кимсетелгән, фахиш—һәммәсенең иң нәзек җирен—йомшак ягын эләктереп ал! Бер үк вакытта аларның да синең сереңне алырга, йомшак ягыңны тотарга тырышканын онытма! Үзеңнең йомшак ягыңны күрсәтмә! Берчакта да беркемгә дә сереңне ачма! Кеше серенә хуҗа булсаң—син җиңүче! Ике кеше янында бервакытта да ачылма, икәүдән-икәү калганда гына сөйләш, анда да авызыңны үлчәп ач! Гомере буе бер сүз әйтмичә яшәгән кешеләр дә балда-майда...

Бабасы әйткәннәрне арттырып үтәде Асаф. Аралашкан кешеләрен чикләде, олыларның, көчлеләрнең серен чәчмәде, җайлы кешеләр аша югарыдагыларга яхшы сүзләр генә ишеттерде. Үзе кирәкле булырдай кешеләрнең туган көннәрен, хатыннарының, балаларының исемен ятлап алды...

Судан коры чыгарга өйрәнде. Ахыр чиктә суга кермичә дә кала башлады. Андый кешеләр хакында «Сабан туенда көрәшкә кермәсә дә гомергә батыр исеме алып яшәде», дип сөйлиләр...

Кирәкмәгән кешеләр белән очрашканда аларны күрмәскә өйрәнде. Туптуры карап торса да аның күз карашы бөтенләй читкә таралган була иде. Җыелышларда, мәҗлесләрдә, бәхәсләрдә, пленумнарда, талашканда, фикерләр чәкәләшкәндә һавада ун тавыш йөзеп йөрсә дә, ул бары тик бер тавышны—иң кирәклесен генә ишетергә өйрәнде.

Һәм көннәрдән бер көнне министрны иплә п-сыйпап пенсиягә озаткач аны Үзе чакырып алды һәм:

—Сине министр итеп куябыз,—диде.

Үзенә карышып кара син, рәхмәт әйтеп башыңны и дә тын.

Үзенең хатыны—Казанның Беренче дамасы, министр дәрәҗәсе алган Асаф белән очрашкач, мәҗлестән кайткач: «Шул мокытны тәки күтәрдең»,— дип әрләп алды.

—Кыяфәтен кара син аның. Буе нәкъ минем буй! Ияртеп йөргәндә күңелле. Җыен кәтәнәләрне ияртеп йөри алмыйм ич инде мин,—диде Үзе. Көлеп алды, әмма аның сүзендә мәгънә бар иде: гөрес-мәрс ирләрне туплап, көчле төркем булып көтмәгәндә районга, хуҗалыкларга, райкомнарга барып керергә ярата иде ул.

Асаф Зәкиевнең шулай югары күтәрелүендә буй да аерым урын тотты, мәгәр бу житди эш бабасы Кәримжаннан, бик якын туганнарының булышлыгыннан башка эшләнә алмас иде, алар да ярдәм итте. Суфияның зирәклеге дә тиешле ролен уйнады. Суфия берничә мәртәбә бик яшертен генә йөри торган мунчада Үзенең хатыны белән бергә көн үткәргән иде. Югары дәрәҗәдәге кешеләрнең хатыны керә торган бу мунчада Суфия искиткеч тәкъдим кертте. Өч-дүрт хатын җыелалар да парда, саунада, бассейнда тәннәрен эретәләр дә, бөтен тәннәрен бал белән күмеп озак кына мәмрәп яталар. Суфия тәкъдиме белән эшләнгән бу эш Үзенең хатынына—Казанның Беренче дамасына ифрат ошаган иде.

Суфия үзе дә күркәм эштә. Хезмәт сараенда чит ил туристларын әзерләү бүлегендә эшли, ләкин ул асылда министр Асаф Зәкиевнең хатыны иде.

Гадәттә, җаваплы эштә эшләүче хезмәткәрләрнең хатыннары үзләреннән чак кына өлкәнрәк була, чөнки, гадәттә, ирләрне алар үзләре сайлап ала. Җаваплы эштә утырган кешенең хатыны башка хатыннардан бүтәнчәрәк яши. Ул берчакта да иренә кайда булдың, ник шулай тоткарландың, дип әйтә алмый. Ире кунарга кайтмаса да аның әрләргә хакы юк. Чөнки аның ире—ил тоткасы. Ул теләсә кайчан, теләгән вакытында кайтып керә, чыгып китә, чөнки ул—җаваплы дәүләт эшлеклесе. Аның мең төрле көтелмәгән бурычлары бар, Мәскәүдән, бүтән шәһәрләрдән килгән югары затларны каршы ала, аларның кәефен күрә, озатып кала. Кунаклар да әрсез, Казаннан буш кул белән китәргә теләмиләр, затлы тун да кирәк аларга, әйбәт бүрек тә булсын, хатыннарын да бүләк-күчтәнәч белән сөендерергә яраталар алар, ашарга-эчәргә дә каршы түгел. Казан хуҗалары нишләсен, алар алдында ярарга тырышалар, мәҗбүрләр!

Авыр, мәшәкатьле хезмәттән соң, кунаклар белән танга кадәр сыйланып утырып, хәлдән тайган иреңне әрләп каршылап кара син! Ярамый! Аның авыр язмышын түземле рәвештә бүлешергә генә кала.

Бер вакыт житте, Суфия ханым да олыгая башлады, муенына хыянәтче җыерчыклар алкаланды, куллар, бармаклар ябыкты, тәненең төрле урыннарына чуар-чуар пигментлар чәчелде. Чәч сирәкләнде, корсак ямьсезләнеп салынып төште. Асаф Сәхипович гайрәтле ир иде, хәзер дә үз көчендә калды. Суфия ханым Асафының кайда йөргәнен, хатын-кызлардан кемнәр белән очрашканын белә иде. Үзе теләмәсә дә министр белән булырга теләгән, аның белән якынлашырга омтылган хатыннар буа буарлык иде. «Министр!» дигән сүз үзе генә дә хатыннарның итәген очыртып йөрткәнен сизгер һәм зирәк Суфия бик шәп белә иде.

Суфияның элгәре шпионнары да бар иде, ул Асафның шоферларын бер җайга гына сатып алды. Шоферлар—министрның күләгәләре, алар күләгәдән аермалы буларак көндез генә түгел, кара төннәрдә дә арттан калмыйлар. Әүхәди атлы аумакай гына ир иде башта Асафның шоферы. Шуның аша Суфия ханым Гөлсинә хакында да белде, белгәнен чыгармады, түзде. Асафка кемдер кирәген, күңел юаткычы зарурлыгын чамалады. «Бер Гөлсинә генә хәвефле түгел!» Гөлсинәнең авылда яшәве дә аны тынычландырды.

Әүхәдинең ваклап-ваклап хатынына сатканын Асаф шактый озак белмичәрәк йөрде, сизенүгә бер көн тотмады—эшеннән куды.

—Күземә күренмә!—диде Асаф Сәхипович зәһәр яман тавыш белән. Әүхәдинең квартира чираты житеп килә иде, өстәлгә капланып җылады:

—Суфия апа бит... Бәгыремә төште, Асаф Сәхипович!—дип хуҗасына да серне ачты.

Ак димәде Асаф Сәхипович, кара димәде, ишекне генә күрсәтте.

Тәлгать авыр характерлы егет иде, үзе дә уенчак хатыннарны чит күрми торган шофер, Асаф Сәхиповичны яратты, сүзе аз булганы өчен дә яратты, шоферына ирек биргәне өчен дә якын күрде.

Суфия инде байтактан Тәлгать белән юньләп сөйләшми, сорашканы да юк, әмма бүген түзмәде, гаражга шалтыратты.

—Тәлгать, минем янга кереп чыгыгыз,—диде.

Тәлгать юк-бар сәбәпләр табып бармаска тырышса да Суфия ханым тешләгән жиреннән өзә торган иде.

Тәлгать килеп керүгә үк ул аны борып алды:

—Әйтегез әле, Тәлгать... Соңгы командировкада Асаф Сәхипович белән ни булды?

—Ни булсын?.. Искитәрлек берни дә булмады.

—Юк, мин синең ялганларга оста икәнлегенне дә, Асаф Сәхиповичны аяп калырга яратканыңны да, хәтта сезнең кайбер серләрегезнең уртак икәнен дә беләм. Минем болай гына калдырмасымны да аңлыйсың. Арага читләр керткәнче, мин бүтәннәрдән сорап бөтенесен дә белгәнче, үзен һәммәсен дә сөйләп бир.

—Бардык,—диде Тәлгать.—Кайтышлый Акъюл авылына кагылып чыктык. Кайтканда яңгыр яуды, батып яттык.

—Шул гынамы?

—Шул гына,—диде Тәлгать кинәт моңсуланган гөнаһсыз күзләрен тутырып карап.

—Әгәр берәр нәрсә яшергән булсаң, яхшылык көтмә, республикадан кудырырмын,—дип озатты аны Суфия ханым.

Тәлгать урамга чыккач тирән итеп көрсенде дә, бишенче кат тәрәзәләренә күтәрелеп карады. Тәрәзәләрнең берсенә капланып, аның өстенә кунардай булып Суфия ханым күзәтә иде.

Асаф Сәхипович белән утыз елга якын торган хатын ирендәге үзгәрешләрне күрми түгел иде, ул аның чирләп ятуының сәбәбе дә көтелмәгән хәсрәттән генә дип саный иде. Тик сәбәбен генә ачыклый алмады. Әлегә Суфия ханым үзенең бар танышларын, элемтәләрен эшкә җиксә дә, эзләнүе белән ирен җайсыз хәлдә калдыруыннан курка иде. Ирен уңайсыз хәлдә калдырмыйча гына барын да ачыкларга кирәк. Бары тик шул гына. Тәлгатьнең хуҗасын сатмаслыгын да белә иде ул, әгәр бүген Тәлгать Асаф өстеннән яман сүз әйтсә, ул аны шул минутта ук иренә җиткереп эшеннән кудыртыр иде. Ләкин, кызганычка каршы, Суфия ханымның шулай кыланасын Тәлгать тә бик яхшы аңлый иде. Ул да беренче ел гына аралашмый иде шул югары баскыч араталарында!..

* * *

Йөрәге кысып-кысып ала да, авырту сул беләккә күчә, кабырга астында ниндидер борчулы төер хасил була, арка сөяге тирәләре чымыр-чымыр килә. Телефон шалтырады исә Асаф Сәхипович кабаланып барып житә, йөрәк кагышы ешая, мангаена тир бөртекләре бәреп чыга: Гөлсинәме? Нишләп йөри ул Казанда? Нигә кайтып китми?.. Асаф Сәхипович үзенең чирләп ятуына рәхмәт тә укыды: нигәдер Гөлсинә белән күрешәсе килми иде аның, очрашудан курка иде, шикләнә иде. Хәтта үзенең Гөлсинә янына кагылып чыгуына да үкенә башлады. Хатын-кызга мохтажлыгы бар идеме, нигә аяк калдырып, бәла-казаларга очрап барып керергә иде?.. Хәзер тыптын гына, эш, гаилә, картлык хакында уйлап ятыр иде шунда...

Бер яктан авылга кайтырга кирәк...

Икенче яктан Гөлсинәнең хәлен дә караштырырга кирәк.

«Хатын-кызга мохтаҗлык» дигәннән. Гөлсинә Асаф Сәхипович өчен гади бер сөяркә генә идемени?.. Әгәр шулай булса, нигә Гөлсинә кияүгә чыкмады, тәкъдимнәрне кире какты, сирәк-мирәк очрашуларга да искиткеч канәгать булып, шул сирәк-мирәк эләккән очрашу бәхете өчен дә Асафка ихлас рәхмәт укып, аңа тугрылык саклады. Хатынына ышанмады Асаф, мәгәр Гөлсинәнең хыянәтсез мәхәббәтенә ышанды. Бәхетле булган ич ул Гөлсинә белән! Бик күп ирләр шундый тугрылыкны, ихлас, эчкерсез мәхәббәтне татымыйча дөнья куялар. Гомумән, җитәкче сфераларга үрләргә теләгән натуралар тормыш, мәхәббәт нечкәлекләрен аңламыйча яшиләр. Тормыш мәшәкатьләре, власть өчен көрәш, властьны яулап алгач аны саклап калырга тырышулар кешенең максатын чикли, аның табигатенә катылык, шәфкатьсезлек сыйфатларын сеңдереп ныгыта. Яшертен уйлар белән яшәргә мәҗбүр итә.

Август үтеп китте, сентябрьгә керделәр. Көннәр көне-сәгате белән үзгәрә торды. Асаф Сәхипович эшкә чыкты. Министрлыкның отчетын өлкә комитеты бюросына әзерләргә туры килде. Тагын бер атна узды. Җомга көнне, эш сәгате бетәр алдыннан секретарь кыз:

—Асаф Сәхипович, сезне Совет районы милициясеннән сорыйлар,—диде.

—Тыңлыйм,—диде Асаф Сәхипович тыныч булырга тырышып.

—Хәерле көн, Асаф Сәхипович. Сафиуллин әле бу, Совет районыннан.

—Ә, исәнмесез, Рәфгать Камалиевич.

—Монда бер күңелсезлек килеп чыкты бит әле...

—Туктагыз, мин хәзер барып җитәм...

Асаф Сәхипович Сафиуллин янына кош булып очып барып җитте. Ул кергәндә полковник янында яшьрәк кенә, озынча буйлы, йончыган кыяфәтле бер лейтенант утыра иде, Асаф Сәхипович кергәч ул ялт кына урыныннан торды, ләкин чыгып китмәде. Сафиуллин өстәлдә таралып яткан документларны сул кулы белән каплагандай итте...

—Тыңлыйм, иптәш полковник.

—Эш болайрак әле, Асаф Сәхипович.

«Нигә чыгып китми инде бу какча лейтенант?!»—Моннан дүрт көн элек сезнең танышыгыз Гөлсинә Мостафина апасы Гасимә Яруллина квартирасыннан чыгып китә... Һәм Мостафинаның бүгенгә кадәр кайтып күренгәне юк. Аның кайдалыгын беркем дә белми...

Бусы бөтенләй көтелмәгән яктан искән әшәке җил иде.

—Нигә мине чакырырга булдыгыз алайса?

Сафиуллин ирен чите белән көлемсерәде дә какча лейтенант белән таныштырды.

—Лейтенант Петров. Ул шушы эш белән мәшгуль.

—Асаф Сәхипович, сез безне гафу итегез,—диде Петров.—Мин эшегезгә дә кереп чыга ала идем, кинәштек тә, сезнең белән монда очрашуны кулайрак таптык.

—Аңлыйм,—диде Асаф Сәхипович, гәрчә берни дә аңламаса да. Сүзне полковник түгел, Петровның алып китүе аңа аңлашылмады да, ошамады да...

—Мостафина чыгып киткәндә «хәзер кайтам», дип әйтеп калдырган. Үзе белән акча алмаган, документларының һәммәсе апасында, өсте дә юка гына: күлмәкчән, беләгендә юка гына жакет булган.—Петров полковник алдында яткан кәгазьләрне үзенә табарак тартып, өстәлгә якынрак килеп утырды.

—Мин ни әйтергә тиешмен?—диде Асаф Сәхипович көтелмәгән җилнең җимергеч давылга әйләнә баруын чамалап.—Нигә мине чакырдыгыз?

Бу сорауга Сафиуллин җавап бирде.

—Кәгазьләр арасында Мостафинаның куен дәфтәре дә табылды. Ул бик кыска-кыска гына кайбер фикерләрен беркетеп калдырган. Арада сезнең исем дә килеп чыккалады, Асаф Сәхипович. Ашыкмагыз, без сезгә гаеп ташларга җыенмыйбыз. Ялгыз хатыннарның күркәм ирләргә мәхәббәте булуы бик ихтимал. Безне бер нәрсә кызыксындыра: соңгы мәртәбә Гөлсинә Мостафина белән кайда очраштыгыз? Ниләр сөйләштегез? Ул үзенең алдагы планнары хакында аны-моны әйтмәдеме? Казан шәһәрендә апасыннан тыш аның якыннары бармы?..

Петров хәзер кәгазьләрне Асаф Сәхипович утырган яккарак эшереп җибәрде. Асаф ирексездән Гөлсинәнең паспортын кулына алды, «улмы?» дигәндәй ачып карады. Ул! Ике төрле фотосы бар, соңгысы—ун ел үткәннән соң ябыштырылганында ул элеккегә караганда да яшьрәк күренә әле. Чибәр! Томырылып аңа текәлеп карап тора. Ул паспортны ябып, әмма кулыннан ычкындырмыйча гына уйланып торды. Монда инде Суфия гына түгел... Алар һичшиксез Тәлгатьне дә чакырачаклар, Асаф командировкада узган маршрутны җентекләп өйрәнәчәкләр, арага теге төнге хулиганнар да килеп керәчәк... Аларга бүләк ителгән эчемлекләр дә телгә керәчәк... Монда стенага терәгәч, яканнан алгач гадел дөреслектән башка котылмак юк!

Ул түкми-чәчми бөтенесен дә сөйләп бирде. «Хатын-кыз итеп түгел, иске дус итеп, күңел белән сагынып кына кердем», диде.

Казанга кайткач та берничә тапкыр шалтыратуын, көнеленең кая барып бәрелергә белмичә тинтерәвен, газапларын әйткәләде, «очрашыйк, сиңа бер сүзем бар!» диде... Тик, чирләп ята идем, очраша алмадык, диде. Тәлгатьне җибәреп кайтаруын да әйтте.

Полковникнын сул кул ягында торган зәп-зәңгәр телефон шалтырады.

—Тынлыйм,—диде полковник.—Менә хәзер минем янда утыра ул, иптәш генерал.

«Димәк, бу эш белән генерал да кызыксына!» дип уйлап өлгерде Асаф Сәхипович.

—Юк, иптәш генерал...

Сафиуллин «юк», «әйе», «шулай булса кирәк», дигән кыска-кыска җаваплар биреп утырса да Асаф Сәхипович эшнең шактый тирәнгә китүен, чуалчыклануын аңлады. Ул чын көнеленнән рәнҗеде, Гөлсинәгә үпкәләде. «Нигә кеше төсле генә тәмамламадың безнең танышлыкны?» дип эченнән генә кабатлады.

—Асаф Сәхипович,—диде Петров.—Алайса сез шоферыгыз Мирзануровны чакырып торунын хаҗәте юк дип исәплисезме?

—Мин сезгә бар булганны әнәсеннән җебенә хәтле сөйләдем.

—Гөлсинә Мостафина кайда булыр? Кая китәр?—дип гөман кыласыз?..

—Белмим.

—Хәтерләгез әле, ул төнге очрашуда, соңгы күрешүегезне әйтәм: «көтелмәгән, гайре табигый хәлләргә ишарә ясамадымы? Акылы, зиһене сәламәт идеме?..»

Асаф Сәхиповичның соңгы көннәрдә чирдән сары йөгергән киң маңгаена тирән сырлар ятты.

—Мондыйрак бер уе булды булуын,—диде ул авырлык белән генә сүзләрен тезеп.—«Туйдым дөньядан! Әллә шәһәрләрнең берәрсенә барып, трамвай астына ташланасы инде! Гәүдән изелеп бетсен, беркем сине танымасын, белмәсен!», дигән иде.

Сафиуллин белән Петров бер-берсенә караштылар.

—Сез монда сөйләгәннәрнең һәммәсен дә бик җентекләп, көнен-сәгатен күрсәтеп минем исемгә язып бирегез инде,—диде полковник. Петров аның каршысына ак кәгазь җәеп салды, ручка чыгарды.

Асаф Сәхипович укый-яза торган күзлеген алмаган иде, өстәлгә иелеп, шактый саллы тукмак борынын кәгазь өстендә йөртә-йөртә шактый интегеп язып бетерде.

—Әгәр дә Гөлсинә Мостафина хакында бер-бер хәбәр ишетсәгез, зинһар, шушы телефон белән шалтыратыгыз,—диде Петров.—Мин булмасам, Галләмов булыр. Без ул эшне бергә алып барабыз.

Петров Асаф язганны да, бүтән кәгазьләрне дә барлап, хушлашып чыгып киткәч, полковник белән Асаф беравык сөйләшмичә утырдылар.

—Асаф Сәхипович,—диде Сафиуллин.—Сез бала-чага түгел, монда сезнең гаебегез бардыр дип уйламыйм... Әхлак, мораль ягын үз көнелегез белән хәл итәрсез... Әмма мәсьәлә бик җитди. Бу араларда югалган кешеләр ишәеп китте. Әллә бер-бер җинаятьче группа пәйда булды инде?! Аңлагыз, сезне, дәрәҗәгезне аяп, без белгәннәребезне читкә чыгарырга тырышмабыз. Сез дә үз ягыгыздан хәрәкәт итегез:берәр нәрсәне сез ачыклый алмассызмы?

Асаф ашыгып-ашыгып эзләшергә вәгъдә биреп милициядән чыгып китте. Ишек катында утырган дежурный ул үтеп киткәндә аягүрә басып честь биреп калды.

Мондый хәлдә авылга кайтып китү турында уйларга да ярамый иде. Әллә нинди хәлләрнең килеп чыгуы бар. Асаф Сәхипович югарыдан тәкъдим ителгән кыска командировкадан да баш тартып, сәламәтлеге какшауга зарланып, өйдә калды. Урынбасарлары берәм-берәм уйлап, ялгыз башка фараз кылып, икешәрдән очрашканда шыпырт кына сөйләшкәләделәр:

—Хуҗаның ни... кәефе юграк...

—Үзгәрә кеше! Тимер багана иде бит!

—Алтмышка җиткәч юкка гына пенсиягә чыгармыйлар инде.

—Картая кеше!

Бер-берсенә ышанырга тырышкан урынбасарлар болай дип тә өстәделәр: «Политбюро членнары һәм министрлар бер чакта да картаймыйлар!»

Асаф Сәхипович көннән-көн биреште. Төннәрен шабыр тиргә батып уянды, төш күреп саташып кычкырып Суфияны тәшвишкә төшерде. Врачлар Зәкиевләр квартирасына ешладылар, бу хәлгә Эдуард та игътибар итте.

—Нәрсә,—диде ул бер иртәне әнисенә,—безнең картка пенсиягә китәргә вакытмы?

—Авызыңнан җил алсын!

Суфия фикеренчә Асаф Сәхипович әле министр булып һич югы житмешкә кадәр утырырга тиеш иде. Ул ашыгыч чаралар күрергә кереште: шәһәрнең атаклы медицина әһелләре карады Асаф Сәхиповичны, консилиум үткәрделәр, больницага кереп ятырга кинәш иттеләр, Кырым-Кавказ якларын урап, һава үзгәртүнең дә файдасы турында искә төшерделәр. Әмма Асаф Сәхипович беркая чыкмады диярлек, дачасына бармады, балыкка чыкмады, ни кызыктырсалар да гөмбә җыярга яратуын да онытты. Ул һәр минут, һәр секунд куркып-шүрләп милициядән хәбәр көтте. Әгәр Гөлсинәнең сүзләре чынга чыгып үзен-үзе харап итеп ташласа?.. «Уголовный гаебең булмаса да, асылда рухи яктан син гаепле булып чыгасың?!» дип өзеп әйтте ич теге чакта полковник Сафиуллин.

Илле сигез яшенә җиткәндә, бөтен шәһәр генә түгел, республика сине белгәндә, югары сфералар сиңа тәмам ышанганда, эше гөрләп үк бармаса да бүтән республикалар белән чагыштырганда ким-хур булмаганда, ел йомгакларын ясаганда ике ел рәттән аңа орден эләккәндә генә, яманатың кеше арасына чыкса...

Ул урынбасарларын, бүлек мөдирләрен ешрак җыйды, эшкә иртәрәк килде, соңрак кайтып китте, таләпчәнлеген көчәйтте, инструкторлар, аларның ярдәмчеләре, гади хезмәткәрләр командировкалардан кайтып кермәде. Асаф Сәхипович уйламаган районнарга шалтыратты, җирле җитәкчеләрне пошаманга салды, каты куллы, усал теллегә әйләнде.

Бер көнне Петров шалтыратты.

—Асаф Сәхипович, мин әле бу, Петров. Сез беләсездер дә инде...

—Нәрсә белим? Каян?!

«Министр булгач та минем шәхси шпионнарым бар дип уйлый ахрысы бу лейтенант!»

—Табылды Мостафина.

—Ничек? Кайда?

—Исән-сау, ләкин зиһене югалган, хәтере калмаган... Аны Зеленодольск янында, көймә астыннан балыкчылар табып китергән... Хәзер психбольницага салдык...

—Рәхмәт.

Ни өчен рәхмәт әйтте ул аңа? Асаф Сәхипович шушы сүзе өчен соңыннан байтак кыйналды... Ләкин бүтәнчә ни әйтсен?.. «Тәгаен Гөлсинә Мостафинамы?» дип кенә сорый алды.

—Апасын чакыртып күрештердек. Районнан фатир апасын да алып килдек... Икесе дә таныдылар. Апасы: «Шул явыз гына харап итте аны, шул гына!» дип кочаклый-кочаклый җылады. Фатирчы апа да исемен атамыйча гына кемнедер каргады... Ләкин, Гөлсинә Мостафина бу сүзләргә дә бернинди реакция ясамады...

Соңгы сүзләрендә кемне күз алдында тотканын Петров яшереп тә тормады... «Лейтенант... Министрны тешләргә җай чыкканда кинәнеп кала!» дип аның хакында усал гына уйлап алды Асаф һәм аның фамилиясен күңелендә беркетеп калдырды.

* * *

Сөенечләрнең бер-бер артлы килгән чагы була. Сөенечләр бер-берсенә ялганалар да күңелдә олы бер сөенеч туа, аның бәрәкәте шактый озакка

бара, күңелгә бетмәс җылылык өстәп, кеше гомерен бизәп тора... Бер-бер артлы килгән хәсрәтләр бергә ялганмыйлар, алар күңелдә аерым-аерым яшиләр, зуррак хәсрәт кечеләрен йота бара, кече кайгылар белән баеган олы кайгы берзаман күңелне кимереп торучы кара көчкә әйләнә. Сөенеч тора-бара исемен югалта, күңелдә исемсез сөенеч кенә тора, аның барлыгын беләсең, нидән, каян килеп күңеленә кунуын уйламыйсың да, рәхәт, күңелле яшисең, бары тик шул гына. Ә кара кайгы күңелгә исеме белән ертып килеп керә, кайгының адресы, каян туувы, дәвамы—һәммәсе ап-ачык булып күңелдә саклана.

Әтисенең вафаты, аның үз үлеме турында улына хәбәр итмәскә кушуы, үлем хакында Асаф Сәхиповичның шактый соңарып, гафу ителмәслек дәрәҗәдә сонга калып ишетелүе зур хәсрәт иде. Әйе, авылдашлар алдында оят, намуссызлык. Исән чагында үз атаңны җирләргә дә кайтма инде! Битне кызартырлык вакыйга!

Ләкин, бу хәбәрне ничә кеше белә дә, күпме халык моны ишеткән?..

Әйе, «әти янына кереп чыктым, хәлен белештем», дип ялганлавы да тормышны чуалта, телдән ычкынган һәр ялган язмышны катлауландыра... Ләкин, монда да түзәр чама бар икән әле... Суфия бер тузыныр, ике үпкәләр дә тынар. Министр хатыннары ирләрен саклый белә, кеше арасына чыкканда Суфия Асафны ашарга бирмәс, ыжгырып яклап чыгар. Өлкә комитеты секретаре хатынының ире өстеннән шикаять белән килеп йөргәне юк, министр хатыннары да телләрен тыя беләләр... Хатыннары язучыларны, бухгалтерларны һәм домуправларны гына ашый!

Яшьли сөйгән дустың, көннәрдән бер көнне, көннең иң күңелсезендә «дөнья куям!» дип үз ихтыяры белән кайлардадыр саташып йөри икән, бу инде уен түгел. Моңарчы булган хәсрәтләре вак-төяк булды да калды Асафның.

Кайгының шул хасияте бар, ул кешенең йөзенә чыга, холкын үзгәртә, кайгы кичерүче кеше аның җан үзгәрешләрен бөтен кеше белә, тик аяп, әдәп саклап кына белмәмешкә салышып йөри дип уйлый. Кайгы—хыянәтче ул, кешенең рухын изә, түбәнәйтә, кайгылы кеше саклыгын югалта.

Нык булырга тырышып карый Асаф, барып чыкмый, аның атлавы, аяк адымнары гына түгел, тавышы да үзгәрде. Моны Суфия, Эдуардлар гына түгел, хезмәттәшләре, югары урыннарда утыручылар, Тәлгать, көндез ашарга кергән ашханәдәге аш ташучы кызларга кадәр белделәр. Алар Асаф Сәхиповичка хәзер икенче күз белән кызыксынып һәм кызганып карыйлар иде.

Бу кайгы китә торган кайгы түгел иде, бу кайгы бүтән хәсрәтләрдән өстен чыгып, Асафның күңелен тулысынча биләп алды, хәзер ул гомере буе шушы кайгыга уралып яшәячәк.

Ни эшләргә тиеш хәзер ул?.. Гөлсинәне күреп сөйләшер өчен больницага барырга тиешме? Барса?.. . Бармаса?.. Врачлар Гөлсинәнең үткәне белән, аның тормыш юлындагы вакыйгалар, вакыйгаларның сәбәпчеләре—якын кешеләре белән кызыксынмый калмаганнардыр?! Дөрес, үзе берни дә хәтерләми диделәр. Ә апасы? Фатир хуҗасы? Асаф Зәкиевнең исеме Гөлсинә язмышында калкып чыкканмы? Ни дәрәҗәдә калкып чыккан?.. Врачлар, шәфкать туташлары аны эт итеп сүгәләр булыр, сүгәләр дә каргыйлардыр... Әмма Асаф Сәхиповичның үз кичерешләре аларның сүгү-каргауларыннан мең тапкыр артыграк икәнне беләме икән алар?..

Ул эштән хәзер бер ялгызы, җәяү генә кайтырга тырыша. Җомга көннәрендә аңа мәчеттән намаздан кайтып килүче сөйкемле, пөхтә татар картлары очрый. Ул аларны туктап көтеп ала, үтеп киткәч тә озак кына карап тора. Ул үзе Ибраһимнарда утырган картларны эзли. Ләкин Казан зур шул, картлар ишле, каян килеп тегеләре очрасыннар Асаф Сәхиповичка!..

Шулай да бер көн ул аларны очратты. Биш-алты кеше иплəп кенә аның каршысына киләләр, бүтәннәр таныш түгел, мәгәр картларның икесе аның танышлары, Ибраһимнардагы утырдашлары иде. Ул алар каршысына килеп

басты, бабайлар да тукталдылар. Алар өсләренә юка бишмәтләр, плащлар кигәннәр, башларында һәммәсенен дә түгәрәк бүрекләр, аякларында читеккәвешләр иде. Кулларын артка куеп ярым алка ясап тукталдылар да Асаф Сәхиповичка сәлам бирделәр. Таныдылармы, юкмы? Танымадылар ахрысы. Ул «Тәбәрәк» сүрәсен тәэсирле итеп укыган картка карады һәм һич көтмәгәндә:

—Сез мина кирәк идегез,—диде.

—Тынлыйм сезне, туган—диде карт бераз читкәрәк китеп, аның юлдашлары күндәм генә көтеп, тукталып калдылар. Аларның төркем һәм бердәм булып, ниндидер беркем дә белмәгән дөнья серләренә хужа булган шикелле басып торуларыннан көнләште Асаф. Кайгылары булса да болар аның кебек яна-көя торганнардан түгел, аларның өметләре, яклаучылары, ышанычларытәнреләре бар! Шулай уйлады министр Асаф Сәхипович һәм бабайлардан нык көнләште...

—Минем әтием вафат!

—Сезгә хәсрәт килдеме?

—Кайчан? Хәзерме?

—Түгел... Күптән инде. Май азагында.

Карт ирен читләрен кыймылдатып кына дога укып алды, ияген сыпырып куйды. Асафны баштан аяккача карап алды.

—Коръән укытырга уйлыйсызмы? Бик күркәм эш, үлгәннәрнең җаны өчен, тереләрнең күңеле ак булсын өчен укырга кирәк аны...

—Тик менә ничек?! Өйдә хатыным һәм улымның белүен теләмәс идем мин.

—Алай икән,—дип куйды карт һәм бераз уйланып торгач ихлас тавыш белән әйтте:

—Ә сез иртәгә татар зираты капкасы төбенә килегез,—диде.—Без өйлә намазыннан соң шунда барырга тиешле. Мәет куясыбыз бар.

—Сәгать ничәгә?

—Сәгать өчтә анда булыгыз.

Асаф Сәхипович вәгъдә биреп, килешенеп өенә кайтып китте. Юл буена аны бер уй борчыды: чыннан да теге дөнья дигәннәре булып, хәзер аның әтисе ләхетендә рәнжеп ятса? Керәшен зиратында куйганнары өчен дә рәнҗесә? Улының соңгы бер уч туфракны салырга кайтмавына да рәнҗесә!!. Бәлки аның соңгы сүзләре булгандыр? Нигә чакырып кайтармаган инде шунда?! Нигә Җәгүр аның сүзен сүз итеп Асафка хәбәр итмәгән!? Ул эткәсенә рәнжеп, Җәгүр яшьтәшенә ачуланып, өенә кермичә озак кына йортлары тирәсендә әйләнде.

Эштән кайтып килүче Ибраһимны күрде, аңа кушсаң картлар белән очрашуны ул җиренә җиткереп һәм беркем дә белмәслек итеп оештыра алыр иде. Әмма Асаф икеләнеп торганнан соң, Ибраһимның да белми калуын мәслихәт күрде.

Икенче көнне ул зиратка бармады. Шикләндеме, курыктымы, әйтеп булмый, мәгәр барыр сәгать житкәч хәле китеп, арып, кулларын күн креслоның сыртына җәеп салып, күзләрен йомып, сөремле мунчадан чыккан шикелле җебеп-йомшап озак кына кабинетында утырды, беркемне кабул итмәде, телефоннарга «юк!» дип әйтергә боерды.

Бу Асаф Сәхиповичның бишенче квартирасы. Ул хезмәтендә шушы биек баскычка үрмәләп менеп житкәнче биш урын алыштырды, бишенче квартирасына—соңгысына күчте.

«Моннан туп-туры инде зират дигән әүлияләр шәһәренә!» дип шаяртты ул квартирага күчкән көнне. Һәм шушы, иң соңгы квартирада кем беренче булып котлар икән дип көтеп торды. Аның дәрәҗәсендәге кешеләр, күршеләр, каршылар, янәшәдәгеләр, өстәгеләр, астагылар—һәммәсе үз мазаларына чумдылар. Беркем Асаф Сәхиповичның ишеген какмады, беркем керептә: «Нихәлләрегез бар?» дип кызыксынмады. Үткән-сүткәннәр, ашыкканда баш кагып исәнләштеләр, аяк кагып кына котладылар да һәркем үз өенә кереп бикләнде. Туган-тумачалар өй котларга иртәгә чакырулы, бүген үз иткән,

күз күргән кешеләр килеп китәргә тиеш иделәр. Инде өмет өзелде дигәндә, эч пошудан бер-ике чәркә коньяк эчеп суынган эчне жылыткач ишектә звонок яңгырады. Урыныннан ашыгып кубарга яратмаган Асаф Сәхипович бу юлы шактый ашыгып ишекне үзе ачты һәм аптырап туктап калды...

Әле бик түбәндә, бүлектә гади инструктор булып эшләгәндә ул Гафур Бикчурин дигән егет белән танышкан иде. Икесе дә янарак кына тормыш корып, өйләнешеп, туйларда йөрешеп, шактый якынаеп киткәннәр иде. Шуннан Асаф тиз арада диярлек өскә үрли башлады, Гафур һаман шул элек эшләгән урынында калды, үрләргә тырышмады да шикелле, начальствога яраклашырга маташмады, телле-тешле булды, яхшы эшләгән кешене алып та ата алмадылар, күтәрелергә дә ирек бирмәделәр..

Дәрәжәләр аерылган саен аралар ераклашты. Гафур әллә кайда түбәндә калды.

Урын, квартира алышынган саен аның танышлары, аралашкан кешеләре, йөргән юлы, больницасы, ательесы, ял йортлары, кунакханәләрдәге бүлмәләре тулысынча алышынып беттеләр. Үсеп, ныгып, властьны үз кулына ныграк ала барган клан, аның чордашлары бер иярткәч беркемне дә үзләреннән калдырмадылар. Асаф Сәхиповичны шактый якын күреп йөргән, ара-тирә биллиард уйнаганда партнер саналган бер иптәш көлемсерәп:

—Иң соңгы дигән квартираларга урнашабыз—һәммәсе искиткеч! Тик монда авыл тирәсеннән килгән гыйбадларны, вак-төяк таныш-белешне генә түгел, әти-әнине дә кертергә һәм күрсәтергә ярамый. Безнең квартираларны күргәч һуштан язарлар,—диде. Асаф Сәхиповичның күнеленә дә шундыйрак уй килгән иде.

Әле Казан шәһәренең иске урамнарында—Яңа Бистәдә, Бишбалтада, элекке Сорочий базары тарафларында, бүтән төбәкләрдә никадәрле кеше юеш подвалларда бакалар, күселәр һәм кумаклар белән өйдәш булып яшәгәндә, Ватан сугышы инвалидлары юньле бер бүлмә артыннан йөри-йөри хәлдән таеп тәгәрәп үлгәндә, торыр урын юклыктан яшьләр өйләнә алмаганда, өйләнешкәннәр тавыш-гаугa чыгарып аерылганда өч жанга биек-биек биш бүлмә, ике туалеты, бәләкәй малайлар футбол уйнарлык кухнясы булган квартирага кереп утыру, лотереяда ожмахка билет оту белән бер иде...

Партнерның ярым уйнап әйткән сүзе дә, Асаф Сәхиповичның икелемикеле уе да фатирга ныклап кереп утыргач онытылды, алар һәммәсе дә бергә төйнәлгәннәр һәм мондый фатирлар хаклы рәвештә аларга гына тиеш дип ышаналар, бүтәнчә уйлый да алмыйлар иде. Бүтәннәрнеке кебек үк Асаф Сәхиповичның ишеге дә ата-анасына, туганнарына, чакырылмаган бөтен кешегә һәрвакыт ябык иде. Аскы катта, иркен һәм житез лифт тирәсендә сак өзелми, кизү милиционерлар начальствога ярарга тырышалар, аларга: «Беркемне кертмәскә!» дип боерылган иде. Андый-мондый кеше килеп чыкса: «Фәлән-фәләновичмы? Ул өйдә юк!» дип күзгә карап саескан очыралар иде.

Жәгүр моны белә идеме, Сәхип абзый улының жирдән, халыктан аерылып, ожмахның бишенче катына менеп утыруын аңлаткан идеме ана, Жәгүр жаен табып кунакханәгә урнашкан, шуннан шалтыраткан булып чыкты...

Дачада, чәй янында, Асаф сүз югында сүз булсын өчен генә, аннан-моннан сүз чүпләп буш жөмләләр укмаштырып утырганда:

—Авылда кемнәр белән аралашасың? Кемнәр белән йөрешәсең?—дип сораган иде.

—Ничек кемнәр белән? Туганнар белән аралашасың инде, жанга якын дуслар да бар. Дөрес, авыл бик таланды, халык калмады диярлек. Яшьләр юк. Ләкин бергә яшәгән яшьтәшләр, чордашлар әз-мәз бар әле. Аларны ничек ташлыйсың? Менә яшьлек дуслары, дип язалар... Нигә бер дә «картлык дуслары» хакында әйтмиләр. Картайгач дуслар сирәгәя, бер үк вакытта кадерләре дә арта, Асаф яшьтәш. Ә син кемнәр белән аралашасың?..

Әлбәттә, ул кемнәр белән аралашуы турында Җәгүр алдында җәелеп тормады...

Яшьлек дусларыннан берсе Гафур Бикчурин хәтеренә килеп төште... Асаф Сәхипович җанын авырттырып Гөлсинә турында уйлый иде. Гафур белән икәү командировкага барганда Гөлсинә белән танышканнар иде алар. Бөгелмә аэропортыннан алар барасы районга тәгәл илле биш чакрым икән, әле асфальт юллар юк диярлек, юллар чокырлы-чакырлы, автобус иске, калтырап, зәһәр төчкерә-төчкерә сөйрәлә, бара-бара да туктап хәл җыя. Гафур белән Асафтан алдарак ике яшь кыз күңелле сөйләшеп, сирәк-мирәк егетләргә борылып карап баралар иде. Егетләргә аларны да үз янәшәләренә алырга туры килде. Күз карашлары гына кызларны канәгатьләндермәде, алар сүз каттылар. Егетләр елмаеп җавап бирделәр. Алар ике пар бер үк урынга баралар икән. Кызларның Нәфисә исемлесе кунакка медицина училищесында бергә укучы Казан кызы Гөлсинәне алып кайта икән, ә егетләр комсомол эше белән командировкага баралар. «Безнең авылгамы?» диде Нәфисә. «Сезнең авылга!» «Казаннанмы?» «Шуннан инде, шуннан!»

Кызларның берсе, кыюрагы Гафур янына килеп утырды. Асаф аның урынына Гөлсинә янына күчте. Кызлар янәшәдә утырганда шактый чаялан-ганнар иде, берәм-берәм калгач, сүзсез калдылар, ярдәм сорагандай бер-берсенә карап, тыйнак кына елмаеп, шул елмаюлары аша нидер аңлашып шактый бардылар. Менә автобус төчкереп тагын туктады, шофер: «Чишмә бар монда! Су эчәсе килгәннәр төшә!» дип белдерү игълан итте. Халык бүселеп чыга башлады. Гөлсинә белән Асаф, Гафур белән Нәфисә житәк-ләшеп чишмә янына барып та җиттеләр...

Көн яп-якты, кояшлы, чишмә суы көмеш, халык арасында кыенсынып барган егетләр кызлар белән танышып, кыска гына арада исемнәрен белешеп, адресларын алышып, Казанга кайткач һичшиксез күрешергә вәгъдәләр беркетеп өлгерделәр. Гафур озак вакыт автобусның үшән булуына, юлларның начарлыгына, чишмә буеның матурлыгына рәхмәт укыды, алар бер елдан өйләнештеләр дә тату гына гомер итә башладылар...

Гөлсинә, Гөлсинә...

Зәңгәр күзләрен каймалаган озын керфекләрен бер тибрәтеп җибәрсә теләсә нинди егетне дә шып туктата ала торган кодрәтле чибәрлек иясе Гөлсинә... Асаф кыз белән нык ук мавыкты, моңарчы егет кулы тотып карамаган сылу Гөлсинә аңа шашып гашыйк булды... Күркәм егет иде Асаф! Чын күңелен ачмаска өйрәнеп килгән, кешеләргә, бигрәк тә хатын-кызларга каты күңелле Асафны яшь кыз бөтен барлыгы, кырыслыгы, корылыгы, хаталары белән үзенеке итте. Гафурлардан күрмәкче алар да өйләнергә тиешләр, быел көзгә туй!

Шәфкать туташы дигән диплом белән Гөлсинә өйләнешүләре турындагы таныклыкка да ия булачак. Аның Асафы бар, сөйгәне! Кадерлесе, бердәнбере!..Моңарчы кызлар игътибарын, яшьлек мавыгуларын татыган, тормыш мәктәбенең ачысын-төчесен татып өлгергән Асаф кыз күңелендә нинди урын алуын аңлап та, бәяләп тә өлгермәде. Тормышта бик сирәк очрый торган, бары тик бөек җаннарга гына хас кайнар мәхәббәт очраган иде аның юлында. Хатын-кызларның бик күбесенә эләкмәгән саф, кайнар йөрәк тибә иде Гөлсинә исемле татар кызының күкрәгендә... Иң беренче мәхәббәте керәшен кызы Миңнешне, поляк кызы ятимә Лида Вжеснев-скаяны Гөлсинә янәшәсенә куеп карый да чагыштыра Асаф. Юк, моңарчы аның юлында Гөлсинә кебек риясыз, саф күңелле, юмарт тере җанлы кыз очрамаган икән әле... «Нәфисә шәп, мәгәр синең Гөлсинәң Нәфисәдән дә шәбрәк!» дия иде аның сөенечен уртаклашып Гафур Бикчурин...

Һәм алар кәбестә чистартып яшелчә базасыннан бергәләп кайтып баралар иде... Чәй эчәргә Суфияларга барып керделәр... Яшьләр чәй эчеп, аны-моны капкалап утырганда Фазыйла карчык Асаф дигән егетне бер кабуда йотты...

Аның бер минут тормыйча, шушы сәгатьтә Гафур Бикчуринны күрәсе килде. Кайда эшли икән? Һаман шул урынбасар булып калганмы? Югары күтәрсәләр ишетелер иде, күчәр башлары орынмый калмас иде, шунда утырадыр, бахыр. Квартирасын да яхшырта алмагандыр. Өч баласы, хатыны Нәфисә белән Восстание урамында, эшчеләр арасында яшәп ятадыр бичара...

Восстание урамын каһәрләнгән «Тасма» берләшмәсе көне-төне агулап утыра. Берләшмә елдан-ел киңәя, Казан халкына агу тарата торган корпуслары арта тора. Җил искәндә Мәскәү, Ленин районнары өстенә газ, агу, зарарлы матдәләр ява. Силикат заводыннан бөркелеп чыккан сасы ис белән «Тасма» берләшмәсе тараткан агу форточка-төннекләр аша квартираларга керә, духовкада пешкән ризыкларга кадәр үтеп, аларның тәмен үзгәртә. Киров районында әфлисун төсле куе төтен чәчеп утырган заводларның агуы да җил белән монда килеп җитә, бугазларны буа, күкрәкне кыса. Врачлар Мәскәү, Ленин районнарында яшәүчеләр арасында рак авыруларының бермә-бер артык булуын язып та чыкканнар иде шикелле. Асаф Сәхиповичның танышлары арасыннан инде берәү дә ул зарарлы урамнарда яшәми, алар берәм-берәм ару якка, Чехов базары тирәләренә, Совет районына күчеп беттеләр. Ульянов урамы тирәсендә югары катлау вәкилләре өчен зиннәтле йортлар салынды. Ул йортлар кеше күзенә кереп, күнелләрне тырнап тормасыннар өчен ширдый-бырдый халыкка, урта кул җитәкчеләргә багышлап Вишневский урамының ике ягына, шырпы тартмаларын әле яткызып, әле торгызып бер-берсенә охшаган котсыз игезәк йортларны тезеп утырттылар...

Адреслар бюросыннан Гафур Бикчуринның кайда яшәвен ачыклап, троллейбуска кереп утыргач, юлда Асаф Сәхипович әнә шулай уйлады...

Гафур белән алар яшьтәшләр...

Бер чорда, бер кояш астында, бер үк рәхәтлекне, кимчелекне тоеп яшәделәр. Бер үк законнарга буйсындылар. Бер ил, бер шәһәр, бер милләт кешеләре. Ә чагыштырып, уйлап карасаң тормышлары нинди төрле-төрле аларның! Тик күпчелек кешеләр язмышка ансат буйсыналар, үз тормышларының көйсезлегеннән зарланырга яратсалар да югарылар белән чагыштырып карамыйлар. Югарыдагылар шулай яшәргә тиеш дигән колларча фикер йөртү күпчелеккә бик борынгыдан килгән. Берәүләрнең зиннәтле пулатларда, дәүләт исәбенә салынган иркен, бай дачаларда яшәп ятуына нәфрәт белдереп аваз салган кешеләрнең очраганы бармы?.. Күрәләр, шыпырт кына эчтән сүгенәләр, йодрык җиндә, ә йомгак ясап, хөкем итәргә көч җитми, рух түбән..

Ленин районының жиргә сеңгән, көне-төне машина шавы астында утырган ялгыз йортларына карап Асаф Сәхипович бүген нигәдер шулай уйлады...

*Ахыры киләсе санда.*



**Илдус Гыйләҗев**

# ГОРУРЛЫГЫН ЮГАЛТМАГАН ҖАНЫМ

## Киметегез саныгызны

“Йөз кырык биш миллион кеше бар,
Дип, Рәсәйнең тынчу сандыгында”,—
Бик тә ялгышасыз. Мине—кыстырмагыз,
Бергә киметегез саныгызны да:
Канга баткан, хәсрәт баскан илдә
Килми генәм гомер кичерәсе...
Ничек кенә ата-бабам корган
Тирмәләргә кире күченәсе?!
Һәм яшисе азат бөркет булып,
Иминлеген саклап күгебезнең.
Бөтенлеген яклап, данын хаклап
Татарстан дигән Илебезнең!
Шул дәүләтнең халкын барлаганда,
Иң беренче мине күрсәтегез:
“Һәр кешенең җаны тәне белән
Бергә йөрсен!”—диеп кисәтегез.
Гәүдәм генә йөри Рәсәй буйлап...
Күпләр әйтер:—Әллә шашканмы бу?

Кем өлешен яшим?
Үз җаным бит
Туганда ук күккә ашкандыр күк...

Илдус ГЫЙЛӘҖЕВ (1946)—*шагыйрь, “Җир китабы”, “Өмет ае”, “Хак сүз” һ.б. китаплар авторы. Азнакай районы Түйкә авылында яши.*

## Без күп тә бит...

Чыңгыз, Бату явы белән
Татар атлы халык килгән.
Кара халык—сарык, көтү...
Орышка да алдан кергән.
Алтын Урда таралгачтын,
Кемдер кире кайтып киткән.
Татар дигән исемнәре
"Йогып калган безгә" күптән.
Бүген алар—иреклеләр...
Уйламый да безнең хакны.
...Күпме татар яши җирдә
Кыргыз, үзбәк, казах атлы...

## Белмәсәң, бел

"Мин үзем кадәр әле!
Кизәнмә..."
*Равил Фәйзуллин*

Дала исе аңкый миннән,
Бабаларым—төрки-кыпчак.
Савап булыр—без, аларны
Искә алып, дога кылсак.
Болгар атлы халыкның да
Чаткылары миндә уйный.
Шул дәвернең төсе итеп
Саклыйбыз ич Сабантуйны!
Алтын Урда мәмләкәте
Уйларыма салган киңлек.
Тарих юлын турыласак,
Аңлашыла безнең кемлек.
Дөрес булыр, алда өмет,
Яктылык бар әле дисәм.
Ханлык бетсә, Казан калган!
Димәк әле татар исән!
Шулай булгач, Былтыр[1] сүзен
Кабатларга хак бар минем:
—Бу җегет абзаң булыр бу,
Бик белеп тор син, энем!

## Белеп язам

Белеп торам, кемдер бу шигырьгә
"Милли" диеп тамга саласын.
Соң, җаныем, нәслең татар булгач,
Татар булмый кая барасың.
Яхшы атлы булам диеп кенә
Ят кавемгә, дингә күчимме?
Татар—бөек! Шуны аңлатырга
Юнәлдерәм барлык көчемне.

[1]Сүз Г. Тукайның "Шүрәле" әкиятендәге батыр турында

Тәрҗемәләрен дә булдырмаслар—
Дөрес сүз бит миргә китәчәк...
Татар булса—яшәр! Шигъри фикерем
Татар бетсә генә бетәчәк...

## Коры куаныч

Парижны бит урыслар да,
Нимесләр дә басып алган.
Ни могҗиза, бүгенгәчә
Халык исән, дәүләт калган.
Испаннар да гарәпләрдән
Җиңелгәннәр, зыян күреп.
Ә дәүләтен халык саклый
Батырларча, данга күмеп.
Безнең дәүләт кая киткән,
Ник югалган—Казан чүккәч?
Халкы яши исәңгерәп,
Сәлам биреп һәрбер чүпкә.
Горур булган кавем генә
Матур яшәр, дәүләт тотар.
...Мин болай да бөек диеп,
Саташа шул кайчак татар!..

## "Милләтләр зираты" яки телевизор караганда бер уй

Телимме мин, теләмимме—
Мәҗбүр карарга.
Урыс бии, урыс шаша
Һәрбер каналда.
Юкмыни соң бездә тагын
Башка милләтләр?
Бар бит әле дуслык дигән
Олы кыйммәтләр.
Экраннарда фәхешлек һәм
Эчү ярышы.
...Татарлыгын югалтмаган
Җаным карыша.
"Рәсәй—төрмә",—диләр иде
Элек халыклар.
Зур зиратмы әллә бүген?
Әйе... хаклык бар...

## Уйласаң, уйланырлык

Ул сугышлар нигә кирәк булган,
Кан коеп та, акыл тапмагач?
Үлем газапларын күрә торып,
Кешеләргә кадер артмагач?!
Ул җиңүләр нигә кирәк булган,
Юлыбызга бәхет чәчмәгәч?—
Егылган ил халкы үзебездән
Мең мәртәбә затлы яшәгәч...

## Юньсез тарткалаш


Туйлар узып, кияү-кәләш
Бергә яши башлагач,
Гаиләдә кем өстен дип
Китә көрәш, тарткалаш.
Көрәш булгач, кемдер инде
Җиңелергә тиештер.
Мәсьәләне нәсел-ыру
Ачыкларга керешер.
Нәтиҗәсе тиз күренер:
Булган әйбер—бүленер.
Бала-чага ятим калыр,
Чит кулларга бирелер.
Минем белән килешерләр
Гомер иткән кешеләр:
Гаиләдә көрәшмиләр,
Гаиләдә—яшиләр...

## Әлегә түзәм

Син бит әле мине сагынмыйсың,
Күз салмыйсың киткән юлларыма.
Тулган айга карап моңаймыйсың,
Күз яшеңне сөртеп юрганыңа.
Син бит әле мине сагынмыйсың,
Кат-кат укыймыйсың хатларымны.
Дога көйли-көйли сорамыйсың
Яннарыңа кире кайтканымны.
Син бит әле мине сагынмыйсың,
Мин дә түзәм—хисләр бирешсә дә...
Сагынасыңны беләм! Көне җиткәч,
"Килеп әйтер миңа фирештәләр"...

## Күрәзәче булмасам да

Мин әйткәннәр сиңа килеп бара:
Ялгышасың, дидем—ялгыштың.
Нәтиҗәсен, әнә, күреп торам—
Күзләреңнән ага сагыш-моң.
Барма дигәндә дә, тыңламадың,
Күрәчәгең тартты—ашкындың.
Бер йомычка булдың уртасында
Үкенечләр тулы ташкынның.
Кире кайт дип күпме үгетләдем,
Колак салмый үттең—тискәре.
Ә үзеңне тормыш чоңгыллары
Алып кереп китте әчкәре.
Кисәттем бит юкса, ә бит үзем
Күрәзәче булып тумаган.
...Мәхәббәттән качып бәхет тапкан
Кеше әле җирдә булмаган...



## Әхәт Гаффар

## ХИКӘЯЛӘР

### Утын

Иртән Миннур Дияров болдыр баскычында утыра иде инде. Өйгә кереп барган Фрау атлы мәчеләрен тотып алып, ул аның аркасын сыйпарга, колак артын кашырга тотынды. Әле генә суелган ике яшь әтәч белән сугым пычагы тотып, җиләк-җимеш бакчасының ян капкасыннан чыгып килүче атасын күргәч, йөзен читкә борды. Ул әтәчләрнең җансыз асылынып төшкән муеннарыннан капка төбендәге шома, чиста ташка тамган ике-өч кан тамчысын шәйләп өлгерде. Атасы Шәехнең:

—Утырасыңмы, улым?—дип соравына җавап кайтармады. Аны болдыр ишегенә уздырып өчен баскыч читенәрәк шуышты.

Атасы, ана ияреп, мәче дә эчкә кереп китте. Миннур әтәчләрнең идәнгә йомшак кына шапылдап төшүләрен ишетте. Кулын югач һәм бераз гына өйдә югалып торгач, ата кеше аның янына чыгып утырды.

—Тартып алыйкмы әллә?—диде ул.

—Юк әле—дип, Миннур кире какты.

Шәех учы белән чиста баскыч тактасын сыйпады да:

—Җылы монда,—диде.

—Күз әйбәт килгән икән.

Улының болай әйтүе ата кешегә сәеррәк тоелды. Күңел төбенә боз кисәге шуып төшкәндәй булды. "Анын өчен туган авылындагы көз "килгән" генә. Ә минем өчен ул күз алдымда килде",—дип уйлады ул.

Чыннан да, көн кояшлы иде. Ә менә Шәехнең җаны шомлы, караңгы ук. Уллары кичә генә кайтып керде. Шәех үзе һәм хатыны Сания шул якты шатлыкны йокы пәрдәсе белән араларга теләмичә, таң беленә башлаганчы керфек какмый чыктылар. Хәзер дә: "Бу баланы ни көтә инде?" дип, көн арты көн җыелып килгән сагыш хисенең таралырга исәбе юк әле. Караңгы төннәрне уяу тота, ә якты көннәрне сүрән итә торган ул сагышның иге-чиге бардыр ич

---

Әхәт ГАФФАР (1948)—*прозаик, драматург, публицист. «Әҗәт», «Гозер», «Язлар моңы», «Яшиселәр алда иде» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

инде анын, әй? Шөкер, ни булса, шул булган инде. Ни хәл итмәк кирәк. Улынын яманрак хәлгә дә юлыгуы ихтимал иде бит әле дип куанырга гына калды.

Ул яман хәлнең ни белән очланырга ихтимал икәнлеген Шәех уйлап бетермәде. Дөнья менә хәзерге шикелле жылы, үз хәлләре алай ук жиргә ятып еларлык түгел икән, тагын ни кирәк? Әйе, биргәненә шөкер.

—Әһә, улым. Көз әйбәт. Бар нәрсә житеш. Бер генә нәрсә яман—дөнья буталчык.

Шулай, Шәех арттырмый. Житешен дә житеш. Тик, болай дип ният корган буласың да, шунда нидер чәлпәрәмә китереп ташлый. Калган гомернең ни белән очланасын да белгән юк. Шул ук вакытта зарлансаң да гөнаһ. Менә ич, уллары исән-сау кайтты. Хәер, исәнлеккә исән, саулыгы гына... чамалы дияр идең, тик Аллага шөкер әле, күз тимәсен. Бөтен гаилә белән үз өендә кунасың икән, моннан да житешрәк тагын ни бар?

—Бәрәңгегез уңмаган икән. Окопны ачып караганыем,—диде Миннур.

"Окоп" дигән сүзгә сәерсенеп, Шәех кулын, кайнар нәрсәгә тигәндәй, баскыч тактасыннан тезенә күчерде. Моны Миннур шундук абайлады да сүзен:

—Базны инде, базны!—дип төзәтте.

Шәех, улын сагайтуын сизеп, кулын тагын баскыч тактасына төшерде. Әмма учы жылы тоймады инде. Такта, кырау төшкәндәгечә, чәнчеп-чәнчеп алды шикелле.

—Булганы житә-ә-әр,—дип сузды ул. —Быел сугымга ике яшьлек үгез, дүрт бәрән бар. Шуна өстәп—ике оя каз. Дөнья тулы тавык-чебешен дә куш,—дисә дә, Шәех бу араларда күнелен борчып йөргән уйларын әйтеп бетермәде. Житешен-житеш тә бит... житсен өчен хәзер бер пот тоз ашарга кирәк. Житкәннең ин зурысы—калган гомер инде анын. Дөнья йорты—михнәт йорты ул. Әй, ярар сана! Аты коргыры дип сүгенергә калганмы?! Шуна күрә Шәех, тавышын күтәреп, сүзен шат кыяфәттә:—Менә шул: туйга артыгы белән житә, Алла теләсә,—дип очлады, улын жилкәсеннән кочып, кулын шапылдаткалады.

—Туйга?—дип сорады Миннур аңа таба кырт борылып.—Кем туена?

—Ят сүзме әллә? Кызган тимерне вакытында сугарга кирәк аны! Мин үзем армиядән соң буйдак килеш озак йөрмәгәнием.

—Ул син бит...

—Күктән белен яуганны көтәргәмени? Сиңа ни житмәгән?

—Чак кына житми, әти, чак кына.

Ата кеше тыенкы гына көлеп куйды:

—Азан әйтми камәт төшермиләр дисенме?

Киң ишегалдына талгын жил килеп керде. Миннур инбашын жыерып, иненә салган кысан пинжәгенә иркенәебрәк сыярга теләгән шикелле, бөрешә төшеп утырды, сул жинен бот арасына кыстырды.

—Күр дә тор, килеп чыгар әле, әһә. Ни житкәнен-житмәгәнен шунда чамаларсың. Күз генә тимәсен, сөбханалла күренә ул. Миннурыйны әйтәм... Аны кулдан ычкындырасы түгел. Моннан ары ан бул. Алла бирсә, Миннурыйны үзебездән арттырмаска исәп. Хәер-фатиха... Өй—ындыр табагыдай иркен. Яна мунчанын нинди леген кичә үзен сынагансыңдыр.

Жил ургымы ишегалдына коелган тупыл, алмагач яфракларын кугалады. Ләкин аларның күмәк кыштырдавы Шәехкә улының тешләрен шыгырдатып кысуын ишеттерми калмады. Бер үк мәлдә жил Миннурдан атасының авыр сулап куйганын да яшерә алмады.

—Ярый, улым. Трактор тирәсендә чуалып кайтыйм инде,—диде Шәех.

Күнел түрендәге авыр уйларын сиздереп, баскычтан уфылдап күтәрелә язуын искәрде дә, жайлабрак утырган булды. Чалбар кесәсеннән таушалган сигарет кабы чыгарса да, кире тыкты.

—Каяле, кичәгенәк синеке катырак тоелганые шикелле,—диде ул.

Миннур янтайды да пинжәгенен уң кесәсеннән сигарет кабы кармалап алды, аны кисәк каккач, бәреп чыкканын атасына сузды. Ул аны угалап, иренենә капкан арада, газлы кабызгычын яндырып жибәрде.

Улының кабызгычын сүндерүен, затлы сигарет кабын баскыч култыксасына куюын күреп, Шәех:

—Үзен дә көйрәт, улым. Жанын басылыр,—диде.

—Ярый алайса,—дип килеште Миннур.

"Юатма сана!—дип өстисе килгән иде дә, тыелып калды. Атасы яшь шул

әле. Кырык бердә генә. Белгән кадәресен генә белә. Ә менә ул, Миннур, күреп кайтты. Күрмәгәнен күрсәтteләр.

Ата белән ул, һәркайсы үзенекен уйлап, бераз сүзсез утырдылар.

—Фермадан кайткач, әнкәң әтәчләрне чистартып куяр,—дип, Шәех урыныннан кузгалды.—Абзарда тәкә калдырдым. Кара аны, ашатасы-эчертәсе түгел. Үзең беләсең. Мин озак буталмам, кайткач хәл итәрбез.

—Торсын иде әле, әти.

—Нәзере шундый аның. Син кайтырга исәпләнгән. Дус-ишләрең белән утырасыгыз бар.

—Мина бирер эш юктыр ич?

—Ниткән эш ди әле ул?! Иркенләп ял ит, туйганчы аша-эч... Әһә, тавыкларга өч-дүрт уч бодай сипсәң генә инде.

Миннур кинәт ярсуланып:

—Эчсәм ярыймы соң?—диде.

—Тегене... нитмә генә... исермә. Сеңелкәшләрең килештермәс.

—Ә син?

—Эштәге егетләргә сөенче итеп, бер шешә эләктердем мин. Шунда күз күрер.

Капканы үзе сыярлык кына ачкач, ата кеше улына әйләнеп карады. Ул аның элек нинди икәнен яхшы белә иде, ләкин алда кем буласын начар чамалый әле.

Ялгызы калгач, Миннур агачлардагы яфракларның шыбырдавын, атасы ишегалдын иртүк себергәч коелганнарының кыштырдавын тыңлап утырды. Ишегалдын күз алдыннан кичереп, кулы, җаны тансыклаган бирер эш эзләде. Табалмады. Ансыз да бар җирдә тәртип икән. Йорт-җир нык. Болдыр юылган. Абзар-кура тирәсе чиста. Лапаста яңгырдан ышыклап, салам түшәлгән пөхтә печән чүмәләсе тора. Мунча түбәсе астына утын ярып өйгәннәр. Тәрәзәсенең утын белән ничек каймаланганына игътибар итте: пулемет оясымыни... Бөтенесе аннан башка эшләнгән. Аны көткәннәр. Тик ни уйлап көтсәләр, шулай көткәннәре күзгә бәрелеп тора. Югыйсә аның өлешенә дә эш калдырырлар иде.

Ул түзмәде, өйгә кереп, аракы эчте, тозлы кыяр кетердәтеп чәйнәде, аяк астында сырпаланган мәчегә ит кисәге ыргытты. Яңадан болдыр баскычына чыгып, сигарет кабызды. Шунда утын өеменең сукыр капка ягына терәлгән өлешендә ярмыйча гына тезелгән бер дистә чамасы имән пүләннәренә күзе төште. Утын яра торган юан бүкән дә шул турыда. "Туктале, ярып карыйм әле",—дип уйлады ул. Җаны сискәнеп китте. Сигаретын төкереп сүндерде дә, тычкан сизеп сагайган мәче шикелле тын гына атлап, шул тарафка юнәлде. Калун балтаның мунча алачыгында икәнен кичә мунча кергәндә абайлаган иде. Шунда кергәч, калунның тупас сабына үрелгән иде дә, аның белән утынны ничек ярырга кирәклеге исенә төшеп, балта алды. "Үткер",—дип уйлады ул аның йөзен чамалап. Бусына канәгать калмады. Үткер балта пүләнгә бата гына бит ул. Ярыр өчен кат-кат бәрәсе була.

Чыкты. Пинжәген иңеннән кузлага кагып төшергәннән соң беренче пүләнне бүкәнгә бастырып куйды. Учына төкереп, бармакларын угалап торды, балта сабына ябышты. Кыска селтәнеп, балтаны пүлән уртасына каптыргач, аны инбашына терәп әйләндерде дә тутәне бүкәнгә китереп орды. Ишегалдында йөргән әтәч, шул тавыштан өркептер инде, гөлдерәп куйды. Абзар ягыннан тәкә аваз салды.

Шул рәвешчә ике тапкыр китереп бәргәннән соң, пүлән шыгырдап ярылды, яртышар-яртышар булып, бүкәннән җиргә мәтәлеп төште. Ярылган төшендә аларның үзагачы, еллык боҗраларыннан сузылган юллары шома, ялтыравыклы, матур иде.

Аларны яра алуына сөенә-сөенә ваклап тураклагач, ул бүкәнгә яңа пүлән утыртты. Анысы ике аерлы иде. Җинел ярылсын өчен кыскарак кискәннәр. Шулай да биш тапкыр көчәнеп бәргәннән соң гына бирешге.

Өенчесен яргалап бетергәч, карашын үзе ярган утын күченнән алалмыйча, ул сигарет тартып утырды. Әчкелтем агач исе тәмле иде. Сагындырган да икән. Утын исе кояш астында кибеп яткан яфраклар исен дә басты.

Җанына рәхәт булып китте. Солдат күлмәге арка тиренә юешләнгән, тәненә ябышкан. Күкрәк уемыннан бер-бер артлы эре тир бөртекләре тәгәрәште. Күзен әчеттергән маңгай тирен ул әледән-әле сул җиңе белән сөрткәләде.

"Әни сөенер инде,—дип уйлады ул.—Әти ни әйтер икән? Мәктәптә укучы

сеңелкәшләре дә аннан күз карашларын яшерергә тырышмас инде, ятсынып караудан туктарлар бәлки".

"Ә мин сөеним микән соң? Әйтерең бармы?"—дигән соравына күңеле җавап бирмәде. Болдырда салкын су эчеп төшкәч, балтасын янадан баш турысына күтәреп, бәрер алдыннан төзәп торганда арттан үзенә эндәшкәннәрен ишетте:

—Миннур...

Тавыш иясенең кем икәнлеген шундук танып, ул балтасын түбән төшерде.

—Синме?—дип сорады ул карлыккан тавыш белән. Аркан әйләнеп карамады. Карарга шикләнгәнен сизде.

—Исәнме!

—Саумы.

—Мине кичә көттеңме?

—Кичә.

—Килеп булмады. Дежур идем. Бер апа бик азапланып бәбәй тапты.

—Шулай. Постны ташламыйлар.

—Йә, борыл инде!

Аркасына кул орынгач, Миннур туныц китте.

"Чепуха!—дип уйлады ул.—Күлмәк тиргә чыланган. Шул туңдырды".

Әмма борылды. Миңнурыйга ничек борылмыйсың ди? Ул бит—Миңнурый!

"Мин—Миннур, ә ул—Миңнурый. Ике исем—бер язмыш",—дип шатланды ул, тегендә иң моңсу чакларда искә алып, үзенең язмышы дип хыялланган, ә моннан соң кем булачагы әлегә билгесез кызны күз алдында күргәч. Миннур эндәшмәде. Болай да билгеле, күренеп тора ич инде.

Кыз, аның уен дәвам иткәндәй:

—Исеңдә тот: минем кызгануымны мәңге көтмә,—диде.

Миннур болай гына, сүз булсын өчен генә:

—Ни көтәргә соң?—дип сорады.

—Сөю генә... Хәер, юк...

Шуннан соңгы кыска тынлык Миннурга бик озын тоелды. Киртләч-киртләч таш-тау арасындагы бушлыкны тоташ ядрә уты астында йөгереп узарга әзерләнгән чакта шулай булучан иде.

—Хәер, юк,—дип кабатлады кыз һәм, оялган шикелле, карашын читкә күчерде.—Юк нәрсәне генә көтәләр. Син монда. Мин дә шушында. Мин син булган җирдә һәрчак булырмын.

Шулай дигәч, Миңнурый көтмәгәндә аның күкрәгенә сыенды. Бу юлы ул Миннурның күкрәген туңдырып җибәрде инде. Үз сүзеннән кайтырга теләмичә, ул тагын: "Күлмәк юеш. Шул туңдыра",—дип уйлады.

—Кайттыңмы?

—Җибәрделәр.

—Кайткан булгач, нигә кочмыйсың?

—Кул буш түгел.

—Балтаңны куй.

Миннур балтасын сак кына бүкәнгә яткырып куйды. Тик кулы бушаса да, кызны кочакларга барыбер базмады.

—Оныткансың,—диде Миңнурый.

—Онытмадым.

—Алайса нигә үпмисең?

—Онытканмын.

—Ә мин онытмадым.

Һәм Миңнурый, күзен йома төшеп, аның ирененә үрелде. Бу юлы аның сарылып кагылуы Миннурны туңдырган кебек итмәде. Әйтерсең лә ул үз исемен нилектәндер онытып, янадан хәтерләгән сыман, күңеленнән әллә кайчан җил булып таралган үбешү тәмен исенә төшерде, шул үбешүнең әсиренә әйләнде. Болай булганы бар иде инде. Армиягә алынганчы, Миңнурыйны капка төпләренә кадәр озаткан кичләрдә. Әзгә генә, кыяр-кыймас, тансыклап кына, моның ни икәнлеген белер-белмәстән, ихтимал бер бәхет мизгеле төсендә тоеп кына.

Шуларның бөтенесе исенә килеп төште, җәйге чилләдә авыр эштән соң салкынча үләнле җылы җиргә ятып хәл алгандай булды. Сул кулын күтәрде, аның нинди үләнгә, нинди җир кантарына тигәнен тойгандагыча, хәзер дә нәрсәгәдер орынганын сизде, шул сизүнең тәненә дә, җанына да рәхәт икәнен искәрде. Гүя учы җылы туфрак кисәгенә орынды, шуны кысты, таратырга

теләп угалады. Ләкин әлеге туфрак, юеш кантар сыман, уч төбеннән шуып чыга иде.

Чыннан да, Миңнурый үз тәнен аның сул кулы ягыннан үзе дә белештермәстән ятсынып читләштерде, ерагайтырга теләде. Хәзер нидер Миннурыйның тойгы-кичерешенә туры килмәде бугай. Шуңа күрә ул үз иренен Миннурыйның иреннән аерды, оялгандагы кебек, күз карашын түбән юнәлтте һәм кызның ачык ак халаты астындагы зәңгәр күлмәгенең калку урынын ничек итеп назлаганын күрде...

Очрашу һәм тансык назлану газапка гына әйләнеп калды. Ул Миннурыйның күкрәген үз кулының өзелгәннән соң чит жирдә күмелеп калган өлеше белән сыйпаган икән!

Миннур читкә сикерде, озын жинен селтәп, кыздан кулын каплады, аркан борылды. Кандагардан ерак түгел аяк астында мина шартлаганда "Әни!" дип, әллә ыңгырашкан, әллә уйлап кына өлгергәндәге кебек:

—Чыгып кит!—дип кычкырды.

—Ни булды?

—Кит дим, кит!

—Миннур!

—Ки-и-ит...

Ишегалдын төнге госпитальдәге сыман тынлык басты. "Мин—Миннур, ә ул—Миңнурия. Бер исем—ләкин ике язмыш икән инде",—дип үкенде ул бу юлы. Һәм, таң сызыла башлаганын хәтерләтеп, кызның пышылдап:

—Тагын кабатлыйсыңмы?—дип сораганы ишетелде.

—Кит, Миңнурый!

Агач яфракларының жирдәгеләре тын иде, ә агачтагылары салмак кына шыбырдашты. Әйтерсең лә аларны кыз белән егетнең тирән-тирән итеп сулаганнары жилфердәтә иде.

Шунда Миннур, окопка иңгәндәгечә бөрешеп, кинәт иелде, чүкте, кулы белән колагын каплады. Ул ташлар арасыннан миләш чыпчыгыдай күтәрелеп чыгып, үзенә таба томырылган гранатаның кабызгычы шартлавына охшаган аваз ишетте. Авызын ачты да тынын кысты. Дүрт секундтан соң кулларын төшерде, тезендә калкып, киң ишегалдына карады, аннары турайды, башын гына борып, артка караш ташлады. Анда-монда айкалган күз алмалары бер ноктага төбәлгән килеш хәрәкәтсез калды. Һәм бүкәнгә чабылган балтаны, аның йөзе янындагы чәнти бармагы очын күреп алгач, күзен йомды. Аннары кинәт ачты. Башы әйләнеп китте, күңеле болганды. Кыз сул кулын учлап, түшенә кыскан, беләге буенча агып төшкән ал кан юлы ак халатының жиңенә житеп җәелә иде.

Миңнурый, иреннәрен кысып, күкрәк түреннән саркып чыккан тавыш белән:

—Моннан соң... кит дигәнең саен... тагын дүрт тапкыр шушылай булыр...—дип пышылдады.

## КАЗЫЙНЫКЫЛАР

Ул әллә кайчангыдан иялләшкән, гадәтләнгән вакытында уянып китте. Болай дип тә әйтеп булмастыр—уяттылар: өйләре тирәсен ата-бабаларыннан калган тал, тупыллар әйләндереп баскан, аларны әллә ничәмә кара карга өере сырып алган. Әнә шулар сызылып таңнар атканда дәррәү каргылдашырга керешә инде. Әллә кайчангы истәлек хатирәләрен төшенә кереп, иң татлы берәр күренеш, хис мизгеленә ирешкән мәлендә хәтмәле өркетеп уяткан шикелле итәләр.

Аның каруы шул мәлдә үк йорт-кура артындагы инде кыргыйланып беткән куе чия бакчасында сандугач сайрап торып жибәрә. Әнкә сандугачлар сайрамый. Алар сабыр гына үз көмешләрен көтеп торучан. Әлеге асыл кошның аваз салуы дәвамында каргаларның каркылдашуы да һичкайчан тотылмаган бакыр акча кебек тоныкланып кала.

Вәдүт берара тегесен-бусын ишетеп тыңлап ятты әле. Көннең аяз, эссе буласын ул күзен ачуы белән үк башта тойды, аннары күрде.

Ул иплэп кенә җәелгән урыныннан торды да, үзе генә белгән, үз-үзенә

Аллаһы Тәгаләгә, ахирәттәгеләргә, исән-сауларга әйтә торган догасын багышлагач, үзләренең бакчалары ызаны буйлата агып төшкән чишмә суында тешен чистартты, кырынды, кулын, битен юып алды. Тегe-бу хаҗәтләреннән соң үзе төндә йоклап чыккан болдырга кереп, шундагы газ плитәсенә ут кабызды да, чәйнеккә чүмечләп чишмә суы салгач, утка куйды, ул кайнап чыкканчы, баскычка утырып, "Ява" сигаретын тартып алды.

Ишегалдын баскан кычытканны, әрекмәнне бер тапкыр чабып, кипшенгәч җыйнаштырып куйган иде инде. Карасана, ни арада тагын баш төртеп чыкканнар да янабаштан буй җибәргәннәр икән. Шулай инде: өйләрендә әниләренең вафатыннан соң торучы юк. (Әтиләре сугыш җәрәхәтеннән иде.) Һәр бирмеш көндә йөреп, җылы табан асты белән шомартып такырламагач, чистартып себермәгәч, йорт-кураны чүп үләннәре, төрледән-төрле чәчәкләр басымчак итә.

Су кайнап чыкканнан соң чәй ясагач, өйалдына кереп, ул чаршау артында яткан энесенең бил чамасына аягы белән төрткәләп:

—Тор, Вәлиша. Җиләккә барасы бар,—диде.

—Нитмә әле, җәме!—дип, Вәлиша теге ягына әйләнеп ятты.

Әмма торды әле, ишегалдына чыкты да, якты көнгә, кояшка карагач:

—Бүген эссе була икән. Мин җиләккә барып тормыйм,—диде.

—Алайса кышкы зәмһәрирдә кайтып җыярсың инде. Мин челләдә җыеп кайтыйм әле,—диде Вәдүт. —Чәй кайнады, ясалган, эч.

—Җарар,—диде Вәлиша.

—Яхшы. Мин әйләнеп кайтыйм инде.

—Алай-болай була калса, кайда йөрерсең?

—Бу юлысы—Карама чокырында. Алай-болай булмас, борчылма. Яхшымы?

—Җахшы,—диде Вәлиша.

Ә Вәдүт өйалдына кереп, унике литр сыешлы эмаль чиләген алды, җиләк җыйганда тизлек, җәһәтлек өчен муенына тагып йөртә торган бамбуктан телеп үрелгән тырысын, су тутырып, "армейски" флягасын тотты да китте-барды. Вәлиша исә, гадәтенчә, тәмләп йоклап калды.

Вәдүткә үзе белгән өч чакрымдагы җиләкле җиргә барып житүе ни тора соң ул. Андагы һәр төштәге җиләклекне аңа үзенең вафаты елы алдыннан да күпкә элгәрерәк әнкәсе өйрәтеп калдырган иде.

> Айга менеп китәр идем,
> Сине анда дисәләр.
> Кайда соң син,
> Кайда соң син,
> Жилләр дә әйтми исәләр,—

дип җырлый-җырлый, тырысы аша үткәрә-үткәрә җиләк белән чиләген тутыра ук язды.

Тургайлар юк, тынганнар, ә анда-санда аяк астына килеп чыккан еланнар—карасы, көл төслесе, алтындае аны өркетми. Ялгыш басмаса, ызламыйлар да ичмасам—тимиләр.

Җиләккәме, чикләвеккәме, гөмбәгәме барды исә ул үзен табигатьнең күндәм фәкыйре дә, зарыгылган патшасы да итеп тоя, шушы тоюы белән кырмыскаданмы, шөпшәдәнме башлап, "кый-ак" дип очкан тилгәннәргә хәтле үзен таныганнарын, үзеннән шөбһәләнмәгәннәрен белә, шул белүе белән горур да, мәгърүр дә, тыныч та, сабыр да. Булды, чиләге тулды инде. Анын җиләк-фәләнме, чикләвекме җыйганда кулы-кулга иярми дә йокмый—әллә мизгел, әллә кан агышы кебек, вакытны тоймыйча эшли дә эшли. Тик ул төштән соң берәр сәгатьтән сонга кадәр өлгертәсен өлгертеп, җыясын җыеп куя инде. Шуннан ары мәгънәсе юк: кояш төшлектән авышкач, барча нәрсә югала, поса, кача.

Җыйганын күтәреп, тузанлы юлдан өч чакрымлы юлдан җәяүләп кайткач, энесе Вәлиша:

—Суң?—дип сорады.

—Яхшы әле, яхшы,—диде.

—Миңа өлеш чыгарасыңмы суң?

—Ярар. Бар әле, чишмә суы алып төшә тор.

—И-и,—диде Вәлиша. —Бераз ятып тор, абый. Хәл ал, җәме?

Вәлиша чиләк, чүмеч тотып, бакча башындагы тирән ерганакта күзе тибеп торган чишмәгә чыгып китте. Ә Вәдүтнең челлә йомшарткан, җебеткән,

изрәткән, йокымсыраткан тәнен, буыннарын бер кавем язып алу нияте белән болдырдагы үз урынына ятуы гына булды,—капка төпләренә бер машинаның килеп туктаганын сизенеп кенә түгел, ә бәлки белеп үк торды.

Ул ишегалдындагы араларына чирәм сарган яссы ташларга яланаяклап баса-баса капка төпләренә чыкты. Чыннан да, кап-кара "Волга" тора, аның ян-як ишегеннән ике кеше җиргә төшеп басты.

Чәче ап-ак берәү аңа кулын сузып:

—Әссәламегаләйкем,—диде.

—Вәгаләйкем әссәлам,—дип, Вәдүт аның кулын кушучлап алды.

—Ялгыш кермәдек микән?

—Бу өйгә ялгыш кермиләр. Алай кергәннәрнең дә әйдәр маягы шушында.

—Әйбәт... Без Ленинградтан идек.

—Кайдан, кайдан?—дип сорады Вәдүт.

—Петербургтан.

—Яхшы, узыгыз,—диде Вәдүт.

—Рәхмәт. Аннары безне сезгә җибәрделәр.

—Кем?

—Теге очтан бу очка. Син белә дип әйттеләр.

—Нәрсәне?

—Сезнең зиратыгызга минем әти Габдулла күмелгәнен.

Вәдүт аны:

—Җирләнгәнен,—дип төзәтте.

—Әйе, җирләнгән. Мин бер туганым белән аның каберенә таш яздырып алып кайткан идем. Кайда җирләнгәнен, каберен авылда беркем белми икән.

—Ә мине белә дип киллдегезмени?

—Белә диделәр. Белә торгандыр диделәр... Без аның каберенә таш яздырып кайткан идек.

—Брат,—диде Вәдүт. —Мин үз авылымның сигез йөз ел әүвәл үк шушында торганын беләм. Ә... кем әле? Габдулла. Бездә андый исемнәр күп ич ул. Бездә кушамат белән әйтешле. Калганы—уч төбендә генә шикелле. Шуннан беләбез.

—Казыйныкылар без.

Моның шулай дип әйткәне соңында Вәдүт аңа төбәлебрәк карап алды. Әһә, чал чәчле, чал кашы тоташыр-тоташмас, чал мыек, ә бу шул мыегын йә учлап тоткалый, йә сыпыргалый.

—Казыйныкылар мени?—дип сорады Вәдүт.

—Казыйныкылар,—диде килгән кеше.

—Ул—без инде,—диде Вәдүт. —Безнең нәсел. Морзалар нәселе.

—Мин аларын белмим инде... кем әле?

—Вәдүт мин.

—Әйе, белмим инде, Вәдүт.

—Әһ!—диде Вәдүт. —Әйдәгез сун инде алайса.

Тегеләр капка төбендәге машиналарына кереп утырды.

—Утырыгыз,—диде чал мыеклы кеше.

—Мин җәяүләп кенә барам,—диде Вәдүт. —Миңа иярегез.

Зират алар өеннән дүрт дистә сажин чамасында гына иде.

Барып җиттеләр, коймa буена туктадылар. Теге якта өч кабер тоташлый куелган яшел буяулы тимер чардуган, анда куе канәфер куаклары үсеп утыра, шул канәфер арасында ике ак мәрмәр кабер ташы агарып тора.

Ул ташлар җим чүпләргә ниятләп кунган ак күгәрченнәргә охшаган иде.

—Әйдәгез. Шушында ул,—дигәч, Вәдүт чүгәләде дә күңеленнән генә иренен сизелер-сизелмәс кенә кыймылдатып, үзе белгән догасын укып алды. —Монда безнең әти белән әни ята,—диде ул аннары. —Ә Габдулла абый—әнә, алар янәшәсендә. Уртак чардуганда,—дип, ул ата-анасы каберләре белән бергә тимер чардуганга уратып алынган тәрбияле калку җиргә ымлады.

—Ә чардуганын кем куйган?—диде кунак.

—Без.

—Гафу итегез, ничек инде... ул сезгә чит кеше бит.

—Түгел. Зиратта чит кешеләр булмый. Без—Казыйныкылар,—диде Вәдүт.

Шулай дигәч, ул, кырыс күз яшен күрсәтмәскә теләп, йөзен тирә-юньдәге каен яфракларын, чукларын, толымнарын сак кына сыйпап агылган мәңгелек җил иркенә бирде. Аннары тыныч, сабыр, түземле итеп:

—Ташыгызны үзегез куярсыз,—диде. —Зарыккансыздыр. Үзегез тәмләп эшләгез. Сез хәзер—Жир белән Күк арасында. Ә, болай, сез кем соң әле?

Агай:

—Казыйныкылар,—диде.

Белүенчә, аның улы Гомәр эндәшми, сүз әйтми иде әле. Үзенең нинди адәми зат, кем нәселеннән икәнлеген бераздан соң аңа еpактан—әйткәннәренчә, Ленинградтан алып кайтылган кабер ташы әйтер, зират тынлыгы пышылдар.

Казыйныкылар. Болар мең елдан ашып көн күргән, тереклек иткән, яшәгән бу авылның Тимер Казык йолдызлары ише иде дә...

Шулай дип уйлады гына әле. Чулпан йолдызыннан торып түгел.

Моннан.

Жирдән.

Зираттан гына.

Кояш авышкан, түбәнәйгән иде инде. Вәдүт янәшәдәге бер каберне әйләндереп алган тимер чардуганның көнбатыш тарафы төбендәге миләүшә чәчәге башларының ябылырга керешкәнен искәреп алды. Тегендәрәктәге әллә кем, әллә кайчан, әллә кемгә утыртылган ике колач чамасы юанлыгындагы, инде өч җәпле тармаклары корып, кайрысы кутырлаганнан соң әләмләнгән карт каен төбеннән биш-алты сөям арырак үсеп утырган Татар билчәне чәчәгендәге вак-вак таҗларга соңлаган ике умарта корты эзләренә кирәккә тыныч, сабыр гына нindидер ниятле мәшгульлектә иде.

Ул "Казыйныкылар"ның калай тагарагында вак комга чуерташлы цемент измә болгатканда көрәкләре чыгырдаганын ишетеп торды. Үзеннән унбиш сажинлап түрдәрәге борын-борынгыдан бирле мәңге яшел ылыслы киң тармаклы ялгыз кап-карт ялгызак нараттан шушыңынчы былтыргы көзен, быелгы кыш, язын үз урынында эленеп торган бер күркәнең ниһаятьтә барыбер җиргә килеп төшкәнлеген искәреп калырга өлгерде.

Ул: "Әни безне самавырда чәй кайнатырга дип шундагы күркәләрне җыярга чиләк тоттырып җибәрә торган иде",—дип уйлады.

Кайдадыр шушы тирәдәрәк аның бабасы Габделнасыйр казый белән әбисе Гәүһәрҗиһан җирләнгән булганын ул чамалый иде чамалавын. Тик ул кайдалыгын күпме генә сораштырып йөрмәсен, тәгаенен әйтеп, күрсәтеп бирүчене тапмады.

Алайга китсә, кемнең җинел туфрагы кайда да анда хәзер ни нәрсә икәнлеген белергә калсаң, мәхлукларга зират кынамы соң—бөтен дөнья җире тәтмәс иде ул.

Оныту, оныта алу—мәңгелек мән.

Коръән шулай куша.

Аның каруы Вәдүт бу зиратта кая тезләнсә дә үзенә дип аталган өч аршин җир ачылып китәргә әзер икәнлеген яхшы белә.

Җылы, йомшак җил сирпелеп узганда каен, анарат, усак, өрәнге агачларының, канәфер, сәрви, балан, миләш куакларының яфраклары лепердәшеп алды, рәшәткә буендагы кычыткан, сукыр кычыткан, әрем, әрекмәннәр—тагын әллә нинди үләннәр, үсемлекләр башларын талгын гына иешеп куйды.

Гүя бер-берсенә сәлам индерештеләр, әлегә исән-сау икәнлекләрен үзара хәбәр итештеләр.

Күк йөзе ап-аяз иде. Көнчыгышның миләүшә төсенә кергән, көнбатышның алсулана барган, Күпер урамына тузан туздырып, яңа сөт исе таратып, авыл көтүе кайтып кергән чак.

Зираттагы һәммә карышта хәрәкәт сизелеп торып, кемнәрдер кемнедер эзләп йөриләрдер шикелле иде.

Вәдүт теге үз янындагыларга:

—Алай-болай көрәкләрегезне онытып калдыра күрмәгез тагын. Кирәге чыгуы ихтимал,—диде.

Гомәр әллә ничегрәк сагаеп:

—Нәрсәгә?—дип сорады.

Вәдүт:

—Җиләк җыярга,—диде.

## Чәчедә

Кызлар карап йөрергә гомерем буена вакытым житмәде.
Тимәде дә.
Авылда гына үстем ич.

Үз очыбыздагы берәр малайның кызларны кыерсытырга ниятләгән мәлендә аларны якларлык түм-түгәрәкме, кырлы-кырлымы нииндидер таш минем үзе бәләкәй, үзе үтә дә нык учымда сак кына йомарланган килеш тора торган иде. Бәлки шуна күрәдер, ул кызлар "өй-өй" уйнаганда мине гел "әти" итеп сайлап тоттылар.

Гармунда уйнарга өйрәнүемә күрә, үсә төшкәч, ул кызлар белән иркенләп биемичә дә калынган.

Жүләр.

Берзаманны кыеп, үз очыбызга тарафтагысын коры көзнең инде дөм караңгылык ингән кичендәме, төнендәме сон— мәңгелеккә дигән ният белән югары очтагы өйләренең капка төпләренә хәтле озатып куйган идем дә ялгыш кына инде кочаклыйм дигәндә ул, гарьләнепме соң, терсәген терәп, күкрәгемне авырттыргач, үз иткәнем көйне өздерепләр торып гармунда уйнауга биргесез төстә сызгыргалый-сызгыргалый өйгә кайтып да киттем.

Ул төн коп-коры, ә күз төбем нигәдер юеш иде.

Бугай.

Шулай тоелгадыр инде. Тоелган гынадыр.

Ул чагында йөрәкнең кай турыда икәнлеген белмим ич әле. Йөрәкне генәме сун—өй чикерткәсенең дә тәгаен кайда сайраганын искәрергә дә вакытның кысан чагы. Әллә мич аралыгындамы, әллә астындамы—шәйләп, сагаеп торасыңмыни? Аска киез җәелгән дә, өскә корама юрган ябылган икән,—бар дөньяң тып-тыныч.

Иде.

Ә ул чикерткәләр менә хәзер хәтеремнең кыл уртасындагы кылларга кунган да алгы аякларын сизгер мыекларына ышкый-суза чыңлыйлар да чыңлыйлар, зыңлыйлар да зыңлыйлар.

Ә бер дә бер заманны төнгә каршы көз кичендә әнә шул чың белән зың көтмәгән-нитмәгәндә бөтен җанымны уятмадымы, йә йокыга талдырмадымы икән? Киезсез, юргансыз килеш.

Ихтимал.

Бәлки тәгаендер?

Әйтәм ич: кызлар карап йөрергә гомерем буена вакытым булмады. Гармун уйнаганда алар күренми. Күрекнең уң ягында биш бармагыңны биетәсең дә, сул ягындагы бакаларга дүрт бармагыңны җайлап-җайлап басасың. Гармун телләренәме, төймәләренәме, бакаларынамы хаталы бастың исә, биючеләрнең аяк җае гына түгел, ә бәлки йөрәк көе дә бозылып китүе бар ич.

* * *

—Без алып бетердек инде,—диде Рәсилә.

—Безнеке биш-алты буразна чамасы калды әле,—диде Баязит.

—Бетә ул,—диде Рәсилә.

Баязит:

—Калмас,—дип килеште.

—Әти-әни белән бүген чәче куйдык. Керәсеңме?

—Монда бүрәнә бар ич.

—Күлмәгем юка. Бүрәнә каты ул,—диде Рәсилә. —Анда җылырак та.

—Ышыктыр да,—диде Баязит.

—Ышык,—диде Рәсилә.

Аларның клубтан кайтышлары иде. Берсе—уң, берсе сул кулларының чәнти бармакларын гына тотышып килешләре. Кайсы уң да, кайсы сул икәнлеген тәгаен бүлешмәгәннәр анысы.

Мөгаендер инде.

Урам буенча Рәсилә—алда, ул ике адым арттарак калып килгәч, инешкә таба унга кырт борылган тыкырык очындагы өйләрен узып, өч дистә адым чамасы араны сагаеп вак-вак кына атлап үткәч, тагын уң кул ягындагы бәрәнге

бакчасы коймасындагы капка боргычын кармалап ачылу ыңгаена борганда да Рәсилә аның шул чәнти бармагын җибәрмичә, хәтта ки кысыбрак та куйды.

Шикелле.

—Сабакларның чәчедән артканын эчкә җәйдек,—диде Рәсилә.

—Безнеке койма башларында.

—Кирәге шул тиклем генәдер. Кер, кер. Син быел күп җыйдың.

Баязит:

—Каян беләсең?—дип сорады.

—Беләм инде менәтерә. Күпме печән чапканыңа, җиләк җыйганыңа, күпме утын кисеп ярганыңа хәтле белеп торам.

—Каян?

—Турыгыздан үткәлим ич.

—Беләм,—диде Баязит.

—Яп,—диде Рәсилә.

Баязит капканы күтәребрәк ябып куйды. Төнне кузгатырдай шыңгырдау уянганда ул: "Күгәргәннәрен майлап җибәрәсе бар икән,—дип уйлап алды. — Хәер, моны кем җайлап, майлап торсын инде?"

—Кер,—диде Рәсилә.

Моңынчы үзенчә сөйләшә иде әле. Бусын пышылдап әйтте.

Нигәдер.

—Яхшы.

Алар чәчегә узды. Куышка инде. Болай да калын түшәлгән бәрәңге сабакларын җыйнаклаштыргалап куйгачыннан соң Баязит:

—Утыр,—диде.

—Ятуы иплерәк,—диде Рәсилә. —Мин монда көндезен ятып караганыем инде.

Утырыштылар.

—Бәрәңге сабагы исе килә,—диде Баязит.

—Чәчең исе дә,—диде Рәсилә. —Үпкәләмә, яме. Үбим әле.

—Рәсилә,—диде Баязит.

Ул кerә-керешлидәге миләш агачыннан бер җимешен өзеп алган иде дә, шуны кабып куйгач:

—Әче,—диде. —Ярмалана башлаган икән.

—Дәшмәле. Дәшмәсәнә инде.

Баязит терсәген терәргә өлгерми калды.

Әллә ничә кырлы җир ташымы, күк йөзендәге Ай тулы чакта аның янынннан һич аерылгысыз ияреп йөри торган ничәмә-ничә нурлы ялгыз йолдызмы арасыннан узып, Баязит уң кул учы белән Рәсиләнең сул күкрәген йомарлап тотты. Әйтерсең лә сап-салкын чишмә төбендәге нindидер бер йомрыдан да йомрырак кап-кайнар ташка орынды.

Ул:

—Яхшы,—диде.

—Яхшы,—диде Рәсилә.

—Берәү елаган иде,—диде Баязит.

—Кем?

—Син белмисен.

—Нишләгәндә жылаттың?

—Үбәм дигәндә.

Баязит Рәсиләнең сагаеп калганлыгын искәреп алды.

—Үптеңме соң?

—Елаганны үпмиләр,—диде Баязит.

—Ә мин көлсәм?

—Көлгәннән—көл кала.

—Учак ягылмаган ич әле.

—Ягылган учакның күмере озак көйри.

—Көйрәми дә, көлмисең дә,—диде Рәсилә.

—Җан көлгәндә йөрәк елый,—диде Баязит.

—Көлмә алайса,—диде Рәсилә. —Курыкма.

Баязит кинәт калкынып утырды да кырыс итеп:

—Мин укыйм гына ич әле,—диде.

—Укы, укы. Ә гармунында уйныйсыңмы соң әле?

—Юк инде. Хәзер гитарада уйнап җырлыйм. Әз-мәз.

—Гармунда әйбәт биетә иден.
—Кемне?
—Тәнәфесләрдә син уйнаганда мин биеми торганыем.
—Беләм,—диде Баязит. —Син биемәгәндә мин уйнамадым.
—Алайса син дә... яратадырыеңмыни?
—Яратадырыем.
—Әү?
—Яратадырыем.
—Ниме дип әйтмәдең соң, Баязит?
—Яратканны әйтмиләр аны.
Рәсилә:
—Нишлиләр?—дип сорады.
—Бернишләмиләр. Яраталар гына,—диде Баязит.
—Гына?
—Гына.

Ул чәчегә таратып салынган бәрәңге сабагы арасыннан әле генә бер йолдыз күренеп торганын күргән иде. Аның әллә ничек кенә итеп кинәттән янга авышып юкка чыкканлыгын чамалап өлгермәс борын ул үз күкрәгенә Рәсиләнең сул йодрыгы белән сукканын, аннары бәрәңге сабакларының кискен кыштырдавын, үзенең инде баягыча чалкан ятканлыгын, ә теге йолдызның үз урынында һаман җемелди бирүен генә искәреп өлгерде.

Юк, һич юк. Йолдыз качмаган, ул чалкан ятмый, ә бәлки Рәсилә аннан теге якка авышып яткан да... елый иде.

Баязит:
—Нигә инде?—дип сорады.
—Белмим,—диде Рәсилә. —Хәтереңдәме?
—Нәрсә?
—Үләнле арба тартып кайтканыңны.
—Исемдә,—диде Баязит.

Ул чәче турысыннан мәче башлы ябалак очып үткәнлеген тоеп алды. Зират очыннан, ялкау гына итеп, бер этнең нигәдер өргәне ишетелде. Бүтәнчә тыптын. Инеш агуы гына сизелеп тора. Инеш ага да ага инде ул. Аннары ул Рәсиләләрнең әүвәлге Кара мунчасы алачыгы астындагы Салкын чишмәнең челтерәвен, чылтыравын ишетте. Рәсиләнең сулыш алганы саен "аһ" иткәне шикелле итепме соң?

Әйе. Шуның шикелле итебрәк.

Түзмәде инде. Ничек чыдамак кирәк. Әлеге инеш агуын, чишмә челтерәвен тыярга, Рәсиләнең тынын тынычландырырга теләгәндәй, әллә шунда көтмәгәндә дулап, аягурә баскан бер-бер байталныңмы, алашаныңмы авызлыгындагы өзәңге ыргакларын кискен тартып тыйгандай, ул сул кулының учын төйнәп кысты, аннары суң бармакларын җәйпәп җибәрде. Ындыр табагына әле генә кайтарып бушатылган чүп үләнле, җылы борчак көшеленә тыккандай гына итеп, шул учын, кулын Рәсиләнең түшенә индерде дә... әлеге көшел булып көшелдән бер борчак бөртеген капшап тапмас шикелле иде.

Тапты.

Тойды.

Рәсиләнең киерелеп торган биле белән кыштырдавыклы бәрәңге сабаклары, аннан соң җир арасына дуга сыярлык иде.

—Минем дә исемдә,—диде Рәсилә.

Баязит аның тын алуы басылганлыгын сизде.

—Әти кырда калды да, арбасына үлән чабып җәелгән атын мина биреп, өйдә бушатып килергә кушты.

—Шунда син мин тартып барган арбамны тактың. Авыл көтүе болынын суйкыйлата кистереп үткән ат юлында кайтып җитәремә бер чакырымлап кына ара калган шәтта.

—Түгел. Түге-е-ел.
—Беләм,—диде Баязит.
—Нәрсәне?
—Арбамны таккан атлы булып, мине утырткаңыңны.
—Синеме? Тиргә баткан, кояшта пешкән, янган, сусаган, сипкелле, трусик-

чан гына. Иренең кипшенеп яргаланган, кашың, керфегең сап-сары. Ямьсез, килбәтсез... Синеме?

—Шуны.

Рәсилә:

—Ә мин нинди идем?—дип сорагач, Баязит:

—Матурыен,—диде.

—Нинди?—дип кайтарып сорады Рәсилә. —Кай төшем? Мин йөзтүбән яткан килеш бара идем бугай бит.

—Шунда мин күлмәк итәгең төбеннән бер кигәвенне учым белән шапылдатып бәреп төшердем.

—Үзем сузылырга әллә ничек ятсынганыем инде. Синнән. Тик син аны бәреп төшермәдең ич, тотып алып кына аттың,—диде Рәсилә.

—Аягыңны авырттырырмын дип курыкканыем.

—Аягымны түгел шул,—диде Рәсилә. —Ботымны. Аннары мин чалкан әйләнеп ятмакчыем.

—Толымың ирек бирмәде ич. Ә синең күлмәгең матур иде,—диде.

—Тегеме? Зәңгәргә вак кына итеп ак борчак төшерелгәнеме?

—Юк. Бусы—акка зәңгәрсу эре кыңгырау чәчәге төшкәне.

Ул Рәсиләнең тыенкы гына, канәгать кенә итеп көлеп куюын ишетеп алды. Әйе, тыенкы гына итеп.

Куанып. Куаныптыр.

Әллә кайдан—әле генә ул кыяр-кыймас иркенләп кагылган, ягылган киң күкрәге турысыннанмы, арасыннанмы көлүен. Төнге җылы җил исеп, чәчедәге бәрәңге сабакларының кипшегән яфраклары кыштырдадымы суң, әллә Рәсиләнең шушы тыенкы, сабыр көлүенә уянган акка зәңгәрсу эре кыңгырау чәчәге индерелгән күлмәгенең кендегенә шайлы тезелешеп төшкән ак сәдәпләре кузгалып, теккән барча җөйләре буйдан-буйга сыпылыр хәлгә җиттеме, әллә сиздерер-сиздермәс, тик авыр тын алуының төнге һаваны җилпетүе булдымы—Баязит боларның һәммәсен ирене белән каплап сүндерергә ниятләгән, омтылган иде дә... Ул арада, үз күкрәгендә кайчан дөрләп киткәнлеге тәмам билгесез учакка чиләге белән гөмбердәтеп су сирпеп җибәрүләрен теләгән шикелле итеп, йөзен, җанын, бар иманын, дөньясын Рәсиләнең уң култык асты белән каплап, ябып куйды.

Андагы ис әллә әче, әллә татлы иде.

Рәсилә:

—Синең күз яшең җылы икән,—диде дә, житди, өлкәннәрчә өлгергәнлек белән: —Елама,—дип өстәде. —Аннары. Кайчан да булса. Бүтән чакта. Икенчеләй.

Ул минем гармунда уйнамаганлыгымны белә икән инде.

Мин дә аның бүтәннәр уйнаганга биемәгәнлеген кеше-карадан ишеткәләдем.

Чәче бөтен куышлыгы белән бер тын алып куйды. Инде җил исмәсә дә, аңа киптерергә дип ыспай җәеп салынган бәрәңге сабакларының кайсыдыр яфраклары гына кыштырдап алды.

Сыман.

Вакыт иксез-чиксез булып, аның башлангычы белән ахыры кайдадыр адашты. Аның очы-кырыен иңләрлек түгел.

Икән.

—Күрешербездер әле,—диде ул.

Рәсилә:

—Инде кирәкмәс,—диде.



Рэмзия
Габделхакова

## КӨЗГЕ ЯШЕН

Көзге яшен—тәүге яшен түгел лә,
Алып килми җылы көләч яңгырлар:
Өр-яңадан үсәрме соң саф гөлләр,
Күңелеңне бер өшеткеч кыраулар?
Көзге яшен—көткән яшен түгел лә,
Шомландыра, сискәндерә нигәдер.
Кышлар килә, тыныч кышлар дигәндә,
Тетрәүләргә түзәрме соң йөрәгем?
Көзге яшен, нишләтәсең син мине?
Яндырасың, көйдерәсең бәгырьне.
Күз чагыла күтелмәгән балкыштан,
Яшен телә бүген язмыш күгемне.
Көзге яшен... соңгы... Соңгы яшем дә...
Утлы уклар—дөрләп янган хисләрем.
Яшен үтәр, үтми калмас...
Ләкин мин—
Яшеннәрсез, күкрәүләрсез—нишләрмен?!
Нишләрмен?!

### Синең илдә

Ялгыш кына килдем синең илгә,
Кичерә күр әрсезлегем өчен.
Мең кат үкенермен киләчәктә
Шул мизгелдә көчсезлегем өчен.

---

Рэмзия ГАБДЕЛХАКОВА—*шигырь һәм хикәяләре белән көндәлек матбугатта, күмәк китапларда даими катнаша. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Лениногорск шәһәрендә яши.*

Синең илең миңа шундый таныш,
Бит үзем дә анда булган идем.
Мин ул илнең бөтен матурлыгын,
Сихри ямен, тәмен тойган идем...

Мин ул илдә янар чәчәк идем,
Утлы яшен идем мин анда!
Син күрмәдең... Ник соң, матур дустым,
Шулай соңлап килдең дөньяга?!
Язгы хисләр башка кабатланмас,
Соңгы тамчы сөю—касәмдә.
...Яшьлек ишекләрен шакып йөрим,
Мәңге ачылмасын белсәм дә...

## Бүген

Бүген көн бәхет мизгелләрен
Бүләк итәр әле күпләргә.
Кемдер сине кичә яраткандыр,
Кемдер сөяр тагы иртәгә.

Күзләреңдә бүген мин чагылам,
Утлы сулышыңны мин йотам.
Сыенам да кайнар күкрәгеңә,
Башкаларның барын онытам.

Син дә оныт. Бу бәхетле йөздән
Таныш чалымнарны эзләмә.
Тәүге тапкыр кояш күргән сыман,
Карыйм ич мин синең күзләргә.

Мәңге, димим, менә бүген ярат!
Кичә югалтканны таптырмыйм.
Бүгенгенең якты учагыннан
Йөрәгеңә күчкән чаткы мин.

Бәлки сүнәр, бәлки әле дөрләр,
Ул йөрәктә нинди хәлләрдер.
...Бүгенге көн сагындырып куйса,
Киләчәктән миңа хәбәр бир.

## Хат

Хат язалмый азапланам бүген,
Хаталанам, бозам...
Ак болынга күбәләкләр түгел,
Куна бары тузан.

Тузан булып куна күңелдәге
Ачу, әрнү, үпкә...
Сабыр итик, диеп, каләмемне
Алып куям читкә.

Ачу, нәфрәт—бәхет өчен тозак,
Үкенечкә юлдаш.
Борчылырсың хат килмәгәч озак,
Ләкин рәнҗү булмас.

Килер мизгел: аяз күңелемдә
Күбәләкләр уйнар:
Алар синең арган йөрәгеңә
Шатлык булып кунар.

## Яратам

Тәүге кояш нуры тәрәзәңә
Кагылганда килеп,
Мин уятам сине назлый-назлый,
Күзләреңнән үбеп.

Хәерле көн, хәерле юл теләп,
Атлыйм янәшәңдә.
Сакла аны!—диеп ялварамын
Тугры фәрештәңә.

Һәр адымың, һәр сулышың тоеп,
Җаның аңлап яшим.
Мин барсын да эшлим! Күзләреңнән
Тик таммасын яшең.

Бу сихер дә, могҗиза да түгел,
Юк тылсымы, сере.
Барсы гади... Бәлки, бик катлаулы?!.
Мин—яратам сине!

※

*Язучы Факил Сафинга 50 яшь*

# ЙОЛДЫЗ НУРЫ

Мин бик озак еллар буе Мөслим район газетасы редакциясендә әдәби түгәрәк алып бардым. Сиксәненче еллар башында анда Әмәкәй авылыннан укытучы Факил Сафин активлашып китте. Шигырьләре, юморескалары район газетасында дөнья күрә башлады. Үзе бәләкәй чандыр гәүдәле, нечкә муенына кызыл галстук таксаң, пионер диярсең, валлаhи. Шуның өстенә ул беркайчан да чәчрәп чыкмый, сүзгә ифрат саран, өч-дүрт авыз сүз әйтсә, алары да, талгын искән җәйге җилдәй, колагыңны сыйпап кына уза. Ә менә кап-кара кашлары астыннан караучы, озын керфекләр белән әйләндереп алынган коңгырт күзләреннән яшерен уйчанлык, моң, сабырлык сирпелә. Бу халәт гадәттә ятимнәрдә, яисә нәрсәдәндер газапланучы-сызланучы кешеләрдә күзәтелә... Ләкин шушыңа ике искәрмә зарур. Әлеге билгеләр шулкадәр тирән яшерелгән ки, аларны күрүе дә кыен. Тагын шунысын искәртим: теге яшерен моң, сабырлык, уйчанлык Факил сөйләгәндә дә, көлгәндә дә, хәтта бәхәсләшкәндә дә (сирәк-мирәк анысы да булгалады) югалмый! Әйтерсең дә ул үзенең эчке дөньясы белән башка планетада яши...

Тора-бара Факилне мәктәп директоры иттеләр... Ярар, бервакыт редакциягә керсәм, егетем җиң сызганып эшләп утыра. Райкомның идеология секретаре "унбиш көн эчендә фатир, хатынына—эш, балагызга ясле була", дип әйтте ди. Андый вәгъдәләргә ышанырга ярыймы соң! Эчемнән генә "чын дивана икәнсең!" дидем дә чыгып киттем. Акылы бар, әйбәт кенә яза бит, ничек мондый ахмак адымны ясады икән, дип әллә никадәр ара урамнан төкеренеп бардым.

Ярар, көннәр, атналар, айлар уза торды. Редакциягә кергәлим, хәлләрен белешәм—вәгъдә ителгән фатирның исе дә юк. Кызганам тегене, булдыра алганча юатам. Ул элеккечә сабыр гына, басынкы гына сөйләшә сөйләшүен. Әмма, күреп торам, тышкы "пейзажы" үзгәрде. Күзләрендә рәнҗеш катыш аптыраш, борын астында матур гына сызылып торган кара мыегы тычканың ычкындырган мәченеке кебек усал кабарды. Кабарыр да, бер дигән эш урыныннан колак кагып, көн саен 35 чакрым ераклыктагы авылыңа "голосовать трамвае" белән кайтып йөри башласаң! Райкомнан да, райсоветтан да һаман фатир даулый Факил. Тавышы ачылып китте. Ләкин ул ныграк һөҗүм иткән саен фатир вакыт офыгының иң ерактагысына чигерелә. Шуннан соң "кайтып китәм" дип куркытуга күчте бу. Курыктылар—ник дисәң, кадр алтынга тиң: белемле, эчми, тынгысыз, күпме өйсәң дә тарта, күпме әйтсәң дә күтәрә. Юк, ычкындырырга ярамый! Иң гаугалы, ел саен директор алыштырыла торган Татар Бүләре урта мәктәбенә директор итеп җибәрделәр. Фатиры да бар иде, бер ел эчендә яна директор бик күп унай үзгәрешләргә ирешә, тик аны җәберләделәр һәм кудырттылар! Тәфсилләп язып тормыйм, кызыксынучылар "Соңгы көз" повестеннан укый алалар. Ул башлыча хакыйкатькә туры килә.

Факил төкереп тә бирмәде: Чаллыга китеп барды. Очрашкан чакларда шаккатам—бу, минәйтәм, шул кадәр җәбер күреп, әзрәк борчылмады микәнни? Ул хакта сүз чыкса, елмаеп бер-ике сүз әйтеп куя—шуның белән вәссәлам. Моның нервылары алтылы чыбыктан ясалган микәнни, дим. Сипсеп тә карамады: һаман шулай салмак хәрәкәтле, синең ун сүзенә бер сүз белән җавап бирә, зарланмый да, мактанмый да. Күзләрендә дә элекке яшерен моң, сабырлык, уйчанлык... Шигырьләре матбугатта күренеп тора, үзебезнең "Авыл утлары" газетасына да җибәргәли. Әйбәт яза, аз яза. "Януы җитми, артык тыныч, шуна күп язмый", дим үз-үземә.

Бервакыт бөтенебезне хәйран калдырган бөек шартлау булды: ул берничә ел эчендә күңелендә гомер буе җыелган, бәгырен көйдергән, сулкылдаткан ут тауларын актарды да ташлады! Атлы казак яу кырында шашкасын унлы-сулы ялт-йолт уйнаткандай, Факил үзенең каләме белән әле поэзия, әле проза бакчасында янадан-яна катламнарны актарырга тотынды. Очрашкан саен хәйран калам: ул һаман шулай салмак, акрын, сөйләшү элеккедән дә басынкырак. Инде мин баш ватам: кинәт кенә каян чыкты соң әле бу шундый да ялкынлы, нәтиҗәле иҗади талпыныш, берсеннән-берсе күркәмрәк, камилрәк әсәрләр? Ходайның бирмеш бер көнендә хөкүмәт эшеннән аерылганы юк үзенең. Әле нинди генә эшләр! Иң элгәре күренекле публицист, әдип, җәмәгать эшлеклесе Айдар Хәлим белән берлектә "Аргамак" журналын чыгарды. Аннары үзе башлап: "Көмеш

кыңгырау" исемле балалар газетасын, "Фән һәм мәктәп" журналын оештырды, соңгысында шактый вакыт редактор булды. Аның мөхәррирлегендә чыгучы "Мәйдан" журналы да инде халкыбызның кайнар мәхәббәтен яуларга өлгерде. Шуның өстенә Ф.Сафин матур-матур көйләр дә яза, күптөрле җәмәгать эшләрендә дә катнаша. Гади адәм баласы бер дә өлгерер кебек түгел бит! Уйлана торгач, моның серен ачарга Ф. Сафин үзе ярдәм итте:

Мин күктән! Йолдыз иленнән.
Ә җирдә—вакытлыча.
Җил-давыллар силәсендә
Гамьнәр галәмен кичәм.
Мин—кайнар йолдыз төшенен
Сүрелмәс җете нуры.

Мәңгелекнең бер чатында
Кисәк өзелсә юлым—
Атылчак узар күк буйлап,
Офыклар дертләп куяр,
Нәкъ шул таңда алмагачлар
Ап-ак чәчкәсен кояр...

Аны ул "гамьнәр галәменә" нинди көч күтәргән соң? Халык гаме, ил гаме, милләт гаме, әлбәттә. Бу—бәхәссез хакыйкать. Алыгыз шигырьләрен, укыгыз повесть-романнарын. Аларда халыкның фаҗигале үткәне һәм бүгенгесе, берсеннән-берсе гыйбрәтлерәк, берсеннән-берсе ачырак язмышлар. Аларның тормышчанлыгына хәйран калмалы. Чөнки Ф. Сафин бармактан суырып түгел, йөрәк каны белән яза. Ул туктап уйланып та тормыйдыр кебек. Гүя тормышның агышын күзәтеп-теркәп кенә бара, ана берни уйлап чыгарырга да кирәкми сыман. Шул чакта йөрәк каны да, күңел җылысы да, күз яшьләре дә, җорланулар да кушылып китә, чөнки автор үз геройларына бер мизгел дә битараф кала алмый. Ул халык яшәеше һәм андагы гаделсезлекләр тарафыннан йолдыз төшедәй кысылган. Шулай булмаганда мондый юллар тумас иде:

Кысыр сыер—партиянең
Корган жиленен имеп,
Үскән бозаулар—
бик серле
бүсерле буын идек.

Язучы олы гамьнең үзенә әверелгән инде. Ул аның гомер буе гизә торган җиһаны. Җирдә үтәсе бер елны бәлкем үз галәмендә ул бер айда үтәдер. Олы гамь аны тәмам баскан, алай гына түгел, тулаем биләгән, канына, җанына сеңгән. Гел уйчан, гел моңлы күзләрнең серен аңладыгызмы инде? Күрәсең, ул синең белән сөйләшеп торганда да үз гамьнәренең галәмендә яши, андагы хәлләр өчен янып көя, әрни. Ул үзе юк инде, ул бу фани дөньяның кызыктыргыч шатлык-ләззәтләреннән баш тарткан, олы халык гаме өчен йолдыз төше шикелле яна бирә. Райондашым, Әмәкәй авылының ир-егете Факил Сафин үзенең 50 яшен әнә шундый халәттә, иҗатта дөрләп янып каршылый.

"Саташып аткан таң" әсәренең өченче китабында *("Казан утлары", 2003 ел, 10, 11 сан)* без шушы хәлләрне Сталин һәм Ежовларның үзләреннән башлап аларның корбаннарына кадәр җанлы образларда күрдек. Язучы репрессияләр чорының коточкыч атмосферасын, халык өстендә җәллад кылычының асылынып торуын, тимер келәшчәләрнең ничек китереп кысуын тәннәрдә бала йоннарын кабартырлык дәрәҗәдә сурәтли. Мона ирешү өчен шушы җәһәннәмне һәр күзәнәгең белән тою, гомер буе бәгыреңне сызлатып йөрү кирәк булгандыр ул. Кем белә, бәлкем "Даһига эндәшү"не Факил әчке аңы белән мәктәп елларында ук язарга керешкәндер? Һәрхәлдә дистәләрчә еллар архивларда утырып, тау кадәр материал тупласаң да, шул чор келәшчәләре кысуын, кабыргалар суырылуын тоймасаң, миллионлаган корбаннар өчен аһ ормасаң, әлеге тауга җан өреп булмый.

"Соңгы көз" повестена тукталыйк. КПСС бетсә дә, аның системасы һәм кадрлары әле һаман хакимлек иткәндә, бу әсәрнең дөнья күрүе күпләргә бомба төшкәндәй тәэсир итте. Ничә еллар буе халык күңелен сызлаткан шешне, күпләр "ай сытарга иде" дип кыҗраган шешне, Ф. Сафин ярды да ташлады! Яшь язучының беренче зур әсәрендә партия хакимияте чорында тамыр җибәргән хәтәр күренешләр, җитәкчеләрнең азынуы җете буяуларда ачыла. Бу иҗади кыюлык кына түгел, гражданлык батырлыгы да иде. Авторга теш кайраучыларның да пәйда булуы моның шулай икәнлеген тагын бер мәртәбә раслый.

Ф. Сафинның икенче зур батырлыгы—"Биек тауның башларында" романы. Рәсәй халкының, бигрәк тә рус булмаган милләтләрнең бәгырен телгәләгән чечен сугышы хакындагы ачы хакыйкатьне бөтен тулылыгы белән ул әйтте. Әсәр үзенең әдәби эшләнеше, җанлы образлары, гаҗәеп халыкчан бай теле белән сокландыра. Аны укымыйсың, шифалы бәлзәм эчкәндәй, рухына сеңдерәсең. Татар авылындагы үзара ярдәмләшүгә, игелеклелеккә корылган ипле, тыныч яшәешне күрсәткәннән соң, автор солдат тормышының тетрәндергеч күренешләренә күчә. Рус армиясендәге кыргый тәртипләр, кешелексезлек, чит милләт вәкилләрен түбәнсетү һәм җәберләүләр аның тәмам череп таркалганлыгына инандыра. Гади татар кызы Раушаниянең, ире Шәфкатьне эзләп, чечен сугышы барган җирләргә йөрәксенеп чыгып китүен, хәвефле, газаплы юллар кичеп, ире белән очрашуын, шуннан соң авылда булган хәлләрне тетрәнмичә уку мөмкин түгел. Ирексездән, бүгенге

шуннан соң авылда булган хәлләрне тетрәнмичә уку мөмкин түгел. Ирексездән, бүгенге яшьләргә: "Күрегез, Раушания да—сезнең замандашыгыз, тормышыгызны, теләк-омтылышларыгызны анык белән чагыштырып карагыз!"—дип кычкырасы килә. Романның бу өлешләрендә үзенне авыл-шәһәрләре бомбага тотылучы, илен-жирен яклаучы чечен халкы белән бергә итеп тоясын, аның фажигасен бөтен тирәнлеге белән кичерәсең. Тау илендәге күренешләр күз алдыннан кинокадрлар кебек узалар, алар шул кадәр ышандырырлык куе буяулар белән сурәтләнә ки, моны шунда булган, шундагы мәхшәрләрне үзе кичкән кеше язгандыр, дип уйларга гына кала.

"Саташып аткан таң" исемле зур полотносы белән Ф. Сафин тагын егетлек күрсәтте. Берничә дистә ел дәверне эченә алган, Ленин, Сталин, Троцкий, Ежов, Алемасов, Дәүләтьяров, Ш. Усманов, Һ. Такташ, М. Җәлил кебек тарихи шәхесләрне теге яки бу дәрәҗәдә гәүдәләндерүче бу әсәр, революциягә кадәрге еллардан башланып, социализм өчен көрәш исеме астында эшләнгән коточкыч репрессияләргә кадәрге чорны колачлый. Әсәрнең исеме җисеменә чыннан да туры килә: таң ата, әмма ул канлы туй булып ата. Авторның әдәбиятыбызга, гомумән иҗтимагый фикергә, халкыбызның рухи дөньясына яңалык алып килүе бәхәссез. Әсәрне мин роман-кисәтү дип атар идем.

Ф. Сафинны зур әдип итеп күтәрүче тагын бер мөһим нәрсә—характерлар тудыру осталыгы. Аның әсәрләрендәге геройлар, персонажлар ак һәм кара төсләргә генә бүленмиләр, алар күп планлы, төрле-төрле сыйфатлары белән җанлы кешеләр булып күз алдына басалар. Аның тәүге повестендагы Тимерхан Заманов шул чорның типик җитәкчесе генә түгел, ә бәлки тулы канлы, үзенең эчке һәм тышкы бәргәләнүләре, шатлык-кайгылары белән яшәүче җанлы кеше дә. Мыңгыр Тәкый кабатланмас сөйләме, уй сөреше, һәр нәрсәгә үз фәлсәфәсе, үтә дә кызыксынучанлыгы, хәйләкәрлеге, тормышка оптимистик карашы һәм тагын бик күп сыйфатлары белән чын мәгънәсендә гади халык вәкиле. Ул һәрберебезгә таныш, гүя син аның белән гомер иткәнсең, бүген дә бергә яшисең. Шушы җәһәттән "Гөлҗиһан" повестена тукталмыйча булмый. Язучының ул әсәре нишләптер тәнкыйтьчеләребез игътибарыннан читтәрәк калды. Аның төп каһарманы нинди генә сынаулар үтми! Чынлап торып караганда, ул бүгенге татар прозасы тудырган хатын-кыз образларының иң күркәмнәреннән. Әлеге повестьтагы берсеннән-берсе кызыклы Фәрвәй, Әүхәт, Гыйльметдин, куян Сәйфие, Әхнәф—һәркайсы характер буларак күңелдә уелып кала.

Факил Сафин үз стилен тудырган язучы. Моңа һәркем ирешә алмый. Стиль, кайберәүләр уйлаганча, тел-сурәтләү чаралары гына түгел. Ул беренче чиратта, әсәрнең сюжет-композициясе, архитектоникасы. Факил теория буенча билгеләнгән кануннарны зырыйбырый китереп бетерә һәм җиңеп чыга! Төп вакыйганы башлау—укучыны әсәрнең төп магистраль юлына кертеп җибәрү дигән сүз. Әз-мәз чигенүләр, читкә чыгулар булса да, син шушы юлны ташламаска тиеш, юкса укучың әсәреңне атып бәрәчәк. Факил әлеге магистраль юлны ташлый бит! Бер сукмакка гына түгел, икенчесенә, өченчесенә, дүртенчесенә күчә һәм, ни гаҗәп, иткә алданган эт сыман, аның артыннан тотам да калмый ияреп барасың. Бик озак уратып, бутап йөрткәч кенә, теге төп юлга алып килә. Укучы арымаган, игътибары һаман да кимемәгән, ул яңа дәрт белән автор хыялы тудырган тормышка чума. Кармакка олы җәен, карп балыклары капкач, аларны бик озак хәйләләп суда йөртеп, әллә нинди алымнар кулланып алалар. Кинәтрәк тартсаң, шартлатып җебенне өзеп, яки авызын ерып китә, ди. Факил да укучыны оста "каптыра" белә, каһәр. Башка берәү аның кебек ул кадәр читкә китүләрне кулланса, укучы дигән "балык", йә сюжет җебен шартлатып өзеп, яисә күңелсезләнеп исни торгач, фабула кармагыннан авызын ерып китәчәк. Кыскасы, һәр балыкчының үз хәйләсе, һәр язучының үз стиле. Зинһар өчен, хөрмәтле укучым, синең өчен бик матур булмаган чагыштыру куллануым өчен кичерә күр. Мин бит Ык суларының бер исәре. Балыкны да үлеп яратам. Чынлап әйткәндә, дөрес чагыштыру киресенчә була: безнең һәр әсәребез—синең кармагыңны көтеп торучы балык ул. Аларның синең кармагыңа кабуы, синең "һи, вак бит бу!" дип кире ыргытмавын—безнең өчен чиксез бәхет.

Язучының теле турында сүз әйтми калу дөрес булмас иде. Ул—чын халыкчан тел, һәртөрле сурәтләү чараларының, бизәкләрнең муллыгыннан раушан көзгедәй уйнап тора. Бу ясалма чуарлык түгел, ул сүзләрне кушучлап энҗе-мәрҗән сипкәндәй сипми. Аның әсәрләрендә урынсыз, бүлтәеп чыгып торган сыңар сүз дә таба алмыйсың.

Факилнең шигърияте хакында әдәби тәнкыйть тарафыннан бөтенләй диярлек сүз әйтелмәгән әле. Миңа калса, аның поэзиясе—шулай ук үзе бер дөнья. Ул тирән уйландыра, дулкынландыра торган, нечкә лирика белән фәлсәфәне табигый берләштерүче, беркемне дә кабатламаучы интеллектуаль поэзия. Аның шигырьләре башлыча "Тузганак чәчәге" (1994) һәм "Сәфәр" (2001) исемле ике җыентыкка тупланган. Соңгысына кереш сүз язган Зөлфәтнең бер генә җөмләсен китерәм: "Китапка кергән һәр шигырь дәва булырлык тылсымга ия, алар аерым бер кешенең бизәклә п, чуклап аңлатып бирүенә мохтаҗ түгелләр".

Факил Сафинның ир-егет буларак өлгереп җиткән чоры. Аның иҗаты да үзенең иң камил, иң бәрәкәтле, иң җимешле чорына кереп килә. Йолдыз төшенең якты нуры халкыбызга бик озак еллар хезмәт итсен иде.

Фоат САДРИЕВ



Факил
ӘМӘК

# ГӨЛЛӘРЕМ, СИРЕНЬНӘРЕМ...

ХИКӘЯ

## I

—Һә-әй ходабәндә, инде күз бәйләнгәч, кая чыгып барасың, нием калган капка төбендә?..

Карчыгының чәпчүен ишетмәгәнгә сабышты Әхмәди агай. Тәнеңдә жаның барда, ничекләр итеп сәкегә үрмәләп менеп ятасың ди, мондый жылы җәйге кичтә. Җәй үзәге бит, җәй үзәге. Их, һавадагы печән исе! Кышлык печән чабылган, киптерелгән, кибәнгә куелган. Уракка әле иртәрәк. Җәйнең бу мәле ямьгә дә, төскә дә үзгәрәк шул. Бөтен хикмәт шул печән исендә!

Тупсаны атлап чыкканда, карчыгы янә бер кәлимә сүз ыргытуны кирәк тапты:

—Бишмәтеңне кияргә онытма! Күзенә ак-кара күренми, башына эш төшкәндәй, ашыга, кабалана, чистый. Чәйдән соң тирләгән килеш капка төбенә чыгып утырмасаң...—Кеткелдәп көлеп тә алды әле.—Кем генә көтеп утыра микән бу чибәр егетне, һәй-й ходабәндә...

Бусы инде, кем әйтмешли, карты белән булышып алудан тәм табарга өйрәнгән карчыкның, форсаттан файдаланып, күңелен күкәй салдырып калырга маташуы гына. Шулай да карчыгын тыңлыйсы калган ла—бишмәтен эләктерсә, ак сакаллы карт буласы икән. Менә бит, капка ачып чыгарга өлгермәде, кичке дымык һава аркасына ырлап та ябышты. Ябышмагае, карчыгының сүзен сүз итеп, җил өреп керткәндәй, кире өйгә теркелдәп булмый инде.

Күзе эңгергә өйрәнеп җиткәнче, бер тын капка төбендә басып торды ул. Әйтерсең, беренче кат күрә авыл урамын.

Урам буш дисәң дә була. Уйласаң үзәкләр өзелеп китә—үзгәрсә үзгәрә икән бу дөнья дигәнең. Кая китте ул теге чактагы ихлас кич утырулар?.. Шушындый да җәйге жылы кичләрне бу кадәр кадерсезлә инде, ә? Элек булсамы?! Нәкъ китапта язылганча инде—көтүләр кайтып, абзар-кура тирәсендәге эшләрне бетергән уңайга, олысы-кечесе дигәндәй, капка төбенә чыгып утырыр иде. Капкалардан саркып чыккан күршеләр, сүз берләшкәндәй, берәрсенең өй турысына өеп куйган бүрәнәләргә килеп кунаклар, төчеләнмичә генә сәлам бирешер, артык җәелмичә хәл-әхвәлләр сорашкан булыр иделәр. Сүз артыннан сүз китә: кемдер гәзит-китаптан укыганын сөйләп кинәнә, кемдер күргәнен, кемдер ишеткәнен... Сөйләр сүзең булса, тыңларга иренми ул авыл халкы. Бүрәнә өстендә корган гапнең үз җае, үз тәртибе, үз фәлсәфәсе бар иде шул. Йомышы төшеп, күршедәге урыс авылына Сандрга барып кайтуын да әллә нинди төсмерләр биреп, тәм-ләззәт белән сөйләп бирә ул Әрәмәле Елга кешесе...

Әхмәди агай ирексездән көрсенеп куйды. Бу кичтә ашкынган кыяфәттә капка төбенә чыгып басуы шул кадәрле урынсыз, җәл сыман тоелды аңа. Хәтта тамак төбенә төер килеп утырды.

Авыл урамын кысып алган әлеге кичке тынлык шыксыз, күңелне бөрештерә иде. Әле кайчан гына гөрләп торган авыл, кул белән сыпырып алгандай, җансызланып, кибеп, корып калсын инде. Ничекләр исең китмәсен бу хәлгә. Ачуың килмәгере, теге чакта һай-һулап халыкны беркем дә өйләреннән урамга куып чыгармый иде, хәзер дә өйгә куып кертүче юк, кая китеп бетте бу халык? Нәрсәдәндер куркып, шикләнеп үз өендә посып ята дисәң дә инде. Дөрес язалар китапларда: җәйге кичләрдә капка төпләре болай буш булмый иде. Анда бер төркем оешкан, монда бер төркем булыр иде. Өлкәннәр тирәсендә бала-чага кайнашыр иде. Эх... Ни хәл итмәк кирәк, заманасы үзгәрде, мәңге үзгәрмәс тоелган гореф-гадәтләр дә юкка чыгып бара. Туганның ишегән, күршенең исемен белми торган дәвер килде. Күрше-күләннең бер тирәгә җыелып, гәп корулары, тешкә бер дигәндәй, торган саен сирәкләнә бара.

Әхмәди агай сары буяулы утыргычка чүмәште. Кытыршы учы белән утыргычның шома, калын тактасын сыйпап куйды. Буяулы такта салкынча иде. Шушы салкынлык әкрен-әкрен тәнгә үрмәли, аркаларны чемер-чемер иттереп, агайның хәлен ала иде.

Юкса, агайга болай каефсезләнеп утырасы түгел. Шәп йорт-курасы Әхмәдинең. Эше барның—ашы бар. Иренмәс, тынгысыз җан иде. Көн-төн колхоз эшендә булды. Трактор белән сабан сөрде, чәчүен чәчте. Яше пенсиягә җитә башлагач, җилкенеп китеп, шыңгырдап торган усактан болын кадәр өй салып кергән иде. Малае Вәдүт, күршесе Камай әйтмешли, клуб тиклем КамАЗ машинасында эшли башлагач, өр-яңа диярлек йортны туздырып атты да, кирпеч-таш ташып, хан сарае төзеп куйды.

—Ник кирәк ул кадәрле йорт, ничек җылытырсың аны, кыш көннәрендә утын ничек җиткерерсең?—дип әйтеп карады Әхмәди. Малае, кул гына селтәде:

—Башка кайгың булмаса, әткәй, юк өчен баш ватма,—диде.—Ике-өч машина ташкүмерне мин аны җәһәннәм чокырыннан да табып, кайтарып аударам. Машинаның артына чуан чыкмаган, дөнья көтәргә файдасы тимәсә, ник шул убыр арбасында көн-төн диңкеп чабам мин?

Шулай, авылда да яшәргә өйрәнделәр. Бер Әхмәдидә генә түгел хан сарае, әнә—урам буйлап тезелеп киткән шундый таш пулатлар. Хәзер яшьләр авылда калуны кулай күрә. Ни таралмаган, ни алга баралмаган колхозга карап ятмый халык, көн итәргә тырыша, иҗтиһат итә. Югарыдан, күрәләтә торып, илне җимерә, талый башлагач, аңгы-миңгерәк торган иде сала кешесе. Үзең иҗтиһат итмәсәң, ачка үлсәң дә ярдәм кулы сузучы юклыгын абайлап алгач, аңга килде дә дөнья куарга тотынды бәндә, сөбханалла, күзгә күренеп, тернәкләнә менә авыл. Шулай да үткән дәвер сагындыра, ни хәл итәсең, адәм баласының күңеле үткәннәрне сагынып яшәргә көйләнгән бугай аның.

Элек төшкә дә кермәгән асфальт юл салып куйдылар Әрәмәле Елга урамына. Сөенергә генә кирәк тә бит, шушы урамны нигәдер үз итә алмый гына инде. Тип-тигез урамнан шалтыр-дөбер килеп арбага җиккән ат үтеп китүен шәйләп алса, Әхмәдинең тәненә суык үрмәләгән кебек була. "Әх-ти,—ди ул эченнән ачынып,—аткайның аягын эштән чыгаралар бит..." Таш йортлардан урамга салкынлык түгелгән сыман... Ни дисәң дә, җайсызрак хис итә ул үзен авыл урамына чыгып басса.

Урамның буеннан-буена үт—ник бер йорт эргәсендә бүрәнә өеме күзгә чалынсын! Йортлар таштан, өйләргә газ кергән. Бер кайгысы юк авыл кешесенең элекке дәверләр белән чагыштырганда. Әй башлар катадырые җәй чыкса утын юллап, анасын корт чаккыры. Бәрәңге бакчасы артыннан ничә еллар нимескә газ аткарып ятты бит, тинтәк хөкүмәт, үз крестьянын рәхәткә тиендерәсе урынга. Нимесләр ни бирде микән үзләре сәвит иленә?.. Шымытыр башыдыр инде. Элекке елларда таң атмас борын Богыл кордонына, лесник Илҗә янына агыла иде халык. Кышка утын хәзерләү мазасы белән инде. Ул Илҗәнең вәкарьлекләрен, кылануларын күрсәң! Ун мәртәбә иелеп сәлам биреп, берсен алса ала, алмаса юк. Япун императорыннан ким түгел иде. Бер йөк утын өчен атна буе йөртә иде, чукынчык. Хәзер сирәк кенә Әрәмәле Елгага килеп чыкса, тегеңә сәлам бирүче булса да, шул, Әхмәди кебек карт-коры булыр, ягъни кайчандыр үзе үк утын бирми изалаган, җаннарын кортып йөргән "знакум"нары гына инде.

Бер көнне Әхмәдигә кереп, баш төзәтеп утырган җирдән, Илҗә үкереп җылап җибәрде.

—Их, авызын корт чаккыры, көкүмәт, хараплар итте, авылларга газ кертеп, кадерле башкайларны кадерсезләде,—диде ул, аккан күз яшьләрен җиңе белән сөртеп.—Үзең уйлап кара, Әкъмәди кода, атна буе кордонга кеше килми. Берәрсе адашып килеп чыкса, бер алдына, биш артына төшеп, көмешкә белән кунак итәм. Көне буе җөреп, сезнең авылда, берсе чәйгә чакырмый бит, Әкъмәди кода, нинди көннәргә калдык, ә...—Ул гөнаһсыз күзләрен хуҗага текәп, инрәүле тавыш белән сорап куйды.—Әйт әле, кода, пичкә газ ягу дигән нәмәне кем уйлап тапты микән? Гомергә бәкъет чыраен күрмәсение ул адәм, иеме?!.

Әхмәди аны ни дип юатырга белмәде.

Илҗә исә, янә бер мәртәбә инрәп, ярып салды:

—Их, тыгылып катсыные, иеме, шушы газ торбасы, къалыкъ утын җага башласыные пичкә... Җыелсыные къалыкъ Богыл кордонына, чыксыные шулар каршысына Илҗә җәшел пуражкысын киеп...

Әхмәди, үзе дә сизмәстән, көлемсерәп, Илҗәне төзәтеп куйды:

—Фуражка диген, Илҗә туган... Бәк матур ие шул кәпәчең...—диде ул, Илҗәнең керле кителенә, ямьшәйгән фуражкасына кызганулы карап.

Илҗә, көтмәгәндә үҗәтләнеп, урыныннан сикереп торды:

—Юк, Әкъмәди кода, безнең телдә пуражкы була ул. Син әле белмисең, без, керәшен халкының үз теле бар!—Илҗәнең тавышы ачулы иде.

Әхмәди агай, аптырап:

—Бәй, бәй....—дип, авыз эченнән ботка пешереп алды.—Гел дә татарча сүләшеп йөргәч ни... Алайсам, үдегедчә сүләшеп күрсәт әле, Илҗә туган. Гаеп итмәсәң инде... Ишетәсе килә бит.

Кулын Әхмәдинең җилкәсенә салып, Илҗә:

—Бер нинди каеп итеш жук!—диде һәм, кин елмаеп, дәвам итте—Пожалыста, тыңла! Җаз көне җапраклар җәшәрә, көз житкәч, җапраклар, коелып, җиргә җата. Озакламый карлы җаңгыр җава башлый. Җә, ничек?

— Кара әле, аңлашыла бит...—дип суды Әхмәди.—Гелләр дә Әрәмәле Елга кешеләре сүләшкән кебегрәк икән...

...Тирән күкне көл төсенә манчып, баш очында ай калыкты. Әхмәди утын әзерләп интеккән чакларын сагынып утыруын өнәмичә, урыныннан калкынып куйды. Шулаен шулай да ул. Илне җимерүгә ничектер эчке җене карыша бит. Атай малы катай. Гәзитләргә ышансаң, хәзер бөтен илне күтәрәмләп сатып бетергән икән хөкүмәткә сырышкан денсез бәндәләр. Ачуы кузгалганын тойды агай. Чарасызлыктан кузгалган ачу иде ул. Сатсалар соң, нигә әле миен кайнатып утыра капка төбендә. Әхмәдидән торамыни инде, ник чукынып бетмәйләр шунда.

Әхмәди йөзен чытып, читкә төкереп куйды да, кесәсеннән тәмәкесен чыгарды. Карчыгы күрмәгәндә, бер тәтәтсәң дә ярый. Кортка, картаймыш көнендә, картының тәмәке тартуына кул куймый башлады бит әле. Күрсә, хәзер ысылдап: "Карт башың белән яшь җилкенчәк кебек, авызыңа фәфирүс кабып, тәтәп утырасың, җүнсез,—диячәк.—Әнә олы кызыбыз шәһәрдән намаз-ниязга өйрәткән китаплар алып кайткан. Шуларны караштыр, тәртипкә өйрән",—дип, тиргәп ташларга гына тора... Караштыра аларны Әхмәди, караштыруын, бер дә җаена төшенә алмый шул. Укыганы калебкә кереп кенә утыра алмый менә.

Койма ярыгыннан бәргән нәзек җил теңкәгә тия башлады, чыннан да җилкәгә бишмәт салып чыгасы калган ла...

Әхмәди, күзләрен чекрәйтеп, әле югары очка, әле түбән очка күз салды. Төп-төз урам буп-буш кебек. Бая искә алган ник бер бүрәнә өеме күзгә чалынсын. Бүрәнәсе өелеп тормагач, кунаклаган кешесе дә юктыр инде аның. Бала-чагасы да кайнашмыйдыр. Урамнарның бер яме калмады, адәм тәганәсе. Бала-чага хәзер урамда чабулап йөрми шул ул, өйдә, түр якта идәнгә сузылып ятып, телевизор карый. Вәт бәла тек бәла булды бу телевизор дигәнең. Көне буе әби-чәби китми шул шайтан тартмасы алдыннан. Өзмикуймый бушлай кино күрсәтәләр. Халык кинәнә генә кино карап. Кич житсә, шул шайтан тартмасын бала-чага сырып ала. Зиһенгә ярашлы бер нәмә күрсәтмиләр бит, ичмасам. Атыш та тартыш...

Ул телевизордан көн-төн чит ил кинолары күрсәтүнең сере бар икән. Бер көнне шул кинога мавыгып, килене сыер саварга оныткач, Әхмәди сукранып алган иде, улы Вәдүт бу хикмәтнең серен чиште.

—Болай ул, әткәй,—диде Вәдүт, диванга кырын яткан җиреннән калкынып.—Чит илләр тиеннәр түләп бездән нефть, урман, тимер-томыр сатып алалар да, аны чимал диләр инде,шул чималдан телевизор, суыткыч, тагын әллә нинди товарлар ясап, йөзләгән тапкыр артык бәягә кире үзебезгә саталар. Өскә кигән киемгә кадәр бездән алдап-йолдап алынган чималдан ясалган. Халык шул телевизорны юк акчасын бар итеп алсын өчен, әллә нинди хикмәтле кинолар төшерәләр. Ансын да бушка бирмиләр, халык акчасына сатып алына ул. Чимал сатучы халык аңга килмәсен, үзе иҗтиһат итеп, үзе товар ясый башламасын өчен эшләнгән эш бу. Рәхәт бит, дөньяны онытып, телевизор карап кына ятулары. Халык көннән-көн миңгерәүләнә, башын эшләтмәскә күнегә. Чит илләр исә безнекеләр аңышканчы дип, булдыра алганчы талап калырга тырыша илне. Анысының да хикмәте бар, илне аларга үзебезнең хөкүмәт сата.... Эшләмичә баерга була, дигән акыл салмакчы алар яшьләрнең башына. Адәм тәганәсе, акчага төрле уеннар уйнатып, баш әйләндерәләр бит. Имеш, гомер буе тир түгеп эшләгәнче, Мәскәүгә барып, берәр уенга кереп чыгасың да, миллионер буласың да куясың....

Дөрес әйтә Вәдүт. Җүләрләнә халык шуның ише нәрсә күрсәтә башласалар. Карчыгына кадәр экранга бет урынына кадала, уен бетмичә, урыныннан кубарам димә.

Тә-әк... Бәй, уйга йотылып, күрми дә тора—күршеләр дә чыккан ич капка төбенә! Күңелен басып торган ялгызлык тойгысы чигә төште, җанын ниндидер шатлык биләп алды. Сөенеп китте. Әхмәди күз кырые белән генә күрше Камай ягына күз салды. Кече кызы шәйләнә әнә. Исемен генә онытып тора, әллә Ирина, әллә Ирида шунда. Каникулга кайткандыр инде. Казанга институтка керткәние Камай кече кызын. Уку дәвамында ел саен бер кышлау тана ите биреп бару хисабына. Кем белән сөйләшкәндер, ансын үзе әйтеп биргәне юк, Әхмәди сорамый. Әмма кышка кергәч, тана түшкәләрен Вәдүт, Әхмәдинең КамАЗ иярләгән малае, Казанга аткарып кайта. Инде дүртенче ел шулай. Әхмәди аптырап, уйлап та куя. Ул Камай кызы ишеләр бик күптер бит ул институтта, итләрен кая гына куеп бетерә органнардыр инде хәлфәләре. Шуны уйлап, бичара хәлфәләрне кызганып та куя. Авылдан иттән башка ни

җибәрәсең инде? Ишетелеп тора, хәзер ни дә булса төртми торып, балаңа югары белем алып булмый, имеш. Үзеңнең башыңа төшкәч кенә беленә дөньяның хикмәтләре. Вәдүт тә олы малаен бер-бер институтка "чумдырырга" яскынып йөри. "Армиягә алып, чәчән ягына озаттырасым юк. Кирәк булса, ел саен ике кышлау үгезен җибәреп торырга да риза",—ди. Түлке, сөйләшкән хәлфәсе бер дә тана түшкәсенә риза түгел ди әле. "Мин диетада торган кеше, акча булса, теләгән ризыгымны үзем сайлап алып кайтам базардан, ит мазар алып килеп мәшәкатьләнмәгез,"—ди икән. Әлегә нык тора ди, ничегерәк җайлар инде Вәдүт ул хәлфәне. Авыл җирендә ашау ягы мулдан булса да, акча ягы такыр бит әле аның. Оныкны бер дә күрә торып утка илтеп тыгасы килми анысы. Әнә Хәйрүшнең малае кайтты чәчән сугышыннан. Кесәсе тулы акча. Акча түләп сугыштыралар бит халыкны, бер дә аңлашылмый бу нәмәрсә. Хөкүмәт туктаусыз: "Безнең сугыш—дөрес сугыш,"—дип такылдый. Ышанасы гына килми, дөрес сугышны шулай акча түләп алып барырларые микән? Җитмәсә, Хәйрүш малае наркоман булып кайткан. Авыл яшьләрен җыеп, наркоманга әйләндереп бетерә инде, шәүкәтсез. Акылга китерергә җыенган, сүз әйткән кеше юк. "Каршы әйтеп карагыз, барыгызны шартлатып, көлегезне күккә очырам! Теләсәм, авылыгызның бар кызларын сатып алып бетерәм,"—дип, кычкырып йөргән әзмәвергә кем каршы төшсен ди. Фирме тирәсе тулы киндер, шуннан ясыйлар икән наркотик дигән нәмәне, инде авылга шәһәрдән наркоман малай-шалай кайтып тулды. Эчәргә яраткан җитмеш яшьлек Бәдри картка тикле шулар белән наркоман булып ята ди. Кая бара бу дөнья, ә?.. Һи, сугыш бит ул наный, сугыш... Бик хәтәр бит ул сугыш дигәннәре. Әхмәдигә сугышның койрыгы гына эләкте. Шунсы да җиткерде. Яраланып, как сөяккә калып, көч-хәл белән кайтып егылды Әрәмәле Елгага. Каян килеп баеп кайту булсын сугыштан. "Бер кайтып керсәм, яңадан чит җиргә аяк та атламас идем,"—дип, антлар эчкән иде, Ходайның амин дигән чагына туры килгәндер инде, менә бит, гомере үтте авылдан чыкмыйча. Сизми дә калды, үтте-китте гомеркәйләр...

Камайның төпчек кызы кереп шылды өенә. Исәнләшеп тә тормады, шелма кызый. Әхмәди агай урыныннан кузгалып, Камай янына бармакчы иде, әллә нигә үз капка төбен калдырып китәсе килмичә, бу уеннан кире кайтты.

Искәреп тә бетермәгән: караңгылык ныклап иңә икән инде дөньяга. Шулай да урамнар якты—ай тырышкан була, үзенчә. Әх, бу койма арасыннан искән җилне! Хәленнән килсә, бәгырьгә үтеп керер иде.

Вәт кызык, караңгылык куерган саен, капка төпләрендә дә кешеләр арта бара. Һәр утыргычта бер-ике шәүлә шәйләнә. Берсе дә үзенең таш пулатын калдырып, күршесе янына килеп чүмәшәсе килми. Янәсе: "Йортымның, бизәкле эскәмиямнең синең өеңнән, утыргычыңнан кай төше ким, көткән дөньям синекеннән кайтышмы? Нишләп мин синең капка төбенә килеп утырырга тиеш әле, ниндидер ялынычым бар сыман. Бигайбә, күршекәем, бөтен нәрсәм бар, һәммә нәрсәм җитеш, киләсең килсә, үзең кил дә утыр минем янга." Менә шулай фикер йөртә адәм баласы хәзер. Ара-тирә урамның бер ягындагы күршенең каршы яктагы шәүләгә дәшеп алулары ишетелеп киткәли китүен. Тик нәрсә әйткәннәрен аңлап бетереп кенә булмый. Капка астыннан этләр өрешкән кебек, һау-һаулап алган кебек шунда. Шушы күзаллаудан Әхмәди көлемсерәп куйды. Чистый, үз ихатасын саклаучы йорт этләре—Акбай, Актырнаклар хөкемендә шикелле, капка төбендә утыручыларга баксаң...

## II

...Әхмәди аркасына үткән җилне каһәрләп, өйгә керергә кузгалмакчы иде, аны утыргычка кадаклап куйган хәл булды. Югары очтан җыр ишетелде:

> Гөлләрем, сиреньнәрем лә,
> Гөлләрем, сиреньнәрем...

Шушы җыруны ишетүгә Әхмәди ике куллап утыргычка тотынды. Әһә, Хәсби тагын кодаларына барып чыккан икән. Аның үзләре турысыннан үтеп киткәнен көтмичә булмый тек булмый инде.

Айга бер була торган хәл бу. Хәсбинең тавышы карлыга төшсә дә, әле дә моңлы, йөрәккә ятышлы. И-и, яшь чакта җырлап җибәрсәме? Әхмәди аптырап та куя, җырчыларны Казанда җиде-сигез ел укыталар икән. Ел саен көтүе белән укып чыгалар, комга сеңгән су кебек, юкка да чыга торалар. Кая микән соң алар—зур белемле, тыңлап туймаслык җырчылар? Хәсби менә ярты көн дә укымаган җырчылыкка, өздерә генә инде, телә генә инде бәгырьне. Йә, кем тыңламаслык ди аның җырлавын? Менә бит, урам буйлап әйттереп килә, мәрткә киткән авыл дертләп уянган кебек булды.

Әхмәди аркасының җылына башлавын тойды. Хәсбинең исә беркемдә дә эше юк,

әйттереп килә бирә. Ул көчәнеп җырламый, моңы күңел түреннән актарылып, тугарылып чыккан сыман. Тавышын басарга да тырышмый, моң урамнарга гына сыешмый, ихаталарга үтеп керә, анда да тукталыр урын тапмый, күпереп торган ак чәчәккә төренгән бәрәңге бакчалары буйлап чаба, аннан елга буена төшеп китеп, әрәмәдәге куаклар арасында бөргәләнеп, каядыр елга аръягына китеп югала.

Җанны сагыш били. Тиктомалдан Әхмәдинең күңеле йомшап, күзеннән яшь сытылып чыкты. Утырган җиреннән сикереп торып Хәсбигә каршы йөгерәсе, яшьлек дусты белән кочаклашып, урамны шаулатып җырлап үтәсе килеп китте.

Яннан бер төркем үсмер үтеп бара. Аларның пырдымсыз кыланмышларыннан җанда җыр тудырган рәхәтлек чигә төште, тик озакка түгел.

Хәсби урам уртасыннан барган җиреннән кырт борылып, Әхмәдинең күршесе— утыргычта кич буе тавыш-тын чыгармыйча бөкрәеп утырган Әкълимә каршысына килеп чүгәләде. Тавыш көчәйткеч кирәк түгел, Хәсбинең һәр сүзен авыл башындагы Чукрак Сәлах та ишетерлек.

—Әй, Әкълимәкәем, багалмакаем, сине күргәч, үзәкләр өзелә бит минем...—Хәсби, калкынып, авыр куллары белән Әкълимә карчыкның аркасыннан шап-шоп сөеп алды. Тегесе ах-ух килеп, аның кулларын читкә алып маташты. Хәсби исә, сөйләнүен белә.— Ну, Әкълимә, күпме йөрдем артыңнан, күз дә салмадың, малай. Турфтан кайткач, бигрәк эреләнеп кайттың. Ялтыравыклы эрҗинкә киеп кайттың бит, шту син. Безнең ише чабаталы сала малаена карарга соң...

—Куй инде, Хәсбиулла, әллә кайчан булган хәлләрне...

—Юк, юк, рәнҗеп әйтүем түгел, Әкълимә. Үзем кыюсыз идем, чүпрәк булдым. Трәпкә идем бит мин. Шул харап итте инде. Хатыным Сәвия дә начар булмады булуын дөнья көтәргә. Ну сиңа кызыккан идем, Әкълимә.

—Һәркемнең үз насыйбы инде, Хәсбиулла...

Хәсби ашкынып, җырлап җибәрде:

Гөлләрем, сиреньнәрем лә,
Гөлләрем, сиреньнәрем лә...
Кайсы гөлләргә кунарга
Белмәдем, сине эзләдем...

...Әй, Әкълимә, ямьле яшәдек, матур яшәдек әйеме бу дөньяда? Карале мәйтәм, исеңдәме, яшь чакта синең белән икебезне генә Мөслимгә симәнәгә җибәргәннәр иде. Бәләкәй чана тартып киттек. Колхозны җүләр димә, атлар кәяләгән чак булгандыр инде, югыйсә дим, бала-чаганы җәяүләп җәһәннәм артына олактыралармы! Сугыштан соң бу... Әй авыр еллар иде, Әкълимә, әйеме? Бардык, симәнә төяп кайтырга чыктык. Язгы бозлы, сулы юл буйлап өстерибез чаналарны. Икебезгә дә өчәр пот симәнә салынган. Шуткы түгел ул ачлы-туклы кешегә. Юлы бармыни соң аның, мин сиңа әйтим. Ярты юлга җиткәндә икебезнең дә чабаталар таралып бетте...

—Кулың эш беләдерие, Хәсбиулла, урманга кереп юкә алып чыктың да ныгытып бирдең чабаталарны...

—И-и бигрәк тә матур, таза гәүдәле кыз идең син, Әкълимә. Һаман да күз алдында тора сылу гәүдәң. Син алдан, мин арттан кайтам. Кулдагы җәпле таяк белән синең чананы этеп кайткан булам. Егет бит үземчә, уналтынчы яшь. Кызганып, йөрәкләр сыкрый, күз алдымда синең кып-кызыл үкчәң елык-елык килеп бара... Язгы суга чыдамый гына чабата, огыың тишелеп, үкчәң якты дөньяга килеп чыкты, миңа күз кыскалап кайта шулай.

—Сиңа сөйләргә булсын инде, Хәсбиулла...

—Их, бәгырьләрем суырылып чыга, ул чакны уйласам. Шулай бит, Әкълимә, булды бит шундый хәл, ә? Их, җаптырный!..

Гөлләрем, сиреньнәрем лә,
Гөлләрем, сиреньнәрем...

Ул көнне кайтып җитеп булмады. Укада кундык, әйеме. Бәчүк дәдәйдә. Шәп карт иде. Шунда тәмәке тартырга өйрәндем. Авыр туфрагы җиңел булсын, Бәчүк дәдәйнең. Тәмәке бетсә, фирмедән бер чучка баласы чәлдерәбез дә, шунда чабабыз. Интектермәде тәмәкегә Бәчүк дәдәй, урыны җәннәттә булгыры.

Шулай, йоклап ятам. Сәндерәнең бер ягында мин, икенче ягында син. Уртада... Бәчүк дәдәйнең кайры туны. И-и ул тунның исләре, әйеме, Әкълимә. Дөньядагы бөтен ис тә бар иде анда. Уянып киттем, син мышык-мышык елап ятасың. Тунны тибеп төшердем дә синең янга тәгәрәдем.

— Әлләниләр сөйләп бетермә инде, чукынчык...

— Юк, алай сиңа карата күңелдә этлек юк. "Нигә җылыйсың, мәйтәм, берәр төшең

авыртамы?" Син... син шул чагында... малайкаем...кулны алдың да изүеңне ачып, күкрәк астыңа китереп куйдың. Шыр җибәрә яздым, прәме. Кул белән үрелү түгел, күз белән капшап караган нәмә дә түгел бит әле ул чакта. Юлда тирләп кайтып, күкрәк астың чиләнеп беткән икән, җаныкаем. Шуңа елап ятасың икән.

—Сызлавына түзеп булмагач... Таза идем бит, тирләткәндер дә инде, күкрәкне кисеп кайткан да бау, чиләнеп чыккан. Кулың салкын иде, шуңа куйдым синең кулны...

—Их, җаптырныйкайлары! Менә бит дөньялары ничек иде аның. Элек тә алай рәхәт күрмәдең, хәзер килен кыен ашата сиңа, Әкълимә, әйеме. Ничекләр итеп үстердең бит малаеңны. Ирең бик пырдымсыз иде, үзен-үзе белгән кебек, иртә китеп барды.

—Ярый инде, үлгән кеше турында әллә нәмә сөйләп торма!

—Ачуланма, урыны оҗмахта булсын дибез дә вәссәлам. Ну сиңа көн күрсәтмәде ул. Хәзер киленең йончыта. Бел-ә-әм, ишетәм... Әрәмәле Елгада кемдә нәрсә шылт итсә, сәгате-минутында Сәвиягә килеп җитә. Турыгыздан үткәндә, кул кычыта, малай. Каеш белән җарып чыгасы килә, шул кычыткан чыпчыгын. Гөнаһасыннан куркам.

—Тәүбә диген, төрмә юлында башың черер...

—Курыкмыйм анысыннан... Әй ямьле яшәдек, матур яшәдек без дөньяда, Әкълимә, әйеме.

Гөлләрем, сиреньнәрем лә,
Гөлләрем, сиреньнәрем...

Җырлагач та... Минем дә капчык буш түгел, җан елый, Әкьлимә. Улым Хәзрәт ялгышты-ы. Нык ялгышты... Сугышта үлгән абый памятына Хәзрәт дип куштык, ну хәсрәт булды, җаптырный малай. Урман артыннан, Сандрдан өйләнде бит... Килен безнең кеше түгел инде, хет үкереп ела, үз ягына бөгә. Сандрга кадәр кайта, малайның машинасына җәелеп утырып, оныклар белән бергәләп. Әрәмәле Елгага килеп җитә алмый инде. "Якшәмбе көнне мин, әбәзәтелни, чиркәүгә барам!"—дип әйтә дә, төшеп кала икән авылларына җиткәч. Сандр чиркәвен яңадан ачтылар, ишеткәнсеңдер. Малай шырантай булып, хатыны-балаларыннан башка, бер үзе кайтып керә өйгә. Ни диясең инде аңа?..

—Әйтмә дә инде, Хәсбиулла, кемгә килеп орынсаң, шуңарда кайгы-хәсрәт...

—Әле бүген урман буенда печән чаптым, колхоз малларына алып кайтырга. И-и, Әкълимә, өйдә ятып булмый, җан түзми. Гомер буе фермада бит мин. Үлсәм дә шул маллар арасында үләрмен инде.

—Тәүбә, әстәгыфирулла.

—Шул, печән чабам, үзем җырлыйм, үзем елыйм. Күңел гел Сандр ягында. Уйлама, миңа аларның тозлы гөмбәсе, тозлы кыяры бер нәмәгә дә кирәк түгел. Оныкларымны күрәсем килә. Җәйгә шунда кайтарып куйды килен. Шулар сагындыра. Юкса, урман аша гына чыгасы да безгә килеп җитәсе. Бәләкәйләр шул әле, юл белмиләр, үзең барып алып килмәсәң, адашалар, ике дә уйламый адашалар... Килеп кердем ишек алларына, ике кара чутыр—шәп-шәрә ике оныгым кочакка атылдылар. Һи-и, җан тартмаса, кан тарта, үләм шулар өчен. Муеннарына күз салсам, егылыплар китә яздым, икесенең дә муенында киндер җеп белән тәре тагып куйганнар. Ачудан шартларга җиттем. Ни йөзләре белән минем оныкларның муенына китереп тәре тага алар, ә?! Тәреләрен йолкып алдым да, бәдрәфләренә томырдым. Өйдән килен килеп чыкты, шәп-шәрә, өстендә уч төбе кадәрле ике трәпкә, әйеме. Китте тавыш, китте сугыш, мин сиңа әйтәем. Кода арага кереп, юмалап, бераз сыйлап җибәрде менә. Их, ялгышты малай, ну нык та ялгышты инде.

—Инде Ходай үзе сакласын...

—Ямьле яшәдек без дөньяда, Әкълимә, әйеме. Ну, кызыктым яшьлектә үзеңә. Йөрәк җитмәде, турфтан эреләнеп кайттың шул. Ялтыравыклы эрҗинкә киеп кайкач, синең янга барырга кыймадым, винават, Әкълимә...

Алып китте, тота алмадым,
Яулыгымны кар суы.
Һич кемгә дә мәгълүм түгел
Йөрәгемнең ярсуы...

...Хәсби авыр адымнар белән кайту ягына кузгалган иде, Әхмәдине күреп, аңа таба килә башлады. Килә-килешкә үк гөрелдәргә тотынды:

—И-и, Әхмәди абзыкай, ямьле яшәдек, матур яшәдек синең белән дөньякайларда. Мә әле берне, биш булсын,—дип, шап итеп сөялле кулын Әхмәдинең итләч кулына китереп сылады.—Гомер буе кешегә инәң к... дә димәдең бит. Үлгәч, урының оҗмах түрендә булыр инде синең. Түлке үләргә ашыкма! Анда барган кешенең кайтканы юк, әйеме, Әхмәди абзыкай. Гомер буе онытмаем сине, гомер буе рәхмәт укыйм. Исеңдәме, үгез җигеп йөргәндә син мине төрмәдән алып калдың. Сандр глубинкасына икмәк илтә

идек, әйеме. Мин йөк ташыдым, ул чакта. Ат арбасын әллә кая югары менгереп, бушатабыз. Шунда мәшәләнгән булып, бер капчык төбендә ике пот чамасы бодайны калдырам да, буш капчыклар белән күмеп куям. Капка төбендәге каравылчыга Сандр самагуны әллә кайчан биреп куелган инде. Ул безне, без аны күрмибез. Соңгы юлда караңгы төшкәнне көтеп, урманда ятам, аннан атны әкрен генә атлатып елга буйлап кайтырга чыгам. Ач чаклар бит инде, Әхмәди абзыкай, урлашып йөрер идек мени. Тотсалар, башлар Себер китәсе ие. Теләсә кайсы борылмада әрәмә арасыннан упалномуч Хәйри белән милиция Гатау килеп чыгып, тикшерергә мужыт. Тамак гүргә кертә, ачтан үтерәсе килми инәкәйләрне. Сугыш вакыты ничава булган икән ул, сугыштан соң интектек ачка. Шулай, шым гына кайтып киләм, кинәт ешкынлыктан берәү килеп чыкты да ат башын эләктереп алды. "Беттем икән,"—дидем. Шыр җибәрдем дисәм, аз булыр. Ходайның рәхмәте төшкере, син икәнсең, Әхмәди абзыкаем. Сугыштан йөреп кайткан чагың. Тиз-тиз генә хәлне аңлаттың: "Алган бодаең булса, хәзер үк елгага бушат, күпер төбендә Хәйри белән Гатау көтеп торалар,"—дидең дә, ешкынлыкка кереп тә югалдың. Йоклап торыш юк, күз ачып йомганчы, ике пот бодайны елгага агыздым. Күпер төбендә тегеләр көтеп тора мине. И-и тентеделәр дә инде. Штан бөрмәләремә кадәр тикшерделәр. Бер бөртек икмәк чыкмады. Башлар Себер китәдерие, син булмасаң, Әхмәди агай. Их, бар иде дөнья, ә?

Алып китте, тота алмадым,
Яулыгымны кар суы...

...Ямьле яшәдек, синең белән Әхмәди ага, рәхәт яшәдек дөньякайларда, иеме!

—Яшәргә язсын әле, Хәсбиулла, яшәргә язсын...

—Ну, малаем ялгышты, Әхмәди абзыкаем. Хәзрәт-хәсрәтне әйтәм. Шәһәрдә машинада йөри иде. Үткән көз авария ясады. Кеше машинасын җимерде.

—Күрәчәгең булса...

—Ихатадагы бөтен малны сатып бетердем. Каз-үрдәккә кадәр аткардым. Теге машинаны төзәттек тәки. Безнең еллык пенсия акчасына хәзерге әмерикә машинасының бер тәгәрмәчен дә яматып булмый икән. Малай үзе дә бә-әк кайгырды. Коры сөяккә калды. Ну таптык, җиткердек, коткардык малайны. Әле менә Сандрдан, оныклар яныннан кайтып киләм. Ну, малай ялгышты-ы, нык ялгышты. Эчем тулы ялкын, кешегә генә сөйләп булмый. Йә, Әхмәди агай, бигайбә, бераз тел чишелгән чак...

Хәсби җыр сузып җибәрде:

Түбән очтан агып килә
Кулдан үргән дилбегә.
Үзем китсәм, тауышым калсын,
Сез дусларга билгегә...

...Әхмәди озак кына Хәсби артыннан карап торды. Күңеле тулышканын сизеп, өйгә керергә кузгалды. Аркасына янә дымсу җил китереп бәрде. Ул урыныннан торып, аякларын язды. Аягына басып, алга омтылган уңайга, Камайларның өй кыегына эләгеп торган ай да ычкынып китте һәм биек тирәк ябалдашы артына кереп яшеренде. Һәркайсы үз капка төбен саклап утырган карт-коры да, әмер бирелгәндәй, берәм-берәм өйләренә керергә кузгалдылар: шалт-та шолт капка келәсе тавышлары яңгырап алды. Һәркем белә, Хәсби инде беркем янында тукталмаячак, кычкырып беркемгә сәлам бирмәячәк. Вәкарь генә алга атлар, каршысына очраганнарга, исәнлек бирүен белдереп, эре кыяфәт белән башын гына селкеп алса алыр, әмма артык бер сүз катмас.

Тагын бер мәртәбә тәмәке көйрәтмәкче булып, Әхмәди агай кесәсеннән шыгырдавыклы кап тартып чыгарган иде, йөрәге дерт итте: карчыгының нәзек тавышы ишетелде:

—Кер инде, ябалак, яшь-җилкенчәккә урын бирмичә, капка төбендә бөкшәеп утырма! Клуб юк, оныкларың төннәр буе капка төбен саклап чыга хәзер. Барыр җирләре булмагач ни...

Әхмәди кулына алган тәмәке кабын җәһәт кенә кире кесәсенә шудырды. Алга иелә төшеп, керергә кузгалды. Капканы ачкач, янә тукталып калды. Җыр тавышы ишетелә иде әле:

Гөлләрем, сиреньнәрем лә,
Гөлләрем, сиреньнәрем...

Моңсу иде бу кич, бик моңсу иде... Җил үз итеп, Әхмәдинең гәүдәсенә сарылып маташты да, чалтлап ябылган капка тавышыннан курыккандай, утыргыч астына кереп посты.

*2001 ел.*

Чаллы.

Publisistika
Публицистика

## МӘУЛӘ КОЛЫЙ КАНЫ

Минем ерак бабамнарның берсе шагыйрь Мәүлә Колый икән! Мин моны әле бер ел элек кенә белдем. Бу күңелле хәбәр-бүләкне миңа Әлмәт энциклопедиясен төзү төркемендә эшләүче галим-каләмдәшем, профессор Марсель Әхмәтҗанов җиткерде. Безнең төбәктә туып-үскән, күркәм исеме-даны чыккан мәгълүм нәселләрнең шәҗәрәләре язып-туплап барылган бер дәфтәргә юлыккан икән галим. Өстәвенә, бу кадерле дәфтәр минем туган авылымда табылган!

Безнең буын үскән чорда, ни кызганыч, ата-бабаны фәкать ул ярлы катлау вәкиле булган очракта гына телгә алырга ярый иде. Әгәр дә синең мулла, йәисә бүтән төрле хәлле-таза нәселдән икәнлегең билгеле булса, югары уку йортына керүең, коммунистлар партиясе сафына басуың, гомумән, карьера ясау мөмкинлегең бик тә икеле иде. Әйе, ни кызганыч, тоталитар совет системасының шартлары шундый иде. Ата-бабаларыбызны искә алган чагында олылар, ягъни әти-әни иң башта як-ягына карана: берүк чит-ят кешеләр, кечкенә балалар ишетә күрмәсен! Әтиемнең энесе Сөләйман абый әйтмешли: "пышылдап кына сөйләшегез, диварның да колагы бар..." Шуңа күрә дә, мин нәсел шәҗәрәмнән ни дә булса хәтерлим икән, алары да әнә шул кечкенә чакта колакка кереп калган очраклы җөмлә вә ишерен гәп кыйпылчыкларыннан гына гыйбарәт. Мәсәлән, әниемнең кемгәдер әти турында сөйләгәне хәтердә калган. Әтием Хөсәен (әле әнигә өйләнгәнче) беренче алман сугышы вакытында әсирлеккә эләгә һәм бер гроссбауэрда, ягъни кулакта ялчы булып хезмәт итә. Тора-бара кайнар канлы, дәртле татар егете алман кулагының зәңгәр күзле гүзәл кызына бер малай да ясап бирә. Шушы малай аркасында ул Алманиядә бөтенләйгә торып кала яза. Димәк, әти ягыннан минем алман абыем бар булып чыга. Кем белә (һәм бик тә мөмкин), ул малай икенче урыс-алман явында—Бөек Ватан сугышында—бәлки әле миңа каршы да сугышкандыр. Ихтимал, минем кебек үк, ул да бу сугыштан исән чыгып, үзенең демократик Faterlandын төзүдә катнашкандыр. Алман абыем хакында ни дә булса белү теләге—нияте миндә әле бүген генә—яңа заманда гына уянды. Элек исә бу хакта авыз ачып сүз әйтү түгел, хәтта хыялланырга да мөмкин түгел иде. Органнар алдында шүрләүдән дә түгел бу, һич юк. Тарихи һәм милли хәтергә ихтыяҗны калдырмаганнар иде бездә. Совет хакимияте безне мәхлук дәрәҗәсенә төшереп, бу ихтыяҗны безнең вөҗүдебездән, җаннарыбыздан мыскалына кадәр сыгып чыгарган иде шул. Менә бит хикмәт нидә иде?!

❁

Минем нәселемнең чишмә башы унҗиденче гасырның икенче яртысында яшәгән шагыйрь Бәйрәмгали Колыевтан ук килә. Бу мәгълүм шәхесне гади халык Бимкә суфи дип йөрткән. Суфи, ягъни үзен Аллаһыга хезмәт итүгә багышлаган кеше. Шигърияттә исә ул "Мәүлә Колый" һәм "Муллагол кол" тәхәллүсләре (псевдонимнары) белән билгеле. Әмма дә ул татар әдәбияты тарихына фәкать Мәүлә Колый булarак кереп калган.

Мәүлә Колый Казан өязенең Чыты авылында (хәзер бу авыл Татарстанның Питрәч районына карый) якынча унҗиденче гасыр урталарында дөньяга килә. Туган елы, ае, көненең төгәл датасы юк. 1699 елда ул Петр Беренченең фәрманы нигезендә туган

авылыннан сөрелә. Кайбер тарихи һәм әдәби чыганаклардагы мәгълүматларга караганда, дәүләтчелеген югалткан татарларның тормыш-көнкүрешен оештыру, алар белән җитәкчелек итү вазыйфасы дин әһелләренә күчә. Янә шунысы да мәгълүм ки: Иван Грозный татарларга Казан тирәсендәге авылларда яшәүне тыя. Шулай итеп, 1699 елда Бимкә суфи (аның җитәкчелегендә?–бик тә ихтимал!) Чыты авылы мөселман татарлары белән туган нигезләрен калдырып китәргә мәҗбүр булалар. Алар шактый ерактагы көньяк-көнчыгыш тарафларына юл алалар һәм Бөгелмә өязенең (хәзер-Татарстанның Лениногорск районы) Иске Иштирәк авылына килеп төпләнәләр. Казан, Санкт-Петербург һәм Уфадагы кулъязма фондларында Мәүлә Колыйның йөзгә якын шигыре сакланып калган. Ул үзенең шигырьләрен, уничәнче гасыр шагыйре Әхмәт Ясәви кебек, "хикмәтләр" дип атаган. Кыска күләмле, әмма тирән мәгънәле, кинаяле, фәлсәфи колачка ия булган бу хикмәтләрне безнең заман гыйбарәсенә күчерсәк, без аларны "притча" дип атар идек. Шагыйрьнең кайбер әсәрләре татар әдәбиятының хрестоматиясе дәреслекләрендә дә дөнья күрде. Аның байтак кына шигырьләре бәхетсез кешеләрнең, ярты-ябагайның хәл-халәтен күңеле аша үткәреп язылган. Бу-аның шигъриятендә төп юнәлеш. Менә, мәсәлән, "Гариплар хәле" исемле шигыре:

Гарипләрне һич бер адәм алмас санга,
Аш-тәгам ләззәт бирмәз һәргиз җанга.

Гарипләргә үлем килсә монлуг башы,
Юк аның гүргә куяр карендәше.

Уңлы-суллы хәлен сорар оясы юк,
Хак бирмәсен һичбер кемгә гарипләкне,
Гарипләк барча хәлдә михнәт икән,
Би микән, вә бичара горбәт чигәр,
Йөрәкнең дә хәсрәт уты янар икән.

Мәүлә Колыйның нәсел-нәсебе, өченче буыннан алып, Сарабиккол авылының муллалар династиясен дәвам иткән. Бу чылбыр фәкать тугызынчы буыннан соң—мулла бабам Мирхәйдәрдән соң гына өзелә. Әтием Хөсәен—унынчы буын, мин исә—унберенче буын. Ир-ат ягыннан килүче нәсел шәҗәрәм әлегә уникенче буында тукталып тора- чөнки улларым Әнвәр белән Тимурның гына ир варислары юк. Хатын-кыз ягыннан исә ике кызым да шәҗәрәбезне унөченче һәм унбишенче буыннарга ук җиткерделәр инде.

❁

Үз гомеремдә мин төрле хакимиятләрне күрдем. Еш кына үз-үземә сорау да бирә идем: нигә мин бу хакимиятләрнең берсе белән дә дус-тату итеп, килешеп яши алмыйм соң? Мин, гәрчә партиягә чын күңелдән бирелеп, тугры хезмәт итәргә тырышсам да, большевикларның байтак кына караш-фикерләре вә гамәлләре белән һич тә килешә алмадым. Мин, әлбәттә, хакимияткә демократларның килүен бик тә тели идем. Ниһаять, алар килделәр. Әмма ләкин болары да өметемне акламады. Беренче очракта, ул чактагы коммунист дигәннәре—мин уйлаган, мин аңлаган дәрәҗәдәге коммунистлар түгел иде. Ә инде икенчеләренә килсәк, болары-бөтенләй ялган демократлар Россиядә чын мәгънәсендә гражданлык җәмгыяте оешмый торып, әлеге ялган демократлар да хакимияттән тиз генә төшмәячәк. Монысы исә кызыл кар яуса гына була торган хәл. Чөнки гражданлык җәмгыятен кору өчен социаль база юк һәм ул якын киләчәктә көтелми дә. Бөтенесен дә албастыдай басып торучы бюрократия моңа ирек тә бирмәячәк. Әлеге җәмгыять җиңүгә ирешкән очракта, бюрократиянең сукыр бер тиенгә дә кирәге калмаячак лабаса.

Инде менә хәзер, нәсел шәҗәрәмнең кемнән башлануын тәгаен ачыклагач, мин үземнең һәртөрле хакимият даирәләрендәге тамыр җибәргән явызлыкка каршы көрәшүемнең төп нигезен дә тойдым, аңладым. Мәүлә Колыйдан, каннан килә икән бу көрәш! Бер китабымның эпиграфына мин болай дип язып куйган идем: "Табигатем белән коллык галәмәтеннән азат кеше, бернинди дә хөкүмәт бүләкләре белән түбәнсетелмәгән, мыскылланмаган автор буларак..." һич кенә дә дипломатик мөнәсәбәткә дәгъва итмәгән бу сүзләрне язарга да, бактың исә, нәкъ менә Мәүлә Колый каны этәргән икән

ләбаса! Бу хакта искә төшерүемнең янә бер сәбәбе бар: таныш-белешләремнең бик күбесе минем социаль дәрәҗәмә туры килми торган күренешләргә тап булалар да, миңа уңайсыз сораулар яудыралар. Чыннан да, ошбу гөнаһлы дөньяда мин инде шактый үк яшим. Үземә күрә эзем бар, үз гомеремдә файдалы-мәгънәле гамәлләр дә кылдым сыман. Ярты гасырдан артык фән белән шөгыльләнәм. Югары фәнни дәрәҗәләрем һәм исемнәрем дә бар. Өч йөздән артык фәнни һәм публицистик хезмәтләрем басылып чыкты. Социаль яктан да активмын, тормыш-көнкүрештә дә гаепле гамәлләр кылганым юк. Югары даирә түрәләре минем белән очрашканда сәлам бирәләр, кул бирел күрешәләр, һәм бу, бюрократик карашлар буенча, аерым бер хөрмәт, санга сугу билгесе булып санала. Ә шулай да, бу югары даирә тарафыннан минем хезмәтләремне дәүләт дәрәҗәсендә билгеләп-бәяләп үтүчеләр булмады. Югыйсә минем шәкертләрем инде күптән "атказанган"нарга әверелде, кайберләре исә югары вазыйфаларга да иреште. Аллага шөкер, диик! Бу хакта сөйләргә мәҗбүр булуымның янә бер сәбәбе бар: минем бер хезмәттәш дустым (югары кимәлле белгеч, фәнни дәрәҗәләргә дә бик тә лаек, гәрчә фәннәр докторы түгел үзе) Мәскәү галимнәре арасында үзенең бердәнбер Татарстанның атказанган фән эшлеклесе булуы белән һәрдаим горурлана. Миңа исә мондый горурлык өчен хакимият тарафыннан сәбәп тудырылмады. Әйе, хакимиятне өнәмәсәң, ул да сиңа шундый җавап кайтара. Совет хөкүмәте, мәсәлән, фәннәр докторы дәрәҗәсен миңа егерме өч елдан артык вакыт дәвамында расламады. Чөнки мин язган докторлык диссертациясе партиянең тарихи һәм сәяси концепциясенә туры килми иде. Коммунистик дәүләт үз-үзен, ничек булдыра ала—шулай якларга тырышты. Мин әле җиңел котылдым. Бу бииһая кодрәтле албасты-машинаның мине сытып-тапман китүе дә бик ихтимал иде. Дөнья шулай корылган: аерым бер кешеме, сыйныф, милләтме, дәүләтме—һәркайсысы үз хокукы өчен, җирдә яшәү хокукы өчен көрәшә. Үзенә хас чаралар, алым вә юлларны кулланып көрәшә ул. Кабахәте-кабахәт, вөҗданлысы—вөҗданлы чарага сыгына. Беренчесе икенчесен җиңгән чаклар да еш була. Әмма бу-баштарак кына. Тора-бара вөһдан миллионлаган йөрәкләрдә туплана да, ахыр чиктә җиңүгә ирешә. Мең вә меңнәрне харап иткән, кешелеккә каршы бихисап җинаятьләр кылган совет хакимияте дә, әнә, мизгел эчендә җимерелеп төште.

Мәүлә Колый һәм аның нәселен дәвам итүче буыннарның (шул исәптән-минем дә) иңенә кешеләрне яхшы якка үзгәртү, аларның күңеленә мөмкин кадәр күбрәк яктылык, мәгърифәт нуры иңдерү бурычы йөкләнгән. Инде менә илле ике ел дәвамында мин, югары мәктәп мөгаллиме буларак, әнә шул бурычны гамәлгә ашырырга тырышам. Ә кешеләр яхшы якка үзгәрдеме соң? Һәрхәлдә, бөтенләй үк начараймадылар. Шунысына сөенергә кала. Югыйсә, Сталинның совет режимы дәверендә кешелеккә явызлык кылу гамәле иксез-чиксез колач алган, дәүләт дәрәҗәсенә күтәрелгән иде. "Иблис кодрәтле, әмма Аллаһы Тәгалә дә рәхмәтле"—дигән борынгылар. Чыннан да, кешелекне чолгап алган караңгылыкта вакыт-вакыт өмет нуры булып яктылык та чагылып-балкып куя.

Чыгышым белән муллалар нәселеннән булсам да, рухани-дини җәһәттән бик сай йөзүем сәбәпле, мин Аллага дан җырламыйм. Әмма дә иманым камил: адәм баласы Аллаһы Тәгаләдән башка әлек тә яши алмаган, хәзер дә яши алмый. Һәм менә ни өчен: Кеше, җир йөзендәге башка җан ияләреннән аермалы буларак, акыл вә аң белән коралланган зат. Вәләкин бу коралны яхшылыкка да, яманлыкка да бертигез дәрәҗәдә юнәлтергә мөмкин. Акылны фәкать яхшы ният белән генә куллана алырдай көн кайчан да булса бер килер микән соң ул?—Бик тә шикле... Ә менә адәм зиһененең бөтен җир шарын, кешелекне һәлакәткә илтеп җиткерүе, дөньяда коточкыч экология афәтен кузгатуы ихтимал. Бик тә ихтимал. Шуңа күрә дә, кешегә, акыллы зат буларак, үз ишләре белән гыйлемсез, имансыз килеш яшәве мөмкин түгел. Гыйлемең булса, бик әйбәт. Ә инде шуңа өстәп иманың да бар икән-тагын да яхшырак. Әмма дә монысы кешеләрнең бик азларына гына хас. Гавам исә нинди дә булса бер изгелек-илаһилыкка, аң белән ирешә алмаслык затка—Аллага табына, аңа ышанычын яшәү коралына әверелдерә. Бүтәнчә булганда исә нәкъ Достоевский әйткәнчә килеп чыгар иде: "Әгәр дә Алла юк икән, димәк, һәммәсе дә мөмкин, рөхсәт ителгән". Бу очракта хаос, тәртипсезлек, вә чиксез таркаулык кына тантана итә ала.

**Әгъдәс БОРҺАНОВ**

## ДИСКУССИЯ: «БЕЗНЕҢ ЗАМАН ГЕРОЕ»

XX гасыр азагында һәм XXI гасыр башында кешелек дөньясының һәм икътисади, һәм рухи тормышында гаять тирән үзгәрешләр барлыкка килде. Элеккеге СССР җирлегендә—без яшәгән җәмгыятьтә—алар аеруча кискен һәм үзенчәлекле чагылыш тапты. Күп дистә еллар буе яшәешебезнең асылын тәшкил иткән икътисади тотрыклылык бетү белән бергә, әхлак критерийлары да сизелерлек какшады, сәяси ориентирлар үзгәрде. Моңарчы халыкның «уртак малы» саналган мөлкәт таланды, таратылды, бүленде; ясалма интернационализм кысаларына куып кертелгән, әмма асылда канәгатьләндерелмәгән милли ихтыяҗлар милләтара мөнәсәбәтләрнең киеренкеләнүенә китерде, хәтта гражданнар сугышы учаклары хасил булды, яңа буыннарны тәрбияләүдә иҗтимагый идеаллар алышынды... Шул ук вакытта, җәмгыятьтә демократия чалымнары да үсеш ала башлады: сүз һәм вөҗдан иреге, ил-дәүләтләр арасындагы «тимер чаршау»ның алып ташлануы, шәхси инициативага өстенлек бирелү әнә шундый уңай күренешләрдән саналырга хаклы.

Менә шушындый катлаулы, байтак язмышларны ботарлап ташлаган, хәтта катаклизмнарга кадәр барып җиткән җәмгыятьтә әдәбиятның, анығрак әйткәндә, матур әдәбиятның роле кимеде түгелме? «Әдәбият—тормыш көзгесе» дигән шигарьне өлге итеп алган күбебез өчен табигый борчылудыр бу. Моңа кадәр без әдәбиятны кеше аңын формалаштыруда иң төп факторларның берсе дип инанып килдек. Хәзерге вәзгыятьтә бу чыннан да шулаймы? Гомумән, әдәбиятның үзендә нинди процесслар бара? Сораулар күп. Без, бу очракта, әдәбият, тәрбия чарасы буларак, үз миссиясен югалтмаган дигән фикердә торып, мәсьәләнең бер ягына игътибарны юнәлтмәкче булабыз.

**—Бүгенге татар әдәбиятының (соңгы 20 еллар) каһарманнары кемнәр?**

**—Аларда яшьләр күңелен яуларлык нинди сыйфатлар бар?**

**—Язучыларның бу каһарманнар образын ачып салуда уңышлы һәм кимчелекле яклары нидән гыйбарәт? Гомумән, ихтирамга лаек олы язмышлы шәхесләр тиешле дәрәҗәдә чагылыш табамы?**

Әлбәттә, сорауларның формулировкаларын теге яки бу төсмердә үзгәртебрәк тә куярга мөмкиндер, әмма сөйләшү-әңгәмәгә чакыруның мәгънәсе бер: бүгенге татар әдәбиятында «безнең заман герое».

Әдәбиятыбызның бөтен жанрларын да инләргә тиешле бу сөйләшүдә язучылар, тәнкыйтьчеләр һәм, гомумән, әдәбият белән кызыксынган киң катлам укучылар актив катнашырлар дип өметләнәбез. Фикер алышу 2004 ел дәвамында барачак.

Бу санда дискуссиягә килгән беренче язма тәкъдим ителә.

**Рәфыйк Шәрәфиев**

# КИЛӘМЕ, КҮРӘБЕЗМЕ?

“Татар килә!

Әйе, ат өстендә татар гына үзен шулай горур, җинел, кылтыкланып тота белә. Татар гына атны бар хәзинәләрдән дә өстен күрә. Фәкать татар гына башын аямыйча яуга баса”.

Бу юлларны без Марат Әмирханның 2003 ел башында “Казан утлары”ның өч санында басылган “Тояк эзе” исемле романыннан укыдык. Ымсындыргыч һәм өметләндергеч ике сүз: татар килә! Хәере белән килә генә күрсен иде дәүләтле, ирекле, милләт җанлы, хөр фикерле чын татар. Кайтсын иде ерак тарихлардан! Яшәешебезгә дә һәм... әдәбиятыбызга да.

Татар килә! Тик нинди ул, без зарыгып көткән кыяфәттәме? Марат Әмирхан бик өметле ике сүзе белән безнең бар игътибарны җәлеп итә дә, романның баш каһарманы Кәшшафка ияртеп, тарих галимнәренең иҗади эзләнүләр, үзара интригалар, аяк чалулар, эреле-ваклы бәхәсләр, хыянәт һәм алдашулар, күп очракта мәгънәсез булган сүз көрәштерүләр тулы көндәлек ыгы-зыгысына алып кереп китә. Интригалар дигәннән, “Звезда Поволжья” гәзитеннән күпме укыдык без мондый холыклар (һәм холыксызлар!) бәрелешен! Дөрес, андагылар тәҗрибәле әдип каләме аша үткәрелмәгән, кием-бизәкләргә төренмәгән, шуңа күрә романдагыдан шокәтсезрәкләр иде. Ләкин “Тояк эзен”дәге әдәби сурәтләү чаралары да андагы байтак каһарманнарны әлеге гәзит битләрендәге конкрет шәхесләрдән аерып бетерә алмый. Алайса, “татар килә!” дип шатланып, “Звезда Поволжья” каһарманнарының әдәбияттагы гәүдәләнешләрен генә көтеп алганбыз булып чыгамыни? Нәрсә соң бу, заман әдәбиятының тормышка якынаюы шушылай пародия төсен алды мәллә?

Хәер, башкача ничек булсын, без бит үз заманында татар әдәбиятының зур казанышы саналган, дәүләт бүләкләре алган “Язгы җилләр”, “Намус”, “Гади кешеләр”, “Саф күңел”, “Сүнмәс утлар” кебек әсәрләрнең каһарманнарын, чын тормыштан алынмыйча, социаль заказ буенча уйлап чыгарылуда, әдипләребезне исә чынбарлыктан аерылуда, бик зур “гөнаһлы” социалистик реализмда гаепләдек, шулай гаепли-гаепли каләм ияләрен үз иҗат биеклекләреннән кара җир “чынбарлыгына” тартып төшердек.

Әдәби әсәр каһарманнарын тормыштагыларга якынайту бик кирәк тә кебек—чөнки безнең, әдәбияттан укып, үз-үзебезне таныйсыбыз бар иде. Таныдык та, “көзгегә” баккан килеш исебез китеп торабыз менә. Чынлап та безме соң бу? Бигрәкләр дә пычранганбыз, гөнаһка батканбыз, миһербансызланганбыз, йөзебезне үк югалта барабыз икән бит. Инде тәүбә итү, мәңгелек тәмуг газабыннан котылу әмәле дә юк икән безгә—барысына кул селтәп, элек ничек яшәгән булсак, калган гомеребезне дә шулай дәвам иттерергә генә дучарбыз. Әдәбият белән реаль тормыш үзара ярышып, бер-берсеннән өйрәнеп казна караклары, мафия, азгынлык корольләре һәм королевалары, алар янында ялманып йөрүче мескеннәр үрчетә. Инде менә яшьләр дә шундый каралыкны язып әдәбиятка килә. Әле генә Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителгән Рәмзия Габделхакованың 27 июньдә “Ватаным Татарстан”да дөнья күргән хикәясе “Соңгы һөҗүм” дип атала. Әсәр каһарманы, заманында фашистларга каршы кыю сугышкан Гафур карт гомер азагында үзенең хәләлдән-хәләл пенсия акчасын ай саен эшлексез имгәкләр төркеменә биреп барырга мәҗбүр ителә. Чөнки бүген дәүләт тә, законнар да кыерсытылучы гади кешеләрне чынлап якларлык хәлдә түгел, алар барысы да көчлеләр һәм акчалылар ягында.

Рәмзия Габделхакова хикәясенең азагы да фаҗигале: Гафур карт имгәкләрне өенә бикләп ут төртә дә, үзе йөрәгеннән тотып җиргә ава. Әйе, соңгы һөҗүм аның файдасына түгел: ул—коточкыч гаҗизлектән, бер чарасызлыктан үлеп котылучы гына. Яшь мәлгуньнәр төркеме уттан исән чыгачак, хәтта бер сабак та алмаячак, аларга беркем җәза бирмәячәк. Чынбарлыгыбыз шундый. “Хосусыйлаштыру нәтиҗәләре кабат каралмаячак”—Путинның чираттагы сайлау уңаеннан иң төп вәгъдәсе әнә шундый булырга охшап тора. Чөнки аның сайлану-сайланмавы Гафур картларга түгел, хосусыйлаштыру чорында

---

*Дискуссиядә катнашучы авторларның фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин.*

кулларына хәрам мал эләктереп калучыларга бәйле. Хәрамлеген үзләре дә таныйлар, югыйсә, эшнең кабат каралуыннан өркеп тормаслар, карала калса, илдә коточкыч гражданнар сугыша башланачак, дип кисәтмәсләр иде. Ә җәзасыз калган һәр гөнаһ яңа гөнаһлыларны тудыра. Тиңсез көрәштә Гафурны һәлак иткән мәлгуньнәрне без әдипләрнең "заманча" яңа әсәрләрендә, һичшиксез, кабат очратачакбыз әле. Әнә, нәфис зат каләм ияләре дә үзара узыштан дөньябыз пычраклыгын яза. Сәмигә Сәүбанованың "Кызтәкә"се (*"Идел" журналы, N2, 2000 ел)*, Дилә Булгакованың "Үрмәкүч"е *("Сөембикә" журналы, N11, 1998 ел)*— "әстәгъфирулла" дип кенә укырлык әсәрләр. Бозыклык "анатомиясе"н шушының кадәр җентекләп тасвирларга кирәк бит! Тәҗрибәле әдибәбез Мәдинә Маликова да "Шәфкать"ләрдән "Алтын ятьмә"ләргә, "Өермә"ләргә кереп китте.

Узган гасыр азагындагы яңарыш елларында нәкъ үзебез кебек вак интригалар белән яшәүчеләрне, уй-хыяллары көнкүреш ыгы-зыгысыннан, парлашу-аерылышу кичерешләреннән уза алмаган, аның каруы, "уйлап чыгарылмаган" әдәби геройларны иң элек без чит ил телесериалларында күрдек. Изаура исемле кол хатын нинди якын тоелды безнең рухыбызга! Менә ул инде "Намус"та Гомәр Бәширов "уйлап чыгарган" Нәфисә түгел! Кол өчен дәүләтле булу да, милләтең дә, тел дә мөһим түгел: хуҗасының дәүләтен—үз дәүләте, аның малын—үз малы, аның телен—үз теле дип юана ул, артыгын уйламас, баш ватмас өчен, табигый ихтыяҗлар белән яши бирә. Укучыларның һәм тамашачыларның шундый әсәрләргә ябырылуы әдипләребезне аптыраш та калдырды, беркадәр рәнҗетте дә бугай, мәгез, алайса, кинәнегез, дигәндәй, кемдер уйлану-эзләнүләрдән соң, кемдер шактый җиңеллек белән "шул" темаларга кереп китте. Бу хәл прозада да, шигырьдә дә сизелә, соңгысында ул гамәлгә ашмаган якты хыяллар өчен сызлану, сагыштан моңлану белән үрелеп бара. Миңа калса, проза "бозыклык реализмы"на бигрәк тә каты биреште. "Казан утлары"ның 6 нчы санында басылган Әсгать Сәләх повестен ("Каеннар юлы") һәм Тәлгат Галиуллин романын ("Төнге юллар") укыган кеше әдәбиятта мондый "яңарыш"ның вакытлы гына булмыйча, әле бөтен киңлекне иңләп дәвам иттерелүен ачык күзаллый. Бүгенге әдәби геройлардан без хәзер "үзебезне" җиңел танысак та, алар торган саен кызыксызрак була баралар. Тормышта да, телеэкранда да, инде хәзер әдәбиятта да игечиге булмаган күңелсез хәлләр... Китапларның, әдәби журналларның азрак укылуында да күп сәбәпләрнең берсе шушыдыр, мөгаен. "Кол колны ярата алмый, чөнки үзе белән бергә бил бөгүчегә карап социалистик кол үзен күрә. Ничек яратып булсын шундый ялагай, куркак, хөсетле бәндәне!"—дип язган иде Миргазиян Юныс үзенең "Соңгы сулыш" әсәрендә (*"Казан утлары", N8-9, 1997 ел)*. Ә без әдәбияттан үзебез кебек "бил бөгүчене" генә күрәбезме? Андагы геройлар "куркак, ялагай, хөсетле" генәме? Аларны "күргәч" укучы имәнеп китәрдәйләре дә күбәеп бармыймы? Чынлап та, ничек яратып булсын аларны? Көчле, максатлы, бүгенге идеал дигәне дә йә бүтәннәрне изә-сыта үз байлыгын арттырырга, хатын-кызларны яулап алырга гына сәләтле, йә мәкергә остарак. Мисаллары, әнә, Тәлгат Галиуллинның соңгы елларда иң әйбәт укылган "Тәүбә", "Элмәк" романнарында. Андыйларга милләтең ни дә, дәүләтең ни! Депутат булып алганнары да үз төркеме мәнфәгатенә генә эшләячәк. Нәкъ тормыштагыча! Тик менә әдипләр хыялының шушыларны сурәтләү белән генә туктап калуы урынлымы икән? Алайса, күп сорауларыбызга җавапны кайдан эзләргә, тормышта кемне маяк итәргә? Әдипләр хыялын нәрсә чикли бүген? Моңа кадәрге хыялларның челпәрәмә килүеме, әллә тормышның аяусыз чынлыгымы? Әйе, бер сәбәбе шушыдыр. Җәмгыятебез—тирән торгынлыкта. Бүген гүя әдипләр—җәмгыятьтән, җәмгыять—үзенең әйдәүче көчләреннән яңа фикер, алга бер ыргылыш көтә, тик берсе дә беренче булып кузгалырга теләми. Көтеп тору, билгесезлек никадәр озакка сузылса, шулкадәр начар—"тымызык күлдә корт үрчи". Өметләрне җилкендергән милли кузгалыш чоры да әдәбиятта заман геройларын, халык каһарманнарын тудырырга өлгермәгән килеш пыскып сүнде. Югыйсә, әдәби геройга әверелерлек шәхесләребез мәйданга килгән иде. Алар азмы-күпме шигырьләрдә һәм публицистикада (әйтик, шагыйрь Рәфикъ Юнысның "Татарстан референдумы" китабы) гына чагылып калды, ә проза—әдәбиятның авыр артиллериясе—фикер җыйган арада татар милли хәрәкәтенең, "хөр мәмләкәт" идеясенең судларда хөкем ителү көннәре килеп җитте. Үз дәүләтчелегебез өчен, ирек, демократия өчен уңышлы гына кебек башланган көрәшнең казанында кайнаучы, Татарстанның бәйсез үз Конституциясен кабул итүдә, дәүләтнең үз символларын, үз Президентын булдыруда катнашып куанучы депутат-әдипләребез дә без көткән, безне алга чакыра торган әдәби геройлар тудырырга өлгермәде.

Киләчәкнең ачык булмавы, туннель азагында бер яктылык күренмәү язарга уйлаганнарның да илһамын алды: байтак әдипләр, бүгенге вәзгыятьтә геройларының бәхетле киләчәген, көрәштә җиңеп чыгуын "күрмичә", әсәрне аларның үлеме белән тәгәлләйләр. Илһам килерлек хәлмени: Татарстаныбыз үзенең бер ел яулаган, бөтен җәмгыятебездә рухи күтәрелеш кузгаткан шартлы гына мөстәкыйльлегеннән дә берничә ел буе тырышып чигенә инде.

"Ирекле" таралуны милләт җанлы язучы-депутатларыбыз да кузгатмады, күрәсең, парламентта калып, мөстәкыйльлекне әйбәтрәк сакларга уйлаганнардыр. Язучы Фәүзия Бәйрәмова, ике тапкыр омтылып та Татарстан Дәүләт Советына сайланмый калгач, халыкка беркадәр дәгъвә-үпкә белдереп язган иде. Депутатлыкка үткәрмичә, язмышымы, бер Ходаебызмы аны "йөз югалту"дан саклап калган икән. Чөнки мең газаплар белән үзе тудырышкан ирек, дәүләтчелек яралгысын үзе үк ашау аңа бигрәк тә кыен булыр иде. Бер үзе көрәшеп тә ни кыра ала!

Ирешелгәннәрдән чигенмәгән булсак, мөстәкыйльлек юлына басарга яңа җай чыккач, эшләп китү өчен әзер базабыз булачак иде. Кем ихтыяры беләндер, без аннан да колак кактык. Тагын бер тапкыр өр-яңадан башлау өчен көч хәзергедән дә күбрәк кирәк булачак. Үзәк тә "хаталарын" кабатламаска, сәясәт йөгәнен азга гына да йомшартмаска тырышачак. Дөрес, Татарстан бүген алар өчен проблема түгел инде, аны "хәл иттеләр", ә менә татар халкы белән ни эшләргә? Бүген чигенгән лидерлар урынына иртәгә ныграгын, изге юлдан тайпылмый торганын тудырырга сәләтле икән ич бу халык! Димәк, иң элек халыкның рухын сындырырга кирәк. Беренче чиратта—рухсыз әдәбият, бозыклык телевидениесе белән! Карагыз, "Татарстан—яңа гасыр" исемле бөтенебез өметләнеп көткән "милли татар телевидениесе"ннән ни килеп чыкты?

Романтиканы, бөркетләрнең табигый төстә кыяларга омтылышын да әдәбиятыбызга теләп-чакырып кайтара алмыйбыз. Эзләнүчән "Идел" журналы матур эш башлап карады: каләм ияләренә алдан хәбәр итеп, романтик сан чыгарды. Тик андагы бөтен романтика Илдар Юзеевның бер драмасына, Габдрахман Әпсәләмовның бер романына яки Мирсәй Әмирнең бер "Агыйдел"енә торырлык микән? Шуңа күрә бүгенге укучы "Элмәк"ләрне, "Үрмәкүч"ләрне, безне алга дәшеп, киләчәгебезгә юл күрсәтеп тора торган халык каһарманнары урынына, ниндидер албасты, убыр, сихерче, күрәзәче кебекләрне укып канәгатьләнергә мәҗбүр. Тик аларга ияреп ерак китәрбез микән соң? Саташып кына бетмәбезме? Кайбер каләм ияләре, дәүләтчелегебез өчен көрәш башындагылардан ниндидер "феномен"нар ясап, калын-калын ялтыравыклы китаплар да чыгардылар, шулай ышаныч казандылар, әмма аларны әдәбиятта безнең заман герое дәрәҗәсенә күтәрә алмадылар.

Халыкның бүгенге рухи тормышын, дәүләтчелек өчен, үз хокукларын киңәйтү өчен авыр көрәшен, ул көрәштә җиңелүен һәм киләчәктә, һичшиксез, җиңәчәген, ирекkә омтылышын киң планда, күңел төшенкелегенә бирелмичә яктырткан әсәрләрне көтүебез шулкадәр көчле, әдипләребезнең һәр иҗат җимешен "шушы түгелме?" дип укырга керешәбез. Флүс Латыйфиның "Ишелеп төшкән бәхет" романын "Казан утлары"нда кулга алып, беренче битләрен укый башлагач та шулай кыбырсып куйган идек. Чөнки элегрәк дөнья күргән "Хыянәт"еннән соң, халык гаме белән гамьләнә, бүгенгенең тамырларын тирәннән эзли, офыкның арьягына да караш ташлый ала торган әдип дип, аңа өметебез арткан иде. Ә яңа романында ул татарның тамырларын тарих тирәнлегеннән генә түгел, дөнья киңлекләреннән эзләп яктыртырга һәм шул тамырларны бүгенгегә китереп ялгарга батырчылык иткән кебек. Ходаем ла, милли мохитебезнең мәйданы әнә нинди зур икән, моңа кадәр күреп кенә җиткерә алмаганбыз. Анда әдипләребез дә "кермәгән" иде шул, яңа заманда аны Тәүфикъ Әйди белән Флүс Латыйфи гына башлады. Тамырлар киңлеген белү бик мөһим безгә: монда, кече татар илендә, бәләкәй Татарстаныбызда мөстәкыйль дәүләт кору өчен җитди эш башласак, рухи таяныч һәм теләктәшлекне әнә шул мәйданнардан эзли алабыз, дигән сүз.

Романны уку барышында хыялларыбыз белән дөнья киңлекләренә чыгып керәбез дә, әсәрнең баш каһарманы Сирингә ияреп, ул хезмәт иткән хәрби частька, солдат казармаларына килеп төртеләбез. Менә ул—безнең "ишелеп төшкән бәхет"! Ни хәл итәсең, әдип үз хыялы белән дөнья кинлекләрен колачларга, борынгы тамырларыбыз буйлап тарих тирәнлекләренә җитәргә, үз иҗатында дала иркенлекләренә омтылса да, ахыр чиктә җәмгыятьнең үзе яхшы белгән тирәнлеген, таныш мохитен сурәтләү белән чикләнергә мәҗбүр. Әйе, Гаяз Исхакый романнарына тиң эпик әсәрләр язу, гомуммилләт гамьнәрен аның дәрәҗәсендә күтәрү өчен, аныкы кадәр талантның булу өстенә, дөньяны аның кадәр күреп белү дә зарур, аралашу даирәсе дә киң булырга тиеш икән. Ә безнең бүгенге татар әдибе нинди киңлекләр күреп үсте, кайсы ил университетларында белем җыйды? Инде төрки кардәшләребез белән дә рухи бәйләнешләребез юк диярлек. Бер-ике шагыйрь-язучыбыз Төркиягә барып кайтса, алардан үзебез үк күпсенәбез. Читлектәй кысан бүлмәсенең сыңар тәрәзәсеннән нәрсә генә күрә безнең әдип? Яшьлегендә дә бар исендә калганы—солдат хезмәте белән чикләнә түгелме? Чөнки чит илләрдә, бәрәңге-фәлән үстерү тәҗрибәсен өйрәнү сылтавы белән, хакимнәребез генә йөреп торды. Аннары анда күреп кайткан рухи хөрлекне үзләре тудырган кысан мохит, караңгы чырайлы дөнья, гаҗизлек, моң-зарлы халык белән чагыштыралар да, килеп чыккан аерма өчен, каләм ияләрен гаепли башлыйлар. Яңасе, безнең әдипләрдән булмады инде: халыкны да тәрбияли белмәделәр, дөньяны да пакьламадылар, берсе дә

беркайчан "Война и мир" ише әсәр язып, милләтне Җир шарына таныта алмады, шуңа күрә "анда" безне белүче дә юк. Чөнки һәркайсының үзен бу роман-эпопеядагы Наполеон яки Кутузов итеп күрәсе килә. Ә чынлыкта бармы соң безнең реаль Кутузовыбыз? Кем ул? Алар булмаганга күрә дә Сириннәребез өстеннән тәкәббер лейтенант Майорчуклар гына командалык итә, буын-буын яшьләребезне әнә шулар әхлакый зәгыйфьли, кеп-кечкенә район хөкемдары милләт байрагын күтәргән фидакарьне юк гаебе өчен дә тотып ябa ала ич. Әнә 1937 ел азагында Татарстанның кеше ату һәм төрмәгә утырту планын ничек үтәве турындагы рәсми мәгълүматны да (лимиттагы 2350 урынына 2196 "гына" кеше атарга өлгергәннәр) Үзәккә Дәүләт иминлеге кече лейтенанты Горский язып җибәргән. Халык язмышын менә кемнәр хәл итә! Шушындый мохиттә туып үскән әдипләрнең иҗатына тәэсир итмичә, әсәрләрендә чагылмыйча кала аламы бу хәл? Ә бит, ишелепләр генә төшмәгән булса, бәхет дигәнебез Сирин Сабировка үзеннән-үзе килергә тора иде. "Татарстанның иң ерак төбәге саналган Зәй буендагы авылдан Казан университетына укырга кергән беренче егет" иде бит ул. Лев Толстой укыган университетка! Монда ул пар канатын—бәхет гөле Асияне тапты. Әмма укып бетерергә ирек бирмәделәр, мәкер корбаны ясап, икенче курстан ук солдат хезмәтенә озаттылар. Аның да иң хәтәр ноктасына! Тик бернинди дә очраклылык, әдип уйлап чыгарган гайре табигыйлык юк монда. Бәхете ишелеп төшәчәге Сиринненң язмышына ук салынган ич. Армиядән нурланыш зәхмәте эләктермичә, сау-сәламәт килеш кайткан булса да, йә эчүгә сабышып, йә әҗерсез авыр хезмәттә интегеп, гомерен вакытсыз очларга мөмкин иде ул. Миллионнар шушындый тормыш юлын кичә. Беркайчан кеше кадере булмаган, шәхесне, хәтта бөтен-бөтен милләтләрне михнәт казанында кайнатып кына "кеше итеп" яшәтә белгән, бүтән тәрбия чарасы да булмаган бу мәңгелек сугыш илендә тууың белән генә дә авыр киләчәгең билгеле инде синең. Хәтта исем-атың, әлеге романдагыча, "профессор" булса да. Монда бәхетле булып кыланырга гына мөмкин. Һәм шулай кылanучыларыбыз бар да. "Нинди бәхетлеләр сез, чөнки никадәр начар яшәгәнегезне белмисез", дигән иде чит дөньяның бер сәясәтчесе безнең хакта. Белә башладык менә, алда язганымча, моңа әдипләребез хәйран булышты инде. Әмма монда туктап калырга кирәкмидер, беркадәр алгарак, ераккарак та карарга вакыттыр.

Сиринне университеттан солдат хезмәтенә озаттыручы да әлләкем түгел, аның кебек үк студент Дамир Гыймаев. Асияне, сөйгәненнән аерып, үзенеке итәсе килә Дамирның. Аның әтисе—"смеш" майоры Гыймаев кайчандыр Кытай иленең Чәнчүн шәһәрендә татар милләтчеләрен аулый торган төркемгә командалык итә. Герман җирендә фашистларны җиңеп, инде илгә кайтабыз дип йөргән татар сугышчыларыннан туплыйлар бу төркемне. Аңа Сириннең әтисе Хафиз да кертелгән була. Ау вакытында "милләтчеләр атасы" Гаяз Исхакыйны кулга төшерә алмасалар да, "Идел-Урал" оешмасы сәркатибе Әмирҗан Акчуринны эләктерәләр. Әмирҗанның улы Илдар, "АКШларында тикшеренүләр һәм эзләнүләр" дигән күргәзмә белән Казанга килгәч, бирелдәге фәнни-тикшеренү институтларының берсендә эшләүче Сирин Сабиров белән таныша. "Тиешле" оешмаларда эшли торган Дамир Гыймаев аларның һәр хәрәкәтен күзәтеп йөри. Бу хәтәр "уен"да катнашучыларны татарның бүгенге милли-азатлык хәрәкәтенә китереп ялгау әдипнең зур отышы, әдәбиятыбызның без зарыгып көткән уңышы булыр иде дә бит, юк шул, ялганмый, чөнки буыннар өзелгән. Дамир Гыймаев "нәселе" генә нык тора, "шәҗәрә"се, төрле-төрле төсләргә кереп, гел тармаклана. Ирек дип, милләт дип авызыңны гына ач, әллә нинди сәбәпләр тапкан булып, хәзер җәзага тарттырырга мөмкиннәр. Дөреслек түгел, хөкем үзе алар ягында. Сириннәрнең фаҗигале тәкъдирен дә шулар билгели. Ә тулаем милләт фаҗигасенә, ихтимал, моннан дүрт-биш гасыр элек юл салынгандыр. Әнә шул чорда ул дәүләтсез калган. Без ул вакыйгаларның бер өлешен Флүс Латыйфиның "Хыянәт" әсәреннән укыган идек. Дәвамы исә "Бәйсез этләрне атарга" исемле роман-нәсерендә сурәтләнде. Бу әсәр дөньяга чыгып бер елдан артык кына вакыт узгач, Татарстан Конституциясенең бәйсезлек турындагы маддәләре Россия суды тарафыннан хөкем ителеп "атылды". Әсәрдәге тиз ышанучан, мәкер белми торган малай кебек, безнең җитәкчеләр дә, "атарга" җиңел булсын, дигәндәй, яңа туган мөстәкыйльлегебезне үз куллары белән бәйләп Мәскәү кулына бирделәр. Нәкъ шушылай килеп чыгасын "Бәйсез этләрне атарга" авторы шактый алдан сизгән, күрәсең. Менә ул—әдип пәйгамбәрлеге! Нигәдер, күңелсез фаразларыбыз ешрак аклана безнең.

"Ишелеп төшкән бәхет" каһарманы Сирин Сабиров романда никадәр реаль сурәтләнмәсен, татар укучысы күңеленә күпме генә якын булмасын, милләт башында торырлык кыю көрәшче түгел әле. Хәтта андый көрәшчене тудырып үстерерлек киләчәге дә юк аның. Әсәрдә без Сириннәребезнең ничек итеп буыннан-буынга рухи имгәтелүен генә ачык күрәбез. Ләкин, ничек кенә булмасын, Сирин ахырдан үзенә үги ана булган ватанны ташлап китәр көч таба. Ул заманнарда моның өчен чиктән тыш зур кыюлык, ихтыяр көче кирәк иде. Мондый нәтиҗәне, бәлки, әдип үзе дә көтмәгәндер, тормыш чынлыгы роман каһарман-

нары язмышын автор бөтенләй теләмәгән якка боргандыр. Безнең бөтен тормышыбыз диярлек үзебез көткәнчә, өметләнгәнчә, хыялланганча бармый ич әле. Көчсезлегебездән генә дә түгел бугай бу, тагын нидер җитми кебек безгә. Нинди көчле һәм тугры Тукаебыз да "Өзелгән өмид"ләрне язып, җаны сыкрап китеп барган.

Бүгенгенең әхлакый имгәтелмәгән әдәби героен, күтәренке рухлы әсәрен, бәлки, яшьрәк әдипләр, әйтик, матур хикәяләре белән өмет уяткан Зиннур Хөснияр язып яткандыр? Менә бит, "Терсәк сугышы" романының беренче юлларында сурәтләнгән күренеш борынгы бабаларыбызның киң дала тормышын күз алдына китергәндәй була. Әнә әрем арасыннан пырхылдап очкан ике нәни кош, күз күреме биеклегендә әйләнделәр-тулгандылар да, "кинәт югарыга, аккош каурые сыман ак болытларга таба күтәрелә башладылар. Алар иксез-чиксез күк белән хозурланып туя алмыйлар иде".

Ләкин кошчыкларның хозурлануы озакка бармый, каяндыр килеп чыккан иләмсез дәү кош тегеләрнең берсен авызына кабып, икенчесен тырнагына эләктереп, кыя башыннан егылып төшкән таш кебек, җиргә якынлашты... Төшеп җитәм дигәндә генә кош балаларын мәхбүслектән ычкындырып, ирекkә җибәрде; тегеләре исә, чырык-чырык елашып, болын өстеннән әйләнделәр дә, янә тузанлы әрем арасына кереп югалдылар".

Ходаем, монысы тагын—безнең күңелсез бүгенгебез ич. Хыялдагы зәңгәр ирекkә омтылганда гына яңадан тузанлы әрем арасына тартып төшерелгән кошчыкларны һәм "бөркеткә дә, тилгәнгә дә охшамаган кыяфәтсез кош"ны да таныйбыз, шул әрем арасының тын бугыч кысынкылыгына кабат кайтасыбыз килмичә җаныбыз бәргәләнгән көнебез бит безнең. Чын әдип боларны күрмичә һәм язмыйча кала аламы соң! Бу роман "Казан утлары" аша укучыга килеп җиткәндә Татар иленең, Төп Канунызбыздагыча, "Россия Федерациясе составында" үз "әремлегенә" кайтуына нибары ике ай калган иде. Ә без милләтнең хәзергесе хакында зур итеп язучы юк, дигән булабыз. Бәлки, "зур" итеп язарлык гамәлебез генә юктыр әлегә?

Кошларны күзәтеп, тузанлы юлдан җәяү генә авылына кайтып килүче Мөхәммәт—инде шактый танылган, эшләре чит ил күргәзмәләренә куела башлаган рәссам—иртәгә Сабан туена бармыйча, әти-әнисе өчен сарык көтүе чиратына чыгачак. Зиннур Хөсниярның Мөхәммәте тормышны тирәнрәк аңлавы белән Флүс Латыйфиның роман башындагы Сириненнән күпкә тәҗрибәлерәк инде. Белеме дә зуррак, аралашкан даирәсе дә киңрәк, тарихи һәм фәлсәфи мәгълүматка да баерак. Талантлары бер чамадыр, мөгаен. Урман кызы Гөлчәчәккә булган мәхәббәте Мөхәммәтне зур рәссам, ихтыярлы күренгән егет итеп үстерә, димәк, сөю-сөелү ягыннан да бәхетлерәк ул. Әмма тормыш дилбегәсе аның кулында түгел. Шунлыктан, күпләгән Мөхәммәтләрнең мәхәббәтен ваклау һәм ихтыярын сындыру яман чирле җәмгыять өчен берни тормый. Монда Сабан туйлары (яки республикаларның бүтән рәсми бәйрәмнәре) аерым, үз көтүе белән Мөхәммәт—аерым. Милләт кичерә торган уңышсызлыкларның төп сәбәбе дә шушы ике төркемнең берегә алмавында түгел микән? Бер як та бер-берсенә якынаймый, бер-берсен кичерә белми. Алар тартышкан арада, тагын да явызраклар, милләт хакын түгел, шәхси мәнфәгатен кайгыртучы алйотлар эләктерә бара дилбегәне. Теге икелекне мәңге килештермәү, гел чәкәләштереп тору өчен дә шушылар тырыша. Җитәкчеләр белән милләт җанлыларның, зыялыларның бер генә мәсьәләдә дә уртак фикергә килмәве, гел капма-каршы юнәлештә торуы мөһим аларга. Кызганыч, араларында язучылар, зур исемле әдәбият белгечләре дә бар.

Әнә Мөхәммәтнең яшьтие Сәмигулла, "мәктәптә укыганда бик тә надан, җылак малай", Казаннан чираттагы "Нива" машинасын алып кайтышлый, рәссамны соры тузан болыты эчендә калдырып, авылларына узып китте (монда автор бер нәрсәне алдан күрә белмәгән: Сәмигуллалар чит ил "арба"сына күчеп бетә инде). Тагын бер яшьтие һәм балачак дусты Барый, әтисеннән колхоз кабул итеп, авыл кадәр авылны тау башына күчерергә йөри. Бабасы шул авылны тау өстеннән үзәнгә төшереп утырткан булган. Хакимнәр халык өстендәге сынау һәм уеннарның да яңгыравыклысын, киң колачлысын ярата шул. Менә кемнәрнеңдер ихтыяры белән татарның мөстәкыйль дәүләтен кору уены уйнап алдык. Барый үзенең "зур" ниятен Ницше карашлары белән аңлатса да, студент чагында фәлсәфә фәненнән шактый мәгълүмат җыйган, дөнья белән кем идарә итә дигән сорауга җавап эзләп, масоннар белән дә нык кызыксынган, үзе әйткәнчә, әдипләр белән дә аралашкан, татарның чын тарихын яхшы белгән Мөхәммәт аны барыбер аңлый алмый. Димәк, монда да бер-берсен аңламый торган ике төркем. Әлегә боларның берсе дә әйдәүче көч була алмый. Ә аңлыйсы бик килә Мөхәммәтнең. Күп нәрсәләрнең серенә төшенми торып, "алдынгы сыер савучыларның портретларын яки натюрмортлар ясаудан ары китә алмаячакмын"—дип фикер йөртә ул. Тик яшәгән саен җавапсыз сорауларыбыз күбәя генә бара. Бәлки күп уйланудан киләдер бу. Монысы инде әдип-шагыйрьләребез казанышы да. Башларыбызга уй салып киләләр, димәк. Киләчәкнең тарихчылары кайта-кайта өйрәнерләр әле бу катлаулы чорны. "Гасыр капкасы ябылыр алдыннан безнең татар милләтен салып бәйләгән "капчык"ның авызын ачып алдылар. Бераз

һава керде. Иркен сулыш алып җибәрдек. Ул янә ныклап, каты итеп бәйләп куелды. Сулап калган һавабыз тагын күпмегә җитәр?!"—роман каһарманының һәм аның авторының уртак фикеredер бу. Сулап калган һавабызның бик озакка бармаячагын күпләр чамалыйлар, чөнки татарның "тынын" кысу гомер-гомергә ике яктан—Мәскәүдән һәм үзебезнекеләрдән—килә. Шуңа күрә, вак эшләргә, үзара ызгышларга түгел, мәгънәле гамәлләргә генә сарыф итәсе иде аз гына бирелгән ул "иркен сулыш"ны. Романдагы Барыйның авылны урыннан-урынга күчереп уйнавы бик гыйбрәтле бит, югыйсә. "Файдасы турында кем уйлап торган инде аның, брат. Самый главный хәрәкәт булсын. Селкенергә кирәк халыкка"—ди Барый. Шунда ук Ницше фикере: "Кем муеннан эшкә чумган, аның нәрсә эшләгәнен уйлап торырга вакыты юк". Ә Ницшене Гитлер да үз иткән, диләр.

Романдагы Мөхәммәтне, аның күп гамәлләрен, бөтәннәр белән мөгамәләсен аңлавы җиңел түгел. Әсәр, гомумән, әзерлекле укучыга исәпләп язылган кебек. Яшьлегендә бер зур максаты була Мөхәммәтнең: Гөлчәчәк урманын, кызы-ние белән, шәһәргә алып китәргә тели ул. Рәсемгә төшереп. Урманчы кызы Гөлчәчәк шәһәрдә урмансыз сулмасын өчен. Кызга шундый вәгъдә дә биргән иде. Ләкин рәсемне төгәлләгәндә Мөхәммәт үзе терсәк сугышларында шактый ук тәрткәләнгән, интригаларга кереп вакланган, мәхәббәттә дә суындырылган була инде. Максатка омтылу ихтыяры кайда ул, хәтта "киребеткән" кушаматы да тәңгәл килми инде аңа. Чөнки Сиринә Самуиловна да, дусты Барый да Мөхәммәтне әкрен-әкрен генә бөгеп, үзләре теләгәннең барысын эшләтеп киләләр. Аларда—өер бердәмлеге, өер көче. Шуның белән җиңәләр дә. Өергә каршы торырлык милли бердәмлек, милләтне бер максатка туплый алырлык каһарман җитми бүген. Зиннур Хөсниярның Мөхәммәте дә, Флүс Латыйфиның Сирине кебек, милләт узаманы, әдәбиятта безнең заман герое булып җитә алмадылар. Аның каруы, романнарны укып, без андый геройларның нилектән арабызда юклыгына ап-ачык, ышандырырлык җавап таптык. Бөгәләр дип бөгелгәнбез, таркаталар дип таркалганбыз, һәм... геройларыбыз юк дип тә артыгы белән ышанганбыз менә. Шуңа күрә дә "тапмыйбыз" аларны. "Эзләдем, бәгърем, сине" спектакленә шагыйрә һәм публицист Асия Юнысова язган бәяләмәдә игътибарга лаек шундый фикер бар: яратыгыз, мәхәббәт булмаса, уйлап чыгарыгыз, ди ул шушы әсәрдәгедәй яшьләргә. Чынлап та, очсыз-кырыйсыз гаҗизлектән интеккәнче, күңелендә уйлап кына чыгарылган, мәхәббәт, иман, идеал булу да әйбәтрәктер, бәлки. Тик менә андый идеалны әдип күңеленә кем һәм кайчан иңдерер? Җәмгыятьтән могҗизалы гамәл көтү урынсыз, чөнки без нинди булсак, ул—шундый. Бөрәзлексез үзебезнең авыр язмышыбызда казыну, чиребезне ачык күрсәтеп тә, аңа дәва эзләмәү безгә рух көче өстәми, әдәбият исә гасырдан-гасырга сүнгән йолдызлар, канатсыз акчарлаклар, өзелгән өметләр, бәхетсез егет һәм бичара кызлар, "атылган кош, адаштырган эттәй, үткәннәргә мәэюс карый" торган мескеннәр хакында кинәнеп, тәм табып яза, милләткә инкыйраз юрый. Әмма бу язулардан һәм безнең шуларны укуыбыздан бер файдалы нәтиҗә күренергә вакыттыр инде. Тормыш артыннан гына барырга түгел, кемдер алгарак карарга, ә бүгенге әдәбият иртәгәгә геройларын үзе үк тәрбияләшергә дә тиештер, ләбаса. Әдәбиятны фән буларак өйрәнә торган, бик аз санда булмаган галимнәребез, академиклар бу хакта ни уйлый, дөресрәге, уйлана микән? Әллә алар һаман да бүгенгене "борынгыга әверелгәч" кенә өйрәнергә исәплиләрме?

Татар килә! Марат Әмирхан аның килүен ераккарак, үзенең Кәшшафларыннан арырак карап күргәндер, мөгаен. Ерактанрак карый белмәгәнебезгә күрә генә әлегәчә аның килүен яки киләчәген абайламый торганбыздыр? Бәлки аның ат өстендә, сугышчы киемендә булуы да мөһим түгелдер бүген, чөнки үзгә чорда яшибез. Нәкъ шушылай, ерактанрак күрүче әдәбиятыбызга чынбарлыктагыдан алдарак та килеп керер ул—без көткән милли каһарман, заман герое. Кемгә ничектер, мин үзем аны Минтимер Шәймиев белән Фәрит Мөхәммәтшинга да, Туфан Миңнуллин белән Фәндәс Сафиуллинга да бераз охшаган итеп күз алдына китерәм, димәк, реаль тормыштан аерылган булмаячак ул. Тәкәббер хан кирәкми, үз милләтенә ачык йөзле булсын, халык белән киңәшеп эш итсен, берүк. Килсен татар!

# МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

*ТӨЗҮЧЕДӘН*

Бу сүзлек авторның төрле дини төшенчәләрне, аларның язылыш вариантларын, мәгънәләрен, милләт һәм дин тарихына кагылган әһәмиятле һәм кызыклы фактларны, тормышта эз калдырган күренекле затлар турындагы мәгълүматларны күп еллар буена көндәлек эш өчен теркәп барган дәфтәрләреннән, аерым кәгазьләрдән һәм картотекасыннан башланып киткән иде. Картотекасына төзүче Шиһабетдин Мәрҗани, Ризаэддин Фәхреддин, Әхмәтһади Атласи, Нәкый Исәнбәт, Фатих Әмирхан, Гаяз Исхакый һ.б. кебек күренекле шәхесләребезнең игътибарны җәлеп итәрлек фикерләрен, совет чоры китапларыннан сөрелгән хикмәтле сүзләрен дә терки барган иде. Тора-бара андый язмалар күбәеп, алардан файдалану кыенлашкач, төзүче тупланган төшенчәләрне, төрле гыйбарәләрне һәм совет хакимияте елларында онытыла төшкән канатлы сүзләребезне бер җепкә тезеп тәртипкә салырга керешкәндә, бәхеткә каршы, илгә компьютерлар үтеп керде, компьютерлашу чоры башланды. Әгәр берничә техник хезмәткәр эшен алмаштырган компьютер булмаса, ихтимал, төзүче ялгыз гына мондый күләмле эшне ерып та чыга алмаган булыр иде.

Әйтелгәннәрдән күренгәнчә, Сүзлегебез үзенең колачы һәм эчтәлеге белән гамәлдә йөри торган күпчелек сүзлек һәм белешмәләрдән аерыла. Асылда анда төрле характердагы, төрле юнәлештәге төшенчәләр бергә тупланган һәм мин мондый тарихи синтезда гайре табигый нәрсә күрмим, киресенчә, кристаллаша торгач, ул яңа сыйфатларга ия булган эретмә, ягъни Бер Бөтен тәшкил итте, татарның милли космосын киңрәк һәм панорамалы итеп ача торган китап туды дип уйлыйм.

Сүзлегебез практик максатларны күздә тота, хәзерге заман татар укучысын—гади укучыны—язма чыганакларга, тарихыбызга һәм иманыбызга якынайтуны, артык вакыт сарыф итмичә генә күпчелек тарихи, дини, фәлсәфи әдәбиятны зиһенгә алу эшен җиңеләйтүне максат итеп куя. Шушы күзлектән караганда, ул күренекле әдибебез һәм сәнгаткярыбыз Миргазиян Юныс күп тапкырлар тәкрарлаган "Татар Ренессансы"на хезмәт итәр дип өметләнергә батырчылык итәм.

Мин баштарак Сүзлекне "Кырык бакча" дип тә атамакчы булган идем. "Кырык бакча" исеме кадимирәк, дәрәҗәсезрәк, фәннилектән ерак булып тоелырга мөмкин. Дөрес, ахырда мин бу исемгә тукталмадым, ләкин ул исем белешмәнең характерын һәм колачын төгәлрәк чагылдыра кебек, ә тирәнлеккә килгәндә, объектив укучы монда бүгенге көн югарылыгыннан торып язылган һәм чор таләпләренә җавап бирерлек хөр фикерле мәкаләләрне яки сайлап алынган үлемсез цитаталарны күрми калмас дип уйлыйм.

А.Солженицын үзе төзегән "Русский словарь языкового расширения" сүзлегендә: "Телне баетуның иң әйбәт ысулы—электә тупланган, ә аннары җуелган байлыкларны кайтару" дигән фикерне алга сөрә. Безнең сүзлегебез татар дөньясында бу юнәлештә дә атланган тәүге адымнарның берсе. Ул онытылган сүзләребезнең кулланылыш үрнәкләрен һәм чикләрен күләмле генә мисал-иллюстрацияләрдә күрсәтеп, аларны тергезергә тырыша (*ак киек*—пушной зверь; *аламан*—отряд; *алык*—хан заманында халыктан җыеп алына торган салым, җыем, алык-салык, алман; *артыл*—хан сакчылары, ярдәмче гаскәр, арьергард. Хәзерге телдә: "әртил"; *аю сөңгесе*—аю аулаганда кулланыла торган (ике) җәпле сөңге, рогатка; *әшкярә*—ачык (ап-ачык, аермачык), күз алдында, яшермәстән, русча—гласно; *багавыл*—караучы, химаячы, опекун, авыл башы (*бәк авыл*); *беркетелмешләр*—крепостнойлар, чура-коллар; *бозгын божра*—логикада ялгыш (бозгын) дәлилләү,

руста: "порочный круг"; *боктырма* — яшеренгән гаскәр, поскак, засада; *бола* — чуалыш, фетнә, гыйсъян; *болачылар* — фетнәчеләр; *бөркетлек, боркытлык* — капище; *буралгы* — сукбай, русча — *бродяга*. Ихтимал, *бурлак* сүзе дә шушы буралгы сүзенә барып тоташа булыр; *бурган би* — шаман, кам. Сүзлеккә теркәлгән мондый сүзләр байтак, аларның саны, ихтимал, берничә йөздән ашып китәдер. Бу яктан караганда, Сүзлектә төрки асылга кайтырга, гомумтөрки һәм уртак сүз тамырларын эшкә җигәргә омтылыш та сизелә торгандыр дип уйлыйм.

Татар телендә һәм, гомумән, төрки телләрдә сан (бер, ике, өч һ.б.) атамаларының мәгънәләре һәм килеп чыгышы турында төрле чыганаклар нигезендә язылган материалларда да күбәүләр үзләре өчен яңалык табарлар.

Игътибарлы укучы төрле авторлардан алынган мисал-иллюстрация һәм өзекләрнең билгеле бер идеологик юнәлештә тезелүен, фикрияти система тәшкил итүен, гадәттә уйлануларга этәрүен дә күрми калмастыр. Бу яктан ул татар өчен мәшһүр саналган "Гарәпчә — татарча — русча алынмалар сүзлеге"нә, төрле объектив сәбәпләр аркасында, керми (кертелми) калган сүзләрне дә колачларга омтыла. Тәкъдим ителә торган сүзлегебез татар телендеге шәрык алынмалары сүзлеген алмаштыра алмаса да, аңа, "Гарәпчә — татарча — русча алынмалар сүзлеге"нә теркәлүләренә дә карамастан, шул заманның кырыс таләпләре яки нәшрият хезмәткәрләренең элементар куркаклыгы аркасында, дини-фәлсәфи мәгънәсе ачылмый калган лексик берәмлекләр дә кертелде.

Аннары, "Русча — татарча — гарәпчә алынмалар сүзлеге"ндә алынма сүз дип үк аталырга "хаклары житенкерәмәгән" берәмлекләр дә очрый. "Миллият сүзлеге"нә без андый окказиональ һәм сирәк сүзләрне теркәмәскә тырыштык, ләкин моны бәяләүдә субъективлыктан котылып булмавын да онытмаска кирәк.

Сүз һәм төшенчәләргә, аларның кулланылышына мисаллар китергәндә, ул мисалларның, беренче нәүбәттә, фикри кыйммәтенә, оригинальлегенә, тулылыгына һәм бөтенлегенә игътибар итәргә тырыштык.

Сүзлектә Татарстандагы, Русиядәге һәм чит илләрдәге байтак кына тарихи һәм хәзерге мәчетләр һәм мәдрәсәләр турында кыскача мәгълүмат бирелде. Әлбәттә, аларның Татарстанда булганнарын гына да теркәп бетерү мөмкин түгел (хәзерге вакытта Татарстандагы мәхәлләләр саны 1 меңнән артып китә). Һәрхәлдә, монысы — киләчәк эше.

Сүзлектә милләт тарихында эз калдырган, ләкин хәзергә кадәр нәшер ителгән белешмәләргә теркәлмәгән шәхесләр игътибар үзәгендә торды. Шул ук вакытта тискәре бәяләнә торган шәхесләр турында да мәгълүмат теркәлде, чөнки еш кына хәлләрдә аларның биографияләре һәм кылган кылмышлары чорны аеруча калку итеп чагылдыра (мәс., Ишми ишан, "Шкафчы Әхмәтҗан", "Һинди Минһаҗ", Мәмлиев Төхфәтулла һ.б. турындагы материаллар).

Бүгенге дин әһелләрен сүзлеккә теркәү мәсьәләсе исә шактый катлаулырак. Турысын әйткәндә, бу очракта, объективлык хакына, бер ун-унбиш ел көтү акылга муафыйк булыр иде кебек. Ул вакытларга дин әһелләребез дөньясы очраклы һәм җаһил гонсырлардан (элементлардан) арына төшәр дигән өмет бар.

Сүзлек Коръәнне татарчага тәрҗемә итүгә нисбәтле мәсьәләләрне игътибар үзәгендә тота, чөнки хәзерге вакытта, Изге Китапның татарчага күпсанлы тәрҗемәләре нәшер ителгән бер чорда, тәрҗемәнең пөхтәлеген тәэмин итү өчен, ныклы әзерлек кирәклеген онытып җибәргәлиләр.

Игътибарлы укучы Сүзлектә суфичылыкка аеруча зур игътибар бирелгәнлеген дә күрми калмастыр. Моның сәбәбе бер генә: Ислам философиясе суфичылыкта иң югары дәрәҗәсенә күтәрелә һәм нәкъ менә суфи әдәбиятта бүгенге позитив (иҗаби) фән әле генә ирешеп килгән хакыйкатьләргә һәм даһиларча алдан күрүләргә, пәйгамбәрлек үрнәкләренә тап буласың. Кызганычка каршы, безнең җирлектә совет хакимияте беренче чиратта нәкъ менә фикер ияләрен — димәк, тарикать әһелләрен — юк итү кирәклеген аңлап эш иткән...

Күп кенә очракларда, тарихи ачыклык кертү йөзеннән, Казан шәһәрендәге урам исемнәрен (искеләрен һәм яңаларын), табигать ядкярләрен, шулай ук аерым микротопонимнары да теркәү мәгъкуль күрелде, чөнки алар да безнең милли космосыбызга карыйлар. Язылышны унификацияләү өчен дә моның әһәмияте булыр дип өметләник.

Чыннан да, ихтимал, сүзлегебезнең язылыштагы чуарлыкны бетерүгә дә азмы-күпме файдасы тияр. Югыйсә, XIX гасырда ук мөстәшрикъ И.Н.Березин татарларның сүзләрнең язылышына игътибар бирмәүләрен һәм шуның аркасында

текстларны дөрес укырга уңайсыз булуын искәртеп китә. Бүгенге һәм фәнни, һәм популяр әдәбиятта, хәтта сүзлек-белешмәләрдә дә, бигрәк тә алынма сүзләрнең танымаслык дәрәҗәдә үзгәртеп язылганлыгына тап буласың. Хәтта, әгәр Березин әфәнде бүгенге китапларыбызны күрсә, татарның язу культурасы бер дә алга китмәгән икән дип уйлап куяр иде сыман. Соңгы елларда күпләп нәшер ителә башлаган дини китапларыбызда бу кимчелек аеруча күзгә ташлана. Хәтта пәйгамбәрләр исеменең язылышы да тотрыксыз, сүрә исемнәрен язуда да чуарлык хөкем сөрә. Мондый чуарлыктан телебезнең үзенчәлекләре өчен яраклы латин хоруфатына күчкәч кенә котылып булыр шикелле, ләкин бу юнәлештә хәзер үк эшләргә кирәк. Мин һич югында төрле вариантларны бергә туплап, аларны чагыштырырга, бәяләргә һәм мөнәсәбәтемне белдерергә тырыштым.

Аерым очракларда төзүче кулъязма хәлендә сакланган борынгы сүзлекләргә мөрәҗәгать итеп, алардан да файдаланды. Мәс., *мәгълүмләү* (игълан итү, халыкка белдерү, публикация) сүзе Казан университетының Фәнни китапханәсендә саклана торган кулъязма сүзлектән алынган.

Әлбәттә, Сүзлегебез гадәти энциклопедияләрне алмаштыра алмас, ләкин кайбер мәсьәләләрдә коры энциклопедия мәгълүматларын тулыландырырга да мөмкин.

Укучы Сүзлегебездә еш кына "кетелмәгән информация"гә дә тап булып, ул мәгълүмат төшенчәне (теманы) өстәмә рәвештә ачыклый алса яки теге яки бу фактны истә калдырырга ярдәм итсә, төзүче аеруча канәгать булыр иде.

Сүзлекнең тулылыгына килгәндә, төзүче аның әлегә камиллектән ерак торуын бик яхшы аңлый һәм шуңа күрә аны "Дини-тарихи аңлатмалы сүзлек өчен материаллар" дип атады да. Ләкин киләчәктә Сүзлекнең лөгатьлеген тагы да тулыландыру һәм төзекләндерү күздә тотыла. Мәс., сүзлектә сугыш киемнәре темасын тиешенчә ачарга, аларны классификацияләргә һәм тасвир итәргә әлегә мөмкинлегем булмады.

Киләчәктә, әлбәттә, мәкаләләрне бердәйләштерүгә дә, тарихи даталарны ачыклауга да, персоналияләр исемлеген киңәйтүгә дә ныграк игътибар ителер, тик шунысы хак: мәкаләләрдәге шәхси төсмерләрне, үзенә бер төрле "кыр чәчәкләре"н, үткәнебезне сагыну кебегрәк ностальгия хисләрен дә саклап каласым килә.

Сүзлекнең ахырында бирелгән "Әдәбият" исемлеге төзүче файдаланган һәм мөрәҗәгать иткән барлык чыганакларны да колачлап бетерми. Анда күрсәтелгәннәрдән тыш, мин күпсанлы (нигездә рус телендәге) энциклопедияләргә һәм йөзләгән татарча газет-журнал мәкаләләренә дә таяндым. Шунысы куанычлы, сүзлектә урын алган күпчелек темаларга үзебезнең татар һәм мөселман авторларыннан матур-матур өзекләр, канатлы сүзләр һәм хикмәтләр табарга мөмкин икән. Юк, милләтебез төшеп калганнардан түгел, халкыбызда фикер ияләре, чын гыйлем әһелләре җитәрлек (булган һәм бар), ә төркилеген гасырлар буена саклап кала алган телебез иң нечкә һәм "гали материяләр" турында да фикер йөртергә мөмкинлек бирә икән. Сирәк очракларда "Шан кызы дастаны" кебек тарихилыгы икеле булган мифологик чыганакларга да мөрәҗәгать ителде, чөнки алар да, мәгълүм дәрәҗәдә билгеле, яңа эзләнүләргә этәрәләр. Мәс., "Шан кызы дастаны"на *(Микаил-Башту Ибн Шамс Тәбир, Әнкара, 1991)* кушымта рәвешендә бирелгән сүзлекчәдәге борынгы болгар тәңреләренең исемлеген безгә башка чыганаклардан билгеле булган реестр белән чагыштыру да җимеш бирергә мөмкин шикелле. Фальсификация дип уйланыла торган "Җәгъфәр тарихы"нда Казан мәчетләре турында китерелгән кайбер мәгълүматларны да гипотеза тәртибендә кабул итәргә ярый дип уйлыйм. "Җәгъфәр тарихы"нда телгә алынган затларның характеристикасы башлыча И.Р.Мусинаның "История Древней Руси в булгарских летописях Бахши Имана "Джахфар тарихы" дигән хезмәтеннән алынды *(Йордан Табовның "Когда крестилась Киевская Русь" китабына кушымта)*. Шулай ук Хисаметдин бине Шәрәфетдин әл-Мөслиминең "Тәварихы Болгария" ("Болгар тарихы") китабында да дөресләккә туры килә торган фактларны табарга була. Олжас Сөләйменовның "Аз и я", Морад Аджиның "Европа, тюрки, Великая степь" китапларына карата да шуны ук әйтә алам. Һәрхәлдә, бу очракларда чыганак атап күрсәтелде һәм мин укучыбызның сәламәт, тәнкыйди акылына исәп тотам.

Сүзлекнең структурасы турында бер-ике сүз.

Сүзлектә сүрәнең исеме янында җәя эчендә бирелгән сан сүрәнең Коръәндәге тәртип номерын күрсәтә.

Коръән сүрәләренә юнәлткәндә сүрә һәм аять номерлары гадәти гарәп цифрлары белән бирелде. Мәс., *(3:152/145–175/169)*– Коръәндәге өченче сүрәнең

152 ннчедән алып 145 нчегә кадәр аятьләре һәм 175 нчедән алып 169 нчы аятьләренә кадәр дигән сүз. Аять номерларында әүвәл бездә кабул ителгән нумерация күрсәтелде.

Коръән сүрәләрен кайчан һәм ничә тапкыр уку файдалы һәм фазыйләтле булуы турындагы гамәли киңәш-рекомендацияләр башлыча "Коръәни-Кәрим" китабыннан алынды (төзүчесе – Фәрид хәзрәт Сәлман). Аларның күбесен аутотреннинг кысаларында аңлатырга һәм нигезләргә мөмкин. Теге яки бу сүрәне ничә тапкыр (3, 7, 10, 18, 21, 40, 41, 70, 71, 100, 180, 1000 яки 40 мең тапкыр) кабатлау турында санлы күрсәтмәләр үзләре дә игътибарны җәлеп итеп, сораулар тудыралар.

Библиядәге шигырьләр нумерациясен Рим цифрлары белән күрсәтү кабул ителде.

Квадрат җәяләр эченә автор текстына өстәмә яки аңлатма сүзләр урнаштырылды.

Аңлатма өлешендәге куш авыш сызыклар ("параллелькалар") иллюстрация өчен китерелгән һәм курсив белән җыелган мисалларны, сүзнең кулланылыш үрнәкләрен, тотрыклы сүз тезмәләрен һ.б. ны аеру өчен куелды. Сүзнең берничә мәгънәсе булган очракларда һәр мәгънә өчен аерым куш сызык хезмәт итә.

Адлер ТИМЕРГАЛИН

## ШАРТЛЫ КЫСКАРТУЛАР ҺӘМ АББРЕВИАТУРАЛАР

A.D. – Anna Domini ("алла елы" мәгънәсендә). Миляди ел. Рус әдәбиятындагы Р.Х.га тәңгәл
*бор.* – борынгы
*бор.т.* – борынгы татарча
*бор.төр.* – борынгы төрки
*вә илх.* – һәм башкалар (һ.б.); "Ила ахири"дан кыскартып *илх.* сүзе ясалган
*г.* – гарәпчә
*гр.* – гарәпчә-русча
*грек.* – грекча
*г.с., г-с* – галәйһиссәлам
*гт.* – гарәпчә-татарча
*гф.* – гарәпчә-фарсыча
*гфт.* – гарәпчә-фарсыча-татарча
*иск.* – искергән
*к.* – казакъча
*кер.* – керәшеннәрдә
*км.* – километр
*кыт.төрк.* – кытайча-төркичә
м. – миляди
*м.* – метр
мәс. – мәсәлән
*млн.* – миллион
*неол.* – неологизм
P.S. – постскриптум
*р.* – русча (һәм көнбатыш телләре)
*р.а.г.* һәм *р.а.* – Разый Аллаһу ганһу
*рф.* – русча-фарсыча
*с.г.в.* – салләллаһу галәйһи вәсәллам
*с.г.с.в.* – салләллаһу галәйһиссалатү вәссәлам
*см.* – сантиметр
*т.* – татарча
*төр.* – төрекчә
*тар.* – тарихи
*тф.* – татарча-фарсыча
*ф.* – фарсыча
*фг.* – фарсыча-гарәпчә
*фт.* – фарсыча-татарча
һ. – һиҗри
һ.б. – һәм башкалар
чаг. – чагыштыр
я.э. – яңа эра (безнең эра)

## СҮЗЛӘРНЕҢ АЛФАВИТ ТӘРТИБЕНДӘ БИРЕЛЕШЕ

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Аа | Әә | Бб | Вв | Гг | Дд | Ее | Жж | Җҗ | Зз | Ии |
| Ий | Кк | Лл | Мм | Нн | Ңң | Оо | Өө | Пп | Рр | Сс |
| Тт | Уу | Үү | Фф | Хх | Һһ | Цц | Чч | Шш | Щщ | Ъъ |
| Ыы | Ьь | Ээ | Юю | Яя | | | | | | |

*АБ ф.*—Су. Гадәттә кушма сүзләрдә очрый: *абруй*—йөз суы, авторитет. // *Аб вә нан*—су һәм ипи, ипи-су. *Аб зәмзәм*—Зәмзәм суы. *Абе бәка*—мәңге суы. *Абе зөлал*—саф, салкын су. *Абе Кәүсәр*—Кәүсәр суы. Шигърияттә "күз яше" мәгънәсендә дә очрый. Гарәпчә "*маи зәмзәм*" дә "зәмзәм суы" дигән сүз. *Гөлаб*—гөл суы. *Абе раван*—агымсу. *Ширин аб*—татлы су. *Шураб*—тозлы су.
Фарсы телендә күплек саны шәкеле—*абһа* (сулар).

*АБЕЛХӘЯТ, АБХӘЯТ фг.*—Терек суы, тереклек суы (мәңге суы). Күчерелмә мәгънәдә—*аракы*. Сәйф Сараида "абелхәят" мәгънәсендә *абе хәйван* сүзе очрый. Кайбер риваятьләрдә *чишмәи абелхәят*—терек суы чишмәсе. Риваяттә бу чишмәдән су эчкән кеше мәңге вафат итми тора һәм *Хозыр Ильяс* та шуның суын эчкән, дип сөйләнелә (*Хозыр суы* дигән төшенчә дә бар). Аннары Аллаһы Тәгалә чишмәи абелхәятне кеше күзеннән яшергән. Риваятьләргә караганда, бу чишмә ниндидер бер караңгы җирдә икән. Искәндәр Зөлкарнәин, абелхәят чишмәсен эзләп, Көнбатышка сәяхәт кылганда үзенә Хозырны да ияртеп барган имеш. Аннары Хозыр, Сөләйман Бакырганиның шигырьләренә сокланып, аның авызына төкергән дә, шуннан соң Бакыргани үлемсез шигырьләр иҗат итә башлаган дип сөйлиләр.
// *Кем, караңгылык эчендә табылыр абехәят (Сәйф Сараи).*
"Суфичылык серләре" китабында бу сүзнең *аб-ы бәка, аб-ы җавидан, аб-ы хайван, аб-ы Хызыр, аб-ы рәуан, аб-ы зиндәги, аб-ы Искәндәр* һ.б. синонимнары китерелгән.
XIII гасырда Европада икмәктән куылган аракы күренә башлагач, аны aqua vita, ягъни "терек суы" дип атаганнар һәм ул башта аптекаларда дару сыйфатында сатылган. Көньяк Русьта бу суны баштарак "оковита" дип атаганнар әле, "водка" атамасы (*су* сүзеннән) соңрак килеп чыккан. Украинада аны, ут ярдәмендә хәзерләнүеннән чыгып, "горилка" дип йөрткәннәр.
Абелхәятнең капма-каршысы—үле суы.
*Әбелхәят* язылышы да очрый.
Тагын кара: *Хозыр Ильяс, Зөлкарнәин.*

*АБЫЗ*—Ш.Мәрҗани фикеренчә, "*хафиз*" сүзеннән үзгәреп барлыкка килгән атама: "Хәзерге көндә телебездә калган "абыз агай", "абызтай", "абзый" сүзләре дә шуннан алынган. Тора-бара ул олы яшьтәге яки, чама белән генә булса да, ниндидер өстенлеге булган кешегә олылау теләге белән әйтелә торган сүзгә әйләнеп киткән".
Электә һәр авылны һәм өммәтне (общинаны, җәмәгане) аксакаллар (шурасы) идарә иткән. Аксакаллардан башка, авыл башында иң хөрмәтле кешеләрдән берсе—*абыз* торган *("Татары Среднего Поволжья и Приуралья", VIII бүлек, Г.М.Хисаметдинов)*. Тормыш-көнкүрештә килеп чыккан барлык бәхәс-низагларны хәл итү өчен абыз катына килгәннәр. Шул рәвешле, башта абызлар үзенә бер төрле демократик идарә функциясен дә башкарганнар. Халык кузгалышлары, чуалышлар вакытында абызларның шушындый халыкчан тенденцияләре калкып чыккан һәм, гади халык арасыннан күтәрелгән кешеләр буларак, абызлар хакимият башында торучы феодалларга, аксөякләргә каршы көрәшергә тиеш булганнар. Әлбәттә, тора-бара, иҗтимагый үсеш-үзгәреш нәтиҗәсендә, абызлар катлавы, гавәм арасында үзләренең элекке рольләрен һәм дәрәҗәләрен югалтып, эре феодаллар белән бер тарафта торып эш итә башлаганнар. Нәкый Исәнбәт: *"Абызлар халык күтәрелешләре вакытында җитәкчелекне үз кулларына алып, явыз хөкемнәр йөрткәннәр"*,—дип яза.
Төбәк Россиягә кушылып, элекке хакимиятләр юкка чыккач, халык авылларда сайланып куелган старосталарны, десятникләрне әүвәлгечә абызлар дип атап йөрткән әле.
Степан Разин үзенең татарларга язган мөрәҗәгатендә *"әһле мәчет баш абызларны"* телгә ала (XVII гасырның икенче яртысы). Т.Җанузаков *Абыз* исеме гарәби чыгышлы, "саклаучы, яклаучы" дигән мәгънә аңлата дип саный (Г.Саттаровның "Татар исемнәре сүзлеге" бу мәгънәне аерып карый). Ләкин Алтай төбәгендә яши торган һәм мөселман булмаган төрки халыкларда да (телеутларда, шорларда һ.б.) "абыс" сүзе актив. Мәс., алар рус руханиын (попны) *"абыс"* дип, ә архиерейны *"улу абыс"* ("өлкән абыс") дип атыйлар.
Шунысы кызык, удмуртларда (вотякларда) һәм мариларда татардан кергән *абыз* сүзе ырымчы, им-томчы мәгънәсен белдергән *("Религия у народов волжско-камского края прежде и теперь", 1929)*. Бу сүз чуаш теленә дә үтеп кергән.

Шуңа күрә безнең якларда абызлар табиблык белән дә шөгыльләнгәннәр дип әйтә алабыз.

*АБЫЗ ТУТЫКАЙ, АБЫЗ ТУТАЙ*—хафиз (укый-яза белә торган?) кардәш апа, ягъни *абыстай* сүзе чыннан да кыскару нәтиҗәсендә килеп чыккан булырга тиеш сыман. Р.Әхмәтьянов та шушы фикердә. Ул: "Абыз "ученый мулла, интеллигент, писарь, дьяк (во времена Казанского государства)"—гом. кыпчак сүзе, гар. хафиз "(Коръәнне) яттан белүче" сүзеннән үзгәргән: элек гаиләдә иң олы баланы укырга җибәргәннәр, шуннан абыз-ый, абыз агай "өлкән ир туган мәгънәсен алган",—дип аңлата. Ләкин мәсьәлә катлаулырак шикелле. "Абыз" тамырының мәгънәви диапазоны бик киң һәм ул туганнар арасында эндәшү формасы булып кына калмаган. Ульян өлкәсенең Карсун сөйләшендә *абзалим абз'и, абыз абз'и, күркле абз'и, матур абз'и, хүрмә абз'и, чибәр абз'и* кебек сәеррәк сүзләр очрый. Минзәлә сөйләшендәге *шәкерт абзый* сүзе исә *абзалим абз'и* белән мәгънәдәш (кат-кат укымышлылар, галимнәр?). Мәләкәс һәм Чистай сөйләшләрендә каенсеңелләренә *абызастай* дип дәшәләр икән (ягъни формаль яктан *абыстай* сүзенә тәңгәл диярлек). "Татар теленең диалектологик сүзлекләре" *(Казан. 1969, 1993) "абзалим абызстай", "абыз абыстай", "севәр абыстай"* (яраткан абыстай), *"туганым абыстай"* сүзләрен дә белә. Тау ягы сөйләшләрендә *"абҗанага"* (абызморза, ирнең агасын, биаганы шулай дип атаганнар), *"абҗиңги"* (иң олы абыйсының хатынына эндәшү сүзе) бар. Бу соңгы очракларда "хафиз" сүзе инде бөтенләй төсмерләнми, сизелми.

"Мулла абзый" сүзенең телдә актив булуы бик аңлашыла. Чистай якларында "мулла абыстай" сүзе дә йөргән. Татар телендә "ишан абызтай" сүзе дә билгеле. Татар диалектларында "абыз эти" (өлкән эти, остаз эти—бабай), "абызбабай", "абыз әни" (өлкән әни—әби), "абыз әби", "абызҗиңги", "абыз бикә", "абыздәдәй", "абызагай", "абызморза" (Темников якларында килен иренең абыйсына шулай эндәшкән), "абызлачын" (Темников якларында килен кеше каенсеңелесенә яки иренең туганнан туган кыз кардәшенә шулай эндәшкән), "абызапа", "абызтүти", "абызтүтеш", "абыстуганый" (каенсеңелесе җиңгәсенә шулай эндәшкән), "абыстуды" (туганнан туган апа), абыстумачи (килендәшләр берберсенә шулай эндәшкәннәр) сүзләре дә очраган.

Телдә "абыз"ның нечкә варианты да күзәтелә: "Диалектологик сүзлек"тә (1969) әбзи, әбзә(й), әбзәни, әбзәнкий, әбзәткий, әбзәңкә сүзләре дә теркәлгән.

"Абыз" сүзе исем компоненты буларак та актив. "Татар исемнәре сүзлеге"ндә "Абыз", "Абызбай", "Абызбакый", "Абызбикә", "Абызкилде" ("Абызгилде"), "Абызгәрәй", "Абызхан" исемнәре теркәлгән. Чыганакларга караганда, XVIII гасырның беренче яртысында Арча төбәгендә Габдеррәзак Алма абыз углы дигән хәттат яшәгән. Татар телендә Абызов, Абязов, Абызагаев фамилияләре билгеле. Шул ук вакытта татар исемнәре хәзинәсендә "Хафизниса", "Хафизҗан", "Хафизхан" исемнәре дә бар.

Шушылар нигезендә абыз һәм хафиз сүзләрен генетик яктан тәңгәлләштерү безгә шикле тоела. "Хафиз" сүзе үзе телдә сакланган хәлдә, аның фонетик варианты булган "абыз"ның гадәттән тыш активлашуы, мәгънәви колачы һәм таралыш географиясе гаҗәпләндерә. Ихтимал, "абыз" сүзенең тамырын төрки телнең үзендә эзләү нәтиҗә бирер иде. Мәс., ир-ат исеме Абай өлкән ир туган мәгънәсенә ия (гомумтөрки туганлык термины аба-га -ай кушымчасы ялганып ясалган). Казакъ һәм кыргыз телләрендә Абай исеме "сак", "игътибарлы" мәгънәсенә ия икән *(Г.Саттаров)*. Бу мәгънә аны тагын гарәпчә "хафиз" сүзенә якынайта һәм абый-абзый-абыз терминнарының килеп чыгышына күпмедер ачыклык кертә ала шикелле. Һәрхәлдә "могтәбәр апа, әби, бабай, туганый, килендәш" кебек эндәшү сүзләре колакны сагайтмас иде. Боларга өстәп, тагы казакъ телендәге "абзалы" (иң яхшы, барыннан да яхшырак) сүзен искә төшерү урынлы. Мәс., казакъчада "адәмнең абзалы"—адәмнәрнең яхшысы дигән мәгънәдә. Бу сүз исә гарәпчә "әфзал(ь)" (артыграк, кадерлерәк, яхшырак) сүзенә барып тоташа. Кыскасы, "абыз" сүзе "әфзаль"гә бик ерак тормый дияргә була.

*Дәвамы алдагы саннарда*





# 65—ТАЛАК (ТАЛАК) СҮРӘСЕ

*(Талак сүрәсе 12 аятьтән тора. Мәдинәдә иңгән.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Әй, пәйгамбәр, хатыннарыгызны аерасы булсагыз, гыйддәт вакытын төгәл тотып, санап аерыгыз. Раббыгыздан *(җәзасыннан)* куркыгыз. Ачыктан-ачык әшәкелек кылмасалар, аларны өегездән куып чыгармагыз, үзләре дә чыгып китмәсен. Менә Аллаһ куйган чикләүләр. Аллаһның чикләрен бозган *(хәттин ашкан)* кеше, һичшиксез, үзенә зарар китерәчәк. Белмәссең, моннан соң Аллаһ ярдәме илә хәлнең үзгәреп куюы да бар бит әле *(ир кешенең кире уйлавы бар).*

*(«Гыйддәт вакыты–хатынның өч тапкыр күрем күреп, пакьләнү вакыты була. Аерыласы хатын, ире аңа якынлык кылмыйча, өч тапкыр пакьләнергә тиеш. Балага узганмы, узмаганмы икәне беленсен өчен. Балага узган хатынны аерырга ярамый. Талак кылучы ир кинәт кенә аерган хатынына тартыла башласа, яңадан кушылып тора башлар өчен талакны өч тапкыр әйтмәскә тиеш. Ягъни, ир кеше: аерам, талак итәм, сүзләрен ашыгып әйтмәскә, ул сүзләр белән сак кыланырга тиеш».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

**2.** Гыйддәт вакыты узганнан соң, хатыныгыз белән яхшы торырга ният итсәгез, никахыгызга кайтарыгыз яки аны кануни нигездә аерыгыз. Бу эштә гадел булган ике кешене шаһит итеп алыгыз. Алар шаһитлекләрен Аллаһ куйган чикләрдән чыкмыйча башкарырга тиеш. Бу–Аллаһка һәм Ахирәт көненә ышанганнар өчен куелган тәртип. Аллаһның җәзасыннан курыккан кешегә Аллаһ *(кыенлыклардан)* чыгу юлын күрсәтер. **(3)** Һәм аңа көтелмәгән җирдән ризык бирер. Аллаһка ышанган кешегә бер Аллаһ җитәр. Шик юк ки, Аллаһ Үз әмерен җиренә җиткерми калмый. Аллаһ бөтен нәрсә өчен чик һәм үлчәү куйды.

**4.** Аерасы хатыныгызның *(картлык яки авыруы сәбәпле)* айлыклары бөтенләй туктаган булса, яшь булып та айлыгы булмаган хатыннарыгызны аерганда *(балага узмадымы икән дигән)* шиккә калсагыз, гыйддәтләре өч ай булыр. Йөккә узган булсалар, бала туганга чаклы аерылмаслар. Аллаһтан *(җәзасыннан)* курыккан кешегә Аллаһ кулайлыклар бирер. **(5)** Менә болар Аллаһның сезгә иңдергән боерыклары булыр. Аллаһтан (җәзасыннан) курыкканнарның хаталарын Аллаһ каплар вә аңа әҗерен бирер. **(6)** Көчегездән килгәнчә, аларга *(аерган хатыннарыгызга)* яши торган йортыгыздагы бер бүлмәне бирегез, аларны җәберләмәгез, рәнҗешләр китермәгез. Әгәр алар йөкле икән, бала тапканчыга чаклы аларны тәрбия кылыгыз. Сезнең балагызны имезгәне өчен аларга хакын бирегез, мәсьәләләрне үзара килешеп хәл итегез. Әгәр аңлаша алмасагыз, баланы башка бер хатын имезсен. **(7)** Мөмкинлекләре мул булган кеше *(аерылган хатынына)* күбрәк бирсен. Кысан хәлле булган ир дә Аллаһка биргән кадәрлесеннән өлеш чыгарсын. Мөмкинлектән артыгын бирергә Аллаһ берәүне дә мәҗбүр итмәс. Аллаһ бер кыенлыктан соң җиңеллек тә бирер.

**8.** Раббының һәм пәйгамбәрләрнең әмереннән ераклашып азган-тузган ничәмә-ничә кавемнәр булды. Без аларның халыкларын читен газапка тарттык вә аларны моңарчы күрелмәгән җәзага дучар иттек. **(9)** Шулай итеп, алар кылган азгынлыкларына күрә әҗерен дә татыдылар. Аларның ахыры да тәмам һәлакәт булды. **(10)** Аллаһ аларга дәһшәтле газап әзерләде. Әй, иман китергән зиһен ияләре! Аллаһның җәзасыннан куркыгыз. Аллаһ сезгә, хакыйкатән, кисәтүче *(Коръән, Пәйгамбәр)* иңдерде. **(11)** Иман китереп, игелек кылганнарны карангылыктан яктылыкка чыгармак өчен, Аллаһ сезгә ап-ачык аятьләрне укып бирсен дип, пәйгамбәрен күндерде. Аллаһка иман китереп, игелекле эш кылганнарны, Аллаһ арыкла-

---

Журнал өчен **Рабит БАТУЛЛА** әзерләде.

рыннан чишмәләр агып ятучы, эчендә мәңге калачак җәннәткә урнаштырыр. Аллаһ андый кешеләргә иң яхшы ризыклар гына бирер.

**12.** Аллаһ–җиде кат Күкне вә шулай ук Җирне яралткан Раббы. *(Аллаһның)* фәрманнары шулар арасыннан иңеп тора. Шулай итеп, Аллаһның бөтен нәрсәгә кодрәте житкәнлеген вә һәр нәрсәне гыйлеме белән урап алганын беләсез.

# 66—ТӘХРИМ (ХАРАМ) СҮРӘСЕ

*(Тәхрим сүрәсе 12 аятьтән тора. Мәдинәдә иңгән. Тәхрим–тыю, рөхсәт итмәү, харам кылу мәгънәләрендәге сүз.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Әй, Пәйгамбәр, хатыннарыңның күңеле булсын дипме, Аллаһ сиңа хәләл кылган нәрсәне син ни өчен үзеңә харам иттең? Аллаһ–ярлыкаучы, чиксез мәрхәмәтле кичерүче.

**2.** *(Аерым бер шартларда)* Аллаһ ант сүзен кире алырга рөхсәт итте. Сезнең ярдәмчегез Аллаһ. Ул–барысын да белүче, хикмәт иясе.

**3.** Бервакыт Пәйгамбәр хатыннарының берсенә серен сөйләде. Ләкин хатыны бу серне башка көндәшләренә житкерде. Аллаһ *(хатынының сер тотмавы турында)* Пәйгамбәргә хәбәр итте. Моны белгәч, Пәйгамбәр *(сөйләгән сүзенең)* бер өлешеннән танды, икенчесен раслады. Хатыны:

–Бу турыда сиңа кем житкерде?–дип сорады. Пәйгамбәр:

–Бөтен нәрсәне белеп торучы, һәр нәрсәдән хәбәрдар Аллаһ хәбәр итте,–диде.

**4.** Икегез дә тәүбә итсәгез, яхшы булыр иде. Сезнең икегезнең дә күңеле адашкан. Сез Пәйгамбәргә каршы гамәл кылсагыз, белеп торыгыз ки, аның дусты вә ярдәмчесе–Аллаһ һәм Җәбраил белән иң яхшы мөселманнар. Шулар өстенә фәрештәләр дә аны яклаячак. **(5)** Әгәр ул сезне аерып жибәрсә, Раббы аңа сездән дә яхшырак, үзләрен Аллаһка багышлаган, иман китергән, тугрылык белән итагать итүче, тәүбәгә килгән, гыйбадәт кылучы, ураза тотучы, тол яки саф кызларны хатын итәр.

**6.** Әй, иманлы бәндәләр, утын урынына кешеләр һәм ташлар ягылган җәһәннәмнән үзегезне һәм гаиләгезне саклагыз. *(Җинаятьчеләрне)* кызгана белми торган, көчле һәм Аллаһның әмеренә каршы килми торган, бары тик Аллаһ боерганны гына үти торган *(зобанилар)* фәрештәләр шул җәһәннәмнең сагында тора.

**7.** Әй, кяферләр, бүген *(Кыяммәттә)* ярлыкау сорамагыз. Сез бары тик кылмышларыгызга күрә җәзаланачаксыз.

**8.** Әй, иманлы кешеләр, ихлас тәүбә итеп, Аллаһка кайтыгыз. Ихтимал, сезнең хаталарыгызны Аллаһ кичерер. Пәйгамбәрне вә аның белән бергә иман китергәннәрне кыен хәлгә куймый торган Көнне (Кыяммәттә) Аллаһ сезне, арыкларыннан чишмәләр агып ята торган җәннәтләргә урнаштырыр. Аларның алдыннан, уң якларыннан *(игелекләренең)* нуры яктыртып барыр, алар:

–Йа, Раббыбыз, нурыбызны тагын да камилләштер, безне ярлыка, зинһар!–дип әйтерләр.– Йа, Аллаһ! Синең кодрәтең чиксез.

**9.** Әй, Пәйгамбәр, кяферләргә вә монафикъларга каршы Җиһад ит, аларга каты куллы бул. Аларның барасы жире–җәһәннәм. Ул бик тә хәтәр урын.

**10.** Аллаһ Нухның һәм Лутның хатыннары белән булган хәлне инкарьчыларга гыйбрәт мисалы итеп китерде. Аларның икесе дә Аллаһның тугры бәндәләренең никахында иде. Алар хыянәт итте. Ирләре аларны Аллаһның җәзасыннан коткарып кала алмады. Аларга:

–Әйдәгез, утка керүчеләр белән бергә сез дә җәһәннәмгә керегез,–диелде.

**11.** Иман китергәннәргә дә Аллаһ Фиргавен хатынын үрнәк итеп китерде. Аның хатыны әйтте:

–Йа, Раббым, миңа үз хозурыңда җәннәттә бер йорт салып бир, мине Фиргавеннән һәм аның нәҗесеннән коткар вә мине залимнәр арасыннан йолып ал,–диде.

**12.** Кызлык мөһерен саклаган Гыймран кызы Мәрьямне дә Аллаһ үрнәк итеп күрсәтте. Без аңа рухыбызны өрдек, ул Раббының сүзләрен вә китапларын раслады. Ул чын күңеленнән итагать итүче булды.

# 67—МӨЛЕК (ПАДИШАЛЫК) СҮРӘСЕ

*(Мөлек сүрәсе 30 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Мөлек, малик–падиша, дигән сүз.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Бөтен хөкемдарлыкны хозурында тотучы Аллаһ олугларның бөегедер вә Аллаһның көче бөтен нәрсәгә җитә **(2)** Аллаһ кемнең игелек кылачагын сынап карар өчен, үлемне, яшәеш тормышны бар итте. Аллаһ–җиңү белмәс кодрәт иясе, чиксез мәрхәмәтле ярлыкаучы. **(3)** Аллаһ бер-беренә ярашкан җиде кат Күкне бар итте. Галәмнәр Раббысының бар итү гамәлендә сез һичбер кимчелек күрмәссез. Күтәрелеп бер багыгыз сез Күккә, анда һичбер җитешсез урын күрмәссез. **(4)** Аннан соң тагын кат-кат карагыз, багышыгыз *(Күк төзелешендә бозыклык табалмыйча)* гаҗиз булып, бичара хәлдә кире кайтыр. **(5)** Хактыр ки, сезгә иң якын Күкне кандилләр (йолдызлар) белән бизәдек. Аларны *(йолдызларны)* шайтаннарга ата торган итеп ясадык һәм шайтаннарга ялкынлы ут газабын хәзерләдек. **(6)** Раббыны инкарь иткән бәндәләр өчен җәһәннәм газабы бар. Ул бик тә хәтәр урын. **(7)** Аларны *(кяферләрне)* утка атканда җәһәннәмнең *(кяферләргә)* булган ачуыннан кайный-кайный **(8)** шартлар дәрәҗәгә җитеп үкергәне ишетелеп торыр. Гөнаһлылар төркеме утка атыла барган саен, ут сакчылары *(зобанилар)* аларга:

–*(Шушындый газап булачак дип)* алдан кисәтүче бер генә пәйгамбәр дә сезгә килмәдемени соң?–дип сорарлар. **(9)** Алар шулай җавап бирер:

–Дөресен генә әйткәндә, шушы газапның киләчәге турында кисәтүче бер Пәйгамбәр килгән иде, ләкин без аның кисәтүләренә ышанмадык, аларны ялганга чыгардык. Аллаһ берни дә иңдермәде. Сез саташкан бәндәләр,–дидек.–**(10)** Их, аның сүзләренә колак салган булса идек, акылыбыз белән уйлап караган булса идек, утта янучылар арасында булмас та идек.

**11.** Шулай итеп, алар гөнаһларын таныдылар. Алар Аллаһның ярлыкавыннан ерак булырлар! Алар инде ялкынлы җәһәннәмнең әһелләре.

**12.** Үзен күрмәенчә дә, Аллаһка иман китергәннәргә, Аллаһның җәзасыннан курыкканнарга хакыйкый ярлыкау һәм дә бөек әҗер хәзерләнгән. **(13)** Сүзегезне яшерсәгез дә, яшермәсәгез дә, белеп торыгыз ки, Аллаһ–күңелегездәгеләрнең барысын да белеп торучы. **(14)** Юктан бар итүче белмәсме? Ул иң яшерен гамәлләрне дә белеп тора вә һәрнәрсәдән хәбәрдар. **(15)** Җир йөзен сезнең карамакка биргән–Аллаһ. Шулай булгач, Җирнең күкрәгенә басып йөрегез вә Аллаһ биргән нигъмәтләрне ашагыз. Ахырда кайтыш барыбер Аллаһ хозурына булыр.

**16.** Күктәгеләр *(Аллаһ, фәрештәләр)* сезне *(гөнаһкярларны)* Җиргә йоттырмас, дип ышанасызмы? Ул чакта Җир калтырана башлар, тетрәр һәм сезне Җир убар. **(17)** Күктән *(Аллаһ гөнаһлы)* башыгызга давыллы таш яңгыры яудырмас, дип уйлыйсызмы? Кисәтүләребезнең ни икәнен сез озакламый белерсез. **(18)** Хактыр ки, алардан элек яшәгәннәр дә моны *(Коръәнне)* ялганга чыгарды. Ләкин минем аларга китергән җәзам нинди дәһшәтле булды. **(19)** Күктә баш очларында канат кага-кага оча торган кошларны алар күрмимени соң? Аларны миһербанлы Аллаһтан башка беркем дә һавада тота алмый. Шик юктыр ки, Аллаһ барысын да белеп тора. **(20)** Аллаһтан котылырга сезгә ярдәм итүче гаскәр кемнәрдән тора? *(Аллаһның җәзасыннан бары тик Аллаһ үзе генә коткара ала.)* Кяферләр алар–юл табалмаслык булып адашкан халык. **(21)** Аллаһ сезгә ризык бирүне туктатса, сезгә кем ризык бирер? Хәер, алар азгынлык һәвәслеге белән *(Хактан)* тәкәббер рәвештә ераклашты. **(22)** Хәзер инде уйлап багыгыз, йөзе аска килеп, кара көеп йөрүче бәндә тугры юлга күнәрме, әллә тугры юлдан тел-тез атлап баручымы *(Сәгадәткә барып ирешәчәк)*? **(23)** *(Рәсүлем)* әйт:

–Ул сезне юктан бар итүче, сезгә колаклар, күзләр, бәгырь бирүче,–диген. Бик аз шөкер итәсез. **(24)** Тагын әйт син:

–Җир йөзенә сезне Аллаһ ялтты һәм сез *(җавап бирер өчен)* Аллаһ хозурына барачаксыз,–диген. **(25)** *(Кяферләр мыскыллы киная белән)*:

–Сөйләгәннәрегез хак булса, вәгъдә иткәннәрегез *(Кыямәт көне, газаплар)* кайчан килер?–диярләр. **(26)** Әйт син аларга:

–Бу турыдагы мәгълүмат бары тик Аллаһ хозурында гына. Мин бары тик Аллаһ газабының, һичшиксез, киләчәге турында сезне кисәтүче генә,–диген.

**27.** Әмма аны (газапны) якында күргәч, кяферләрнең йөзләре каралыр һәм аларга:

–Менә, бу сез бик тиз күрергә теләгән нәрсә шушы булыр,–дип әйтерләр. **(28)** Әйт син:

–Әгәр Аллаһ мине, минем белән булган якыннарымны һәлак итсә яки рәхмәте илә исән калдырса, хәтәр газаптан кяферләрне кем коткарыр?–дип сора. **(29)** Әйт син:

–Аллаһның рәхмәте киң вә Ул - ярлыкаучы. Без Аллаһка иман китердек, тәвәккәл итеп, Аңа сыендык,–диген. Кемнең ялгыш юлда адашып йөргәнен озакламый күрерсез. **(30)** Әйт син:

–Миңа җавап бирегез сез, әгәр су–елгалар, чишмәләр качса, бәреп чыккан чишмәләрне сезгә кем кире кайтарыр? *(Әлбәттә, Аллаһ кына бу эшне башкара ала.)*

*

Kitap küzətü
Китап күзәтү

# ХӘТЕР СЫЗЛАНУЫ

Егерменче гасырның алтмышынчы елларыннан татар әдәбияты фәлсәфи һәм әдәби фикердәге яналыклар, иҗтимагый кануннарны алга куйган идеологик кысалардан арынуга омтылу, дөньяны, яшәешне сәнгатьчә кабул итүнең яңа яклары ачылу белән бәйле кинәю-тармаклану чорына аяк атлый. Поэзиядә реалистик иҗат юнәлеше белән янәшәдә фәлсәфи-пессимистик (Х. Туфан, И. Юзеев, Р. Фәйзуллин) һәм оптимистик (Р. Гаташ, Зөлфәт) романтизм яңа югарылыкларга омтыла. Сиксәненче-туксанынчы еллар чигендә шигърият үсешнең яңа сукмакларын барлый башлый: Зөлфәт, Л. Шагыйрьҗан, Р. Зәйдулла, Г.Морат, Р.Аймәт, Р. Сүлти һ. б. модернистик эзләнүләр юлына керә, әлегә постмодернистик шигърият турында зурдан кубып сөйләргә иртәрәк булса да, Сөләйманның аерым шигырьләре постмодернизмның беренче билгеләрен хәбәр итә. Бүгенге поэзиядә әлеге юнәлеш, агымнар бергә берегеп үсә-үзгәрә, теге яки бу юнәлешкә мөнәсәбәтле шагыйрьнең иҗатында да башка агым, метод билгеләре күренә. Зиннур Мансуровның соңгы еллар иҗаты да әлеге сыйфат үзгәрешләрен үзендә тоя. Иҗади үсеш эволюциясендә тулы бер баскыч буларак бәяләнергә хаклы "Җәрәхәтле йөрәк җылырак" җыентыгы моны тагын бер кат исбатлый.




Сиксәненче еллар башында әдәбият мәйданына чыгып, Тәлгат Галиуллин, Рәдиф Гаташ, Мансур Вәлиев, Салих Маннапов һ. б. ларның уңай бәясен алган шагыйрьнең бу җыентыгы "Кул бирәм" (1979), "Йөз суы" (1983), "Тысячелистник" (1983), "Ваем" (1988), "Душицы белый запах" (1991), "Яшәү үзәне" (1998) кебек китаплары арасында иң тулысы булып тора; Зиннур Мансуровның мона кадәр үстереп килгән төп тематик юнәлешләрен бергә туплый. Аның исеме үк мәгънәви һәм эстетик эчтәлекнен юнәлешен, агышын чагылдыра. Әсәрләр язылу еллары ягыннан гына түгел, жанрлары җәһәтеннән дә, күтәрелгән тема-проблемалары, аларны чишү юллары белән дә бер-берсеннән шактый аерыла. Әмма аларның барысын да лирик геройның сызлануы, җәрәхәт образы бер бәйләмгә җыя, берләштерә.

Сызлануны тудырган җәрәхәт китапның буеннан-буена төрле мәгънәви төсмерләрдә катлатланган символик яңгырашлы төшенчә, ягъни ачкыч-символ хезмәтен үти. Дини кануннардан читләшүнең мәгънәсез яшәешкә илтүе, яшәү мәгънәсен югалтуның ачылыгы, шуна бәйле битарафлыкка, ваемсызлыкка чуму, татар халкының ачы язмышы (лирик герой язмышы еш кына милләт язмышына берегеп китә), табигатьтән аерылу, ана саксыз мөнәсәбәтнең ахыр чиктә кешегә фаҗига булып кайтуы, бердәнбер юану чарасына әйләнгән балачак, яшьлекнең үтүе, ана кабат кайтырга мөмкинлекләр булмавыннан туган ачыну—болар барысы да лирик шигырьләрдә төп хисләрнең (борчылу, үкенү, сызлану, әрнү) сәбәбенә әйләнә, "Ике егълау", "Хозыр галәйһис-сәламне эзләү" кебек поэмалары лирик геройның уйлану-кичерешләрен эпик әсәр мөмкинлекләреннән файдаланып тирәнәйтә. Композицион төзелешләре, үткәрелгән фәлсәфәләре белән дә, мәгънәви җәһәттән дә шигырь-поэмалар бер-берсенә якын торган шигъри ояларны хәтерләтә.

Җыентыкның беренче, икенче бүлекләренә урнаштырылган шигырьләрне татарның бәйсезлеге, киләчәге, язмышы өчен сызлану берләштерә, җәрәхәт милли фаҗига эчтәлегенә төреп бирелә ("Төрмә эчендәге читлек", "Киек каз юлы",

Зиннур Мансуров. Җәрәхәтле йөрәк җылырак.—Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2003 ел.

"Тартар", "Баш", "Беренче киселгән ярымай", "Татар бугазы" h. б.). Бу төркем шигырьләрдә төп эчтәлек аерым символик образ, метафора, детальләр аша гомумиләшә. Мәсәлән, "Төрмә эчендәге читлек" шигырендә шундый образлар тезмәсе итеп төрмә, читлек һәм кош образлары алына. Читлек эчендә бәргәләнгән кош образында бәйсез, хөр булып яшәргә хыялланган татар халкы гомумиләштерелсә, төрмә хөкем сөргән система, коллыкны максат иткән идеологияне символлаштыра, соңгысының асылын ачып бирүгә кан эчүче черки, тәмуг, иблис авы кебек метафора, чагыштырулар да ярдәмгә килә. Шундый халәттәге тормыш-яшәеш, үз чиратында, лирик герой күнелендәге сызлануга сәбәп була:

Ишеттереп тора өшеттергеч
Тимер ишекләрнең чың-шавы,
Утырасың хөкем ителмичә,
Менә нинди язмыш сынавы.

"Рояльнең кара телләре" шигырендә романтик шигъриятькә хас антитезалар белән очрашабыз. Шигырь романтик контрастларга корылуы белән аерылып тора. Күзгә төн, кара болыт, кара язмыш—ак шомырт чәчкәләре каршылыгы, кара рояль телләре—"Карурман" янәшәлеге аша автор халыкның кара язмышын чагылдыра, аның үткәне, киләчәге өчен сызлана. "Илбакча һәм колонист", "Ай кызына төбәлгән уй", "Баш" кебек шигырьләрне тугандаш Кырым татарлары язмышы өчен әрнү, борчылу бер үзәккә җыя.

Тарихи темага язылган "Ике егълау" поэмасы да—әнә шул төркемгә кергән әсәрләрнең берсе. Татарның дәүләтчелеген югалту тарихын сурәтләгән шигъри, эпик әсәрләр иҗат итү белән мавыккан чорда язылса да, поэма милли тема-проблеманы үзенчә бәяли һәм чишә. Милләт язмышы бирелә Сөембикә фаҗигасе аша чагылдырыла. Сөембикә һәм Ярославнаның егълашулары, "диалогы" нигезендә композицион җәһәттән үзенчәлекле төзелгән поэма төгәл ике—вакыйгалар һәм хис катламына аерыла. Беренчесе—вакыйгалар катламы—Сөембикә һәм Ярославнаның егълашу сәбәпләрен ача. Бу диалог үзе үк символик яңгырашка ия: ул ике халыкның эчке кичерешләрен уртаклашуын да гәүдәләндерә, ике арадагы фаҗигале каршылык кебек тә кабул ителә. Сәяси-дини әһелләр куерткан конфликтлы ситуация рус һәм татарларның холык-фигыльләрендә, эшгамәлләрендә чагыла. Урысларның башлап татарга яу чабуы, коллыкка төшерүе, хәрәмләшүе гаепләү булып яңгырый.

Татар шигъриятендә еш кулланылучы, билгеле алымнардан саналган төшләр, хәтта төсләр дә әсәр тукымасына табигый рәвештә әнә шул максаттан кертелә. Булачак вакыйгаларны, киләчәк фаҗигане искәртүче төш бирелә, барыннан да бигрәк, ике арадагы каршылыкны ачып бирү вазифасын ала. Сөембикә үзенең төшендә энҗе-мәрҗәннәр белән саташса, Ярославнаның күргән төшләре кара төсләр белән бәйләнә: кара кошлар, җиргә кара яулыгын япкан әнкәсе. Каралык аларның үз кайгысын ачып бирү белән бергә, татар дөньясына китергән хәсрәтен дә гәүдәләндерә. Сөембикә төшендәге энҗемәрҗәннәрнең дә үз мәгънәви чишелеше бар. Урта гасырларда ук киң әдәби әйләнешкә кергән энҗе символик образы күз яше мәгънәсендә йөри, аның семантикасы күз яшенең дә кыйммәтле хәзинә булуын белдерә. Образның күпмәгънәлелеге поэмада ике катлам эчтәлек тууга—татар дәүләтенең данын, зурлыгын, бөеклеген һәм шуны югалту белән бәйле милләт фаҗигасен чагылдыруга—ярдәм итә.

Әсәрнең үзәгендә торган милләт фаҗигасе бик күп күренеш, деталь, элементлар аша көчәйтелә: Идел-Йорттагы көз күренеше, җилелү кайгысыннан хәтта ташларның, бичураларның елавы, шәмдәлләргә шомландыргыч яшьләрнең тамуы, сусыз дала кылганнарының болытлардан яшь көйгән бөркеткә сәҗдә кылуы h. б. Соңгысы метафора хезмәтен дә үти. Ә. Еникидәге кылганнар "җил кая иссә, шул якка авышучылар", ягъни максатсыз, битараф кешеләр булып чыга. Сусыз дала белән янәшәлек мәгънәне яңа төсмерләр белән баета. Милли тарихны, дәүләтсезлекне гәүдәләндерүче сусыз дала һәм кылганнар татар халкының кыйбласызга әйләнүен, яраклашуын аңлата, олы милли фаҗига буларак кабул ителә.

Бәгырьләрдәге Вакыт белән Хәтер бәрелеше, бердәмлеге, ягъни хронотоп әсәргә үз мәгънәсен алып керә, ул автор әйтергә теләгән фикер-идея белән кисешә. Хәтер—ул халык күргән-кичергәннәрнең күңелләге чагылышы, вакыт агышына да карамый канында, бәгырендә саклана торганы. Көзгеле композиция ярдәмендә аның ахырда кабатлануы мәгънәне тагын да көчәйтә генә.

Каршылык шул рәвешле үстерелеп, шигъри тукымага Хәзрәти Мәрьямнең иңүе белән чишелә. Дини затның "күк дөньясыннан" җиргә төшерелүе нәфрәт белән тулы аң-акылны ачарга, җинелүне "күк каргышы" төшү дип аңлатырга мөмкинлек бирә. Хәзрәти Мәрьямнең "Сезне гирьян иткән дошман явы—Аллаһ биргән сынау вәгъдәсе" сүзләре шуны раслау кебек яңгырый. Каргыш төшүнең башы һәр халыкның үз холык-фигыленә, Хакыйкатьтән, милли асылларыннан

ераклашуга барып тоташа, ягъни халыкларның җинелүенә, башка бер халыктан бигрәк, иң беренче чиратта ул үзе гаепле дигән гыйбарә ассызыклана ("Искәртмиме безнең өстебезгә ябырылып торган яу үзе? Үткапчыкта гына утырадыр дошманыныңның үтә явызы."). Бу фикер Мәрьям авызыннан әйттерелеп, Сөембикә тарафыннан кабатлаттырыла. **Сабырсызлык**—"Чыдамлыгын яшькә чылатмаган сабырларны сөя Аллабыз.", **диннән, Аллаһтан ерагаю, имансызлык**—"Алыштырмый зекер әйләүләрне, гыйбадәтне андый аһ-ваһлар", "Үтәмисез фарыз кануннарны—унның берсен генә булса да", **масаю**—"Ил-суларын җәннәт мисалында күреп масайганнар кем иде?" (Хәзрәти Мәрьям) кебек ике халыкка да хас тискәре сыйфатлар саналса, Сөембикә монологы **вакланышу**—"Вакланыша торды алыплары киртә булып калкыр тау саен", **таркаулык**—"көчен туплый алмый төрки кавем зурдан купкан дошман каршында", **кардәшлекне сакламау**—"Безнең халык бер көн тора алмас туганара ызгыш, дау юкта...", "Карымталар кырды кардәшлекне, онытылды ыру вәгъдәсе", үй белән гамәлнең аерылуы, **масаю**—"Күккә сыймас мәгърур бөркет җаны яши кебек... хәзер тавыкта", **үчләшү**—"Безнекеләр һаман бугазлаша кечтек кенә иске бер үчтән", **мордарлык**—"Мордарлыкка баткан мирзаларым, нәрсә җене сезгә кагылган? Аллаһының сөю тәһарәте кылынмыйдыр алай кан белән", **мескенлек**—"Гарьсезләрең дала горурлыгын сатты юкбар бүләк хакына; мескенләнеп сорау мисалында Мәскәүләргә китте хат кына", кебек тулаем тискәре сыйфатлар ассызыклана, үз чиратында алар "Аллаһ каргышы"—җинелүгә этәрүче көч дип алына. Шушы өлештә әсәр тукымасына автор фикере кушылып, аның үз халкын кисәтүе, җәрәхәте, әле дә булса дәвам иткән начар сыйфатлардан арынырга чакыруы булып яңгырый.

Милли дәүләтчелекне югалту вакыйгалары белән бәйле халык фаҗигасе хис катламының эчтәлеген билгели: лирик герой күңелендәге әрнү, сызлануга сәбәп төсен ала. Татарларның тискәре холкы тудырган борчылу аша сызлану үзенең югары ноктасына күтәрелә, киләчәкнең билгесезлеге аны тагын да көчәйтә:

> Исәннәргә нинди аһлар ишетәсе,
> Алгы көндә тагын ниләр күрәсе?!
> Ике бикәч көн-төн егълый ике ярда,
> Яраларга тамып тора күз яше...

Икенче төркем шигырьләрне балачак, яшьлек, аның аерылгысыз юлдашы булган мәхәббәтнең югалу, үтү җәрәхәте, аларны кабат кайтару мөмкинлеге булмауны төшенү, аңлау тудырган сызлану, әрнү хисе бер бәйләмгә туплый. "Яшьлек кайтавазы", "И балачак...", "Пирамида", "Туган йортта" һ. б. лирик шигырьләре шундыйлардан. "И балачак..." шигырендә төп эчтәлек бүгенгене һәм балачакны чагыштыру аша җиткерелә:

> Дөньяң кысан булса да бит,
> Ямьлерәк иде бугай.
> Елаганда күз яше дә
> Тәмлерәк иде бугай.
> Бүлешәсе малыбыз юк,
> Юк сиңа барачагым.
> Әй, яшел балачагым...

Балачакның матурлыгы—аның гамьсезлегендә, беркатлылыгында, ә бүгенге лирик геройга нәкъ әнә шул сыйфатлар җитми, сабыйчакның самимилеге сагындыра.

Бу фикер үзенә бер шигъри ояны хәтерләткән, татар халкының бүгенгесе, җәмгыять, аның торышы өчен борчылып, кешелекнең әхлакый яктан түбәнгә тәгәрәве нәтиҗәсендә туган җәрәхәтне күрсәткән өченче бәйләм шигырь-поэмаларда тагын да тирәнрәк ачыла.

Кыйсса, миф традицияләренә таянган, композицион яктан катлаулы һәм үзенчәлекле әсәрләрдән саналган "Хозер Ильясны эзләү" поэмасы берничә катламның әдәби кушылмасын тәшкил итә. Гомумән, соңгы елларда мәйданга чыккан татар поэмаларында төрле катламнарның синтезына омтылыш көчле. Ул синтез еш кына дини-мифологик образлар, гыйбарәәйтелмәләр аша уздырылган фәлсәфи уйланулар: кеше һәм гомер, яшәү һәм үлем, вакыт агышы, кеше гомеренең бәясе, яшәү мәгънәсе; сәяси-иҗтимагый фикерләр: идеология һәм милләт язмышы, система алып килгән фаҗига, милләтнең үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге; әдәби-мәдәни мәсьәләләр: шагыйрь шәхесе, аның вазифа-бурычлары турында уйлануларның бер әсәр чикләрендә берләшүе белән аңлатыла. Катламнарның бергә кушылуына әдәби текстның үз эчендә башка текстлар белән ассоциациясе аша—интертекстуальлек (Борев Ю.) ярдәмендә—ирешелә. Әлеге сыйфатхасиятләрне "Хозер Ильясны эзләү" поэмасы да чагылдыра.

Эпиклыктан бигрәк лирик башлангычка өстенлек биргән әсәр милли-сәяси, фәлсәфи катламнарның берлегеннән гыйбарәт. Поэмада милли-сәяси катлам иҗтимагый халәткә бәя төсен ала. ГУЛАГ, төрмә-лагерьларның бар куәтенә эшләве, меңләгән шәхесләрнең җанын кыйган шәхес культы, инкыйлаб, сугышлар, җәмгыятьтә хөкем сөргән намус һәм намуссызлык ("намус җаннан кадерле"ләр белән

намуссызлар көрәше), фәхишәлек ("карулanган "кызлар" карыныннан күпме җаннар китте гарешкә"), битарафлык ("борчылуны белмәс бәндәләрнең бәгырендә бүген каты боз"), ямanлык кебек күренешләр аша көчләп урнаштырылган система, идеология кире кагыла, мәгънәсез сәясәт татар милләтенә төшкән фаҗига буларак бәяләнә һәм милләтнең хәтере югалу, колга әйләндерелүе битараф затларга әверелүе белән исбатлана. Милләт таркалуның татар авыллары юкка чыгу белән янәшә баруы фаҗиганең икенче ягын ачып бирә. "Вөҗданның вөҗүдтән аерылуы", буыннар арасындагы бәйләнешләрнең йомшаруы, ата-угыл мөнәсәбәтләренең катлаулануы татар фаҗигасенең өченче ягы булып аңлашыла. Поэма тукымасына кертелгән карт һәм аннан кинәш сораучы да шушы катламга карый һәм җәмгыятькә бәя булып яңгырый. Әсәрдә яшь буынның өлкәннәр каршындагы җавапсызлыгы тискәре сыйфат буларак бәяләнеп кенә калмый, ә җәмгыятьнең бәхетсезлеге әнә шуңа тоташа дигән фикер дә ныгытыла. Җәмгыятьтәге әхлакый, сәяси хәлләр, милләт фаҗигасе хисснең сәбәбенә әйләнеп, лирик геройның тирән борчылуы аша әрнү, сызлану, сыкрануга кадәр үстерелә.

Поэмадагы милли-сәяси һәм фәлсәфи катламнарны тоташтыручы, чорларга бәя бирү өчен дә, фәлсәфәне, әхлакый яңгырашны тирәнәйтү өчен дә отышлы сайланган Хозер Ильяс образы Аклык, Сафлык, Мәрхәмәтлелек үрнәге буларак кабул ителә. "Аллаһ бүләге" шигыренә исә ул тормыш авырлыкларыннан сыгылган лирик геройны юатучы, аңа яхшылык теләүче ярдәмче карт сыйфатында килеп керә. Аның яшәешен бәян итүче Ак әби дә—шундый типларның берсе, аклык, сафлыкны гәүдәләндергән Акъәбиләрнең дәвамы булып тора. Хозер Ильяс белән янәшә дүрт символик образ килә: гөлчәчәк, камчы, сал һәм учак. Гөлчәчәк—Хозер Ильяснын дәвамы—аның күнел, яшәеш матурлыгы билгесе. Икенчедән, аңа йөкләнгән тагын бер вазифа шагыйранә дөньяны шартлы икегә—Хозер Ильяслы үткәнгә һәм "имансыз, денсез" бүгенгегә бүлүдән гыйбарәт. Ак чәчәккә әверелүе Хозер Ильяснын Җиранадан аерылмаган зат, табигать баласы булуын да аңлата кебек. Табигать баласы булган бүгенгеләр исә—анардан ераклашып, сукырларча идеологиягә табынучылар. Бу бәйләнеш табигый башлангычтан аерылу белән дә бәйле дигән фәлсәфәгә китерә. Сал—иминлек, муллык, рухи байлык билгесе, Хозер Ильяс кабызган учак, ут—иман ныклыгы, иман нуры, намус байлыгы, алай гына да түгел, кешелеккә рухи кыйбла символы да. Сугышлар, явызлык билгесе булып йөргән камчы образы да бирелә башкачарак мәгънә белән баетыла: яхшылыкка фатиха кебек аңлашыла:

> Хозер Ильяс камчы селтәр иде дә,
> Карлар-бозлар китә башлый Иделдә!..

Хозер Ильяс яшәеше—яшәү үрнәге булып тора, ягъни автор чынбарлыкны әнә шулай үзгәртергә тели, романтик әсәрләргә хас булганча, аны үз хыялы, идеалы яктылыгында бәяләргә омтыла. Дини-мифологик образ белән бәйләнгән фәлсәфи катлам автор фикерен, идеясен үткәрә: кеше бу җиргә бары бер мәртәбә җибәрелә, ә ул тормыш исә иман, намус, вөҗдан берлеге белән бизәлергә, "Хозер Ильяс биеклегенә" омтылырга тиеш. Бу фәлсәфәне аңлауга поэмага эпиграф итеп китерелгән "Пәйгамбәребез галәйһиссәлам әйтте: бу тормыш—бер сәгатьлек, шунлыктан аны изге эшләргә файдалан" гыйбарәсе дә ачкыч булып тора.

Әсәр тукымасында Хозер Ильяс күзләргә сеңгән изгелек булып һәр кеше күңелендә дәвамын эзли, ягъни кешеләр күңелендәге иман, изгелек чаткыларының яктысы булып та тәгәлләшә. Аның юкка чыгуы—кешеләр җанындагы иман нурының югалуы, имансызлык, рухи салкынлыкның өскә чыгуы да ул. Әнә шулай Хозер Ильяснын югалуы хисснең икенче сәбәбе булып тора. Иман һәм имансызлык, изгелек һәм явызлык каршылыгы аша Зиннур Мансуров җәмгыятьтә генә түгел, ә һәр кешедә барган күңел тартышын ачып бирүгә ирешә. Автор ялгыш юлдан киткән кешелекне иманга кайтару аша савыктырырга ниятли һәм фикерен Хозер Ильяс образы, аңа салынган мәгънә аша җиткерә. Әсәр тукымасына уңышлы кертеп урнаштырылган салаватлар, аерым дини гыйбарәләр, хикәятләр дә шуңа хезмәт итә.

Поэмадагы фикерләр аерым шигырьләрдә дә дәвам иттерелә, үстерелә. Мәсәлән, "Исерек бал кортлары", "Дәһрилек", "Тагын "урысныкы" турында" шигырьләре әхлаксызлык өчен сызланып язылса, "Ромашкино ромашкасы", "Кайтавазсыз урманда", "Ятим су анасы", "Меңъяфрак" әсәрләре лирик геройның табигать үлә баруы, кешелекнең анардан аерылуы нәтиҗәсендә туган кичерешләрен ачып бирә.

"Балкыш, яки Хәйретдин Мөҗәйнең сугыш язмаларыннан юллар" поэмаруладасы әхлакый бөтенлек, бөеклекне үткәннән эзли. Шагыйрь һәм сугышчы-офицер шәхесенә багышлап иҗат ителгән поэманың бер яңалыгы булып шәхси көндәлекләрне әдәби әйләнешкә кертеп, үзара мәгънәви бәйләнгән өзекләрне авторның шәхси уйланулары белән бер

үремтәдә бирү тора. Сугыш көндәлекләреннән алынган юллар төп шигъри текст белән бәйләнеп, һәр бүлекнең мәгънәви юнәлешен ачыклый. Поэма чикләрендә төрле стиль һәм жанрларның берлеге—интертекстуальлек алымы—иҗтимагый, әдәби, фәлсәфи катламнарны барлыкка китерә.

Иҗтимагый уйланулар сугыш чоры вакыйгаларын—окоп сугышларын, Журовкага бару күренешләрен яңарта һәм эпик башлангычны тәшкил итә. Бу өлештәге Бакчасарай шәһәрен саткан әтәч турындагы хикәят метафора хезмәтендә үз иленә тугрылык, сату-сатылу мәсьәләләрен күтәрә. Ватан сугышында кичерелгән вакыйгаларны җанландыру аша әсәрдә фаҗигалелек көчәйтелә, аерым образ, әдәби детальләр, хәтта төсләр дә шул максатка хезмәт итә. Мәсәлән, кара төс сугыш фаҗигасенә, үлемнең аяусызлыгына һәм якынлыгына, язмышның котылгысызлыгына ишарә тудыра. Ләкин поэмада сугыш вакыйгаларын тасвирлау беренче урында тормый, Мөҗәйнең эчке дөньясын, рухи кичерешләрен, әхлакый үсеш юлын чагылдыру үзәккә алына.

Шагыйрьлек бурычы, аның халык тормышындагы урыны, вазифасы кебек мәсьәләләр әдәби катламның төп эчтәлеген тәшкил итә. Шагыйрьлек бурычы үз халкының азатлыгы өчен көрәштә дип билгеләнеп, милли көрәшче идеалы саналган Тукай бизмәне белән үлчәнә. Кол Гали, Шиһап Мәрҗани, Каюм Насыйри кебек шәхесләрнең әсәр тукымасына кертелүе ике катлам, хәтта капма-каршы мәгънә үткәрә. Тарихи шәхесләрнең рәсемнәре дә калмау бер яктан эчке фаҗигане күрсәтсә, икенче яктан, аларның рәсемсез дә үз эшләре белән халык хәтерендә мәңгеләшүләрен раслый.

Поэмада үлем һәм үлемсезлек, вакыт агышы, тән һәм җан сафлыгы турындагы уйланулар фәлсәфи катламны тәшкил итә. Әсәрнең идеясе дә шулар белән бәйләнештә үткәрелә. Кеше—язмыш, үлем—үлемсезлек каршылыклары яшәүнең мәгънәсе, зурлыгы турындагы идеягә алып килә. Х. Мөҗәйнең гомере, бигрәк тә сугыш чорындагы кебек соң чиккәчә кысылганы, халкының үлемсезлеге, Ватан азатлыгы өчен көрәш белән аклана. Җан сафлыгы да шуңа бәйләп аңлатыла:

> Җанга—мунча?!
> Сафлануның
> Бардыр башка юлы да.
> Халкың өчен фида булсаң,
> Барысы да юыла.

Үлем—үлемсезлек, яшәү—үлем каршылыгы, үлемнең үлемсезлеккә әйләнү концепциясе үлемсезлек фәлсәфәсен җиткерә. Поэмада фәлсәфә сугыш чоры поэзиясендәгечә хәл ителә. Кырыгынчы илленче еллар шигъриятендә яшәүнең төп максаты хакыйкать дип карала, ә хакыйкатьнең төп эчтәлеге ил азатлыгы өчен көрәш, илең өчен үлү белән бәйләнә һәм бетү, югалу мәгънәләрендә йөргән үлем төшенчәсе мәңгелек яшәешнең, ягъни үлемсезлекнең башлангыч ноктасы, үлгәннән соң яшәүгә юл алу буларак аңлана. "Балкыш, яки Хәйретдин Мөҗәйнең сугыш язмаларыннан юллар" поэмаруладасында да лирик геройның вакытсыз өзелгән кыска гомерен ил язмышына кушарга теләве үлемсезлеккә омтылу булып аңлашыла: "Минем үлемем—минем Ватаным, минем сыйныфым үлүе түгел ич. Шулай булгач, без: "Безгә үлем юк!"—дибез". Поэманың идеясе дә яшәү мәгънәсе, аның бөеклеге, зурлыгы илгә, Ватанга, үз халкына хезмәт итүдә, рухи азатлыкка омтылуда дигән фикер аша үткәрелә:

> Утка каршы фидаичә
> Януыңны ил көтә.
> Йөрәккәйне күнел кошы
> "Үлем юк" дип җилкетә,
> "Үлем юк" дип җилкетә!

Әнә шулай итеп, Зиннур Мансуровның "Җәрәхәтле йөрәк җылырак" җыентыгында урын алган шигырь һәм поэмалары фәлсәфи катламның, дөньяны фәлсәфи иңләргә омтылышның көчәя баруын дәлилли, шагыйрь иҗатында образ-детальләрнең яңа мәгънәви яңгыраш ала баруын күрсәтә. Бу үзенчәлек исә шагыйрь иҗатында романтик реализмнан фәлсәфи-романтик лирикага күчеш турында сөйли.

**Нурфия ГАФИЯТУЛЛИНА,**
*филология фәннәре кандидаты*

*Безнең календарь*

# "ВАКЫТ ИНДЕ: БЕЗ ДӘ ТОРЫЙК, ИРЕК АЛЫЙК"

ШАГЫЙРӘ МАҺРУЙ МОЗАФФАРИЯНЕҢ ТУУЫНА 130 ЕЛ

XX гасырның икенче яртысында татар иҗтимагый тормышында мәгърифәтчелек идеяләре кабаттан тернәкләнә башлый. Шушы дәвердә хатын-кызлар шәхсән үзләренә белем өстәү яки нәни балаларга сабак укыту" белән генә канәгатьләнмичә, моң-зар, үгет-нәсыйхәт белән тулы шигырь-хикәяләр язып, башкаларны да белем, ирек өчен көрәшкә өнди башлаганнар. Шундый мәгърифәтче ханым-туташлар арасында Галимәтелбанат Биктимерова, Хәнифә Гыйсмәтуллина, Хәбирә Насыйрия, Фәҗелбанат Сөләймания, Маһруй Мозаффарияләрне күрсәтергә була.

Маһруй ханым Мозаффария 1873 елда Казан губернасы Тәтеш өязе Олы Тормы авылында Габделвәли мулла гаиләсендә дөньяга килә. Әнисе—Зөя өязе Кече Кайбыч авылы мулласы Төхфәтулла хәзрәт кызы, ягъни Уральскидагы "Мотыйгия" мәдрәсәсе мөдәррисе, Габдулла Тукайның остазы Мотыйгулла хәзрәтнең апасы. Ләкин Маһруйга әнисе кулында озак иркәләнергә насыйп булмаган—әнисе үлгәндә аңа нибары ике яшь кенә була. Кечкенәдән үк зирәк, белемгә омтылучан ятимә кызчык башта апасыннан хәреф танырга өйрәнгән. Әтисе кызының укуга һәвәслеген күреп, аңа үзе дөрес бирә башлаган. Шул рәвешле Маһруй әтисеннән яхшы тәрбия алган, төрки, гарәп һәм фарсы телләрендә укып язарга өйрәнгән, үз өйләрендә авыл кызларын җыеп үзе үк укыта башлаган. Ләкин 18 яше тулганда, гүзәл Маһруй тормышында кискен үзгәреш булган. 1891 елның 20 сентябрендә аны Казандагы Печән базары мулласы—илле ике яшьлек Хуҗаәхмәт Мозаффарига (1838—1907) икенче хатынлыкка кияүгә биргәннәр.

Ләкин үз вакытына күрә шактый яхшы белем-тәрбия алган ачык фикерле яшь абыстай төшенкелеккә бирелмәскә тырышкан, "язмыштан узмыш юк" дип, авыру көндәшен, карт кайнанасын тәрбияләгән, әлбәттә, йортны алып бару да аның өстендә булган. Хуҗаәхмәт мулланың "әүвәлге хатыны зәгыйфә булып, әнкәсе дә бик картаю сәбәпле, сабак шәкертләрен укыту һәм барча мәхәллә эшләрен карау Маһруй ханымның үзенә калган",— дип күрсәтелгән М. Мозаффариянең 1914 елда "Сөембикә" журналында басылган тәрҗемәи хәлендә. Юанычны ул эштә, китапларда табарга тырышкан.

Яшь абыстай үз вазифаларын башкаруга күнегеп килгәндә, аларның гаиләсенә кайгы-борчулар килгән. Яше житмәгән бер кызга никах укыганы өчен 1893 елда Хуҗаәхмәт хәзрәтнең указы алынган, аңа күпмедер вакыт төрмәдә дә утырып чыгарга туры килгән. Шул ук елда Маһруйның кайнанасы вафат булган. Озакламый, каты авырудан соң, аның көндәше Нәгыймә дә дөнья куйган. Шулай итеп, Хуҗаәхмәт хәзрәтнең өлкән балаларын—Мәхмүтне һәм Җәмиләне тәрбияләү дә яшь абыстай өстенә калган. XIX гасыр азагы—XX гасыр башында Мозаффариләр гаиләсендә тагын өч бала дөньяга килгән: Мәхмүдә (1893—1969), Габбаса (1898—1921) һәм Мансур, ягъни булачак олуг композитор Мансур Мозаффаров (1902—1966).

XX гасыр башында Маһруй ханым татар кызлары өчен дәүләт хисабына ачылган беренче рус-татар мәктәбендә укыта башлый. Эш болайрак була. Казан уку-укыту попечителе А. Остроумов, Казан губернасы халык мәктәпләре инспекторы Никольскийның унай фикере белән килешеп, Россия халык мәгарифе министрлыгына мөрәҗәгать иткән. Мәктәпнең попечителе (башлыгы) итеп Хәдичә Әхмәрова, рус телендә укытыла торган дөньяви фәннәр укытучысы—аның кызы Маһипәрвәр, татар телен һәм дин сабагын укытучы итеп Маһруй

ханым Мозаффария билгеләнгән. Мәктәптә дәресләр 1901 елның 5 сентябрендә Захарьевская (хәзерге Каюм Насыйри) урамында урнашкан Шәмсетдинов йортында 25 укучы белән башланган.

Остазларыннан яхшы тәрбия алган, рус телен өйрәнгән, белемгә омтылучы кызлар белемнәрен рус мәктәпләрендә арттыру мөмкинлегеннән яхшы файдаланганнар. 1914 елда "Сөембикә" журналы бу мәктәпне бетергән утыздан артык кызның рус гимназияләрендә укуларын дәвам итүләре хакында хәбәр урнаштырган. Мәһруй ханым язып калдырган тәрҗемәи хәлендә үзенең укучылары арасында күп кенә укытучылар, Сәхипҗамал Гыйззәтуллина, Гөлсем Сөләйманова, Мәрьям Рахманкулова кебек олуг артистлар булуын горурлык белән искә алган.

XX гасыр башында Мәһруй абыстай чын мәгърифәтче булып формалашып җиткән. Аның хатын-кызлар тәрбиясенә багышланган "Нәсыйхатнамә" исемле беренче китабы 1901 елда дөнья күргән. Татар вакытлы матбугаты барлыкка килгәч, ул "Казан мөхбире", "Баянелхак", "Әл-ислах", "Сөембикә", "Мәктәп" кебек газета-журналларда да шигырь һәм хикәя, мәкаләләрен бастырган. Аның хатын кызларның шәхси иреген богаулап килгән гореф-гадәтләргә каршы көрәшкә, белемгә өндәүче әсәрләрен җәмәгатьчелек, бигрәк тә яшь зыялы кызлар һәм егетләр җылы каршы алган. Мәһруй ханымның 1906-1917 елларда татар матбугатында дөнья күргән әсәрләрендә хатын-кызлар арасында аң-белем тарату, гаиләдә һәм мәктәпләрдә гигиена кагыйдәләрен куллану һәм бала тәрбиясе мәсьәләләре күтәрелгән. Кайбер хикәяләрендә ул шул чор татар хатын-кызлары кичергән фаҗигаи тормышны да сурәтләгән. Мәсәлән, "Сөембикә" журналында басылган "Кызганыч Миңлеҗамал" исемле хикәясендә ул, авылдан шәһәргә килеп асраучылыкта җәфа чиккән, бай хатыны тарафыннан урамга ташланган ятимә кыз образын сурәтләгән. Кыска гына хикәядә автор ул чорга хас булган реаль тормышны җан ачынырлык итеп гәүдәләндергән.

Ләкин Мәһруй ханымның иң танылган дип, мөгаен, аның "Әл-ислах" газетасында басылып чыккан "Мәшһүр хатыннар" исемле шигырен атарга кирәктер. Шуна күрә дә бу шигырьнең басылып чыгуы хакында бер-ике кәлимә сүз әйтеп китү артык булмастыр.

1907 елның 3 октябрендә Казанда "гыйлем юлларыны һәрбер сыйныфка бертигез ачык итә торган" гыйльми-әдәби атналык "Әл-ислах" яшьләр газетасы дөнья күрә. Рәсми редакторы һәм нашире Вафа Бәхтияров саналган, чынлыкта исә Фатих Әмирхан җитәкләгән һәм Габдулла Тукай актив эшләгән бу газета беренче көннәреннән үк үз тирәсенә белемгә, ирекккә омтылучы шәкертләрне, яшь зыялыларны туплаган.

Көннәрдән бер көнне "Әл-ислах" идарәсенә ундүрт-унбиш яшьлек берничә кыз килеп кергән. Болар—Мәһруй Мозаффариянең "Әл-иҗтиһад" мәктәбендә укучы кызлар. Бу тыйнак, гүзәл кызлар арасында иң чаялары—Мәхмүдә Мозаффария һәм Зәйтүнә Мәүлүдева. Бәлки кыюлык бирү өчен алар белән шул мәктәптә үк укучы апалары Җәмилә һәм Бәдриҗиһан да булгандыр. Моның шулай булуы бик мөмкин, чөнки Чистай кызлары Бәдриҗиһан һәм Зәйтүнә Мәүлүдевалар үзләренә кода тиешле Фатих Әмирхан янына "Әл-ислах" редакциясенә килгәли торган булганнар. Фатихның кызларны ачык йөз, илтифат белән каршы алуында шөбһә юк. Газета һәм аны чыгаручы яшьләр белән танышкач, "Әл-иҗтиһад" мәктәбе кызлары да газета аша үз моң-зарларын фикердәшләренә җиткерергә уйлаганнар. Бу килүләрендәме, икенчесендәме, кызлар "Әл-ислах"та бастырыр өчен берничә язма да алып килгәннәр. Һәм газетаның җиденче санында ук инде алар исеменнән мөхәрриргә җибәрелгән хат та урын алган. Ул гына да түгел. Бу хат алдыннан укучы кызлардан күп кенә хатлар килү сәбәпле, редакциянең "Хатын-кыз галәме" дигән исем астында даими бүлек ачуы хакында аңлатмасы да урнаштырылган.

Күрәсең, көн саен мәктәпкә барганда артларыннан ишетелеп калган хурлаулар кызларның үзәгенә үткән булгандыр. Мәһруй Мозаффариядән тәрбия-белем алучы кызлар үз зарларын укучыларга җиткереп кенә калмаганнар. "Безләр ничек тәрәккый табыйк! Без кайчан үзебезнең хакларыбызны табарбыз?"—дигән мәсьәләне дә куйганнар. Бу хакта кул куйган унбиш кыз (алар арасында Мәхмүдә һәм Җәмилә Мозаффарияләр, Зәйтүнә Мәүлүдева, Рабига Казакова, Фәхриҗиһан Субаева һ. б.), димәк, шулай үзләренең белемгә хаклы булуларын газетаның беренче саннарында ук ачык әйткәннәр.

## Мәшһүр хатынлар

Риза казый язган "Мәшһүр хатынлар" бар,
Анда гали зат зур хатынлар бар.
Әдиблек, табиблек, философлык,
Тәдрис *(укыту)*, шигырь берлән мәшгуль хатынлар бар.

Ул заманда нигә алай, инде болай
Кыйлды нигә *(сөаль илә)* безне ходай?
Ходай мәгъйүб *(гаепле)* түгел, монда иректә эш,
Ирек булса, без дә булыр идек шулай.

Ул заманда хатын-кызлар кысылмаган,
Һәрбер эшкә мулла килеп кысылмаган;
"Хатынларның сачы озын, гакылы кыска"
Дигән сүзләр аять булып тотылмаган.

Вакыт инде: без дә торыйк, ирек алыйк,
Ирекләнер чаклар житте, ирекләник;
Нигә төшсә төшсен, куркып юлдан кайтмыйк,
Ни китсә дә китсен, шуны биреп алыйк.

Һәр тугрыда ким түгелбез ирләрдән без,
Гыйлем алсак, иң галимнәренә тиң без.
Бер милләтнең там яртысы без булгачдыйн,
Карап карыйк: ирәнләрдән ничек ким без?!

Ирләр Галим булса, бездә Галимә бар,
Ирләр Заһид *(диндар)* булса, бездә Заһидә бар,
Ирләр шагыйрь булса, бездә шагыйрә бар,
Мөршид *(юл күрсәтүче)* булса, Мөршидә бар, Камилә бар.

Алар Сәмин *(кыйммәтле)* булса, бездә Сәминә бар,
Алар Әмин *(ышанычлы)* булса, бездә Әминә бар.
Мөселманда булмаса да булмас, әмма
Башкалада "бог"ка каршы "богиня" бар!

Маһруй ханым әсәренең башында ук аны Ризаэтдин-казый Фәхретдиннең 1903-1904 елларда Оренбургта басылып чыккан "Мәшһүр хатынлар" исемендәге китабы йогынтысында язылуын билгеләгән. Бу әсәрендә галим ислам дөньясында шөһрәт казанган хатын-кызларның биографияләрен сурәтләгән. Казан хатын-кызларыннан беренчеләрдән булып урамда ачык йөз белән йөрергә жөрьәт иткән курку белмәс мәгърур ханым шигъри юллар белән башкаларны да хәрәкәткә, уяныргa чакырган. Ничек кенә чакырган әле! Аның бәгыреннән кайнап чыккан сүзләре XX гасыр башы хатын-кызларында гына түгел, хәтта бүген бездә, бер гасыр соңрак яшәүчеләрдә дә горурлык хисләре тудыра, күңелнең ниндидер бик нечкә кылларын кузгата кебек. Димәк, шигырь бүген дә үз актуальлеген югалтмаган.

Маһруй ханым Мозаффария 1945 елның 5 декабрендә 72 яшендә вафат була. Кабере Яна бистә зыяратендә, Салих Сәйдәшев кабере янәшәсендә.

*(Язмада Казан дәүләт университеты доценты* ***Альта Мәхмутова*** *хезмәте файдаланылды.)*

# ҖИР ҺӘМ ХЕЗМӘТ КЕШЕЛӘРЕ ҖЫРЧЫСЫ

ЯЗУЧЫ РАФАИЛ ТӨХФӘТУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Рафаил Төхфәтуллинның 2 томлык "Сайланма әсәрләр"енә язган кереш мәкаләсендә тәнкыйтьче һәм әдәбият галиме Фарваз Миннуллин: "...Төрлесе-төрле якка карабрак, Арчадан дүрт олы юл чыгып китә. Шуларның төньякка сузылганы буйлап егерме чакрымнар җир киткәч, Яңа Иябаш исемле авылга барып керәсен. Танылган язучыбыз Рафаил Төхфәтуллин туган авыл бу,— дип язып чыккан иде. —Иябашның күршесендә генә—Тукай-Кырлай. Аннан ерак та түгел Ташкичү, Кишет, Кышкарлар... Мәшһүр Казан арты бу!"

Әйе, Рафаил Газиз улы Төхфәтуллин "әнә шул мәшһүр Казан артында"— Татарстан АССРның хәзерге Арча районы Яңа Иябаш авылында 1924 елның 1 гыйнварендa укытучы гаиләсендә дөньяга килә. Яңа Кенәр мәктәбенең IX классын тәмамлагач, Донбасска китеп, Горловка шәһәрендә ФЗӨ мәктәбендә укый, аннары берникадәр вакыт шахтада забойщик булып эшли. 1941 елның октябрендә эвакуация белән туган якларына кайта һәм X класста укуын дәвам иттерә. Бер үк вакытта, кыска сроклы курсларга йөреп, тракторчы профессиясен үзләштерә. 1941 елның августында Р. Төхфәтуллин армиягә алына һәм, алты ай чамасы хәрби училищеда хәзерлек курсы үткәннән соң, фронтка җибәрелә. Башта— пулеметчылар, соңыннан элемтәчеләр отделениесе командиры сыйфатында, ул Брянск, Орша һәм Рига янындагы каты сугышларда катнаша, күрсәткән батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз ордены һәм медальләр белән бүләкләнә. Сугыш кырында ике тапкыр авыр яралана һәм бер тапкыр контузия ала. 1945 елның гыйнварендa армия хезмәтеннән азат ителеп, Р. Төхфәтуллин туган авылына әйләнеп кайта. Шул вакыттан алып 1957 елның көзенә кадәр ул Яңа Кенәрдә чыга торган "Кызыл юл" район газетасында җаваплы секретарь булып эшли. 1957—1989 елларда Мәскәүдә СССР Язучылар союзы каршындагы Югары әдәби курсларда укый. 1959 елның июненнән ул—профессиональ язучылык хезмәтендә.

Р. Төхфәтуллин мәктәптә укыган елларында ук әдәби иҗат белән кызыксына башлый. 1948 елда "Кызыл Татарстан" (хәзерге "Ватаным Татарстан") газетасында "Сабантуйлар" исемле беренче хикәясе басылып чыга. Хикәяләре тупланган беренче җыентыгы ("Таныш гөрелте") 1954 елда дөнья күрә. Шул вакыттан бирле узган дәвер эчендә берничә пьеса, җиде повесть, йөздән артык хикәя һәм очерк иҗат итә. Татар һәм рус телләрендә өч дистәгә якын китап бастырып чыгара.

Язучының күпчелек әсәрләре сугыш еллары һәм сугыштан соңгы авыл тормышына багышланган. Аларда шул кырыс чорга хас реаль чынбарлык һәм кеше язмышлары тасвирлана, хезмәткә, җиргә, яшәү шартларына мөнәсәбәттә авыл кешеләренең тормышчан, тулы канлы образлары, кызыклы, үзенчәлекле характерлары сәнгатьчә гәүдәләнеш таба. Әдипнең авыл темасын яктырткан күп кенә хикәяләре ("Җәяүле чолләдә", 1954; "Елга аръягындагы йорт", 1956; "Күләгә", 1955 һ. б.) һәм бигрәк тә "Авылдашым Нәби" (1957), "Йолдызым" (1962), "Тамчылар ни сөйли (1964) кебек повестьлары 50-60 еллар татар прозасының алга таба үсүен, камилләшүен күрсәткән, тормыш материалларын сәнгатьчә анализлауда яңа төсмерләр, сыйфат үзгәрешләре алып килгән әсәрләр буларак бәяләнә.

1959 елда Р. Төхфәтуллин нефтьчеләр шәһәре Әлмәткә күчеп килә. Нефтьчеләр, төзүчеләр арасында яшәү, алар белән даими аралашу язучының иҗади офыкларын тагын да киңәйтеп җибәрә: авылны, авыл кешеләрен сурәтләү белән бергә, аның әсәрләренә эшчеләр тормышы темасы, төрле профессия, төрле буын кешеләре арасындагы мөнәсәбәтләрне ачуга багышланган әхлак темалары килеп керә. Бу яктан ул Г. Бәширов, Ф. Хөсниләр буынын А.Гыйләҗев, М. Мәһдиевләр буыны белән бәйләп торучы әдип буларак гәүдәләнгән.

Рус теленнән тыш, Р. Төхфәтуллинның аерым әсәрләре күмәк җыентыкларда казакъ, үзбәк, каракалпак, чуаш, башкорт телләрендә, "Җиләкле аланнар" повесте чит илләр өчен чыгарыла торган "Советская литература" журналының 1974 елгы санында инглиз, француз, немец, испан, поляк һәм чех телләрендә басыла.

Р. Төхфәтуллин 1994 елның 18 июлендә Әлмәт шәһәрендә вафат булды.

## *«Казан утлары» архивыннан*



*Моннан 40 ел элек алынган рәсем. Бер төркем әдипләр һәм зыялылар Тукай һәйкәле янында үткән шигъри митингтан соң. Сулдан уңга, беренче рәттә—Шәүкәт Галиев, Әхмәт Исхак, Мөхәммәт Садри, Мәхмүт Бәдәйли, Сибгат Хәким, Роберт Әхмәтҗанов, Мансур Мозаффаров, Абдулла Әхмәт; икенче рәттә—Илдар Юзеев, Хәсән Туфан, Котдус Дәүләтшин, Галим Рябков, Хатип Госман, Ширияздан Сарымсаков, Габдрахман Әпсәләмов, Шәйхи Садретдинов. 1964 ел.*



*Укучылар белән очрашуларда шагыйрьләр белән бергә артистлар да еш була. Уртада—шагыйрә Саҗидә Сөләйманова, җырчы Венера Шәрипова. 1963 ел.*



*Г. Тукайның 90 еллык бәйрәменә килгән кунаклар шагыйрьнең Кырлайдагы музее бинасында. Сулдан уңга—Нәкый Исәнбәт, Михаил Луконин, Мөҗәһит Вәлиев (Татарстанның партия өлкә комитеты секретаре), Мостай Кәрим. 1976 ел.*



*1999 елда Удмуртиядә "Казан утлары" көннәре уздырылды. Ижау шәһәрендә үткән бер очрашу истәлеге. Төркемдә—журнал хезмәткәрләре һәм актив авторлар—Шаһинур Мостафин, Мөдәррис Әгъләмов, Камил Кәримов, Флүс Латыйфи, Җәүдәт Дәрзаманов һ. б.*

*Берлекнең яңа әгъзалары*

## Вәсимә Хәйруллина



Хәйруллина (Талипова) Вәсимә Лотфулла кызы 1943 елда Сарман районының Чураш авылында туа. 60 еллар башында Минзәлә педогогия училищесын тәмамлагач, Казан педогогия институтында укуын дәвам итә һәм аннан рус теле һәм әдәбияты укытучысы дипломы алып чыга. Күңелендә яшьтән үк шигырь уты йөрткән Вәсимә ханым гомеренең кырыклап елын укытучылык хезмәтенә багышлаган, үз туган төбәгендә укытып балалар тәрбияләгән. Ул—туган ягына береккән кеше, яшәгән, эшләгән җире дә туган Сарман ягы: Чураш, Карашай-Саклау...

Вәсимә Хәйруллинаның беренче шигырьләре район газеталарында 60 елларда ук басыла башлый. Әмма шагыйрә буларак киң җәмәгатьчелеккә танылуы соңгы ун еллыкка туры килә. 1992 елда аның беренче китабы—"Тәгәрмәчле янгыр"—Татарстан китап нәшриятында басылып чыга. Аннан Казан һәм Чаллы басмаханәләрендә бер-бер артлы балалар өчен язылган китаплары дөнья күрә: "Чәчәкле төш", "Көмеш балдак", "Тормыш бакчасы", "Чәчәк саен бер кояш", "Син бик кирәкле кеше", "Табышмаклы букча".

Язучылар берлегенә тәкъдимнамә язган тәҗрибәле шагыйрьләр В. Хәйруллина иҗатын югары бәялиләр. "Аңа дидактика, укытучыларга хас үгетнәсихәт ят, ул образлы шигырь ярдәмендә укучы күңеленә тәэсир итә белә" (И. Юзеев). "Шагыйрә-мөгаллимә. Әйе, татарда шундый шагыйрьләр бар, алар олы шигърияткә мәктәп аша, балалар күңеле аша киләләр. Рафаил Газизов, Мөҗәһит Әхмәтҗанов, Фәйрүзә Исмәгыйлевалар төркемендә Вәсимә Хәйруллина дигән каләм иясе дә үз кеше хәзер" (Г. Гыйльманов).

"Ул укытучы булып эшләгән елларында шигырьләр язган, аларны үз дәресләрендә мәктәп программасына өстәмә материал сыйфатында балалар тәрбияләүдә файдаланган... Шигырьләре дөньяны танып белү буенча да, тәрбия ягыннан да әһәмиятлеләр" (Р. Корбан).

2003 елның сентябрь аенда Кабул итү коллегиясенең карары нигезендә, Татарстан Язучыларының идарә утырышында Хәйруллина Вәсимә Лотфулла кызы Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул ителде.

## ХӘТЕР БУЛЫП КАЛКА ҺӘЙКӘЛЛӘР

Үзенең 1000 еллыгын каршыларга әзерләнүче башкалабызда 18 ноябрьдә янә бер истәлекле вакыйга булды.

Кремльдәге Благовещение соборы каршындагы бакчада "Казан Кирмәне мигъмәрләренә" дигән һәйкәл ачылды. Авторлары—сынчылар Александр Головачев, Владимир Демченко һәм архитектор Рөстәм Зәбиров. Композициянең үзенчәлеге нидән гыйбарәт соң? Ул Спас манарасы сызымын тезләренә куеп утырган рус кешесен һәм аның артында Хан кирмәне сызымнарын тотып басып торучы татар мигъмәрен гәүдәләндерә. Һәйкәлнең нигезендә архитектура сәнгате традицияләре чагылыш тапкан. Ә бизәкле билбауда шәрекъ һәм славян халыклары, татар вә рус мәдәнияте чалымнары күренә. Тантанада катнашкан Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев үзенең чыгышында: "Казан Кремле мигъмәрләренә куелган әлеге һәйкәл башкалабызның 1000 еллыгына әзерлек барышында күпмилләтле Татарстан тарихына яна сәхифә булып кереп калыр,—диде.—Аның аркылы без борынгы заман төзүчеләре, архитекторларына гына түгел, бүгенге Кремльнең тарихи йөзен булдыру өлкәсендә эшләүчеләргә дә зур хөрмәтебезне белдерәбез. 2005 елга кадәр Кремльне төзекләндерү эшләре төгәлләнер дип көтелә. Бүгенге көндә Кол Шәриф мәчете төзелеп бетеп килә. Благовещение соборы төзекләндерелә. Яна ачылган һәйкәл иҗади һәм рухи бердәмлеккә якынаюда бер адым булсын иде".

## ТИНЧУРИН ТЕАТРЫНДА ТАНТАНА

6 ноябрьдә Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрына 70 ел тулуга багышланган тантаналы кичә булды.

Икенче төп театрыбызның (Камал театрыннан соң) биографиясе якты һәм үзенчәлекле. Ул 1933 елда Кәрим Тинчуринның шәхси инициативасы нигезендә Татар дәүләт академия театры филиалы буларак оештырыла. Труппаның нигезен төрле елларда танылган артистлар Гөлсем Болгарская, Зариф Закиров, Касыйм Шамил, Вера Минкина, Зәйнәп Камалова, Фәридун Юнысов һ. б. тәшкил итә.

50 нче елларда труппа Казан театр училищесын тәмамлаган яшь артистлар белән тулылана, хәзер алар—театрның өлкән буын актерлары. Алар арасында Татарстанның халык артистлары Люция Фарсина, Сания Исмәгыйлева, Гата Нуруллин бар. 1988 елда Татарстан Министрлар Советы карары нигезендә театрга бөек драматург, актер һәм режиссер Кәрим Тинчурин исеме бирелде. Шул ук елда театр үзенең статусын да үзгәртте: күчмәдән стационар театрга әйләнде. Г.Камал исемендәге академия театры яна бинага күчкәннән соң ярты гасырдан артыграк вакыт дәвамында күченеп йөргән Тинчурин театры "өйле" булды. Шуннан башлап театр тарихында яна сәхифә башланды. Театрның бүгенге баш режиссеры—Рәшит Заһидуллин.

Театрның юбилей кичәсендә Татарстан Премьер-министры урынбасары Зилә Вәлиева Минтимер Шәймиевнең Рәхмәт хатын укыды. Анда, аерым алганда, болай диелә: "Сез, икенче татар театры буларак, милли традицияләрне дәвам иттерәсез һәм камилләштерәсез. Татарларның театр сәнгате аеруча зур әһәмияткә ия, шуна күрә милләтнең тәрбиячесе булу—бик зур җаваплылык алу дигән сүз. Безнең бурыч—мәдәниятә бүгенге көнгә ирешелгән биеклекне саклап калу..."

Театр артистлары Зөләйха Хәкимҗанова ТРның халык артисты; Шамил Фәрхетдинов, Люция Галләмова һәм Әлфия Хәсәнова ТРның атказанган артисты дигән мактаулы исемнәргә лаек булды. Театрның рәссамы—сценографы Роман Моровка ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исем бирелде. Республика җитәкчелеге театрга ике микроавтобус бүләк итте.

Тинчуринлыларны юбилей белән Татарстан мәдәният министры Илдус Тарханов, шәһәр хакимияте башлыгы Камил Исхаков исеменнән аның урынбасары Әлфия Тутаева, Вахитов районы хакимияте башлыгы Рафис Борһанов, Камал театрының баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәев һәм Качалов театрының баш режиссеры Александр Славутский, Камал театры артистлары Шәүкәт Биктимеров, Вера Минкина, Равил Шәрәфи һ. б. котлады.

## ПЛАНЕТАР ФИКЕРЛӘҮ ҮРНӘГЕ

21 ноябрьдә Татарстан Милли китапханәсендә атаклы казакъ шагыйре, төрки телләр белгече, Казакъстанның ЮНЕСКОдагы вәкиле Олҗас Сөләймановның "Тарихкача төркиләр" дигән яна китабын тәкъдир итү булды. Хезмәт борынгы төркиләрнең телләре һәм язуларының килеп чыгышын өйрәнүгә багышланган. Республикабызның күренекле зыялылары катнашында узган әлеге мәҗлескә Олҗас Сөләйманов үзе дә килгән иде.

—Бу хезмәт—40 ел дәвамында эзләнүләр, уйланулар нәтиҗәсе,—диде ул үз чыгышында. —Төрки-славян мәдәни бәйләнешләре мен

еллар буена дәвам итә. Хәзер без үткән юлыбызны янача бәялибез. Бүген дустанә яшәүнең, федерализмның яңа үрнәкләре эшләнә. Безнең тәкъдим белән ЮНЕСКО 2006 елны Галәми аң елы дип игълан итте. Ләкин ул һич тә милли анны томалап кую дигән сүз түгел. Галәми аң милли аңнан чак кына күтәрелеп тора. Халыклар үзара корылган ясалма киртәләр аша атлап чыгарга тиеш. Без кемгәдер бәйлелектә түгел, үзара бәйлелектә яшибез. Бәйсезлеккә ирешкән дәүләтләрне дә мотлак бәйсез дип әйтеп булмый. Бүген кешелекнең әхлагы цивилизация үсеше артыннан өлгерә алмый. Шуна күрә XXI гасыр һичшиксез гуманитар фәннәр гасыры булачак.

О. Сөләйманов төрки халыкларның әлифбасына тукталып, кириллицаның да төркиләр әлифбасы булуы турында әйтте. Аның карашынча, Орхон—Енисей язуы угызлар тарафыннан кулланылса, кириллица—төркиләштерелгән грек-болгар (кыпчак) язуы ул.

Очрашуда чыгыш ясаган күренекле галимнәребез Нурмөхәммәт Хисамов, Мирфатыйх Зәкиев, Фатих Урманчеев, Фоат Галимуллин да Олжас Сөләймановның китабына югары бәя бирде. Тарихның Шәрекътән башланганлыгын белсеннәр өчен әлеге хезмәтне Европа телләренә дә тәрҗемә итеп бастырып чыгарырга кирәк, диде алар.

Аннары Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев сүз алды.

—Бүгенге очрашу—тарихи очрашу, көндәлек ыгы-зыгылардан арынып, бервакытта да югалмас, киләчәктә дә дәвам итәчәк мирасыбыз турында сөйләшү ул,—диде Минтимер Шәрип улы.—Евразия төшенчәсенең шушылай зур янгыраш алуында, Олжас Гомәрович, Сезнең өлешегез зур.

Бу—рухи гына түгел, матди төшенчә дә. Бүгенге көндә кешелек әледән-әле юлыга торган фаҗигаләр—соңгы гасырларда эшләп бетермәвебез, дөньяны үтә гадиләштерүебез нәтиҗәсе. Без бер-беребездән күбрәк кимчелекләр эзләдек. Шуңа күрә үзара каршы торулар алгы планга чыкты да. Дөнья җәмәгатьчелеге мәдәниятләр аралашуына игътибарны арттырырга тиеш. Беренчедән, галәми аң төшенчәсе безне глобальләштерү дигән өрәктән сакласа, икенчедән, бу һәр халыкның дөньяда үз урынын дәгъвалавына каршы килми. Һәр халык үз тавышын ишеттерергә хаклы. "Сез һәрвакыт тынгысыз, тәвәккәл булдыгыз, үз сүзегезне әйтә килдегез. Тел өлкәсендәге бу эзләнүләр элеккерәк елларда бигүк хупланмаса да, әлеге эш белән шөгыльләндегез. Шушылай эшләмәсәгез, мөгаен, без бүген бу өлкәдә торгынлык кичерер идек".

Тәкъдир итү кичәсен Татарстан мәдәният министры Илдус Тарханов алып барды.

Тантанада вице-премьер Зилә Вәлиева, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Роберт Миңнуллин, Казан шәһәре хакимияте башлыгы Камил Исхаков катнашты.

Олжас Сөләйманов шулай ук Казан дәүләт университетында, Милли музейда да очрашулар үткәрде.

## МӘГЪЛҮМАТ КЫРЫНДА НИЛӘР БАР?

Түбән Кама шәһәрендә ТР "Татмедиа" массакүләм коммуникация агентлыгының кинәйтелгән утырышы булды. Анда республикабызның гаммәви мәгълүмат чаралары, нәшриятлар шәһәр һәм район типографияләре житәкчеләре катнашты. 2003 елның 9 аендагы эш йомгаклары һәм тармак үсешенең перспективалары турында доклад белән агентлыкның генераль жиректоры Марат Моратов чыкты.

Күчмә утырышка жыелучыларны Түбән Кама районы һәм шәһәре хакимияте башлыгы Илсур Метшин сәламләде, кунакларны шәһәрдәге мәгълүмат чараларының эшчәнлеге белән таныштырды, бүгенге җәмгыятьтә матбугатка язылган, телевидение һәм радиодан яңгыраган сүзнең нинди зур роль уйнавын искәртте, мөселманнарны Ураза бәйрәме белән тәбрикләде.

Фикер алышуда "Татмедиа" агентлыгының юридик бүлек житәкчесе Юлия Мифтахова, Түбән Кама районының "Ленинская правда" газетасы баш мөхәррире Галина Бортникова, "Татарстан—Яңа гасыр" телерадиотапшырулар компаниясе генераль директоры Ильшат Әминов, Татарстан Журналистлар берлеге рәисе, Татар-Информ агентлыгы генераль директоры Римма Ратникова катнашты.

Татарстан Премьер-министры урынбасары Зилә Вәлиева үзенең чыгышында утырышта катнашучыларның игътибарын бүгенге медиа кыры таләп иткән мөһим бурычларга юнәлтте, дәүләти массакүләм мәгълүмат чаралары эшен заманча үзгәртеп кору, дәүләт заказлары өчен субсидияләр бүлеп бирү формалары һ. б. мәсьәләләр турында сөйләде, сайлаулар алдыннан матбугат басмаларында һәм телевидение-радио тапшыруларында халыкка кирәкле мәгълүматларны бирүдә нәтиҗәлерәк эшләү зарурлыгы хакында искәртте, күп кенә сорауларга җавап бирде.

Кинәшмә эшендә Татарстан Президенты Аппаратының җәмәгатьчелек белән элемтәләр һәм милләтара мөнәсәбәтләр бүлеге мөдире Александр Терентьев катнашты.

## УКУЧЫЛАР БЕЛӘН ОЧРАШУЛАР

18-22 ноябрь көннәрендә бер төркем әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре Кама арьягы районнарында булып, "Татар әдәбияты һәм "Казан утлары" журналы атналыгы" кысаларында әдәби-музыкаль очрашуларда катнаштылар. Алар Чаллы шәһәренең педагогия колледжында, Түбән кама драма театрында, Зәй районының Бигеш авылы мәдәният йортында һәм урта мәктәптә, Бөгелмә шәһәренең үзәк китапханәсендә, "Мир" мәдәният-спорт үзәгендә, Карабаш бистәсендә, Азнакай татар гимназиясендә һәм шәһәр мәдәният сараенда, Әлмәт нефть институтында чыгыш ясадылар. Тыңлаучылар алдында Татарстанның халык шагыйре, "Казан утлары" журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллин, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Шәһинур Мостафин, "Татарстан—Яңа гасыр" телерадио

компаниясенең әдәби тапшырулар буенча баш мөхәррире, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Шәмсия Җиһангирова, шагыйрь һәм публицист, Г. Исхакый премиясе лауреаты Әхмәт Рәшитов, прозаик һәм шагыйрь, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Марсель Галиев, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, язучы Камил Кәримов, Татарстанның халык артистлары Рафаэль Сәхәбиев белән Рамил Курамшин иҗади хисап тоттылар, тамашачыларның күпсанлы сорауларына җавап бирделәр.

### НУРИХАН ФӘТТАХНЫ ОЛЫЛАУ

17 ноябрьдә К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры бинасында күренекле әдип, Татарстанның халык язучысы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Нурихан Фәттахка 75 яшь тулу уңаеннан тантаналы кичә булды. Нурихан ага әдәбиятыбызда үз мәктәбен булдырган олпат остазларыбызның берсе. Ул, тоталитар хакимият тарафыннан халкыбызның үткәне турында сөйләү-язу хупланмаган, хәтта тыелган бер заманда да, ерак тарихыбызны тасвирлауга багышланган "Итил суы ака торур", "Сызгыра торган уклар", "Кол гали" кебек әсәрләрен язып, каһарманлык үрнәге күрсәтте. Шуңа күрә бүгенге көндә тарихи әсәрләр иҗат итүче каләм әһелләребезнең күбесе Нурихан Фәттахны үзләренең остазы итеп таныйлар.

Әлеге кичә дә бик үзенчәлекле башланып китте. Әдипнең бер тарихи романының каһарманы: "Игътибар! Хан килә! Нурихан хан килә",—дип, аксакалыбызны сәхнәдәге хан кәнәфиенә чакырып утыртты.

—Ул әдәбиятыбызның да ханы,—диде үзенең котлавында Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин.—Ерак тарихыбызны халкыбызга җиткерергә гаять зур тырышлык куйган шәхес ул.

Татарстан Премьер-министры урынбасары Зилә Вәлиева үз чыгышында Нурихан Фәттахны юбилее белән котлап, аңа Минтимер Шәймиев юллаган Рәхмәт хатын ирештерде.

Аннары әдипне Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Дәүләт Советының фән, мәгариф, мәдәният һәм милли мәсьәләләр буенча даими комиссиясе рәисе, язучы Разил Вәлиев, Казан мэры урынбасары Әлфия Тутаева һ. б. котлады.

Кичәдә Н. Фәттах әсәрләре буенча сәхнәләштерелгән спектакльләрдән өзекләр күрсәтелде. Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Айрат Арсланов аның әсәрләреннән өзекләр укыды, җырчыларыбыз исә бу күркәм кичәне моңнар белән бизәде.

### ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ЯКЫН ДУСТЫ

Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең концертлар залында Татарстанның һәм Россиянең халык артисты, Г. Тукай исемендәге дәүләт бүләге лауреаты Айрат Арслановның тууына 75, иҗат эшчәнлегенә 55 ел тулуга багышланган иҗат кичәсе булды.

Юбилярны Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин котлады. Ул Президентның "Рәхмәт хаты"н тапшырды, Дәүләт Советы һәм үз исеменнән дә җылы котлау сүзләрен әйтте, Айрат Арслановка бүләк ителгән "Жигули" машинасының ачкычларын да ул тапшырды.

Рәсми котлаучылар белән аралашып сәхнәгә җырчылар Илһам Шакиров, Зилә Сөнгатуллина, Зөһрә Сәхәбиева, Георгий Ибушев, Зөһрә Шәрифуллина, Рөстәм Маликов, Юрий Борисенко, Лилия Гобәйдуллиналар чыктылар. Язучылар исеменнән рәхмәт сүзләрен И. Юзеев, Р. Әхмәтҗанов, Ф. Галимуллин әйтте.

### ШӘҮКӘТЛЕ ШӘҮКӘТКӘ 75 ЯШЬ

2 ноябрьдә инде 27 ел буе сәхнәдә даими уйналып килә торган "Әлдермештән Әлмәндәр" спектакле" СССРның халык артисты, Россиянең Станиславский, Татарстанның Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты Шәүкәт Биктимеровның 75 яшьлек юбилее уңае белән тамаша кылынды.

Спектакльдән соң Ш. Биктимеровны Президент М. Ш. Шәймиев котлады. Ул артистка: "Синең колач җәеп уйнавың безне гаҗәпләндерә. Өлкән яшьтә булуга карамастан, осталыгың арта бара. Киләчәктә дә шатландыр әле безне",—диде ул. Аннан соң Россия Президенты Владимир Путин җибәргән Мактау грамотасын тапшырды. Юбилярны Премьер-министр урынбасары Зилә Вәлиева, шәһәр хакимиятенең мәдәният идарәсе башлыгы Лилия Маврина һәм башкалар тәбрикләде.

Әлдермеш авылы күмәк хуҗалыгы рәисе Мәннаф Сәгъдиев артистка "Жигули" автомобиле бүләк итте.

### ХӨРМӘТ БИЛГЕСЕ

Казанның Галактионов урамында халкыбызның күренекле галиме, мөхәррир һәм нәшир Шиһабетдин Әхмәровка истәлек тактасы куелды.

Шиһабетдин Әхмәровны без иң беренче чиратта Тукайның иҗатына-язмышына зур йогынты ясаган шәхесләрнең берсе буларак беләбез. Тукай да, Сәйдәш тә Әхмәровлар өендә еш булалар, монда кичәләр, төрле аралашулар булып тора.

Ш. Әхмәров—татар телендә "Мәктәп" журналын беренче чыгаручы, аның мөхәррире һәм нәшире. Быел бу олуг затның тууына 120 ел тулды. Ә мемориаль такта исә ул 1934-1966 елларда яшәгән йорт диварына куелды.

### ОЛУГ ЗАТЛАРНЫ БАРЛАУ

Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетында күренекле төрек-татар галиме, тарихчы, педагог Әкъдәс Нигъмәт Куратның тууына 100 ел тулу уңаеннан (1903-1971) "түгәрәк өстәл" очрашуы үтте.

Мәгълүм булганча, Әкъдәс Нигъмәт Курат 1903 елның апрелендә Татарстанның хәзерге Чирмешән районы Бәркәтә авылында туып-үскән кеше (Галим турында журналыбызның

4 нче санында тәфсилләбрәк язып чыккан идек инде).

"Түгәрәк өстәл"дә билгеләп үтелгәнчә, Ә.Куратның фәнни эшчәнлеге берничә өлкәгә карый. Беренчедән, ул—төркиләр тарихы буенча фәнни хезмәтләр авторы, икенчедән, Төрки югары уку йортлары өчен рус тарихы буенча хезмәтләр язган белгеч. Өченчедән, ул Төркиядәге күп кенә күренекле төрек галимнәренең остазы санала. Шулай ук Әкъдәс Курат югары уку йортларында педагогик эшчәнлек алып барган, һәм аның методикасы, фәнни хезмәтләре бу илдә әле бүген дә кулланута. Галим башка дәүләттә гомер кичереп, андагы фәнне алга җибәрү өчен күп тырышлык куйса да, үзенең татар икәнлеген беркайчан да онытмаган.

БТК Башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров билгеләп үтүенчә, чит илләрдә төрле эшчәнлек алып барган милләттәшләребездән күбесенең исемнәре үз илебездә әле киң билгеле түгел. Шуңа күрә БТК Башкарма комитетының бу юнәлештәге эше даими төс алырга тиеш. Әгъдәс Куратның әсәрләре татар һәм рус телләренә әлегә кадәр тәрҗемә ителмәгән...

"Түгәрәк өстәл" утырышында БТК Башкарма комитеты әгъзалары, галимнәр Н.Хисамов, М. Госманов, М. Зәкиев, Д. Исхаков, И. Гыйләҗев, Ф. Шәрәфетдинов һ. б. зыялылар катнашты.

### ҖИРДӘ ЯШӘП ЭЗЕҢ КАЛДЫРСАҢ...

Шагыйрь, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Рәшит Шиһаповка быелның гыйнварында 65 яшь тулган иде. Каты авырудан соң шушы елның августында ул арабыздан китте. Лениногорск шәһәре хакимияте белән бергә шәһәр җәмәгатьчелеге 18 ноябрьдә шагыйрь истәлегенә багышлап бик матур истәлек кичәсе оештырдылар.

Рәшит Шиһапов Казан педагогия институтын тәмамлаганнан соң бу төбәктә балалар укыткан, беренче телевизион тапшыруларны эфирга чыгаруда башлап йөрүчеләрдән булган. Татарстан нефть ятмаларын үзләштерүгә үз өлешен керткән шәхес. Иҗат белән шөгыльләнергә дә вакыт таба: 9 шигырь китабы, ике дистәләп җыр авторы, шәһәр мәдәният йорты каршында оешкан драма түгәрәгенә нигез сала. Ул драма түгәрәге күптән инде халык театры исеменә лаек булды һәм аның дәвамлы җитәкчесе дә мәрхүм Рәшит Шиһапов иде.

Әдәби-музыкаль кичәдә шагыйрьнең шигырьләре укылды, аның сүзләренә язылган ул яраткан җырлар җырланды.

Шәһәр башлыклары кичәгә җыелган җәмәгатьчелеккә Лениногорск татар халык театрының шушы көннән башлап Рәшит Шиһапов исемен йөртәчәге турында хәбәр иттеләр.

### ЧЫНБАРЛЫККА ТУГРЫЛЫКЛЫ РӘССАМ

Татарстан Рәссамнар берлегенең күргәзмәләр залында Әнвәр Сәгыйтовның иҗатына 40 ел тулуга багышланган күргәзмә ачылды.

Ә. Сәгыйтовның эшләре Татарстан, Башкортстан музейларында, Истанбул һәм башка шәһәрләрнең картиналар галереяларында, шәхси һәм дәүләт коллекцияләрендә саклана. Рәссам төрле жанрларда иҗат итә, әмма өстенлекне лирик пейзаж темасына бирә. Ул танылган рәссам Николай Фешин традицияләрен дәвам итүче дә. Ә. Сәгыйтов иҗат иткән лирик пейзажларда—Истанбул, Татарстан, Башкортстан шәһәрләре һәм авыллары, Идел, Мишә елгалары күренешләрендә узган гасыр рәссамы йогынтысы сизелә.

### ФОТОЛАРДА КАЗАН ТАРИХЫ

"Казан гасырлар һәм 1000 еллыклар чигендә" сериясенең 5 нче чыгарылышы дөнья күрде.

Аның авторы—танылган журналист, коллекционер-филокартист, туган якны өйрәнүче Абдулла Дубин. Чыгарылыш борынгы Казан турындагы риваятьне дәвам итә. Аның "Идел борынгы открыткаларда", "Казан турында риваять", "Әстерхан. Гасырлар чигендә" кебек буклетлары, "1000 яшьлек Казан борынгы открыткаларда", "Борынгы Казан кош очкан югарылыктан" һәм башка фотоальбомнары тарих сөючеләргә яхшы таныш. Яна чыгарылышта башкалабызның истәлекле урыннары моннан 100 ел элек төшерелгән һәм хәзерге фотоларда чагылыш тапкан.

### ҖЫРЧЫ ДИРЕКТОР БУЛДЫ

"Россия Федерациясе Театр эшлеклеләре берлеге" Бөтенроссия иҗтимагый оешмасының республика бүлегендә үзгәрешләр булды: актерлар йортының яна директоры итеп Татарстанның халык артисты, М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрының әйдәп баручы солистларыннан берсе Сәет Рәенбәков билгеләнде.

Күпләр аны эшкуар һәм Татарстандагы "Себер" якташлык җәмгыятенең активисты буларак белә. Сәет Садыйк улы Театр эшлеклеләре берлеге рәисе урынбасары вазифасын да башкарачак.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Борынгы бабаларыбыз тормышыннан.
*Тышлыкның дүртенче битендә:* шагыйрь **Госман Садә**.

# ЯҢА КИТАПЛАР




**Равил Фәйзуллин. Мәхәббәтнамә: Мәхәббәт шигырьләре.** —Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. —400 бит. Тиражы—3000 данә.

Бу китапка Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллинның кырык елдан артык вакыт (1961—2003) дәвамында иҗат иткән мәхәббәт шигырьләре тупланган. Язылу вакытлары буенча хронологик тәртиптә урнаштырылган бу шигырьләр "Үсмерчак дәфтәреннән", "Солдат дәфтәреннән", "Әлмәт дәфтәреннән", "Гомер туе" дәфтәреннән, "Көзге күкрәү" дәфтәреннән, "Кыска шигырьләр" дәфтәреннән дигән бүлекләргә аерып бирелгән.

"Кемнәрнеңдер күңел тибрәнешләре—өзгәләнү-сагышлары, ярсу-янулары, өмет-хыяллары минеке белән күпмедер тәңгәл килә алса, укучыларым белән аңлашуга, ягъни аларның фикердәш, күңелдәш булуларына ышаныч бар... Шатлык һәм Бәхет һәркемгә тансык. Бер җырымда әйтелгәнчә, "җирдә күпме җаннар йөри, иясез шатлык булып!.." Бу шигырьләр кемгәдер ияле шатлык булырга булыша алса икән дигән теләктә калам,"— ди Равил Фәйзуллин үзенең "Янә Мәхәббәтнамә" дип исемләнгән кереш сүзендә. Шагыйрьнең теләкләре кабул булсын!

Китапның мөхәррире—Харрас Әюпов.





**Марсель Галиев. Арыслан йокысы.** — Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. —256 б. Тиражы—2000 данә.

Шагыйрь, прозаик Марсель Галиевнең бу китабына төрле елларда язылган көлкеле хикәяләре тупланган. Алар, нигездә, язучы халкы, сәнгать кешеләре тормышындагы мәзәк хәлләр турында. Автор көнкүрештәге гап-гади хәл-вакыйгалар фонында теге яки бу шәхеснең үзенчәлекле портрет-сурәтен тудыра алган. Җиңел, йөгерек тел белән иҗат ителгән бу бәләкәй хикәяләрдә халкыбызның мәзәккә, хикмәткә бай булуы, яшәүдән тәм таба белүе, зиһенле холкы чагыла. Көлү-елмаю аша кешеләрне ярату, яшәү мәгънәсен эзләү зур әдәбиятка, талантлы язучыларга хас сыйфат ул.

Китапның мөхәррире—Роза Заһидуллина.

Индекс 73210



Госман Садә

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)